ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2005



Фронтовик шагыйрьләр

# Әхмәт Исхак һәм Нур Баян

туууларына 100 ел



**Әхмәт Исхак**
*(1905-1991)*



**Нур Баян**
*(1905-1945)*

*Еллар арты еллар агалар...*
*Тормыш үзәгендә яңалар...*
*Соры Җәтер безнең үткәннәргә*
*Тугрылыкны саклыймы алар?*

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

5

(991)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир— 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге—43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
✆: **Факс** — (8432) 43-56-12.
🖳: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әдип МАЛИКОВ. Сугыш кичкән иргә таян. *Шигырьләр.* ........ 5
Мөҗип ИМАМОВ. Сугышның мәрхәмәтсез йөзе. *Фронт язмалары.* ........ 8
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Учак хакындагы кыйсса. *Шигырьләр.* ........ 53
Шамил МАННАПОВ. Янгыннан калган баганалар. *Хикәятләр.* ........ 56
Резеда ВӘЛИЕВА. Җиңү килгән көн. *Шигырьләр.* ........ 73
Флүс ЛАТЫЙФИ. Хикәя остасы. (Мәгъсум Хуҗинга 75 яшь). ........ 77
Мәгъсум ХУҖИН. Айның уты сүнгән. *Хикәя.* ........ 79
Әхмәт ГАДЕЛ. Саба җилләренә йөрәк ачам. *Шигырьләр.* ........ 86
Әхәт ГАФФАР. *Хикәяләр.* ........ 89

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА. Аклыктан яралдым. *Шигырьләр.* ........ 103
Айдар ҖАМАЛИЕВ. Күкләр сыяр микән күкрәккә? *Шигырьләр.* ........ 105

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әхәт МУШИНСКИЙ. “Авызың кыек булса...” ........ 107

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XV КОРЫЛТАЕН КАРШЫЛАП**

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Илһамлы хезмәт нәтиҗәләре. ........ 116

**ДИСКУССИЯ: “БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ”**

Рафаэль МОСТАФИН. Төгәл булыйк! ........ 121

**ҖИҢҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА**

Әлфия ШАМОВА. Газета битләрендә фронт сәхифәләре. ........ 137

**ТАРИХ**

Наил ТАИРОВ. Фабрикант Акчуриннар һәм татар әдәбияты. ........ 151

**ФӘН**

“Татар энциклопедиясе” битләреннән. ........ 132
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ........ 158

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Фәрит БӘШИР. Галиҗәнап шигырь—хәзрәти шагыйрь. ........ 163

Рифат СВЕРИГИН. Кеше үзе җавап бирә (Вакыйф Нуруллинга 70 яшь). ........ 168
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Күпкырлы иҗат иясе. ........ 173
Язучылар берлегенең яңа әгъзалары. ........ 175
Хатлардан юллар. ........ 176
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. “Заманыбыз тәрәккыят заманыдыр...” (Шакир Мөхәммәдевнең тууына 140 ел). ........ 180

**НУР БАЯН ҺӘМ ӘХМӘТ ИСХАКНЫҢ ТУУЛАРЫНА 100 ЕЛ**

Нур БАЯН. Өч бөркет. *Шигырь.* ........ 178
Әхмәт ИСХАК. Хакыйкать төсе. *Шигырь.* ........ 179

“Казан утлары” архивыннан. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": фронтовые заметки М. ИМАМОВА "Истинное лицо войны", рассказы Ш. МАННАПОВА, А. ГАФФАРА, М. ХУЗИНА (с предисловием Ф. ЛАТЫФИ); стихи А. МАЛИКОВА, Ф. ГАБДРАХИМА, А. АДЫЛЯ, Р. ВАЛИЕВОЙ.
"Творчество молодых": стихи И. ВАЛИУЛЛИНОЙ, А. ЗАМАЛИЕВА.
"Публицистика": статья А. МУШИНСКОГО "Не пеняй на зеркало..."; статья председателя Союза писателей РТ Ф. ГАЛИМУЛЛИНА посвящена к XV съезду писателей Татарстана.
Дискуссия: "Герой нашего времени": статья Р. МУСТАФИНА "Истина требует точности".
"Страницы из "Татарской энциклопедии".
"К 60-летию ВОВ": статья А. ШАМОВОЙ "Из страниц татарских фронтовых газет".
"История": статья Н. ТАИРОВА "Фабриканты Акчурины и татарская литература".
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"Книжное обозрение": рецензия Ф. БАШИРОВА на книгу Н. Акмала.
Статья Р. СВЕРИГИНА к 70-летию В. Нуруллина и Л. ХАМИДУЛЛИНА к 65-летию М. Шигапова.
"Наш календарь": статья А. ЗАКИРЗЯНОВА к 140-летию Ш. Мухамедова.
В номере так же отмечаются 100-летие Н. Баяна и А. Исхака.
Новые члены Союза писателей.
Строки из писем.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Парк Победы в г. Казани—фото Н. ИСМАГИЛОВА; драматург Р. САГДИ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": notes from war by M. IMAMOV "True face of war", stories by Sh. MANNAPOV, A. GAFFAR, M. HUZIN (with preface by F. LATYFI); poems by A. MALIKOV, F. GABDRAHIM, A. ADYL, R. VALIEVA.
"Creation of young people": poems by I. VALIULLINA, A. ZAMALIEV.
"Publicistics": article by A. MUSHINSKI "Don't offense at the mirror..."; article by chairman of Union of composers, writer F. GALIMULLIN devoted to the 15th conferention of writers of Tatarstan.
Discussion : "Hero of our time": article by R. MUSTAFIN "Truth demands exactitude".
"From pages of Tatar encyclopedia".
"To 60th anniversary of World War II": article by A. SHAMOVA "From pages of Tatar war newspapaers".
"History": article by N. TAIROV "Factory owners the Akchurins and Tatar literature".
"Science": A. TIMERGALIN "Dictionary of Nation".
"Book review": review by F. BASHIROV book N. Akmal.
Article by R. SVERIGIN to the 70th anniversary of V. Nurullin and article by L.HAMIDULLIN to the 65th anniversary of M.Shigapov.
"Our calendar": article by A.ZAKIRZYANOV to 140th anniversary of Sh.Muhamedov. In the number 100th anniversary of N.Bayan and A.Ishak is celebrated .
New names of Union of writers.
Lines drom letters.
From photoarchive of the magazine.
Dairy of public-cultiral life.
On our covers: "Victory Park in Kazan city", photo by N.ISMAGILIV; playwriter R.SAGDI.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.04.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7011. Заказ А-296.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



## Әдип Маликов

# СУГЫШ КИЧКӘН ИРГӘ ТАЯН...

### Сынатма, улым

**Китми йөрәгемнән сылу кызлар,
Тальян моңы...
Яшьләр бию...
Әткәемнең мине озатканда:
"Хуш, сынатма, улым"—дию.**

**"Сынатма, улым..."
Юеш окопларда
Догам булды шушы сүзләре.
Кузгалганда канлы атакага
Озата барды әткәм күзләре.**

*1945.*

### Ил язмышы—ир язмышы

**Ул игенче иде.
Кырда үсте,
Җырлар җырлап иркен сулышка.
Арышлары белән саубуллашып,
Китеп барды канлы сугышка.**

**Бер гомергә торыр "хезмәт көне"н
Фриц башы белән исәпләп,
Кыр патшасы—пехотачы бүген
Азат итә җирен кисәкләп.**

---

Әдип МАЛИКОВ (1921) — *шагыйрь, прозаик; Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны. Күпсанлы китаплар (лирика, поэмалар, балалар өчен шигырь-әкиятләр, повестьлар, истәлекләр) авторы. Әлмәттә яши.*

Күтәрмәсә бергә ил язмышын,
Ир булуда мәгънә бармы соң?!
Алып кайтыр егет иңнәрендә
Җиңү иртәсенең нурлысын!

*1942.*

## Окопташлар каны тибә миндә

Тормыш миңа аек хәтер биргән
Үткәннәргә кире кайтырга.
Чигенүләр, югалтулар аша
Шул үткәннәр алга чакыра.

Окопташлар каны тибә миндә,
Адресларын йөртәм күңелдә.
Алар, тынычлыкка юллар салып,
Зур һөҗүмгә бара бүген дә!

Иреннәре көеп кысылса да,
Дәшә дуслар еллар аркылы:
—Туфрак аша тойсын табаныгыз
Җиргә күчкән йөрәк ялкынын!

Чын дусларны вакыт үзе сайлый,
Дуслык булсын утка чыдарлык;
Туган җиргә булган мәхәббәтне
Үлем аша алып чыгарлык!

Үткәннәрем баскан таш кыядай,
Алар миңа:
—Чигенү юк!—диләр.
Заманалар безнең җилкәләргә
Бурычларның кыенын йөклиләр!

*1961.*

## Тормыш кичкән иргә таян

Тормыш кичкән иргә таян!—
Өстен торыр ваклыклардан,
Мәхрүм итмәс шатлыклардан.
Гаебең күреп сүксә-сүгәр,
Яратып бер сукса-сугар,
Яманнардан әмма яклар,
Һәлакәттән сине саклар.

Сугыш кичкән иргә таян!
Ул тубыктан кан эчендә
Җиңеп барган бар көченә.
Гаделлекне яклап барган,—
Шул канында аның калган.
Үзен илгә багышлаган,—
Шуның белән ялгышмаган.

Таян
иле белән бергә
Үлем аша узган иргә!

*1978.*

***

Ул дуслык окопта туганмы,
Походта, җырдамы?—онтылган.
Солдатлар дуслыгы кайчакта
Башлана бер бөртек шырпыдан.
Учыңа яшереп җилләрдән,
Сызасың кадерләп соңгысын.
Тайгада кабынган учакның
Тоям мин хәзер дә җылысын.

*1978.*

## Бер уч туфрак

Бер уч туфрак.
Салмак, көлсу туфрак,
Металл, сөяк оны аралаш,
Шул туфракны кысып йөрәгемә,
Уйга талып тордым яланбаш.

Бер уч туфрак...
Күктә тузан булып,
Очкандыр ул бомба яуганда.
Аңа батырларның ирене тигән,
Үлем кочагына ауганда.

Бер уч туфрак...
Малах курганыннан,
Гөлләр үсеп чыккан тутәлдән.
Чакрымнарга төшәр газап йөген
Шушы бер уч туфрак күтәргән!

*1961.*

## Унбер каска

Тарих узган урыннарга
Еллар аша килдем кабат.
Бер аланда—унбер каска,
Йоклый монда унбер солдат.

Сез, туганнар, кайсы яктан?
Кыен хәзер барлавы да.
Иңнәренә кайгы салып,
Тайга тора каравылда.

Бормаланып-бормаланып,
Таудан төшә йөгерек сукмак.
Текә ярга җиткән сыман,
Кинәт монда кала туктап.

Кабер түгел, гүя окоп...
Алар менә калкынырлар,—
Бер көйрәтик, полкташ, дип,
Яннарына чакырырлар...

Металл тирли, елый белә,—
Каскаларда көмеш чыклар.
Пуля кергән тишекләрдән
Кыяк үлән үсеп чыккан.

Каскаларны музейларга
Күчерергә кыймаганнар.
Йолдызларын яныл торган
Кызыл төскә буяганнар.

Кабер түгел, җир ярасы...
Җөйләнсә дә ул яралар,
Дөньядагы хәлне күреп,
Кызаралар, яңаралар.

*1968.*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Мөҗип Имамов

# СУГЫШНЫҢ МӘРХӘМӘТСЕЗ ЙӨЗЕ

### ФРОНТ ЯЗМАЛАРЫ

*Мөҗип Рамазан улы ИМАМОВ 1925 елны Башкортстанның Миякә районы, Канбәк авылында туган. 1943 елны армиягә алына. Сержант дәрәҗәсендә, артиллерист буларак, сугышларда Белоруссияне, Польшаны азат итүдә, Көнчыгыш Пруссияне, Берлинны алуда катнаша. Сугыштан соң да 1950 елга кадәр армиядә хезмәт итә.*

*Мәскәүдә М. Ломоносов исемендәге университетның философия факультетында белем ала. Илленче елларда Миякә районында—газет редакторы, КПСС партия райкомында эшли. 1962 елдан—Салават шәһәрендә Уфа нефть институты филиалының уку-укыту мөдире, философия фәннәре кандидаты, доцент. Хәзер пенсиядә.*

### Кереш

Бу язмаларымның башланып китүенә, чираттагы Җиңү бәйрәме көннәренең берсендә бер авылдашымның: “Мөҗип абый, нишләп сез, башкалар кебек, үзегезнең армиядәге хезмәтегез, фронтта кем булып, кайда, ничек сугышканыгыз турында бер дә сөйләгәнегез юк?”, дигән соравына, шаярып кына: “Чират җитмәде бит әле, туган, мин ул турыда сөйләп тормамдыр инде, язармын гына”,—дигән җавабым сәбәпче булды. Уйламастан гына әйтелгән бу сүз күңелгә керде дә күпмедер вакыттан җиңә алмаслык таләпкә дә әйләнде.

Сүз дә юк, Ватан сугышы турында күп язылган, тагын да күбрәк сөйләнелгән. Әмма ки, аның турында ни кадәре генә язма, сөйләмә, ул бетәрлек түгел. Андагы вакыйгаларның күплеге, анда койган каныбыз, халыкка китергән югалтулары, кайгы-хәсрәтләре чиксез—үзе бер океан. Кемнәрнеңдер анда йөзәселәре килә икән, илаһи—чум да йөз, һәркемгә дә урыны да, хикәяләргә материаллары да җитәрлек. Аннары һәрбер фронтовикның, сугышка үз карашы, үз фикере, үз күзаллавы да бар бит әле. Армия, фронт генераллары биеклегеннән ул бер төрле күренсә, полк, батальон, рота командирларына ул икенче төрле күренгәндер. Ә инде ургылып торган дошман утына каршы, аның солдаты белән күзгә-күз, якадан-якага килеп, улмы—мине, минме аны, дип алышырга күтәрелгән окоп солдатларына ул үзенең бөтен ыржаеп торган кара йөзе белән килеп баса. Шуңа күрә аларның барысы да игътибарга лаек; барысы да тормышчан, барысын бергә җыйганда гына сугышның катлаулы авыр сәхифәләрен,

бер өлешен дә игътибарсыз калдырмыйча, мөмкин кадәр тулы, эчтәлекле итеп тасвирларга мөмкинлек туа.

Пехотачылар, артиллеристлар, очучылар турында күп язылган, ә менә безнең фронттагы профессиябез—фото-, топо-, звукоразведчиклар турында язмалар юк кына түгел, күпләр аларның барлыклары турында белмиләр дә. Ә аларсыз, беренче чиратта, “Сугыш алласы” артиллеристлары күзсез дә, колаксыз да булыр иде. Минем бу язмаларымны да, бернинди гомумиләштерүгә дә дәгъва итмәгән, сугышны, фәкать аның да әле үзенчәлекле хәрби һөнәргә ия булган аерым бер солдат позициясеннән тасвирлауга нигезләнгән истәлекләр генә, дип кабул итәрсез.

## Менә нинди икән ул сугыш...

Мин сугышны, фронтны, аның алгы позицияләрендәге күренешләрен—туп атуларын, ядрә шартлауларын, пулеметларның тыкылдап торуларын—күңелемнән, барысын бергә җыеп, үзем анда барып сугышларда катнаша башлаганчы, укыган китап, караган кинолар, аз булса да үземнең тормыш, табигать күренешләреннән дә туплаган тәҗрибәмнән чыгып, башлыча җәйнең яшенле-яңгырлы көннәрендәге, өйләрнең тәрәзә-ишекләрен дер-дер селкетә-селкетә, берсенең кайтавазлары әле офык артларына китеп югалып, тынып та бетмәстән, икенчесе, өченчесе, тагы да көчлерәкләре, туктаусыз гөлдер-гөлдер килеп, берсе артыннан берсе, куыша-куыша кабатланып торган күк күкрәүләре, яшен атуларына охшатып күз алдына китерә идем.

Ул чынлап та шулай була да кебек. Һәрхәлдә армия, фронт гаскәрләренең зур күләмле, киң колачлы, һөҗүмгә күчәр алдыннан йөзләгән, меңләгән туплар белән дошман позицияләрен (күп вакытта алар ике яклы да булалар) сәгатьләр буена утка тоту вакытларында шуңа охшап кала. Бу очракларда тирә-як, җир белән күк, ас белән өс бергә кушылып, тоташ гөрселдәп, янып, кайнап, гүләп торган гарасатка әйләнә. Туплар атуы, ядрәләр шартлавыннан, газ төтеннәреннән дөнья караңгылана, кояш нурлары сүрелеп, күренеше, кыяфәте белән кояшның тотылган вакытларын хәтерләтә башлый. Тын алулары авырая, күзләр әчешеп яшьләнә. Чикле бер урында туктаусыз туп атулары, ядрә шартлауларыннан тетрәп, биеп торган җир тора-бара сине дә үзе белән бергә селкетә, тетрәтә башлый. Тешләр, яңак сөякләре көзән җыергандагы кебек кысылалар, кул бармаклары йодрыклана, җаныңны, тәнеңне күкрәк авызы янында йомарланып калган төен кебек кенә хис итә башлыйсың.

Ә кайчакларда, киресенчә, ул бик күренеп, сиздереп тә бармый. Җиргә сылашып, көтмәгәндә хассынган корбанына ташланырга җыенган ерткыч кебек тынып та кала.

Безнең башлап фронтка килеп керүебез менә шушы соңгы искә алган, чагыштырмача тыныч вакытка туры килде. Бәлки без аның монда, якында гына икәнлеген һаман да әллә абайламыйча барган булыр идек, алга карап баручыларыбызның колонна буйлап: “воздух!” дигән сигнал тавышы сискәндереп җибәреп, үзебезнең кайда икәнлегебезне искә төшермәсә.

Мондый очракларда ни эшләргә кирәклеген хәрби мәктәпләрдә, аннан соңгы хезмәт вакытларында да үзләштергәнлектән, без, колоннабызның туктап калуын көтеп тормастан, туптай атылышып машиналарыбыздан сикерешеп төштек тә, кайда нинди качар-посар урын бар, андыйлары булмаганда “җир-ана” кочагына сыенып, шәхси коралларыбыз белән булса да дошман һөҗүмен каршы алырга әзерләнә башладык.

Дивизион, батарея, взвод командирлары да һәркайсысы үз урынында. Тавышланмыйча (тавышлансалар, күрәсең, “тегеләкларның да” ишетүләре ихтимал, дип уйлаганнардыр), сержант-солдатларга үзләренең приказларын теш араларыннан гына кысып чыгарып, йодрыклары белән янап алырга да онытмыйча, йөгерешә-йөгерешә урнашып беттеләр. Дивизион командиры таягы белән төрткәләп күрсәтеп (ул бу таягын сугыш беткәнче ташламаячак) машиналарны кайда куярга, техниканы ничегрәк яшерергә кирәге турында күрсәтмәләр ясаудан туктамый. Командирлар кабаландыралар, ачулары килгәндә сүзләрен дә эзләнеп-сайланып тормыйлар, сүгенеп тә җибәрәләр.

Билгеле, без үзебез дә мондый хәлдә катып калганнардан түгел—тик тормыйбыз. Аңлыйбыз: самолетларның очу тизлекләре пуля, ядрәнеке кебек үк тиз булмаса да, көттереп тормаячаклар, дип уйларга да өлгермибез, самолет үзе дә күренде—бездән

берничә километрларга алдарак, шактый биектә разведчик самолет—“рама” иде ул. Аның шундый җәһәннәм биеклегендә бер үзенең әкрен генә очуы ачуыбызны гына китерде. Безнең якка үтеп тә бетми, ул янында берничә зенит снарядының төтен тарата-тарата шартлаулары була, ул да үз якларына чыгып югала.

Моңарчы берме, икеме мәртәбә фронтта булып, анда алган яраларын яматып-төзәтеп, безнең белән яңадан фронтка кайтучы карт солдат Ожогин безнең гайрәтләнеп, кабарынып китүебезне ошатмыйча, әллә үзенең берникадәр “шүрләп” китүен, безгә, яшь солдатларга, күрсәтмәскә тырышуыннанмы: “монысы әле аның чәчәге, җимешләрен алдарак күрерсез, башкалары килеп чыккач”, дип безне ачулана, әрли. Бу хәл 1944 елның июнь аенда булып, сугыш барышында хәлләр нигезеннән үзгәргән, саннары, сыйфат яклары белән дә безнең самолетларыбыз өстенлек итә иде инде.

Безнең артиллерия инструменталь разведка солдатларының фронтта үтисе хәрби бурычлары үзенчәлекле булу сәбәпле—синең яныңда командирларың да, иптәшләрең дә юк, булганда да берән-сәрән, үзеңне, техниканы саклау үз өстеңдә, үз бурычыңа, үз карамагыңа күчә.

Сугыш шартларында, ике яклы туп атышлары асларында калганда да (ә ул безнең эштә даими булачак) куркынычның кай яктан килгәнлеген—минамы ул, туп ядрәсеме—кайда бара, алдарак, арттарак, уңдарак яки сулдамы, җитепме, үтеп китепме төшәчәк икәнлекләрен, колакларыңны торгызып, сагаеп тыңлап тормастан, интуитив рәвештә белергә, сизәргә, үз вакытында дөрес нәтиҗә ясарга өйрәтә.

Бу җәһәттән шунысы да игътибарга лаек. Айлар, еллар буе шушындый шартларда йөри, эшли торгач, син үзеңнең бербөтенлегеңне онытып, үзеңне параллель рәвештә ике кешегә аерылган кебек хис итә башлыйсың. Берсе аның матди булып, автоматик рәвештә синең физик вазифаларыңны тормышка ашыру белән мәшгуль булса, икенчесе рухи булып, нинди очракларда ничегрәк эш итәргә кирәклекләре турында сине искәртеп, сине саклап йөрүче көч—фәрештәгә әверелә иде кебек.

Билгеле, болар барысы да эчке тойгы, кичерешләр нәтиҗәсендә туып, үсеп формалашсалар да, аларның төп чыганаклары сугышның реаль сәхифәләренә нигезләнеп туа иде.

Сугыш кырында гомерең, исәнлегең өчен курку, шикләнү хисләре синең көндәлек юлдашың булсалар да, алар турындагы уйлар күңелеңнең төбенәрәк күчеп, беренче урында һәрвакытта да хәрби вазифаларыңны тиз арада, җиренә җиткереп тормышка ашыру теләге була.

Отбой булу белән без фронттагы билисе урыныбызга ашыктык. Анда безне тупчыларыбыз көтә иде. Болай да инде алар, бездән айга якын алдан килеп, Белоруссияне азат итү өчен барган “Багратион”—дип аталган һөҗүм сугышларында катнашып, югалтулар да кичереп, кайберләре күрсәткән батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнергә дә өлгергәннәр иде.

Тревога булган урыныбыздан әлләни еракка китмибез (ярты сәгатьтән дә артык бармаганбыздыр) фронтның алгы позицияләренә 2-3 километрлар кала зур булмаган, шулай да куе гына урман кырында гомум колоннабыздан аерылып туктап калабыз да, алгы сызыкка барырга әмер алабыз.

Солдатка ни-нәрсә, ул—закон-приказ. Була ул, ди дә, йөгерә-йөгерә аны үтәргә керешә. Безнең дә батареябызның барлык звеноларында—взвод, отделение, постларда эшлекле ыгы-зыгы башлана. Һәркем үзенә беркетелгән техникасын, элемтә коралларын машиналардан бушата, карый, барлый, алай-болай уралып-чорналып онытылып калмасын, дип тырыша.

Фронтта урнашкан “тынлыкны” файдаланып калу да безгә зарури иде. Ул гел генә шулай тынып тормаячак. Аның әлеге тынлыгы да шул читтән караганда гына. Гомумән, фронтта тынлык дигән нәрсә ул тышкы күренеш кенә.

Әлбәттә, кабаланабыз, ашыгабыз. Фронт җитезлекне ярата. Комбатыбыз килеп туктау белән, взвод, отделение командирларын, пост начальникларын үз янына җыеп алды да, барысы да карталарын җәеп салып, алдагы сызыкта билисе урын, постларның координатларын, җиренең ниндирәк икәнлекләрен аныкладылар. Безнең эш өчен аның соңгысы мөһим. Тавыш алгычларыбыз ачыграк та, берникадәре калкурак та урында булырга тиеш, туп, миномет атулары, ядрә, мина шартлау тавышлары сугылырдай урыннарда булу кирәк. Шулай булмаса, ул тавышларны “ишетми” калуың да ихтимал.

Җәһәтләп эшкә тотындык. Берәүләребез землянка казырга, икенчеләребез аны ябу өчен агач кисәргә кереште. Станция—безнең төп сугыш коралыбыз. Аның сафтан чыгуы безнең бөтен батареябызның сафтан чыгуына тиң. Шуңа күрә дә аны саклау безнең төп бурычларыбызның берсе иде.

Әзерлек эшләрен бетерүебезгә без барасы урынны карап кайтырга киткән иптәшләребез килеп җиттеләр. Аларны әзерләнеп көтеп торган солдатлар, звукоприемникларны, телефон аппаратларын, башка кирәк-яракларын күтәрделәр дә, җиде постның, җиде группасы да алгы сызык ягына урман аша, элемтә чыбыкларын суза-суза передовойга, эш урыннарына юнәлделәр. Аякларыгыз җиңел, эшләрегез уң булсын, егетләр, диешеп озатып калдык иптәшләребезне.

Ләкин… Күрәсең, йөкләр күтәргәч егетләрнең аяклары авыраеп киткәндер, эш урыннарына барып җитмәстән, кисәтү пунктыннан Иваново өлкәсе егете Евремов, пехота минасына басып аяк үкчәсен өздерә. Әйе, сугыш шулай, аның барлыгы һөҗүм, чигенү, җиңү, җиңелү генә түгел. Иң элек ул—кеше язмышы. Үләме ул анда, каламы, үлсә ничек тә, калса ничек? Саумы, исәнме, җәрәхәтләнеп беткәнме? Кемнеңдер язмышы сугышның тәүге көнендә (безнең очрактагы кебек), беренче мылтык атуы, граната, беренче туп ядрәсе, мина шартлавы белән хәл ителсә, кемнеңдер, еллар буе ничәмә ничә фронтларда, канкойгыч сугышларда булып, аның бөтен авырлыкларын үтеп-кичеп, дошманны җиңеп, сугыш менә-менә бетә инде дигән көннәрдә хәл ителә.

Ефремовны санчастька озатканда кайбер солдатларыбыз мондый язмышның үзләре белән дә булуы ихтималын күз алдына китерепмедер, әллә аны җәлләп, әллә аның шулай тиз тылга китүенә, җиңел генә сугыштан котылуына (каян беләсең) көнләшепмедер, "отвоевался солдат", диешеп озатып калдылар. Чынлап та, сугыш аның өчен башланып та җитмәстән бетеп тә куйды шул.

Безнең бу беренче югалтуыбыз булса да, билгеле, аның соңгысы түгел иде. Берлинга кадәр ай-һай күпме юллар үтәсе дә, күпме сугышларда катнашасы бар иде әле. Көтмәгәндә килеп чыккан бу югалтуыбыз шаукымыннан туган күңелсез уйларыбыздан безне постларыбыздан килә башлаган сигналлар айнытып җибәрде. Аларның эшкә әзерлекләре турындагы докладлар килеп бетү белән, комбатыбыз ПП начальнигы сержант Табоховка: "Давай-ка, сержант, контрольный запуск, проверим, как посты работают, заодно послушаем, что там у вас на передовой",—дип команда бирде. Менә, станциябез беренче мәртәбә фронт, сугыш шартларында эштә. Бөтенебез тасмадагы язмаларны карарга ябырылыштык. Беренче күзгә бәрелгән, башка килгән уй: чыннан да монда гына тыныч кебек икән. Көчле, калын шартлау тавышы язмалары хәзергә ишетелмәсә дә, вак-төякләренең күплеге… Нинди генә тавышлар юк монда. Күпләре белән безнең беренче мәртәбә очрашуыбыз. Хәрби уку мәктәбендә, полигоннардагы күнегү вакытларында да мондый күп төрле, куе, берсенә-берсенә бәрелә-сугыла барган язмалар белән эшләргә күнекмәгәнбез, боларның "кемнең-кем" икәнлекләрен дөрес итеп танып аларны аралый, араларыннан кирәкләрен таба белергә, "укып" бирергә өйрәнергә тиешлебез.

Шулай мәж килеп, югалту кичереп, эшкә әзерләнеп бетүебезгә безнең фронттагы тәүге көнебез үтте. Төнлә бөтен фронт сызыгы өстендә, еш булмаса да, яктырткыч пуля, ракета утлары уйный башлады. Аларны күрү, күзәтү безгә кызыклы да, гаҗәп тә, шул ук вакытта борчылулы да иде. Кайда очалар да, кайда төшәләр? Юк, юк та, хәзергә бездән читтәрәк мина, туп атулары, ядрә шартлау тавышлары да ишетелгәли. Без дә "менә-менә" диешеп көтәбез. Көтсәк тә, барыбер кинәт кебек булып чыкты. Станциябез эшли башлап, секундлар да үтми, безнең торган позициябездән хәтсез арттa—тупчыларыбыз тирәсендә снаряд шартлавы ишетелде.

Бик каты бәрелмәсә дә, бу тавыш безгә таныш. Укыган вакытта мондый язмалар белән эш иткәнебез бар иде. Постларыбызның барысының да язмалары ачык, димәк, тавыш алгычлар әйбәт урнашканнар. Комбат, взвод командирлары, алар белән бергә без дә тасмадагы язуларны "укырга" керештек. Берничә минуттан, мин бөтен мәгълүматны эшкәртеп, планшетта эшләүче иптәшем сержант Ильницкийга тапшырдым. Координатларны комбат аннан алган тупчыларга тапшыра. Тыныбызны кысып, аларның җавап биргәннәрен көтә башлыйбыз. Түземсезләнеп көткәнгәдер, минутлары сәгатькә тиң кебек тоела. Һәм менә, һава шартлатып, безнең снарядлар очкан тавышлар ишетелә. Комбат тагын трубкадан Табоховка: "Үзебезнекен не прозевай",—дип кычкыра. Юк, молодцы! Хәзер үзебезнең снаряд ярылу тавышларын

планшетка төшерәбез, снарядыбыз дошман позициясен бераз үтебрәк, сулга төшкән, икенче снаряд, өченчесе… зур булмаган төгәлсезлек белән… Берничә минуттан бөтен батарея залпы төгәл, дошман өстенә. "Получай, враг, и нашу долю!"—диешәбез, канәгатьләнеп.

Шулай итеп тупчыларыбыз безне үзләренең ышанычлы ярдәмчеләре иттеләр. Димәк, без дә сугышчан сынау үттек.

Ләкин без бу урында озак тукталып тормадык. Без "Багратион" планының төп өлеше тормышка ашырылып, аның икенче өлеше башланган—Белоруссияне тулысы белән немец-фашист оккупантларыннан азат итеп, үзебезнең 1941 елга кадәр булган ил чигенә чыгу өчен барган һөҗүм сугышларының иң кызган вакытына туры килгәнбез икән.

Бу сугышларда дошман гаскәрләре, Витебск, Орша, Могилев, Бобруйск шәһәрләре тирәләрендә камалышта калып, безнең көчләр тарафыннан каты тукмалып, күп санлы коралы көчләрен югалтып, йөзләгән мең солдатларын әсирлектә калдырып чигенергә мәҗбүр булсалар да, алар әле бөтенләе белән тар-мар ителмәгән, безнең көчләргә ныклы каршылык күрсәтүләрен дәвам итәләр, юк-юк та, контратакага да күчәләр иде.

Көн саен булмаса да, һәрхәлдә, еш кына без дә позицияләребезне алыштыра барабыз. Кайбер көннәрне ныклап урнашып эшкә керешергә дә өлгерә алмыйбыз—яңа урынга. Дошман гаскәрләре биләгән позицияләрен, көндез тотып тора алсалар да, төннәрен калдырып китәргә мәҗбүр булалар иде.

Без фронттагы тәүге көннәребездә, немецларның мондый туктаусыз чигенә баруларын табигый, киләчәктә дә шулай булырга тиеш кебек итеп карый башлаган идек, озакламый монысы безнең "малайлык фикерләүләребез"нең нәтиҗәләре генә икәнлеген аңладык. Алга барган саен дошманның каршылыгы артканнан арта, кайбер көннәребез туктаусыз туп атулар, ядрә шартлаулар астында үтә башлады. Болар, билгеле, барысы да, әкренләп булса да дошманның хәрби көчләрен туплавы турында сөйли иде. Бу үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак, безнең эшләребез дә артканнан арта, катлаулана, бигрәк тә постларда эшләүче иптәшләребезнеке. Йә бер пост белән элемтә өзелә, йә икенчесе белән, еш кына берничәсенеке берүк вакытта сафтан чыга. Аларны ремонтлау өчен постлардан үзәк станциягә, үзәк станциядән постларга, солдатларыбыз соса шүреләре кебек, тегендә-монда, монда-тегендә йөгереп кенә тора. Барысы да дошман уты астында.

Фронт ул—тере организм. Анда да кешеләр яши. Аларны өзлексез азык, корал, башка сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итәргә кирәк. Позициядәге частьлар да бер урында гына тукталып тынып тормыйлар, өзлексез хәрәкәттәләр. Фронтның бер участогыннан икенчесенә—оборона өчен йомшакланган участокларны ныгыту, йә булмаса һөҗүмгә күчәргә билгеләнгән частьларны көчәйтү, тулыландыру өчен китерәләр.

Аларның юлдашлары буларак—машиналар, танклар, самоходкалар, авыр тупларны тартып йөрүче тягачлар, хәтта ат җигелгәннәре дә туктап тормый. Барысы да безнең линияләребезнең төзеклегенә куркыныч тудыра. Кайберләре аларны өзү белән генә чикләнмичә, тәгәрмәчләренә уратып, кисәкләре белән сөйрәтеп алып китәләр. Юллар аша чыгарырга кирәк булганда, транспорт зыян китермәсен өчен, аларны юл өсләренә күтәреп куябыз. Моның өчен мөмкинлек булмаганда, җирне казып аларны күмеп куярга да туры килә торган иде. Сазлыклы, артык дымлы урыннарда да шул ук хәл. Сугыш барышының көчәюе элемтәчеләребезнең генә түгел, безнең үзәк станциядәгеләрнең дә эшләрен катлауландыра. Туп атышлары көчәйгән саен, тасмадагы тавыш язмалары да куерганнан-куера бара. Араларыннан кайсыларының кайдан икәнлекләрен табу өчен күзләреңне чекрәйтеп, керфекләреңкибеп, күрмәстәй хәлгә җиткәнче эзләнәсең, чокынасың. Барысын да хәзер үк, тиз табарга, координатларын тупчыларга тапшырырга кирәк. Ләкин чынбарлыкта моның өчен никадәр генә тырышма, барыбер син аларның барысын да бер үк вакытта тотып, табып, әзерләп бирә бетерә алмыйсың. Булыша торгач, алар арасында да мөһимрәкләре күренә башлый. Кайсысыдыр әле аның хәзергә сиңа әлләни зыян китерми. Алары хәзергә көтебрәк торырга да мөмкин. Икенчеләре исә, фәкать синең позицияңне, барасы, йөрисе урыннарыңны утка тота. Иң элек шушындыйларның язмаларын табып, координатларын тупчыларга бирергә тырышасың. Аеруча

тупчыларыбызның үз позицияләрен дошман белеп алып, аларның үзләрен утка тота башласа. Бу очракларда безнең эшләргә тупчыларыбыз тарафыннан таләпчәнлек кискен арта. "Һәркемнең үз күлмәге үзенә" принцибы монда да беренче урында. Тырыша торгач, аларның координатларын табып бирәсең. Яңалары, әлегә сиңа таныш булмаганнары монда гына икән. Янә эзләнергә тотынасың. Көннәр, төннәр, атна, айлар буе алга барган, позицияләрне алыштырган саен, барысы да яңадан кабатлана. Элегрәк табылганнарын да контрольдән ычкындырырга ярамый. "Яңадан эшли" башлаулары ихтимал. Тавышлары чыктымы, таныш тавыш, кабаттан эзләнеп тормастан, исәнлекләре турында тупчыларга хәбәр итәсең.

Гомумән, мондый кара-каршылыклы атыш-сугыш барышында безнең эшләребезгә таләпчәнлек арта гына. Бу дөрес тә, без аны аңлыйбыз. Тыныч чактагы "кыска вакыт", "аз ара", "вак-төяк" дигән нәрсәләр монда үзләренең капма-каршылыкларына әйләнәләр. Мондый чакта синең хәрәкәтеңнең һәрбер секунды, һәрбер адымы, мизгеле синең исәнлегең, булуың-булмавың, гомерең белән бәяләнә. Өлгердеңме—син дошманны, соңладыңмы—ул сине.

Шулай, сугышның хәтсез генә авыр хәлләрендә калып йөри торгач, фронтка килеп керүебезгә айга якын вакыт та үтеп киткән. Хәзер инде без тәүге көннәрдәге, кайдадыр очкан туп ядрәләре, мина шартлаулары тавышларына игътибар итеп, һәрбер сызгырган пуляга "баш иеп, сәлам биреп" йөрүче "яшел" малайлардан түгел. Сугыш утларында какланып җитмәсәк тә, ару гына кыздырылган, чыныккан солдатлар булып килә идек инде.

Бу бер ай вакыт эчендә безнең эш нәтиҗәләребезне, биргән координатларыбыз дошманның биләгән позицияләренә туры килгәннәрме-юкмы икәнлекләрен дә берничә мәртәбә тикшерергә өлгергәннәр иде инде. Дәгъвалар булмады. Димәк, безнең эш канәгатьләндерә, нәтиҗәләре ышандыра, киләчәктә тагы да яхшырак, тырышыбрак эшләргә дәрт, теләк тудыра иде.

1944 ел, июнь азаклары, 1939 елны СССР-Польша чигенә якынлашып киләбез. Анда якынлашкан саен сугыш тагы да катылана, дошманның каршылык күрсәтүе күзгә күренеп арта, көчәя.

Дошманның чигенүләре сирәк, берничә көн каты сугышлардан соң гына, анда да чикле урыннарда гына.

Бара торгач 1939 елгы СССР-Польша чигенә дә килеп җитәбез. Алда зур тимер юл станциясе—Барановичи. Ул фашист гаскәрләренең стратегик яктан соңгы терәк пункты. Монда аның өчен каты сугышлар булачагы күренеп тора. Аны штурмлауга күчәр алдыннан, без берничә көнгә тукталып калабыз. Алгы сызыкларга яңа көчләр килә. Күпчелек пехотачылар булса да, техника да артканнан-арта. Аларның килгәнлекләрен безнекеләр бик яшереп тә тормыйлар булса кирәк. Бәлкем, үзенә күрә монысы аның "психик атака" да булгандыр. Дошман күрсен, белсен үзен ни көткәнлеген!

Ә безнең тупчыларыбыз, һәр вакыттагы кебек, килү белән Барановичи алдындагы дошман ныгытмаларын эшкәртергә дә тотындылар. Без аларның атыш барышларын тыңлап, координатларын төзәтәбез. Барановичи тирәләренә дошманга нинди өстәмә көчләр килә, килсә, нindиләре, кайда урнаша икәнлекләрен күзәтеп, "капшап" торабыз. Яңа көчләрнең тавышлары чыктымы, координатларын шундук тупчыларыбызга тапшырабыз.

Менә, ахрысы, штурмга әзерлек бетте булса кирәк. Июль башы көннәренең берсендә алгы сызыкта шомлы тынлык урнашты. Монысы инде аның хәзер безгә билгеле—һөҗүм алды тынлыгы. Чыннан да таң алды яктысы белән, көчле артподготовка башланды. Санаулы минутларда Барановичиның бөтен тирә-ягы утлы өермәгә әйләнде. Безнең мондый көчле артподготовкада беренче мәртәбә катнашуыбыз. Моңарчы без чыннан да, карт солдат Ожогин әйтмешли, сугышның "чәчәкләрен" генә күреп йөргәнбез икән. Менә кайда, ничек була икән аның чын җимешләре! Тәүлек буена барган туктаусыз каты һөҗүм сугышларыннан соң, Барановичи фашистлардан азат ителде.

Без шәһәрдә. Аның җимерелеп беткәнлеге турында сөйләп торасы да юк. Мондый күренешләргә без күнегеп бара идек булса кирәк. Һәрбер үткән авыл урыны белән генә диярлек билгеле, сөрәеп калган мич торбаларыннан башка нәрсә юк. Барановичида иң истә калганы—Белоруссиянең күл, сазлыклары суларын эчеп

йөргәннән соң беренче мәртәбә туйганчы тап-таза, салкын артезиан коесы суы эчүебез.

Безнең бригадабыз, Барановичины штурмлау вакытларында, аның нәкъ үзәгендә булып, анда күрсәткән батырлыклары өчен Верховный главнокомандующийның приказы белән "Барановичи" исеме алып, "Богдан Хмельницкий" ордены белән бүләкләнде. Тупчыларыбызны да онытмаганнар. Алар белән беррәттән безнең разведдивизионның хәтсез генә солдат, сержант, офицерлары да, шулар арасыннан комбатыбыз өлкән лейтенант Васильев та орден белән бүләкләнде.

Тик шунысы, бу сугышларда югалтуларыбыз да булды. Штурмга әзерлек барган көннәрнең берсендә, дүртенче пост начальнигы өлкән сержант Волков югалды.

Ул көнне немец минометчылары дүртенче пост юлын көн буена утка тоттылар. Посттагыларыбыз өзелгән линияләрне төзәтеп кайталар, күп тә үтми, тагы өзәләр, тагы юлга... Инде солдатларның һәркайсысы берничә мәртәбә йөреп, арып кайткач, төнгә каршы, чираттагы өзелүдә пост начальнигы үзе юлга чыга. Озакламый пост эшли башлый. Ләкин Волков үзе постка кайтмый, үзәк станциягә дә барып җитми. Посттагы иптәшләре, линияне төзәтеп, кире кайтырлык вакыт үткәннән соң, берникадәр көтәләр дә, шалтыратып, аның үзәк станциядә дә юклыгын белгәч, бер-бер хәл булгандыр дип, постта бер дежурный калдырып, командирларын эзләргә чыгып китәләр. Линия буйлап, гел шул бер өзелә торган урынга килеп җиткәч, кабель берникадәре урман ягына борыла, ләкин тирә-якта бер кем дә юк. Кычкырып та карыйлар, тавыш биргән кеше булмый.

Эзләнә торгач, ерак та түгел урман кырында ташландык бер землянкага тап булалар. Керсәләр, анда командирларының пилоткасы, магазинсыз, җимереп ташланган автоматы ята. Күренеш, монда ни булганлыгы турында шик калдырмый. Безнең якка чыккан дошман разведгруппасы Волковны алып чыгып киткән, дигән фикергә киләбез.

Волков безгә фронтка китәр алдыннан гына килгән иде. Солдат. Бездән хәтсез яшькә олы. Сугышның тәүге айларында прожекторист булып, Баку һавасын дошман самолетларыннан саклауда катнашкан. Соңрак диңгез пехотасында булып, яраланып, госпитальдән чыккач, безгә килгән иде.

Буйга озын булмаса да, калын, таза гәүдәле, үз вазифаларын белеп, эшләрен бәрелмичә-сугылмыйча, җиренә җиткереп үти, авыр шартларда калганда да сабыр, безгә үрнәк булырлык абзый иде.

Аның шундый аянычлы язмышы безнең күңелләргә бик тә авыр тәэсир ясады. Яраланса, яисә үлгән булса, бәлкем, ул кадәре кызганмаган да булыр идек. Күрәсең, дошман да үзенә кем кирәклеген—безнең кебек 17-18 яшьлек малайларны түгел, ә бу тирә-яктагы хәрби обстановкага дөрес бәя бирә алырдаен көтеп торгандыр, диештек. Әгәр дә ул көнне безнең күңелләребездә дошман, ни максат белән бер урынны нык утка тота икән, бу тикмәгә түгелдер дигән сорау туган булса, бәлкем, без аңа кирәкле җавабын да тапкан, чарасын да күргән булыр идек. Башыбызга да килмәде. Бу вакыйгадан соң безнең иптәшләребез берәмләп түгел, парлап, берсен-берсе саклап йөри башладылар. Ләкин монысы да аның хәвефсезлекләрдән чара түгел иде. Шулай итеп, Волков үзе дә, исеме дә кайдадыр Белоруссия яланнарында югалып калды. Башкача аны рәсми урыннарда искә алучы булмады.

"Барановичи" безнең барыбыз өчен дә уңышлы хәрби операция булып кына түгел, физик, рухи көчләребезне, ныклыгыбызны, чыдамлыгыбызны, сугышчан сәләтебезнең үсү дәрәҗәсен дә, кемнең-кем икәнлеген билгеләүче гыйбрәтле сабак та, җитди имтихан да булды.

Сугыш барышларында кемнең-кем икәнлеге бик ачык чагыла икән. Фронтка китәр алдыннан гына безгә зур гәүдәле, киң күкрәкле бер солдат кушылган иде. Халыкның "Карама беләккә, кара йөрәккә" дигән әйтеме бу егеттә үзенең 100 проценты белән хак сүз икәнлеген раслады.

Барановичи сугышларына кадәр дә посттагы иптәшләре, аның турында "туп атышлары, ядрә шартлаулары якынлаша, ешая башладымы, коела да төшә, төсе кача", диләр иде. Атыш башланса, ул землянканың бер почмагына кереп утыра да, колакларын каплап, күзләрен бер ноктага теки дә паралич суккандай ката да кала. Синең ни әйткәнеңне ишетми дә, күрми дә. Тыныч вакытта да шаярмас, иптәшләре белән аралашмас, күз карашлары да тормыштан ваз кичкән кебек—чынбарлык монда, ә ул кайдадыр. Эшләгән эшләрен дә аңлар-аңламас хәлендә диярлек кенә башкара торган иде.

Барановичига кадәр, сирәк-мирәк атыш вакытларында, линияләр әллә ни еш өзелмәгәндә, аның мондый сәер чыгышларына иптәшләренең ачулары килсә дә, нидер дәрәҗәдә аны җәллиләр, күбрәк телефон төбенә утыртып, җитезрәкләре аның эшләрен дә эшли торганнар иде. Ә инде кызу сугыш барышларында җәлләү кебек нәрсәләргә урын калмый, һәркемнең үз җаны үзенә газиз, үз эше үзенә җитәрлек. Безнең элемтәчеләрнең эше сугышның кызган вакытында күбәя дә инде. Ут астына барасың, кердсең, өзелгән линияләрне ялгыйсың, төзәтәсең. Туп атулары, ядрә шартлауларының туктаганын көтеп, аларның төшкән урыннарын читләтеп, уратып та үтә алмыйсың. Берсе төшеп, икенчесе төшкән арада, линияне төзәтеп калырга тырышасың. Дошманның кайдан атканлыгын белү, координатларын табу, аларны тупчыларыбызга бирү өчен постларыбызның эшләүләрен тәэмин итәргә тырышасың. Безнең бу төп сугышчан бурычыбыз—дошман туплары белән көрәшүебездә иде.

Барановичи өчен сугышта беренче залплар яңгырау белән безнең теге әзмәвер украинлы егетебез постын, иптәшләрен ташлый да тылга чаба. Иптәшләре кычкырып, артыннан куркытыр өчен атып карасалар да, туктата алмыйлар. Әйтүемчә, ул элек тә мондый эшләрне эшләштергәли иде. Гадәттә ул Үзәк станциягә бездән берничә километрга калып арттарак килә торган иде. Килә дә, беркемгә бер сүз дә әйтмичә, берәр аулаграк, кеше күрмәсрәк урынга посып утыра. Без аны эзләп табып, кире постка җибәрәбез, иптәшләре килеп алып та китәләр иде.

Бу юлы аны эзләп карасак та ул табылмады. Без аны бөтенләе белән дезертир булып, фронттан качкандыр дип тә уйлый башлаган идек, алай булып чыкмады. Барановичины азат итеп, яңа позициягә күчәргә җыена гына башлаган идек, ул табылды. Җиргә казып куелган махсус машинабызның моторы астына кергән дә, тәүлектән артык, Барановичи өчен барган сугышлар тынганчы шунда яткан булып чыкты. Пехотада булса, моның өчен аны, шундук атмасалар да, штрафной ротага җибәргән булырлар иде. Ә бездә чираттагы шелтә, иптәшләренең бәргәләүләре белән генә чикләнелде. Батареябыз аны шулай "тәрбияли-тәрбияли", Белоруссия территориясен үтеп, ярты Польша буйлап—Варшавага, Висла елгасына барып җиткәнче сөйрәп йөртсә дә, барыбер аңардан эшкә ярарлык ышанычлы иптәш, кирәкле солдат килеп чыкмады. Күз җиткәч, Көнбатыш Пруссиягә баргач, аны штрафной ротага тапшырдылар. "Әллә кайчан шулай кирәк иде",—диделәр күпне күргән солдатлар.

Барановичидан соң безнең бригаданы ялга чыгардылар. Аның бер звеносы буларак, безнең дивизион да, фронттан хәтсез артка китеп, агачлары күккә ашып үскән зур урман кырына килеп урнашты.

Урманнан ерак түгел, ялан кырда зур гына күл бар. Килеп туктау белән без барыбыз да кызулап землянкалар казырга, куышлар корырга тотындык. Форсаттан файдаланып, тыныч кына ял итеп каласыбыз килде. Кайчан әле аның икенчесе булачак. Монысы да аның, фронт шартларында нинди ул ял, дигән сыманрак, башларыбызга да килгән нәрсә түгел иде. Дөрес, алмаш-тилмәш булса да, моңарчы безне тылга алып чыгып, юындырып, өс-башларыбызны алыштырып кергәлиләр иде. Ләкин болай барыбызны да бергә, бер үк вакытта—беренче мәртәбә. Орудиеләр атмый, ядрәләр шартламый, июль аеның аяз, җылы матур көннәре. Бөтен тереклекнең җанланган, кыр, урман, болын үләннәренең котырынып үскән, җир өсләренә яшел хәтфәләрен җәйгән вакытлары. Тирә-якка тараткан хуш исләре, күңелдә тудырган тойгы-хисләре—тәмуг утларыннан алып чыгып оҗмах түрләренә үрләттеләрмени!

Ялга чыгып, боларны күрү, тынычлыкның нәрсә икәнлеген аңлау, безнең күңелләрдә үзеннән-үзе: "Ни җитмәде икән бу кеше дигән бәндәләргә, шушы оҗмах төсле матурлыклар арасында явызлыклар кылырга?" дигән сорауларны да тудыра иде.

Ялга чыгуыбызның төп сәбәбе июль аеның гүзәллекләренә сокланып карап, кояшларында кызынуында түгел иде, әлбәттә. Сугыш барышында таушалып, тузып, күпләре инде эштән чыгып беткән техникабызны карап-барлап, сүтеп—тазартып, ватык-җимерекләрен ремонтлап, яңадан сафка бастыруда иде. Төннәрен—постларда, Үзәк станциядәге эш урыннарын яктырта торган күчмә лампаларыбызның аккумуляторларын корабыз, телефон аппаратларын ремонтлыйбыз. Башка вак-төяк җиһазларыбызны да тәртипкә китерәбез. Гомумән, эштә кайныйбыз.

Болардан башка көн саен үзебезнең агымдагы тормышка багышланган төрле тикшерүләр дә булып тора. Бу занятиеләрдә командирларыбыз үткән сугышларда булган уңай якларга, анда очраган җитешсезлекләргә тукталалар, югалтуларыбызның—бу вакытка алар дивизионыбызда хәтсез генә иде—сәбәпләрен анализлыйлар, киләчәккә аларны әзәйтү, мөмкин кадәр булдырмау чараларын да билгеләргә тырышалар. Замполитлар партия-комсомол җыелышларында сугышларда батырлык, тырышлык күрсәткән, иптәшләрен әйдәкләп баручы солдат, сержантларны партия, комсомол сафларына алалар. Көндәлек политинформацияләр дә булып тора. Гомумән, барыбыз да матди яктан да, рухи яктан да яңа походларга, яңа сугышларга әзерләнәбез. Без бит әле үзебезнең 1941 елгы ил чигенә барып җитмәгәнбез.

Эшләр күп булып, безне тик тотмасалар да, яшьлек барыбер үзенекен итә. Эш араларында булса да, йөгерешә-йөгерешә, күлгә барып су коенып килергә дә өлгерәбез. Күпме кирәк адәм баласына! Судан соң үзеңне яңадан туган кебек хис итә башлыйсың, үзебезгә кирәк нәрсәләрне дә истән чыгармыйбыз. Армиядә хезмәт иткән кешеләр белә—солдат кайда гына, кем булып хезмәт итүенә карамастан, ул һәрвакытта да ике нәрсәгә мохтаҗ—берсе туйганчы ашау, икенчесе—йоклау. Дөрес, ничек кенә гадәттән тыш кебек күренмәсен, атлый-атлый, хәтта төшләр күрә-күрә, поход вакытларында да йокларга була. Ә менә ашау ягына килгәндә, моның өчен солдат казаннары бер генә вакытта да җитәрлек булмый. Аеруча көчле сугыш барышларында әйбәт кенә ашаталар дигәндә дә, алар синең сарыф иткән энергияңне барыбер тулысынча тутыра алмыйлар.

Безнең ялга туктаган урыныбыз бу яктан безнең теләгебезгә ярашлы булып, кара җиләк, кызыл бөрлегән, гөмбә ишегә бай урын икән. Авыл, юл тирәләрендә кыргый армуд, ягъни груша очрап тора. Без аларны, агач башларына менеп селкетеп, менәрлек булмаганнарын таяклар белән бәргәләп төшереп, вещмешокларга тутырабыз. Беләкләсәң, алар тизрәк йомшый, карая башлыйлар. Берничә көннән ашардай хәлгә киләләр. Туклыклыгы әлләни булмаса да, корсак тула. Сугыш шартларында монысы да әз түгел, витамин бит, ризык, иш янына куш.

Кайбер шук малайлар, командирларыннан бик сорап та тормастан, икешәрләп-өчәрләп, тирә-як авылларга, шул ук өстәмә азык табып булмас микән, диебрәк эзләнеп "походларга" чыгып китkәлиләр.

Без һөҗүм сугышы барышларында Белоруссиянең 1939 елга кадәр Польша составында булган, олы магистраль юллардан ерак, урман эчләрендә утырган авылларында, сугышның берничә еллар баруына карамастан, аларның сугышны гына түгел, тере немецны да күрмәгәннәрен белә идек инде. Мондый авыллар, 1939 елны гына СССР составына кергән булып, анда әле чын совет власте, колхоз дигән нәрсәләр дә урнашып өлгерә алмаганлыктан, андый авылларның кешеләре үзләренә үзләре хуҗа булып яшәүләрен дәвам итәләр иде.

Мондый авылларның аралары берсеннән-берсе шактый ерак булганлыктан, сугыш елларында аларның кешеләре үзара бик йөрешеп тә, аралашып та бармаганнар. Шуңа күрә андый авылларны тоташтырган юллар саз үләннәре белән капланып, ташландык хәлгә килеп беткәннәр иде. Йөрешкән кешеләре булса да, үзләре салган, үзләре белгән сукмаклар аша гына. Без ул авылларның барлыкларын, исемнәрен, кайда урнашканнарын карталардан карап белә, таба торган идек.

Шундый, зур гына авылларның берсендә хәтта дүртенче сыйныфка кадәр балаларны укыту да туктатылмаган булып чыкты. Бу безгә,—моңарчы Белоруссия җирләрендә күпсанлы, җимерелеп-яндырылып, халыклары таралышып бетеп, мич торбалары гына утырып калган авыллар аша үткән солдатларга,—гаҗәеп вакыйга булды. Сугыш алды елларында Минскидан шушы авылга мөгаллимә итеп җибәрелгән кыз сугыш елларында да үзенең эшен ташламаган. Бу авыл Барановичи—Пружаны арасында булып, минем исемдә калган.

Немецлар сугышның тәүге көннәрендә, бу җирләрдә мондый авылларга тукталып тормастан, тиз арада үтеп киткән булсалар, хәзер безнең һөҗүм вакытларында да шул ук юллардан ашыгыч чигенергә мәҗбүр булганлыктан, бу авылларны сугыш өермәләре бу юлы да читләтеп үткән иде. Кешеләре бар яклап та, бер төрле мобилизациягә дә эләкмәгәннәр. Алманиягә дә куылмаганнар, партизанлык та итмәгәннәр. Аларга тимәгәннәр, алар да беркемгә тимәгән.

Менә шушындый авылларны табып, кешеләреннән сорап, кайчакта бик сорап та

тормастан, безнең малайлар сөт-катык, бәрәңге, юк-юк та, самогон да алып кайткалый башладылар. Беренчеләрдән булып бу яктан безнең батарея егетләре өлгер булып чыкты. "Пункт предупреждения" начальнигы Ырымбур яһүде, сержант Табохов, лагеребыздан берничә километрда гына урнашкан авылларның берсенә барып, инде дә "трофейланып" кайтып килгәндә, авыл читендәге бер йорт бакчасында умарталар барлыгын күреп кала, егетләр төнлә барып рамнарын тазартып кайта. Шул авылда артиллерист офицерлар анда туктаган булган, безнең сержант белән солдатны күргәннәр, кайдан икәнлекләрен белгәннәр, иртәгә ук караклык хәбәре безнең дивизионга да, батареябызга дә килеп җитте. Караклык шиге безнең малайларга төшсә дә, моны исбатлау өчен дәлил генә табылмаганлыктан, аларны самовольно чыгып киткәннәре өчен шелтәләү белән эш бетте. Моннан соң безне авылларга рөхсәтле дә, рөхсәтсез дә чыгарулар катгый тыелды гына түгел, андыйлар табыла калса, каты җәза булачагы турында искәртеп куйдылар.

Сугыш елларында, фронтта гына түгел, тылда да үзенә күрә "гөнаһларны йолу"— "война спишет" дигән әйтем модага кергән иде. Шуңа күрә мондый гөнаһлар турында бик кычкырып та, түрәләргә җиткереп тә тормыйлар. Әмма ки, ни чара гына күрмә, алама мисал тиз таралучан, тиз йогучан. Корал бар, теләк туды исә, бүген монда, иртәгә тегендә булу да шуңа этәрә. Барысын да карап та, күзәтеп тә бетерә алмыйсың. Авылларда табыш итәргә мөмкинлек барлыгын сизеп алган солдатлар, форсаты туу белән, араның ерак булуына карамастан, киресенчә ераграк булса, эләкмәскә ышанычлырак та дип, шунда юнәләләр, кайдан аны эзләсеннәр дә, кемгә алар турында жалоба бирсеннәр?

Командование солдатларны мондый адымнардан тыярга тырышса да, юк-юк та, андый нәрсәләр булып тора иде. Хәтта кыска гына ял вакытларында да. Шуны белептер, безнең батарея командиры еш кына: "Солдат не должен оставаться без дела",—ди торган иде. Дөрестән дә, солдат хезмәте агышында вакыт бушлыгы хасил булдымы, көт тә тор, ул аны үз хаҗәте хисабына тутырачак.

Бу юлы бер старшина белән бер өлкән сержант шундый бер авылга барып, самогон табып эчеп исерәләр дә, төнлә торган урыннарына кайтып килгәндә бригаданың азык-төлек тәэминаты начальнигына тап булалар. Аны күргәч, старшина белән өлкән сержант, майорга честь биреп, аның күз алдыннан тизрәк таясы урынга: "Стой!"— дип акырып туктаталар да: —"А ну-ка, майор, поприветствуй нас строевым шагом!"— дип акыралар. Бу майор олы яшьләрдә булуына карамастан, унбиш-уналты яшьлек малай кебек кечкенә гәүдәле, кәкре борын астын гына түгел, берникадәре бит өлешен дә каплап алган куе кара мыеклы була. Теге ике исерек автомат төбәп, көлешә-көлешә, майорны строевой адым белән, тегеләй-болай йөрергә мәҗбүр итәләр. Тора-бара гәйрәтләнеп китеп, аны по-пластунски, аннан беләсезме икән, дип төрле тактик маневрлар ("танки справа, танки слева", "воздух") ясарга кушалар. Боларның кызыгы беткәч, "Кавказ лезгинкасын" биетәләр. Майорны хәлдән тайганчы, пычракта аунаган дуңгыз хәленә җиткергәнче интектерәләр.

Табигый, майор алар кулыннан ычкыну белән—комбригка... Төнге сәгать дүртләрдә безне "Тревога" белән күтәрделәр. Без барганда "геройларыбыз" айнып та җитмәгән, үзләренең ни кылганлыкларын да, үзләре белән ни булачагын да әлегә белмәстән, баш киемсез, бил каешсыз, дистәләгән кораллы солдатлар белән уратылып алынган килеш саф алдында басып торалар иде. Димәк, үтә дә яманлык эшләгәннәр. Эшләгән эшләренә карата җәзасы да әзер булып чыкты. Укый башлаганда без аларны атарлар дип курыккан идек, штрафной батальонга гына җибәрделәр. Хәер, монысы да атудан ким йөрми иде. Бигрәк тә һөҗүм сугышы барышларында. Билгеле, штрафникларны фронтның иң авыр урыннарына җибәрәләр. Таләп бер: "безусловное выполнение задания", девиз: "искупите свою вину своей кровью!" Һәм җәза озак көттерми. Озак та үтмәстән, теге старшинаның сугышта үлүе, өлкән сержантның каты яралануы турында хәбәр килде.

Бу вакыйгадан соң безнең өчен иркенлек бетте. Хәер, ялыбыз да. Ялыбыз ничек көтмәгәндә башланып киткән булса, бетүе дә шулай ук көтмәгәндә булды.

Июль азаклары. Төнлә "тревога" белән күтәрделәр дә, көндәлек паек бирделәр. Болай булгач, юл кыска булмаячак. Берничә сүздән генә приказда: көн азагына... шунда булырга тиешбез. Ара алтмыш километрлар чамасы. Ял иткән урыныбыздан көньяк-көнбатыш. Брест шәһәре юнәлешенә карап, "по батарейно, колонной, шагом

марш!" Хуш, мәрхәмәтле, безне күпмедер вакытка үз иткән Белоруссиянең күркәм табигатьле урыннары. Булдыра алсаң—ярлыка безнең кайбер малайларның шуклыкларын.

Без кузгалу белән вак кына җәйге яңгыр сибәли башлады. Бер-ике сәгатьтән ул ару гына кыза төшеп, плащ-палаткаларыбызны ябынырга мәҗбүр итте. Җил юк. Куе урман аша атлыйбыз. Эссе. Бара-бара тын алулары кыенлаша, тирләтә, атлаулар авырайганнан-авырая.

Төштән соң артта калучылар саны күбәйгәннән-күбәя. Күпчелек—шәһәр егетләре. Безнең батареяда алар хәтсез генә иде. Авыл малайлары шулай да ныграклар. Эшләбрәк үскәнгәдер. Мондый очракларда мин еш кына үземнең ат белән көннәр буе буразнада атлап сабан сөргән, тырма тырматкан, соңрак, сугышның тәүге елларында трактор бригадасында эшләгәннәремне искә ала идем дә, алар миңа әйбәт чыныгу биргәннәр икән, дип уйлый идем.

Приказда күрсәтелгән урынга батареябызның сиксәнгә якын кешесеннән тәгаенләнгән вакытка нибары тугыз кеше килеп җитә алды. Алары да арып-алҗып, аяк табаннарын кабартып, бот араларын чиләндереп килделәр. Баштанаяк шыбыр суда иделәр.

Безнең килүебезгә артиллеристлар алгы сызыктагы үзләренә күрсәтелгән позицияләрен биләп, дошман тупчылары белән атыша да башлаган булып чыкты, ләкин "күз-колаксыз". Болары безнең—разведчикларның вазифалары, артта калган иптәшләребезнең җыелып беткәннәрен дә көтеп тормастан, килә баручылар хисабына алгы сызыкка китәргә приказ алдык.

Шушы кадәре ялыктыргыч, озак, авыр юлдан соң, монысы аның безгә бигүк ошап бетмәсә дә, без аны үзебезгә тиешенчә кабул иттек. Сугыш кырларындагы тәҗрибәбездән белә идек: мондый очракларда аның иң хәерлесе—тизрәк алгы сызыкка, билисе позициягә баруда. Бардыңмы—үзеңә-үзең хуҗа. Телисеңметеләмисеңме, монысы инде аның сугыш хәлләре таләбе. Окоплар казырга, землянкалар корырга тотынасың, коралларыңны барлап, әзерләп, эшеңне башлап җибәрергә тырышасың. Болардан соң гына, анда да әле алгы сызыктагы хәлләр сине тагы да бимазаламаса, берникадәре тынычланып, иптәшләрең белән чиратлашачиратлаша булса да, аз-маз ял итеп алырга мөмкинлек туа. Шулай булгач, тизрәк алга! Шулай да тоттың да киттең түгел, кергәнче чыгарыңны чамалабрак. Югыйсә, кермәстән, чыкмыйча торып калуың да ихтимал. Алгы сызыкның "холкы" иркә хатыннарныкы кебек, ни вакытта, ни кыяфәттә керәчәген белә алмыйсың. Бер үк урында, бер үк вакытта ул ут өермәсенә әйләнә.

Безнең бу очрактагы хәлебез ул кадәре куркынычлы дип әйтерлек булмаса да, урыны-урыны белән барыбер, әгәр дә батареябызның киң җәелеп, таралып утырачагын истән чыгармаганда, безнең каршыбыздагы үтәсе араларда да куркыныч урыннар юк түгел иде.

Фланглардагы постларга барасы иптәшләребезнең—алар күпчелек—юллары тынычрак булып, снарядлар сирәк-мирәк төшкәләсә дә безгә тынгы бирмәс өчен генә диярлек. Кисәтү постына барасы иптәшләребезнең юлларын (алар батареябызның нәкъ уртасыннан үтәргә тиешләр) дошман тупчылары бик каты утка тоталар иде. Дөрес, монысы да безнең өчен яңалык түгел, чөнки аның белән беренче мәртәбә генә очрашмыйбыз.

Тупларның ату тизлекләре вак-төяк автоматик коралларныкы кебек өзлексез тыкылдап торучан түгел. Аларның ату араларында—залплапмы ул, берәмләпсирәкләп кенә аталармы,—бераз "вакыт бушлыгы" барлыкка килә. Болардан башка да, аеруча гаубицаларның ату тавышлары белән снарядларның килеп җитеп, төшеп шартлаулары арасында (әгәр дә ул турыдан-туры булмаса) беренчеләренең тизрәк, икенчеләренең калыбрак килүләре хисабына шундый ук "бушлыклар" хасил була. Менә шушы секундлы, минутлы вакытлардан файдаланып, аларның барлыкка килүен эләктереп кала алдың исә, катушка, тавыш алгычларыңны күтәрәсең дә, шул ук үз батареяңның ату тавышлары ишетелгәнче, ни көчең бар, чабулап барып, ишетелмәсә, чама белән шәйләбрәк булса да, катушкаларыңны "баш очына" атып бәрәсең дә (башың исән калса, калган җирләреңне ядрә ярчыклары ерткаласалар да ямарлар, теккәләрләр әле, диеп) җиргә сылашасың. Көткән снарядның "фиулап" килеп төшеп, шартлап ярылып, кыйпылчыкларының баш өсләреннән фырылдашып үтеп китүләре

була, сикереп торасың да, янә әйберләреңне кармап алып, тагы да шундый ук “бросок”—алга. Тагы, тагы да. Куркынычлы полосаны үткәнче, кай чакларда билисе позицияңә барып җиткәнче әнә шундый “үлем уены” була.

Әгәр дә син миномет утлары астында калсаң, монда инде синең тактик маневрың беразга үзгәрә. Аның үзгәрүе—снаряд белән миналарның җиргә төшкәч ярылу аермалыкларында. Гамәлдә снаряд берникадәре җиргә үтә биребрәк ярылганлыктан, аның кыйпылчыклары һавага күтәрелебрәк очалар, бу очракта синең җиргә ятып калу тактикаң акланса, миналар җиргә тию белән ярылганлыктан, аның ярчыклары җир өстен ертып, сыдыртып-тырнап оча. Шунлыктан җиргә ятып калу тактикасы монда үзен акламый гына түгел, күпсанлы югалтуларга китерүе мөмкин. Мондый урыннарны үтү синнән житезлек, елгырлыктан башка, үзеңне саклау өчен җир өстендәге бөтен мөмкинлекләрне—калкурак, чокыррак, агачлырак урыннарны дөрес файдалануны таләп итә. Немецларның бик оста минометчы икәнлеген дә истән чыгармаганда, безнең солдатларыбыз өчен дошман миналарының никадәр куркыныч икәнлекләрен күз алдына китерүе кыен түгел.

Безнең шушы авыр шартларда үткән көнебез—килеп җитеп, ашап та тормастан алгы позициягә приказ алуыбыз, бик аздан гына фаҗигале булып бетмәде. Артта калган иптәшләребез инде җыелышып, алга кузгалырга гына дигәндә—“мә сиңа!” Моңарчы күрелмәгән, башка да килмәгән, ишетелмәгән дә яңалык—кисәтү посты начальнигы сержант Табохов: “Нәрсә, мин дуракмыни күрәләтә үлем авызына барып керергә, атыш туктасын, аннан барырбыз”,—дип, алгы сызыкка барудан баш тартты.

Болай да батареябызның берничә километрга таркалып, соңлабрак килүе өчен дивизион командирыннан кисәтү алып өлгергән комбатыбыз, моны ишетү белән ачуыннан кызарынып-бүртенеп: —“Ты что сказал, а ну повтори!” дип, Табоховның җавап сүзләрен дә көтеп тормастан: “Ты что, забыл о нашем предназначении? Забирай свои вещи и немедленно! В противном случае”,—диде дә, башына килгән ниятеннән үзе үк куркыптыр, әйтәсе сүзен дә әйтеп бетермичә тотлыгып калды. Ләкин сержант Табохов, кузгалып китәсе урында звукоприемникның өстенә барып утырды. Монысы инде Табохов тарафыннан ачыктан-ачык киреләнү иде. Комбат: “Ты что, не слышишь?—дип кычкырды, пистолетына тотынды: “Считаю до трех”. Моңарчы мондый тамашаны күргән юк иде, йә, хода, ни була бу, диешеп, баскан урыныбызда катып калдык. Комбатның кыяфәте Табоховка бер юньлелек тә вәгъдә итми иде. Моңарчы без комбатыбызны үзебезгә карата гадел, кайгыртучан командир итеп кенә белгән булсак, ул урыны, вакыты, шартларның үзгәрүенә карап таләпчән генә түгел, гаять ачулы, хәтта рәхимсез дә була икән.

Туп атулары туктагач, безнең анда баруның ни кирәге булачак? Безнең фронттагы бөтен эшебез дә шул бит—дошман тупларының кайдан атканлыкларын табып, аларның координатларын үзебезнең тупчыларыбызга тапшыру. Алар атудан туктагач, аларның кайдан атканлыкларын каян беләсең, яңадан ата башлаганнарын көтеп утырасыңмы? Фронт тылдагы күнегү полигоны түгел. Дошманның безнең якка очкан һәрбер ядрәсе синең солдатларыңа үлем куркынычы: хәрби корылмаларына җимерү алып килә. Моны булдырмас өчен бердәнбер чара—аларның позицияләрен табып, утка тоту—эшчәнлекләрен туктату. Мөмкин булса, бөтенләйгә сафтан чыгару, ким дигәндә “бастыру”, аларга “эшләргә” ирек бирмәү.

Бер кешенең мәгънәсезлеге аркасында купкан “коткы” ни булып беткән булыр иде. Һәрхәлдә Табохов файдасына түгел, әлбәттә, әгәр дә аның белән постка барасы иптәшләре, комбатның янаулары Табоховны “өркетер” өчен генә түгеллеген күреп торган солдатлар, командирның “өч”кә җиткәнен көтеп тормастан, җилкәсеннән бәреп алып кабалана-кабалана үзләре белән алгы сызыкка алып китмәсәләр.

Әйтергә кирәк, Табохов кеше буларак та—үзенең эчке халәте, кыяфәте белән дә, урыслар әйтмешли, “пренеприятнейший” тип иде. Бездән берничә яшьләргә олы (моңарчы ничек фронтка эләкмичә йөри алгандыр), дугаланып торган үркәчле зур гәүдәсенә ярашлы ясалма кебек утырып торган олы баш, чыгырыннан чыгардай, кайдан нәрсә эләктереп булыр икән дигән сыман туктаусыз эзләнеп торган шар күзләр, бервакытта да кибеп тормаган, кайтарылып төшкән селәгәйле иреннәр. Ябылуны белмәгән эре тешле, алап зурлыгы авыз, чиксез белдеклелек, сүз көрәштерү, өстенлеккә омтылу, үзенә буйсынганнарга өстән аска карау.

Вакытлар үтү белән дә Табоховтан чын командир килеп чыкмады. “Бүре баласын

бүреккә салсаң да, урманга карый", ди халык мәкале. Фронт шартларындагы әлеге кыска гына ял вакытында Табохов тагы авылларга чыгып китә дә, җинаять өстендә тотылып, хәрби трибуналга бирелә һәм штраф ротага озатыла. Берничә атнадан: "туп ярчыгы тиеп, сул кулым яраланды, хәзерге көндә туган калам Ырымбурда госпитальдә ятам",—дигән хаты килде.

Югарыда сөйләнгән Табохов белән булган күңелсез хәл безнең сугышчан рухка йогынты ясамады. Барыбыз да билисе позицияләргә исән-сау барып житеп, төн чыкканчы постларны кирәкле эш дәрәҗәсенә җиткереп, элек үзләренең барасы, йөрисе юлларын утка тоткан дошман тупларының кайдан атканлыкларын табып, аларның координатларын тупчыларыбызга тапшыруны да тәэмин итәргә өлгердек.

Алай гына да түгел, шул ук позициядәге, тагы берничә көнгә сузылган сугыш барышларында, тупчыларыбызны төгәл разведмәгълүматләр белән тәэмин итә алганыбыз өчен бригада командованиесе безгә рәхмәт белдерде. Рәхмәт хәзергә әле солдат батырлыгы билгесе—медаль түгел, күкрәккә тагып йөреп булмый. Шулай да югарыдан эшләренңне зурлап бәяләү, безнең күңелләребезне күтәреп, бәлкем аның медальләре дә ерак йөрмидер дигән өмет тә тудыра иде. Шулай итеп бу урындагы эшләребез бигүк күңелле башланып китмәгән булса да, эш уңаенда җайга салынып, азагы күңелле генә булып бетте.

Аннары да...

Ул көнне безнең билисе позициядәге хәлләребез безгә бернинди кыенлыклар да вәгъдә итми иде кебек. Фронт линиясе хәзергә чагыштырмача тыныч. Авыр артиллериядән ату-фәлән дә юк. Аларны бер яклап та куертып, көчәйтеп җибәрергә теләүчеләр сизелми кебек. Шуңа карамастан Барановичидан чыкканнан бирле кай урында гына тукталмыйк, командование тарафыннан өзлексез кабатланып торган әмер: "тизрәк тә—тизрәк!" Бу "тизрәкнең" безнең өчен бердәнбер мәгънәсе: позициядән-позициягә барып урнашу хәрәкәтләрендә без дошманнан иртәрәк өлгерергә тиешбез. Бу аңлашыла да иде. Дошман, чигенә баруына карамастан, туктаган һәрбер урыннан безнең позицияләрне тиз-тиз генә утка тота да, син аларның кайдан атканлыкларын эзләнеп торгалаганчы, позициясен калдырып китәргә дә өлгерә. Аңардан алдарак урнашып өлгергән (һәрхәлдә, соңлап түгел) туплары тавыш бирә: "рәхим итегез, без монда". Берничә минуттан координатлары билгеләнә һәм... "сәлам" залпы яңгырый.

Менә шулай җавап бирү өчен без берничә мәртәбә инде практикабызда каралган методтан чыгып, бу очракта да, тәгаенләнгән урыныбызга килеп җитү белән, рекогносцинировкага барып тормастан, постка барасы иптәшләребез Үзәк станция яныннан гына ориентир ала да—юлга!

Өлгерәбез! Дошман да ерак түгел икән. Беренче туп тавышлары яңгырау белән, станциябез эшли башлый. Ләкин... Моңарчы практикабызда бер дә очрамаган хәл—чит флангларлардагы ике постыбыз дошман орудиеләренең тавышларын язмый. Үзәк станциядә дежурда утырган сержант Локманов: "Тавыш алгычларыбызны карагыз, эшләмиләр, әллә сез аларны каплап куйдыгызмы?",—дип кычкыра. Тегеләре дә, күрәсең, җавапсыз калмыйлардыр, Локманов сүгенеп ала да тагы аларга кычкырырга тотына. Ә вакыт?! Калганнары эшләсәләр дә, бу ике посттан хәбәр булмагач, гомум нәтиҗә булмаячак. Ул булсын өчен, иң кимендә постларның бишесе эшләргә тиеш. Сәбәп нидә? Теоретик яктан аның иң ихтималы—кисәтү постында. Яисә кисәтү посты башка постларыбыздан арттарак калган, яисә шул ук постларыбыз аңардан алдарак. Бер үк полосада булсалар да, шул ук хәл килеп туачак. Бу юлы үзәк станция эшли башлаганчы, туп тавышлары аларны үтеп өлгерәләр. Нәтиҗәдә аларның тавышлары тасма язмаларына эләкми.

Мондый житешсезлекләрне белгәннән соң, постта эшләүче солдатларыбыз үзләре дә, үзәк станциядән ярдәм сорап тормыйча да төзәтә алырлар иде. Шуңа карамастан, нинди ният беләндер—бәлкем, солдатларның пост шартларында ничек яшәгәнлекләрен күреп, хәлләрен белеп, аларның рухын күтәрү нияте беләндер, (фронтта монысы да солдат өчен аз түгел) комбат, сержант Плотниковны ала да, алар икәүләп юлга чыгалар. Постларда булып, эшлисе эшләрен эшләп, күрәселәрен күреп, сөйлиселәрен сөйләшеп кайтырга чыгарга гына дигәндә, алар үтәсе араны дошман каты мина утына тота башлый. Моны күреп торган солдатлар: "Иптәш өлкән лейтенант, әзрәк басыла төшсен, аннан кайтырсыз", диюләренә карамастан, алар тукталып калмыйлар.

Ерак та китә алмыйлар, дошман минасы комбатыбызның алдына ук килеп тә төшә. Төшә дә, алар икесе дә егылган урыннарында ятып калалар. Бу фаҗигале хәбәр шундук бөтен батареябызга таралып, безнең барыбызны да кайгыга салды. Әле генә исәннәр иде бит... Бу безнең фронттагы беренче зур югалтуыбыз иде. Кем бит әле! Комбатыбыз!

Посттагы бу хәлне күреп торган иптәшләребезнең берничә мәртәбә аларны алып чыгарга тырышулары уңышлы барып чыкмады. Дошман минометчылары якын җибәрмиләр. Моңардан без: дошман комбатыбызны күреп, утка тоткан, дигән фикергә киләбез.

Без аларны төнлә генә алып чыга алдык. Карарга куркыныч, комбатыбызның бер өзелмәгән урыны да калмаган иде. Йөзе караланып бетеп, күз урыннарында батып кергән ике чокыр гына. Ә аның артыннан барган сержант Плотниковның, киресенчә, бер җире яраланса икән? Алып кайтканнан соң без аның яраларын эзләп карасак та, таба алмадык. Әллә мина шартлавы дулкыныннан гына үлде микән, дип тә уйлый башлаган идек, икенче көнне иртән, аларны җирләр алдыннан өлкән сержант Мальцев, эзләнә торгач, аның лепкәсеннән маңгаена төшәрәк чәч арасында шырпы сыярлык кына тишек, чәченә укмашкан кан бөртеге тапты.

Сержант Плотников Ырымбур өлкәсенең Сорочи районыннан килгән, таза, матур егет иде. Ул бик ышанычлы иптәш, батыр сугышчы, көр күңелле егет булып исемдә калган... Кул астындагы солдатларның берәрсенең эше белән канәгать булмаса, башкалар кебек кабынып китеп тавышланмас, йөзе гаҗәпләнеп, кашлары күтәрелеп китәр иде дә: "шуны да булдыра алмыйсыңмы?" дип текәлеп карап калыр иде.

Командирларыбызның икесен дә иркен итеп казылган бер каберлектә җирләп калдырдык. Калганнарыбыз—яңа сугышларга, кичерешләргә, җиңүләргә, югалтуларга...! Алга!

## Ил чигенә җиткәндә

Атлый, сугыша бара торгач, 1941 елгы ил чигенә дә ерак калмыйбыз. Аңа якынлашкан саен сугыш та көчәйгәннән-көчәя, югалтулар да арта, ишәя. Кайбер урыннарда, фашистларның чигенә баруларына карамастан, аларны эзәрлекләү түгел, алардан азат ителгән җирләрне яңа көчләр килгәнче саклап, тотып торырга сугышчы да калмый. Аларны "тулыландыру", сугыштагы профессионал вазифаларына хас булмаган, башка гаскәри көчләрнең, тупчыларның, минометчыларның һәм башкаларның бу урыннарны үзләренә сакларга, "ямарга" туры килә. Кыскасы, һөҗүм сугышларын тоташ алып бару өчен фронтка җәяүле көчләр җитми башлый. Дөрес, монысы вакыты-вакыты белән безнең алга бару тизлегебезнең көчәюенә дә бәйле иде. Шуңа күрә кайбер тирәләргә хәрби яктан бөтенләй әзер булмаган солдатларны алып килеп җибәрә башладылар. Нәтиҗәдә—тагы да күбрәк югалтулар. Шундый югалтуларның берсенә безгә дә, Пружаныга (Барановичидан соң немецларның безгә каршы торган иң зур терәк пунктларының берсе) якынлашып килгән көннәрдә шаһит булырга туры килде.

Ул көнне без хәрби җиһазларыбызны тәртипкә китерү өчен алгы сызыктан берникадәре артка чыгыбрак эшләп йөри идек, безнең кырдан, әйтерсең лә, юри көндезге сәгать уннар тирәсендә, Көнбатыш Белоруссия авылларыннан атасы-улы, агасы-энесе, туганы, кодасы, баҗасы, күршесе—барысы бергә солдат киемнәренә киендерелгән өч йөздән артык кешене, кулларына мылтык тоттырып, тынлы оркестрның дәртләндергеч хәрби марш озатуы астында, алгы сызыкка алып килделәр дә сугышка кертеп җибәрделәр.

Фашистлар да, аларның килгәннәрен көтеп торган кебек,—сизмичә дә, белмичә дә булмагандыр,—аларның алгы сызыкка килеп керүләре була, утка да тота башлыйлар.

Йомгак шул: көн азагына өч йөздән артык кешедән нибары утыз-кырыгы гына исән торып кала. Алары да беткән булырлар иде, әгәр дә төнлә алыштырып алып чыкмасалар. Исән калганнары да, физик яктан таза кебек күренсәләр дә, рухи яктан изелеп, миңгерәүләнеп бетеп, тышкы кыяфәтләре белән дөньядан ваз кичкән кешеләрне хәтерләтәләр иде. Аларны алып чыгучы командирларын күреп сорашканнан соң, боларның шулкадәр тиз дә, фаҗигале дә бетүләренең сәбәпләре

ачыкланды. Өсләренә дошман ядрәләре, миналары төшә башлау белән, тизрәк, ышанычлырак итеп, җиргә казынып кереп, дошманга отпор бирергә әзерләнәсе урынга, алар позицияләренең бер башыннан икенче башына йөгерешә башлыйлар: "Фәләнгә әйтегез, атасы авыр яраланды, агасына әйтегез—энесе үлде, киявенә, күршесенә..." Тегеләренең бу хәбәрләрне алу белән күтәрелүләре була, аларны да—"хоп"! Китә тавыш, кычкырыш, җылаш—барысын да үлем җәзасына хөкем иткәннәрме. Кыска гына вакыт эчендә ике йөздән артык кеше кырыла да бетә. Бу фаҗигале хәлне күргәннән соң, без фронтта "пушечное мясо"ның хикмәтле әйтем генә түгел икәнлеген, кеше гомеренең сукыр бер тиен дә тормаганлыгын аңладык. Шулай да, соңлап булса да, тиешле нәтиҗә ясалгандыр. Һәрхәлдә безнең юнәлештә башкача мондый "сугышчыларның" үзләрен генә, ветераннар белән аралаштырмыйча, алгы сызыкка кертеп җибәрмәделәр.

Бу вакыйгалардан соң, июльнең 15-17 ләре тирәсендә, безнең бригада Пружаныны уң якта калдырып, Көнбатыш Буг елгасының аръягына чыкты. Бу урында ул әле безнең хәрәкәтебезгә киртә булырлык зур су түгел иде. Ул СССР-Польша чигендә генә зур суга әйләнәчәк.

Аны үткәч, безнең бригаданы икенче эшелонга күчерделәр. Бу күчерү безгә ял бирергә теләгәннән генә түгел иде, әлбәттә. Алда—Польша. Бер-ике җитди генә омтылсак, без анда булачакбыз. Димәк, моның өчен ныклы әзерләнергә кирәк. Бу юлы хәрби яктан гына түгел. Безгә "дус" ил булса да—пропагандабыз шулай ди иде—барыбер чит ил. Ил чиген үттекме, безнең статусыбыз да үзгәрә—без азат итүче армиягә әйләнәбез. Шушы тарихи зур миссиягә лаек булырга тиешлебез. Шушы юнәлештә "эшкәртергә" дә тотындылар. Парт-политработникларыбыз лекция укый, доклад сөйли. Гомумән, безне иҗтимагый-сәяси яктан Польша, аның халкы белән очрашуга әзерлиләр. Анда кергәч үзеңне тота белергә тиешсең! Үзебез дә, йөзгә оят китермәслек булыйк, дип тырышабыз. Хәрби җиһазларыбызны карау, аларны тәртипкә китерү, алдагы сугышларга әзерләнү белән беррәттән, үзебезне дә карарга тырышабыз. Тазартынабыз, яманабыз, юынабыз. Старшиналар солдатларның тишек-тошык киемнәрен алыштырдылар, мөмкин булганча ремонтладык. Кайберләребезгә яңа гимнастерка, ботинка, обмоткалар да эләккәләде. Тазарыну, юыну өчен су якын. Бушаган арада кумәкләшеп су коенып, юынып килергә дә өлгерәбез. Рәте чыкканда, балык шартлатып алуны да онытмыйбыз. Моның өчен мөмкинлекләр юк түгел.

Без туктаган урында Көнбатыш Буг елгасы, безнең тирәдәге Димнән киңрәк булса да, сайрак, тирәнлеге күкрәктән артмый. Ашкынып аккан, төбе ялтырап яткан таза сулы матур елга. Көннәр кояшлы, җылы. Шундый көннәрнең берсендә без иптәшем Ильницкий белән бер-ике "лимонка" алдык та елга буена барып, аның әйләнмәләнеп аккан, тирәнрәк урынына граната бәргән идек, вак балыклар белән бергә су өстенә зур гына чуртан калкып чыкты. Мин тиз генә өс киемнәремне салып ташладым да—елгага! Суның агышы шәп булганлыктан, мин чишенгәләгәнче, суга төшкәләгәнче, чуртаныбыз бата-калка ару гына агып та өлгергән. Иптәшем Ильницкий яр башыннан минем балыкка карап йөзүемне: "уңга, сулга, үтеп киттең, арттарак", дип бара торгач, чуртанны куып җитеп тотып алдым да, муенын сындырып, борынынннан авызга кабып, йөзә-атлый балыкны алып чыктым. Кәсебебез уңганга шатланып частька кайткан идек, бригадабызда "ЧП".

Без балыкта йөргәндә, башкалар да тик тормаганнар икән.

Ике солдатыбыз—берсе ару гына олы яшьләрдә иде—латыш, ул безгә Тамбов урманнарыннан ук таныш, уңны-сулны, яраган белән ярамаганны белми торган кеше дә кебек түгел иде, икенчесе рус егете—ерак булмаган бер хуторга барып, кулында корал булгач куркытып, анда яшәгән ана белән кызны чиратлап көчлиләр. Моның белән генә эш бетсә, бәлкем, тегеләре дә тавыш күтәреп тормаган булырлар иде. Юк шул, "ләззәтле" эшләрен бетергәннән соң, өйдә ни нәрсә бар, җыеп алалар да алып китәләр.

Тегеләре артларыннан ук—бригада командованиесенә. Һәм бригада буенча "тревога". Сафка тезделәр. Менә алар үзләре дә! Шул көннәрдә генә: "Әгәр дә кем дә кем мародерлыкта, яисә башка шундый эшләрдә беленсә, аңа җәза каты булачак",—дигән кисәтү булган иде. Моны раслау өчен мисал да булды. Шундук хәрби трибуналның карары чыкты: атарга!

Бу приговорны ишеткәч, теге апалар җылый-җылый: "Без бит әйберләребезне

кайтарып бирсеннәр дип кенә килгән идек"—диешеп карасалар да, "Әйберләрегезне алдыгыз, калганы сезнең эш түгел",— дип, аларны озатып куйдылар. Бригада алдында чокыр казыттырып— приговорны башкарырга! Моның белән генә "җәзалау" церемониясе бетми әле. Бригаданың һәр офицеры, үзенең шәхси коралыннан, аларның һәрберсенә тагы да берәр тапкыр атарга тиеш булды. Монысы инде аның әгәр дә мәгәр тагы да шушындый эшләрне кабатлаучы табылса, аны менә нәрсә көтә, диюгә кисәтү иде. Икенчедән, ул вакытта бездә һәр җирдә дә хөкем сөргән гомум мәрхәмәтсезлекнең чагылышы иде ул.

Бу вакыйгалардан соң икенче көнгә каршы төндә без алга киткән фронтны куа киттек.

## Польша җирендә

Безнең бригада фронтны куып җиткәндә, безнең көчләр, фашист гаскәрләрен эзәрлекли барып Көнбатыш Буг елгасын үткәч, сугышны туктатып та тормастан, Польшага да барып кергән булып чыкты.

Ул көннәр, ил чигенә чыгу өчен барган һөҗүм сугышлары тарихи әһәмияткә ия булулары белән билгеле. Бу хакта әле Мәскәү, Сталинград окопларыннан, Идел ярларыннан хыялланып килгән солдатлар һөҗүмне шулкадәре зур рухи күтәренкелек, тәвәккәллек белән алып бардылар ки, дошманга оборона өчен уңайлы шартлар булса да, алар ашыгыч рәвештә качарга мәҗбүр булдылар.

Бу һөҗүм без килер алдыннан төнлә генә үткәрелгән булган, аның әле шаукымы да бетмәгән иде. Караңгы. Таң сызылып кына килә. Вакытның шулай иртә булуына карамастан, күпер алды, Буг елгасы яр буйлары хәрби техника, төрле гаскәрләр—танкистлар, тупчылар, саперлар, кыр кухнялары, атлылар, җәяүлеләр белән шыгрым тулы.

Күпердән ерак та түгел урман кырларында зенитчылар да урнашып өлгергән. Барысының да көн ачылганчы, Буг елгасының ар ягына—иркенлекләргә чыгып каласылары килә. Билгеле, хикмәт анда гына түгел. Әгәр дә бу шартларда монда озакка тукталып калып, дошман безнең позицияләребезне утка тота башласа,—һаваданмы, җирдәнме—аермасыз, безгә аларның зур зыян китерүләре мөмкин иде. Тизрәк алга, елга аръягына! Ләкин бу мәхшәр халыкны, кылдан нечкә сират күпере диярлек тар күпердән тиз арада үткәреп җибәрү мөмкин булмаганлыктан, елга аръягындагы яулап алынган плацдармнарны ныгыту, киңәйтү, тәүгеләр артыннан барасы авыр коралллы көчләргә уңай шартлар булдыру ниятеннән беренче чиратта җәяүле гаскәрләрне үткәреп җибәрү мотлак иде. Хәер, моңа алар үзләре дә—карабин, автомат, пулеметларын иңбашларына салып, авырайган аякларын лашпыр-лошпыр сөйри-сөйри, күпер такталарын шыгырдатып-шыгырдатып туктаусыз үтеп кенә торалар.

Күрәсең, беренче эшелон белән бер сафларда килгән булгандыр, чик сакчыларыбыз да мондалар. Аларның яшел фуражкаларын монда күрү, безнең күңелләрдә горурлык, канәгатьләнү хисләре тудыра, авыр югалтуларыбыз юкка гына булмаган, без ил чигендә! Фронтның башка участокларында да шул ук хәлләр булгандыр, дип уйлыйм. Ни арададыр, ераклардан күренерлек итеп, күпер алды мәйданына "СССР" дип язылган чик баганаларын утыртып куярга да өлгергәннәр. Хәзер инде син аларның күзәтүләреннән, тикшерүләреннән, рөхсәтеннән башка, ил чикләрен тиз арада—дөбер-шатыр гына үтеп китә алмыйсың.

Дивизион командиры капитан Волков, һәрвакыттагыча, безне кабаландыра, ашыктыра, күпер алдына китереп җиткерә алса да, булды дигәндә... Стоп! Күпер аша үткәреп җибәрү белән командалык иткән гомумгаскәри полковник, безнең нинди частьтан икәнлегебезне белгәннән соң, коры гына: "Капитан, вам там еще нечего делать, отведите свой дивизион вон туда и не мешайте здесь работающим",—дип зенитчылар тукталып калган урынга күрсәтте. Үзе күпер аръягына чыгарга чәбәләнешеп йөрүчеләр арасына кереп югалды.

Фронтта нинди генә гаҗәеп хәлләр булмый. Күрсәтелгән төбәккә барып урнаша гына башлаган идек, Буг елгасы буйларын яңгырата-яңгырата, сул флангтан буталчык рәвештә мылтык ату тавышлары ишетелде. Коралларыбызны алабыз да урман кырына ташланабыз. Бер яктан икенче якка чайпала-чайпала, зур гына бер соргылт нәрсә безгә таба агыла икән. Шуңа карап аталар булып чыкты.

Көн әле ачылып җитмәгән, эңгер-меңгер. Яр буйларының уйсурак урыннары томанлырак. Шуңа күрә бу нәрсәнең ни икәнлеге бик күренеп тә тормый. Ярга килеп җитмәстән, аңа таба уң флангтан тагын ата башладылар. Карана торгач, минем башка суккан кебек булып китте—бу бит сарыклар. Ике-өч йөз башлап булыр. Каян, ни рәвештә монда килеп чыкканнар? Аларның сарыклар икәнен белеп алуымнан шатланыпмы, әллә адәм балаларының аларны вәхшиләрчә кыруларына ачуым кузгалыпмы: "смотрите, смотрите, на овцов стреляют",—дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым. "Прекратите стрельбу!"—дигән тавыш яңгырады. Ләкин соң. Эшлисе эш эшләнгән. Безнең алдагы ачыклык үтерелгән, яраланган, аякланырга тырышып үрмәкләп, арт саннарын сөйрәп, әүмәкләп тә яткан сарыклар белән тулып өлгерде. Исән калганнары да озак вакыт кая барып бәрелергә белмичә чабулашып йөрделәр.

Без төш алдыннан гына күпер аша үтеп китә алдык. Буш түгел. Солдатларның иртәнге тынлыкта шау-шу куптарып сарыкларны күпләп аткан-кырган чагында, безнең арада аларны җәлләүчеләр булган булсалар да, күпләребез, фронтның алгы сызыгында көн саен сиңа трофей очрап тормый, ә монда алар үзләре чабулашып килә, әгәр дә без форсаттан файдаланып калмасак, ахмаклык булыр иде, дип уйлаганбыздыр.

Бер төркем иптәшләребез "тайт" дигәндә—табылып кына торалар, сарык төркеменә ябырылып, дистәләгән сарыкларны җилкәләренә салып алып та китте. Атылган, яраланганнарын түгел, чабулап йөргәннәрен. Без аларны, өлкән офицерлар күреп калгалаганчы дип, ашыга-ашыга, машиналарыбызның кузовына яшереп, үзебез күперне чыкканда каплап утырабыз, дип урыннар да әзерлибез. Бу гамәлебез дөрес булып чыкты. Күпер аша үткәндә, чик сакчыларының: "Кузовыгызда нәрсәләр ул?", диюләренә, гамьсез генә кыяфәткә керергә тырышып: "Нәрсә булсын, хәрби приборлар" дигәч, актарынып тормадылар. Үтеп киттек.

Менә без Польша җирендә. Бераздан Буг елгасының яр буена урнашкан, зур булмаган шәһәрчеккә килеп кердек. Беренче карашта туган уй, хисләр! Нәрсә-нәрсә, мондый хәлне күрербез, очратырбыз дип уйламаган идек—аерма җир белән күк арасы. Сугыш алды елларындагы гадәти тыныч тормыш хөкем сөрә кебек. Бәлкем, сугыш кырларында йөреп, мондый күренешләрдән ерагаеп өлгергәнгә дә, шулай күренгәндер.

Фронт әле төнлә генә үтеп китүенә карамастан, шәһәр кибетләре эшли иде. Хәтта фәхешханәләре дә бар икән, аның да эшләгәнлеге беленде. Бу хәбәр яшен тизлегендә таралып, солдатларыбыз арасында дәртле җанландыру тудырды. Солдат эшсез торып калдымы, көт тә тор: ул эзләнә башлый. Берничә сәгатькә тукталып калган арада, дивизионыбызның, хуҗалык взводының ике сержанты фәхешханәдә күңелләрен күреп чыгарга да өлгергәннәр. Безнең батареяның егетләре дә тик утырмаганнар. Алтынчы пост начальнигы сержант Ковалев та шундый ук диярлек очрашуга тап була. Бер йортта аңа карт белән карчык—бер капчык он, яисә шуңа бәрабәр булырлык азык-төлеккә 16 яшьлек кызны тәкъдим итәләр. Моны кайтып сөйләгән сержантыбызның тел төбе, күз карашы, йөзе, капчыгын түгел, йөген дә җәлләмәс, диләр иде.

Бу көтмәгәндә, аяк астыннан гына купкан ыгы-зыгы ни булып беткән булыр иде, әгәр дивизион командованиесе, болар турында белеп, безне җыеп алып, каты шелтәләр белән янамаса. Сарык инициаторлары белән фәхешханәгә барып йөрүчеләргә каты гына җәза да эләккән булыр иде, фронт шартларында боларны штраф ротадан башка тормышка ашыру мөмкин булмаганлык кына аларны коткарып алып калды.

Безнең фронт тормышыбызда Висла елгасына барып җиткәнче, әллә ни искә алырлык башка вакыйгалар да, авыр сугышлар да, сафларыбызда югалтулар да булмады. Шулай бара торгач, июль азаклары—август башларында Варшавадан астарак Висла елгасына барып җитмәстән, берничә километрлар кала, калын нарат урманы эчендә туктап, үзәк станциябезне шунда урнаштырдык, постларыбыз Висла яр буйларына пехотачылар белән бер сызыкта туры килде. Бу тукталуыбыз хәтсез озакка булып чыкты.

Поляклар безне Варшаваларына гына түгел, илләренә дә кертергә теләмиләр. Аларның төп максаты—без килеп ныгып өлгергәләгәнче, Варшаваларын азат итеп, Лондондагы буржуаз хөкүмәтен кайтарып утыртып куюю икән.

Аларның безгә карата шундый карашлары, билгеле, күңелләребездә ризасызлык тудырды, ачуыбызны китерде—без аларны азат итәбез, ә алар?! "Теләмиләр икән, ну и хрен с ними",—дип сүгенеп тә җиппәргәли идек.

Әйтергә кирәк, бу вакыйгаларга кадәр дә, бездә полякларга карата әллә ни тугандашлык тойгылары кайный, дип әйтеп булмый иде. Моның сәбәпләре дә юк түгелдер. Ырымбур өлкәсенең Тоцк хәрби лагереның АИР мәктәбендә укыган вакытыбызда безгә болай аңлаттылар. 1939 елда Алманиян Польшага һөҗүм башлагач, поляклар чигенә барып, безнең ил җирләренә килеп керәләр, әмма 1941 елны Германия безгә сугыш башлагач, безнең белән бер сафта үз илләрен азат итәргә барырга теләмиләр, шунлыктан аларны 1942 елны илебездән чыгарып җибәрәләр.

Кая безгә—ул вакыттагы 18-19 яшьлек малайларга барысының да төп сәбәпләрен аңларга, руслар белән поляклар арасында гасырлар буена килешә алмаслык катлаулы мөнәсәбәтләрнең яшәп килгәнлекләрен, киләчәктә дә аларның нинди юнәлештә дәвам итәчәкләрен белергә. Әгәр шул көннәрне Варшавадагы баш күтәргән Польша патриотлары үзләренең ил язмышларын үз кулларына ала алмасалар, сугышның ничек кенә бетүенә карамастан, аларның илләре барыбер оккупация астында калачакларын сизенә идек. Ул шулай булып бетте дә. Дөрес, алар 1945 елны, теләсәләр-теләмәсәләр дә, барыбер безнең ярдәмнән башка фашистларны җиңә дә, үз илләрен үзләре генә азат итә дә алмыйлар иде. Сугыштан соң безнең илгә бәйле булып каласы килмәсә дә, ярты гасыр диярлек Польша безгә бәйле булып яшәде, тик СССР дигән ил таркалгач кына үзләре теләгәнчә яши башлады. Ул чакта, ягъни 1944 елда, без моны каян белик? Әле 1939 елда ук СССР белән Германиянең Польшаны бүлешү турындагы яшерен килешүе булганын, шул елда ук 20 мең поляк офицерын Сталинның приказы белән атып үтерүне без сиксәненче еллар азагында гына белдек.

Бу чакта фронт исә Варшава вакыйгаларына бәйле хәрәкәтләрен берникадәре әкренәйтә төшеп, безнең участокта тукталыбрак калган кебек булып күренсә дә, профессионал таләпләренә ярашлы үз тормышы, үз мәшәкатьләре белән яшәвен дәвам итте—алгы сызыкларга яңа көчләр килә, хәрби корал, матди җиһазлар белән тулыландырыла. Гомумән, фронтыбыз, күзгә күренеп, Висла елгасының аръягына чыгарга әзерләнә иде.

Бу таләпләргә ярашлы безнең тупчыларыбыз да, фашист гаскәрләренең төп игътибары әле гамәлдә Варшава восстаниесен бастыруга юнәлтелгәнлегеннән файдаланып, моның өчен дошманның анда тупланган кораллы көчләренә мөмкин кадәре күбрәк югалтулар китерү ниятеннән Висла аръягы позицияләрен интенсив рәвештә утка тотты. Кайбер көннәрне бу атышлар артиллерия дуэленә әверелеп, гадәттә дошман туплары да безнең бригаданыкы кебек еракка ата торган эре калибрлылары белән атып, ядрәләре безнең түбә очыннан (объектлары без түгел) һава тыгызлыгын ярып, кайбер мәлләрдә ике якның да ядрәләре бер тәңгәлдә очраша иде. Нәтиҗәдә барлыкка килә торган һава дулкыны күп мәртәбәләргә артып, тирә-якны күк күкрәп, яшен аткан кебек дер селкетә иде. Безнең баш очларыбыздан ике якка үлем ява:—безнекеләр елга аръягына ата, немецлар—бездән хәтсез артта урнашкан тупчыларыбыз позицияләренә. Менә шулай ике ут эчендә калабыз.

Безнең белән дошман арасында зур су киртәсе—Висла елгасы булу, безне аларның утларыннан да, гаскәрләренең турыдан-туры безгә каршы һөҗүм оештыра алу мөмкинлекләреннән дә саклый. Вакыты-вакыты белән без монда үзебезне бөтенләй диярлек тыныч шартларда кебек хис итә идек.

Тирә-якның күккә ашып үскән куе нарат урманы, аның аңкып торган сагызлы агачларының хуш исләре бу тойгы-хисләребезне тагы да көчәйтә, күңелләребезгә җиңеллек өсти иде. Чык, йөре, аяк астындагы үлән аралаш, күпереп торган ылыс түшәкләренә сузылып ят, ауна, тәгәрә, ял ит. Алда әле күпме чакрымнар атлыйсы…! Гел генә фронт, сугыш, үлем, яралану турында гына уйланырга, сөйләнергә дигәнме… Ә дөнья нинди матур. Безгә нибары унсигез-унтугыз яшь. Күңел ачасы да килә. Үзәк станциябезнең дежурдан буш солдатлары шулай эшлиләр дә. Уңае чыкканда, кайберләре Висла елгасы яр буйларына барып, аңа карап: —"Эх, суында да коенып булса иде",—диешеп кайтып, аның матурлыгы, гүзәллеге турында сокланып сөйлиләр иде.

Хәзергә безгә биредә никадәре генә тыныч, куркынычсыз, уңайлы кебек күренсә дә: "Югалтма, солдат, сизгерлегеңне, сак бул, фронт кайда да фронт"—дигән

кагыйдәне онытмый идек. Көндезме ул, төнләме, тыныч булып күренсә дә, якында гына сугыш кайный.

Безнең тирәдә дошман көчләренең игътибарын җәлеп итәрдәй әллә ни зур көчләр дә юк. Бердәнбер тупчылар батареясы гына. Алары да әле аның көненә берничә мәртәбә тиз-тиз генә атып алалар да тукталып калалар, атып алалар да...

Шундый атышларның берсендә—ату-шартлау! Бу ни хәл? Әллә күрше тупчыларыбыз үзләрен шартлаттылар инде, диешәбез. Минометчылар арасында андый хәлләр булгалаганын беләидек, әмма...

Чираттагы ату-шартлаудан соң, кырдагы агач башлары өзелеп төшеп, ярылган ядрә ярчыклары пырт-пырт машинабызның брезент япмасын ерта-ерта кереп, иданнәргә бәреләсугыла башлагач та әле эшне аңлап бетермибез. Үзәк станция начальнигы сержант Титков: —"Ребята, это же по нас стреляют, быстро в укрытие",— дип кычкыргач кына кабаланышып: "Башларыбызны гына булса да коткарыйк",— диешеп, тизрәк сикерешеп төшәбез дә машина астына кереп ятабыз. Барыбыз да түгел. Наушниклар киеп, үзәк станция артында дежурда утырган сержант Локманов, берничә секундка артта калып: —"Ребята, я ранен"—дип кереп ятты.

Ул арада: "Прекратите! Что вы делаете! По своим же, сволочи! Мать вашу..." дигән сүгенү, акырыш, кычкырыш тавышлары белән бөтен урман эче тулды. Атыш туктау белән, яткан урыннарыбыздан шикләнә-шикләнә генә бер-бер артлы чыга башладык. Сержант Локманов кына, куллары белән башын тоткан да, ятуын дәвам итә. "Атыш бетте, Локманов, чык!" дибез. Ләкин җавап юк. Үзе кереп ята алгач, без аны җитди яралангандыр, дип уйламаганбыз, күрәсең, чөнки болай караганда андыймондый яра булырлык нәрсәсе дә күренми иде. Тагы бер дәшүебезгә дә җавап булмагач, куркыша-куркыша гына машина артыннан иплəп кенә тартып чыгардык. Йөз ягына әйләндереп салу белән йөрәкләр "жу" итеп китте—авыз тирәләрендә күбек, маңгаенда кан тамчысы һәм кечкенә генә яра. Күзләре төссезләнеп сүнеп тә өлгергәннәр. Күңелләрдә ачу, рәнҗү! Кем гаепле? Үзебезнең тупчыларыбыз кулыннан һәлак булу. Нинди фаҗигале үлем!

Бәлки, үзебезнең тупчылар кулыннан һәлак булгангадыр, һәр хәлдә онытылганнан түгел, сугыштан соң дивизионыбызның фронтта эшләгән эшләренә, югалтуларына йомгак ясаган чакта да аның фамилиясенә урын табылмады. Хәер, ул гына да түгел, андыйлар әле безнең батареябызда берничә булды.

Сержант Локманов (үзенең сөйләве буенча) бәләкәйдән ятим калып Башкортстанның Дүртөйле балалар йортында тәрбияләнеп үсеп, шуннан армиягә алынган, буйга зур түгел, чибек кенә гәүдәле сержант иде.. Тазалыгы да шәптән түгел, бер ягына кырынаебрак атлый иде. Бер кулбашы икенчесенә караганда күтәренкерәк, шуңа күрә бер кулы икенчесеннән кыскарак та кебек күренә иде. Шунлыктан аны авыр эшләргә алмыйлар, аерым заданиеләргә җибәрмиләр иде. Аның батареядагы төп вазифасы—үзәк станция артында утырып, постлар белән телефон аша өзлексез элемтәне тәэмин итү. Ә менә холкы ягыннан ару кырыс, ярыйсы гына үзсүзле дә. Командирлар белән әрепләшергә дә бик тартынып тормый. Башкалар белән бик аралашмады, якын гына иптәше-сердәше булмады. Тик олы яшьләрдәге украинлы, шоферлар командиры өлкән сержант Христич белән генә якын булды. Тамбов урманнарыннан бирле Локмановка шефлык күрсәтә килде. Ул аны үз энесе кебегрәк якын күрә иде. Локмановның үлеме аның өчен зур кайгы булды. Үзенең нииндидер без белмәгән юанычын югалтты булса кирәк. Безгә ул аны җирләргә рөхсәт итмәде. Үзе алып китеп, юып, таза киемнәрен киендереп, каберен мөселманча ләхетләп казып, урман кырына чыгарып җирләде. Без Локманов кабере өстенә туфраклар гына сала алдык. Өстенә үзен алып киткән ядрә гильзасын кисеп ай билгесе белән һәйкәл дә утыртып куйдык. Андагы позициядән киткәнче, аның каберен әйбәтләүне дәвам иттек, өстен чирәм белән каплап, киртәләп куйдык.

Локманов белән бер вакытта үзәк станциягә килгән икенче пост начальнигы сержант Новоцельцев та яраланган иде. Ярасы артык авыр булмаганлыктан, ул госпитальгә барудан баш тартты (ядрә ярчыгы җилкә тирәсен ертып үткән иде). Ай чамасы муенын бора алмыйча йөрсә дә, постын калдырмаганы өчен батареябызда беренчеләрдән булып аны өченче дәрәҗә "Дан ордены" белән бүләкләделәр. Бу хәл сугышта: "У одних грудь в крестах, у других голова в кустах", дигән әйтемгә ачык мисал булды. Ул әле тагы да бер мәртәбә шулай ук җиңел генә яраланып, икенче

дәрәҗә “Дан ордены” белән бүләкләнергә дә өлгерде. Егетләр: “Бер нәрсә кабатлана башласа, өчкә кадәр була, диләр, хәерлегә булсын”,—диделәр. Исән калды. Ул Мәскәүдән иде. Миңа аның белән тагын бер мәртәбә, 1952 елны, Мәскәүдә очрашырга туры килде. Ул Мәскәү университетының яңа бинасын төзүдә катнашып, тагы бер, бу юлы Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнгән иде.

Без әле Локманов үлгәч, шул урында хәтсезгә калсак та, безгә Висланы кичеп чыгарга, Варшаваны азат итүдә катнашырга туры килмәде. 1944 елның сентябрь азакларында безне кире Белоруссиягә алып киттеләр.

Китәр алдыннан Локмановның кабере янына барып пилоткаларыбызны салып саубуллаштык. Сугышта үлгән кешеләрнең урыннары оҗмахта була диләр, шулай булсын, амин, дип киттем мин аннан.

## Литваны үткәндә

Берничә атналар ял итеп, бригадабыз, дивизионыбыз, батареябызны өстәмә корал, хәрби җиһазлар белән тулыландырып, сугыш барышларында таушалган, ватылган, җимерелгәннәрен мөмкин кадәре яңадан хезмәт итәрдәй хәлгә житкереп—ремонтлап, запасларыбызны азык-төлек белән тулыландырып, солдатларыбызның өс-башларын, аяк киемнәрен дә карап, ямап, бөтенләндереп, “рухи-сәяси азык” белән “тукландырганнан” соң без Белоруссиянең Волковск шәһәре тирәләрендә эшелоннарга төялеп (димәк, барасы җирләребез, үтәсе юлларыбыз якыннардан булмаячак) Белоруссиянең төньяк-көнчыгышына карап, яңа фронтка, яңа сугыш-бәрелешләргә таба юл алдык.

Фронтның бу тирәләрдән күптән түгел генә үтеп китүенә карамастан, безнең барасы юлларыбыз төзекләндерелеп, алардан хәрби техника, солдатлар төялгән эшелоннар һәр якларга туктаусыз гөжләшеп үтеп кенә тора. Без аларның шулкадәре тиз арада сафка керүләрен күреп, шатланышып кына калмыйча, аларны үзебезнең җиңүләребезнең нәтиҗәсе, һөҗүм темпларының үсеше, тылларыбызның ныгый баруы нәтиҗәсе дип тә кабул итә идек. Ә менә юл өстендәге очрый барган авыл, разъезд, станция, шәһәрләрнең күренеше… Кая карама, ватык-җимерек, көл-күмергә әйләнеп беткән йорт-каралтылар. Кеше, мал-туарлар, хәтта этләр дә күренми, өрмиләр дә. Алары да фашист солдатлары тарафыннан кырылып бетерелгәннәр. Һәр тарафларда күңелләрне авырайта торган моңсу тынлык, кошлар да очмый, сандугачлар да сайрамый, җилләр дә исми кебек. Кешеләр күренсәләр дә сирәк-мирәк, уттан калган калдык-постыклардан өелеп, ябып куелган лапаслар, куышлар, землянкалар тирәләрендә эзләнеп, актарынып, йорт җиһазларын яңадан аякка бастырырга тырышып йөрүче карт-корылар гына.

Билгеле, без моңарчы да андый күренешләр белән очрашкан, янган, җимерелгән авыл, йортларның күплеген белгән булсак та монда бигрәк тә күплеге күңелләргә нык тәэсир итте.

Хәзерге юл барышында аларны чакрым, адым саен диярлек күреп була, сугышның ил, халык өчен никадәре авыр югалтулар белән сугарылганлыгын маңгай күзе белән генә түгел, күңел күзе, зиһенең, бөтен барлыгың белән күрә, аңлый башлыйсың. Болар безнең фашистларга булган нәфрәтле карашыбызны тагы да кискенләштерде. Бу адәм актыкларын тизрәк бетерәсе иде, дигән теләкләребезне көчәйтте. Шушы җимерекләр безне алга өнди, тизрәк алга, дошманга каршы сугыш алып баручы иптәшләребез янына ашыктыра иде.

Шушындый уй-фикер, тойгы-хисләребезнең астында, сугышның “эшләгән эшләрен” күзәтә-күзәтә хәтсез көннәр барганнан соң, без Литва чигенә килеп терәлдек. Терәләбез диюем…! Ул вакытта Литва безнең союздаш республика булып, фашист оккупантларыннан азат ителеп бетелгән булса да, Польшага керере алдындагы кебек (аның чигенә килеп житүебез белән), сәбәпләрен бигүк аңлатып тормастан, командирларыбыз: —“Хәзер без Литвага керәбез, анда кергәч, эшелоннарыбыз тукталып торганда, вагоннардан чыкмаска, эзләнеп, күренеп йөрмәскә, кешеләре белән аралашмаска, сакта сизгер булырга”,—дип боерык бирделәр. Кирәк-нитә калса, шәхси коралларыбыз әзер булырга тиеш, дип кисәтеп тә куйдылар. Кисәтү генә түгел, фронт штаты таләпләренә ярашлы, карабин, автомат патроннары, кул гранаталары кирәгенчә тулыландырылды. Әмма солдатның башына никадәре генә тукыма, аңлатма,

күпләренең канына сеңгән: "Бу минем өчен түгел, минем белән мондый хәлләр булмаячак", дигән фикер йөртүчеләр дә булмады түгел.

Менә шушындый "минем өчен түгел"ләргә мисал. Безнең дивизионның бер солдаты серле рәвештә үлде. Ул Литваны үтеп беткәнче, төрлесе-төрле урыннарда литвалылар тарафыннан фаҗигале рәвештә үтерелеп, кайсысы кайда эләкте шунда тиз-тиз генә чокылган каберлекләрнең берсенә күмелеп калдырылды.

Литвалыларның шундый дошман караш белән озатуларын тоеп, без 1944 елның октябрь азаклары—ноябрь башларында Вильнюс, Каунас шәһәрләренең күкләренә ашып торган биек манаралы йортларын еракларлан гына карый-карый үтеп, "менә кайда булган икән безнең юл очларыбыз, киләсе урыннарыбыз",—диешеп, Алманиянең Көнчыгыш Пруссия территориясенә килеп кердек.

## Көнчыгыш Пруссиядә

Бу вакыйганы без сугышларда катнаша башлаганнан бирле дулкынланып көтеп алдык, аның шулай булуын кулыбыздан килгәнчә тизләтергә, якынайтырга да тырышып, аның белән ничегрәк очрашачагыбызның төрле вариантларын күз алдына китереп йөрсәк тә, чынбарлыкта бөтенләй дә без көтмәгәндә, бик тә гади, бертөрле героик вакыйгалар белән дә бәйләнмәгән шартларда үтте. Ни сиңа дошман солдатлары, ни һавадан утка тоту, ни пулемет тыкылдаулары, мина, туп атышлары, ядрә шартлаулары—берсе дә булмады.

Ике ил чиге, алар арасында безнең Дим чамасы гына елга. Аның аша үзебезнең саперлар салган агач күпер. Ар ягында ил чиге баганасына, еракларлан күренерлек итеп, "Германия" дип язылган такта беркетелеп куелган.

1941 елны шушы кырлардан безнең илебезне яулап алабыз, дип походка чыккан идегез—рольләребез алмашынды. "Ни теләсәгез, шуңа ирештегез булса кирәк, хәзер инде без монда, поделом вам", диешеп күперне үтеп китәбез.

Беренчеләрдән булып түгел. Без килгәндә, Көнчыгыш Пруссиянең ару күләмле генә өлеше безнең көчләр тарафыннан яулап алынып, алар анда позицияләрен ныгытырга да өлгергәннәр иде инде.

Бу турыда "Икенче бөтендөнья сугышы тарихы"ның 9 томында (146 битендә): "Наступление Советских войск в Прибалтике способствовало успешным действиям 3-го Белорусского фронта в Восточной Пруссии.

С 16 по 30 октября 1944 года силами пяти общевойсковых армий они прорвали оборону противника на Гумбиненском направлении и в 100 километровой полосе продвинулись на глубину 60 километров, перенеся, таким образом, боевые действия на территорию фашистской Германии",—дип язылган.

Күперне чыгып, 10-15 километрлап барганнан соң, без зур гына Гросс Тракенин дигән немец авылы уртасына кереп тукталып, хәрби җиһазларыбызны бушатып, сугышчан позициягә урнашырга дигән боерык алдык. Рекогносцировка вакытында без бу плацдармның уң флангында туктаганлыгыбызны белдек. Шушы көннән алып безнең өчен сугышның иң авыр, иң озакка сузылган "Көнчыгыш Пруссия операциясе" башланды.

Безнең Көнчыгыш Пруссия сугышларында катнашу вакытын ике периодка—пассив позицион һәм актив (һөҗүм сугышлары) периодларга бүлеп булыр иде. Беренче периоды Гросс Тракенинга килеп керүебездән башланып, 1945 елның 13 гыйнварына кадәр дәвам итсә (бу периодта безнең көчләр үзләренең күптән түгел яулап алган позицияләрендә тукталып калып, каты оборонага күчеп тора), икенче периоды шушы, әле генә искә алган датадан, ул асылда Көнчыгыш Пруссия операциясенең рәсми башлану датасы да булып, Алманиянең монда тупланган барлык кораллы көчләрен тар-мар итә-итә территориясен яулап алганчыга кадәр дәвам итте.

Югарыда без бу сугышларның тәүге өлешен позицион, ягъни пассив дип атасак та, аңлашыладыр, аны шулай дип шартлы рәвештә генә атап була иде. Фронт пассив дигән чакларында да бөтенләйгә тынып бетеп тормый, пыскып янган учак уты кебек, вакыты-вакыты белән, йә бер, йә икенче, чикле урында дөрләп китеп алгы сызыктагы бөтен кораллы көчләрнең утын өскә бәреп чыгаргалый, кайбер чакларда мондый хәлләрне каршы торган көчләр, үзләре бер-берсенең ут нокталарын аныклау, оборона

линияләренең торышын капшап карау, сугышчан разведка ясап тел эләктерү өчен файдаланалар, бер-берсенә коткы салгалыйлар.

Билгеле, боларны каршы яклар үзләре дә аңлый: болар булачак сугышларга әзерлек чаралары. Берәүләренең яулап алган позицияләрендә озаклап утырып тормаячаклары, икенчеләренең каршылык күрсәтмичә генә чигенмәячәкләре билгеле инде. Бигрәк тә сугыш бөтен фронт линияләре буйлап Алманиянең үз чикләренә килеп җитеп, үз җирләренә күчә барган көннәрдә. Бу хәл сугыш барышының характерын да үзгәртә иде. Хәзер инде алар өчен сугыш, моңарчы үзләре оккупацияләгән илләрдә ни теләсәң шуны эшләп йөрү түгел, ә үз иленең бөтенлеген, җирен, халкының иминлеген, киләчәген саклау, яклау бурычына әйләнгән иде. Ягъни сугышның максаты да үзгәргән. Алай гына түгел, сугышның ахыры якынлаша барган саен, мәсьәлә тагы да җитдиләнеп, фашистик Алмания бетү чигенә китерелеп терәлгән иде. Билгеле, болар буласы сугышларның мәрхәмәтсезлеген күпкә арттырачак иде.

Без аларның шулай булачагын монда килгәнче аңласак та, Гросс Тракенинга килеп керүебез белән, әгәр дә "үз өеңдә стеналар да ярдәм итә" дигән фараз дөрес булса, ул да безнең кулдан китеп, дошман ягына күчә иде. Дөрес, бу очракта без дә югалып калмый идек. Дошманны эзәрлекли барып, аның үз иленә, үз территориясенә килеп керүебез үзе генә ни тора. Безнең күңелләрдә бу тойгылар моңарчы сизелмәгән тәвәккәллек, горурлык тойгылары тудыра—безне яңа позицияләргә, үзебез өчен генә түгел, безгә кадәр дә шушы көннәрне якынайту, күрү өчен каты сугышларда, үзләрен аямыйча безгә юллар ярып килеп җитә алмыйча, күпсанлы сугыш яланнарында ятып калган каһарман абыйларыбыз өчен дә алга, яңа җиңүләргә чакыра иде. Хәзер эстафета безнең кулда, безнең бурыч—өлкән абыйларыбызның шушы эшләрен дәвам итеп, ерткычлыкка чыккан дошманны үз өненә кире куып кертеп, юк итеп, озын сугыш елларында күп авырлыклар кичереп, иминлеккә, тынычлыкка сусаган халкыбызга җиңү алып кайту. Димәк, безнең өчен Көнчыгыш Пруссиягә килеп керүебез, фронтны алыштыру гына түгел, ә бәлки үтисе бурычыбызның мөһимлеген, әһәмиятен тагын да арттыра иде.

Гросс Тракенинга без төш вакытларында килеп кердек. Шәһәр уртасындагы бер-берсенә охшаган стандарт кирпеч йортларның берсенә барып туктадык, приказ алдык—үзәк станцияне шушы йортның подвалына урнаштырырга, калганнарыбызга—алгы сызыкка!

Хәзергә монда тыныч, сугыш җимерекләре дә күренми. Күренмәсәләр дә... Каян беләсең? Кабаланышып эшкә тотынабыз.

Безнең урнашасы подвалыбыз йорт күләменә тиң булып, берничә кат кирпечтән көймәләп, бүлмәләп, өстенә вак-төяк туп ядрәләре генә түгел, эреләре төшсәләр дә бирешмәслек итеп эшләнгән. Аның шундый ныклы булуы безне, үзәк станциябез өчен кат-кат түшәлмәләр салып блиндаж корудан азат итү генә түгел, исәнлегең өчен шикләнмичә эшләү өчен әйбәт шартлар да тудыралар иде. Блиндажына килгәндә, күпме без аларны казыдык та, кордык та, салдык та. Әгәр дә барысын бергә җыйганда, һәрберебезгә берәр җир асты сарае туры килгән булыр иде.

Билгеле, без бу подвалга бик тә риза. Кайчан әле аның шундыена очрыйсың? Зурлыгы да, үзәк станцияне урнаштырудан башка, аны хезмәтләндерүче сержант, солдатларыбызга ял итү өчен урыны да җитәрлек. Йортның торак өлеше дә өч бүлмәле, йорт җиһазлары да юк түгел. Аларның берсендә батарея командиры, өлкән лейтенант Тихонов, калган икесендә взвод командирлары-лейтенантлар Щербатенко, Аснес, Шайнер урнаштылар.

Йортның чардак өлешендә дә, аерым керешле бүлмә булып, анда, үзенең матурлыгы, ачык күңелле йөзле булуы белән солдат, сержантларыбыз арасында мәхәббәт яулап, абруй казанган санинструкторыбыз, украин кызы Мария урнашты. Йортыбыз болдыры алдында күләме белән 20х30 метр чамалары сарай да бар. Аның артына без махсус машинабызны урнаштырдык. Тора-бара ул безнең постлардан килеп-китеп йөрүче иптәшләребез белән җыйнаулашып тәмәке тарта, гәпләшеп утыра торган урынга әйләнде.

Шулай арлы-бирле тәүге мәлне эшлисе эшләребезне йомгаклап, урыннарыбызны үзләштереп беткәләгәнче, постка барасы иптәшләребез рекогносцировкадан кайтып, алгы позицияләренә барып, тавыш алгычларын боевой взводка куеп, үзәк станциябезне эшкә җибәрергә өлгерде.

Алда әйткәнчә, без туктаган урында фронт ярыйсы тыныч кебек тоелса да, тасмадагы язмалар аның бигүк алай түгеллеге турында сөйли иде. Шуңа карамастан, без ул көнне әллә ни эш кыра алмадык. Дөрес, төнлә дошманның берничә ут ноктасын эләктереп, координатларын ачыкларга өлгерә алдык алуын. Артык түгел. Алдагы берничә көнне дә шул ук хәл кабатланды.

Бездән элгәрәк килгән тупчыларыбыз, кайбер дошман батареяларының позицияләрен билгеләп, утка тотырга өлгергән булсалар да, күрәсең, бигүк бастырып, сафтан чыгарып бетә алмаганнар. Без килү белән, алар безгә шушы батареяларның координатларын ачыклау бурычын куйдылар. Көннәр үтеп дошманның активлыгы үсә бару белән генә безнең игътибарыбызны яңа ут нокталары җәлеп итте. Бу зур түгәллек, җитезлек таләп итүче эш. Ничек тә тизрәк эләктереп алырга кирәк. Шулай да булгалый. Берсенең тавышларын язып барган вакытта икенчеләре атып өлгерсә, аларның тавышлары безнең язмаларга эләкми калуы ихтимал. Бу очракларда аларның тагы да атканнарын көтеп торырга туры килә.

Хәзерге мәлдә кайсысы куркынычрак, кайсысы күбрәк зыян китерә, шуларны алданрак эләктерергә тырышасың. Ә мондый куркыныч нокталар артканнан-арта бара...

Безнекеләр дә тик тормый. Без килгәндә Гросс Тракенинның тирә-ягы ачык ялан диярлек булса, октябрь азаклары—ноябрь башларында андый урыннар бетеп, бөтен тирә-ягы яңа көч, яңа техника белән тулып та өлгерде. Болар күзгә күренеп фронтыбызның яңа һөҗүм сугышларына әзерлек алып баруы турында сөйли иде. Шул ук фикерне хәрби частьларыбызның материаль-техник яктан әзерлеге арта баруы гына түгел, подразделениеләребездәге иҗтимагый-сәяси эшләрнең җанлануы да раслый. Соңгысына аның тагы бер сәбәп—якынлашып килгән Бөек Октябрь социалистик революциясенең 27 еллыгы кушылды. Аңа багышлап политинформацияләр, партия, комсомол җыелышлары үткәрелде. Сугышта тапкырлык, батырлык күрсәткән солдат, сержантларыбызга багышланган “боевой листок”лар чыгаралар, армия газеталары да шул юнәлештә эш алып бара. Сирәк булса да тылдагы эшләрнең ничек барганлыгы турында, андагы аерым әһәмияткә ия булырлык фактларга урын бирелә. Исемдә калган шундый материалларның берсе: газеталарның кайсысындадыр Башкортстанның бөтен җир байлыкларын күрсәткән картасы басылган, аның кырында бер капитанның (кызганычка каршы, фамилиясе хәтердә сакланмаган) “Башкирия—жемчужина Урала” дигән мәкаләсе бирелгән иде. Мин ул мәкаләне газетадан кисеп алып, озак вакытлар иптәшләремә тәмәке төрергә бирмичә, таушалып беткәнче гимнастеркам кесәсендә саклап йөртеп, форсаты чыкканда “менә ул нинди безнең Башкортстаныбыз” дип горурланып сөйлим, мактанып җибәргәли идем.

Оборонада торган вакытларыбызда без хәрби вазифаларыбызны үтәүдән башка үзебезнең шәхси теләкләребезне тормышка ашыру өчен дә вакыт таба идек.

Гросс Тракенинга килеп кереп, булачак эш урыннарыбызны карап йөргәндә, мин югарыда искә алган өйнең чардак өлешендә, тәгәрмәче резинасыз велосипед күргән идем. Мөмкинлек килеп чыгу белән, мин аны алып төштем дә, бәлкем, берәр рәте чыгар дип, ышыграк урын табып, яшереп куйдым. Беренче буш вакыт килеп чыгу белән, аны үзебез урнашкан йортның артына алып чыктым да тәүге мәлне бәреләсугыла педаленә баскалый башладым. Буш вакыт булдымы, тизрәк велосипедка. Атна чамасы үтүгә калтыр-колтыр булса да, егылмыйча шөйлә тәгәрмәчне әйләндерергә өйрәнеп тә җиттем. Хәзер инде шәпләп йөрү өчен чыныгу кирәк иде. Моның өчен әлеге урын мине канәгатьләндерә алмый—иркенлек җитми. Без торган урынның уң флангында—Гросс Тракениннан чыгып фронт линиясенә параллель рәвештә, аңардан ике-өч километрлар чамасы болайрак, җимерелмәгән таш юл бар иде. Дәртләнеп, гайрәтләнеп китеп, бер чыктым шунда, ике. Андый-мондый куркыныч нәрсә сизелмәде. Бу хәлгә гадәтләнеп тә бетеп бара идем, чираттагы бер чыгуымда, көн шундый матур, кызарып кояш батып бара, сугыш юк диярсең, кызулап педальгә басам. Кылтыр-калтыр тавыш булса да, колаклар торгызылган. Ишетәм: алгы сызык—фронт ягыннан “Пок” дигән тавыш ишетелде. Җәһәт кенә шул якка башны борам, күрәм: юлдан ерак та түгел җирнең калку гына урынына “шап” итеп вак калибрлы туп ядрәсе килеп бәрелде. Төшкән урынында нидер мәл зырылдап әйләнеп, ычкынып китеп миңа таба очты. Мин шул ук мәлне, таш юлдан велосипедым белән канауга очтым. Теге

нәрсә әллә болванка, әллә туп ядрәсе булып, ярылмады. Ә тәгәллек—снайперларча, димәк, миңа төзәп атканнар, дип йомгак ясадым һәм башкача монда чыкмас булдым.

Без дошманны мыскыллау, кимсетү ниятеннәндерме, аларны булдыксызлар, мәгънәсезләр итеп күрсәтергә ярата идек. Чынбарлыкта алар бик оста сугышчылар, төз атучылар. Аларның шундый икәнлекләрен бәяләп бетермәү вакыты-вакыты белән безгә бик кыйммәткә төшә иде.

Миңа әле аларның шундый ук оста снайпер булуларын тагы бер мәртәбә, бу юлы Берлинга керер алдыннан, "Мессершмит" астында калып, татырга туры килде.

Чираттагы заданиедән кайтып килә идем, көтмәгәндә алгы сызыкта, бөтен кул коралларыннан котырынып ата башладылар. Тәҗрибәмнән белә идем, мондый атыш якында дошман самолетлары килеп чыкканда гына куба. Шунлыктан мин инстинктив рәвештә күзләремне һавага юнәлтәм, өстә берни күренми.

Тәүге мәлне атышлар мин атлаган урыннан сул флангта, ераграк та кебек тоелса да, тиз арада минем турыга да килеп җитте. Мин һаман да әле өскә каранам. Шулчак бер немец самолеты бөтенләй түбәннән, җиргә тия язып, мине күрепмедер, кинәт борылып, ярсып очкан карлыгач сыман кыйгачлап, янтайды да туп-туры миңа оча. Мин дә аны күрү белән (икебезнең дә маневрлар бер вакытта булган булса да), шулай да мин аңардан ярты секундка алдарак янтаеп өлгердем. Күрәсең, заданиесен үтәп бетереп, уңае килеп чыккандыр да бу летчик минем белән үлем уены уйнарга булган. Янәшәдә тирән генә канау—сикер шунда. Шул ук мәл пулемет чираты, брустверны туздырып, минем өсне җир белән тутырып күтәрелеп китте. Әгәр дә аның очышы шулкадәре җиргә якын булып, пулялары нык яссы очмасалар, ул мине җиргә тегеп китәсе иде. Сизәм, җиргә күмеп китсә дә—исәнмен. Әмма бу нәрсә? Шулкадәре сасы ис. Күземне ачып җибәрсәм, танау очына тия язып..., алланың каһәре генә суккыры, кортлап беткән кеше тизәге. Вәт сволочь, бетерә алмаса да, иснәтте бит дип, сүгенә-сүгенә торып кагындым да, агачлырак җирдән, тизрәк батареябызга ашыктым.

Әйтүемчә, Октябрь бәйрәме алды көннәрендә, безнең тирәдәге көчләрнең арта баруы, моңарчы бер дә булмаган, күрелмәгән 100 граммны да бирә башлаулары, ахры, шушы көннәрдә безне һөҗүмгә җибәрерләр дигән фикергә юнәлтсә дә, бәйрәм дә килеп җитте, үтеп тә китте, андый-мондый хәрәкәт юк. Ике якның да, бик масштаблы булмаса да, 6 ноябрьдән 7сенә каршы төндә кыска гына вакыт интенсив рәвештә туп дуэле булып алды. Бәйрәм салютлары белән алышып, алгы сызыкны ракеталар белән гадәттәгедән көчлерәк яктыртуларыннан, яктыртып оча торган пуля өермәләренең куеруларыннан башка әллә ни искә алырлык вакыйгалар, бәрелешләр булмады. Алдагы көннәрдә дә ике як та позицияләрендә утыра калдылар.

Тора-бара һөҗүм сугышларына күчүебезнең тиз арада булмаячагы матди яктан да ачыклана башлады. Аның шуңа барганлыгының төп билгесе—ашауларыбызның начарлануы.

Французларның, "игътибар белән иркәләнгән, узындырылган солдат начар сугыша", дигән фикере, күрәсең, безнекеләр өчен дә ят нәрсә булмагандыр. Аучы да бит этен, сунарга чыгар алдыннан тотасы җәнлегенең эзен тиз алсын, эзәрлекләргә ташлансын өчен махсус рәвештә ач тота. Безне дә: "ач кешенең ачуы яман",—һөҗүм сугышларын якынайту өчен тырышып эшләсеннәр, көтеп алсыннар (аның барышларында ашау, кагыйдә буларак, арулана) дип тә бик ашатып бармаганнардыр. Бер яктан, мондый утыру теләгеңә ярашлы кебек тоелса да, ул юлларны бездән башка кемнәрдер үтмәячәген белә торып, аны көтеп утыру эчеңне пошыра, ялыктыра, нервларыңны талый иде. Йөрисең, уйланасың да, буласы булгач, тизрәк булсын иде инде, дип куясың. Өстәвенә көз бит әле, көннәр кыскара, төннәр озыная, салкынайта, яңгырлары да ешая, аяк асларын юешләтә, йөрүләреңне авырайта. Көннән-көн фронтның беренче, икенче эшелоннарындагы техника, транспорт средстволарының арта баруы безгә кыенлык тудыра. Безнең элемтә линияләребезне еш кына әләктереп, сөйрәтеп тә алып китәләр, өзеп, уратып бетерәләр, постлардагы иптәшләребезнең эшләрен авырайталар. Ә аларны тиз арада сафка кертү өчен иптәшләребездән күп көч, җитезлек таләп итә. Ә ашау?

Гросс Тракенинга килгән чакларда көннәр әле җылы иде. Мондый шартларда 2-3 километр ара—ара түгел, шуңа күрә аш әзерләүне үзәк станциябез янындагы ялан кухнясында оештырып, посттагы иптәшләребезгә термосларга салып озаталар. Шундый аш салу вакытларының берсендә, повар абзыебыз (ул олы гына яшьләрдәге

кеше иде) кулындагы зур чүмечен төшереп җибәрә дә, үзе дә ава башлый. Янында торган солдатлар, аягы таеп киткәндер дип, аны күтәреп алалар да аягына бастырырга әйтәләр. Бәй, бу ни хәл? Ул басу түгел, сыгылып төшә... Эшнең нидә икәнлеген аңлап та бетмәгән солдатлар, аны җиргә салып, якаларын ычкындыргалаганчы, абзыебыз "үтеп тә" китә.

Фронт шартларында мондый тиз үлүнең бердәнбер сәбәбе—пуля. Шуңа күрә озаклап эзләнеп торасы юк—пилоткасын салдырып, башын карасак, түбәсенә үзебезнең яктырып оча торган пуля кереп утырган. Төбе генә калкып күренеп тора. Алып тормыйбыз. Якын-тирәдә мылтык аткан тавыш ишетелмәгән кебек иде дә, бер иптәшебез, әле генә аңа теге яктан берәү атты дип, тыл ягына күрсәтә.

Аңлашыла, бу атыш дошманга да, кемгә дә, нәрсәгә дә булса төгаенләп атылганнардан түгел. Гадәттә андый ату, тутыккан мылтык көпшәсен тазартканда килеп чыга. Солдат, пуляның үтәсе юлын үтеп, төшкән җирендә дә кешене үтерерлек көчен саклый алганлыгын белсә дә, аны-моны уйлап тормый, тота да ата. Һәм менә сиңа шундый атуларның бер нәтиҗәсе.

Бөтен тирә-як солдат белән тулган җирдә, кем кемне эзләп торсын да, каян табасың да, тапсаң да нәрсә? Без дә эзләнеп тормадык. Берәү артык, берәү ким. Кемгә кирәк тә, кем белә. "Война спишет", дибез дә—эш тә бетә. Үзебезнекеләр кулыннан вафат булгач, сержант Локмановныкы кебек, аның исем-фамилиясе дә дивизионыбызның югалтулары хисабына керми кала.

Бу вакыйгадан соң безне батарея масштабында (дивизионыбызда да) әзерләп ашатуны бетерделәр. Билгеле, аның төп сәбәбе повар үлүдә түгел иде. Сәбәп казанга салып пешерерлек ризык бетүдә иде. Моңарчы, әз булса да ашка итен, яисә балыгын бирсәләр, поварыбыз үлгән көннәрдән башлап, алары да бетеп, алар урынына ниндидер, авызыңа каба алмаслык (моңарчы мин күрмәгән, белмәгән) нәрсә бирә башладылар, әгәр дә ризык турында андый чагыштыруны гөнаһ дип санамасаң, югарыда искә алган кеше... исеннән җиңелрәк түгел, ниндидер сасы, йомшак сыр бирә башладылар. "Голод не тетка"—танавыңны бармакларың белән кысып тотасың да, авызыңа тыгасың. Декабрь башларында эш моның белән генә чикләнмәде, ярма дигәне бетте. Алар урынына арпа оны. Ә ул тоташ кылчыктан гына тора. Аш пешереп карыйбыз, ашап булмый. Үзебезнең поварыбыз Ожогин запеканка да ясап карый, анысы да тамактан үтми, тырышып үткәреп җибәрсәң дә, кылчыклары тамакка утыра, ках та-кох киләсең. Тышка чыгулары проблемага әйләнә. Нишләргә? Ач торып булмый бит инде. Уйлана, эзләнә торгач, повар Ожогин: "Егетләр, барыбер ашап булмый, рөхсәт итсәгез, мин апара ясыйм",—ди. Башта без аның нәрсәгә ишарәләвен аңлап бетермәсәк тә, серле итеп тамагына чирткәнен күргәч: "Валяй",—дибез.

Күпме көннәр үткәндер, бер көнне кичләтеп Ожогин: "Егетләр, өлгерде, мин инде тәмләп тә карадым, менә дигән чыга",—дип безне төнлә үз янына чакырды. Без төн буе чиратлашып барып алюмин кружка белән яртышар кружка менә дигән самогон эчеп кайтабыз. Күңелләр күтәрелеп китте. Икенче көнгә дә җитәрлек иде әле анда. Ефрейтор Супрунов каяндыр безнең бу эшебезне белеп калган да, замполит капитан Гурзога әләкләгән. Ә ул дөбер-шатыр килеп, зур тәрбияви эш башкарган кебек: "Вы что тут, пьянку устраиваете? А ну сейчас же",—дип, апарабызны чыгартып түктертте. Кызганыч кына булу түгел, ачуыбыз килде. Комбатыбызга да белдерделәр, әмма ул әйбәт егет иде: "Что же Вы, не могли поосторожнее",—дип, безне шелтәләүдән ары әллә ни эшләмәде.

Егетләр Супруновның әләкләгәнен белеп калгач: —"Ну и сволочь же ты, Супрунов, твое ли, свое же кровное. Ну погоди, вот пойдем в наступление...", дигәч, "Вы что, ребята? Я же за Вас, как бы чего не вышло", дип караса да, батареяда озак вакыт әле аны битәрләүдән туктамадылар.

Ашау үз чиратында начарланганнан-начарлана барды. Шулай да солдат кыен вакытларында җебеп утырмый. Эзләнә. Ә кем эзли, шул таба.

Бер көнне миңа станциябез пульты артында утырган Юра Сорокин: "Сержант, Вас Махмутов к телефону просит",—ди. Телефонны алдым да: "Тыңлыйм",—дим. "Мөҗип, без монда ат суйдык (ул вакытта без торган авыл кырларында еш кына немецлардан калган авыр йөк атлары очрый иде) итен китеримме, ашыйсыңмы?,—ди. Мин әйтәм: "Ник ашамаска". "Алай булгач, мин сиңа иртәгә алып килермен",—ди. "Күпме кирәк, ә урыслар ашармы, безнең посттагылар ашыйлар, әйбәт,—дип

мактыйлар”. Мин тиз генә иптәшләрем белән киңәшләшеп алдым да, кемдер: “Ә ул ашарга ярыймы соң?” дип сорады. Мин: “Татарлар гомер буена ашый”, дигәч китерсен, диләр.

Иртәгәсе көнне Мәхмүтов вещмешогын тутырып ит алып килде. Ожогин безгә аңардан, балта белән тапап, котлетлар кыздырды. Исе генә дә ни тора!

Борынга килеп бәрелүе белән, борын тишекләреңне кытыклап, киңәйтеп җибәрә. Ул ит күп булып, алай-болай бозылып киткәләгәнче ашап калыйк, дип Мәхмүтовларның постына барып үзебез дә алып кайттык. Көннәр буена кыздырылган котлет ашыйбыз. Берничә көннәр шулай иписез ашый торгач котлетыбыз үтләтеп тә бетте. Озакламый бу процесска офицерларыбыз да килеп кушылды.

Каяндыр иснәнеп, эзләнеп йөргән песи кебек, исеннән сизепмедер, вычислительләр взводыбызның командиры, лейтенант Яша Шайнер бер көнне: “Ит каян алдыгыз, нәрсә ите ул?”—дип кухнябызга килеп керде. Без: “Ат ите”,—диешәбез. “Нәрсә пешерәсез?” “Котлет”. “Кая, күрсәтегез әле котлетыгызны”. “Рәхим итегез”. Башта ул чирканган кебек итеп бармак очлары белән чеметеп кенә алып кабып карады да, тагын да күбрәк итеп, тагын да… Ахырда: “Бу нәрсәгез күпме әле”,—ди. Без әйтәбез: “Җитәрлек!”. “Алай булгач, бер ун килосын безнең аш пешерүчегә дә илтеп бирегез әле”,—ди.

Моңардан соң без, сугыш барышларында тапкан, очраган ашау ганимәтләребез турында офицерларыбызга бик сөйләнеп бармас булдык.

Көне-төне эш өстендә, авыр, кыен, ачлы-туклы дисәң дә фронт шартларында да, аеруча оборонада утырганда буш вакыт булмый тормый. Дошман тупчылары да гел генә синең өсләреңә “ырылдашып”, позицияләреңне утка тотып ватып-җимереп кенә утырмыйлар. Мондый чакларда солдатлар, барлыкка килгән “бушлыктан” файдаланып, үз хәҗәтләрен тормышка ашырып калырга тырышалар. Күпләре—ял итәргә—йокларга яталар, кайберләре өс-башларын, аяк киемнәрен тәртипкә китерергә, карарга, ямарга керешә. Кемдер хат язарга утыра. Яраткан кызлары булганнары—кызларына, булмаганнары әти-әнисенә, туганнарына яза. Кайберләре хат язуны нindидер бер йолага, үзен рухландыру процессына әйләндерә иде. Шундыйларның берсе, минем кулдаш, Курск өлкәсе егете, сержант Раков турында монда берничә сүз булса да әйтеп китмәсәм безнең Гросс Тракениндагы тормышыбыз тулы булмас иде кебек.

Хат яза башлады исә, барыбыздан да арттыра ул. Аны безнең частьта кулланыла торган тастымалдай озын кәгазь тасмага бер утыруда гына язып бетерә алмыйча, берничә көн утырып, хатның озынлыгын берничә метрга җиткерә яза иде.

Минем: “Нәрсә язасың шулкадәре?”,—диюемә. —“Э, э, Имамов, ни черта ты в любви не понимаешь, а это брат такое чувство, такое…, Жив останусь, обязательно только на ней женюсь”,—ди дә, армиягә китәр алды көннәрендә үзе белән кызы арасында булган мәзәкле хәл турында, инде ничәнче мәртәбәләр түкми-чәчми сөйләп бирә.

“Без күршедә генә торабыз. Ул миннән өч яшькә олы. Олы булса да бергә үстек. Минем үзенә гашыйк булганлыкны белә, шаярткалый да иде. Ул көнне мин, кая барып бәрелергә дә белмичә, моңсуланып йөрдем. Йөрдем дә, күрәсең, шушы хәлне очратасы булгандыр, кереп, күреп, бәлкем саубуллашуым да шул булыр, дидем дә киттем. Бардым, ишекләрен шакыйм, дәшүче юк. Кире китәсем килмәде, ишекләрен тарттым, ачтым. Тупсаларыннан үтүем булды, күрәм: өйдә кыз бер үзе генә. Кулларын баш астына куеп, күзләрен йомып сәкегә сузылып яткан. Керүем булды: “Вася, это ты? Садись”,—ди. Бардым, утырдым. Мондый итеп мин аны моңарчы бер дә күргәнем юк иде. Тәне бөтен барлыгы белән шундый рельефланып күренеп тора, өстендә күлмәге юк диярсең. Олы күкрәкләренең башлары күлмәген күтәреп, тишеп чыгардай булып тырпайганнар—алмаз, бриллиантмыни, шундый матур, шундый ыспай, шундый күркәм. Күземне йөгертеп чыгуым белән тәнемне ток суккандай булды. Матурлыгына, гүзәллегенә соклануымнан хәтта күз яшьләрем бәреп чыкты. Мондый хис-тойгыларны минем беренче мәртәбә кичерүем иде. Күпме вакыт үткәндер, һәрхәлдә миңа ул бик озак кебек булып тоелды. Ул да дәшми, мин дә. Ни дип әйтергә дә, нәрсә эшләргә дә белмим. Нигә кергәнлегемне дә оныттым, телемне йоттым кебек. Шулай да күзле бүкән түгел бит. Утыра торгач, әкрен генә аягына, андый-мондый уйдан түгел, кулымны тидердем, дәшми. Шулай бераз сыпыргаланып утырганнан

соң, кулымны чак кына тагы да өскәрәк этәрдем. Бу юлы да дәшми. Бара торгач, башыма… бәлкем ул: "Нәрсә сыпырынып утырасың, кулыңнан килә икән", дип уйлыйдыр дидем дә, салкын суга чумарга җыенган кеше кебек, гайрәтләнеп китеп, тиз генә әзерләнеп, аның күлмәген күтәреп, аякларын аера башлап, инде булды гына дигәндә… Сизми дә калдым, кушаяклап (айгыр теләмәгән бия кебек) типте ки, киттем дөбер-шатыр тәкмәчләп идәнгә. Ә ул, ишетәм, берни булмаган кебек, шундый тыныч, йомшак куллары белән бәрелгән урыннарымны сыйпыймыни, ягымлы тавыш белән: "Вася, ты не ушибся, ну как, посмотрел, понравился?"—ди. Мин кая ди аны-моны сөйләнеп, уйланып торырга. Ашык-пошык тугарылган нәрсәләремне эләктерәм дә тизрәк таярга. Җир тишеге булса? Бөтен китәр алды көннәремдә, әгәр дә иптәшләр белеп калсалар, ояты гомерлеккә, дип куркып йөрдем. Ярый әле, беркемгә дә сөйләмәде. "Исән кайтсам, барыбер аңа гына кияүгә чыгам",—дип кабатлар иде дә, хатларын язуын дәвам итәр иде.

Хатлар язу гына түгел, без аларны алабыз да, кайберләрен күмәкләшеп укыйбыз, үзебезнең аңлау дәрәҗәбезгә ярашлы алар турында гапләшеп тә ала идек. Әйбәт хәбәр килсә, шатланышабыз, авырына кайгырабыз. Кайчан бетәр икән бу сугыш, диешеп фараз кора идек.

Күңел төшенкелегенә бирешмәскә тырышабыз. Сугыш шартларында солдатның рухи торышы икенче дәрәҗәле нәрсә түгел. Төшенкелеккә бирелгәннәр булса, аларны кул белән дә, тел белән дә эткәли-төрткәли, үгетләп тә җанландырып җибәрергә тырыша идек (мондый шаяруларны без "заводить" дип атый идек).

Актив ял итүчеләр, хат язучылар рәтенә кермәсәм дә, минем дә эшем юк түгел. Теге вакыйгадан соң да мин велосипедымны ташламадым. Күңегүем соңрак бик тә кирәк булып, күрше егете кордашым, иптәшем—Әхмәтшин Закир белән очрашырга сәбәпче булды.

Чираттагы шундый буш вакытларның берсендә кылтыр-кылтыр Гросс Тракенин урамнарыннан чыгып бара идем, аркаларына карабиннарын, иң башларына балталарын салган, билләренә аркылы пычкыларын уратып бәйләгән, сафлары бигүк төгәл булмаган бер төркем солдат каршыма килә. Беренче күз ташлавым булды, алгы рәттә таныш йөз күзгә чалынды. Текәлебрәк карасам… "Закир!"—дип кычкырып та җибәрдем. Миллионлаган солдатлар арасында, фронтта, сугышта үзеңнең бергә үскән иптәшеңне очрату нинди шатлык: авылыңа, өеңә кайттыңмыни. Ул да мине күреп калган икән. "Товарищ командир, односельчанин",—диде дә тиз генә миңа таба атлады. Кочаклашып күрештек. Бу минутларда: "Кайда, кем, ничек, кайчаннан бирле", кебек сораулар белән алышырга да өлгерәбез.

Мин велосипедымны борам да, без бергә атлый башлыйбыз. Юкка гына кабаланганбыз икән. Ул үзенең саперлар батальонында хезмәт иткәнлеген әйтте. Бу авылга тимерчыбыклы киртәләр ясау өчен агач әзерләргә киләләр икән. Алар хәтсез генә булып, Закир белән бер татар абзые без торган йорт артына ук туктап, эшкә дә тотындылар. Армиягә китәр алды көннәрендә таза гәүдәле, һәрвакытта да көр күңелле, көләч йөзле Закир, чүкмәсә дә—ябыккан, каралган, арыган, йончыган кебек күренде миңа. Өстәвенә туп ярчыгы тиеп аның уң кул сырты да яраланган икән. Минем соравымны да көтеп тормастан, үзе сөйләп бирде. Яраланганына икенче ай икән, хәзер аруланып бара. "Госпитальгә дигәннәр иде дә, мондый яралар белән барыбер авылга кайтармыйлар, аннан чыккач, кайда җибәрәләр әле, ә монда мин инде күнеккән, иптәшләремне калдырып китәсем килмәде, бармадым",—диде. Аның белән бергә эшләгән, күкрәге берничә орден-медаль белән бизәлгән, олы гына яшьтәге татар абзые (ул Бөгелмә якларыннан булып чыкты): "Менә фашистларны бетергәннән соң, бөтенләй дә кайтырбыз, исән калуың гына кирәк",—дип сүзгә кушылды. "Ә сез күптәнме фронтта?",—дигән соравыма: "1941 елның октябрь аеннан, Мәскәү кырларыннан, шушы батальонда, диде. —Мәскәү янындагы 600 кешедән өчәү генә исән калдык, исән йөрибез. Алдагысын Ходай белә".

Ул көнне Закир белән без көн буе бергә булдык. Хәтсез генә үзебезнең авыл тормышыбызны, иптәшләрне, яшьлек елларыбызны искә төшереп, аңгәмәләшкәннән соң Закир миңа: "Мөҗип, мин ранен булганчы ук Канбәк кызы Т...дан хат алган идем, эшләр болай булып киткәч, җавап яза алмый калдым, мин әйткәләп торырмын, яз әле син аңа хат",—диде. Ул сул кулы белән пычкы тарта-тарта әйтеп торды, мин яза бардым.

Кичкә миңа Үзәк станциядә дежурга иде. "Китмәсәгез, иртәгә дә очрашырбыз",— әле дигән идем дә, барып чыкмады. Төнлә алар безнең кырдан киткән булдылар. Моңсу булып калды минем күңелгә.

Белмим, татар абзыебыз исән калып, җиңү тантанасын күрә алгандырмы, юкмы, Закир юк. Рейхстаг өстендәге җиңү флагын ул күрә алса да, сугыш бетү тантанасын күрә алмый. Инде җиңелгән Берлин урамнарын миналардан тазартып йөргәндә, 3 майда Закир һәлак була.

Яңа ел җитеп, һөҗүм сугышлары башланып киткәнче, безнең Гросс Тракениндагы тормышыбызда, әллә ни күренекле вакыйгалар булмады. Тик көзге, кышкы көннәрнең начарлануы кыенлыклар тудырды. Кар катыш яңгырлар ешайды, салкын җилләре көчәя барды. Безнең йортыбыз түбәсендә санинструктор кызыбызга да урын табылды, дигән идем. Командованиенең аны шулай хәстәрлекле итеп аерым бүлмәгә урнаштыруын без хуплап каршы алган булсак та, көннәр үтү белән аның өчен бу бүлмәнең тозакка әйләнгәнлеген аңлый башладык. Санинструкторның монда килеп урнашуы була, дивизионыбызның штаб начальнигы белән аның ярдәмчесе, икесе дә бер чама яшьтәге, таза гәүдәле матур егетләр, берсе артыннан икенчесе килеп йөри башладылар. Көндәшләр кебек, алмаш-тилмәш, берсе килә, берсе китә. Билгеле, алгы сызыктагы үзгәрә барган стратегик, тактик обстановка турында фикер алышу өчен түгел инде. Тәүге көннәрне санинструкторыбыз ныклы гына тора алса да, көн артыннан көн, төн артыннан төн, тынгы бирмичә, йокламыйча, арытып, алҗытып бетәләр. Кайбер көннәрне кызыбыз алардан качып, безнең кырга төшеп утыра иде. 1945 нче елның яңа ел көннәрендә теләкләрен тормышка ашыру өчен иң гади, шул ук вакытта ышанычлы ысул—эчертеп-исертеп кызыбызны җиңәләр. Аның шулай булганлыгы турында кызыбызның атна буена бүлмәсеннән чыкмыйча елап ятуы, шешенеп беткән күз кабаклары әйтеп торалар иде. Бу хәл безнең өчен дә зур югалту булып, безнең бигүк якты булмаган фронт тормышыбыздагы бердәнбер якты нур сибеп торган йолдызыбызны кара болыт каплаган кебек тәэсир ясады. Моңардан соң без аның үзебезгә карата булган көләч йөзен күрү генә түгел, ул бездән көннән-көн ерагая барып, азак чиктә аның үпкәле йөзе: "Нәрсә миңа мәхәббәтегез, яклый алмагач",—диләр иде.

Аңа кереп йөргән офицерларның кайсысы (бәлкем, икәүләшеп тә) бу эшне эшли алгандыр. Ботыннан тотып тормагач, каян беләсең дә, төгәлләп кенә ничек әйтә аласың. Алсаң да, белсәң дә, кем аны сугыш шартларында тикшереп йөри. Фронтта югары чинлы офицерларның, шулар арасында безнең комбригыбызның да үз сөяркәләре бар чакта бит әле ул. Мондый шартларда синең шикаятеңә кемнәр игътибар итсен, итсәләр дә, ишетсәләр дә, хөкем итсәләр дә, шул, бер урын—передовойга: "Искупи свою вину своей кровью!". Шулай да без бу эшнең авторы штаб начальнигы ярдәмчесе, өлкән лейтенант Чижевский булгандыр, диештек. Ни өчен дигәндә, һөҗүм сугышлары башланып китү белән дивизион командиры капитан Волков, аны бер кирәкмәстән, алгы сызыктагы постларыбызның эшләрен координировать итәр өчен дип, кайнап торган ут эченә җибәрде. Постларыбыз тирәсенә барып та җитә алмый, янына төшеп ярылган туп ядрәсе аны эзләп табалмаслык итеп өзгәләп ыргыта. Шулай итеп, шәп матур егетебез, өлкән лейтенант Чижевский "искупил-таки свою вину своей кровью".

Мондый күңелсез хәлләр безнең дивизионда беренчесе дә, соңгысы да түгел иде. Гомумән, фронттагы хатын-кызларның көнкүрешләре ир солдатларныкына караганда күп мәртәбәләр авыр булудан башка, аларга әле тирә-яктагы күп санлы ир затларының— алар арасында кемнәр генә юк—сугышка кадәре семьялы булып яшәгәннәре дә, хезмәттә булып, өйләренә кайтырга өлгерә алмыйча сугышка китеп, күп еллар хатын-кызларны күрә, коча алмыйча, аларның күңел җылысына сусаган, рухый ярдәмнәренә, физик теләкләренә мохтаж ир урталары да, сугыш яланнарында үсеп җитеп, үзләре өчен хатын-кызларның нәрсә икәнлекләрен беләсе килгәннәре дә—һәр тарафлардан корбанына ташланырга әзер торган ач бүре кебек, үзләренә юнәлтелгән урынсыз таләпчән күз карашларын даими тоярга туры килә иде. Безнең очрактагы кебек дорфа, комсыз, дәгъвале тел, кул һөҗүмнәренә дә каршы тору аларга бик кыен булгандыр. Ә бит аларга физик көчтән тыш, күп мәртәбәле рухый көчкә дә ия булырга кирәк иде. Көн саен үлем белән тормыш арасында яшәгән чакта—әллә үләсең, әллә каласың, туры килгәндә файдаланып калыйм, дип фикерләүчеләрне истән

чыгармаганда, фронттагы хатын-кызлардан бигрәк тә нык чыдамлы булуларын таләп итә иде. Әгәр дә чынбарлыкка хыянәт итмик дисәк, күпчелек барыбер үзенекен эшли, максатына ирешә иде, дип әйтәсе килә. Шунысы да—фронттагы хатын-кызлар да бит шул ук адәм балалары, аларның да үз теләкләре юк түгел. Мондый очракларда ике якның теләкләре дә тап килгән очраклар да аз булмавы шул турыда сөйли. Барысына да ничек каршы тора аласың...

Дөрес, солдатлар арасында да (мисалга безнең Марияга булган карашларыбыз) күпләре фронттагы хатын-кызларның күп санлы басымнарга дучар булганлыкларын аңлый, аларны чын күңелләреннән кызганып, аларның хәлләренә керә белсәләр дә, аларга ачуланып караучылар да, бигрәк тә ачыктан-ачык командирлар белән яшәгәннәренә карата мыскыллап, ППЖ (походно-полевая жена) дип караучылары да юк түгел иде. Мондый карашлар солдатлар арасында гына түгел, офицерлар арасында да булгалады.

## Каты сугышлар барганда

Гросс Тракениндагы оборона вакытында, безнең фронт участогында әллә ни искә алырлык вакыйгалар булмады дисәк тә, фронт барыбер тик тә тормады, эшсез дә утырмады—позицион сугышлар дәвам итте, беренче, икенче эшелоннарга яңа көчләр килә торды. Аларны хәрби техника, башка фронт кирәк-яраклары белән тәэмин итү, тулыландыру эшләре дә тукталмады. Шушы мәшәкатьле эшләр арасында 1944 ел да үтеп бетеп, яңасы да килеп җитте. Ә без әле һаман да шул биләгән позициябездә утыра тордык. Бу елны, дөрес, безнең утыруыбыз әллә ни озакка сузылмады. 1945 елның 12 гыйнварыннан 13 енә каршы төнне иртәнге сәгать 4-5 арасында, бөтен алгы сызык буенча күп санлы туп көпшәләреннән ургылып чыккан, йөзләгән, меңләгән туп ядрәләре бер тоташтан дошман позицияләренә ябырылды. Шуны гына көтеп торган кебек, дошман тупчылары да безнең белән бер үк вакытта диярлек безнең позицияләребезне утка тота башлады. Берничә минуттан бөтен тирә-як мәхшәргә әйләнде, кемнең кайда атканын да, ядрәләренең кемнәрнеке, кайда очканлыклары да, төшкәнлекләре дә аера, аңлый алмаслык итеп бөтен фронт өсте, бер туктаусыз гүләп, кайный башлады.

Ул вакыттагы безнең 3 нче Белоруссия фронтында барлыкка килгән обстановканы масштаблы, ачык итеп күз алдына китерү өчен маршал А. М. Василевскийның истәлекләреннән бер өзек китерәм. "Начали наступление фронты успешно. Этому во многом содействовала сильнейшая артподготовка. Замечу попутно, что Восточнопрусская операция по расходу боеприпасов вообще не имела себе равных среди всех операций в истории войн. Два фронта получили 13,3 млн. снарядов и мин, 620 млн. патронов, 2,2 млн. ручных гранат. Только за 13-14 января войска 3-го Белорусского фронта израсходовали более 1000 вагонов основных номенклатур боеприпасов, а войска 2-го Белорусского лишь за 14 января 950 вагонов. Всего же оба фронта израсходовали более 15 тысяч вагонов боеприпасов. Для перегрузки их из вагонов и подачи в войска потребовалось (в расчете на 2,5 тонны автомашины) около 100 тысяч автомобилей".

А. М. Василевский. "Дело всей жизни". (М. Политиздат, 1974 ел. 479 б.).

"К 1945 году восточнопрусские укрепленные районы и полосы обороны со включенными в них крепостями, сочетавшимися с естественными припятствиями, не уступали по своей мощи западногерманской линии "Зигфрида", а на отдельных участках превосходили ее. Особенно сильно была развита в инженерном отношении оборона для нас направлении—Гумбиннен, Инстербург, Кенигсберг". (Шунда ук, 475 б.).

Бу һөҗүм сугышын без үзебез әзерләшеп, аның киләчәген көтеп алган булсак та, артподготовкабызның шундый көчле, масштаблы, шулай кинәт башланып киткәнен көтмәгән идек, тәүге мәлне чәчләребезне үрә торгызып, бөтен тәнебезне чымырдатып, хәзергә әле бигүк аңлашылып та бетмәгән борчулы тойгылар тудырды. Ләкин инде фронт кузгалган, һөҗүм сугышлары башланган, шәхси тойгы-хисләргә бирелеп, үзең турында уйланып торыр вакыт түгел. Артподготовка башлану белән, батареябызга "сняться с боевых позиций!" дигән приказ килде. Бу безнең үзәк станциядә эшләүчеләр өчен, һәрвакыттагы кебек, посттагы иптәшләребезгә ярдәмгә барырга, дигән сүз иде.

Без кулдашым сержант Раков белән батареябызның иң ерак, уң флангтагы беренче

постына йөгердек. Күпме мәртәбәләр мондый эшләрне эшләгән булсак та, кайнап торган ут эченә керергә кирәк бит. Безнең ул вакыттагы артык борчылуларыбыз, бәлкем, шуңа да булгандыр: уникесендә кичләтеп безнең бөтен группа дошман тупчыларының һөҗүменә дучар булып, бик әздән генә исән калган иде. Алдарак әйтүемчә, ул көнне кичләтеп фронтыбыз нидер вакытка тынып калган иде. Менә шушы мәлдән файдаланып калу ниятеннән, безнең үзәк станциядә эшләүчеләребез (Титков белән миннән башкалары) саф һавада берникадәр ял итеп, тәмәке тартып керергә диешеп сарай артындагы иң ышанычлы, тыныч дип йөртелгән спецмашинабыз янына киткәннәр иде. Күп тә үтмәде, моңарчы тыныч кына утырган станциябез эшли башлады, димәк… Титков миңа: —"Имамов, тиз генә малайлар янына, комбат күреп калса…"—диде. Мин дә йөгерә-сикерә алар янына бардым да: "Егетләр, тизрәк эшкә",—дидем. Ә алар: "Нәрсә, атмыйлар бит әле, тартып бетергәч",—диешәләр. Мин: "Аталар, комбат көтеп калды",—дигәч, кенә иптәшләрем, миңа ачуланып, мыжый-мыжый машинадан сикерешеп төштеләр дә, сарайның почмагыннан борылуга сарай кирпечләрен пыр туздырып, колак пәрдәләрен ертырдай көчле шартлау яңгырады. Сугышта йөрсәк тә, күп мәртәбәләр ут астында калган булсак та, бу кадәре якын көчле шартлау безнең барыбызны да ниндидер вакытка параличлаган кебек туктатып калдырды. Ай ярым вакыт эчендә бу якта мондый көчле шартлау булганы юк иде. Ни булды бу диешеп борылып килеп карасак, безнең спецмашинабызның рамы гына сераеп калган. Билгеле, бу вак-төяк ядрәнең эше түгел, кимендә 150 мм-лы гаубицаның эше иде. "Имамов, әл дә килдең бит, малай, югыйсә…" диешәләр иптәшләрем миңа соңыннан. Хәзер безгә аның аерым шартлаганы астына гына түгел, кайнап торган җиренә барырга кирәк иде.

Дөрес, бу артподготовканың тәүге залпларыннан соң, үз окопларыннан сикереп чыгып, ут яудырып торган дошман позицияләренә ташланучы пехотачыларның хәле белән чагыштырганда әллә ни куркыныч та, авыр да түгел кебек булса да, барыбер дә ут астында инде. Шунысы да: алга барганда безнең шәхси коралларыбыздан башка йөгебез дә юк, төгәл генә маршрутка да бәйләнмәгәнбез. Шулай безгә куркынычсызрак, чокыр-чакырлырак урыннарны сайларга, кирәк вакытында маневр ясарга да мөмкинлек бар. Шулай эшлибез дә—тынычрак, ышанычлырак, куркынычсызрак урыннарны сайлый-сайлый, йөгерә-атлый, бер төрле мажарасыз иптәшләребез янына барып җиттек. Ә менә кире якка, линияләребезне урый-урый кайтканда, бу өстенлекләр бетә генә түгел, адым саен җилкәдәге катушкалар авырайганнан-авырая бара, артында әле тагы бер катушка, кайберебездә икәү дә була. Үтәсе юлыбыз дошманның нәкъ утка тоткан өлешенә туры килә. Аның төп өлеше, калку гына урында булып, аңа алып бара торган ара хәтсез озынга сузылган битләү өлешен, без берничә мәртәбәләр туп ядрәләренең төшкәнлекләренә ориентир ясый-ясый, тәгәри-ята тора, элемтә линияләребезне урый-урый үтә алсак та, түбә өлешен ничек үтәргә соң? Мин алдарак, Раков арттарак. Бу куркыныч урынны тизрәк үтәргә тырышып, чираттагы артзалп килеп җиткәнче диешеп, йөгерешеп үргә менеп җитүебез була—мә сиңа: һава киңлекләрен шырлап ярып безнең өскә снаряд килә. Катушкаларымны җиргә атып бәрәм дә, аларны баш тирәмә тартып алып, җиргә сыланам. Туп ярчыклары фырылдашып баш өстеннән үтеп бетәләр… Исән икәнмен. Чираттагысы килгәнче дип, катушкаларны бәреп алдым… Бәй? Әле генә мондагы иптәшем—катушкалары монда, ә үзе юк, йөрәк "жу" итеп китте. Алай-болай дисәң, аның янында туп ядрәсе дә ярылмаган кебек иде. Кычкырам, йөгерәм, тирә-якны карыйм, эзләнәм. Үзе дә юк, тавышы да килми. Шигем арткannan-арта бара. Катушкаларымны калдырам да тиз генә кирегә, түбә астына йөгерәм. Без әле генә андагы бер ару гына тирән чокырны үткән идек. Өстенә басып егыла яздым: куллары белән колакларын каплап токтан да, йөз түбән чокыр төбенә чумган. "Раков, ты что тут, ранен что ли",—дим, ә ул: —"Что, обстрел кончился?",—ди. Менә шуннан соң бар инде син шундый иптәш белән разведкага гына түгел, гади задание үтәргә дә…

Без кайтуга башка посттагы иптәшләребез дә җыелышып беткәннәр. Фронт алга киткән. Алгы сызыктагы сугыш барышының гөрелдәү, гүләү тавышлары сизелерлек булып ераклашкан, тоныкланган, һөҗүм алып баручы частьларның тыллары да урыннарыннан купкан. Гросс Тракенинның бөтен тирә-ягын, урам эчләрен тутырып барысы да алга, һөҗүм алып баручы частьларга, иптәшләренә ярдәмгә, ялап алган яңа позицияләргә, аларны үзләштерергә, ныгытырга ашыгалар иде.

Нигәдер без генә, кабаланышып җыелышып беткән булсак та, кузгалмыйбыз. Барысы да алга омтылганда бу хәл бездә: нәрсә көтәбез, дигән сорау тудырса да, урыныбызда утырып калдык. Бу утыруыбыз хәтсез озакка сузылып, кышның кыска көне кичкә авыша башлагач кына батареябыз алга, яңа позициягә барырга дигән боерык алды. Бу вакытка фронт та, һөҗүмгә кадәр биләгән дугалы позициясен (без аның бу яклап нәкъ эчке түбәсе астында идек) турыландырып бетереп, ике як флангларын да хәтсезгә алга җибәрергә өлгергән. Ә без бу юлы да әллә ни алга да, ерак та китмибез, фронт турыланып бетеп кире ягына бөгелә башлаган өлешенә (бу юлы тышкы як түбәсе өстенә) барып, приказда күрсәтелгән урыннарыбызга тарала башладык. Урнашып бетеп, эшләрне уңайга салгач кына, без үзебезнең нигә болай башкалардан соңлабрак, моңарчы биләгән позициябездән артык ерак китмичә тукталып калуыбызның сәбәпләрен белә алмадык. Хәер, моның шулай булуы сәбәпләрен әллә ни уйлап, эзләп торасы юк иде. Без килүгә алгы сызыкта барлыкка килгән сугыш нәтиҗәләре, аларның юнәлешләре үзләре үк, хәзергә монда шәпләп алга китү каралмаган, максат итеп куелмаган, дияләр иде. Моның шулайлыгына дәлилләр дә юк түгел. Фронтның мондагы барлык хәлиткеч көчләре, шул исәптән безнең тупчыларның утлары да фәкать флангларга гына юнәлтелгән иде. Шул ук вакытта безнең алдагы көчләр дә бу вакытны тик утыралар, дигән сүз түгел иде әле. Киресенчә, артподготовканың башлануы белән, шуның ышыклавы астында алар да хәтсез генә алга китәргә өлгерәләр. Арытабан, һөҗүм көчләренең дошман территориясенә керүе тирәнәя, масштаблары арта, киңәя бара. Дошман көчләренең каршылыгы да артканнан-арта, ныгыганнан-ныгый барып, безнең пехота билгеләнгән рубежына барып җиттек дигәндә генә немецларның каты каршылыкларына очрап, күп кенә югалтуларга дучар булып, үзләренә ярдәмгә яңа көчләр килгәнче тукталып калырга да мәҗбүр була.

Без Гросс Тракениндагы йорт подвалларының ныклыкларына, куркынычсызлыкларына, аларның эшләү өчен уңайлыкларына шатланышып яшәгән идек тә, фронтның һөҗүмгә кузгалып китүе белән аларның үтә дә ныклы ныгытма булуларын татыдык. Алар безнең һөҗүм алып баручы солдатларыбыз өчен бер төрле кул кораллары белән дә вата, җимерә алмаслык әзер ДОТ, ДЗОТларга әйләндерелгән иде.

Бер мисал. Безнең килеп урнашасы авыл кырындагы бер йортның подвалында аталы-кызлы ике немец үзләрен су үткәргеч торбаларга чылбырлап-йозаклап беркетеп куеп (сугыш шартларында бу дөньядан ваз кичү дигәнне аңлата иде), дошманның мондагы оборонада торган төп көчләре авылны калдырып киткәннән соң да, икесе ике як подвал тәрәзәләре уемнарыннан кул пулеметлары белән безнең һөҗүм алып баручы пехотабызны берничә сәгать буена авылга кертмичә торып, аларга күп кенә зыян китерергә өлгерделәр. Бу хәлне ничек атарга? Аларны гаепләп буламы? Димәк, алар да үз иле, үз җире, үз йорты өчен сугышкан. Без бу хәлләрне белгәннән соң, аларның утка тоткан урыннарын карталарыбыздан да, болай да җентекләп караганнан соң,—"менә нинди урыннарда "фанатиклар", туа икән" дигән фикергә килдек.

Штурмлаучылар белән авыл арасы километр чамасы булып, аның тәүге җидесигез йөз метрлары түбәннән, текә булмаган үргә күтәрелә бара да, авыл йортлары янына 150-200 метрлар кала, авылга таба тагы бик аз гына яссулана төшеп, уч төбендәге кебек, һәр яктан күренеп торган тигезлеккә әйләнә. Күп калмаган, менәменә килеп җиттек, дигәндә ургылып торган ут авызына килеп бәреләсең.

Һөҗүмгә кадәр, тупчыларыбыз тарафыннан авыл йортларының торак өлешләре җир өсләреннән себерелеп бетерелгән булса да, аларның подвал өлешендәге ут алып баручы нокталарын, яннарына барып җитеп, ни белән булса да шартлата, яисә каплый алмасаң, —мондый очракларда солдатның үз тәненнән башка нәрсәсе булсын, — аларны туктата алмыйсың. Дөрестән дә, бу ике ут ноктасын авылны урап үтеп, ут алып барган йортларының подвалларына төшеп андагыларны кулга алгач кына туктата аласың. Бу сугыш эпизодының шулай булганлыгын белгәннән соң, безнең өчен иң гаҗәбе югалтуларыбызның күплегендә түгел, әзме андый югалтулар була, булачак та иде әле. Андыйларны, безнең солдатларны күпләп кыруларына карамастан, богауларыннан азат итәләр дә, исән-сау көйләренә тылга озаталар. Бәлкем, ул вакыттагы сугыш барышлары өчен ул шулай кирәк тә булгандыр. Дошманга каршы уңышлы көрәш алып бару өчен аның коралды көчләренең санын, мөмкинлекләрен белү генә җитми, безнең очрактагы кебек, халыкларның рухи халәтен белү кирәк

иде. Чөнки без бит әле аларның территорияләренә керә генә башлаган идек. Шундый өметсез, чаялы каршылык күрсәтүләренең мотивацияләрен белү дә кирәк бит. Алда әле әллә ниләр белән очрашасылар бар…

Яңа позициягә килеп урнашуыбыз белән, печән кибәненнән энә эзләгән кебек, без, гүләп кайнап торган сугыш яланнарындагы үз урыннарын туктаусыз алыштырып, күченеп торган дошман тупчыларының позицияләрен эзләргә, табарга, эзәрлекләргә тотындык.

Фронтның шушындый авыр, алгы сафлардагы солдатларыбызның бөтен төр сугыш коралларын ходка җибәреп, атна буена йөзгә-йөз, маңгайга-маңгай, күкрәккә-күкрәк килеп, канкойгыч каты сугышларда дошманга каты удар ясаганыннан соң, немец-фашист гаскәрләре, зур югалтулар белән позиция артыннан позицияләрен калдыра-калдыра, бөтен фронт линияләре буйлап чигенә башларга мәҗбүр булалар. Әгәр дә һөҗүм алып баручы көчләрнең югалтулары оборонада торганнарныкына караганда гадәттә күбрәк булганлыгын истән чыгармаганда, бу сугышларда безнең югалтулар да әз булмагандыр, дип уйларга кирәк.

Ул көннәрдә бу юнәлештәге сугышлар барышы турында үзенең истәлекләрендә маршал Василевский менә нәрсә яза: “К 18 января немецкие войска, несмотря на отчаянное сопротивление, потерпели тяжелое поражение в местах главных ударов наших армий и начали отступать от рубежа, постоянно вводя в бой свежие силы”.

*(А.М. Василевский. Дело всей жизни. Политик әдәбият нәшрияты, Мәскәү, 1974 ел, 479 б.)*

Шушы көннәрдән башлап без дә бер биләгән позицияләребездә озаклап тукталып та, оборонага кучеп тә тормадык. Фронтның алга китүе әкренәя барган көннәрдә дә безне тик тотмыйлар, тупчыларыбыз белән фронтның бер участогыннан икенче участогына, кагыйдә буларак, дошман көчләренең каршылыклары, оборона корылмалары ныграк булган участокларга җибәрәләр. Безнең өчен бу күчеп йөрүләрнең иң авыры—ул вакыттагы һава шартларының катлаулы булуы иде.

Балтик буйларында гыйнвар-февраль айлары күпчелек көннәрдә кар катыш яңгырлы булып, аяк аслары, юл өсләре күп санлы хәрби техника, машина, меңләгән кешеләрнең изү-таптауларыннан ватылып, җимерелеп бетеп, баскан саен аягыңны алалмаслык үзләнеп беткән мәтегә әйләнә. Менә шушындый юлларда йөри-йөри аякларың суланып, өшеп, тора-бара берни тоймас хәлгә килә. Хәрәкәттә булганга гына туңып бетмичә, бәргәләп-суккалап карасаң да авыртмас, зыңгылдап торган түмәрләргә әйләнә иде.

Мондый юллар синең өчен генә авыр түгел, техника төялгән машиналар өчен дә үтмәслек булып, үзең белән аларны да этеп-төртеп, сөйрәп йөрергә туры килә. Машина бара алмаса да, кеше бара, кеше чыдый, барырга, чыдарга тиеш. Кеше барса, башкасы да туктап калмый. Ә ял, йокы турында уйлаган юк. Алар булса да сирәк. Вакыты-вакыты белән, кайда эләксә шунда, анысы да йокы түгел, черем итеп кенә алу. Күпчелек шушы авыр, лашпыр-лошпыр, лач-лоч атлау тавышлары ритмына, күзе йомык килеш атлый. Приказда күрсәтелгән урынга барып җитсәң дә, туктап тору юк, алгы позициягә, эшкә. Кайда ул ял, кайда ул йокы...

Менә шушындый фронт буйлап күчеп йөрүләребезнең, ял итүләребезнең иң истә калганнарының берничәсе. Кагыйдә буларак, мондый күчеп йөрүләр төнләтеп, яисә бик иртә башлана торган иде. Гыйнвар азаклары, таң белән юлга чыктык. Көн буена—карлы яңгыр, көн урталарына өстебездә бер коры урын калса! Кичкә, төн җиткәндә, бер йорт, дөресрәге йорт кына да түгел, бөтен бер хуҗалык корылмалары белән тоташтан булган бинаның подвалына килеп керәбез. Нинди шатлык, Ходай Тәгалә безне җәлләгәндер: без килер алдыннан гына моннан пехотачылар киткән булган. Каян тапканнардыр—подвал идәннәренә салам җәелгән. Безгә нинди дер вакытка ял. Шундук салам өстенә авабыз. Күпме вакыт үткәндер, мин бер мәлне калтыранып уянып китсәм, бу ни? Карасам, без бөтенебез дә су эчендә ятабыз. Су, кайберләрнең авыз кырларына ук килеп җитеп, бүлкелди башлаган булса да, йоклауларын дәвам итәләр. Көндезге кар катыш яңгыр, кичкә яңгырга әйләнгән дә подвалның тәрәзә уемнары аша бөтен подвалны су баскан икән. Анда, нәрсә өчен булгандыр, зур чаннар бар иде, алар суда йөзеп йөриләр. Мин тиз генә иптәшләремне уяттым да, котелокларыбыз белән идәндәге суларны шул чаннарга тутырып, аннары чишенеп киемнәребезне боргалый-боргалый сыгып, корытып киенәбез. Без бу су

процедураларын бетергәнче, боевой порядокка басарга боерык та килеп җитте.

Сугыш аяусыз, тагы шушындый ук кучеп йөрүебезнең берсендә, көн буена җепшек кар төшкәләп торды да, төнгә каршы Балтик буйларыннан килгән салкын карлы буран бөтен тирә-якны каплап шытырдатып туңдырды. Таң белән безгә тагы юлга, яңа позициягә. Күп тә үтмәдек, ни булды? Башта аңламый да торабыз. Мондый хәл белән бер дә очрашкан да, андый хәлләрнең булганлыкларын белгән дә юк иде әле. Карана-карана торгач, ни күрәбез: кар астыннан берсенең куллары, икенчеләренең башлары, ботлары күтәрелеп, яландагы җыелмаган ашлык көлтәләре кебек, ялан тулы мәет. Күпме булганнардыр, әллә нинди позаларда катып калганнар. Яраланыпмы, үлепме, өшеп-катыпмы туңганнар. Акыл күтәрә алмаслык авыр тойгылар. Барлык көчебезне җыеп, тизрәк бу урыннан ерагракка ашыгабыз. Ни булса булсын, мондый гына язмыш булмасын, диешеп атлауларыбызны тизләтәбез.

Атна буена барган туктаусыз авыр, каты сугышлардан соң, гыйнвар аеның 19-20 нче числоларында, салкын җилле иртә белән немецларның бу юнәлештәге безгә каршы торган иң зур терәк пунктларының берсе булган Гумбиннен шәһәренә килеп керәбез.

Без керүгә, сугыш шәһәрдән хәтсезгә ераклашкан булса да, аның гүләү, гөрелдәү тавышлары, кайтавазланып, һаман да ишетелә иде әле. Без бөтен шәһәрне үтеп, төньяк чигендәге, тышыннан ук иҗтимагый икәнлеге күренеп торган матур бер бина кырына килеп туктадык та йөгерешеп эченә үттек.

Бинаның ишек як стенасы буенда дистәләгән пианинолар тезелеп киткән, идән уртасында пыскып яткан учак. Керүебез белән бер-беребезне эткәли-төрткәли аның өстенә кулларыбызны сузабыз. Ләкин җылысы… Тизләтеп кенә дөрләтеп җибәрергә иде дә бит, тирә-ягында ягардай бер нәрсә дә юк. Озаклабрак торган булсак, бәлкем, без аларны тапкан булыр идек тә, ләкин моның өчен түгел, иркенләп тәмәке тартырга да вакыт бирмиләр. Ничек итеп өшеп-катып шәһәргә килеп кергән булсак, шул ук хәлдә яңа позициягә чыгып китәбез. Чыгып киткәндә без тукталып торган бинаның (без аны балалар музыка мәктәбе булгандыр, дидек) бер почмагы, тирә-як урамнарын яктыртып, дөрләп яна иде. Эх, менә кайда җылынасы иде ул диешеп, шәһәрне калдырып киттек.

Сугышның шушындый авыр, фаҗигале күренешләре арасында да, шартлары туры килсә, юк-юк та, солдатларыбыз арасында Хуҗа Насретдин мәзәкләре кебек көлкеле-кызыклы, күңелләрне җанландырып, җиңеләйтеп җибәрә торган вакыйгалары да булмыйча да тормый иде.

Фронтта, һөҗүм сугышлары барышында аеруча, аларны уңышлы ясаучы фактларның берсе—вакыт. "Глазомер, натиск, быстрота"—монда олы хәрби шәхеснең истәлекле әйтеме генә түгел, сугышның объектив хакыйкате дә чагыла. Өлгерден—оттың, соңладың—бәясе исәнлегең, иң кимендә—уңышсызлык. Безнең өчен дә ул шулай иде. Ул көнне дә яңа позициягә күчәргә әмер булды, якын постлардан кайткан иптәшләребезнең кайберләрен яңадан ераграк посттагы иптәшләренә ярдәмгә җибәрергә кирәк иде. Алар арасында олы яшьтәге солдатларыбызның берсе (без аны болай да беркатлырак дип йөртә идек—эчендәге тышында), солдат Притворов яшь иптәше Лаптевка:

—Лаптев, син җитезрәк, бар әле минем урынга,—ди. Тегесе: —Бәй, нишләп мин барырга тиеш, әмер сиңа бит,—дип җавап бирә.

—Ул якта бик аталар бит әле, үтереп куюлары бар.

—Ах, сине үтереп куюлары бар, ә мине?

—Син җитез, үлмәссең, үлсәң дә әллә ни түгел, атаң белән инәң бер еларлар да бетәр, ә минем өйдә берсеннән-берсе бәләкәй дүртәү, минсез алар да бетәчәкләр.

—Ну и сволочь же ты, Притворов.

—Ну вот и оскорблять. Я от души, а ты что?

—Что, что, ты уже успел четверых наделать, а я еще девочек-то не целовал, а ты если умрешь?

Күп санлы сугыш яланнарының берсендә булган бу ике солдат иптәшләрем арасындагы диалог минем гомер буена күңелемнән чыкмас бер мәзәкле истәлек булып калды. Юк, Притворов үлмәде. Сугыш бетү белән, аны үзе кебек олы яшьтәге иптәшләре белән беренчеләрдән булып кайтарып та җибәрделәр.

Кызганычка каршы, "тизрәк-тә-тизрәк" принципы кайчагында үзен бик аклап та бетми генә түгел, бер кирәкмәгән югалтуларга да китерә иде. Гумбиненнан соң безнең

беренче югалтуларыбыз менә шушындый кабалануыбыз нәтиҗәсендә булды. Дивизионның элемтә начальнигы лейтенант Шереметов, үзенең бригада начальнигы капитан Иванов белән алдагы барасы авыллары немецлардан азат ителгән дигән хәбәрне алалар да, аның шулайлыгын үзләре тикшереп тормастан, машиналары белән авылның уртасына ук барып керәләр, ә анда немецлар китәргә җыенып кына торалар икән. Нәтиҗәдә ике офицерыбыз белән өч солдатыбыз дошманга бер төрле каршылык та күрсәтә алмыйча башларын салды. Ашыкканда да "җиде мәртәбә үлчәп, бер мәртәбә кис" кебек кирәк шул, күзең үткер, колагың тырпайып торсын, фикерләвең төгәл, җитез булсын. Ялгышлыкның, әлеге-баягы, бәясе бер нәрсә—үлем!

Икенче мәртәбә без бөтен дивизионыбыз белән шул ук хатаны кабатлап, бик әздән генә дошман позициясенә барып кермәдек. Төнлә эшләп утырдык та иртәләтеп—алга. Аларның шулай тизләтеп чигенүләренә без күнегеп тә бара идек инде. Хәзер гел генә шулай булырга тиеш, диярсең. Алда зур булмаган елга, аның аша киң генә озын күпер. Ярыйсы әле безнең бару ул кадәр кызу түгел иде. Күпернең уртасына барып җиткән идек, бу яктагы үзебезнең пехотачылар:

—Куда, назад—дип кычкыра башладылар. Күрәсең, мондый хәлне көтмәгән немецлар да тәүге мәлне безгә карата бер чара да күрми калды. Без тиз генә борылабыз да—артка. Немецлар эшнең нидә икәнлеген күреп калып, миномettан җибәрә башлаганнар иде дә, без ераклашып өлгердек. Шулай итеп, безгә дә бер мәртәбә булса да кабаланышып чигенергә туры килде.

Дөрес, "кто успел, тот съел" кебек кабалануларыбызның уңайлы очраклары да булмыйча тормый иде. Бер мәртәбә тәүгеләрдән булып без дуңгыз абзарына туры килеп, ару гына итле булып калдык. (Исегездәме "Чапаев" кинофильмындагы "На войне и поросеночек божий дар" дигән эпизод).

Икенче мәртәбә, дөрес, бу юлы мин бер үзем генә идем, чираттагы аерым заданиедән кайтып килә идем (заданиеләр турында алдарак), алда—хутор, керергәме-юкмы дип шикләнебрәк тордым да, кеше-фәлән юк кебек күренгәч, кереп каранырга булдым. Хуҗалык сарайлары ягында ниндидер тавыш ишетелгән кебек тоелды. Бардым, абзар эчендә биш-алты тавык, бер әтәч. Кемгә аларны калдырып китәсең? Тиз генә ППШ-дан шып-шып... Җыеп алам да, батареяга. Ләкин үземә тавык итләрен тәмләп карарга насыйп булмады—срочно яңа заданиегә.

Тагы бер мәртәбә эшне тизләтү өчен комбатыбыз, батареябыз сугышчан тәртипкә җыелып беткәнче, дип үзәк станциядә эшләүчеләребезнең берничәсен машинага утыртты да, картадан алдагы барасы урыныбызга, күз-колак булып кайтыгыз, чынлап та азат ителгәнме-юкмы, дип безне үзе күрсәткән урынга җибәрде. Безнең болай йөрүләребезнең төп сәбәбе—немецлар калдырып киткән позицияләрне белү, ныгыту, саклау өчен пехотаның җитмәвендә иде. Бу шартларда яңа позициягә күчкәндә, үзеңнең саклыгыңны, иминлегеңне тәэмин итү үз өстеңә күчә. Бу турыда безнең ул вакыттагы фронт командующие маршал А. М. Василевский болай язган: "До конца февраля шли напряженные бои... Советские войска несли серьезные потери. Резко сократился боевой состав частей, снизилась ударная сила фронта. Пополнение почти не поступало, так как Советское Верховное главнокомандование по-прежнему все усилия направляло на берлинское направление". *(Шул ук хезмәт, 487-488 битләр)*

Барсак, карыйсы урыныбыз күккә ашып торган карагай урманы эчендә. Кай яклап карасаң да, күренмәслек озын бер сарай, кырында бер йорт, тирә-ягында беркем дә юк, сарайның капкалары ачык. Эче машина белән кереп йөрерлек, без шулай итәбез дә. Нинди төрле продуктлар гына юк монда, барысы да машиналап төярлек. Шик тә юк, бу немецларның фронтмы, армияләренеңме продукт склады. Тиз генә ящикланган ит консерваларын машинага тутырдык та, сыра мичкәсе кебек кранлы мичкәләрнең краннарын ачып агызып карасак—шәраб. Мичкәләр машинабызның ишегенә сыймый. Бортларына бәйлибез дә тизрәк таярга. Көт тә тор, хәзер тыловиклар килеп җитәчәкләр, алар бу складның барлыгын белмичә булмас. Дөрестән дә, складтан чыгып бераз китүебез булды, алар да безгә каршы килә. Әле дә туктап-нитеп тормыйлар. Шәрабның бер мичкәсеннән батареябыз ару гына авыз итеп калды, ә икенче мичкәсен дивизионыбызның хозвзводына тапшырырга туры килде.

Тагы бер мәртәбә монысыннан да зуррак складка очраган идек тә, ләкин нәтиҗәсез.

## Верховный рәхмәте

Шулай, сугыш барышында юк-юк та солдатлар өчен уңайлы, табышлы мәлләре дә булмыйча тормый иде. Ләкин болары аның очраклы гына булып, көндәлек фронт тормышында—салкын җил, җепшек кар, быкылдап торган аяк асты, юеш кием. Кайчак үзәк станциябезне урнаштырыр өчен дә урын табып булмый. Тапсаң да, ниндиләре генә булмый, ниндиләре генә очрамый.

Февраль башы, юнәлеш Прейсиш Эйлау шәһәренә таба. Ачык ялан. Безнең алда бердәнбер, барлыгы 12-15 кв. метр чамасы булыр, будка кебек бер корылма. Янына барып туктыйбыз. Нәрсә өчен төзелгән булгандыр, тирә-ягында моңардан башка берни дә юк. Стенасы көймәләп эшләнгән, түбәсенең калынлыгы... Бер метр ук булмаса да, ким дә түгелдер. Турыдан-туры снаряд барып тисә дә бирешерлек түгел. Түрге зуррак өлешендә авыл мунчасыныкы кебек бәләкәй генә тәрәзә. Алгы сызыктан мишень кебек күренеп торса да, ачык ялан урында үзәк станцияне урнаштыру өчен моңардан да яраклырагын да, куркынычсызрагын да каян табасың. Комбатыбыз: “Занять”,—ди. Ишеген ачып җибәргән идек, мондый нәрсәләрне күрербез дип һич тә көтмәгән, башка да килмәгән, тәннәрне чымырдатырлык, күңелләрне болгатырлык чирканчык күренеш. Һәр вакыттагы кебек, немецларга гына хас метеклелек белән иләннән түшәмгә кадәр әйбәтләп берсе өстенә берсен җыйнак итеп киштәләп өеп куелган немец солдатларының туң мәетләре. Эчке зур бүлмәсе буш булып, чирканырлык ис-фәлән дә булмагач, станциябезне эчке бүлмәсенә кертеп урнаштырдык. Постка китәсе линияләрне тәрәзәсе аша суздык. Безгә монда берничә көнгә тукталып торырга туры килде. Бик комфортлы булмаса да, җил, яңгыр, кар астында түгел инде.

Гумбиненны алгач, безнең барыбызга да, Верховный главнокомандующий И. В. Сталинның 1945 ел 19-21 гыйнвар приказы белән “За отличные боевые действия”, дигән рәхмәт хатын тапшырдылар.



УЧАСТНИКУ БОЕВ В ВОСТОЧНОЙ ПРУССИИ

тов.

Приказом Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза товарища СТАЛИНА от 10 февраля [illegible] года за № 272 войскам, участвовавшим в боях за овладение городом [illegible] ЭЙЛАУ, объявлена БЛАГОДАРНОСТЬ за отличные боевые действия.

КОМАНДИР ЧАСТИ

Гумбиненнан соң туктаусыз барган сугышларда гыйнвар да үтеп, зур булмаган Домнау, Домтау шәһәрләрен, күп кенә эрелеваклы авыл, хуторларын артта калдырып, февраль башларында Прейсиш Эйлау шәһәре каршысына килеп чыктык. Тарихи урыннар. Белүебезчә, монда Русия солдатларының беренче мәртәбә генә булулары түгел. 1802 елны алар үзләренең Балтика буе союздашлары белән фәкать шушы урында “җиңелмәс” Наполеон армиясенә көчле отпор биргәннәр. Югалтулар тигез булмаса да—французлар 20 мең, русиялеләр 30 мең гаскәрен югалтканнар. Наполеон бу сугышта җиңү яулый алмыйча, үзенең көнчыгышка омтылуларыннан тукталып калырга мәҗбүр була. Үзебезнең белүебездән башка, бу турыда безгә политхезмәткәрләребез дә сөйләделәр, безне элекке вакыттагы рус солдатлары кебек батырларча сугышырга өндәделәр. Без дә сынатмыйбыз булса кирәк, 10 февральдә Прейсиш Эйлауга кердек.

Февраль ае сугышларының минем өчен иң истәлеклесе— үзебезнең участогыбызда фронт командующие генерал Черняховскийның каты яраланып, һәлак булуыннан соң фронтның яңа командующие маршал Василевский кырында булып, аны күрүем. Бу бер истәлек булып калды.

18 февраль, төньяктан туктаусыз салкын җил исә. Без зур булмаган елга каршындагы тирән генә чокырда. Моннан километр чамасы артта безнең Канбәк авылы янындагы Олы түбә кебегрәк түбә. Аның уртасында шпильле ике этажлы матур ялгыз йорт. Тирә-якларында—җәелеп яткан басу, яланнар. Иртәнге сәгать 7-8 тирәсендә бездән бер километр чамасы сазлыграк урында ике яктан да бик күп танк

катнашында каты сугыш булды. Шул ук вакытта диярлек безгә зур бер чокырда мунча оештырганнар иде. Бу истә калган беренче һәм соңгы фронттагы юынуыбыз булса кирәк. Сәгать уннар тирәсендә бирегә әле генә булып үткән танк сугышында командующий үзе танкка утырып сугышта катнашкан да, шунда каты яраланган, дигән хәбәр таралды. Кичкә аның үлүе турында әйттеләр, авыр тәэсир итте безгә бу хәбәр— командующийлар да үлгәч, безгә ни сан, дибез. Аның безнең янда гына булуы бу тойгыларыбызны көчәйтә генә иде. Без аны үзебезчә ихтирам итә, аның ике тапкыр Советлар Союзы Герое, яшь булуы белән горурлана идек.

20 февраль. Ул көнне мине иртүк бригадабыз штабына карта алып кайтырга җибәргәннәр иде. Мин кайту ягында киң асфальт юл. Фронт хәтсез алга киткән, тирә-як тыныч, берүзем атлыйм. Кайтасы урынга өч-дүрт километр калган иде. Көтмәгәндә фронт линиясе өстендә өч звено үзебезнең штурмовиклар күренде. Мин, үзебезнекеләр булгач, андый-мондый нәрсә булыр дип уйламыйм да, башны күтәреп аларга карый-карый атлавымны дәвам итәм. Бәй, миңа ерак та калмый, минем якка пулеметтан сиптерә башладылар. Әле дә юл кырларында окоплар күп икән. Мин куркуымнан да, аптырап та тиз генә шуларның берсенә сикердем. Самолетларның берничәсе, шулай минем якка пулеметлардан очередь биреп, борылып китеп тә бардылар.

Хәзер инде мин мондагы тынычлыкка бик ышанып бетмичә, окоптан чыгып, карана-карана атлый башлаган идем, тагы бер көтмәгән хәл—минем барган юл "Г" хәрефе кебек булып, аның бер өлеше урманга кереп китеп, икенче өлеше ачык урыннан фронт ягына сузыла иде. Мин аның озынаеп киткән өлешеннән атлый идем, кыска урман өлешеннән башта бер бронетранспортер, аның артыннан, безнең комбригның "Виллисы" кебек кенә түгел, зур җиңел машина, аның артыннан тагы бронетранспортер. Фронтта нинди генә техника, машиналарны гына күрмәгән—үзе бер могҗиза. Бронетранспортер минем янга килеп җиткәч тә, мин һавага күрсәтеп андагы кешеләргә: әле генә бу җирләрне безнең "Ил-4"ләр утка тотты, дип сөйлим. Алар мине ишеткәннәрдерме, юктырмы—җавап булмады. Шушы урында юл ныклы гына ватылган булып, бронетранспортер чак кына миннән үтә бирде дә, аның артындагы иң зур җиңел машина минем янда туктады. Карасам, алдымда погонының яртысын зур йолдыз каплаган, соры каракүл якалы җылы шинельдән—маршал. Анымоны уйламыйча гаҗәпләнеп калганмындыр инде, алар кузгалып киткәнче баскан җиремдә кузгалмыйча карап тордым. Ул да миңа әйләнеп карап алды. Маршалыбыз миңа бик карт кебек күренде. Уң ягында, күз кырында ук диярлек зур миң.

Машиналар кузгалып киттеләр дә бераздан тагы тукталып калдылар. Мин тагы—алар янына, 19 яшьлек егет бит—күрәсем килептер инде. Янына барып җиттем генә дигәндә, "цап" минем якадан берәү эләктерде. Әйләнеп карасам, минем кадәре ике гәүдәле капитан: —"Ты куда, сержант?"—ди. Мин: —"Хочу посмотреть на маршала",—дим. —"Ты же уже смотрел",—ди. Болай тавышы ачулы кебек түгел, шуңадыр мин кыюланып китептер инде: —"Товарищ капитан, нельзя ли с Вами мне еще 3-4 километра в этом направлении",—дим. —"Нет, нельзя,—ди,—вон ты какой шустрый, добежишь"—диде дә китеп бардылар.

Яңа фронт командующие маршал Василевскийны күрүемнән җанланып китеп, кайтып җиткәнемне дә сизми калдым. Иптәшләргә үземнең ничек фронт командующие белән очрашуым турында сөйләргә кирәк бит.

Еллар үтеп, олагаеп беткәч кенә аңладым: ул вакытларда ук мондый олы шәхесләрне җирдә генә саклап, озатып йөрмәгәннәр, һавадан да саклаганнар икән.

Фронт юлларында шулай, адым саен булмаса да, син көтмәгән нинди генә мажаралы хәлләр очрамый иде. Февраль азакларына Көнчыгыш Пруссия җирләренә үтеп керүебез хәтсезгә тирәнәйгән иде. Бу вакытта Гумбиннен, Прейсеш Эйлау шәһәрләре яулап алынып, алар артыннан дистәләгән авыл, күп санлы эреле-ваклы хуторларны да артта калдырып үткән булсак та безгә бу юнәлештә, бер карт белән бер кыздан башка, немецларның хәрби булмаган кешеләрен очратырга туры килмәде.

Бәлкем, бу юлы да без аларны ("аларны" диюем, хәзергә сүз ике балалы немец хатыны турында гына) күрми дә, күрсәк тә игътибар итмичә үткән булыр идек, әгәр барган җиребездән, нидер сәбәпле юлыбызда тукталып калмаган булсак. Без тукталган урыннан ерак та түгел ялгыз йорт, йорт кырында бер төркем безнең пехотачылар, баш очларында кулларын болгый-болгый нидер кычкырышалар. Башта без аларны нигә, нәрсә өчен кычкырышканлыкларына бик игътибар итеп, ишетеп, аңлап та

бетмәгән булсак, ничектер аларның бик табигый булмаган кыланышлары игътибарыбызны җәлеп итмичә калмады. Нәрсә кычкырышалар икән, дип игътибар белән тыңлап карасак, араларыннан берсе ачык итеп, беренче мәртәбә генә түгелдер: "До Берлина мы их всех пере…"—дип кычкыра. Хәзергә безгә бу янауның анык кына кемгә, нәрсәгә булса юнәлгәнлеге билгеле түгел иде әле. Моны ишетеп калган взвод командиры лейтенант Щербатенко гына: —"Ребята, тут что-то не то, а ну-ка за мной",—диде дә китте. Без аның артыннан. Бу сүзнең мәгънәсе безнең өчен дә шомлы кебек тоелды. Барсак, дистәләгән исерек солдат. Сафлары бик төзек, тигез булмаса да, артлы-алды тезелешеп басканнар. Алардан берникадәр читтәрәк (күрәсең, чиннары югарыраклыктан беренчеләрдән булып эшләрен бетергән булганнардыр), яшь кенә кече лейтенант белән старшина. Алдыбызда гыйбрәтле тамаша: күлмәк итәген башына әйләндереп салганнар да, өй нигезенә терәп куеп… Бу күренешнең иң шаккатарлыгы моны "эшләүләрендә генә дә" түгел иде әле. 6-7 яшьләрдәге ир бала белән 4-5 яшьләрдәге кыз бала, икесе ике яклап әниләренең кул башларына ябышканнар да, куркуларыннан күзләре чыгардай булып, катып калганнар.

Лейтенант Щербатенко кызулап килү уңаеннан чираттагысын тибеп очырды да тәкмәчләп киткән солдатка тагын берничә мәртәбә өстәп алырга да өлгерде. Моңардан соң безгә дә команда кирәк түгел иде инде. Белмим, безнең бу башбаштаклык ни белән беткән булыр иде—барыбыз да бит кораллы—ул арада комбатыбыз өлкән лейтенант Тихонов белән килгән дивизион командиры капитан Волков үзенең һәрвакыттагыча ачулы, кискен адымнары белән килеп җитүгә үк: "Прекратите, что такое, в чем дело",—дип кычкырып җибәрмәсә.

Лейтенант Щербатенко:

—Товарищ капитан, менә бу солдатлар балалары алдында …әниләрен чиратлап,—дип немкага төртеп күрсәтте. Ә немка итәгенә ябышкан балаларын кочып алган… Күзләрендә бетмәс курку. Капитан Волков ачуыннан нишләргә дә белмичә:

—Кто старший, кто такие, откуда? Хотя всех вас растрелять бы, да некогда,—дип кычкырды.

Белоруссиядә шушындый ук хәл өчен ике солдатны атканнар иде инде.

Сорашып, тикшереп бетми, лейтенант: "Возьмите машину, сопровождающих, оружие у всех отобрать и в штаб бригады, в особый отдел. Доложите! Где санинструктор? Пусть женщину—приводит в порядок, их тоже туда, нельзя их здесь оставлять"—диде дә, безгә команда бирде: "По машинам". Күңелләрдә ачу: "Менә сиңа освободители Европы". Хәер, и "семья не без урода", диләр мондый чакта.

Дивизион командирының: "Нельзя их здесь оставлять" сүзе, берничә көннән хак булып чыкты: юл буеннан ерак та түгел яшь кенә бер хатынмы, кызмы булгандыр, атып киткәннәр. Вәхшилек бу очракта да атып китүләрендә генә түгел иде әле. Моны белеп калган әлеге хатын-кызга мөкиббән өлкән сержант Ковалев ни арададыр аның янына барып, чишендереп, 5-6 кат күлмәк, шул кадәре үк ретузы, лифчикларын да салдырып, бөтен җирен карап килгән иде.

Беренче мәртәбә безгә (берничә йөз—күпчелек хатын-кыз, яшьүсмер, бала-чага юк диярлек) имин кешеләрдән торган колоннаны Кенигсбергка якынлашып килгән көннәрдә генә очратырга туры килде. Тазалардан берничә кеше генә булып, алары 100 яшьләрдән дә ким булмаган, нидер мыгырдый-мыгырдый барган картны носилкага утырткannар да, күтәреп киләләр. Безнең янга килеп җиткәч, тукталып калдылар. Карт белән носилканы җиргә куеп, картка төртеп күрсәтеп, нидер сөйли, әллә сорый башладылар. Безнең вычислительләр взводы командиры лейтенант Шайнер немецчә белә иде. Ул аларның сөйләгәннәрен тыңлап торды да, ачуыннан кызарынып, бүртенеп бик каты аларга кычкыра башлады. Тегеләр җирдәге носилкада мыгырдап утырган картны тиз генә күтәреп алдылар да колонна артыннан киттеләр. Лейтенантыбыз бераз тынычлана төшкәч: Бабалары акылдан язган, атарга сорыйлар, ди. Сезнең үзегезне атарга кирәк, бик таза күренәсез, сугыштан качкан "СС"лардыр әле сез дигәч, бик тиз кире кузгалдылар,—диде.

Бара торгач, салкын кышның кар катыш яңгырлы, буранлы көннәре дә үтеп бетеп, март ае да килеп җитте. Көннәр озайганнан-озая барды, кояш та солдат өс-башларын киптереп, аяк асларын да корыта төшеп, текәрәк тә, жылырак та карый башлады. Җир өсләрендә тәүге яшеллек күренде, тын алулары иркенәйде. Фронт, алгы сызык, сугыш барышы гына, зур авырлыклардан басыла барган пружина кебек,

тыгызланганнан-тыгызлана, эчке торышы да куерганнан-куера бара кебек тоела иде. Пехотачыларның артканлыклары бик үк күренеп бармаса да, хәрби техника хуҗаларының—танкистларның, тупчыларның, минометчыларның саны, һәр квадрат километрга исәпләгәндә, һәр көнне артканнан-арта барганы күзгә күренеп тора.

Моңарчы безнең күзгә дә күренмәгән, күренгәч тә солдатлар арасында "Иван Грозный" исеме алган (бәлкем, чыннан да ул шулай аталгандыр да), гаять көчле реактив җайланмалар да, безнең 122-152 мм. калибрлы тупларыбыздан күпкә зуррак, снарядлары катлаулы лебедка белән корыла торган 203 мм-лы туплар да алгы сызык буйларында күбәйгәннән-күбәя барды.

Аларның дошманга зыян китерү, оборона корылмаларын вату-җимерү мөмкинлекләрен күз алдына китерү өчен шундый факт китерәм: немецларның фортлары өсләренә төшеп ярылган снарядларының ярчыклары алгы сызыкны үтеп чыгып, үзебезнең алдагы постларыбызның яннарына ук килеп төшәләр иде.

Боларның барысы да Көнчыгыш Пруссияне, диңгез крепосте Кенигсбергны алу өчен, эчке һәм тышкы яктан да берничә кат уратып алынган тимер-бетонлы фортларын, алардан башка дотлы, дзотлы корылмаларын тар-мар итеп, Көнчыгыш Пруссия операциясен уңышлы тәмамлап, Берлин юнәлешенә юл алуыбызны тизләтергә тиешләр иде.

Безнең көчләр дә, сугыш барышы да көннән-көн куәтләнә барды. Дошманның чигенергә территориясе дә азая, кысыла бара, заманында безнең өчен афоризмга әйләнгән: "Позади Москва, отступать некуда", кебек аларның да чигенергә урыны юк: артта Кенигсберглары гына калган, аның артында—диңгез. Бу хәл аларның каршылыкларын тагы да арттыра, дошман тагы да усалрак була бара иде. Бу шартларда безнең һәрбер алга баруыбыз километрларга үлчәнми, бәләкәй генә рубежларны яулап алу да каты сугыш, күп югалтулар таләп итә иде. Безнең дивизион солдатлары дошман солдатлары белән турыдан-туры бәрелешләрдә катнашмаса да, барыбер безнең югалтуларыбыз да артканнан-арта торды. Немецларның сугышчан осталыклары турында язган идек инде. Бу очракта да алар үзләренең каршылык күрсәтү көчен киметмәделәр. Батареябызның оптика хезмәте сержантлары Гагарин белән Обозныйның стереотруба белән үзебезнең тупчыларыбызның утларына ярдәм иткәнлекләрен күреп, немецлар туры наводка белән бәрделәр. Аларны снаряд шул кадәре изгәләгән иде ки, сержант Гагаринны башсыз гына җирләргә туры килде.

Билгеле, дошман үзенең мондагы оборона позицияләренең стратегик яктан нинди әһәмияткә ия булганны яхшы аңлаган, электән ныгытылганнар өстенә әле дә оборона мөмкинлекләрен арттырырга, аны тагын да куәтләндерергә тырышалар иде. Коры җирдән генә түгел, диңгез якларыннан да.

Бу вакытта без аларның үзебезнең участокта булган барлык артиллерия нокталарын гына түгел, орудиеләренең нинди калибрлы икәнлекләрен дә белеп, координатларын үзебезнең тупчыларыбызга тапшырып, күпчелек вакытыбызны үзебезнең артиллерия утларын ярдәм итү белән мәшгуль идек.

Дөрес, монысы безнең дивизионны күпмедер вакытка аерым бер корпус карамагына биргәч булды. Көтмәгәндә корпус штабыннан ачулы приказ: "Кто такие, откуда стреляют? Немедленно координаты!" Аларның алгы позицияләренә моңарчы билгеле булмаган эре калибрлы берничә снаряд төшеп ярылган икән. Ә тупларның кайдан атканлыкларының тавышлары ишетелми… Аларга гына түгел, алгы сызыкта урнашкан безнең хәбәр итү постларына да. Ишетелмәсә дә, ишетелми, дип акланып утырып булмый бит. Приказ-приказ инде. Әле дә шунысы: аларның ату темплары, снарядларының төшеп ярылулары сирәк.Безнең алдагы постка, снарядларның төшеп ярылу вакытына карап станцияне эшкә җибәрергә дип боерык бирелде. Бу атулар Кенигсберг тирәләреннән дә, аның үзеннән дә түгел иде. Ул тирәләрдән булса, хәзер инде алар бездән ерак түгел, ишетелер иде. Димәк, ераграктан. Үзәк станцияне аларның шулай сирәкләп ату ритмына көйләп, эшкә тотынабыз. Маташа торгач, моңарчы безгә бер дә очрамаган, бик аз, беленер-беленмәс, озынаеп чыккан язма алабыз да, кирәк расчетлардан соң— планшетка. Ераклыгы шундый ки, бар карталарыбыз озынлыкларына сыймый. Ату нокталары чыннан да Кенингсбергны, Фриш-Гав култыгын да үтеп, Балтика диңгезендә үк булып чыкты—бездән 25-30 км-лар чамасы ераклыкта. Карталарыбызны теркәп, ялгап, менә шушы квадратта, дип координатларын корпус штабына бирәбез. Алар шундук—бомбордировщикларны

һавага... Без биргән координатлар дөрес булып чыккан, диңгездән аталар икән. Авиаторлар эшләрен бетергәч, безгә корпус командующие исеменнән тәбрикләү приказы килде. Бу вакыйгадан соң күп тә үтми, дивизионыбызның бер төркем сержант һәм солдатларын орден, медальләр белән, шулар арасында мине—сержант Имамовны да Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

Озакламый Кенингсберг! Март азакларына ул материк яктан тоташы белән камалып алынган иде инде. Аны көне-төне җирдән генә түгел, һавадан да утка тоталар. Конвейер системасында: ике моторлы бомбардировщикларның бер партиясе шәһәрне утка тотып, чыгып китеп, күмелеп тә өлгерми, артларыннан икенчеләре аларга алмашка килә. Аеруча төннәрен бомбардировкалау эффектлы күренә. Шәһәр өстенә яктырткыч фонарьлар элеп куялар. Алары шәһәр өсләрен яктыртып, уралышып-уралышып, яна-яна төшәләр. Ә өстә бомбардировщиклар. Чыннан да, эффект—җиңү фейерверкы мыни. Ләкин минем күңелдә тантана урынына—кайгы-хәсрәт. Шушы сугышлар барышында Бари абыйның һәлак булуы турында хәбәр алдым...

...Шул көннәрдә безне тагын яңа позициягә—Кенингсбергның көньяк-көнбатыш юнәлешенә (Риллауга каршы диярлек) күчәргә куштылар. Күчәргә булгач, мине әлеге карталар артыннан җибәрделәр. Минем болай йөрүем Гросс Тракениннан соң фронттагы икенче вазифама әйләнеп киткән иде. Яңа позициягә күчәргә булдымы, Имамов—давай штабка, югарыракка, ерагракка. Юллары да, вакыты, обстановкасы төрлечә була.

Мине болай йөртүләренең сәбәбе—үзгәреп торган ландшафтта ялгышмыйча ориентирлаша алуымдадыр, дим. Батареябызның хәтсез өлеше олы яшьтәгеләр, шәһәр кешеләреннән булып, аларда мондый сәләт чамалы. АИР мәктәбендә укыган чактан ук белә идем: яланга тактик занятиеләргә чыктыкмы, аеруча төннәрен, кайберәүләр көнчыгыш белән көнбатышны бутый, бәй, нишләп ул кояш бу яктан, кичә башка яктан чыккан иде түгелме соң, диючеләр дә була торган иде. Мин, үзебезнең таулы-урманлы, берсеннән-берсе күчә барган чокыр-чакырлы яланнарында, күп санлы күл буйларында, Дим тугайларында үскән малай, андый ялгышлыкларны ясамый идем. Бу юлы комбатыбыз задание биргәндә минем барасы штабның кайда урнашканлыгы хәзергә төгәл генә билгеле түгел, син аларны эзләп табарга, кичкә карталар белән монда булырга тиешсең, дип чыгарып җибәрде.

Көн буена бер урыннан икенче урынга, попутный машиналарга да утыргалый-утыргалый, күбрәк җәяүләп, полевой почта номеры буенча эзләп йөри торгач, кичкә кирәк штабны барып таптым. Мине кабул иткән майор—ничек, кайдан килдең, дип сорагач, мин картадан: менә шулай-шулай, дип күрсәткән идем, 60 километрлап, диде.

"Ә хәзер ничек кайтырга уйлыйсың?—диде дә, үзе үк алдындагы әле генә караган карта янына мине чакырып алды. —Күрсәт әле үзегез торган урынны. Шуннан соң ул мине үзләренең штаблары тукталган йортның болдырына алып чыкты да, тигез урындагы, еракта булмаган бер авылга күрсәтеп: "Менә шушы инде сезнең торган урыныгыз, моннан нибары алты километр. Ләкин бу ара тоташ сазлык, юл юк",—диде. Килгән юллардан тагын илле-алтмыш километр ураргамы? Моңа көч тә, вакыт та юк. Майор миңа карап торды-торды да: "Сержант, приказ сиңа, решай сам",—диде. Мин бераз уйланып тордым да (олырак яшьтә булсам, бәлкем, тәвәкәлләмәс тә идем, ә ул яшьтә...). Ә, ә, ни булса булыр, дидем дә озын гына таяк табып алып—турыга!

Авыл артына чыкканчы коры булды. Арытабан юлым юешләнгәннән-юешләнә барса да—ике-өч километрлап таягым белән төрткәли-төрткәли үтә алдым әле. Бәлкем, шулай гына булып торса, бер төрле маҗарасыз кайтып җиткән булыр идем, ә юк, алда уңга да, сулга да очы-кырые күренмәгән, биш-алты метрлап киңлектә булыр—канау. Таягым белән төбен капшап, төрткәләп карыйм, өсте су булса да, төбе куертма, каты җир барлыгы бер дә сизелми. Бу кадәре үткәннән соң, ничек инде кире борыласың, борылсаң да? Кояш батарга да күп калмаган, аннан төн. Канауның теге як яр кырында гына яфраклары чыгып яшелләнә башлаган бәләкәй генә каен куаклыгы. Карталарым төргәген ияк астына ук диярлек күтәреп беркетеп куйдым да бер аягымны күпмегә мөмкин булганча алга ыргылып,—канауга. Тиз-тиз генә, бөтенләй батып киткәнче, дип тырыша торгач, аяк төпкә, басарга ныклы урынга барып җитмәсә дә, атлау дисәң атлау түгел, йөзү дисәң йөзү түгел—алга барам. Маташа торгач, яр читендәге каен куаклыгына сузылып җиттем дә бик зур саклык белән,

өзелмәсә генә ярар иде, дип уң кулның баш һәм имән бармаклары белән бармак бите кадәр генә каен яфрагын эләктереп алам, шул ук саклык, урта бармак белән нәзек кенә ботагын да кулга тотам. Хәзер инде, бәлкем, батуын батмам, әмма ничек чыгарга? Аяклар тулысынча мәтегә кереп утырдылар. Куакка тотыныбрак тартып караган идем, куагым үскән җире белән селкенә. Ныклабрак тартсаң, бөтенләй куптарылып чыгуы мөмкин. Бәлкем дип, аякның берсен тартып алыйм дисәм, икенчесе ныграк бата башлый. Батам дип тик кенә торып булмый бит инде. Ничек тә булса бу пленнан ычкынырга кирәк. Күрәсең, ычкыныйм дип ныграк шыбырдый башлаган булганмындыр, тирә-якта беркем дә юк кебек иде дә... Көтмәгәндә: —"Стой, кто идет?",—дигән тавыш сискәндереп җибәрде. Йә хода! "Свои",—дим. Эчкә җылы кереп китте. Күрәм, карана-карана олы гына яшьтәге бер солдат—башта мине күреп тә бетмәде булса кирәк. "Где ты?",—ди. "Здесь",—дим.

Мине күргәч: "Их сержант, как ты сюда попал?—ди. —А если здесь были бы немцы? Здесь же до нас никого не было. Да и мы только-только прибыли".

Мин үземнең арттагы авылга күрсәтеп, аңа теге авылдан, алар артындагы авылга ишарә ясап, әнә тегесендә, дим. Ул арада икенче солдат килеп чыкты. Икәүләшеп мине тартып чыгардылар. Комбат күрсәткән вакытка киемнәрем тәмам җебеп бетеп, бөтен күкрәк авызынача баткаклы кием белән кайтып кердем үзебезнекеләргә. "Товарищ старший лейтенант, Ваш приказ выполнен, карты принес",—дип докладывать итәм. Нигә болай икәнлегемне сорашканнан соң: "Имамовка ике көн без дополнительных нарядов, пусть отдохнет, заслужил",—дигән иде дә, ял итәргә туры килмәде. Таң белән—алга. Берничә көннән безне моннан бөтенләй дә алып киттеләр. Берлин юнәлешенә!

## Берлин өчен сугышларда

Өзлексез, көнне-төнгә, төнне-көнгә ялгый-ялгый, Белоруссияне, Варшавага кадәр Польшаны азат итү, Көнбатыш Пруссияне алу, Кенингсберг өчен барган сугышларда катнашып, фашист гаскәрләрен үз җирләрендә тәпәлитәпәли, аларның оборона корылмаларын тар-мар итә-итә, безнең 157 нче 122-152 мм-лы Богдан Хмельницкий орденлы, Барановичи исемендәге еракка атучы артиллерия бригадабыз, 1945 елның 23-25 апрель тирәләрендә Берлинга килеп керде.

Сугышның бу соңгы көннәрендәге безнең хәрәкәтләребез үзебезгә бик ярсулы булып күренсә дә, гамәлдә андыйларның бездән дә житезрәкләре булып, безнең Берлинга килеп керүебезгә, сугыш барышы шәһәрнең үзәгенә үк үткән булып чыкты. Бу шартларда безгә—звукоразведчикларга анда әллә ни эш тә калмаган иде инде. Бу вакытта Берлинда барган сугыш шартларында дошман тупларының координатларын эзләп торасы юк, алар үз каршыңда. Шулай да без боевой порядокка таралабыз.

Батареябызның сиксәнгә якын кешесе берсеннән-берсе, берәр-икешәр километр ара белән сигез урында, алтысы постларда, жиденчесе—искәртү постында, сигезенчесе үзәк станциядә. Без билгән шәһәр урамнары буш. Үзәк станция тирәсендә дошман солдатлары гына түгел, гражданский кешеләр дә күренми. Обстановканың шулай булуына карамастан, шәһәр эчендәге сугыш барышлары, дошман бoжрасы көннәнкөн кысыла баруын карталарыбыз аша булса да күзәтеп барабыз. Бу турыдагы мәгълүматләрне безгә посттагы иптәшләребез (алар бездән берничә километрга алдарак) хәбәр итеп торалар.

Көннәр матур. Үзебезне бөтенләй иркен тота башладык. Бүген булмаса, иртәгә, иртәгә булмаса... Берлин капитулировать итәр дә сугыш та бетәр диешеп шатланышабыз. Берлин аша өйгә, дигән хыялыбыз тормышка ашар кебек хис итәбез. Белсәк икән алда ни көткәнен? Бәлкем, ул кадәр йөгәнсезләнеп китеп, шатланышып та бармаган, саграк та торган булыр идек. Юкка гына "сикереп чыкмас борын, "хоп" дип кычкырма", димәгәннәр шул. Бәла "аяз көнне яшен суккан кебек" 30 апрель көненнән 1 майга каршы төндә булды. Дөрес, төнге сәгать өчләр тирәсендә безгә, үзәк станциягә, бригада штабыннан: "В вашем направлении движется колонна эсэсовцев—около 300 человек, вырвавшихся из района Рейхстага, примите меры предоосторожности", дип шылтыратканнар иде. Соң булды аларның бу шылтыратулары. Без үзебезне саклау өчен дә берниндн чара да күрә алмаган кебек, посттагы иптәшләребезгә дә берниндн ярдәм күрсәтә алмадык кына түгел, бу турыда

аларга хәбәр дә итә алмадык. Элемтә алар белән өзелгән иде инде. Моның шулай тиз һәм бер үк вакытта булуы, колоннаның бездән урам аша гына үтеп, алар пост линияләрен үзәк станциядән чыккан урыннарында ук өзгәннәр булып чыкты.

Сәгать дүртләр тирәсендә уң флангтагы постларыбызның линияләрен өзгәли-өзгәли кабельләрен җыеп йөрүче фашист солдатларын пленга ала-ала постлардан иптәшләребез килә башлады. Бу вакытка батареябызның уртасыннан нинди куркыныч үткәнлеген күпләребез белә идек инде. Колоннаның батареябезнең сул флангына юнәлгәнлеген белгәч, куркуыбыз янә көчәйде. Әгәр дә андагы иптәшләребез элемтә өзелү белән, аларны төзәтергә дип юлга чыксалар (аның башкача булуы да мөмкин түгел иде), алар фәкать колоннаның каршысына килеп чыгачаклар иде. Кызганычка каршы, шулай булып чыкты да.

Линия өзелү белән сул флангтагы ике иптәшебез—Татарстан егете Гилемханов Шамил, Белгород өлкәсе егете Пузанов юлга чыгалар да, төнге караңгылыкта, фашистлар колоннасын үзебезнекеләр дип (атнага якын фашистларның безнең алда юклыгына күнегеп өлгергән иптәшләребез) колоннаның уртасына ук килеп керәләр.

"Башта,—дип сөйләде Шамил соңыннан,—мин ни булганлыкны да аңлый алмый калдым. Колонна үтеп тә беткән кебек булган иде инде. Без урам уртасыннан, алар ике як тротуардан, аларның немецлар булуы ихтималы минем башка да килмәде. Пузанов алдарак, мин арттарак, ул әкрен генә нидер әйткән кебек булды миңа, ишеттем, әмма әйләнеп карарга да, нидер әйтергә дә өлгерә алмадым, линияне карау белән мәшгуль идем, бирделәр башка, киттем сөрелеп, шулай да егылмадым. Егылсам… Дистәләгән куллар бәреп тә алдылар, өзгәли дә башладылар. Аптырап, куркып, бу ни хәл дип карасам—немецлар. Калганы шулкадәр тиз булды, уйланып торырга… Инстинкт эшләгәндер. Шулай да, ычкына алсам, бәлкем, исән… Шуңа бөтен көч (ул Шамилдә әз түгел иде, җан ачуы тагы да өстәгәндер), бөтен уй, җан-тән җитезлеге туплангандыр, әз генә иелә бирдем дә, башта бер якка әйләнеп, кинәт туктап, икенче якка селтәп җибәрдем, киттеләр төрлесе-төрле якка очып. Мин мондый көрәш алымын үскән чакта, иптәшләр белән көрмәкләшкәндә еш куллана торган идем, күнегүләрем юкка булмаган. Алда кулына пистолет тоткан таза гәүдәле (офицер булгандыр, дидем) үз солдатларына тидерүдән куркыптырмы, яисә минем ычкына алмавыма ышаныпмыдыр, атмыйча басып карап тора иде, анысын да баш белән төкеп очырдым да, тор да йөгер. Йә бер якка сикерәм, йә икенче якка, әйләнә-боргалана, карана-карана йортлар арасына кереп киткәнче, күмелгәнче, югалганчы… Арттан аталар… Гомер бетмәгәндер…

Куып килүчеләр юклыгын шәйләгәч, туктадым. Тыңлыйм, дөпелдәгән тавыш ишетелә кебек—өмет, Пузанов килеп чыкмасмы дип көтәм, каранам. Бераздан гына аңладым, тавыш дигәнем үземнең баш, колаклар шаулавы, йөрәк дөпелдәве икән. Димәк, ычкына алмаган. Ачу, рәнҗү, дошманга нәфрәт, нидер эшләргә дә көчсезлек—барысы бергә каты төен булып тамакка килеп утырдылар. Атлый-йөгерә, карана-карана үзәк станциягә, үзебезнекеләр янына".

Югарыда Шамил белән очрашуым турында язган идем инде. Эре сөякле, тыныч холыклы, кабаланып, ашыгып бармый, командирлар "быстрее, бегом" дисәләр дә, әлпән-төлпән генә. Фронтта да, нинди генә авыр шартларда калмасын, туплар ядрәсе ярылмасын, пулялар сызгырмасын—кабаланмый да, йөгерми дә, иелми дә, сыгылмый да, тыныч кына эшен дәвам итә торган иде. Минем: —"Шамил, әзрәк саграк булсаң иде",—диюемә: —"Курыкма, Мөҗип, минем белән берни дә булмый, менә күрерсең, исән калам мин",—ди торган иде. Исән калды, ләкин нинди хәвефле хәлдән соң. Үзенең тәвәккәллеге, көчле булуы һәм җитезлеге аркасында. Менә бит, нинди хәтәр, үлемле хәлдән дә исән-имин чыга белгән минем Шамил дус! Шундыйлар белән без җиңү яуладык та.

Ул вакытта мин үзәк станциядә идем. Иптәшләребез белән ни булганны белгәч тә комбатыбыз элемтә торгызылган постларга, эшнең нидә икәнлеген аңлатып, уяу булырга боерык бирде. Постлардан чакырылган солдатларның барысының да килеп беткәннәрен дә көтеп тормастан, Пузанов янына ашыктык. Исәнлегенә ышанычыбыз бәләкәй булса да, өмет өзелмәгән иде әле, нинди генә гаҗәеп хәлләр булмый фронтта. Кызганычка каршы, өметләребез акланмады.

Пузановны, әгәр дә өзгәләнгән кеше гәүдәсен ул дип әйтеп булса, аны эләктергән урынында ук калдырып киткәннәр иде. Сул ботын сындырып кына калмаганнар, аны

баш ягына әйләндереп, бөкләп тә куйганнар. Тез, кул сөякләре дә җимерелеп, башы пулялар белән челтәрләнеп беткән. Без аның гәүдәсенең кайбер өлешләрен тирә-яклардан эзләп карасак та, таба алмадык, кая булганлыкларын аңламадык.

Сугыш бетеп, хәтсез көннәр үткәч кенә яңак сөякләре, теш казнасы язмышы бераз ачыкланды. Беренче дөнья сугышында ук Россиядә әсирлектә калып, 1929 елга кадәр Омскида яшәгән бер немец карты болай сөйләде: әгәр солдатның тешләре таза, тигез, матур икән, офицерлар аны яңак, ияк сөякләре белән бергә кисеп алалар да, итләре төшеп беткәнче кайнаталар, аннан көмешләндереп, аңардан тәмәке төпчеге сүндерә торган савыт ясыйлар икән—үзенә күрә "дошманны" ничек кырганлыкларына матди дәлил—сувенир була имеш.

Пузановны мөмкин кадәр саклык белән җыеп, плащпалаткага салдык та үзәк станциягә озаттык, калганнарыбыз колонна артыннан ашыктык. Теләк—күпмегә көчебез җитә, дошманнан үч алу иде. Ашыгабыз, кабаланабыз, йөгерәбез, куып життек кенә дигәндә, безне үзебезнең пехотачылар туктатты. Каршы чыккан батальон командиры безнең нигә, кая юл тотканлыгыбызны белгәч: "Сезгә беркая да барырга да, бу бәрелештә кысылырга да кирәкми, күрмисезмени—сугыш бетә..., без аларны уратып алдык, беркая да китмәячәкләр, әнә алар кайда утыралар",—диде дә, ерак та булмаган куаклы, зур гына уйсу урынга күрсәтте. "Мин танклар чакырттым, алар юлда, озакламый монда булачаклар, ә үч алу дигәндә, алар сезнең иптәшегез белән генә шулай кыланмаганнар. Монда әле генә алар бер полк штабын да командиры белән бетергәннәр. Бер старшина гына өй түбәсендәге һава суырта торган торба эченә яшеренеп кала алган. Дошман үзенең бу явызлыклары өчен җавап бирәчәк, ә хәзер батареягызга кайтыгыз, дошман бирелмәсә, безгә аларны бетерергә туры киләчәк, ә сез монда калсагыз, безгә комачаулаячаксыз гына",—дигәч, без карышып тормадык.

Юк, кайтып та китмәдек. Ул төнне Рейхстаг тирәләреннән колонналап кына түгел, безнең коммуникацияләрне җимереп, арттарак калган штаб, хозчастьларга һөҗүм ясый-ясый Берлиннан чыгып китәргә тырышып йөрүче эреле-ваклы фашист группалары аз түгел иде әле. Менә шундый группаларны тәшкил иткән солдатларның 51ен, шул исәптән 12 офицерын юк иттек без ул көнне. Иптәшебез өчен үч алдык. Ә менә канәгатьләнү хисе урнашмады күңелләрдә. Югалтуыбыз дошманнан үч алу, аларны бетерүдән авыррак булып чыкты. Бәлкем шуңадыдыр: анда булган кайбер сугышчыларыбыз: "Мин Берлинда булдым. Без Берлинга барып җиттек, Берлинны алдык",—дип сөйли башласалар, минем күңелдә канәгатьләнү хисләре кузгалмый, күз алдына Пузанов килә дә баса. Ул безнең батареяда берләнбер 1927 елгы, иң яшь, иң бәләкәй, елмаеп-көлеп кенә: "Менә мин сезне ничек яратам",—дип әйтер кебек итеп, күзеңә карап кына сөйләшә торган, бөтенләй балалыктан чыкмаган солдатыбыз иде. "Эти сугышның тәүге көннәрендә үк хәбәрсез югалды",—дип сөйли торган иде. Семьяларында берләнбер бала булып, үзе сугышның соңгы көннәрендә һәлак булды.



Билгеле, сугыш югалтусыз булмый, ләкин солдатның менә-менә сугыш бетә дигән көннәрендә һәлак булуы югалтуның авырлыгын күп мәртәбәләргә арттыра икән шул.

Пузановны үзебез билгән йортның ишегалдына җирләдек. Икенче майда Рейхстаг өстендә җиңү байрагы җилфердәде.

Өченче майда, төшләтеп, батареябызга: “Сняться с боевых позиции и прибыть в район дислокации штаба дивизиона”, дигән приказ алдык. Алдык та кабаланышып юлга җыена башлаган идек… Бу ни хәл? Әле генә монда йөргән бер солдатыбыз суга төшкән кебек юк булды. Башта без аны “берәр йомышы” белән генә чыккандыр дип уйлаган идек тә, тышкы ишек төбендә сакта торган солдатыбыз: “Ул беркая да чыкмады”,—дигәч, гаҗәпләнешеп—адәм баласы таракан түгел лә ләбаса, җир дә йотмагандыр, кайда да булса булырга тиештер бит, дип шәпләп эзләп карасак та, таба алмадык. Җайлап, уйлап эзләп торырга вакыт та калмаган иде инде. Комбатыбыз: “Башкача тоткарланып тора алмыйбыз, болай да соңга калабыз, үзенә үпкәләр, исән булса, табылыр”,—диде дә юлга кузгалдык.

Кызганыч булды миңа ул егетне монда, билгесезлеккә калдырып китү. Ул минем якташ татар (ә фронтта якташ бертуган дигән кебек була), Дүртөйлеме, Чакмагышмы—шул районнарның берсеннән иде. Безгә күптән түгел, Берлинга керер алдыннан гына запасны тулыландыру өчен килеп, минем белән бергә үзәк станциядә эшли генә башлаган иде. Кызганычка каршы, танышлыгыбыз кыска вакыт эчендә булганлыктан, аның исеме дә, фамилиясе дә хәтеремдә сакланмаган.

Монысы шулай югалту белән бетсә, күрсәтелгән урыныбызга килеп, дивизионыбызның арытабан кайда юл тотачагы турындагы приказны тыңлый гына башлаган идек, тагы… Кыска гына т-р-р—р—т. автомат очереды. Берничә секундтан куркыныч кычкырып, калтыраган куллары белән бот арасына ябышып, санинструкторыбыз җиргә ауды. Бу көтмәгәндә яңгыраган автомат очереды һәм санинструкторның ачы тавышыннан безнең строй: “Бу ни булды”, дип тынып калгач, оптик разведка батареясы командиры: —“Батарея, кругом, по противнику огонь!”—дип команда бирде. Бөтен батареясы борылды да дивизион артында торган, бомбардировка белән җимерелеп беткән зур гына бинага карап дәррәү ут ачты, имеш, шуннан безгә дошман һөҗүм иткән.

Бераздан менә нәрсә ачыкланды. Бер солдат, автоматы белән ни булгандыр, тарткалашып маташканда, очраклы рәвештә атылып киткән һәм…

Санинструкторны шундук кыр госпиталенә озаттык. Берничә көннән соң яңа поход вакытында (сугыш бара иде әле) санинструкторга ашыгыч операция ясаганнар, бик күп каны аккан, исән калырмы-юкмы дигән кайгылы хәбәр алдык. Бу безнең соңгы өч көндә өченче югалтуыбыз иде.

Приказга килгәндә, поход вакытында без үзебезнең Прагага юл тотканлыгыбызны белдек. Анда чехлар немецларга каршы баш күтәргәннәр булып, аларга бездән ярдәм кирәк икән. Ләкин безне Прага түгел, Чехословакия территориясенә дә, анда сездән башка да гаскәр җитәрлек, дип кертмәделәр.

Сигезенче майда, Алмания, Чехословакия, Польша илләре чикләре тоташкан өч почмакта, нәкъ көндезге сәгать дүртләр тирәсендә безнең позициягә немецлар “болванка” белән булса да бер атыш ясап калырга өлгерделәр әле. Шуннан соң бөтен тирә-як тынып калды. Башта без, бу көтмәгәндә бөтен галәмнең тынып калуыннан нидер вакытка саңгыраулангaн кебек булдык. Бу ни хәл, әллә немецлар позицияләрен ташлап качтылармы, дип уйларга да өлгермәдек, комбатыбыз: —“Егетләр, Алмания бирелгән, сугыш бетте, әле генә бригада штабыннан шылтыраттылар, сезне җиңү белән!”,—дип кычкырып җибәрде.

Шатланырга да өлгермәдек, фәкать шул мәлдә безнең батареяда тагын бер фаҗига килеп чыкты.

Ул көнне иртә белән батареябыздагы офицерларга аш пешерүче солдатыбыз—грузин Николашвили кайдандыр агач спирты таба да, башта үзе эчә, аннан тагы ике иптәшен—Чувашстаннан солдат Ивановны, Брянск өлкәсеннән сержант Васильевны сыйлый. Бер мәртәбә генә түгел…

Ул үзе сугыш бетү хәбәрен алганчы ук башта саңгыраулана, ишетмәс була, аннан сукырая. Кечкә таба җәфаланып үлде. Калган икесе сугыш беткәч, аның беткәнлеген ишеткәннән соң шулай ук өзгәләнеп үлделәр.

Бигрәк тә безгә сержант Васильев кызганыч булды. Бердән, ул аларның өчесе арасында иң яше булып, гадәттәге юк-юкта безгә бирелә торган 100 граммны да эчми, тартмый, сүгенми, оялчан, бөтенләй кызлар кебек басынкы, пәһлеван егетләрдән иде. Аңа шулкадәр сасык, чирканчык сыекчаны эчәргә нәрсә этәргеч булгандыр… Без моңа: язмыш чыннан да бар нәрсәдер ул, диюдән башка җавап таба алмадык. Сугыш

бетеп, үзенең үләчәген белгәч: "Егетләр, берәр нәрсә эшләгез әле, бер генә дә үләсе килми бит", дип ялынып-ялварып елады. Без аңа йөгерешә-йөгерешә сөт табып күпләп эчереп карасак та, аның изалануларын тагын берничә сәгатькә озайтудан башка ярдәм итә алмадык.

Ивановны җәлләсәк тә, анысын Ходай Тәгалә үзе җәзалагандыр инде, диештек. Ул безгә Тамбов урманнарында, фронтка китәр алдыннан хатынын үтергәне өчен 10 елга хөкем ителеп, фронтка җибәрүләрен сорап килгән иде.

Шулай итеп, сугыш бетү хәбәре безнең батареябыз өчен күңелсез шартларда яңгырады. Моның белән генә бетсә иде икән әле…

Аның күңелсезлеген тагы да көчәйтеп, дивизионыбызның замполиты аларның ни рәвешле үлгәнлекләрен белгәч, аларны "ил хыянәтчеләре" дип, өчесен дә безнең позициядән ерак булмаган яр астына ыргыттырып, ярны ишеп төшерү белән генә җирләттерде. Билгеле, бу безнең сафларда ачу хисләре тудырды. Ничек кенә үлмәсеннәр, алар үләргә дип эчмәгәннәр, аннан алар ел буена диярлек үзләренә йөкләтелгән хәрби бурычларын намус белән үтәп сугышкан солдатларыбыз иделәр.

Ярый, Ходай Тәгалә бардыр. Икенче көнне, без аларны ыргытып киткән урыннан 40 километрлар чамасы үткән идек, привалларыбызның берсендә безнең батареяга бригада политбүлеге начальнигы Семенов килде. Ул Хасан күлендә сугышкан, Халхин-Гол герое, өч Кызыл Байрак, бер Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. Шуның өчен аны бригадабызда "Боевой подполковник" дип йөртәләр иде. Табигый, без аның янына йөгерешеп бардык та капитан Гурзоның безнең иптәшләребезне ничек мыскыл итеп күмдергәнлеге турында сөйләдек. Ул моның өчен бик тә ачуланып, безнең алда ук аны чакыртып китертте дә: "А ну-ка, капитан, доложите-ка, как вы похоронили погибших солдат?",—диде. Аның сүзләрен тыңлап тормастан: —"Что, вы не знаете, что все это нашим солдатам подбрасывает враг, немедленно сами и никто другой, возьмите взвод солдат, поезжайте, привезите на место нашей будущей дислокации, помойте, переоденьте, похороните всеми воинскими почестями, о выполнении доложите мне лично",—диде. Шулай эшләделәр дә. Бу безнең сугышның азакки көнендәге, бу юлы кеше мәгънәсезлеген генә булса да, барыбер җиңүебез иде.

Соңрак безнең Берлинда югалган солдатыбызның язмышы ачыкланды. Безнең Берлиндагы үзәк станциябез, хәзерге безнең "Хрущевкалар" кебек, биш этажлы йортның беренче этажының, беренче подъездының беренче квартирасында урнашкан иде. Квартира ишегеннән чыккач, бер-ике баскыч түбәндә рәшәткәләр белән бүленеп, аларга йозаклар эленеп куелган подвал бар икән. Ләкин аларның ачкычларын табып, ачып карап йөрергә, әйтүемчә, вакыт калмаган иде. Менә шул, китәргә дип әзерләнеп йөргәндә, безнең солдатыбыз, ни кирәк булгандыр, подвалга төшә дә өч немец солдаты белән күзгә-күз тап килә. Кычкырырга да өлгерми, тегеләре каушап, югалып калмыйлар, моны бәреп алалар да авызына чүпрәк тыгып, бәләкәй баланы биләгән кебек урап-чорныйлар да, шундагы клеткалардагы зур кәрзиннәрнең берсенә тыгып куялар, үзләре яшеренәләр. Икенче көнне, безнең киткәнлекне белгәч, безнең солдатны, таң белән Берлин аша үткән елга ярына алып чыгалар да атарга дип бастырып куялар. Калганы… чыннан да әкияттәге кебек, фронтта ниләр генә булмый дисәң дә, була икән шул. Безнең солдатны бастырып куйган җирдән ерак та түгел күпер булып, аның астында көндезен частеннән аерылып калган безнең бер солдат, адашып йөреп, арып-алҗып төнгелеккә калгач, күпер астына керә дә автоматын әзер куеп, яшеренеп ялга утыра. Таң белән кемнәрнеңдер йөргәнен сизеп, күзен ачса, утырган урыныннан тормастан ППШ—ыннан озын очередь бирә, немецларның өчесен дә берьюлы юк итә. Билгеле, без бу хәбәрне алгач, иптәшебез өчен "күлмәктә туган икән" дип шатланыштык.

Хезмәттән кайткач авылдашларына шулай ук, минем искә алган иптәшләрем, үзләре белән Берлинда ни булганлыклары турында сөйләгәннәрдерме, юктырмы. Юктыр, дим! Сөйләсәләр дә, аларның сүзләренә барыбер дә ышанмаган булырлар иде. Эсэсчыларның кулларына барып эләк тә, ычкына ал имеш, мөмкинме соң бу, дип? Аннан ул чакта мондый истәлек сөйләшүләр дә юк иде әле. Алар соңрак, җиңүнең 30 еллыгын бәйрәм итү алдыннан гына модага кереп киттеләр. Ул елларны каһарманлык турында сөйләрлек идемени? Күп кешеләрнең җан, тән яраларыннан кан сава иде әле. Аналар, апалар битләренә тәгәрәп төшкән күз яшьләрен, җиң очлары белән сөртә-сөртә: "Син кайттың да бит, безнекеләр кайта алмады шул", дисәләр,

батырлык турында түгел, ничектер башкаларның кайта алмаганлыкларына үзеңне гаепле кебек хис итәсең иде. Ни әйтергә дә белмичә, югалып каласың, тамагыңа төен килеп утыра, сөйләшеп булмый, башыңны иясең дә, китеп барасың.

Әйе шулай, сугыш "Шәмси"дә, "Камәри"дә йөзле түгел. Никадәре аны патриотик, героик итәргә тырышма, сугыш, кайвакытта гына булмасын, ул кан коеш, кешеләрнең бер-берсен бетерүгә юнәлтелгән эш. "Чапаев" кинофильмында бер эпизод бар. Ашханә янында бер малайның: —"Дядя, почему люди идут на смерть?"—дигән соравына, карт повар: "Всем хочется хорошей жизни",—ди. Сүз дә юк, Ватан сугышында без кешелек дөньясының иң кара көчләрен тар-мар иттек, законлы горурланырга хаклыбыз. Әмма менә шул ук фильмда Василий Ивановичның: "Война кончится, прекрасная будет жизнь, помирать не надо", дигән сүзләре искә килә. Без дә: "Прекрасная будет жизнь" дип хыялланган идек тә, "помираты" белән кабаланмасак та, "прекрасная будет жизнь" белән ничектер барып чыкмады. Чапаев бабабызның бу хыялларына сиксәннән артык еллар үтеп китсә дә "прекрасная жизнь" аның замандашларына гына түгел, Бөек Ватан сугышы ветераннарына да, аларга гынамы, соңрак туган буыннарга да еллар үтү белән ерагая барган мираж гына булып кала килде. Телисең-теләмисеңме, күз күрә, колак ишетә, кая безнең көчле явыз дошманны җиңгән бөек ил, кайда безнең җиңүләребезнең кыйммәтле вә хөрмәтле җимешләре дә, кайда безгә лаеклы, мул тормыш, дип сорау куясың...

Яңадан фронт хәлләренә әйләнеп кайтыйк.

Берлин бирелгәннән соң, сугышның менә-менә бетә икәнлеге күренеп торган булса да, аның шулай тукталуы безгә барыбер дә көтмәгәндәй кебек тоелды.

Бу хәбәрдән соң күпмедер вакытка тынып калган фронтта берничә минуттан соң ут өермәсе купты: алгы сызыктагы барлык сугышчылар кулларындагы шәхси коралларыннан—карабин, винтовка, автомат, пулеметлардан бөтен тирә-якны дер селкетеп, туктаусыз һавага ата башладылар. Төнгә өзлексез яктыртып очучы пуля, ракета утлары кушылып, чын-чыннан да җиңү бәйрәме фейерверкына әйләнде.

Шулай итеп сугыш бетте! Без җиңдек!

Кемгә ничек булып күренер, безнең сугыш кырларында эшләгән эшләребезгә йомгак ясау, югалткан корбаннарыбызны барлау әле соңрак булачак иде. Сугыш беткәч Алманиядә тәүге көннәрдә фоторәсемнәргә төшеп калырга ашыктык. Тора-бара бу рәсемнәрнең тарих өчен мөһим булачагын бәлки сизмәгәнбездер. Әлегә алар бергә сугышкан, бергәләп кан койган, сугыш михнәтләрен бергә кичергән иптәшләребезгә мәңгелек истәлек өчен кирәк иде.

Июль азаклары, август башларында хәзергә әле өебезгә түгел, илебезгә кайтырга чыктык.

Озакламый башланып киткән "Салкын сугыш" безне әле тагын да биш елга сузылган армия хезмәте сафларында калдырачак иде. Монысы аз гына соңрак билгеле булды.



**Фәрит**
**Габдерәхим**

## УЧАК ХАКЫНДАГЫ КЫЙССА

### Гайре табигый учак

**Тарих шаһит:**
**Бердәнбер көн**
**Бабакайлар учак яккан.**
**Гайре табигый учакны**
**Дөнья, күреп, шаклар каткан.**

**Ә ниятләр изге булган—**
**Караңгылык чыксын юкка,**
**Күшеккән вә туңган җаннар**
**Җыелсыннар ошбу утка.**

**Янсын учак!—очкан утка**
**Тәхет, богау бер-бер артлы.**
**Дөрләп янган ту вә тугра,**
**Дөрләп янган “Иман шарты”.**

**Шул учакта бабакайлар**
**Үзләре дә озак янган.**
**...Учак хакындагы кыйсса**
**Кемгә—чындыр, кемгә—ялган.**

### Ханбикә манарасы

**Сөембикә манарасы.**
**Никтер моңсу Казансу.**
**Гасырлардан гасырларга**
**Сагыш сарка. Ямансу.**

**Мәңгелеккә нидер сөйли**
**Ханбикә манарасы.**
**Бәгыренә кан саудыра**
**Әллә Мәскәү каласы,**
**Әллә Нугай даласы...**

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре; башкорт һәм татар телләрендә дөнья күргән дистәгә якын китап авторы.*

## Күкләр саташкан

**Төпсез күкләр, арып, саташкан,
Фасыллары елның адашкан:
Яңгыр коя кышын кәпәчкә,
Карлар ява җәен как башка.
Төпсез күкләр, арып, саташкан.**

**Алдан төшеп алган сукырлар,
Юлларында тирән чокырлар.
Кыю сүзләр сөйли куркаклар,
И йотлыгып тыңлый чукраклар.
Әйдәп бара алдан сукырлар.**

## Урын табылырмы?

**Явызлыктан, ялган гаделлектән
Беткән идек йөдәп-талчыгып,
Килеп керде кануннары белән
Күңелләргә иблис-большевик.**

**Кануннарның һәр хәрефе алтын!
Кабул иттек чын дип ялганны.
Күңел гарык ошбу кануннардан,
Ә Аллага урын калмады.**

**Менә бүген иблис кануннары
Тарих чүплегенә түгелә.
Демократлар язган кануннарын
Шыплап тутыралар күңелгә.**

**Иблис нишли? Демократ—ул, имеш.
Табынадыр Ай вә Тәрегә.
Тутыралар яңа кануннарны,
Урын табылырмы Тәңрегә?!**

## Көнләшәм

**“Яңа урыслар”, “Яңа татарлар”.
Җилдерә алар иномаркада.
Мин “иске татар”. Йөримен җәяү.
Гомер буена биштәр аркамда.
Һич тә көнләшмим яңа байлардан.**

**Әнә бер малай. Ялан аяклы.
Атланып алган таяк-атына.
Кулында чыбык. Җилдерә генә.
Җитәрмен димә аның артыннан.
Бигрәк көнләшәм шушы малайдан.**

## Әнкәйне юксыну

**Догаларың шайтаннарга
Капкыннар кора иде.
Чәчәкләрне кысмасын дип,
Күңелдәге чүп үләнен
Урагың ура иде.**

**Упкынга илтер юлымны
Кирегә бора идең.
Дәшми торган чагыңда да
Иң кирәкле сүзләреңне
Ишетеп тора идем.**

## Аңламассыз

Барысы да сөйли, иң дөресен
Алар гына белә, әйтерсең.
Тотыналар шуннан бәйләнергә:
—Ник бер сүз дә, абзый, әйтмисең?!

Ишетмәгәч әйтмәгәннәремне,
Укымагач сүзен күзләрнең,
Аңламагач дәшми торуымны,
Аңламассыз әйткән сүзләрне.

## Таш

Шикләнә күрмә, янәсе,
Таш-мазар юк кулымда.
Ике куллап күрешә ул,
Ә ташы... куенында.

## Ишарә

Шигырьләрем һаман кыскаралар,
Моның серен ничек чишәргә?
Осталыкмы арта, әллә соң бу—
Гомер кыскаруга ишарә?!

## Яшьлек иле

*Яшьлегемә йөгереп кайтыр идем,*
*Йөгереп кайта торган юл булса.*
Ә. Ерикәй

Яшьлек иле... Төсләр балкып тора.
Хуш исләре ерак аңкып тора.
Өмет тулы таңнар атып тора.
Ә офыклар серле—тартып тора.

Әй, картлачлар, кайтасыгыз килә
"Яшьлек" дигән шушы гүзәл илгә.
Сагыш тулы күңелегез—аңлыйм,
Аңлыйм да бит—ярдәм итә алмыйм.

Бикле аның, бикле капкалары,
(Кемнәрнең бар анда кайтканнары?!)
Бу җәһәттән җаным тыныч минем:
Киткәнем юк синнән, Яшьлек илем.

## Көннәрем җитсә иде

Упкын да упкын төшемдә,
Тәмам теңкәгә тиде.
...Соңгы җырым төгәлләргә
Көннәрем җитсә иде.



## Шамил Маннапов

# ЯҢГЫННАН КАЛГАН БАГАНАЛАР

ХИКӘЯТЛӘР

### Танклар һәм тавыклар

Бер акыл иясе әйткән: кешелек үзенең узганы белән көлеп аерылыша, дигән. Дөрестән дә шулайдыр. Хәлбуки, ни газаплы сугыш вакытындагы хәл-әхвәлләрнең дә кайсыберләрен хәзер елмаеп-көлеп искә алабыз, үз вакытында шактый хәтәр вакыйгаларны да мәзәк итебрәк сөйлибез.

Илгә гитлерчылар басып кергәч, безнең әти белән Зур абый да бер-бер артлы фронтка киттеләр. Авыру әнинең сыңар канатына сыенып, без—биш бала торып калдык. Эшкә-гамәлгә яраклыбыз Каюм абыйга да нибары ундүрт-унбиш яшьләр генә булгандыр. Шулай да, ул инде укуын ташлап, колхоз эшенә җигелде. Язын сыер җигеп җир сукалады, җәен төннәрендә ат көтүе көтте, кышын дворда атлар карады. Аз гына буш вакыты булдымы, тезенә юкә "каешларын" тезеп, чабата тугырга (безнең якта шулай әйтәләр) утыра иде. Әзер чабаталарын Алпар базарына барып, сатып кайтучы да ул. Ләкин бервакыт чабата саткан акчалары гаилә хәзинәсенә эләкми башлады. Чөнки фронтка танк колоннасы төзү өчен дип, һәр хуҗалыктан сәрмая җыя башладылар. Ә төрле-төрле налог-салымнарның, заемга көчләп-көчләп яздыруларның күплеген әйткән дә юк инде.

Ул да булмады, кышкы бер көндә, янә дә фронт өчен дип, өй борынча берәр тавык җыеп йөри башладылар. Менә тавык түшкәләре төялгән чаналы ат безнең капка төбенә дә килеп туктады. Бу вакытта Каюм абый эштә иде.

—Кайсы тавыгыңны бирәсең фронт өчен?—дип, колхоз рәисе Әслах, каты-усал тавыш белән әнигә эндәште.

—Кайсын дип, нибары бер тавыгым белән сыңар әтәчем генә торып калды лабаса. Үзебез дә бәрәңге кабыгы онына алабута орлыгы кушылган коры аш белән генә җан асрыйбыз...—диде әни, нииндидер мәрхәмәт өмет иткән кыяфәттә.

—Үзем өчен түгел, фронттагылар өчен. Монда саботаж булмаска тиеш!—диде Әслах. —Анда үз атагыз, үз улыгыз да ач утырадыр окопта, нибуч! Тавыгыңны

---

Шамил МАННАПОВ (1938) – *шагыйрь, прозаик; "Тугрылык алиһәсе", "Кайту", "Апрель авазы", "Өңдәге төшләр", "Әти урманы", "Мәңгелектән елмаю" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

калдырабыз, әтәчеңне алабыз. Тавыгыңа күрше әтәче дә житешер, нибучь. Шулаймы, Сәпәр?—дип, янында аның сүзен җөпләп торучы аксак бригадирның янбызына төртте. Икесе дә тәмәкедән саргайган тешләрен ыржайтып, ат кебек кешнәп куйдылар. Һәм ишекне ачык калдырып, чыгып киттеләр. Ишек алдында аларның пыр тузып, әтәчне куып йөргәннәре, аннары тавык кытаклаганы, әтәчнең хәвефле итеп чырыйлап кычкырган тавышлары ишетелеп торды. Бераздан барысы да тынды. Бугазыннан, ак карны кызартып, кан тамчылаган әтәчне тоткан зобаниларның капкадан чыгып китүләре күренде.

Шуннан озак вакыт үтмәде, эштән Каюм абый кайтып керде. Бусаганы атлауга, гадәтенчә:

—Әни, ашарга бармы?—дип сорады.

—Әй, улым,—диде әни, абыйның яңагы яңакка ябышкан, зур булып күзләре генә утырып калган ач йөзенә кызганып караган хәлдә,—казан аскан гына идем, персиятел белән бригадир кереп, эшемне бүлдерделәр.

—Ни калган аларга монда?

—Әтәчебезне фронтка алып киттеләр,—диде әни, үзендә елмаерга көч табып.

Каюм абый чишә башлаган сырма сәдәфләрен аннан-моннан гына кире каптыргалады да, тиз генә урамга атылды. Ә бераздан, кулына зур гына бер әтәч түшкәсе тотып, кайтып та керде, минсиңайтим.

—Мә, әни, тиз генә йолкы да сал казанга!—диде ул.

—И-и, бу бит безнең әтәчебезгә бер дә охшамаган лабаса.

—Әтәч исәбе барыбер,—диде Каюм абый. —Чанадан иң зурысын эләктердем дә, әллүр өйгә. Олаучы Харунша бабай борылып карарга да өлгерә алмый калды.

Ул көнне без бик тәмләп тавык шулпасы белән сыйландык. Әни исә: "Кеше тавыгы—харам ризык…"—дип, чәй генә эчеп утырды. Үзе әледән-әле әтәчебезне кызганып, аның нинди уңган булуы, тапкан җимен дә үзе капмыйча, "Кот-кот-кот!" итенеп, титибикәсен чакырып сыйлавы турында сөйләп алды. "Корт, корт таптым!" дип әйтүе булгандыр инде үзенчә, мескенемнең",—дип, сүзен янә шаяруга борырга тырыша иде шикелле. Итле аштан соң, Каюм абыйның да йөзенә нур кунгандай булды. Башка вакытларда ул мондый җыру суза иде:

Капчыгымда алабута,
Аны ашасам, эч авырта,—
Әпәй бирегез.
Атланып корчаңгы атка,
Киттем военкоматка,
Мине күрегез!

Ә бүген чабата ясый-ясый болай җырлап җибәрде:

Әтәч менгән читәнгә,
Кикерикүк итәргә.
Әтәчкә дә вакыт җиткән
Әрмиягә китәргә.

Әнинең:

—Гитнырны җиңәр өчен танклар гына җитмәгәнме, тавыклар да кирәк микәнни?..—дигән сүзенә җавап итеп Каюм абый әтте:

—И, әни, әллә син ул тавыклар фронтка барып җитәр дип уйлыйсыңмы? Аларның күбесе төрле-төрле түрәләр табынында ятып калачак бит. Сабыйлар күз яшеннән курыкмаган бәндәләр харам ризык дип торырлар дисеңме?!.—диде.

## Юлбасар

Колхоз рәисе Әслахның үзенә охшаган бик усал эте бар иде. Урманда очратсаң, бүре дип белерсең үзен. Шундый ук соры йонлы, тырпаеп торган колаклы, күзләре—ике утлы күмер! Исеме дә ерткычныкы—Юлбарыс. Без аны Юлбасар дип атый идек. Хәлбуки, бу мәлгунь үз турларыннан узып баручыларның әледән-әле каршына чыгып утыра һәм берәр кисәк ризык ташламасаң, ары җибәрми. Ул бигрәк тә мәктәп балаларына каныга. Иртән аларның букчаларын күтәреп, мәктәпкә баруларын сагалап

кына тора да тешләрен хәтәр ыржайтып, юлларын кисә. Укучы бала, бичара, нишләсен инде, озын тәнәфестә тамак ялгарсың, дип, әнисе биреп җибәргән кадерле ипи кисәген, йә мичкә тәгәрәтеп пешерелгән кабыклы бәрәңгесен теге юлбасар алдына ташлый. Эт исә, тәгамны алып, юлдан читкә чыгып ята.

Безнең Каюм абый үзе дә ашауга бик батыр, ә гаиләдә ризык ягы такы-токы гына булганлыктан, черек бәрәңге күмәчен теге туймас тамак белән бүлешәсе килми. Нишләргә? Әһә, аның бит төнлә атлар көткәндә бүре куркыту өчен үзе ясаган наганы бар. Ул бер көнне, шул наганны әтидән калган (әти сугышка киткәнче урман каравылчысы иде) ядрәләр белән корып, букчасына сала.

Әһә, теге ачкүз дә бәбәген алартып, юлга чыгып утырган! Чираттагы узгынчыдан "ясак" алып калырга исәбе.

—Кит юлдан, Юлбарыс, яхшылык белән, югыйсә, минем сиңа дигән хәтәр сыем бар!—дип әйтеп карый Каюм абый. Кая ул! Теге шайтан алап авызын ачып, хәнҗәр кебек казык тешләрен ыржайтып, ырылдап кына куя. Каюм абый аны урап узарга чамалап карый, юк, җибәрми теге, һаман каршы төшә, һаман якынлаша бара үзе, каһәр! Каюм абый уң кулын букчасына тыга. Теге мәләвен миңа ризык ташлый икән, дип, озын телен чыгарып, селәгәен ялап куя. Ләкин, бу ни хикмәт, малай кулындагы нәмәрсәдән ут бөркелеп чыга, һәм күкрәгенә күсәк белән ордылармыни?! Юлбасар башта артка таба мәтәлчек атып китә, аннары үзенә хәтәр куркыныч янавын чамалап, капка астындагы тишектән йортларына шуышып кереп китә. Каюм абый исә, кеше-кара күргәләгәнче, кире борылып, өйгә элдертә. Ләкин өйгә кереп тормый, наганын ышанычлы урынга яшереп куя да, бакча артлатып кына мәктәпкә ашыга...

Мәктәптән кайтуына әни аны борчулы йөз белән каршылады.

—Әй, балам, нәстә эшләдең син?! Монда персиятел пунәтәйләр белән кереп, актармаган җирне калдырмадылар. "Бандит малаең наганын кая яшерде?!"—дип үзәгемә үттеләр чистый. Рәзе персиятел этенә кул күтәрәләр, дүрәк! Ярый әле ул эзвире дә дөмекмәгән, ату падсуд җибәрерләрие үзеңне, Алла сакласын!—дип битәрләде әни.

Әти белән Зур абый фронтка киткәннән соң, иң өлкәнебез булып калган Каюм абый:

—Кайгырма, әни,—диде,—"стрелок" тотылмаган—карак түгел. Табалмаулары яхшы булган наганны. Аның каруы, моннан соң ул юлбасар ризыгыбызны талап калырга җөрьәт итмәс.

—Шулай да, кая яшергәниең соң мылтыгыңны?—дип кызыксынды, инде тынычлана башлаган әни.

Каюм абыйның сипкелле, ач яңаклы йөзендә елмаю чаткылары күренгәндәй булды:

—Хе-хе. Сыерның яңа гына салган "бәлеше" эченә тыктым мин аны. Гаунаның гаунага тимәгәнен беләм лә мин. Хе-хе...

Әни дә тешсез авызын яулык белән каплап, елмайды:

—Кайвакыт тизәкнең дә кирәге чыга шул. Моннан соң начар кешегә дә ул сүзне әйтергә телең бармас инде.

## Ат шаукымы

Сугыш башланганның икенче язында безнең Каюм абыйны, үзе кебек үк чая-үткен, Талибулла абый белән бергә, колхоз атларын көтәргә билгеләделәр. Бу ике яшүсмер көне буе төрле эшләргә җигелгән бахбайларны төнгелеккә Чирмешән буендагы болынга, чәчелми калган кыр-басуларга алып китәләр, таң яралуга, янә нужа бабай йөген тартырга алып кайталар иде. Ул елларда техника ягы шылтыр-пылтыр "колесный" трактор гына булганлыктан, бөтен эш атлар сыртына төште бит. Аның каравы, пар җирләре күп калдырыла, ә анда исә азык мул иде. Печән урман буйларында тагын да куерак, әмма ул тирәдә төнлә куркыныч. Урман ешлыкларында бүре күзләре ут булып яна, аларның Айга карап сузып-сузып улауларыннан йөрәккә шомлы салкын йөгерә.

Каюм абый Ак бәкәл кушаматлы атына атланып эшкә китәр алдыннан әни аны, төрле догалар укып, баштанаяк сыпыра, "Юлдашың Хозыр-Ильяс булса иде, ярабби!"—дип, теләкләр теләп кала, иртән кайткач, җиңел сулап, Ходайга мең шөкерләр итә иде. Һәм аның догалары күп вакытлар кабул да була килде.

Ләкин салкынча бер иртәдә Каюм абыйның кайтуын көтеп торганда, ишектән атылып-бәрелеп Талибулла абый килеп керде. Каушавы-дулкынлануы йөзенә чыккан.

—Сәрмәдия апа! Бүреләр… бер таебызны харап итте! Көтүне куып кайтканда… Каюмның аты кинәт өркеп, силос базына егылып төште. Әйдәгез тизрәк!—диде ул.

Көтелмәгән бу хәбәрдән барыбыз да өнсез калдык. Шулай да әни сорашырлык көч тапты:

—Әй, Ходаем! Каюм үзе кайда соң? Ник ташлап калдырдың аны?!

—Ташламадым. Силос базыннан өстерәп чыгардым мин аны. Азаплана торгач, атны да коткардык. Тик Каюм әллә нишләде… Һаман: "Бүреләр! Бүреләр килә! Тайны коткарыйк!"—дип сөйләнә. Әйткәнне аңламый. Кайтмый…

Әни: "Әй, Ходаем, үзең ярдәмеңнән ташлама. Сабырлык бир!.."—дип сөйләнә-сөйләнә, башына әтинең бүреген киде дә, Талибулла абыйга иярде. Мине дә үзе белән җитәкләде.

Без силос базы янына килеп җиткәндә Каюм абый, Ак бәкәлнең ябык муенына башын куеп, үзалдына нидер сөйләнеп тора иде.

—Улым, нишләп һаман кайтмыйсың? Әйдә, чәй кайнады. Сөтле чәй эчеп, җылынып йокларсың…—диде әни, аның чәбәләнеп беткән чәченнән сыйпап.

Каюм абый күтәрелеп карады, ләкин аның зур коңгырт күзләрендә безне күрү-тану әсәре сизелмәде.

—Бүреләр килә! Талибулла, катырак шартлат чыбыркыңны! Күрмисеңмени, бер тайны көтүдән аерып алдылар!.. Харап итәләр! Минем наган бер генә зарядлы бит, бүтәнчә аталмыйм!—дип өзгәләнергә тотынды.

Әни аның бер ягыннан, Талибулла абый икенче ягыннан култыклап, өйгә таба әйдәкләделәр.

Өйгә кайткач, әни абыйга мәтрүшкәле чәй эчерде, әтинең толыбына төреп сәкегә яткырды. Абый азга гына онытылгандай булды. Әмма кинәт сикереп торды да: "Бүреләр! Бүреләр килә!"—дип, ишекле-түрле чабулый башлады.

Бу тамашадан әни гаҗиз калды:

—Бар әле, улым, тиз генә Маһруй әбиеңне дәшеп чык. Өшкертмичә булмас бу баланы!—диде.

Маһруй әби авылда бердәнбер имче карчык. Яңа туган балаларның кендек әбисе дә ул. Заманында авылның колхозга керми калган бердәнбер кешесе. Арышындыр, бодаендыр үзенең бәрәңге бакчасында үстерә. Ире урман каравылчысы булган. Кышкы бер төндә аны урманда муенына балта белән чабып үтергәннәр. Аты аның үле гәүдәсен һәм кулыннан җибәрмәгән мылтыгын чанасында алып кайта. Утын урларга килгән бәндәләр харап иткәннәр, дип сөйләделәр… Шуннан бирле Маһруй әби тавык кетәге кадәр генә өендә япа-ялгыз яши. Көз көне бакчасындагы уңышын чалгы белән чабарга Каюм абый булыша аңа. Әнинең ахирәт дусты бит. Уйнаганда егылып-нитеп, әнигә зар кылсак, ул безне Маһруй әбидән өшкертерә. Дога сүзләре отып алырга бик тә җайлы:

> "Әтрәк-бәтрәк, әүвәлгедән катырак!
> Килмәдем мин каршыңа, килдем батман арышыңа.
> Өф-ф! Өф-фф!
> Ак кишер, күк кишер,
> Өшкерүем килешер!
> Тьфу! Тьф-фу-у!.."

Чыннан да өшкерүенең шифасы тия бит, әй! Авырту шундук басылгандай була. Янә урамга чыгып чабабыз…

Әмма бүген күрше әби өшкергәндә элек без ишеткән гадәти сүзләрне әйтмәде, без аңламаган телдә укыды догаларын. Үзе өшкерә, үзе авызын әледән-әле зур итеп ачып исни.

—Әй, ахирәткәем, улыңа ат шаукымы кагылган лабаса! Күрәсеңме, ничек иснәтә, мәләвен! Иншалла, минем сулышымның шифасы тими калмас,—диде ул соңыннан.

Дөрестән дә, бераздан Каюм абый селкенеп куйды, торып утырды, күзләрен тутырып безгә карады.

Әни аңа, ничек кирәк алай, өзек-төтек кенә хәлне аңлатып бирде. Абый тынычлангандай, башын иеп тыңлап утырды, төнге вакыйганы хәтеренә төшерергә тырышты бугай.

—Атың нәрсәдән өректе соң, улым? Ничек алай күрәләтә базга барып төште икән?

—Ә-ә, әйе, исемә төште,—диде абый. —Ак бәкәл белән кайтып барганда кычыткан арасыннан кинәт кенә бозау кадәр эт килеп чыкты. Теге, Әслах бурзае. Ат аны бүре дип белдеме, кинәт янга сикерде, ә анда силос базы икән.

—Ул алабай үчен алгандыр синнән,—диде әни, уфтанып. —Син бит ул мәлгуньне аткан идең. Мәптеккә баручы балалар каршына чыгып, юклы-барлы ризыкларын талап калган өчен. Ипи кисәгеңне бирмәсәң, юлыңа аркылы ята да тәки җибәрми, дигән идең бит.

Сүзгә Маһруй әби кушылды:

—Юньле кешеләр Гитнырга каршы яуда кан түгә. Ә ул юньсез китүенә ярты ел да булмады, кулын марляга урап кайтып та җитте. Нимес атканда акуптан үзе кулын өскә күтәреп торгандыр әле, пуля эләксен дип. Персидәтелне әйтәм…

Аннары күрше әби янә Каюм абыйга борылды:

—Син, балакаем, атың урамга чыгып китте, дип сөйләнгәндең мин өшкергәндә. Ничек булды ул?

Абый күгәргән маңгаен учы белән уыштырып алды.

—Әйе шул. Әкәмәт инде. Ак бәкәл кечерәйгәннән-кечерәя барып, эт кадәр генә булып калды. Аннары капка астындагы ярыктан шуышып чыкты да китте…

—Әһә!—диде Маһруй әби. —Аллага шөкер икән! Ат шаукымыннан котылдың болай булгач, балакаем!

Әнинең дә йөзенә элеккеге нуры кайтты.

—Улым, сез бит тайларны көтүгә алып чыкмый идегез, нишләп кичә дә абзарда гына калдырмадыгыз соң?—дип сорады ул.

Инде абый үзенең кайдалыгын тәмам төшенгән иде, ахры, төгәл җавап бирде:

—Кичә дә бикләп калдырган идек, әни. Кешнәүләре белән йокларга ирек бирмиләр, дип, каравылчы Хамматкирам абзый чыгарып җибәргән аларны… Ә җавапны безгә бирәсе инде…

…Дөрестән дә гаепне көтүчеләргә сылтадылар. Бүре бугазлаган тай өчен кәҗәбезне сатарга туры килде безгә. Ә Талибулла абыйлар колхозга бер сарык илтеп бирделәр. Әни әйтмешли, мал малга җиткәнче, Газраил янга җитә, ди. Баш сау булса, мал өчен ничу кайгырырга. Иң мөһиме—Каюм абый ат шаукымыннан котылды!

Хәер, котылды дип өздереп әйтү дөрес үк булмастыр. Хәлбуки, абыйның ат яратуы һич тә кимемәде. Әле офицер булып хезмәт иткәндә дә, кунакка кайткан саен, атлар сараена бармыйча калмый иде ул. "Боларның кайсы минем Ак бәкәлем нәселеннән?"—дип, ат караучы Габделхак абзыйдан сораша. Шул атны яллы муеныннан сыйпый-сыйпый иркәли. Аннары:

—Ат яратмаган татар юктыр ул дөньяда. Безгә борын-борыннан ат җене, ат шаукымы кагылган. Үзенең иярләнгән аты белән дә, "татар" дигән аты белән дә горурланган безнең бабайлар. Безгә шул гадәт нык сеңеп калган,—дип, үзенчә нәтиҗә ясап куя торган иде…

## Уеннан—уймак

Кайбер хәтәр хәлләрнең азагы әкияттәге кебек күңелле генә тәмамланса да, авыр сугыш елларында гел алай булмый иде шул. Ул заманда алдын-артын уйламый әйтелгән сүздән, мәзәктән, хәтта мәҗлестә җырланган җырудан да гаеп табып, кемнеңдер әләкләве белән, аны сәясәткә борулар, бер гаепсез адәмнән халык дошманы ясаулар гадәти хәлгә әйләнде. Мәсәлән, үз кәҗәсен: "һәй, мур кыргыры, Сталин сыеры!"—дип әрләгән Мирза бабайны, даһи юлбашчыбызны мыскыллаган өчен, кулга алып киттеләр. Көннәрнең берендә күрше колхозның рәисен зинданга олактырдылар. Төнлә үз өендә кем беләндер салып утырганда "Колхоз—диңгез, без—пароход, дөбердәтәбез генә…"—дип җырлаган, имеш…

Ә бер көнне колхоз идарәсе каршындагы телеграм баганасы янына узган-барган кешеләр туктала, халык җыела. Баганага карыйлар да, нидәндер шау килеп көлешәләр. Күрсәң-баксаң, кайсыдыр шаяны баганага муеныннан мунчала бау белән чалдырып, тавык үләксәсен һәм бер бәрәңгене асып куйган. Тавыкның муенындагы кәгазьдә мондый сүзләр: "Миңа ел саен 100 йомырка налог салалар. Ач килеш ничек түләп бетерим мин аны? Җитмәсә, әтәчемне дә фронтка алдылар. Болай яшәгәнче, үлүем

артык!" Ә бәрәңге үзенә "кул салу" сәбәбен шигырь белән язып калдырган:

"Иртә дә мин, кич тә мин,
Чуенда да, мичтә мин.
Моннан ары бу хурлыкка
Чыдый алмыйм һич тә мин.

Башымны да кырмагыз,
Күтемне дә кырмагыз.
Басудан әпәй орлагыз,
Миңа ышанып тормагыз!"

Багана янында тукталган һәркем шушы "васыятьнамәләрне" укый да көлә-көлә үз фикерен әсти:

—Ну, шәп әйткән бу, мал-лай!

—Сүлисе юк, прәме өстенә баскан!

—Шулай килештереп кем язды икән, ә?

—Бәрәңгесен дә жәлләмәгән, әй, үзе ашаса, берсәк тамагы туяр иде.

Кай арада бу хәл турындагы хәбәр район үзәгенә барып җиткән, диген. Аннан кара айгырны тиргә батырып, милиция башлыгы Гаскәрев һәм тагын берничә погонлы агай килеп төште.

—Бу нинди саботаж монда? Таралыгыз!—дип кычкырды Гаскәрев, борын астындагы Гитлерныкы кебек квадрат мыегын хәтәр кабартып. —Кем эше бу?!—дип, күзен алартты ул үзен каршыларга чыккан колхоз рәисе Әслахка.

—Бала-чага шаяруыдыр, иптәш Гаскәрев, мин боларны алып ташларга куштым инде...

—Юк, бу дошман эше! Ә сез сыйнфый уяулыгыгызны җуйгансыз, пнимаешь! Без ул кулак калдыгын тиз табарбыз! —Гаскәрев баганадагы язулы кәгазьләрне күн бияләйле бармаклары белән йолкып алып, сумкасына салды.

Шуннан соң ул авылның партия оешмасы секретарен, авыл советы председателен, берничә активистны идарәгә чакырып китерергә боерды. Ләкин болар да әлләни әйтә алмадылар. Бары тик: "Кагыйдәгә туры китереп, сызыклы дәфтәр битенә язылгач, берәр укучы бала эше түгел микән?" дигән уртак фикергә килделәр.

Милиция начальнигы үз иярченнәрен алып, мәктәпкә юнәлде. Болар укытучылар бүлмәсенә бәреп кергәч, анда утыручылар сискәнеп куйдылар. Хәерлегә йөрмәс бу бәндә! Мәктәп директоры Мөгаллимә апа, бик тиз һушына килеп, елмайгандай итенде:

—О, әйдүк, иптәш Гаскәрев. Сезне мәктәбебездә күрүебезгә бик шатбыз,—диде ул.

Мәгәр милиция башлыгының йөзен кара болыт сарган иде.

—Шатланырлык эш юк әле монда! Менә бу язуларны кем язганлыгы кызыксындыра безне,—дип, теге кәгазьләрне өстәлгә җәеп куйды. Язуларны берәмберәм карап чыктылар, әмма таныпмы-танымыйчамы, белмибез шул, диюдән узмадылар.

—Кемнәрнең шигырь язу белән шөгыльләнүен беләсездер бит шәт?—дип сорады Гаскәрев.

—Һи, бездә шигырь язмаган укучы аздыр ул. Югары класс укучылары, борынына кызлар исе керә башлауга шагыйрьгә әйләнәләр. Бер-берсенә шигырь белән истәлек дәфтәрләре язышалар.

—Ә ул дәфтәрләрне без дә укып карасак?—диде Гаскәрев.

—Юу-у-ук, алар аны яшереп кенә тоталар. Бирмәячәкләр.

—Алайса, югары классларда диктант яздырыгыз! Дәфтәрләрне бергәләп тикшерербез.

Һәм бергәләп тикшерәләр дә. Теге, мордар киткән тавык һәм бәрәңге "васыятьнамәләре" белән чагыштыра-чагыштыра тикшерәләр. Һәм, әһә, Гаскәрев бер дәфтәргә йонлач йодрыгы белән шапылдатып суга.

—Менә ул, каналья! Асыл кош аягыннан эләкте! Бер үк кул!

Дәфтәрнең тышына җиденче класс укучысы Нугайбәк исеме язылган булуын күреп, укытучылар хафага төште. Шулай булмыйни? Нугайбәк һәр фәннән отличнога укучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы, мәктәп стена газитен баштанаяк ул чыгарып килә...

Каушаудан-куркудан тагын да агарып төшкән ябык чырайлы үсмерне укытучылар бүлмәсенә җилтерәтеп алып керәләр. Шундук сорау алу башлана. Мәгәр Нугайбәк, уеннан—уймак чыгаруын абайлап, гаебен танудан шүрли, башын гына селки: "Юк, мин язмадым. Мин берни дә белмим!" ди. Аны милиционерлар үзләре белән район үзәгенә алып китәләр.

Шуннан соң, авылда болай сөйләделәр: Нугайбәктән янә бик каты сорау алганнар. "Кем өйрәтте сиңа советка каршы эшне кылырга?!"—дип төпченгәннәр. Юньле җавап алалмагач, башын резин кыршау белән кыса-кыса сорагаННар. Колак-борыннарыннан шаулап кан киткән Нугайбәкнең. Шуннан ул, авыртуга түзә алмыйча, гаебен танырга мәҗбүр булган...

Нугайбәк суга төшкәндәй хәбәрсез югалды... һәм... биш елдан янә калкып чыкты. Ул кайтканда бала хәсрәтен күтәрә алмаган әнисе вафат иде инде. Нугайбәк кайтты. Кайтты, ләкин ул инде элеккеге бик яхшы укыган, зиһенле, шат күңелле яшүсмер булып түгел, ә иртә чаларган башын иеп, каһәрләнгән язмышын яралы күңеленә төреп, аз сүзле, кешеләрдән читләшүчән инсан булып кайтты...

## Тәмле куллы апа

Комбайн ышыгында, саламнан түшәлгән табында тамак ялгап утырабыз. Күршем Миңнур, кулындагы арыш ипие телемен зур итеп кабып куйгач:

—Их, тәмле дә соң, нәкъ Сәгъдия апа икмәге кебек!—диде.

Сәгъдия апа икмәге... Без аны бик еш шулай искә алабыз. Ә кем соң ул?

Сәгъдия апа миңа аеруча якын. Әни ягыннан туган тиешле кеше. Шуңа микән, сугыш елларында һәм аннан соң да әле ул ипи пешергән саен, миңа дип атап, бәләкәй генә ипине (аны безнең якта питрач диләр) безгә дә китерә иде. Әни бу ризыкны янә алты кисәккә бүлә һәм ул бөтен гаиләнең тамагын ялгарга җитә иде. Балтырган, кычыткан, алабута яфрагы кебек үләннәрдән әмәлләнгән аш белән карынны алдап тереклек иткән ул вакытларда әлеге ару оннан пешерелгән ипекәй безнең өзелергә торган тормыш җебен ялгап җибәрергә ярап куя иде.

Сәгъдия апа, мин белә-белгәннән, колхоз механизаторларына ипи пешерде. Осталыгын белеп алгангамы, әллә гаделлеге-тугрылыгы өченме, әлеге изге гамәлне елның-елында аңа кушалар иде.

—Синең кулың тәмле, Сәгъдия апа,—диләр иде механизаторлар.

Ә Сәгъдия апа гадәтенчә кеткелдәп көлеп, болай дия иде:

—Эшләп ашаганга шулай ул, наныйлар, тир түгеп алганга...

Аның салам түбәле, җыйнак кына өе яныннан без—малайлар да тыныч кына узып китә алмыйбыз. Тирә-юньгә таралган тәмле ипи исеннән авызга сулар килә, адымнар акрыная, хәтта уен да онытылып тора. Яңа гына мичтән чыккан ипи исеннән дә тәмлерәк ис бармы икән тагын дөньяда?!

Әнә, ачык тәрәзәдән Сәгъдия апаның кояш кебек түм-түгәрәк ипиләрне кызыл ашъяулыкка куеп, тигез кисәкләргә бүлгәләве күренә. Кырга, механизаторларга илтер өчен әзерли инде ул шулай. Аның кояштанмы, әллә мич кызуыннанмы, алсуланган куллары ипине шундый оста әйдәндерә ки, сабый баланы чәбәкли-чәбәкли бишеккә сала дип белерсең. Бу эш аңа әллә ничек килешеп үк тора. Ипине тагын да тәмлерәк булсын өчен шулай тылсымлый диярсең.

Ул арада Сәгъдия апа да безне күреп ала. Кулларын чигүле ак алъяпкыч итәгенә сөрткәләп, тәрәзәгә килә:

—Нәстә сез, гашыйк егетләр кебек, күзегезне ала алмыйсыз әле?!—ди ул, кеткелдәп. —Беләсегез килсә, сез бит янгыннан калган баганалар инде. Сезнең язмышларны бик яшьли сугыш көйдерде шул, наныйлар.

Без дәшмибез, борыннарыбызны тарткалап, яланаякларыбыз белән юл тузанында таптанабыз.

—Аңлашылды,—ди Сәгъдия апа һәм юка гына ипи телемнәре кисеп, тәрәзәдән суза. —Мәгез, наныйлар, тамак ялгап алыгыз. Картым белән улымның сугыштан исән-сау кайтуларын теләгез.

Әтисе сугышта һәлак булган Миңнурга һәм, туган булларактыр инде, миңа калынрак телем эләгә.

—Үсеп җиткәч, үзегез иккәне белән игелек күрсәтерсез, наныйлар,—ди Сәгъдия

апа, безне озатканда.

Сугыш бетеп, авылдагы морҗалардан ипи исләре тарала башлагач, таныш сукмак ничектер онытылды. Моңа, бәлки, безнең теләкләрнең кабул булмавы да сәбәпчедер. Теләк теләгәндә Ходайны искә ала белмәдекме икән әллә? Безне ипи белән сыйлаган юмарт апабызның газиз кешеләре сугыш мәхшәреннән әйләнеп кайта алмадылар...

Мәктәптә укулар тәмамланып, ап-ак калачны мазутлы кулларыбыз белән үзебез эшләп ала башлаганда, механизаторлар өчен ипине Сәгъдия апа түгел, пекарняда ул өйрәткән кыз-кыркыннар сала иде инде.

...Уйларымны Миңнурның тәкъдиме бүлде:

—Әйдәгез, Сәгъдия әбигә бер бөтен ипи алып барабыз! Бүген үк, эштән соң...

Без килгәндә Сәгъдия әби сәкедә, камыш намазлыгы өстендә оеп утыра иде. Шыпырт кына аның намазын тәгәлләвен көттек.

Менә ул озак итеп дога кылды, авыз эченнән илгә-көнгә изге теләкләрен теләгәннән соң, әкрен генә кузгалып, намазлыгын җыештырып куйды. Шуннан соң гына, төсе уңа башлаган коңгырт күзләрен безгә текәде:

—Сез кем малайлары буласыз, оланнар?—диде ул, аз гына калтыранган башын туры тотарга тырышып.

—Исәнме, Сәгъдия әби? Без—синең малайларың булабыз. Син кайчандыр ипи белән сыйлаган ташбашлар. Менә үзебез эшләп алган ипине алып килдек сиңа.

Сәгъдия әбинең еллар сырлап узган, ләкин иман нуры сирпелеп торган йөзендә бер мәлгә аптырау галәмәте чагылгандай булды. Аннары хәтеренә төшерде бугай, авызын ак яулык чите белән каплый төшеп, элеккечә кеткелдәп көлде:

—И-и, наныйларым, сезмени бу?! Танымый да торам лабаса. Ай, рәхмәт яугырлары.

Ул ипине яшь бала күтәргәндәй, йомшак кына итеп кулына алды:

—Уңган күренә. Чүпрәсе дә, кабаруы да килгән моның. Улларым эшләп алган булгач, бигрәкләр дә тәмледер әле бу ипекәй. Әйдәгез, узыгыз. Сезне үзем салган әпәй белән сыйлармын. Әнә, чәем дә кайнаган, самавырым табында көтә безне... Күңелем сизгән күрәсең, намазга утырганчы ук кайнатып куйган идем...

## Әти урманы

Авылга кайтканда мин иң әүвәл Зариф урманы белән күрешәм. Киткәндә иң соңыннан Зариф урманы белән саубуллашам. Кайтыр юл да, китәр юл да шушы урман аркылы уза. Җил-җиләсле агачлар арасына килеп керүгә, яфраклар кыштырдавында әтием тавышын ишеткәндәй булам.

...Үземне белә-белгәннән бирле минем әти урман каравылчысы булып эшләде. "Габделмәгъйз абзый ул—урманны да тунатмас, утынсыз да калдырмас",—диләр иде авылдашлар аның турында. "Урман җене кагылгандыр сиңа, шуннан кайтып кергәнең юк. Ялгыз ничек кенә эчең пошмыйдыр урманда",—ди әни дә еш кына. Әти исә нарат сагызыдай саргылт мыегы астыннан елмая гына:

—Урманда кеше ялгыз буламыни?! Урман җанлы бит ул.

Чыннан да, әти урманга җитте исә агачлар белән сөйләшә башлый:

—Иһи-һи, матурым, сугыш зәхмәте сиңа да кагылган икән,—ди ул, корыган имән янына тукталып. —Шыр сөяккә калгансың лабаса. Кышлары зәһәр килде шул, кышлары. Сугыш узган урманнарның хәле сезнекенә караганда да мөшкелрәк булды. Агачлар да солдатлар кебек сугышты фашистка каршы. Күпме партизан туган өе итте урманны...

Әти агач тамырлары кебек кытыршы бармаклары белән әле бер кәүсәне, әле икенчесен сыйпый-сыйпый һаман әчкәрәк атлый. Ә минем тизрәк авылга, дуслар белән уйнарга кайтасым килә. Әледән-әле:

—Әти, кайтыйк инде-е,—дип куям.

—Кайтырбыз, улым, сабыр әйлә,—ди әти. —Әниеңнең чәе дә өлгермәгәндер әле. Күрәсеңме, никадәр агач корыган, алар урынына язын яшь үрентеләр утыртырга кирәк булыр. Ир-егет үз гомерендә, ким дигәндә, бер өй салырга, бер булса да агач утыртырга тиеш.

Ниһаять, без кайтыр юлга борылабыз. Урманны чыккач, әти ике көпшәле мылтыктан һавага атып җибәрә. Бу аның әнигә:

“Без кайтырга чыктык, чәеңне әзерли тор!”—дигән шартлы сигналы.

...Кайчандыр бөтен мәктәп белән бергәләп утырткан яшь агачлар инде үсеп җитте. Алар да урманга кушылып шаулыйлар. Без дә җиткән егет булдык. Тик әти генә картайды. Күптән ялга чыгарга вакыты җитсә дә, урманын ташламады ул. Тамырланып китә алмаган үсентеләр урынына яңаларын утыртып, шуларның төпләрен йомшартып йөри бирде. Тагын шунысы бар: өлкәнәйгән саен агачларны кайгыртуы, урманга булган сакчыллыгы һаман арта барды аның. Ул инде утынга да үсеп утырган агачларны кисми, төпсәләр генә кубара башлады. Иртә таңнан балтадыр, ломдыр алып урманга китә. Күлмәге лычма тир белән аркасына ябышканчы төпчек кубара. Яфрак-туфрак белән томаланган булсалар да, аларны тиз таба ул. Кайчандыр шул урында мәгърур гына шаулап утырган имән егетләрен, каен кызларын, усак малайларын яхшы хәтерлидер, күрәсең. Үзе төпчек кубара, үзе иске танышын очраткандай сөйләнә:

—Мынатыраккынасы, синә да вакыт җитте, матурым. Картаймыш көнеңдә тагын бер ялкынланып алырга насыйп икән әле...

Инде мин бала вакыттагы кебек әтине ашыктырмыйм, шулай да төпсәләрне арбага төяп, олауны әйбәтләп бәйләнгәннән соң да, әтинең һаман ашыкмавын абайлагач, әйтми булдыра алмыйм:

—Кайтырга вакыт түгелме икән, әти?

—Кайтырбыз, улым, кайтырбыз,—ди әти,—бераз сулу алыйк. Урман агай белән дә сөйләшеп туймадым бит әле...

...Инде мин дә урман телен аңларга өйрәнеп килəм бугай. Аның әкрен искән җилдә моңлы гына шаулавы миңа әтием тавышы булып ишетелә.

## Тамырлар

Без Кадыйр абый белән өлгереп килгән иген басулары буйлап атлыйбыз. Күпме күзәткәнем бар: сәхрәгә чыктымы, аның җилдә каралган йөзе яктырып-балкып китә, тургайлы күк, иркен кырлар чагылган зур коңгырт күзләре тагын да ягымлылана төшә, хәтта ки ул үзе дә янә бер карышка калкуланып-үсеп киткәндәй була. Бөдрә чәчләрен тузгытып искән җил кебек, иген кыры, тургай моңы кебек табигый тота ул үзен биредә. Аның белән ни турында гына гәпләшмик, сүз, ничектер, үзеннән-үзе игеннәр иленә килеп тоташа. Ул һәр басуга туктала-туктала уңышның күпме чыгасын күзе белән үлчәп-чамалап ала, теге яки бу сортның үзенчәлеге, холкы-фигыле турында мавыгып сөйли. Үзе, барган уңайга, басу кырыйларында аллы-гөлле булып көязләнеп утырган билчән, сөтле үлән, солыча кебек чүп үләннәрен йолкып-йолкып ыргытырга да өлгерә.

—Болардан бик матур бәйләм ясап булыр иде,—дим мин.

Кадыйр абыйның зур коңгырт күзләре миңа елмаеп-сынап карый.

—Иген арасында чәчәк дигәнең дә чүп үләне генә булып кала шул, энекәш...

Имәнсәр янына җитәрәк ул, ниндидер хикмәт очраткандай тукталып, карашын бер ноктадан аермыйча торды. Аннары иелде дә сак кына йолкып алды. Челән борыны кебек нечкә генә кузаклы торна борчагы иде бу. Агроном абый аны башка чүп үләннәре кебек итеп читкә атмады, кузакларын җыеп, икегә бүлде дә кулларын аркасына яшерде:

—Кайсы кулдагысын аласың?—диде ул елмаеп.

Нәкъ бала вакыттагы шикелле...

...Без Кадыйр абый белән куышып диярлек үстек. Бәйрәм көннәрендә генә авызга “ару” аш эләгә торган сугыш заманы иде ул. Башка көннәрдә әни ашны һәртөрле үлән яфракларыннан пешерә. Ә бу “витаминнарны” җыеп кайту безгә—ике малайга йөкләнгән.

Иртә таңнан көтүне куып кайтуга әни тегеп биргән капчыкларыбызны алабыз да урманга, Болан сазлыгына юнәләбез. Монда нинди генә нигъмәтләр юк: балтырган дисеңме, какы, дәгел дисеңме, елан көпшәсе, кузгалак дисеңме, зәрдә яки каз тәпие дисеңме— бары да бар. Шулар белән капчыкларны шыплап тутыргач, баеп барган кояшка аркан борылып, кайтыр юлга кузгалабыз. Кадыйр абый алдан атлый, мин—аның артыннан. Капчык авырлыгыннан иелгәнгә мин аның үзен күрмим, бары тик аю табанычдай билсез аяк эзләренә генә карап кайтам. Эзләр алга таба ераклаша бара,

ераклаша бара. Капчык бавы тирләгән кулларымнан акрынлап түбән таба шуыша. Урман авызына чыгып җитәбез дигәндә капчык кулдан бөтенләй ычкынып китә. Мин, гарьләнеп-үҗәтләнеп, аны кабат күтәрмәкче булам, ләкин никадәр генә азаплансам да, капчыкның яңадан минем арык җилкәләремә менәсе килми. Мин, еларга җитешеп, ачудан капчыкны типкәлим.

Кадыйр абый туктый, тирләгән маңгаен күлмәк җиңе белән сөрткәләп миңа карый:

—Нәрсә, чыгымчылыймыни? Шулай, үлән ашы ул барганда гына алып барам, кайтканда миңа ышанмагыз, дип әйтә ди шул, энекәш. Ярый, борыныңны салындырма, хәзер тыңлатабыз аны.

Ул ике капчыкның авызын юкә кабыгы белән тоташтырып бәйли дә үз җилкәсенә атландыра.

—Киттек!

Булдыксызлыгыма кәефем кырыла, иреннәр бүлтәя, гаебемне аклыйсым, Кадыйр абыйга ничек тә ярдәмләшәсем килә. Теләк кенә булсын, җае табыла дигәндәй, юл читләрендә сузаеп утырган торна борчакларын җыя башлыйм. Вак кына әчкелтем борчакларны кузакларыннан бөрчим дә Кадыйр абыйның авызына каптырам, бөрчим дә каптырам.

—Молодец, энекәш, атны шулай, чыбыркы белән түгел, солы белән куарга кирәк аны! —Бу сүзләр мине тагын да дәртләндереп-канатландырып җибәрә.

Борчак белән мавыгып, ындыр артына кайтып җитүебезне сизми дә калабыз. Шул көннән башлап мин торна борчагын алдан ук хәстәрләп бара торган булдым.

—Әйдә сугыштан кайткан төшенә әтигә дә торна борчагы җыеп куябыз!

Бу тәкъдим икебезгә дә бик ошады. Инде җыелган борчакны өчкә бүлә башладык. Ике өлешен үзебез тәмләп ашыйбыз, бер өлешен әтигә дип җыеп куябыз.

...Соңыннан, әти фронттан кайткач, үзен торна борчагы белән сыйлавыбыз турында кеткелдәп көлә-көлә искә ала торган булды. Шул вакытта яшьләнгән күзләрен җиң очы белән сөрткәләп алуы да хәтердә...

...Солдат хезмәтеннән соң Кадыйр абый туп-туры Казан авыл хуҗалыгы институтына кайтып керде. Авыз тутырып "ару ипи" каба алмый үскән авыл малаеның бу адымына берәү дә гаҗәпләнмәде. Сугыш елларында күбесенчә кысыр калып, чүп үләннәре баскан туган туфракта һәммә кешегә җитәрлек икмәк үстерергә хыяллануы табигый хәл иде.

—Кыргый үсемлекләрнең генетик мөмкинлеге гаять зур. —Кадыйр абыйның күкрәктән чыккан ягымлы тавышы мине яңадан бүгенгегә, рәшә уйнап торган кырга кайтарды. —Утыйсың, йолкасың, гербицид белән агулыйсың—барыбер үсәргә җаен таба, шайтан.

Кадыйр абый туфрак галимнәренең, башлыча Нобель премиясе лауреаты Норман Борлаугның бу өлкәдәге гаҗәеп эшләре турында сөйли. Галимнәрнең әйтүенчә, чүп үләннәрнең культуралы үсемлекләр өчен зарары гына түгел, файдалы яклары да бар икән ләбаса. Башлыча, алар җирдәге дымны яхшы саклый икән. Каршылыклы бу дөнья дигәнең...

Агроном абый, минераль ашламаларга күчеп, аларны сакларга биналар җитенкерәмәүдән, шул сәбәпле никадәр кыйммәтле-туклыклы матдәләрнең ачык һавада исраф булып, юкка чыгуыннан зарланып ала да янә кулындагы торна борчагына кайта:

—Тамырга ашлама кирәк, ләкин ашламаны суырып алыр өчен тамырның да нык булуы мөһим,—ди ул, торна борчагының тырпаеп торган калын тамырларын аралаштыргалап. —Әйтик, менә шушы кыргыйларның тамыр көчен ипекәйгә күчерәсе иде. Тамырда бит хикмәт...

"Әйе, хикмәт тамырда шул",—дип кабатладым мин, үзебезнең нәсел-тамырларыбыз шәҗәрәсенең игенчеләргә тоташкан булуын уйлап.

## Ачы какылар

Туган авылыма кайткан саен мин зират яныннан урап килмичә калмыйм. Бу изге урынга аяк басуга күңелне чиксез бер дулкынлану хисе биләп ала, җанны ниндидер сәмави бер моң сара. Кайчандыр шул тирәгә, Түбән очка, болын ягыннан көтү

каршыларга төшүләр, көтү кайтканны көткән арада зиратка какы җыярга сугылган чаклар хәтердә яңара. Менә әле дә карт тирәкләр, мине таныгандай, талгын җилдә шыбырдашалар. Ә шул тирәкләрнең ябалдашына оя корган каргалар да, нәкъ балачактагы сыман:

—Кар, кар, ка-ар! Кар, ка-ар!—дип сәламлиләр. Әнә кемдер иске бер кабернең тузган рәшәткәсен алыштырып маташа. Якынрак киләм. Күршем Гомәр ләбаса. Агроном Гомәр. Янында чем кара күзле, йомры башлы малай да бар.

—Бу—күрше абыең булыр,—диде Гомәр, аңа мөрәҗәгать итеп. —Хәтерләмисеңмени? Узган ел конфет алып кайткан иде бит үзеңә.

Бераз дәшми торганнан соң малае:

—Бабайны да сурәтеннән генә күреп беләм ич мин, әти,—дип куйды. Аның тоныграк күкрәк тавышы миңа бик тә үз тоелды. Әйе, Гомәрнең дә балачакта сөйләшүе нәкъ шундый иде бит. Аның шушы зиратта: "Әти-и, мин монда-а..." дип еламсырап әйткән тавышы яңгырап киткәндәй булды.

...Күрше Галим абый сугыштан яраланып кайткан иде. Янында чибәр генә бер апа да бар. "Шәфкать туташы икән. Галимне әҗәл тырнагыннан шул гына алып калган икән, инде өйләнешкәннәр..."—дип сөйләделәр авылда. Тиздән аларның улы—Гомәр туды. Ләкин яшәү белән үлем янәшәдә генә йөргән. Улының: "Әттә!"—дип теле ачылуын да ишетә алмыйча, иске яралары ачылып, Галим абый вафат булды.

Үзеннән берничә яшькә олырак булсам да, Гомәр күбрәк минем белән уйнап үсте. Хәер, бик күп уйнарга да туры килмәде безгә. Буразнада абынып егылмаслык булып җирдән калкуга әниләрнең кул арасына керә башладык. Безнең иң зур эш—иртән көтү куып, кичен терлекләрне каршы алу иде. Юл уңаенда киртә арасыннан кысыла-кысыла зиратка керәбез, "бисмилла"бызны әйтә-әйтә, какы җыеп чыгабыз. Тамак тәмугка кертә, диләр бит...

Шунысы гаҗәп, зиратка кердекме, Гомәребез агачлар арасына кереп китә дә гаип була, югала. Аннары, ничек кинәт югалган булса, шулай искәрмәстән килеп безгә кушыла. Үзенең кулында какысы да бик аз, күзләре дә кызарган шикелле.

—Җыйган берен ашап барасың инде әллә?—дип сорыйм.

—Әйе.

—Ә күзләрең нишләп кызарды?

—Какы ачысыннан.

Көннәрдән бер көнне без сиздермичә генә аның артыннан сагалап бардык. Гомәр зиратның аргы башындагы кызыл йолдызлы чардуган каршына килеп тезләнде. Әтисенең истәлеккә калган, кояшта уңып беткән пилоткасын башыннан салып кулына тотты.

Бу якка искән җил белән аның:

—Әти, мин монда-а... мин быел укырга керәм... Әни әйтте... Әти-әти...—дигән өзек-өзек сүзләре ишетелде.

Без, яшеренгән урыннарыбыздан чыгып, Гомәр янына килдек. Үзен зурлар кебек тотарга яратучы Әнвәр әйтеп куйды:

—Нишлисең бит, малай, үлгән артыннан үлеп булмый. Үлгәннәр дә кире кайталмый.

—Дөрес түгел, минем әти кайтачак!—диде Гомәр яшенә буылып. —Әни беләме, әллә синме?

—Әле хет синең әтиең авылга кайтып җитә алды... Минем әтинең кабере дә билгесез...

Без, юатырга тырышып, Гомәргә үзебезнең какыларыбызны бирдек. Ул бер сабакны кабарга дип авызына китергәндә какыга күз яше тәгәрәп төште. Малай какыларны кире сузды:

—Ачы...—диде.

Күршем рәшәткә куйган арада без әнә шуларны искә алып, хатирәләргә биреләдек.

—Ә шулай да, әти кайтачак дип дөрес сукалаганмын бит,—диде Гомәр, зур учлары белән улының кара бөдрә чәченнән сөеп. —Менә Ирек улымны гел дә бабасы кебек, диләр...

—Ә какы ачы дип дөрес әйтмәгәнсең, әти,—диде малай. —Какы бер дә ачы түгел, какы бик тәмле.

Без Гомәр белән гаҗәпләнеп бер-беребезгә карашып куйдык.

—Без ашаганнары ачы иде шул, улым. Сезгә андый ачыны татырга язмасын инде берүк!

## Су тәме

Авылдан хат килде. “Абый, кышкы каникулда барып чыгарга уйлыйм. Сезгә бирер әйбер алып киләсе түгелме? Бал, бәрәңге, ит-мазар кирәктер, бәлки…”—дип язган Салих энекәш.

Мин уйга калдым. Йомышым юк түгел. Авылдан китертергә ниятләп, нык сагынган-тансыклаган әйберем бар минем. Тик ул энекәш язганнарның берсе дә түгел. Бәлки, энекәшкә сәер булып та тоелыр. Чөнки мин тансыклаганы шәһәрдә дә дефицит түгел—торбадан фатирыма шаулап килеп тора. Кранны гына борасы. Әйе, әйе—су. Идел янында да суга сусыйсың икән шул. Хәлбуки, мин тансыклаган су гади генә түгел, ә туган авылым суы! Үзебезнең ындыр артында кайчандыр әти белән икәү тапкан чишмә суы…

Бүгенгедәй хәтеремдә: әтинең сугыштан, Бөек Ватан сугышыннан кайткан елы иде. Солдат итеге белән нык-нык басып бәрәңге бакчасы казый. Бәләкәй генә көрәгем белән мин дә әтигә булышкан булып йөрим. Яз исе, дымлы туфрак исе, яшь бөреләр исе борынны кытыклый. Рәхәт.

Бервакыт әти мине үз янына чакыра.

—Күрәмсең, улым?—ди.

Карасам, көрәк эзеннән мөлдерәп чыккан су буразна буйлап эз салырга азапланып ята. Мин көрәгем белән туфрак сибеп караган идем, шундук яңадан бәреп чыкты.

Әти:

—Чишмәне томаларга ярамый, улым, гөнаһ була!—диде дә учларын төкереклəп, су чыккан урынны казый, тирәнәйтә башлады. Көрәк сабының яртысы күмелерлек булгач, су яхшы ук тибә башлады. Шуннан соң әти аны янәшә генә агып яткан инешкә борып төшерде. Чишмә суы, үзенә бертөрле тавыш белән челтерәп, зур суга кушылды. Гүя ки ул үзенә юл сапканга шатлана, безгә рәхмәт әйтә иде.

Икенче көнне әти чишмәгә каен бура төшерде. Ян-якларына түгәрәкләп тал утыртты. Ялга туктаган арада сугыш хатирәләрен дә сөйләп алды.

Әти сугышта артиллерист булган. Дөресрәге, туп тартып йөрүче атларны караган.

—Дошман—елан, үзе чигенгәндә еш кына суларны да агулап калдыра иде,—дип сөйли әти. —Шунлыктан атларыма суны буралы чишмә, коелардан алмыйча, яңа гына төшкән снаряд чокырларыннан эчертә идем. Җир, улым, безнең халык күңеле кебек бит ул, аз гына кагылдыңмы, чишмә булып ургый. Дошман гына агулап бетермәле түгел аны. Әйе!.. Үзебезгә дә шул яңа чишмәләрдән су алып чәй куя идек…

Кичен әти чәйне яңа чишмә суыннан кайнатырга кушты. Самавырны Кенигсбергтан алып кайткан иде. Янбызына дистәләгән медаль төшерелгән Тула самавыры. Фашистларның да чәй эчеп карыйсы килгән, күрәсең, бездән талап алып киткән булганнар. Әти чәй яратканга аны калдырмаган, үзе белән алган, тик самавырның юлда борынын гына югалткан. Әти аңа яңа борын куйды. Солдат самавыры, күпне күрсә дә, гамәлгә яраклы иде.

Әти, беренче чәшкәне агызып “каплап” куюга, самавыр җизе төсендәге мыекларын сыпыргалап:

—Булган бу, әкәмәт!—дип куйды. —Кәүсәр чишмәсеннән бер дә кайтыш түгел икән ләбаса.

Шул көннән башлап әти самавырны үзебезнең чишмә суыннан гына куйдыра торган булды. Күршедә генә кое бар югыйсә. Суы да көмеш кебек чип-чиста, алып чыгу да җиңелрәк. Үзебезнең чишмәдән китергәндә тау менеп, тау төшәсе бар. Ә бу эш минем өстә…

Кайвакыт суны күрше коедан алам да чишмәдән китердем дип хәйләлим. Буламы соң! Әти иренен тидерү белән үк сизеп ала.

—Нинди судан куйдыгыз самавырны?—дип сорый.

—Чишмә суы белән,—ди әни, мин әйткәнчә.

—Кил әле, эчеп кара әле.

Әни татып карый да:

—Әллә инде тагын. Сукыр тавыкка бар да ярма. Су—су инде,—ди.

Әти җиз мыегын учы белән сыпыргалый:

—Мин үзебезнең чишмә суын дөньядагы бернинди су белән буташтырмыйм, алыштырмыйм да. Ә сез, әкәмәтләр, түмен дә аермыйсыз...—дип куя. Аннары, чәшкәсен читкә этәреп, ачусыз гына әйтә:

—Малай, тагын бер мәртәбә алдашсаң, матри,—ди.

"Су булгач, барыбер түгелме икәнни. Әти аның түмен ничек аера икән?" дип, шакката идем.

Инде хәзер төшендем. Үзем дә су тәменә сизгерләнә барам. Туган җир суы башка сулардан аермалы була икән шул. Чит җирләрдә йөреп, туган ягын өзелеп сагыну сусавын кичергән кеше генә тоядыр аның чын тәмен...

## "Кибән башы"

Кешеләр күп уза бирәдән, әмма чүплек савыты янында, тәмәке төпчекләре арасында тилмереп яткан "кибән башы"на илтифат итүче юк. Инде мин дә узып киткән идем. Шулай да нидер исемә төшкәндәй тукталдым, акрын гына кире борылып килдем. Ипи телеменең кабылган урыны—авыз шикелле булып, миңа нидер әйтте кебек. "Оныттың да мыни?! Хәер, хәтерләмәсәң дә, гаеп итеп булмый. Ул вакытта сабый гына идең шул әле син..." —Ипи телеме миңа гүя шулай эндәште.

...Онытып буламыни ул көннәрне?..

Безгә бик күп кеше җыйналган иде. Менә ишекне киң ачып, өйгә бер өер салкын ияртеп, әти кайтып керде. Керде дә мине көчле кулларына алып күкрәгенә кысты. Аның җиз мыеклары битемә орынды, муенымны кытыклады. Тик мин башка вакыттагыча көлә алмадым—әтинең кызарган күзләрендә яшь тамчысы елтырый иде...

Әни өстәлгә мичтән яңа алынган түм-түгәрәк ипи китереп куйды. Әти "кибән башы"н кисеп алды да, читеннән тешләп, калганын әнигә бирде. Әтинең нигә шулай эшләгәнен мин соңыннан гына белдем.

—Ипи телеме аны ашый башлаган кешенең исән-сау әйләнеп кайтуын тели, улым. Адәм баласын ризыгы тартып кайтара,—диде әни.

Шуннан без әтине сагынган-юксынган саен сандыктагы кадерле икмәкне алып карый, караган саен әтине ныграк сагына торган булдык. Әти булмагач, ничектер өй дә салкын, аш та тәмле түгел кебек иде. Ашка кычыткан, балтырган кебек нәрсәләр кушылды. Хуш исле арыш ипиен черек бәрәңге кәлҗемәсе алыштырды. Инде теге "кибән башы"на караган саен, әтине генә түгел, авыз тутырып тәмле ипи ашаган бәхетле көннәрне дә сагынабыз, авызга ирексездән сулар килә иде. Эх, бер генә кабып карарга! Юк, ярамый. Мин ашамыйча да түзәрмен, тик әти генә исән-сау әйләнеп кайтсын!

Шулай да "кибән башы"н бер көнне чак кына ашамый калдым бит, әй. Авырып тора идем. Кичкә таба төшләнә-саташа башлаганмын. Имеш, әни мич тутырып ипи пешергән. Өйгә тәмле булып яңа пешкән ипи исе таралган. Әни зур гына бер телем кисеп миңа суза:

—Аша, улым, аша,—ди.

Күзләремне ачсам, чыннан да, әни минем кулыма ипи тоттырып маташа иде. Әлеге "кибән башы"н.

—Аша, улым, әтиең болай да исән-имин кайтыр Аллаһы боерса, аша. Сугыш туктагачтын, моннан да тәмлерәк ипиләр пешерербез әле,—ди әни, үзе яшьле күзләрен миннән читкә яшерә.

Мин хәлсез кулларым белән ипи кыерчыгын күкрәгемә кыстым. Шул килеш кабат изрәп киткәнмен. Уянып, күзләремне ачсам, өйгә кояш нуры тулган. Баш авырту да, күңел болгану да беткән кебек. Күкрәгемдә нинди каты нәрсә бар дисәм, "кибән башы" икән. Ярый әле ашамаганмын дип сөенүемнең чиге булмады.

...Сугыш бетте. Әти яраланган килеш булса да әйләнеп кайтты. Ул алып кайткан "куян калачы" белән мавыгып, сандыктагы кисәк турында чүт кенә онытып җибәрмәгәнмен. Сандыкны ачып, "кибән башын" алдым да әтигә суздым.

—Әти, ипекәйнең кешене сугыштан исән-сау алып кайтуы дөресме?—дип сорадым мин.

Әти, "кибән башы"н тамырлары бүртеп торган кулына алып, учы белән сыйпый-сыйпый бераз уйланып торды да әйтте:

—Дөрес, улым, хак әйтелгән сүз ул,—диде. —Гитлер мәлгуньне җиңәргә

булышучы да, безне сугыш мәхшәреннән саклап алып чыгучы да шушы—туган як ипекәе булды…

…Уйларымнан айнып, чүплек савыты янында аунап яткан ипи телеменә карадым. Ул да үзен ташлап калдыручының яңадан кадерләп кулына алганын көтәдер шикелле тоелды миңа.

## Моң

Филармониядән килгән егет баянын сайрата.

Бу моң минем йөрәгемдә күптән тамырланган. Тик тормышның эреле-ваклы мәшәкатьләре вакыт-вакыт аны томан эченә күмгәндәй итә.

Авыл чирәмендә бергә тәгәрәп үскән Адашларда (икебезнең дә исемебез бер булганга, без бер-беребезгә шулай эндәшәбез) бәйрәм ясап утырганда әлеге моң һич уйламаганда-көтмәгәндә яңадан кузгалды.

Җыр-көйне үлеп яратканымны белгәнгәме, Адаш кунакка баянчы егетне дә чакырган булып чыкты. Филармониядән икән. Егет, чыннан да, көйләрнең хасиятен белеп, барлык бормаларын табып, бөтен шартын китереп уйный.

Шулай уйнап-җырлап утырганда күзем өстәл читендәге бәләкәй тальянга төште. Сәерсенепме дим, хәйран булыпмы, аңа карап телсез калдым.

—Таныдыңмы әллә, Адаш?—диде авылдашым һәм гармунны сузылып алды.

—Танымыйча! Кыңгыравына, күрегенең һәр сырына кадәр таныш лабаса. Сәгыйтьваккас гармуны ич бу!

Сәгыйтьваккас… Авылыбызның атаклы гармунчысы иде ул. Яшькә бездән әллә ни өлкән булмаса да, күбрәк зурлар арасында үсте. Безнең ише малай-шалай якын да килә алмаган кичәләрдә, аулак өйләрдә, мәҗлес-мазарда башына чиккән түбәтәен кигән, кулына тальянын тоткан Сәгыйтьваккасның урыны һәрвакыт түр башында булыр иде. Уйнавын да уйнап карый иде шул: чылтырап аккан чишмә тавышыдай гаҗәеп авазлар күңелне сихерли, җанны иркәли, сине гүя ки тылсым канатларында еракка-еракка, әлегәчә күрмәгән-белмәгән гаҗәеп ямь дөньясына очыртып алып китә иде.

Ил өстенә яу ябырылып, авылыбызның ир-егетләрен сугышка озата башлагач, Сәгыйтьваккасның гармуны тагын да моңлырак уйный башлады. Кыңгыраулы тальян гармун фронтка китүчеләрне җырлатып урам әйләндерә, авылны чыкканчы озата бара, аннары, үзәкләрне өзеп, ялгыз гына моңаеп кайта. Ялгыз дип, гармунчы ялгыз каламы соң? Без аны хөрмәт йөзеннән "уфалла" арбасына утыртып кайтабыз. Ә ул уйнавын гына белә. Башын кыңгыр салган. Бизәкле кәләпүше эченнән бөселеп чыккан саргылт чәчләре җилдә тузгый. Җилдәнме, әллә болай гынамы бераз дымсуланган зәңгәр күзләре әллә кая—Чирмешән буйларыннан да узып, офыкка төбәлгән…

Ә көннәрнең берендә аның үзенә дә чират җитте. "Сәгыйтьваккасны каралырга чакырганнар икән", дигән хәбәр һәммәбезне әсәрләндерде.

—И-и, наныкаем, гармунчысыз калырбыз микәнни?! Безнең күңел моңын синеңчә матур итеп кем генә әйтер инде?!—диештеләр фронтовик хатыннары.

Саулыгы чамалы булган, күрәсең—сер бирми генә йөргән—Сәгыйтьваккасны солдатка алмадылар. Мәгәр ул үзе моңа бер дә шатланмады. Район үзәгеннән кайтып килешли гармунын да кулына алмады. Кичен дә тальянның тавышы-тыны чыкмады.

Берничә көннән соң гына яңадан телгә килде тальян. Элеккегә караганда да моңлырак-хәсрәтлерәк иде аның тавышы…

"Сәгыйтьваккас, сыер җигеп чәчүлек орлык ташыганда язгы суга баткан, шунда аякларына салкын тигән. Чирмешән аша ничәмә-ничә капчыкны корыга чыгарган бит. Шунда җилегенә үткән суык хәзер йөрәгенә төшкән икән…" —Авылда әнә шундый хәбәр йөрде.

Сугышның дүртенче язында без Чирмешән бозлары өстенә яккан утлар белән бергә кайгы-хәсрәтләребезне дә агызып җибәрдек шикелле.

Язгы талгын җилләр: "Сугыш бетте! Фашистлар Германиясе тар-мар ителде!"—дигән шатлыклы хәбәр китерде.

Яу кырына төркем-төркем булып киткән ир-егетләр берән-сәрән генә кайттылар. Әйләнеп кайтучылар арасында Сәгыйтьваккасның әтисе дә юк иде. Кара кайгы, төпсез тобадай тирән хәсрәт иде бу аның өчен. Иллә мәгәр кайгы кочаклап кына яши алмый

бит тәнендә җаны бар кеше! Егетнең гармуны күңелле-дәртле көйләрдән дә йөз чөермәде. Киресенчә, дәртле көйләрне юлдаш итте. Армиягә китүчеләрне озатканда да тальян ул кадәр сагыш-моң түкми иде. Китүчеләр дә:

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар,—

дип моңаймады. Исән-имин кайтасын беләләр, аяз күккә, тонык суларга карап, ил сагына көр күңел белән китәләр иде. Тик гармунчының зәңгәр күзләре генә моң белән мөлдерәмә тулы иде.

Мине дә гармун уйнап, җырлатып, Сәгыйтьваккас озатты.

—Яхшы хезмәт ит, ә мин гармун уйнап, әниеңне дә, үз дигәнеңне дә юата торырмын,—диде ул, көлемсерәп.

Күңелгә бәлзәм булып яткан гармун моңыннан соң аның үз тавышы гадәттәгедән тонык булып ишетелде.

—Ярый, Сәгыйтьваккас дус, гармун уйнап каршы да алырсың инде,—дидем мин. Ул дәшмәде. Моңсу гына елмайды да тальянын сузды.

Тик... аңа безне каршылау насыйп булмады. Сагынып көтеп алган хатларның берсе миңа авыр хәбәр китерде: "Сәгыйтьваккас вафат!..

Мин ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Бик ышанмас идең, тәфсилләп язганнар: "Башын тальяны өстенә куеп тынсыз калган. Духтырлар, йөрәге кинәт туктаган, диделәр..."

...Сәгыйтьваккасның үзе юк, гармуны безнең белән. Ил-көн өчен иң кыен елларда авыл халкын юаткан да, елаткан да тальян гармун...

Сугыш дәһшәте һәм тальян гармун моңы... Бер-берсеннән чиксез ерак тоелган шушы ике төшенчә минем күңелдә бер-берсенә бәйләнеп калды. Каһәрле сугыш булмаса, бәлки, меңләгән Сәгыйтьваккаслар бүген үзләре дә безнең арабызда булыр иде.Бәлки, минем мөлаем авылдашым да консерватория тәмамлар, исеме еракеракларга яңгырар иде. Хәер, күпне өметләнмичә, шушы тальянда Җиңү бәйрәме хөрмәтенә җыелган мәҗлестә бер генә көй сыздырса да, бик риза-канәгать булыр идек әле...

## Тугрылык

Юлыгыз төшеп, безнең авылга килеп чыксагыз, бер атлы кешене очратмый калмассыз. Моңсу зур күзләре беләнме, саллы-салмак адымымы, кайсы ягы беләндер үзе дә эшчән атны хәтерләткәнрәк бу кеше минем күршем, ат караучы Габделхак абый булыр. Ул ике куллап көрешкәндә дә йөгәнен ычкындырмас. Хәл-әхвәл сорашсаң, үзе турында түгел, атлар хакында әйтер:

—Барысы да яхшы, наныем, тик менә атлар гына кими бара, атлар гына...

Габделхак абыйның атларга булган яратуы күптәннән килә. Аның әтисе Габдулла абзый да ат караучы иде. Ул вакытта әле колхозда бер-ике бөртек чылбырсыз трактор белән дыңгыр-дыңгыр килеп чабучы "полуторка" машинасыннан башка техника булмаганлыктан, төп йөкне атлар тарта иде.

Әтисен фронтка озаткач, Габделхак абый ат караучы булып үзе генә калды. Хәер, үзе генә дип әйтү дөреслеккә туры ук килмәс. Шат күңелле, җор телле кеше ялгыз кала димени?! Без, тирә-күрше малайлары, үзебездән аз гына өлкәнрәк булса да, "Габделхак әзи* дә Габделхак әзи!" дип, һәрвакыт ат караучы тирәсендә әвәрә килә идек. Төнлә, әниләрдән рөхсәт алып, Габделхак абый белән болынга атлар саклашырга чыгабыз. Малларны утлатырга җибәргәч, учак ягабыз, чикмәнле бәрәңге пешереп ашыйбыз. Аннан китә әкият сөйләш. Габделхак абый әкиятләрне галәмәт тә күп белә. Аның һәр әкиятендә диярлек батыр егет белән алтмыш колачлы Акбүз ат булмыйча калмый. Батыр егет әнә шушы Акбүз атның ялыннан эләктереп ала да, теге ничек кенә егып төшерергә тырышмасын, кулын ычкындырмый.

—Тормыш дигән чаптарның да ялын нык тотарга, какса-сукса да егылмаска, егылган очракта да еламаска кирәк, наныйларым,—дия иде Габделхак абый, кыйссадан хисса чыгарып.

*Әзи—мишәр сөйләмендә абый дигән сүз.

Шулай да булса, үзенең бер тапкыр елаганын хәтерлим әле. Юк, әтисен фронтка озатканда түгел, көтүгә бүре һөҗүм итеп, шуның белән сугышкан төннән соң да түгел, бүре буган кырыкмыш тай хакын бер өй бала-чаганы ач үлемнән саклап торган сыерларын сатып түләргә мәҗбүр иткәннәреннән соң да түгел...

Хикмәт шунда: бервакыт ир-егетләрне алган шикелле, атларны да сугышка озата башладылар. Шулар арасында Габделхак абый елның-елында Сабан туена бәйгегә әзерләп килгән Җирән кашка да бар иде. Шуны колыныннан аерып алу ифрат та кыен эш булып чыкты бит, әй. Борыла да үзәкләрне өзәрлек итеп кешни, борыла да кешни Җирән кашка, аратада калган колынын чакыра, мескенем. Авылны чыгып, үргә күтәрелә генә башлаган идек, карасак, җан-фәрманга чабып бер колын килә. Җирән кашка тае. Ябып калдырган аратасыннан ничек чыга алган диген син аны. Килеп тә җитте, әнисенә барып та сыенды. Габделхак абый башта аны ачуланды, аннары колынның муенынннан кочаклап әйтте:

—Кая бармакчы буласың син, наныкаем?! Авылда болай да атлар аз кала лабаса.

Габделхак абыйның, сагыш тулы тавышы өзелеп, үксеп куюыннан Җирән кашканың да күзенә яшьләр килде шикелле...

Авылдан төркем-төркем булып киткән ир-егетләр сугыш беткәч берән-сәрән генә кайттылар. Фронтка алынган атларның исә берсе дә кире әйләнеп кайтмады. Алар урынына башка атларны—авыр сынлы немец ломовойларын китерделәр. Бер-бер тоягы Габделхак абыйның кәләпүше кадәр, минсиңайтим.

Габделхак абый:

—Фронттан кайталмаган атларга да һәйкәл куясы иде...—дип сөйләнгән, диләр.

Дөрестерме бу сүз, юктырмы—гөнаһсына керә алмыйм, тик шунысы хак: корыч аргамаклар тере атларны елдан-ел кысрыклый барса да, укып механизатор таныклыгы алса да, күрше абый атларга мәхәббәтендә тугрылыклы булып калды.

—Ат әкияттәге Сәмруг кошы үтә алмас юллардан да кичә, узган сугышлар моның шаһиты булды,—ди ул. Аннары бераз уйланып торгач өсти: —Тик менә атлар гына һаман кими бара, атлар гына...

Мондый минутларда мин ат караучы абыйның тавышында Җирән кашканы фронтка озатканда колынны кочаклап үксегәндәгечә сагыш авазлары ишетәм кебек.

## Вәгъдә

Авыл урамында машина очравы күптән инде яңалыкка саналмый. Хәлбуки, юл тузанында аунаган тавыкларны пыр туздырып, кыр капкадан маңгаена "КамАЗ" дип язылган яшел фургон килеп кергәч, игътибар итми калучы булмады. Көтү каршыларга килгән малай-шалай аның артыннан чапты, карт-коры, кулларын каш өстенә куеп, карап калды.

Яшел машина, албакчаларында өянкеләр җилбердәшкән йорт турына җиткәч, кырт борылды да туктап калды. Кабина ачылып китте. Аннан җирән чәчләре янга тараулы, өстенә күн тужурка кигән ир-егетнең нык гәүдәсе күренде.

—Сәлам, авылдашлар!—диде ул, "р" авазын аз гына сакаулабрак.

Әнвәр ләбаса бу! Бергә авыл чирәмендә аунап үскән Әнвәр. Кара син аны, дөнья ничек үзгәртә кешене. Күрешмәгәнгә байтак шул инде. Аның турында армиядән соң Горький автозаводында эшләгән, хәзер "КамАЗ"да машиналар сынап йөри икән, дип сөйләгәннәр иде. Кунакка кайткандыр, күрәсең.

Тик нишләп әле ул үз өйләренә җитмәс борын, Фәләх абыйларга туктады. Әнә, капканы киң ачып, хуҗа үзе дә килеп чыкты. Әнвәр, безнең сорауны сүзсез аңлагандай, тигез ак тешләрен балкытып елмайды да:

—Нихәл, Фәләх әзи! Мин вәгъдәмне үтәргә кайттым,—диде.

Фәләх абый аптырау чагылган яшькелт күзләрен челт-челт йомгалап алды. Эшләпәсен арткарак шудырып, ындыр табагыдай зур, такыр башын кашыштырды.

—Ниткән вәгъдә ул тагын, наный?

—Оныттыңмыни?

Фәләх абый башын кашыштырган арада, хәтердә рәшә уйнагандай, балачак вакыйгалары чагылып китте.

...Әнвәр безне нинди дә булса яңалык белән шаккатырырга ярата иде. Беркөнне ул башына машина көпчәгедәй сырлы-сырлы резин-күн бүрек киеп чыкты.

—Бу каз оясын нәп-нәзек муеның ничек күтәреп тора?—дип көлә башлаган идек, ул безне бик тиз туктатты:

—Бик беләсегез килсә, шлемофон бу!

—Кайдан алдың?

—Фәләх әзи бирде. Танкист ич ул. Шушы шлемофон белән Берлинны алган ул!

Әнвәрнең әтисе дә, абыйсы да сугыштан кайта алмагангамы, Фәләх абый аны һәрвакыт үз канаты астына сыендыра иде. Улы диярсең. Ул заманны Фәләх абый шофер иде. Бүтәннәрдән аермалы буларак, безне машинасы янынннан куып җибәрми, утыртып урам да әйләндергәли. Әнвәрне исә үз янына, кабинага ала.

Ә тегесе шлемын төймәләп үк куя. Танкка керәмени! Шатлыгыннан битендәге һәр сипкеле елмая.

—Әй, Фәләх әзи, синең кебек шофер булмасаммы! Сине дә машинама утыртып, дөнья гиздермәсәмме бер…

…Әнвәр Фәләх абыйның күзләренә елмаеп караган килеш кабатлады:

—Оныттыңмыни? Теге, берзаманны, дөнья гиздерәм әле үзеңне, дигәнне.

Фәләх абыйның калын иреннәре колагына җитә язды:

—Ә-ә, исемә төште, наный.

—Утыр алайса! —Әнвәр миңа борылды. —Син дә кер, яшьти, бөтен авыл сыя бу әзмәвергә. Утырыгыз, малайлар!

Без кузгалып киттек. Киң урамны тар итеп барабыз. Әнвәрнең бу машинаны сынап йөреше икән. Ул да булмый, җырлап та җибәрде:

> Утырабыз да китәбез
> Чирмешән бозларына,
> Күрсәгез сәлам әйтегез
> Муллавыл кызларына.

—И, Фәләх әзи, башка теге шлемофонны да киеп җибәрсәң, ә?

—Син аны әйтәсең, наный, мин үземнекен уйлыйм. Безнең заманда булсыные мондый машиналар!..

Урам әйләнеп кайткач, малайлар, рәхмәт әйтеп, янә көтү каршыларга чапты. Кем белә, бәлки, шушы минутта аларның берәрсе Әнвәр абыйсы кебек шофер булырга, аны үз машинасына утыртып, урам әйләндерергә күңеленнән вәгъдә беркетеп куйгандыр.

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



## Резеда Вәлиева

*Май—шагыйрәнең туган ае (1930 елда туган), бу язда ул олуг юбилеен бәйрәм итә. Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында укытучылар гаиләсендә туып, Кыйгы, Салават районнарында үскән Резеда Вәлиеваның үсмер чагы—дөньяга күзе ачылу чоры—әнә шушы май ае китерәчәк Бөек Җиңүне көтеп алу еллары, яуга киткән ир-егетләр, хәтта кызлар, матур чәч толымнарын кисеп, фронтка үзе теләп киткән бертуган апасы һ. б. белән бәйле тетрәнүкичерешләреннән аерылгысыз. Һәм алар соңрак аның шигырьләренә, поэмаларына күчеп, шагыйрәне бөтен гомере буена шул темага—җиңү өчен бирелгән корбаннар, балаларын һаман да көткән, инде мәңгелек сагыш—һәйкәлләр булып мәйданнарга күчкән Аналар, сабыр, олы җанлы туган халкы, газиз туган тел, моң сурәтенә—изге мираска тугры иткән. Күптән түгел "Идел-пресс" нәшриятында өч том булып дөнья күргән "Сайланма әсәрләре"ндә дә (аларга кереш сүз-мәкаләләрне әдәбият белгече Фоат Галимуллин, шагыйрь Рәдиф Гаташ һәм филология фәннәре кандидаты Рәшит Фәтхрахманов язган) бу темага байтак әсәрләре тупланган.*

*Шагыйрәнең яраткан икенче иҗат тармагы—балалар өчен шигырьләре, әкиятләре. Алар да китап булып дөнья күргән: "Минем дусларым", "Зәңгәр алан әкияте", "Нәниләр китабы" һ. б. нәни укучыларга күптәннән таныш.*

*Тагын бер тармакны—иҗатындагы лирика, мәхәббәт шигырьләре, бигрәк тә җыр жанрындагы әсәрләрен аерып әйтергә кирәктер. "Якты йолдызым", "Китмә, сөю" кебек китапларда тупланган лирик шигырьләренең байтагы композиторлар тарафыннан көйгә салынган.*

*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Язучылар берлеге әгъзасы, танылган шагыйрә Резеда Вәлиеваның иҗатыннан, сайлап, шигъри бер бәйләм тәкъдим итәбез.*

### Җиңү килгән көн

**Идел-ярга, ярсып-ярсып,
Чал дулкыннар каккан чакта,
Ерак-ерак юллар гизеп,
Кошлар илгә кайткан чакта,
Куе кара болытларны
Ярсу җилләр таратканда,
Төн карасын ярып, җирдә
Якты-аяз таң аткандай,
Килде ул көн, балкып килде,
Кояш көлде, дөнья көлде.**

Шаян җилләр, ашыга-ашыга,
Тупылларга чуклар элде.
Яшь бөреләр, бәбкәләрдәй,
Талпынышып куандылар.
Умырзая чәчәкләре
Елмаешып уяндылар.
Җырчы кошлар, матур сайрап,
Шатлык хәбәр итте җиргә:
Ул көн—меңнәр зарыгып көткән
Бөек Җиңү килде илгә...

## Гармун

Авыл өстенә авыр моң ята:
Кемдер өздереп гармун уйната,
Гармуны гүя үксеп елыйдыр,
Авыл, тын калып, аны тыңлыйдыр.
Моңга сусаган ялгыз урамнар,
Гүя онытылып, тынып калганнар...

Кем йөри шулай гармунын тартып,
Ялгыз йортларда сагыш уятып?
Әй гармун, гармун, уйнама юкка,
Моңлы җаннарны елатма, тукта.
Уйнама, гармун, җитте, кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

Туган авылның тын урамнары
Оныткан инде гармун моңнарын.
Онытсын инде, уйнама юкка,
Сүнгән йөрәкне уятма, тукта.
Уйнама, гармун, җитте, кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

Өзмә үзәкне, сүнсен өметләр,
Кайтмаска киткән моннан егетләр,
Алар мәңгегә чит җирдә калган,
Газиз аналар сагынып арган.
Газиз аналар сагынып арган,
Аналар авыр йокыга талган...

Уйнама, гармун, җитте кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

## Япь–яшь кызлар китте ут эченә...

Оныта алмам, мәңге оныта алмам
Йөрәгемнең әрнеп сызлавын,
Озатканда утлы яу кырына
Назлы гөлдәй татар кызларын.

Кызлар китте җырлар җырлый-җырлый,
Ак каеннар сыгылып тыңлады.
Япь-яшь кызлар китте ут эченә,
Йөрәкләрдә калды моңнары.

Гөлләр кебек гүзәл апам китте
Гүләп торган сугыш кырына.
Каерылган пар канатлар кебек
Толымнары калды кулымда.

Киткән икән, бәгърем, мәңгелеккә,
Ут эчендә гомерен җуярга.
Язган икән салкын толымнарын
Кайнар яшьләр белән юарга.

Еллар үтә, сагыш китә, диләр,
Ник әрнетә һаман ул моңнар?
Күз алдымнан китми, пар канаттай,
Сыгылып төшкән шушы толымнар...

## Иң зур мирас

Алтын җыйма, йортлар куйма,
Мираска дип балаңа.
Иң кадерле мирас итеп
Туган телен бир аңа.

Иле белән, дине белән,
Туган җир белән бергә,
Туган телгә мәхәббәт сал
Күңеленә гомергә.

Аерса да хак язмышы
Туган йорттан, иленнән,
Күңеле мәңге аерылмасын
Газиз туган теленнән.

Кайда гына ишетсә дә
Аның татлы авазын—
Туган якка очсын күңеле,
Сагынып ана назын.

Онытмагыз, бу дөньяда
Иң зур мирас бер генә:
Көмеш чыңлы, талгын моңлы
Газиз туган тел генә...

## Кулларыңа каләм алсаң...

Кулларыңа каләм алсаң, җырың булсын
Сөймәс җанны Мәҗнүн итеп сөйдерерлек.
Ядрә булсын, ялкын булсын һәрбер сүзең—
Дошманнарның салкын җанын көйдерерлек.

Назлы йөрәк тылсымлы наз алсын аннан,
Сагышларын бассын сагыш күргән күңел.
Ләйсән яңгыр булсын туңган бәгырьләргә,
Шунсыз бит ул берәүгә дә кирәк түгел...

## Кил әле син миңа, кил әле

Җәйләр әле, җәйләр үтмәгән бит,
Бакчаларым тулы гөл әле.
Син яраткан гөлем чәчәк атты,
Кил әле син миңа, кил әле.

Йөрик әле гөлләр арасында
Шатлык мизгелләре кичереп,
Серле моңга чумган тын бакчада
Җан зарыккан хистән исереп.

Чәчәк кебек матур иреннәрең
Сөям сүзен әйткән чагында,
Җүләр күңелем көзге күбәләктәй
Бер талпынсын әле тагын да.

Таң нурыдай назлы карашыңнан
Тибрәлсеннәр күңел кылларым,
Яз каршына очкан тургайлардай
Очсын әле йөрәк җырларым.

Беләм, тагын зәңгәр күзләреңә
Кара шәүлә булып моң тулыр.
Ул моңнардан якты җырлар туар,
Миннән бүләк сиңа шул булыр...

Кил әле син миңа, кил әле.

## Яшә, Казан!

Илгә бәйрәм килгән чагында
Матурлана дөнья тагын да.
Туган көнен каршы ала Казан,
Горур басып Идел ярында.

Татарстан җире—дуслык иле,
Зур туй бүген татар илендә.
Мәңге яшь бул, Казан,
Мәңге яшь кал, Казан,
Дуслар күңелендә.

Үсә Казан, һаман яшәрә ул,
Бакчалары гөлгә төрелә.
Бер-бер артлы калыккан ак йортлары
Каурый болытларга үрелә.

Чал тарихтан килгән матур исемен
Данга күмгән изге башкала,
Һәйкәл булып җирдә гүзәллеккә,
Бар телләрдә бүген мактала.

Матур Казан, мәгърур, горур Казан,
Халыкларың булсын гел бергә.
Балкып торсын һаман мәйданнарың,
Гөрләп яшә, Казан, гомергә!

Татарстан җире—дуслык иле,
Зур туй бүген татар илендә.
Мәңге яшь бул, Казан,
Мәңге яшь кал, Казан,
Дуслар күңелендә.

*Язучы Мәгъсум Хуҗинга 75 яшь*

# ХИКӘЯ ОСТАСЫ

XXI гасыр башында мәдәни тормышыбызда гаять тә мөһим, әмма, ни кызганыч, әле бүгенгәчә тиешенчә бәяләнеп бетмәгәг олуг вакыйга булды – мең еллык язма мирасны туплаган әдәбиятыбыз тарихында беренче тапкыр буларак "Татар хикәясе антологиясе" басылып чыкты *(Татарстан китап нәшрияты, 2001 ел)*. Беренче карашка, илле басма табактан артык күләмле бу хезмәтне барлау, туплау, бастырып чыгару өчен әзерләү, ягъни төрле чорларда, төрле географик урынчылыкларда яшәп иҗат иткән авторлар хакында биобиблиографик белешмә юнәтү, иң яхшы хикәясен сайлап алу, теге яки бу әсәрнең кайчан һәм кайда язылуы, беренче тапкыр кайда, нинди матбугат битләрендә дөнья күрүе кебек мәгълүматларны эзлекле бер системага салу, һәр хикәягә аерым искәрмә язу, борынгы сүзләргә аңлатмалар бирү өчен тулы бер фәнни оешманың күпъеллык эшчәнлеге кирәк булыр иде. Тау актаруга тиң хезмәт бу. Шулай! Ә баксаң, шушы титаник хезмәтне аерым бер җанатар әдибебез, русчалатыбрак әйтсәк, энтузиаст язучы һәм бу очракта үзенә галим функцияләрен дә алган Мәгъсум ага Хуҗин берүзе башкарып чыккан икән.

Шушы бер саллы хезмәте белән генә дә Мәгъсум абый инде әдәбият тарихындагы лаеклы урын алды дип, һич икеләнмичә әйтергә мөмкин. Үз хикәяләрен фәлсәфи һәм тирән психологик планда иҗат итүче, бүгенге әдәбиятыбызда чын затлы хикәя остасы булып танылган аксакал язучының гаять авыр һәм үтә дә мәшәкатьле бу эшкә алынуы миңа һаман да сер булып кала бирә. Шактый озак уйланып йөргәннән соң гына җавабын да таптым кебек. Мәгъсум абый тәртипсезлекне, шапшаклыкны җене сөйми торган затлардан. Нәрсәдер эшли икән, ул коеп куйган кебек балкып торырга тиеш. Аңа инде черки дә борынын тыга алмаслык булсын. Татар хикәяләренең кайсы кайда таралып ятуына эче пошкандыр, аларның иң яхшы үрнәкләрен бер түбә астына җыеп куясы килгәндер кебек тоела миңа. Аның хикәяләрендә һәр нәрсә үз урынында, һәм тел җәһәтеннән, һәм сурәтләү, сюжет-композиция кору җәһәтеннән булсын, геройларның эчке дөньясын тасвирлауда булсын – барысы да шулкадәр табигый һәм җанга ятышлы булыр, беркайчан да нишләп болай булды соң әле бу дигән аптыраулы сорау башыңа килмәс. Ул хикәяләрне уку нарат урманында күкрәк тутырып сулыш алу, туган якның көмеш чишмәсеннән йотлыгып салкын су эчү кебек табигый бер халәткә әйләнә, җаныңа, тәнеңә, бөтен буыннарыңа рәхәт сулкылдау иңә кебек. Мондый тылсымга бары тик чын талант ияләре генә ирешә ала да. Мәгъсум абый хикәяләрендә беркайчан да гайре табигый вакыйгалар, өнеңне алыйм әле дип язылган куркыныч ситуацияләр табалмассың, барысы да нәкъ тормыштагыча, геройлары да үз арабызда көн күрүче гап-гади авыл агайлары, авыл апалары, тормыш юлын башлап кына җибәргән чиста, саф күңелле, садә җанлы авыл балалары, яшүсмерләр. Аның хикәяләрен укыганда, ирексездән күзләргә яшь тыгыла. Кемнедер кызганудан, чарасызлыктан түгел, ә бәлки язучы сурәтләгән үтә дә саф күңелле геройлар белән очрашу шатлыгыннан, арабызда шундый да кешеләр булуны күрү сөенеченнән туган яшьләрдер дә әле алар. Аның әсәрләрен укыгач күңел сафланып кала, үзеңне нindидер бер рәхәт дөньяда хис итә башлыйсың. Журналның бу санында, хөрмәтле укучылар, сез аның әнә шундый нечкә лиризм белән сугарылган хикәяләреннән берсе белән танышырсыз.

Бәхетемә димме, 1993-1997 елларда миңа Мәгъсум абый белән бергә "Татарстан" журналы редакциясендә эшләп алырга туры килде. Һәм нәкъ менә шул елларда мин язучының иҗатында гына түгел, ә бөтен яшәү рәвешендә чиста һәм саф булып кала белүенә, һәр нәрсәгә күңел җылысын салып башкаруына инандым. Аның кул астыннан чыккан бер генә язмага да инде тел-теш тидерерлек булмас. Вазифасы буенча шул язмалардан хата һәм төгәлсезлек эзләргә тиешле үтә таләпчән, тел стихиясен сизгер тоемлаучы корректорыбыз Клара Миңнуллинаның сүзләре әле бүген дә колак төбемдә яңгырый кебек.

– Һай, бар редакторлар да Мәгъсум абый кебек булсын иде! – ди торган иде ул.

Әле бүген дә Мәгъсум Хуҗин безнең арада, "Казан утлары" журналының проза бүлегендә "Татар хикәяләре хәзинәсеннән" рубрикасын алып бара, штаттан тыш редактор вазифасын башкара. Зиһене үткен, теле йөгерек, буй-сыны төз. Аңа 75 яшь тулганына ышанасы да килми. Тормыш дәвам итә.

1930 елның 15 маенда Татарстанның Саба районы Тенеки авылында (бөтен Татарстанга танылган зәркәнчеләр – көмешчеләр авылы, хикәяләрдә иң нечкә детальләрне ювелирларча чачаклау-чуклау осталыгының сере шунда түгелме) дөньяга килгән Мәгъсум Хәмит улы Хуҗинның тормыш юлы һәм иҗаты аерылгысыз рәвештә татар вакытлы матбугаты, татар әдәбияты белән бәйле. 1948 елда Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң ул, бераз вакыт шул ук мәктәпнең башлангыч сыйныфларында укытучы булып эшли. 1949 елның гыйнварында аны комсомолның Саба район комитетына икенче секретарь итеп сайлыйлар. 1949-1954 елларда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. 1954 елдан алып 1956 елның октябренә кадәр республика яшьләре газетасы "Яшь сталинчы" (хәзер "Татарстан яшьләре") редакциясендә башта әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, аннан пропаганда һәм агитация бүлегендә әдәби хезмәткәр һәм мөдир вазифаларын башкара. 1956 елда ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы бер еллык комсомол мәктәбен тәмамлап кайткач, аны "Татарстан яшьләре" газетасының җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. 1958-1959 елларда үз теләге белән Казакъстанга китеп, чирәм җирләрне күтәрүдә актив катнаша, бер елга якын Караганда шәһәрендә чыга торган "Комсомолец Караганды" редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1959-1969 еллар арасында ул Саба, Арча, Балтач район газеталарында җаваплы хезмәттә. 1969 елның октябреннән пенсиягә чыкканчы М. Хуҗин татар сатирик "Чаян" журналының җаваплы сәркәтибе хезмәтен башкарды. Аннан соң да, алда әйткәнебезчә, төрле газет-журналлар редакцияләрендә эшләвен дәвам иттерә.

Мәгъсум Хуҗин иҗатында хикәя жанрына тугры калган сирәк авторларыбыздан. Аның беренче иҗат үрнәкләре вакытлы матбугат битләрендә, күмәк җыентыкларда узган гасырның илленче еллары башыннан ук күренә башлый, ә "Ерганак юл яра" исемле тәүге китабы 1961 елда дөнья күрә. Хәзерге вакытта М. Хуҗин дистәдән артык китап авторы. "Аның иң әйбәт хикәяләрендә авыл тормышы, бигрәк тә авыл балалары дөньясы ышандыргыч деталь-образлар аша фәлсәфи һәм психологик планда сурәтләнә, геройларның уй-кичерешләре, теләк-максатлары заманча яңгырашлы ситуацияләр һәм мөнәсәбәтләр аркылы ачыла" диелә әдип иҗаты турында "Совет Татарстаны язучылары" исемле биобиблиографик белешмәлектә *(Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б., Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986 ел).*

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

**Редакциядән:** *журналның штаттан тыш редакторы вазифаларын башкаручы күренекле язучы, җор күңелле каләмдәшебез Мәгъсум ага Хуҗинны олы юбилее белән чын күңелдән тәбриклибез, аңа ныклы сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телибез. Алда тагын-тагын яңа хикәяләрен укып сөенергә язсын!*



# Мәгъсум Хуҗин

## АЙНЫҢ УТЫ СҮНГӘН...

ХИКӘЯ

*Әнием Бибирауза истәлегенә*

Иоланта, мин бишенче-алтынчы классларда укыганда, бездә торды. Башта, Эвакуация белән килгәч тә, аның әнисе һәм әбисе дә безгә өйдәш булдылар. Әнисе белән әбисе авылда өч атналап кына тордылар да кырык беренченең август башында ук Казанга күчеп киттеләр. Иоланта алар белән хат алышты. Әнисенең-әбисенең тормышы тернәкләнүгә хат алган саен сөенде. Иоланта шәһәргә барып йөрде. Әнисе һәм әбисе авылга бер дә кайтмадылар, безгә гел күчтәнәч җибәреп тордылар. Минем әни аларны кунакка чакырырга беренче тапкыр кушкач ук, Иоланта:

—Юк, Юу-к, Мәсүфә апакаем, кайтмасыннар!—дип кулларын селтәде. —Монда кайтып эш калдырсалар, аларны эшләреннән чыгарырлар.

Башка юлы, кырык икенченең марты кергәч—моны мин көне-сәгате белән хәтерлим—әни:

—Син дә алар кебек җыр укытасың инде. Барып йөрисең бит әле шәһәргә,—дигәч тә, Иоланта:

—Минем буш көннәрем бар,—дип каршы төште. —Сезнең авыл кешеләре мине, сорасам, бер атнага да җибәреп торалар. —Иоланта, мәктәп директоры, димәде, авылның барлык кешеләренә бер бәя бирде. —Ә әни белән әбине җибәрмәүләре мөмкин. Аннары алар икешәр урында эшлиләр.

—Өенә сыйдырмый безне Мәсүфә, дип, мине ачуланырлар бит. Татар гадәтен санга сукмый, диярләр. Шөкер, әлегә сөтеннән-маеннан, йомыркасыннан-бәрәңгесеннән өзелмибез. Хәзинәмдә бары да якты йөзем—үзләренә.

Иоланта, алай түгеллеген аңлатып, башын чайкады. Елмая иде. Зәңгәр күзләрен тутырып миңа карап алды. Уң кулы белән чәчләрен сыпырды. Аның чәчләре соргылт-коңгырт, калын, дулкыннары эре. Чәч очлары җилкәләренә тигәннәр дә эчкә бөгәрләнгәннәр. Сул кулының бармак очлары белән авызын каплады. Авызыннан сүз чыгуын тыйды кебек. Эндәшмәде. Безнең мәктәпнең җыр укытучысы Иоланта апаның бит алмаларына алсулык йөгерде. Түгәрәк йөзе тагын да матурланды латыш кызы Иолантаның...

Боларга мин нигә игътибар иттем икән? Гүзәллекнең һаман-һаман янаруы малай кешенең дә күңелен туктаусыз җәлеп итәдер шул...

Шуннан соң әни безгә аз вакытка өйдәш булган апаларны авылга чакырмады. Мин Иолантаның авылдан китеп йөрмәвен теләр булдым. Шәһәрдә ул ике-өч көн генә торса да, аның бездә булмавына ел тулгандыр, еллар узгандыр кебек иде. Өстәвенә әни миңа төксе эндәшә башлады. Март

кергән көннән соң шулай кырысланды. Иоланта өйдә чагында мине ачуланмады, ул югында төртке сүзләрен исәпсез сипте. Март кергән көндә Иолантаның гүзәллеге, игелеге, тагын күп-күп изгелекләре чиксез икәнлегенә сокланyuымны миһербанлы әнием нигәдер ошатмады. Ә минем күңелем, сугыш барса да, шул сугыш кырында әтиемә һәм ике абыема үлем янаса да, әнием еш орышса да, гел яхшы сүзләр генә табарга теләде. Иптәш малайларым белән әрләшүне, кемгәдер начарлык кылып булуын оныта башладым бугай мин.

Иоланта...

Бу дөньяда шуннан да матур исем юктыр! Шушы исемнең сихрилеген белгәч, тормышымдагы һәрнәрсәне күңелемә төгәл сеңдерергә гадәтләндем, уй дәрьясына чумуның рәхәтен татыдым. Хыял дөньям Иолантаның мәгърур матурлыгына, күңеле олылыгына тиң иделәр!..

Ә, әйе, болай булды бит әле.

Мартның унбише иде. Мәктәптән кайтып чәй эчкәч, сыер абзарын чистарттым, сарыкларга кич салырга печән бүлеп куйдым. Ишегалды тирәсендә бүтән эш тапмадым, баз юлын ачарга иртәрәк, кар тагын явардыр әле. Аннары баз уңаен такырайтып ук күрергә дә кирәкми, кар тыгызлангач, баз өстенең ишек төбен генә казып төшәм дә, шул тирәдәге кар базга салырга житә.Быел безнең авылда кар мул яуды, базга сыймаганын соңыннан таратырмын.

Баскыч төбенә барып утырдым. Кояш жылыта, селкенмәсәң, битне җәйгечә кыздыра хәтта. Сыер да әнә башын кояшка куеп күши. Көз туган ике кара бәрән ишегалдын буйлап-инләп чабышкалыйлар. Тавыклар да абзар авызында гына тукталып калмаганнар, капкагача сәфәр кылганнар.

Әни кайтып керде. Миңлекәй абый янына барган булгандыр, кулында буш ашъяулык кына иде. Көндезгә бик тәмле итеп кыстыбый пешергән иде, шуны илткәндер. Миңлекәй абый әнинең иң олы туганы ул, ялгызы яши. Үз балалары карасалар да, әни көн саен Миңлекәй абыйның хәлен белмичә калмый.

—Бу кадәр дә ата ялкау булырсың икән!—дип башлады әни.

—Мин абзар тирәсендәге эшләрне бетердем инде.

—Төпчек бала ялкау була, диләр иде аны! Хак икән, Ходаем! Хыялый жан син! Эш сөймәс зат! Ялкауның ҡаралты түбәсендә алабута үсә. Шуны бел!

—Әни, безнең ҡаралты түбәсендә алабута үскәне юк ла.

—Өй түбәсен кар басып төшәргә тора. Шуны да күрмисең, ичмасам!

Менә кая каеруы икән әнинең, түбә карларын көрәр чак житкән икән. Шулай да мин...

—Әни, авылда әле берәү дә түбә карын көрәмәгән,—дип акланасы иттем.

—Яз мисалын бирә әнә! Кешене көтмә! Син башла! Жыен тузга язмаганын да син башлыйсың бит әле!

—Өй түбәсен хәзерендә ялт иттерәм мин аны!

Мин түбәгә менәргә баскыч куярга да өлгермәдем, әни чиләк-көянтә күтәреп чыкты.

—Әни, суга Иоланта апа...

—Синең Илаһәңне көтсән!—дип бүлдерде әни. —Юләр баш син, улыкаем!

—Илаһә! Нәрсә ул... Кем ул—Илаһә?

—Хатын-кыз Алла! Синең Аллаң!

Рәхмәт сина, әни! Син Иолантага тагын да матуррак исем тапкансың ич! Мин аның үз исеменнән дә әйбәтрәк исем булмыйдыр, дип уйлый идем, ә син аңа үзебезчә исем, Иолантага... Илаһиягә үзедәй гүзәл исем куштың! Илаһия...

Мин бу рәхмәтемне әнигә әйтмәдем. Шушы әйтелмәгән рәхмәтемне әни кайчан да булса барыбер аңлар әле...

Әни капкага таба бара башлауга, Иоланта... юк ла инде, Илаһия кайтып керде. Әнинең алдына җәһәт кенә төште дә ана сумкасын тоттырды, чиләккөянтәне үз җилкәсенә салды.

—Ни... ни бит, Иоланта, ни...— дип мәлҗерәп төште әле генә мине ачуланган әни. —Э-э... Бүген озакладың. Ризыкның тәме китә. Кыстыбый пешергән идем.

—И-и, Мәсүфә апа, син пешергән ризыкның тәме китәме соң!—дип елмайды Илаһия.

Күктә кояш балкый, ә җирдә Илаһиянең көләч йөзе кояш булып балкый иде. Ул миңа карамаска тырышкан булды. Карады, башын өскә чөеп, зәңгәр күзләрен тутырып карады.

—Җангәрәй, егылып төшмә яме,—дип, башын сузыбрак кыйшайтты Илаһия. Мин башымны чайкадым. Эндәшмәдем.

—Ни, улым, Җангәрәй, сак була күр,—диде әни. Аның ачуы беткән иде. Илаһия кулында шул бу дөнья, аның көченнән килмәгән нәрсә юк! —Ни, Җангәрәй улым, сиңа булышырга... ни, Миңлекәй абыең килеп җитәр.

Миңлекәй абыйның түбә күрергә ярдәм итә алмаячагын белә әни, бу сүзләрне фикере таралып киткәч кенә әйтүе инде. Әй, миңа булышчы кирәкми ич! Илаһия чишмәдән гел миңа карап кайтыр бит әле! Ярдәм шул миңа! Тик, сукмак читенә басып, карга бата күрмәсен Илаһия...

—Ни, улым, Җангәрәй, чабаталарыңны ямьсез бәйләгәнсең. Юешнепычракны чабаталарың үзләре эзләп табарга тора. Алгай-салгай йөрмә. Тәртипсез киенсәң, йөрешең үзеннән-үзе эленке-салынкыга әйләнә дә куя. Алгыр бул. Зирәк-унган була күр. Нигә итекләреңне кимәдең? Хәзер алып чыгып бирәм. Килбәтең нинди булса, күләгәң шундый булыр, улым. Кешеләр күләгәңнән дә көлмәсен. Кояшы үтә җете бүген, күләгә бик анык төшә...

Мин эндәшмәдем. Әнинең сүзләрен Илаһия ишеткәндер, капканы чыккач туктап торды бугай ул. Әнинең ягымлы сүзләре аның да күңеленә ятканлыр...

Кырык икенченең җәйге каникулын Илаһия тулысынча диярлек әнисеәбисе янында уздырды. Август башында кайтты. Мин колхозда ат җигеп эшләдем. Илаһия кайткан көнне үк ындыр табагына менгән иде. Мин комбайннан ашлык алып кайткач, очраштык без. Исәнләшмәдек. Ул минем җилкәмә кагылып кына алды. Мин, аның күзләренә карап, бер мәлгә тораташ катып калдым. Илаһиянең карашы элеккечә иде. Түгел лә, аның күзләре миннән башканы күрмиләр иде! Без сөйләшмәдек.

Илаһия миңа әрҗәдән ашлык бушатырга булышты. Иптәш малайга да булышты. Бик тә ярдәмчел шул Илаһия. Шәмәрдәнгә ашлык илтәсе көннәрдә ул безгә йөк төяште, безнең—сәфәр чыгучы малайларның— аркаларыбыздан сөяр иде. Илаһия безне араламаган кебек иде, шулай да аның кулы минем җилкәмдә озаграк тора сыман. Әмма моны ындыр табагындагы берәү дә күрмәде, моны мин генә тоя идем...

Кырык икенченең-кырык өченченең кышы авыр булды, ачлык килде. Әни бу кышта кыстыбый-бәлешләр пешермәде, аш бәрәңгесенең генә кабыгын әрчеде. Шулай да ул безне тәүлек буена ач калдырмады. Миңлекәй абыйга да, Илаһиянең әнисенә-әбисенә дә өлеш чыгарырга җаен таба иде минем әни. Безнең өч кешелек табыныбыз тигез иде. Әгәр әни мичкә тәгәрәткән бәрәңгене Илаһиягә яки миңа берне артык куйса, Илаһия аны әнинең үзенә сүзсез генә бирә иде. Минем Илаһиягә томырылып карауларымны күрмәмешкә салынса да, еш әрләде мине әни. Кайчак иплән кенә акландым, кайчак эндәшмәдем.

Бер шимбәдә ачулануына да сүз кайтармадым. Үземә тиешле эшләрне бетергәч, дәрес әзерләргә утырган идем, башыма берни сеңмәде. Ишек уңаендагы ян тәрәзә каршына килеп бастым—шуңа ачуы купкан икән

әнинең. Моннан мәктәп буеннан-буена күренә бит. Уйга чумганмын. Әнинең башта әйткән сүзләрен ишетмәгәнмен.

—...тора шунда корыган агач кебек! Киемең каюы да акка кара ямау булып күренер синең өстеңдә! Аңсыз җан! Кылганың тозсыз! Тозсызны күзсез дә тоя. Юка башлы булып үсәсең бит!

Капка ачылды. Әни, кече якта кыбырсып йөрүе белән, моны күрмәде. Мине әрләвен белде.

—Нәрсә дип тешеңне шыгырдатасың әле? Һе, күр син моны! Чуртан тешен игәгән кебек торуын күр! Эш белмичә үсәсең бит! Каз оясы таралып беткән. Өйдә чит... —Әни сүзенең киртә аша очып чыгуын аңышты. —Өйдә ерактан килгән кеше яши,—дип төзәтте. —Кешеләр бер-берсен сынаучан була. Чыбыклары мең якка тырпаешып торган ояга каз утыртыйммы инде? —Ояны артык хурлап ташлады, ярамаслык түгел әле ул. —Ояты миңа, малаена эш куша белми, диярләр. Хурлык, валлаһи гынам!

Өйалды ишеге ачылды. Әни баскан урынында тукталып калды. Илаһия өйгә кергәнче тагын бер сабагын биреп өлгерде.

—Яшьтән белеп үсмәсәң, һөнәрне соңыннан бурычка алып булмый аны.

Илаһия кергәч, әни үзгәрде дә куйды, йөзе яктырды. Хәтта Илаһиягә пальтосын салырга булышты, әллә каушавыннан булды инде монысы, Илаһиягә беркайчан авыр сүз әйтмәсә дә, аны бик якын итсә дә, моңарчы аны болай иркәләгәне юк иде.

—Ни, улым, Җангәрәй, каз оясы тузыбрак киткән икән. Быелга ярап торыр, дигән идем дә, янасында бәбкәләре ишлерәк чыгар сыман. Мишә буена талчыбыкка төшәрсең. Үзең үрерсең. Минлекәй абыең өйрәтер. Белмәгәнеңне, дим. Анысы үзеңнең дә үргәнең бар инде. Ни, Иоланта, әллә син дә Җангәрәй белән чыбыкка төшәсеңме соң? Бер күтәреп менгәнегез ояга җитәр иде.

Үз әниеңнең әрләве дә иркәләп сөюгә әйләнә дә куя шул...

Илаһия бездә икенче кышын торганда авылга тәмам ияләнеп житте. Казанга да еш бармады. Эвакуацияләнеп килүчеләрдән бу вакытка бүтән кеше калмады. Илаһияне берәү дә чит итмәде, гел дә үз авылыбыз кешесе ул. Хәзер татарча безнең кебек үк сөйләшә. Түгел лә, аның сөйләве йомшак, тавышы ук иркәли. Илаһия белән бер сөйләшкәч, тагын сөйләшәсе килеп тора. Өйдә без татарча сөйләшәбез, әни Илаһиядән өйрәнгән латыш сүзләрен җае саен катыштыра. Безнең авылга килгәндә Илаһия татарча сынар сүз дә белми иде, русчасы да бик-бик чамалы иде. Беренче тапкыр безнең класска җыр дәресенә кергәнен хәтерлим. Баянын—аны үзләре белән алып килделәр—күтәргән иде.

—Сөйли белми,—диде. Без класс белән көлеп туктагач: —Уйнайт итәм,—дип, үзе дә көлде.

Без инде көлмәдек. Илаһия алдына бизәкле кечкенә җәймә җәйде, баянын шуның өстенә куйды да акрын гына уйный башлады. Көе безгә таныш түгел. Аннары кычкыртыбрак уйнады. Башын баян өстенә бер иде дә бер күтәрде. Мишә болынына карый да аннары карашын түшәм почмагына теки. Дәрес буе уйнады Илаһия. Таныш түгел көйләрне без йотылып тыңладык. Аның ин башлап уйнаган көе миңа күбрәк ошады.

...Беркөнне, ут алыр чак житкәч инде, Илаһиянең баянын алдым да шул көйне чыгармакчы булдым. Баянда түгел, гармунда уйнавым да шуның хәтле генә инде минем. Әмма уйный белмәвемнән ояласы юк иде: әни Минлекәй абыйның хәлен белә китте. Илаһия мәктәптә, балалар белән опера куймакчы булып йөри. Илаһия беренче дәрестә башлап уйнаган көй күңелемдә янгырый бит, баянда табам, барыбер табам мин шул көйне! Илаһия кебек итеп барыбер уйныйм!

Илаһиянең кайтып керүен сизмәгәнмен.

Ул:

—Жангәрәй! Нишләвең бу?!—дип кычкырып ук әйткәч кенә туктадым.

Ут кабызды. Пальто изүе чишелгән, әни белән икесе чөкердәшеп бәйләгән мамык шәле башыннан җилкәсенә шуып төшкән. Минем тезләрдә баян күриге сузылган килеш калган. Илаһия каршыма ук килеп басты, кулларын мина сузды, аларны кинәт кире алып күкрәгенә кушырды.

—Жангәрәй...

Ул каршыма чүгәләде, ике кулы белән дә минем битләремне тотты, баш бармаклары белән күз төпләремне акрын-акрын гына сөйде.

—Жангәрәй... Син бу көйне баянда мина охшатырга тырышып беркайчан да уйнама. Акыллы бит син. Мин булганда уйнама,—дип, үтенечен кечерәйтте аннары. —Үзем кушсам... Үтенсәм генә, мин янында утырганда гына уйнарсың. Насыйп булса...

Инде студент булып "Иоланта" операсын тыңлагач, мин бу көйнең Иоланта белән Водемонның беренче очрашуы дуэты икәнлеген белдем. Оркестр һәм җырчылар башкаруында бу көй тулы яңгырый икән. Шулай да бу көй Илаһия уйнаганча әйтеп бетергесез көчле, тетрәткеч, сөендергеч иде...

Шул ике елның минем күңелемә мәңгегә сеңгән көннәре күп. Мондый көннәрнең, Илаһия белән икәүдән калып, сөйләшмичә дә аңышкан көннәребезнең, дим, кабатланганнары да булды. Ә бу көн кабатланмас, кабатланмаячак. Әллә кабатланырмы икән?..

Алтынчы классның соңгы имтиханын тапшырдым. Кырык өченченең июне иде. Ничәсе икәнлеген әйтмим. Нигә хәзер дә әйтмим—сәбәбен белмим. Ихлас.

Иртәгесен үк колхоз эшенә чыгарга кушканнар иде. Пар җирен сөрәсебез икән. Аннары пар җирен август җиткәнче—арыш чәчәр алдыннан инде—быел кабат сөрдерәчәкләр икән. Шундый әмер төшкән югарыдан.

Нигә җәйнең шушындый изге көнендә мин генә өйдә утырырга тиеш ди? Әнигә бүген амбарлар юарга әйткәннәр иде. Илаһия дә өйдә юк. Кайдадыр, белмим. Авылыбыздагы бер укучыга, синнән менә дигән җырчы чыга, син тумыштан актриса, дип йөри, шул кыз янына киткәндер. Өйдә баяны да күренми.

Эшкә бер башлагач, Мишә буйларын күреп булмас, дип, быел суга тимәгән кармакларымны күтәрдем дә киттем балыкка!

Тик җим казырга онытканмын. Хәер, миңа балык эләгүе кирәкми дә иде. Язгы ташу тынганнан бирле Мишә буенда булганым юк, тын урынга утырырмын да хыялыма чумармын. Хыялымда мин күп нәрсәне күз алдыма башта элем-чалым гына китерсәм дә, аннары тоныклык бетә. Һәм томансыз хыялым сихри дөньям булып әверелә.

Мишәнең уң яктан әрәмәлеккә теркәлгән, судан ачык Кызлар тугаена җиттем. Монда тирән, монда буй җиткән кызлар гына коена, монда кеше юк, кызлар хәзер су коенырга йөрмиләр диярлек, алар эштә. Бу тирәдә кармак салмыйлар. Монда кызлар патшалыгы, ә алар балык тотмыйлар. Өстәрәк Мишәнең ике яктан да талларга төренгән тагын бер тугае бар. Каз оясына чыбыкка Илаһия белән шунда барган идек. Монда Мишә тирән үк булмаса да, балык чиртүчән, чабакка салырга берничә бөҗәк тотармын әле.

Чү! Суда кемдер чупырдый! Посып кына килеп, Мишәгә карадым. Без тал чыбыклары җыйган төштә Илаһия йөзә иде!

Шым булдым. Озак йөзде ул. Судан чыкты. Җилкәсенә бөгәрләнеп төшкән чәчләрен селкеде. Яр өстенә менгәч, Мишәгә карап басты. Һәр нәрсәнең чиге була, диләр. Дөрес! Илаһиянең гәүдәсе гүзәллекнең чиге иде! Чиге иде!

Илаһия мине күрде. Икебез ике ярда торсак та, безнең күзләребез якыннар иде.

Мин, йөгереп барып, суга чумдым. Аргы ярда Илаһия мине кулын биреп тартып алды. Ул киенеп өлгергән иде инде. Барыбер шундый гүзәл, ак күлмәге юеш тәненә сыланып алсуланып тора.

—Җангәрәй...

Аннары озак эндәшмәде. Мин исә сөйләшер хәлдә түгел идем.

—Җангәрәй... Син киемнәреңне киптергәч кайтырсың...

Ул китте. Яр буйлап китте. Кызлар тугаена җиткәч кенә, борылып кул болгады. Инде еракта булса да, мин Илаһиянең зәңгәр күзләрен күрдем. Миңа караганда гына аның күзләре шулай җете була иде...

Шул кичне без койма буендагы озын имәндә утырдык. Әти аны капка баганаларын алыштырырга дип алып кайткан иде. Өлгерә алмады, үзе дә, ике абый да сугышка киттеләр. Кичләрен безнең капка төбенә күрше-тирә җыела, авыл һәм дөнья хәбәрләре шунда янара иде. Илаһиягә татарның капка төбендә әңгәмә коруы ошый, имән бүрәнәдә иң башлап ул урын ала иде. Аның уң ягында—әнинең урыны, сулында мин утырам. Кечке әңгәмәләргә Миңлекәй абый да килгәли. Ул, өлкән кеше булса да, бүрәнә башына—читкә утыра, әңгәмәгә катышмый, сүз барышына карап, кул таягы белән бүрәнәгә суккалап кына куя. Бу хакта сөйләүдән тыелыгыз, дию булладыр, чөнки шул шак-шокны ишетүгә, сүз бөтенләй бүтәнгә күчә.

Әни бүген:

—Ай-ай Аллам ла, өйдә эшләрем бар икән лә!—диде дә кереп китте.

Үзе өйдә ут кабызмады. Йокларга ятты бугай. Берәздән башкалар да таралышты. Илаһия белән икәү калдык. Ул минем җилкәмә кулын салды, башымны тартып күкрәгенә кысты. Бу дөньяның рәхәтлеген белсәгез икән сез!..

Мин зәңгәр күкне күрәм. Алай гына түгел лә, мин Илаһиянең зәңгәр күзләрен дә күрәм! Илаһия башын читкә борды, аннары зәңгәр күккә карады. Анда тулы ай. Аңа таба аксыл болытлар йөзә. Шул болытларның кара башы айны каплый бара.

Илаһиянең сөзеп кенә әйтелгән сүзләре ишетелде:

—Айның уты сүнә... Сиңа унөч яшь, миңа егерменче китте... Айның уты сүнгән...

Иртәгесен әни мине таңнан ук уятты.

—Улым, Җангәрәем, торсаңчы. Иоланта китә...

—Ә-ә?!

—Иолантабыз китә. Әйберләрен җыештырды. Төенчеген төйнәде. Баянын безгә калдыра, сиңа. Озатырга Миңлекәй абыең да килеп җитте. Тор инде... Уян инде... Егет кеше шундый чакта йоклап ята диме!..

Уянсам да, мин тормадым. Тора калсам, бу дөньяны җимереп ташлый идем! Шул чактагы кодрәтемә сугыш дәһшәте дә тиңләшә алмый иде!..

Әни белән Илаһия сөйләшә. Өй ишеген япмаганнар, сүзләре миңа аермачык ишетелә.

—Мәсүфә апа, мин мамык шәлне алам, яме. Сезнең төсегез итәрмен.

—Ходаем ла, син үзең бәйләгән шәл ич ул!

—Без аны бергәләп бәйләдек, Мәсүфә апа. Сез өйрәтеп тордыгыз.

—Их, Иоланта, нигә бик кинәт кенә уйладың соң әле? Китмәсәң... Ни, Иоланта, безне онытма...

—Мәсүфә апа, менә сезгә бүләгем. Мине искә төшергәндә шушы яулыкны бөркәнерсез.

Әни җавап кайтармады, кече якка кереп китте бугай, аяк тавышлары шулайга баргандай ишетелде. Миңлекәй абый, гадәтенчә, сәке почмагында посып утырадыр.

Чоланга Илаһия керде. Мин яткан сәкегә утырды. Кулын җилкәмә салды. Бөгәрләнеп кырын яткан идем, чалкан борды. Минем йөземә капланды. Мин аны биленнән кочтым. Хатын-кызны беренче кочаклавым иде бу

минем... Йөрәк чалып-чалып алды...

Бу хәлләр бик тар арада булды. Түгел лә, Илаһиянең сулышын янагымда мин бик озак тойдым!

Көн идеме бу, төн идеме—анык белмәдем. Ә әни танда уяткан кебек иде. Вакыт чамасы югалды.

Өйдән әни белән Минлекәй абый сүзләре ишетелде.

—Мәсүфә, мәсьәләгә кырысрак килдең,—дип тамагын кырды Минлекәй абый. —Үзләре, дим, үзләре хәл иткән булырлар иде.

—Нишләп кырыс булыйм ди мин?! Араларына кысылмадым! Үзләре хәл итте бит. Иоланта үзе китте!

—Китте дә... —Минлекәй абый йомшак күңелле кеше, минем сыман. —Дөнья бу, ниләр булмас, дим дә... Жангәрәй үсеп житәр бит...

—Син утка май сибәргә жыенма, абый! Сугыштан, Алла боерса, әтисе кайтыр, ни дип жавап бирермен мин аңа?! Үндүрте тулмаган малаенны өйләндердем, диярменме? Абыйларыннан уздырып, малайны өйләндергәнсең, кәйтәнле күлмәк тә киертә белмәгәнсең, дип ачуланса, ни диярмен? Аның иң кимендә шулай дип ачуланырга хакы булачак. Ач заман бит, кәйтәнлек бизәгем дә юк. Аптыраш белән йөдәш кергәннәр өйдәш... Икесе тиң шул хәлдә калсыннармы?!

—Алай еракка китмә, Мәсүфә сеңлем. Әтисенә, абыйларына әйтмәссең. Бу хәлне Жангәрәй белән Иоланта үзләре белә дә, аннары син дә мин. Авылда ике бала... ике йөрәк газабын белүче бүтән юк. Дөнья бу... Жангәрәй үсәр...

—Дөнья! Дөнья! Олы дөньяны уйлагач, Иолантаны озата барырга нигә башыбыз эшләмәде соң?!

—Барыйк әйдә.

—Барыйк та барыйк! Иолантабызның киткәненә инде бишбылтыр! Мишә күперен чыгадыр. И-и, Ходаем ла, Мәсүфә Иолантаны озатмады, дигән мәсхәрәгә калдык лабаса! Кайда куып житәрмен инде Иолантаны?! И-и, Иолантакаем ла!.. Илаһиякәем лә!.. Жангәрәем минем янымда кала, жанын яшәтергә жайларын ничек тә табармын. Синең әниең-әбиең беләме соң бу хәлләрне? Әллә белмәсеннәр өчен аларны авылга бер тапкыр да алып кайтмадыңмы? Иолантакаем, балакаем ла минем, син ничекләр түзәрсең икән?! Аллакаем ла...

Шуннан соңгысын мин хәтерләмим. Башта әни мине сөйде кебек. Аннары Миңлекәй абыйның кул таягы баш очымда шакылдады бугай. Ерактан, бик ерактан тавыш ишетелде:

—Егет булыйк...

Миңлекәй абый тавышы иде бу.

Әнинең Илаһияне кайда куып житкәнен белмим. Соңгы очрашулары турында ул миңа беркайчан да сүз әйтмәде. Ә авылда төрле хәбәрләр йөреп алды.

—Иоланта яулыгын оныткан да Мәсүфә шуны илтергә йөгергән икән...

—Беләсең килсә, жаныкаем, Мәсүфә Иолантабызны куып житкән, ди, алар кочаклашканнар да аерылыша алмыйча торганнар, ди...

—Нигә китте икән Иоланта?..

Бу сорауга минем хәзергәчә аңлатмам юк. Тик ахырда шуны гына әйтә алам.

Илаһия бүләк иткән яулыгын әни беркайчан да бәйләмәде, сандыгы төбендә саклады. Хәзер ул яулык миндә. Аны мин, ялгызым гына калгач, башыма бәйлим. Мондый чакларда тилергәнемне дә беләм. Шул тилерүдән мине Илаһия сүзләре айныта:

—Айның уты сүнә... Уты сүнгән...

*1989*



**Әхмәт Гадел**

# САБА ҖИЛЛӘРЕНӘ ЙӨРӘК АЧАМ

***

Моңланмаслыкмыни бу дөнья?
Бу урманнар җырлый көн вә төн.
Каеннарга кушыла да җан,
Булабыз без тулы, бербөтен.

Бер каендай тоям үземне,
Салкыннарга чыдам, түземле.
Ни яшәтә икән күңелне:
Язымны ул, җәем, көземме?

Моңланмаслыкмыни бу тормыш,
Бармы бер иш—тормышлар кормыш?!
...Ни чәчкәнбез, инде без урмыш,—
Юккамыни күңелләр тулмыш?!

Урманнарга кердем—югалдым,
Эзләремә текәлеп калдың.
Яр дигәнем, эзлә, табарсың!
Каеннарны әле санарсың!

Моңланмаслыкмыни бу дөнья,
Уйланмаслыкмыни бу тормыш?
...Күзләремә бак та, күр үзең:
Гамьле ике диңгез—бер үзем!

---

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) — *шагыйрь, прозаик; "Чам", "Көмеш кылган җырлары", "Яшьлек урамы", "Рух бәйрәме" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Еллар үткән саен мин йомылам,
Үз-үземә яшеренәм—эчкә...
Мин ышанам хәзер, Гали Аллам,
Шәфкатьлегең дигән бөек көчкә!

Мин ышанам. Шуңа күңелем азат
Ваклыклардан, мәнсез сөйләшүдән.
Кабатлыймын көн дә, кабат-кабат,—
Күңелем туймый рәхмәт өләшүдән.

***

Син, илаһым, мине иңләп алдың,
Син нур булып миңа тулгансың.
Белә идем, бар затлардан аерып,
Синең—миннән йолдыз кыласың.

Вакыт җитте: Акыл балигъ хәзер,
Мин төшендем тормыш бәясен...—
Һич нишләтә алмый мине залим,
Чөнки җаным —йолдыз иясе!

***

Татлыдан да татлы бал дип,
Эчерделәр агуны.
Сыйлаучының иде йөзе
Сөйкемле һәм ягымлы...

Татлыдан да татлы бал дип,
Агуны эчтем сөзеп.
Газраилнең канатында
Күкләрдән киттем йөзеп.

Сыйлаучым калды елмаеп,
Белә ул агу көчен.
Аңа тау вәгъдә ителгән
Мине юк иткән өчен.

Аңа тау вәгъдә ителгән...
Ирешсен "вәгъдә"сенә:
Мин куаныч булып кундым
Биек тау түбәсенә!

***

Быелгы җәйдән дә тулы җәй
Гомеремдә булмады, булмады:
Бакчалар, урманнар—гел яшел,
Ут кызган зәңгәр күл сулары.

Быелгы җәйдән дә матур җәй
Булырмы икән соң тагын да?!
Болында чәчәкләр биилэр
Әлдермеш чишмәсе янында...

Быелгы җәйдән дә җылы җәй...
Күзләрең диңгезе эчендә—
Йөзәмен, йөзәмен, колачлап,
Көнен дә, төнен дә, кичен дә...

Быелгы гаҗәеп матур җәй
Гомергә сакланыр күңелдә...—
Моң тулы туган як җилләре
Йөздерде ватаным күгендә...

***

Саба җилләренә тәрәзәмне ачтым,
Әй, шөһрәтле сылу, нигә миннән качтың??
Җилгә ятып актың, офыкларга баттың,
Серле күзләреңне кай тарафка аттың?!

Таралган чәчләрең җилләрне үбәләр,
Сиңа гашыйк гөлләр яшьләрен түгәләр...
Хисләрем ташкынын кил, туктат, юлга сал:
Әй назлы, әй чибәр, әй гүзәл, әй усал!..

Ап-ак мәрмәр төсле, дим, синең тәнне,
Синдәй күрерменме, алиһәм, бүтәнне?
Ахактай иреннәр ялкындай балкыйлар.
Карашың нурлары кылычтай айкыйлар.

Кил, миндәй ут-йөрәк, җирдә юк ул башка.
Син—Ләйләм, Мәҗнүн мин, сине күреп шашкан!
Саба җилләренә тәрәз—йөрәкне ачам!

## Аңлашу

Әйтәсе сүзләрең бармы?
Ни теләк, ни омтылыш?!
Ташкын судай, юып ярны,
Хәсрәттәнме котылыш?!

Күзләреңнән моң агыла,
Ни югалттың, ни сагыш?!
Хыялларыңамы әллә
Орындым, чынлык, ялгыш?!


Оялма, уңайсызланма,
Бир, назлыйм, ярым, кулың...
Минем дә җаным сызлана:
Билгесез илдә юлым...

Тирәккә дә терәк кирәк...
Эзләдем сине, көттем...
Ике йөрәк, хис кушылса,
Дөнья була бербөтен.

## Таң җыры

Таңда моңнар кочагында
Былбыл булып калмадым.
Мин—кыяда. Тугайларга
Төшмәсемне аңладым.
Җирне өзелеп сагынсам да,
Очты күкләргә күңел.
Ә Син, дидем, сандугачка
Кунып сайрар тал түгел.
Сиңа мине аңлау кыен,
Юксындың да еладың...—
Бәллүр тамчылар җыелды,
Чишмә булып чыңладың.
Шул чишмәдән көмеш суны
Алды кызлар мул итеп.
Мин назлаган толымнарны
Сузып салдың юл итеп...
Ә юллар нурга тоташты,
Син дә аштың гарешкә:
Безнең моңга тугрымы Син,
Күктә йөзгән фәрештәм?!

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Әхәт Гаффар

## ХИКӘЯЛӘР

### Энә күзе

Авыл кучкыл канга баткан иде.

Ай саен булмаса да, өченчесе дигәндә капка асларындагы ерганак ише җирдән сузылып-сузылып кара кан агып чыккан да укмашып каткан. Бу—көз көне, аның да ахыры; җир туңып, кар яткач була торган хәл.

Әйе, авылда сугым башланган вакыт.

Ягъфәр автобустан төшеп калды да, әлеге кан ерымнарын, мөгезле эре терлек ашказаннарын кире әйләндереп бушатканнан соң калган, инде суык куырып, түмгәк иткән сыек-яшел калдык-постыкка игътибарын, карашын юнәлтәсе килмәстән, ары таба—авыл очыннан бирегә таба сигезенче санынча торган йорт-җире тарафына атлый бирде. Уң яктагы инешнең тирән ярларындагы тал-куакларны, әрекмән, әрем, гөлбадран курпыларын бәс сарган, күк гөмбәзе чалт аяз, һава саф.

Дөнья, болай, тып-тыныч. Әйбәт йоклагандагы шикелле. Йә адәми затның инде вафат булганлыгын мөгаен белгән, ә күңелнең, зиһеннең моны әле тәгаен кабул итеп җиткермәгәнлегендәге кебек.

Эңгер-меңгерле көздән соң кинәттән шикелле тоелган ап-ачык кышка кергәндә шундый тойгы, уй биләп алучан.

Ә бөтен җир, чыннан да, ниһаять, мәрткә киткән, тик тере, ап-ак иде. Табигать үзенчә мәңгелегендә, тик кешеләрнең дә әлегә гүрдә түгеллеген өй морҗаларыннан чыккан яшел-зәңгәр төтен баганаларының югарыга таба үрләгәннән соң да тәмам гаип булмаганнары белгертеп тора иде.

Турылата үрләгән төтен баганалары һәрвакыттагыча нидер әйтеп тора. Нидер дип, әллә нине түгел инде: әнә теге өйдә итле шулпа пешә; тегесендә, бәлки, өчпочмактыр, бусында, ихтимал, ит бәлеше үктер, ә монысында һич кимендә кыстыбый ише бер-бер нәрсәдер.

Менә боларның иң кимендә ике-өч тәүлек чамасына сузыласын Ягъфәр яхшы белә. Җәйге челләдә яңгыр явасын, кышкы зәмһәрирдән соң җылы буран чыгасын чамалагандай.

---

Әхәт ГАФФАР (1949) *— язучы, драматург; «Әҗәт», «Яшиселәр алда иде», «Богау» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Ул үзе белгәннәренең һәммә фаразын бүгенге көндәге моржа төтеннәре әйтмәгәнлеген искәрде.

Ә исә ул үз авылына төтен күзләр, кан исен иснәр, ашар ризыгын эзләр өчен дип кайтмады.

Аңа, болдыр тәрәзәләрегезнең пыялаларын коеп төшергәннәр, ишегенең йозагын кыйганнар, бөтен өегез шәрран ачык тора дип хәбәр салганнар иде.

Менә шундый хәл-әхвәлне—инде өченче тапкыр—төзәтергә, бикләргә кайтып барышы.

Үзенең үксеп туган йортын бимазалаулары аңа бәгъзе мәетнең бакый ләхетен ишүгә тиң сыман тоела.

Шуңа күрә аның синоптикларның Атлантикада һаваның түбән басымы Татарстандагы антициклонга карата көнчыгышка күчү ихтималы бар, тик әлегә аның төньяктан бәреп керүе шикле, дигән фаразына ышанган хәлдә үз авылына кайтып килеше. Кар-буран чыгасы ихтималы булса да, һава температурасы күзәтелгән еллык күрсәтмәләрдән узмаска тиешлеге аны юлга әйдәде. Озакка сузылган кара көзнең бу киңлекләрдән чигенеп, яшь-кыркынның куеннарына елышканнан, карт-корының җаннарыннан үткәннән соң ары үтеп китеше.

Әлегә исә авыл кучкыл канга баткан, һәммә нәрсә күктән иңдерелгән зәңгәрсу нур белән өретелгән иде.

Калганын кем белә инде тагын. Бәлкем, гап-гади генә итеп, көндәлек бер-бер тәмле нәрсә пешереп тора торганнардыр.

Автобустан төшеп калгач, Ягъфәр авылга җәяүли килеп кергән иде. Авылның һәр елдагыдай канга батканына аның исе китмәде. Бала дөньяга килгәндә анасы каный инде ул.

Һәммәсе фани. Һични бакый түгел.

Анда-санда очраган авылдашларына ул дүрт-биш сажин җитәр-җитмәстән үк: "Әссәламегаләйкем!" дип эндәшеп килүчән дә, "Яхшы!" дип узып китүчән. Киң күңеллесенә дә, коры җансызына да. Үзен тансыклаганнары белән, кулын биреп, хәл-әхвәл белешә, ә каршысына таба ике адым ара атлауны авырыксынганнарга үз сәламен фәкать иңдерә белеп кенә ымлый.

Үзенең:

—Исәнмесез,—дигәненә:

—Ярый. Бер көе,—дигәннәрне ул һичничек кабул кылмый. Чөнки ул белә: болар—"Аллага шөкер!" диюдән мәхрүм мәхлуклар.

Аның:

—Шөкер дип әйтегез,—дигәненә мондыйлар барыбер:

—Ярый, шулай диик,—дип узучан.

Мондыйларның авырулар икәнлеген, кешенең сәлам иңдерүен кара җаннары кабул итә алмаганнарын, шуңа күрә андыйларның кешедәге илһамнан, игелек, савап, деннән өрәк кургәдәй тайгышуларын ул әйбәт белә.

Моны алдан сизмәү, белгәненең соңында аңышмый калу—шайтанга әфсен өрүдән гаҗиз калуың белән бер.

Шулай дип әйтмәсә дә, һич кимендә шулай уйларга кирәклеген ул беркайчан да онытмый, исендә тота торган иде.

(Шуңа күрә Ягъфәр кешенең елмаюлы йөзенә караганда, атлап киткәненең соңында калган эзеннән күбрәкне танырга өйрәнде. Күптәннән бирле инде.)

Аның исә үзенең ирене һәрчак алсу, сусыл, изүе ачык, аяк атлавы шөбһәле түгел, ә бәлки нык, ышанычлы, бераз тирбәнүле, тыйнак, бераз шаян, тик гаять сак.

Шәһәр автобусыннан төшеп калгач ук, авыл һавасы бүтәнчә, тын алуы җиңелрәк кебек. Бүтәнчә дип... әйтик, үз авылыңа табантын әйдәгән юлдагы бер әчмуха тузан да, әгәренки бөртекләп, хәерле җыя алсалар, бишегеңдә яткан чагыңда имезлек итеп каптырсалар да ризыктыр ул. Ә кыш көне дисә, әйтик бүген, керфегеңә кунган бер кар бөртеге дә әнкәңнең әллә нидә генә—кемдер чит-ят күреп алганчы ук иң арып тупасланган урта бармагы белән суллы-

уңлы сөртеп алырга өлгергән мул тамчылы тозсу күз яшеннән дә җылырак, баллырак булырдыр иде.

Бөтен һава, челләдән соңгы эңгер-меңгерне тотырган черки көтүен хәтерләткән ише, әлҗе-мәлҗе сыкыга көмешләнеп торса да, Ягъфәрнең сыңар керфегенә дә һични кунмады. Ул, болай, үз мыегының кабарганнан-кабара барганлыгын тоя-тоюын, тик авылына керә-керешли, күрешкәне саен салып тормас өченгә кесәсенә тыккан биш бармаклы бияләеннән арынган, инде бераз туңа төшкән шул бармаклары, учы белән мыегын уңлы-суңлы сөртергә теләмәде.

Гүргә иңгәннәргә генә ни яңгыр тими, ни кар төшми.

Шунысы яхшы.

Һәммә җирнең, ниһаять, ап-ак кебек тоелганы шикелле. Хәер, инде утырган кар әллә зәңгәрсу, әллә алсу, әллә яшькелтем, әллә күксу иде бугай. Кайсы тарафка, нәрсәгә каравыңа карап. Кышның үз фасылына кергән, хуҗа булган чагында зарыккан кешеләр инде утырды дигән карны әле ахак, әле миләүшә, әле зөбәрҗәт, әле—күзне чагылдырганда, камаштырганда—кара төстә итеп күрә ул. Җирне тәмам туңдырганнан соң ике көн дәвамында тыныч кына яткан кар иртән иртүк аяз күкле авылга сул як үр кашыннан ипләп кенә кояш күтәрелгән вакытта атлаган һәр адымың саен иң кимендә кырык дүрт төскә керә.

Кар, шулай, әлегә түземле генә яткан да куйган. Болай итеп асрарга исәпләнгән мал-туар гына тыныч ята. Ә инде сугымга куелганнары яңа карның ятуы адәми затларның уянулы пычак кайравы икәнен һич белми, белә дә алмый. Аларның нәкъ шул һични белмәгәннәре мәлендә сугым башлана.

Мал-туар, терлек-җанвар, кош-корт кичәгене хәтерләми. Аның карауы алар бүген ни буласын белмәү белән... бәхетле.

Авылның кучкыл канга батканлыгын алар беркайчан да күрми инде.

Ягъфәрнең Тегермән очы урамындагы үз өйләренә кадәр атлап кайтырына хәтле чакрым чамасы бар әле. Аның уң иңбашына ике тоткычын кигезеп күтәргән җирән төстәге нык букчасы саллы гына авырлыкта иде. Әллә ние дә юк шикелле үзе: ике бөтен ипи, терсәк буе бер тутырма, төрле-төрлесеннән өч кап чәй, ун савыт шәп сыра, бер шешә аракы, ике кадаклап хәлвә, кистраны белән пешкән ит, ыслы балык, алма, ике литрлы савытта үзе тозлаган кара гөрежде гөмбәсе... Сигарет, шырпы, алты-җиде данә шәм...

Җитәрлек.

Ахирәттәге ата-анасы, шундагы исемле, исемнәре билгесез туган-тумачаларыннан гайре Ягъфәрне бу кыш башында һичкем көтми. Үги өйләренең болдырындагы пыяласын ваткан, ишек йозагын каерып аткан бәгъзе затсызы, оятсызы аның кайтып төшәсеннән шикләнәдер-шикләнүен. Алар Ягъфәрнең үзләрен беләчәген, белгәч нишләтәсен яхшы чамалап торадыр. Монысы тәгаен.

Тик хикмәт анда түгел. Бар мәгънә аның менә кайтып килүендә әле ул.

Ярар. Һич киме бер генә кош-корт та үзе борнап чыккан, җим ашаган, канат ныгыткан ягына мәгънә эзлисе, табасы өчен әйләнеп кайтмый.

Шулай да һәрбер әйләнеп кайту—инде әллә кайчан узганны мәңгелеккә теркәп кую ул. Үзеңнән кала бәлки һичкемгә хаҗәтсез нәрсәне беркем дә күрмәслек йолдыз итеп.

Олы юлдан уңга борылып кергән авыл урамы буйлап үткәндә каршысына очраган, йә аркасы ягыннан килеп чыккан көпчәкле тракторгамы, ат җигүле арбалы кешеләргәме—ул кулын да күтәргәләде, сәламен дә юллады. Ә тегеләр аның шул кулы селтәләгәнен сәлам сынап кына кабул кылдылар, күрәсең: туктамадылар, анда-монда уздылар да киттеләр.

Ул җанын тыеп, яңа карны шыгырт-шыгырт иттерә-иттерә кайтып бара әле. Әнә, мәктәптә физкультура укытучы Илтөзәр капка төбеннән уң кулын күтәреп сәлам биргән булды. Тик "безгә кереп чык әле" дигән ымын

белдермәде. Димәк, хәзергә Ягъфәрнең аңа керәге юграк,—әлегә үзенеке бар. Эчәренә. Чәй түгел инде.

Аларның урам юлыннан арырак торган өе ягыннан да кан исе килгәнен тойган Ягъфәр бу очракта һични уйламады.

Шулай, бүген уй уйлар көн түгел. Ул аяк киеменә ябышкан былчырак катыш карны селеккәләгән, бүгенге көнгә юлының очына таба узышы дәвамында иде. Юл кеше үзе теләгән чакта төгәлләнә.

Югыйсә, кайсы капкадан керсә дә, ул үзенә атап чәй кайната башлыйсыларын белә.

Тик бүген—кирәк түгел. Ул бүген биредә кирәкмәгән вакытта яуган яңгыр белән, алдан белеп торган шәттә дә һичничек туктатып булмастай боз бәрү белән бер; үрелеп, кисеп алганның соңында, кортлы икәне беленгәч, селтәп читкә ыргытылган гөмбә, мал-туар суелгач төшкән җебек көн, кулыннан килмәгән бер адәм актыгы тарафыннан бугазы киселеп бетмәгәнгә күрә җан тәслим кыла алмый азапланган ап-ак каз, аркасындагы канатын күпме җилпүгә карамастан, һичкем күзенә чалына алмауга гаҗәпләнгән фәкыйрь бер фәрештә генә.

Хәер, бу авылдагы һәр өй хуҗалары—аныкы, берәрсенә кергәне сурәтендә очрашып сөйләшүдән гайре һичкемне аптыратканы, йөдәткәне юк.

Сул якта кала торган югары оч тыкрыгы башындагы өйгә ул һичбер мәртәбә борылып карамыйча калмас иде.

Исән-сау кешенең узып китешли карап китә торган ягы була.

Әүвәлтенрәк, әллә кайчан инде, әлеге тыкрык очланып, чирәмле тар урам аша алма бакчалы йортта ул яшертен дә, сиздереп, белгертеп тә җан атып йөргән Фәйрүзә бар иде.

Хәзер юк инде.

Бар. Яши. Тик кеше кешесе булып.

Шунысы хәерле.

Әлеге өй былтыргы шөпшә оясыдай буш, тәрәзәләре соң чикләвегенә хәтле ашаган ашап, каралтып бетергән кишәнке шикелле.

Ярар инде. Ягъфәрнең үз өйләре дә шундыйрак.

Фәйрүзә аның төшләренә кереп йөдәткәли икән, аңа шуның өчен дә рәхмәт яусын.

Ул: "Бу дөньяның синә насыйп итмәгәне шау кайнаган самавырсыз калганы юк әле",—дип уйлап куйды.

Аның ике кызы, Фәйрүзәнең ике улы бар—тагын ни җитмәгән?

Дөньяның бизмәне тигез.

Табан астындагы яңа карның атлаганы саен тигез шыгырдаганы, яшенсез күк күкрәгәне, чишмә күзендә иң киме биш-алты ком бөртегенең тавышсыз гына кыштырдап торганы, тегермән ташлары келтерәгәне сыман.

Юлындагы ары таба йорт турысыннан үз каршысына кара яшендәй чәчрәп өреп чыккан йөнтәс зур эткә ул, сул кулының бармакларын киң тырпайтып, учын каршы куйды. Аңа карамады да. Игътибар итмәде. Шул гына. Эт тынды да, ак очлы койрыгын шәлперәйтеп, капканың асты череп сынган ике такта арасындагы үз тишегеннән кереп шылды.

"Шулай,—дип уйлады ул.—Тагын бер өйдән соң ләтчәсе чыга инде".

Үткән-барганында чалбар балагына кылган угы, тигәнәк кылчыгыдаймы ябышырга торган чәңгелдек сары бер эт бу юлысы аның аяк астына чәчрәп чыкмады. Югыйсә, нәкъ менә шул чәңгелдек эт Ягъфәрнең кайтканы саен теңкәсенә тигәнгә, бөтереплəп торып, кинәттән бот арасы тирәсендә чуалганына күрә ул алдан ук таш әзерләп куючан. Тик ыргытырга язмасын. Аның саен котырына гына.

Юл ачык. Тагын дүрт өйдән ары зиратка җитәсең, ашыкмыйча гына бара торгач, ахирәттәге әти-әниеңнең, барча туган-тумачаларыңның якты рухларына белгән догаңны күңелеңнән әйтәсең дә, аннары—Ягъфәрнең туган өе инде.

Буш. Салкын.

Урамда очраган этләрне ул күз карашы белән дә туктата белә. Туктамасалар, буш кулың белән, каен җилөге өзгәндәй генә сак кыланып, табан астыңнан берәр таш-фәлән алгандай гына итү кирәк.

Теге әнчек эт, күзгә күренмәстән бәреп кергән черки сымак, капка астыннан атылып килеп чыкмады.

Чөнки ул бүген тук икән. Аның хуҗалары сыер суйгандыр, ә моңа талак телеп ашатканнардыр, бавыр, йөрәк, үпкәне ярганда кешеләргә ашарга ярамастай төерләрне, бизләрне ыргыткалап торганнардыр.

Тук эт кешегә өрми.

—Кайтып киләсеңмени?

—Нихәлең бар, Рәҗәп абый?

—Аллага шөкер. Кайтып киләсеңмени дим ич.

Ягъфәр юри-морый:

—Юк, китеп барышым иде,—диде.

—Чү! Алайлыйгамы? Китүчеләр болайлыйга бара торганые.

—Бу очтан нәкъ шулайлыга табантын китәләр ул, Рәҗәп абый,—диде Ягъфәр.

Рәҗәп:

—Кая, энем?—диде.

Ягъфәр аның, сул күзен кыса төшеп, уң кашын ничек сирпүеннән үтә гаҗәпсенгәнен искәртеп алды да:

—Зиратка,—диде.

—Ә!—диде Рәҗәп.—Зират якын ул.

—Чираты ерак булсын.

—Кая, Ягъфәр?

—Әлегә гүргә түгел.

—Алайса, утыр әле.

Юри сүз уйнатуын бүтән кирәкмәс санап, Ягъфәр:

—Утырсам, озакка китә, Рәҗәп абый,—диде.

—Ниме суң?—дип сорагач, Рәҗәп салам җәеп утырган бүрәнәдән торды да, алдын-артын юк-бар чүп-мазардан каккалап алгач:—Әллә таптыңмы, наным?—дип сорады.—Шулай сизәм.

—Рәҗәп абый,—диде Ягъфәр.—Менә хәзер мин сиңа наным түгел, бәлки запастагы капитан.

—Тыңлыйм,—диде Рәҗәп.

Ягъфәр бер тезе ямаулы чалбар, уң җиңе өчпочмаклап умырылып, мамыгы күренеп торган—Урта рус калкулыгындагы һәммә халыкка гадәти җылы сырма, башына инде нинди җәнлек тиресеннән тегелгәнлеге билгесез бүрек, аягына киржә итек кигән, каш-керфеге төссез, күзе әллә яшькелт, әллә зәңгәрсу, борынының сул ягы көрән миңле, ирене кысынкы, ияге рухсызларныкы ише җәйпәк булган Рәҗәп каршысында күн пәлтәсенең сул як кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып барлады. Шуны пөхтәләп ачкач, Рәҗәпкә әле күрсәтергә ашыкмыйча, уң кул учына карап алды, шуңа "уһ" дип тынын өргәннән соң:

—Мә, сержант. Атаң—өлкән лейтенант Казыевның Кызыл Байрак ордены. Бусын да ал,—дип, Ягъфәр аңа, уң кесәсеннән алып, ак тышлы бер кенәгә сузды.—Нумерын карап торма—аныкы.

—Инде!—дип, Рәҗәп Ягъфәр биргән орденны сул кулы учында әйләндерде дә күз карашын уң кулындагы кенәгәгә юнәлтте. Аннары тагын—анда да монда, монда да тегендә.

—Кит әле, Ягъфәр!—диде Рәҗәп.—Эзләп таптыңмыни?

—Эзләмәдем,—диде Ягъфәр.—Таптым гына.

—Ә "За отвагу" медале, Кызыл Йолдыз ордены, "За Кенигсбер" медале?

—Оныкларыңның балалары табып кайтыр әле.

—Дисеңме?

—Димим,—диде Ягъфәр. Аннары:—Аларны—орден-медальләрне хәзер дә коялар,—дип өстәде.

Рәҗәп күз карашын кенәгәдән сул аягындагы инде күгәрек төсендәге кан каткан итегенә юнәлтеп алды да, әллә кайдагы ак еракларга карап, тагын:

—Дисеңме?—дип сорады.

—Дим,—диде Ягъфәр.—“За взятие Берлина” булмас инде булуын. Тик “За взятие Вашингтона” да эләкмәс.

—Ягъфәр наным, әйт әле: әтинең бу орденын каян таптың суң? Әгәренки сер булмаса.

—Сатып алдым.

—Сатып?

—Сатып.

—Ничек инде ул! Әтине фотокарточкыга төшергәннәр дә—тегеләр киткәч карасак, кәчтүме шәп-шәрә!.. Шуннан соң күп тә үтми үлде.

—Урыны оҗмахта булсын,—диде Ягъфәр.—Анда орденгадыр, медальгәдер карап кертмиләр ич.

—Каян беләсең?

—Аннан җәннәт медале тагып чыккан әрвах юк,—диде Ягъфәр.—Медальне бу дөньяның тәмугында гына күп тагалар.

Көн ап-ак. Аяк алыштырган саен кар шыгырдый. Мунчада бер тапкыр парланганың соңында мунчалалап, сабынлап юынып алгач, ләүкәдә ике-өч кат чабынып чыгылган тәннең, бармак белән ышкып карасаң, өлгергән кәбестәдәй сәламәт шыгыр-шыгыр иткәне шикелле.

—Шулай да, наным...—диде Рәҗәп.

—Суык булгач, Хәтер көнендә пычак калынлыгы гына бер-бер нәрсә кабарга киткән идек.

Рәҗәп аннан:

—Пычак калынлыгы күпме була суң ул?—дип сорады.

—Яткырып тотсаң—шул хәтле, кайтарсаң—арта, ә сабына утыртып сагайсаң, нәкъ сиңа таманча, Рәҗәп абый... Әйтәм ич, Казанда Хәтер көне быел салкын туры килде. Бер иптәш белән, чәйме, мәйме эзләгәндәй, Ирек мәйданыннан аскарак төшеп киттек. Анда Ленин орденынача сатыш та алмаштырыш бара. Атаңның бу орденын шул төштә таптым.

—Күпме тора диделәр?

—Анда димиләр, Рәҗәп абый.

—Димиләр үк мәллә?

—Әйе. Араларында кергәнне-сатканны күзәтеп, барлап торучы берәү була.

—Карасана! Нәкъ төрмәдәге сымак икән. Каплаган да куйган смотрящий!

—Анда атаңның бу ордены илле тәңкә тора.

Рәҗәп, гадәтенчә:

—Инде!—дип куйды. Аннары, бүрәнәдәге саламны тараткалап:—Утырыйк әле,—диде.

Утырыштылар.

—Аның минем әтинеке икәнен нумерыннан таныдыңмы?

Аның янында үзеңнең гакыллы икәнлегеңне белгертеп торуның хаҗәте юк иде.

—Эзләп таптым. Тезеп куелганнар. Кеше ул орден-медальләрнең бөтенлеген карый. Янәмәсе сакланышлары нинди дә, эмале кырылмаганмы, ядрә-фәлән тимәгәнме, сугышның башында бирелгәнме, ахырына табамы...

—Аның аермасы бармыни?

—Сугыш башлангандагысының көмеше күбрәк.

—Беткән чагында?

—Әзрәк,—диде Ягъфәр.

—Нигә алай икән?

Ягъфәр теге сугыш алдыннан коелган орден-медальләрдәге алтын-көмеш микъдарының ахырга нигә кимегәнлеген әйтеп, сөйләп тормады. Югыйсә, он белән он, ипи белән ипи аермасыннан ук керешәсе була. Алай итсәң, сүзнең дилбегә очына җитәм димә.

Ягъфәр:

—Казыев абзый бу орденын сугыш башында алган,—диде.—Ул вакытта илнең алтын-көмеше байтак булган әле. Ахырында ничек төткәзеп бетермәк кирәк?

—Алайса теге фотокарточкыга төшереп йөргән адәм актыклары көмеше күбрәк булганга күрә урлаганнармыни инде?

Ягъфәр җавап бирмәде. Чалбарының уң кесәсенә кулын тыкты да, үзе белгән бер-бер нәрсәне капшап алгач, учын Рәҗәп Казыевка ачып күрсәтте.

Ул Рәҗәпнең аптырап калып, сискәнепләр торып киткәнлеген, утырган жиреннән калка торып, тагын сеңүен кырынмы, турымы карамастан ук күреп, белеп торды.

—Тәре бит бу, наным!—диде Рәҗәп.—Фашистларныкы!

—Аларныкы,—диде Ягъфәр.

—Каян алдың?—дип сорады Рәҗәп. Ягъфәр җавап бирмәде.—Шул ук... базардан мәллә?

—Шул базардан,—диде Ягъфәр.—Сугыш базарыннан.

—Монысын да шуннан... сатып алдыңмы әллә?

Ягъфәр әлеге свастикалы көмеш тәренең әнкәсе вафатыннан соң аның сандыгындагы нигәдер патша заманыннан калган кызыл каракошлы “40 копеекъ” маркасы ябыштырылган бер конверттан табып алганлыгын әйтеп тормады.

—Ә моның көмеше күпме тарта?—дип сорады Рәҗәп.

Ягъфәр:

—Монда алтын-көмешкә караганда кан күбрәк,—диде.

—Синең атаңны мең дә тугыз йөз утыз тугызынчы җылның язында әрмиягә алганнар дип беләм,—диде Рәҗәп.

—Бу көмеш тәрегә дә шул ел басылган,—диде Ягъфәр.

Рәҗәп:

—Бу—сугыш ачылган ел ич инде, наным,—диде.—Польша.

—Сугыш ачылган ел, Польша,—дип җөпләде Ягъфәр.

—Шул елны шуның өчен бер-бер нимес солдатына биргәннәр инде,—диде Рәҗәп.

—Орденның мондыен сугыш башында солдатка такмыйлар.

—Офицерга гынадыр шул.

—Иң кимендә—группенфюрерга, Рәҗәп абый.

—Анысы кем була инде, Ягъфәр?—дип сорады Рәҗәп.

—Группенфюрер була,—диде Ягъфәр.

—Суң мин надан ич инде, наным. Ниме дип кистереп әйтмисең?

Ягъфәр:

—Нәрсәне, Рәҗәп абый?—дип сорады.

—Групперфүрер дигәнеңне. Кара, әйтеп бетергәнче телең сынар, ә! Безнеңчә ничек була суң ул?

—Аларча була, Рәҗәп абый.

—Бу тәренең күпме торганлыгын әйтмәдең ич әле.

—Өлкән лейтенант Казыевның орденына караганда күп мәртәбә кыйммәтрәк,—диде Ягъфәр.

—Нигә кыйммәтрәк, наным... капитан?—дип сорады Рәҗәп.—Әгәренки, аңлавымча, бу фашист тәресен атаң кулга төшергәч диюем инде.

Шул вакытта Рәҗәпләрнең кече капкалары ачылып китте; аннан, мунча мичендә тыгылган утын астына каен тузы ягып җибәргәннән соң моржасыннан ургылып чыккан кара төтен шикелле, кара-корым бер эт атылып килеп чыкты

да... Ягъфәрне күргәч, сыртын кырт кирегә борып куйды. Ул капкадан ике хатын күренеп, берсе алдан тартып, арттагысы этеп, калай тагарак өстерәп чыгардылар. Алдагысының Рәҗәпнең хатыны Гөлсинә икәнлеген Ягъфәр таныды инде. Арттагысы кызларының Сәгыйдә атлысы иде ахрысы.

Гөлсинә, аны күреп алгач:

—Исән-саумы, наным?—диде.

—Аллага шөкер!—диде Ягъфәр.

—Менә без шундый инде, наным,—диде Гөлсинә. Аннары Рәҗәпкә: —Пычак бир әле,—диде.

Рәҗәп кесәсеннән чүпрәк төргәге чыгарды да:

—Мә, үткен. Кулыгызны кисә күрмәгез,—дип, пычак чыгарды да бүрәнәнең сул ягындагы черек ботак урынына кадады.

—Кыршалмады микән инде?—дип сорады Гөлсинә.

Рәҗәп:

—Төрмәдә ике ел каешландым,—диде.—Пычакның ни икәнен генә беләм.

Ягъфәр күрде: йөзе трактор двигателе клапанын таптатып ясалгач кайралган, кул тоткычы пластик массадан аллы-гөлле итеп төпләнгән пычак.

Әлеге хатын уңган юка гына ефәк яулык япкан, сырмадан, карамы, күрәнме икәнлеге танымаслык трико тарткан, пычракка катып, кар ягылган бутый кигән.

Шанель ислемайлары сибенеп, Версаче киемнәре киенер урынга Гөлсинә әле генә ишегалдыннан капка төбенә тартып алып чыгарылган тагаракны әйләндереп бушатты да, ире Рәҗәптән сорап алган пычагы белән ак карга яткан яшькелт-зәңгәр өемне буеннан-буена ерып чыкты. Ә аның белән янәшә торган кызы:

—Әни, әйләндеримме?—диде.

—Капла, кызым,—диде Гөлсинә.

Гөлсинәнең ярып, ә кызының әйләндереп каплаган сыер ашказанынннан кайчандыр болыннарда борнап та, аннары суң чәчәк атам дигәндә чабып киптерелгән үләннәр, чәчәкләрнең ахырга ни кыяфәт алганлыгын Ягъфәрнең беренче тапкыр гына күрүе түгел.

Фәкать шунда Гөлсинәнең яланкуллап әүвәлге чәчәкле болын печәне боткасында ни рәвешле кармаланып торганыннан соң:

—Карале, Рәҗәп! Инә кергән булган икән,—дип, нәрсәнедер кармалап тапканыннан соң иренә чистарткандай күрсәтеп биргәндә, Рәҗәп:

—Яхшы. Атом бомбасы түгел лә, Гөлсинә,—диде.—Бер көн ашатмый тотканыем, Ягъфәр энем,—диде Рәҗәп.—Ә каласы нәрсә барыбер кала икән.

—Әле ярый кадалмаган,—диде Гөлсинә.

—Кадалса суң,—диде Рәҗәп.—Аны барыбер суясы иде ич. Эч мае гына да дүрт чиләк чыкты, энем,—диде ул Ягъфәргә.—Ышанасыңмы-юкмы?

—Әйбәт булган,—диде Ягъфәр.

—Әйе... Моның—әти орденының дим инде—бәһасе күпме тора диден әле? Ә! Йөз, әме бит? Шул бәягә сатып алалармы?

Ягъфәр аның "йөз" дигәнен "илле"гә төзәтеп тормады.

—Алалар.

—Әйтик, әгәренки мин шунда барсам. Алалармы?

Ягъфәр:

—Алалар,—дип кабатлады.

—Ә мин, әйтик... Йөз илле сум куйсам?—дип сорады Рәҗәп. Аннары пышылдап:—Сатып алалар да—саталармы?

—Сатылалар,—диде Ягъфәр.—Барып өшәнмә.

Ул утырып торган бүрәнәдән иңә башлаган суыктан арынырга, аягын, җанын, бәгырен язарга теләп торды да, теге хатын-кызларның баягы суелган сыерның ашказанын, эчәкләрен эш итәргә ишегалдындагы мунчага алып кереп киткәннәрен искәреп, урамның үзе кайтышлый тарафыннан бер ир затының

килгәнен күргәч, өске киеме итәген кайтара төшеп, кулын куен кесәсенә тыгып алды.—Шушы җитәме, Рәҗәп абый?

Аның кулындагы өч иллелек акчаны шәйләп алган Рәҗәп, һич кабаланмыйча, тып-тыныч итеп:

—Җитә,—диде.

Күктән, сабыр гына итеп, сирәк, бик сирәк, тик инде озакка киләсе суык кышның җемелдәвек вак кары төшкәли иде.

Ягъфәр өенә таба кайтып китте.

Каршысына килгән әүвәлге ир заты аны:

—Нихәл, энем?—дип сәламләде.

—Аллага шөкер, Сәхабетдин абый,—диде Ягъфәр. Аның чиста тастымалга ни төреп тотканын төгәл аныклап, ул:—Кемнәргә юл тоттың?—дип сорады.

—Тилчә Закир абыйлар дәшкәние. Үгезләре ике яшь ярымлык. Сорагач, ничек тик торасың инде,—диде Сәхабетдин.

—Савап булсын.

Шулай дисә дә, ул әле генә әллә кайдагы Сират күпереннән ары таба үткәндәгедәй бер хис кичереп алгандай булды.

Юк. Тәмугтан үтте бугай.

Кайсы тарафка икән?

Бу дөньяны кемнәр генә белеп бетерсен соң...

Ягъфәр үз чалбарының уң кесәсендәге янәшә ике орденны (берсе—Кызыл Армия сугышчысыныкы, икенчесе—фашистныкы) тоеп барды.

"Күрәсең, Ахырзаманга хәтледер",—дип уйлады ул.

Аннары соң, үзенең ни уйлаганын үзе дә белеп, аңлап, кабул кылып бетермичә:

—Энә күзе,—диде.

## Акбар

Ул—Акбар кушаматлы эт—адәми затларның җансыз берәүне акка төрелгән килеш ниһаять җиргә күмеп куйганлыкларын зираттагы бердәнбер юан карт нарат агачы төбенә посып торганы җиреннән әле бу, әле теге якка күчә-күчә карап торды-торды да, тегеләрнең гамәлләре тәмам икәнлегенә төшенгәч, әле генә җыйнаулашып, ашыгып, алмаш-тилмәш көрәк алыштыра-алыштыра күмеп киткәннәреннән соң калган дымсу бер калку өем туфрагын алгы аякларындагы тырнакларының каерылып, шулардан бөтенесе төпләреннән кан тамчылары чыккач, шул кан, тырнак, җир, җан исе саркып, сыктап беткәненә хәтле актарды да актарды, казыды да казыды.

Һич ни чыкмады.

Ул үз хуҗасының кайдадыр шунда икәнлеген тәгаен белә, ә барча белгәнлегенең чигенә җитәрлек түгел икәнлегенә Кояш тәмам иңгәч кенә ышанды, биреште, чигенде.

Мәңгегә.

Әлеге адәми затларның Кояшның төшлектән авышкан мәлендә билләренә тиклем үләннәр, чәчәкләр арасына иртән үк урык-сурык йөргәннәренә күрә аяк асларында тапталып салынган сукмактан инде менә берсе артыннан берсе тезелешкән көйгә тыныч кына сөйләшә-сөйләшә китеп барганнарыннан, капкадан чыккач, һәркайсы үз тарафларына таралышканнарыннан байтак вакыт узгачыннан соң—Кояш инде бөтенләй сүрелеп бетеп, Ай калыккач кына ул—Акбар—алгы тәпиләрен калку җирән җирдән аергач ялап-ялап алды; тырнак төпләрендәге ком, үзле кызыл балчык катышлы үз канын төчкереп-төчкереп атты. Күпме актарынса да, казып төшәренә ирешүгә көч-куәте җитмәслегенә һич кенә дә килешәсе килмәс бортын, әле вак-вак кына атлап,

әле терек-терек йөгереклəп, әлегə кая барасын белмəгəн хәлдə əллə кайсы тарафка юнəлеп китте.

Кояш калыккандамы, Ай баткандамы вакытларда ул үзенең кеп-кечкенə икəнлеген чамалый. Тик һич кимендə арт аякларына басып барган шəттə дə үз буен кешелəр буе белəн чагыштырмада биегрəк икəнлеген раслар хакына ул үз койрыгын болгап ямакайлануга, ялагайлануга мохтаҗ түгеллегенə үтə төшенə иде. Анысы, нишлəсə дə, аның ни колагы, ни койрык очы беркая да җитми-җитүен. Алайга калса, əтəч кикриге дə Салават күпереннəн узмый; сыерлар көтүендəге ала-кола үгезнең үкерéплəр торып алуы да күк күкрəве түгел; урамдагы ата казларның да, кəкере муеннарыннан гайре, аннан уздырган, алдырган əллə нилəре юк ул.

Әйе, ул—Акбар—бəлəкəй эт. Тик аның, кечкенə, көчсез дип, моңарчы бер генə кырмыскага да басканы, һичбер күбəлəкне тешлəгəне, ичмаса уен өчен генə булса да берəр чыпчыкны тотам дип куркытканы юк əле. Авыл урамы буенча көпə-көндезме, кара төннəрдəме, кышкы бурандамы, язгы ерганаклар ташып аккандамы үтеп барышында тегенди-мондый этлəрнең каршысына чəчрəп чыкканнарын үз капка асларына ничегрəк куып кертү ысулын ул яхшы белə: күрмəмешкə салышасы да, эндəшми-нитми генə үтəсе дə китəсе. Бөтенесе ык итмəгəйлəре мык итсеннəр шунда.

Ул үзенə каныгырга ниятлəгəннəргə тамагын əрəм итеп торсынмыни суң? Үзеңне белдерə белдерергə кирəк. Югыйсə алар—барчасы да ата этлəр. Ә ул үзенең ана эт икəнлеген быелгы язын гөрлəвеклəр агар-акмас тулганда, ташу төшəр-төшмəстə сизде, тойды, белде инде анысы. Тиңең югында корсак күрсəтмəктəн ни мəгънə? Аркага ятуы җиңел ул. Кыр этлəре өере узып киткəндə, бүрелəр-фəлəн килеп чыккан əхрəттə аркан ятып, эч күрсəткəндə ярый: алар бəлəкəйлəргə тими. Ни кышын, ни язын. Җəен бигрəк тə. Кешелəр генə күзлəренə карап өлгермəстəн уздырып сүгенə, тик кенə торганың чагында да тибəргə җай көтеп тора, кул асларына туры килгəн таштыр, агач, тимер кисəгедер атарга яскана.

Эттəн шиклəнгəн кеше үз-үзеннəн, үзе уйлаган уйдан курка.

Акбар үз ниятлəрен кылырга куркучы кешелəрдəн шиклəнергə кирəклеген белергə күптəн өйрəнде инде.

Ул—Акбар: ап-ак булганына күрə кашлары уртасындагы, койрык очындагы, алгы тəпилəрендəге кара тапларга карата юри “Ак бар” аты кушылган Акбар. Әллə күпме этлəрнең, үз хуҗаларын кыяк үлəнле, пəйгамбəр чəчкəле, шайтан таяклы, кычытканлы, инде буйга үсүдəн узып, корыгач сузылыплар торып җиргə авып төшкəн каенлы, шул—Акбар өнəми торган əллə нинди чит-ят исле урынга күмеп киткəннəре соңында килеп, борыннарын төрткəннəре, тырнакларын канатканнары юк. Аларга əйбəт, рəхəт. Өйлəреннəн берəрсен күтəреп алып чыгып, бөтенлəйгə калдырып киткəндə дə аларның караучы кемнəредер кала.

*Ә менə мин—Акбарның—беркемем дə юк инде.*

*Кичəгенəк авыл көтүе кайткач—сыерларны, сарыкны, кəҗə, бозауларныдыр кайсын аратага япкач, кайсысын абзарга куып керткəч, сыерларны, саугачыннан соң, тугайгамы, бакча башларынамы төнгелеккə арканлагач, тавык-чебешлəр, əтəчлəр инде əллə кайчан куначаларына кунаклагач, аның хуҗасын əнə теге яктагы, менə бу яктагы ике ир кеше инешнең түбəнге очына җəтмə белəн балык тотарга алып төшеп киттелəр. Мин—Акбар дəшкəч иярми нишлим инде? Иярдем.*

Һəр адымнарын карап торды, басып йөргəн эзлəрен иснəп барды. Балык күп элəкте. Аның хуҗасы кайта-кайтышлый башта тегелəрдəн утырып калды, аннары җиргə ятты. Ятты да тынды. Акбар моның бөтенлəйгə икəнен тойды. Әлеге ике ир кеше, балыклы букчаларын тотып, юеш җəтмəлəрен озын сапларында тирбəтə-тирбəтə кайтыр якларына табантын туктамыйча киттелəр дə бардылар. Ичмаса бер генə тапкыр да əйлəнеп карамадылар. Югыйсə үткəн

юлыңа әйләнеп карашлы, әледән-әле борылып кайтышлы, барлыйсы, ышанасы ич ул.

Тегеләр китте. Акбар үз хуҗасының битен әллә күпме ялады да ялады—уята, торгыза алмады.

...Бөтенләйгә ятканнарны тәмсез ис бөркүчән кучкыл-шәмәхә чәчәкле, ялгыз нараттан былтыр ук коелышкан күркәле, иссез әрем үскән җиргә күтәреп алып баралар да бер-бер казыганнары чокырына күмәләр дә китәләр. Акбар боларның һичкайсын белмәс иде белүен. Бу сиңа ялгыз хуҗаңның, сине кеше итеп, үзенең җылы, тыныч кочагына кертеп яткыруы гына түгел.

Әнә аны дымсу туфрак өеменнән Ай беткәнче казысаң да чыгарып булмады. Тирән. Ул аннан Кояш тәмам күтәрелеп, су эчәсе килгәченнән суң гына китеп барырга кыйды.

Инешнең комлы ярыннан иелә төшеп, Акбар төче су эчте-эчүен, ә шуннан ары, өметен өзмичә, өйләренә кайткан иде дә—кызыл чәчәкле пыяла тәлинкәсенә бер нәрсә дә салынмаган. Менәтерә, болдыр ишегенә борынын күпме төрткәләде дә төрткәләде инде, баскычны күпме тырнады, өреп тә чинап, өреп тә шыңгып карады—ә аның юан нарат төбеннән кача-поса карап торганы чагында бөтенләйгә күмеп калдырылган хуҗасы өйдән чыкмады, дәшмәде, күренмәде. Югыйсә Акбар бүген бер-бер сугым көне иконлегөн әллә ничә көн белеп көткән иде инде. Каян белә дигәндә, ул кара мыеклы мөлаем ике кешенең машиналар арлы-бирле чабышкан юл ягыннан тәгаен кайтасын, аңа әллә нинди тәмле ризыклар бирәсе көннәре җиткәнлеген өзелеп-өзелеп көтә иде.

Бүген аларның кайтасы көне. Ә аны фермадагы бүгенге сугымга дәшеп алмадылар. Ансыз—Акбарсыз ничек икән инде? Андый-мондый ит-мазар калҗасы, талак (тулысы белән), кап-кайнар бавыр, йөрәкнең тамыр-бизләре, карта (үзләре алып китмәгән шәттә) тәгаен аныкы булган вакытлар шулай бетте дә китте микәнни? Ә андый-мондый ит-мазар калҗасы тияр сыманлыгын ул сиземләп, чамалап куйган иде инде куюын.

Бугай.

Юк. Бүген җир астыннан үзле балчык исеннән гайре бер нәрсә дә бирмәсләр күк.

Икән.

*Күнеккәнемчә, мин бу вакытта әйбәт хуҗамның йоклап ятканын янәшәсендәге мендәрдән саклап, сагалап торам инде. Ул исә көтә-көтә дә кайтмагач, Ай чыкканда тагын су эчеп мендем дә—кырын ятып йокладым. Йолдызлар сүнгәч, мине бер абый үз кочагына күтәреп алып киткәне чагында да йокладым әле. Болай гына инде—йоклаганга сабышып. Юри-мүри генә. Мине тагын нишләтерләр икән дип. Мондый чакта карышырга ярамый. Инде өрсәң—бигрәк тә харап.*

*Кирәге чагында өрмәүдән хәерлерәк нәрсә юк. Моны мин яхшы беләм.*

*Мине әнкәм имиеннән аерып, адаштырып калдырганнарыннан бирле. Мине күтәреп апчыктылар да и уйнаттылар, и чаптырдылар. Карасам—зур ишегалдында беркем дә юк. Ул кичне Ай бик салкын иде. Ап-ак җир суык, тәннәрем туңып бетте. Мин ап-ак маэмайны ак карда ничек күргәннәрдер,—бер апа кеше үз кызы белән үзләренә алып кайттылар да, башта ап-ак җылы урынга куеп, өстемә кап-кайнар су сиптерделәр. Әшим дип торам. Бик тәмле итеп, хуш исле күбектә юдылар. Ак мәчеләре бар икән—мин аңа өрмәдем дә. Икебез бер савыттан ашадык, чәчәкле бүтән ике савыттан чиратлашып су, сөт эчтек. Ашадык та ашадык, эчтек тә эчтек. Шуннан соң безне аерып, мине купшы кара мыеклы бер кеше җылы, кояшлы, салкынча, яшел үләнле җирдә калдырып китте. Ул авыл икән. Сыерларны шунда күрдем. Сөзәм дип, мөгезләрен терәп килгәннәренә өрмәдем. Мин бер кемгә, бер нәрсәгә тимәдем, өрмәдем.*

Аның йомран, әрлән ояларын да казыганы бар. Чыксалар да, ул аларга

тимичә, әллә кая талпынып-талпынып йөгерүләре башында куып җитәргә дә тотып алырга яскана иде дә... үз-үзен тыя иде: күбәләк икән—очсын, әкәм-төкәм икән—шуышсын, керпе икән—туктатканда уфылдап йомарланган булсын; ул аларга тими, мәче башлы ябалакларның үз ниятләре, йорт-җиргә ияләшкән үтә мут, елгыр ике сасы көзән дә әллә ни кыланмак була. Бөтенесе каядыр бара, ул—Акбар күпмесенең усал ниятенә аркылы төште, яхшысына сөенде.

Ә кешеләрнең сүгенсә куркытмаган, ашаса тук булмаган, эшләсә булдырмаганнарыннан ул гелән-гелән читләшә, аларны ят итә, өнәми, үз итми иде. Ул андыйларга өрергә дә артыксынды. Ата казларны котыртудан ни мәгънә?

Акбар, шулай, сыер фермасы, атлар абзарында каравылчы торган хуҗасы Сәлахетдинне озак, бик озак онытa алмыйча изаланды.

Сәлахетдин йоклап ятканда айлы төн уртасындамы, таң ата башлаганда күктәге йолдызлар берәм-берәм сүрелә, сүнә керешкәндәме Акбар гел уяу, сакта була белде. Шуңа күрә ул үзен кичтән иртәнгәчә бөтен хуҗалык малтуарына, мөлкәтенә хуҗа тоя, ә исә андый сизгер хезмәттә чагында бөтен нәрсә—аның хезмәтчесе инде ул.

Ә болай тамак тук, өс-тән бөтенлеккә бөтен.

Чөнки кайбер чакны кичләргә кырын Сәлахетдин:

Танкыларда янган чакта
Көчкә чыгып өлгердем,

—дип җырлый-җырлый әллә кайчангы—янчек, ямалып беткән алюмин савытының капкачын тутырып, аңа ризык куя да:

Әйдә, Акбар, куен җаным,
Сиңа да баш өлгерде,

—дип, аңа кичтән суелып, туналып, туралып, үлчәнеп, ниһаять алып китеп, каядыр җыйналып куелган берәр сыерның шунда калдырылган башының көттереп пешерелгән кайнар итен, җылы сөякләрен иплә куя торган иде.

Ялгызы калганда Сәлахетдин кешеләр, халык арасында, алдында сүз әйтмәү, катмау гадәтен ташлый, иплe итеп, җайга салып, җырга көйләп кенә Акбар белән сөйләшә:

Күпме үлән, чәчәк җыя
Бүз сыер ашказаны;
Пеште инде,
Әйдә, Акбар,
Җырлаек "Ашказар"ны,—диебрәк.

Җәяүле буран себерткәндәме, җәйге чиллә төннәрендә, көзге күктән яңгыр яугандамы чакларда Акбар үзе дә әллә нишләп китүчән, үтә моңаючан бер җан иясе ул. Күрә торып җырласынмыни суң?

Җук. Ярамый. Сәлахетдин әйтмешли, кеше көләр, перәми.

Шул Сәлахетдинне җиргә күмеп киткәчләреннән соң Акбар үз күңеленнән генә моңаюыннан, Айга карап, кешеләрчә җырлыйсы килү ымсынуыннан бизде, кире кайтты.

Онытты.

Инде.

Тәмам.

Хәер, вакыты-вакыты белән үтә гаяр тернәкләнеп, шаяргалап, җанланып, моңсуларны мул суларга агызып җибәргәләгән чаклары да булгаламады түгел. Теге—берсе матур, озын чәчле, житез килеш-килбәтле, бик юмарт сүзле, бүтәне кара мыек-сакаллы, кырыс холык-фигыльле абыйлар үз өйләренә кайтып төшкәләгәндә. Бигрәк тә болар йөгерек сулы инеш буенда төнгә каршы

учак ягып җибәреп, тәмле, хуш исле ит пешереп, үзләренә ияртеп төшкән гармунчыны уйнатып, җырлатып, аңа үзләре дә кушылып китеп, тора-бара болар янына тирә-күршедәге бала-чага җыйналышып, ахырда чибәр, көр кызлар, таза-сау саллы егетләр, ирләр дә тартылып тупланган, көрнәлгән чакларда бигрәк тә ярыйсы, күңелле, җайлы, рәхәт, шәп була торган иде.

Иде шу-ул... Иде-е.

Сыерлар гына ул бүген ни ашаганнарын белмичә күши дә күши; атлар да, камытлары бүген кисмәгән икән дә, ыңгырчаклары сыртларын кырмаган, арба тәртәләре тәжедән читкә каермаган, чана табаннары чалуларга бирешмәгән икән дә шуңа шат-канәгать. Алар бүтән һәммә нәрсәне үз хәтерләреннән тиз кайтаручан, чуалтучан, югалтучан.

Ә Акбарның исендә. Исендә.

Һәммәсе.

Сәлахетдинне тырнакларын каера-каера күпме ясканса, күпме тырышса да казып чыгара алмаган көзге көннән соң япа-ялгызы аның инде бикле болдыры төбендә бөгәрләнеп төн уздырыр-уздырмас газапланган, аннары көн кичергән, кич җиткәндә ул берәүнең аны күтәреп алып:

—Әйдә, Акбар,—дигәнен ишетте дә колагын шәңкәйтте.

Тавышы көр, нык. Акбар битен сыпырып алды да өметле-өметсез көйгә тәпи-тәпи шуңа ияреп китте. Иярмәс тә иде ияргүен. Тик ул тавыш иясе аңа таныш адәми зат. Мал-туар чалырга гел шуны дәшәләр. Ә ул исә аңа—Акбарга талактыр, йөрәк тамырларыдыр, бавыр бизләредер ише нәрсәләр генә ыргытмыйча, корсак итен дә кыеп бирә торган кеше Баһау иде.

Чакыргач ничек бармый калмак кирәк инде. Урлы-сурлы дәшкәннәргә ыгы-зыгыланып илтифат итүне өнәмәгән, сөймәгән, кире каккан Акбар тегенең нык кушканына буйсынуны үзенә зур дәрәҗә санады да—иярде.

Күпме казып та чыгара алмаганны казганып кына татып була ул.

Әйе, иярде.

Ул Баһауның күпер төбендә ялгызак яшәгәнлеген күптәннән шәйләгән иде инде. Аның торган өе, болай, ярыйсы-яравын. Мунчасы бар—тик Акбарның андагы морҗадан мул, хус исле төтен чыкканын хәтерләми. Абзар-курасы да төзеккә төзек шикелле, ә аннан беркайчан сыер көрсенгәне ишетелми; сарык бәтиенең сөтле иренен ялый-ялый, чирәмле капка төбенә чыкканы юк; ичмаса тавык-чебеш ише вак-төяк тә күренми. Акбарның ул тирәдән узып барышлый искәргәне бар: аннан көндезге тилгәннәр, төнге ябалаклар эзләнмичә, тукталмыйча ары таба узалар да китәләр иде. Чөнки—юк. Үзе төрмәдә чагында хатыны бар мөлкәтне сатып бетереп, кызы белән кияве янына киткән.

Ул менә шушы Баһау белән озак тора алмады. Әйбәт, йомшак кеше иде. Әби-сәбиләргә печән-фәлән китергәндә ул Баһау чүмәлә өем башын тотты; чакырым ярымдагы чишмә суына баручыларга бик якыннан гына тәмле чишмә ачып, аны бурап бирде; сер түгел, әби-сәбиләргә кышкы төннәрдә капчыклап фермадан силус китереп биргәләде; җәйге көндезге көннәрдә берәүләргә җыйналышып җир тишәргә тотынып та, су таба алмагач, ташлап китәрләре алдыннан иң төпке тыгыз пычракны уң кулының кытыршы, нык бармаклары белән угалагач: "Тагын ярты сажин да бер дюем",—диде дә шуннан башта болганчык, аннары чип-чиста су бәрепләр торып чыкты. Аңа моның өчен шешәдән бер чынаяк эчемлек салып биргәннәр иде. Ул аны чайкап торып читкә түкте дә атты. Аның каруы теге кое суын алдан аңа—Акбарга эчертте. Акбарның авылдагы бер генә эткә дә хуҗасы пыяла савыттан үзе тотып су эчерткәнен күргәне юк иде әле.

Шул чагында аңа гаять рәхәт булып киткән иде. Ул әлеге вакыттагы кинәнүен онытырга ярамаганлыгын исенә иңдереп куйды.

Ул мәңге онытмый-онытуын. Ә кешеләр генә әллә нишли икән нишләвен.

Әлеге бораулап кое суы чыгарылган өйдәге хатын эш кылганнарны аш-су сыйлаган чакта Акбарга: "Йөрмә әле монда буталып, кеше типкесе!"—дип, галушы йомшак булса да, шактый каты иттереп, аның кечкенә эченә типкән иде.

Аңа—Акбарга типкәләгәннәре булмады түгел-түгелен. Ул президентның авылга сугылып киткән чагындагы бер-бер тән сакчысы типкәнен кичерде-кичерүен (чөнки ул аның мылтык маен сизгергәне өчен генә, бәладан баш-аяк дип, балтырына чат кына капмады, ябышмады), ә инде бу—тулысы хәттин ашкан хатынның үзенә тибүенә Акбар бик гарьләнде. Шуңа күрә Акбар аның ферма мөдире Мөнип коры яшел үлән өемендә ятканда салдырган аммиак исле алсу трусигын, шуңа өстәп, әлеге мөдирнең кепкасын да сизгерттермичә генә эләктереп алып, шул мәлдән соң ук теге тәмле су чыккан коелары төбенә куеп китте.

Зур тавыш, җәнҗал чыкты: имеш, Баһау эше.

Икенче көнне төш җитәр-җитмәстә су буендагы араталы җәйләүгә әллә кемнәр генә килеп төштеләр дә аның яңа хуҗасы Баһауны, кулын артка каерып, башын идерттереп, зәңгәр машиналарында әллә кая алып киттеләр. Баһау аңа—нишләргә белмичә аптырап сырпаланган, аянган, өркенгән, курыккан Акбарга:

—Акбар! Ак барында—тап бар,—дияргә генә өлгерде.

*Югыйсә мин—Акбар теге тулы, матур апаның хуҗам Баһау сыерчык бураннарыннан соң һич кимәгән кожаны кесәсенә бер кәгазь кыштырдатып, учыннан кылтыр-кылтырдатып ни нәрсәләрдер тыкканын, салганын сизеп, күреп, үрсәләнә-үрсәләнә өргән идем лә ул кана. Ферма мөдире Мөнип миңа төбәп сәнәк ыргытты. Мин елгыр-елгырын. Ә хуҗам Баһауны алдылар да киттеләр.*

Әйе, Баһауны йөз сум да җитмеш өч тиен акча урлаган дип гаепләделәр. Хөкемдар карар чыгарды, ул карар һичниндиі каршы гозер булмаганга күрә тәмамы белән расланып куелды: биш еллык төрмә.

Ферма мөдире Мөнип белән яңа коега тиңешкән йорт иясе әлеге матур хатын яккан мунчада бергәләп ~~чабындылар,~~ аркаларын алмаш-тилмәш уыштылар, сый-хөрмәт итештеләр.

Ә Акбар исә боларның инеш суына чумганнары мәлендә үзен шушында алып кайткан теге кара мыеклы ике әйбәт кешеләрнең иясез йорт-җирендәге болдыр астына мәңгелеккә дип кереп ятты да:

"Мин Акбар идем!"—дип исенә төшергәч, авылдагы барча этләрне моң, сагышка, уйга салып, соңгы тапкыр, соң мәртәбә өрде дә—тынды.

*Мин—Акбар үземне тынарга мәҗбүр итеп тындым. Югыйсә былтырлары Сәлахетдин мине Кәрәкә күле буендагы тауда җил каккан су ише дулкын-дулкын айкалган да чайкалган кылган диңгезенә кертеп җибәргән иде дә—и!—кинәнеп, рәхәтләнеп, шунда колачлый-колачлый йөзгән дә йөзгән, инде ул чакны кычкырмас-нитмәс яшь канатлы тәкәрлекләргә өзелеп, кырын карый-карый әз-мәз өргәләгән идем.*

*Минем төшемә югарыдан караганда алгы тәпием табаны хәтле генә тоелган, күренгән түгәрәк күлдәге кыр үрдәкләрен куркытасым, инештәге кондызларны котыртасым,—тагын әллә нишлиселәрем килүләре керә торган иде... Ни ул... берәр матур, тырыш сыерның мышный-мышный үлән ашаган чагында көтүченең аңа селтәгән чыбыркы очын иренемә кабып калганнарым күп булды. Мин әнкәмне имеп яткан чагымда бер адәми затның мылтыгыннан чәчрәп чыккан яшен очын гына эләктереп алырга өлгермәдем.*

*Ә болай... миңа дөнья күрсәткән мыеклы абыйларга мин риза-бәхил. Болдыр аслары коры, тын, ипле иде.*

*Үзем шикелле генә кеп-кечкенә бер үкенечем, куанычым калды-калуын: теге якты җиһанда алдыма куелган ризыктан кала беркемне, һичнәрсәне тешләмәдем.*

*Ә! Соңгы мәлемдә тагын бер әйбер исемә төшеп өлгерде әле: Теге—инде теге—Кояшлы, Айлы, Йолдызлы, таңнар сызылып атканда чык төшкән үләнле—әйтепләр бетерерлек булмаган тагын әллә нәрсәле җирдә минем үз имчәгемнән аерыплар, каерыплар алып, кайсы-кая таратыласы бәгырь көчекләрем булмаганга әллә сөенеп өрәсе, әллә көенеп шыңсыйсы калган.*

*Яшьләр иҗаты*



## Илзирә Вәлиуллина

# АКЛЫКТАН ЯРАЛДЫМ

***

**Һәр фасылда Сине сагынам,
Хисләреңә, юк, юк, кагылмам!—
Мин ерактан, бары ерактан...
Әйтми генә сине сагынам!**

## Язмышым

**Бер шатлыкка сөенсәм мин,
Мең газапка көендем:
Максатыма җитәр өчен
Сүтәм тәкъдир төенен...**

**Кемнәрдер дошман санаса,
Берәүгә дус күрендем.
Кайберәүләр елак дисә,
Күңеле төшә... күңелнең.**

**Бер моңы булдым җанымның,
Бер колы булдым аның.
Очрашканда ярсыдылар
Юләрлегем һәм аңым.**

**Озын юллар үткән чакта
Яктылыкка омтылдым.
Качкан чакта кайгылардан,
Ак бәхеттән... тотылдым:**

**Чатырдатып ябыштым да
Ялларына тотындым.**

## Карлар елый ак моң булып

**Ак кар елый мыштым гына,
Җемелдәп һәм ялтырап,
"Кояшның тозак нурына
Эләктем", дип, аптырап.
Кар хәлләре бик кызганыч,
Яшьләре ага, күрегез.**

---

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА—*шигырьләре, публицистик мәкаләләре көндәлек матбугатта басыла. Түбән Камада яши.*

Бәлки, яшь ага: "Гомернең
Кадерен—дип,—белегез?"
Елый карлар, Җир ананың
Сыенып кочагына,
Әверелә салкын яшьләр—
Утлы зар учагына...
Карлар, суларга әйләнеп,
Уртак яшь булып ага.
Шуны аңлаган өченме
Йөрәктән моңнар тама?
Ул моңнарны, җәһәт кенә,
Ак төсләргә кар мана...
Ак моңнарны хәтерләтеп
Карлы гомерләр ага.

## Юк, яратмадым

Юк, яратмадым, яратмыйм
Иркә җил сарылуын;
Иркә җилләрнең иркендә
Елак хис агылуын.
Юк, яратмадым, яратмыйм
Хисләләр һәлакәтен;
Күкләргә ашкан җанымның
Алсалар бәрәкәтен?
Юк, яратмадым, яратмыйм
Көннәрнең кыскаруын,
Минутлар санап, кемнеңдер
Гөнаһлы эш кылуын.
Юк, яратмадым, яратмыйм
Ак төснең каралуын,
Чөнки үземнең аклыкта
Яңадан яралуым,
Тәүге кат яңаруым.

## Җиңелме?

Җаннарымны кайгы басты—
бөгелдем,
авырлыктан, нечкә җептәй
өзелдем;
күтәрергә көче бетте
иңемнең,
сагыш басты тәмам—моңлы
күземне;
кара җаннар үтерделәр
сүземне;
җилләр кисте, шашып-шашып,
йөземне.
Бу микән соңгы ноктасы
түземнең,
сабыр канатым сынумы—
үземнең?..
Тәңрем әйтте шул чак миңа:
"Җиңелме?"
...Җиңелдем.
Тик җиңеләсе килми ник
күңелнең?!



# Айдар Җамалиев

## КҮКЛӘР СЫЯР МИКӘН КҮКРӘККӘ?

***

**Бөтен җаным сөя,**
**Яна, көя...**
**Янсын! Көйсен!..**
**Тагын янсын!**
**Ә җавап тапмаса, хистән,**
**Моңлы былбыл йөрәгедәй ярылсын.**
**...Ахыргача янсын!**

***

**Мин акылга яшим буйсынып—**
**Хисләр җиңә.**
**Мин яратам, хискә буйсынып,—**
**Акыл күнә.**

**Вакытмы узды,**
**"Иске киеме тузды",—**
**Акылым яңа хисләр тудырды!**

***

**Йолдыз балкый тәрәз артында...**
**Синең нурлы йөзең—каршымда:**
**Йолдыз кебек балкый,**
**Тормышымны яктырта,**
**Яна җанның нәкъ уртасында...**
**Тик атылма, йолдызым, атылма!**

### Казан татарлары—киләчәктә

**Көчле кулны хөр күкрәккә куеп,**
**Казан безнең өчен—җир үзәге диеп,**
**Яшәрбез без—һәр мизгелне күңел белән тоеп.**

**Без—Казанда туган, милли рухлы татар!**
**Туган шәһәр, ул—меңьеллык диеп,**
**Аның иминлеге өчен һәркем җан атар!**

Айдар ЖАМАЛИЕВ (1985) *—КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә басыла. Казанда яши.*

***

Мин сине шундый яратам:
Күкләр күкри гүя йөрәктә.
Акылымны югалтам,
Акыл миңа шундый кирәктә.
Хисләр ташый күңелдә...—
Күкләр сыямыни күкрәккә?!

***

Вакыт туктап тора,
Тирә-як тын, матур, мәһабәт.
Читтә калып тора сәясәт.
Юктыр җирдә кайгы һәм хәсрәт...
Шундыймы син, якты мәрхәмәт—
Мәхәббәт?!

***

Эссе озын җәйге көнне кыш кирәк.
Салкын кышта: "Җитсен иде җәй тизрәк"...

Әй кеше, әйт, сиңа тагын ни кирәк?

## Юк

Шигырь язылмый,
Илһаммы юк?
...Өстем бөтен,
Тамагым тук.

Гел елмаям мин,
Шаян һәм шук.
Газап чикмим,
Борчулар юк.

Йөрәк әрнеми,
Яралар юк.
Акчам да бар хәтта...
Бәхетем—юк:
Шигырем—тәхетем юк!

Publisistika
Публицистика

**Әхәт Мушинский,**
*татар ПЭН—үзәгенең башкаручы директоры*

## "АВЫЗЫҢ КЫЕК БУЛСА..."

*Бу язмамны мин Татарстан Республикасының Югары Советы гозеренә каршы килеп, Россия Федерациясе Конституция судының татар язуын латин алфавитына күчерүне тыю турындагы законсыз карары игълан ителү белән ук матбугатка хәзерләргә уйлаган идем. Ләкин Россиянең югары суды өчен бу мәсьәлә бик тә катлаулы гамәл булып чыкты һәм ул озак айлар дәвамында һавада эленеп торды. Шулай килеп чыкты ки, каләмгә мин суд хөкеме чыгарылганчы ук тотынган булсам да, язуымны соңрак дәвам иттем һәм күптән түгел генә төгәлләдем.*

### Асылына асылыныйм, дисәң...

Мәгълүм ки, 2004 елның сентябрь аенда Норвегиянең Тромсё шәһәрендә ЮНЕСКО канаты астында Халыкара ПЕН-клуб линиясе бунча Язучыларның бөтендөнья конгрессын үткәрү каралган иде. Бу турыда хәбәр алу белән Татар ПЕН-үзәгеннән Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, Борис Пантелеев һәм бу юлларның авторы мин фәкыйрегез юлга җыена башладык. Татар ПЕН-үзәгенең житәкчеләре Туфан Миңнуллин һәм Разил Вәлиев безгә фатихаларын биреп, кат-кат болай диделәр: "Норвегия—ул дөньяда яшәү дәрәҗәсе иң югары булган чын демократик ил; Халыкара ПЕН-клуб конгрессы дөнья язучыларының бик тә абруйлы оешмасы—аның быелгысы 70 нче (!) мәртәбә үткәрелә; Сез анда татар халкы өчен гаҗәеп мөһим булган проблеманы "төяп" алып барасыз, хәер, боларны сез үзегез дә бик яхшы беләсез, нигә аңлатып торырга..."

Конгресстагы безнең тәгаен генә эшебез лингвистика комитетында башланды. Конгресста каралачак төп темаларның берсе "Кечкенә халыкларның телләре язмышы" дип аталганлыктан, без күтәргән мәсьәлә халыкара форумда бик тә актуаль иде. Билгеле, татар телен һич кенә дә "кечкенә" дип атап булмый, ләкин анда бу термин киңрәк мәгънәдә—ирекле үсеше чикләнгән, кимсетелгән диган кебегрәк итеп кабул ителә.

Искәртеп үтик, ике ел элек Македониядә үткәрелгән Язучыларның бөтендөнья конгрессында Россия хакимиятенең татар язуын кабаттан латин алфавитына күчерүгә каршы төшмәүләрен таләп иткән резолюция кабул ителгән иде. Ләкин дөнья җәмәгатьчелегенең бу фикере Россия хакимиятендә хуплау тапмады. Ләкин бүген, мәгълүм булганча, Россия Федерациясендә яшәүче татарларга лингвистик яктан да, аралашу чарасы күзлегеннән караганда да күпкә уңайлырак булган латин алфавитын куллануны тыю турындагы закон гамәлгә кертелде.

Әйтергә кирәк, Франциянең, Бельгиянең, Норвегиянең, Финляндиянең, Португалиянең, Вьетнамның, Македониянең, Хорватиянең, Беларусьның, Рус ПЕН-үзәгенең, Эсперанто теленең делегатлары безне яклап чыктылар һәм Россия Федерациясенең Конституция судына хат юлларга кирәк дигән карар кабул иттелде. Бу хат Бөтендөнья язучыларының 70 нче конгрессы делегатлары Ассамблеясында укып тикшерелде һәм ул үзенең комитетының башлангычын бертавыштан хуплады. Һәм шуннан соң Мәскәүгә, Конституция судына Халыкара ПЕН-клуб президенты, танылган чех шагыйре һәм кеше хокукы яклаучысы Иржи Груша имзасы белән хат җибәрелде. Анда, аерым алганда, мондый юллар бар: "Әлеге мәсьәләне хакыйкый рәвештә хәл итү өчен бары тик гомумтанылу тапкан халыкара хокук һәм лингвистика стандартларына таянып эш итәргә кирәк... Без әлеге проблеманың чын-чынлап чишелә башлавына ышанабыз".

Бездән, әлбәттә, илегездә шундый сәяси хәл хөкем сөргәндә, әллә Сез чынлап та бәйсез мәхкәмә тикшерүләре үткәрелүенә ышанасызмы, дип сораштырдылар.

Ышанасы килә, дип җавап бирдек без аларга. Әгәр дә шулай булмый икән, безнең барыбыз өчен дә Россия хакимиятенең, шул исәптән мәхкәмәи хакимиятнең дә, халыкара хокук һәм лингвистика нормаларын инкарь итеп, халыкара җәмәгатьчелек һәм гомуми цивилизация дөнья кагыйдәләренә каршы хәрәкәт итүе тәгаен ачыкланачак, гәрчә иң югары даирәдә дә аларга берсүзсез буйсынып эш йөртеләчәге турында бәян ителсә дә.

Һәм ахыр чиктә, гафу итегез, латин графикасына карата күтәрелгән гауганың, әйе,—бик тә чикләнгән булса да,—Татарстанның үз билгеләнү "бакчасына" төбәп атылган чеп-чи сәяси сынамыш ташы икәнлеге Мәнди анасына да мәгълүм нәрсә. (Әгәр инде латин графикасы "өстән" килгән фәрман белән тыела икән, халык мәкалендәгечә, "авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә" диясе кала. Чөнки татар халкының монда бернинди дә гаебе юк лабаса.)

Норвегиядә үткәрелгән Язучыларның бөтендөнья конгрессында тел мәсьәләсенә кагылышлы проблемаларның күтәрелүе уңаеннан "Новая газета" *(2004 ел, N 77)* болай дип язып чыкты: "Шул ук вакытта татар алфавитын алыштыруга бәйле проблема, бер халыкныкы булудан битәр, аздан гына бөтен алдынгы карашлы кешелек дөньясы алдында торган проблемага әверелми калды".

Алга табан әлеге газета Татар ПЕН-үзәге проблеманы яктыртуга Европа Советының Парламент Ассамблеясын да җәлеп итте дип хәбәр итте.

Хикмәт шунда ки, ЕСПАның Дэвид Аткинсон һәм Рудольф Биндинг житәкчелегендәге делегациясе октябрь аенда Казанда танышу визиты белән булып киткәннәр иде. Гәрәй Рәхим һәм мин фәкыйрегез алар белән шәхсән танышу һәм кулдан кулга татар язуы проблемаларына кагылышлы документларны тапшыру бәхетенә ирешкән иде.

Үзенең бик тә гыйбрәтле бер мәкаләсендә Георгий Сатаров болай дип язган иде: "Зыялылар халык алдында бик зур бурычлы" дигән совет чорындагы шигарь бүген үтә дә хәвефле диагнозга әверелде. Әйе, бурычны кире кайтару зарур. Яки, тәүфикълы кешеләр кебек, атышырга кирәк".

Юк, минем ышануымча, атышу бер дә муафикъ шөгыль түгел. Барысына да үч итеп, безнең татар зыялылары Мәскәүнең унитаристлык һәм бөек державачылык агымына каршы йөзүләрен дәвам итәләр, чын федерализмны, демократияне, тигез хокуклылыкны, шул исәптән мәдәният өлкәсендә дә, бу очракта халык мәдәнияте диварына нигез ташы булып яткан тел мәсьәләсендә дә хокукый тәңгәллекне яклап көрәш алып баралар. Тел мәсьәләсе тирәсендә алып барылган ясалма ыгы-зыгыдан гына чыгып түгел, әлбәттә, чөнки халыкара демократик хәрәкәт тәҗрибәсе күрсәткәнчә, теләсә нинди халыкның суверенлыгы аның теленең суверенлыгы белән турыдан-туры бәйләнгән. Моның шулай икәнлеге бары тик 1905 елда гына суверенлык алган һәм нибары 99 ел эчендә алып барылган ирекле үсеш сәясәте нәтиҗәсендә яшәү дәрәҗәсе буенча дөньяда беренче урынга чыккан Норвегия Корольлеге тарихында да ачык чагыла. Шуның белән беррәттән, ул Даниягә бәйле тел коллыгыннан да азатлыкка ирешә.

Һич юк, безнең зыялыларыбыз иң җаваплы вә хәлиткеч вакытларда, шагыйрь

әйтмешли, йоклап ятмады. Моны раслау өчен Татарстанның Югары Советы сессияләрендә һәм вакытлы матбугатта Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев, Марат Галиев, Рафаэль Хәкимов кебек милләтпәрвәрләребезнең федераль үзәк кысуына каршы юнәлдерелгән чыгышларын искә алып үтү дә житәр кебек... Бу нәүбәттән Татар ПЕН-үзәге дә шушы юнәлештә максатчан һәм методик яктан ныклы хәзерләнгән эш-гамәлләр башкара һәм алар турыдан-туры халыкара тел проблемалары белән шөгыльләнүче зыялы катлам вәкилләре, инде хәзер аңлашылганча, бөтен алдынгы карашлы кешелек дөньясы тарафыннан яклау таба.

Әлбәттә, башкала кабинетларында утыручылар моның белән санлашырга теләмиләр; чөнки ул, әлеге факт, кире каккысыз һәм инде болай да гадәттән тыш үзәкләшкән Кремль хакимиятен ныгыту өчен уйлап табылган ялганчы уйдырмаларга тамырдан каршы килә. Уй-ниятләрне гамәлгә ашырудагы катгыйлык, аз гына булса да каршы килә торган фикерләүләргә түзеп торалмаучанлык һәм, мәгълүм ки, аларны күрмәскә омтылу әнә шуннан килеп чыга да инде.

Аңлыймын, бу язма Россия матбугатында диңгездән бер тамчы гына. Ләкин дәшми калу мөмкин түгел. Гомумән, алай ярамый. Хәтта бу тарихи вакыт аралыгында оттырган, дөресрәге—чигенгән (тарихи күзлектән караганда вакытлыча гына чигенгән) хәлдә дә үз сүзеңне әйтеп калырга, чынлыктагы хәл-әхвәлләр өстенә капланган томан пәрдәсен куып таратырга тырышырга кирәк. Һәм шул ук вакытта онытмау зарур: һәрбер киң масштаблы эш-гамәл башында хакыйкый Сүз тора!

Без, билгеле, ике төрле "хак юлдан" берсен—хакыйкать юлынмы, әллә сәяси яктан акланган юлнымы—сайлау алдында торып калган Россия Федерациясе Конституция судының карарын билгеле бер дулкынлану белән көтеп алдык. Бүген исә, аның сайлаган юлы һәркемгә мәгълүм һәм ул, кызганычка каршы, җәмгыятьнең демократик үсеше файдасына түгел.

## Менә шундый ПЕН-татоника

Тромсё шәһәрендә үткәрелгән Язучыларның 70 нче бөтендөнья конгрессы үзенең беренче эш көнен университетның иркен вә гүзәл бинасында башлап җибәрде. Университет бик уңайлы итеп төзелгән: аның барлык факультетлары, лабораторияләре, корпуслары күчеш коридорлары белән үзара тоташтырылганлыктан, тышка чыгып йөрмичә генә бөтен югары уку йорты биләмәсен урап чыгарга мөмкин. Кабатлап әйтергә мәҗбүрмен: урамнан караганда алай ук отышлы тәэсир калдырмаса да университет бик иркен һәм эшләү өчен уңайлы. Хикмәт шунда ки, Тромсёдагы бик күп биналар еш кына айсбергны хәтерләтәләр—ник дисәң, аларның шактый өлеше җир астына урнашкан. Шулай бер вакыт без бер катлы супермаркетка кереп чыгарга булдык, ә анда—лифтлар тезелеп киткән. Без уйлыйбыз, нәрсә бу? Кешеләрне алар кайда илтеп җиткерә? Баксаң, магазиныбыз өскә түгел, аска табан үсә икән һәм без, лифт кабинасында тагын дүрт этаж аска төшеп, кондиционерлардан чыккан саф һавалы якты заллар буйлап истирәхәт кылып йөрдек—әйтерсең лә оҗмах инде менә...

Университетның актлар залында без урынны—хәзер инде ышанып әйтергә мөмкин, чын дустыбыз белән, язучыларның халыкара бердәмлеге оешмасында Татар ПЕН-үзәген тиз арада таныткуга зур көч куйган фин әдибе һәм гомумән бик тә киң күңелле вә итагатьле ир-егет Юкка Маллинен белән янәшәдән алдык.

Трибунага күтәрелеп нотык тотучы телмәрләр—ораторлар—университет ректоры, шәһәр хакимияте башлыгы, Халыкара ПЕН-клуб президенты... һәм башкалар берсе артыннан берсе алышына торды, ә Юкка шул арада үзенең йомшак вә аз гына сузынкы сөйләме белән рус телендә безгә Казан университетына 200 генә ел булмыйча, аның күп гасырлык тарихка ия икәнлеген исбатлавын дәвам итә бирде. Ул үзенең дәлилләрен Казанда булган мәдрәсә тарихы белән җөпләде.

—Аңа,—дип дәвам итте сүзен Юкка,—миңа мәгълүм булганча, XII гасырда нигез салынган булган. Үзегез бик яхшы беләсез, Урта гасырларда мөселман мәдрәсәләре асылда теология—дин белгечлеге факультеты вазифаларын башкарып киләләр, бу нәүбәттән алар фәнни дәрәҗәсе ягыннан шулай ук асылда теология факультетлары

булып саналырга тиешле көнбатыш Европа христиан университетларыннан калышмыйлар. Казан мәдрәсәләренең аеруча чәчәк аткан чоры Аксак Тимернең хәрби яу йөрүләре белән бәйле тарихи катаклизмнар нәтиҗәсендә дөньякүләм танылу алган күп кенә галим-голәмәнең Көнчыгыштан Көнбатышка (ул вакыттагыча әйтсәк, Мәшрикътан Мәгърибкә)—Казанга килеп җирләшүе дәверләренә туры килә. Шул рәвешле, Казан университеты Россия биләмәләрендәге генә түгел, ә бәлки шактый киң мәгънәдәге беренче университетлар традициясен дә дәвам итә дип әйтә алабыз.

Соңрак Юкка Маллинен Татар ПЕН-үзәгенә Фин ПЕН-үзәге исеменнән Казан университетының 200 еллыгы белән котлап хат та юллады. Ләкин анда да ул Казан университетының "туган яшен" билгеләүдәге үз карашларын бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде.

Безнең белән шулай ук Рус ПЕН-үзәге генераль директоры, Халыкара ПЕН-клубның Башкарма комитеты әгъзасы Александр Ткаченко һәм "Экология һәм тормыш" журналының баш мөхәррире, хаксыз рәвештә шпионлыкта гаепләнеп, Россия төрмәсенә утыртылган диңгез флоты офицеры һәм гомумән бик шәп журналист Григорий Пасько даими аралашып яшәде.

Александр Ткаченко турында безнең матбугатта шактый күп язылды. Моннан ун ел элек, Мексикада, Рус ПЕН-үзәге исеменнән ул Татар-ПЕН-үзәгенә Язучыларның бөтендөнья ассоциациясенә керү өчен хәер-фатиха биргән иде. Инде килеп, моннан нәкъ ярты ел чамасы элек Александр, Рус ПЕН-үзәге президенты, Халыкара ПЕН-клубның вице-президенты Андрей Битов белән берлектә, Казанда уздырылган "Татар үткән юл: халыкның хокукы һәм сәяси корректлылык" дигән конференциядә катнашкан иде. Аннан да алдарак Александр Ткаченко Казанда Халыкара ПЕН-клубның Генераль секретаре Александр Блок белән бергә булып киткән иде.

Ткаченко безнең делегацияне Г. Паськога тәкъдим иткәч, мин Григорийга болай дидем (юкса, ул тырыша-тырыша үзе белән таныштыра башлаган иде): сине кем генә белмәсен соң, син бит хәзер бөтен дөньяга билгеле шәхес! Һәм, чынлап та, туган җире Ерак Көнчыгышның табигать проблемалары белән "кирәгеннән артык" бер үҗәтлек белән шөгыльләнгән 2 нче ранг капитаны, журналист-экологның хисапсыз тапкырлар кыен хәлләрдә калуын бөтен дөньяның зыялы катлам вәкилләре һәм гомумән намуслы кешеләр җентекләп күзәтеп бардылар һәм үзләренең карашларын белдерә килделәр. Мәхкәмә җәтмәсенә эләккән офицер һәм журналистның язмышы кыл өстендә торган көннәрдә Рус ПЕН-үзәгенең Генераль директоры Александр Ткаченко Владивостокта куна-төнә ятты. Бүген исә, Григорий Пасько иректә һәм, Сахаров белән Никитиннан соң, аңа Россиянең 3 нче номерлы тоткыны дигән "абруйлы" исем бирелде.

Конгресста, әлбәттә, Григорий Паськога сүз бирделәр һәм ул биредә катнашучыларга авыр вакытта ташламаганнары өчен үзенең эчкерсез рәхмәтләрен җиткерде. Шулай да дөнья җәмәгатьчелегенең фикере белән халыкара демократиянең үзәк юнәлешеннән тәмам читкә тайпылган хакимиятләргә дә санлашырга туры килә. Шушы сүзләрдән соң форум делегатлары безнең ватандашларыбызны аягүрә басып алкышладылар.

"Кече халыкларның телләре язмышы" дигән темадан тыш, "Язучылар төрмәдә" исеме астында үткәрелгән утырышлар да конгрессның үзәк мәсьәләләренең берсе булып тордылар. Үзләренең кухня тәрәзәсеннән ачылган дөньядан башканы күрмәгән тар карашлы бәндәләрнең: "Язучыларны әллә хәзер дә утырталармы?"—дип сораштырган очраклар да булгалады. Монда бөтенесе дә аңлашыла сыман. Ә менә профессиональ журналистларның: "Милли мәдәниятне, телне, фикер сөрешен "кысучы", үзләренең кыек күзге патшалыгында хак сүз әйтергә җөрьәт иткән намуслы кешеләрне турыдан-туры эзәрлекләүче һәртөрле хакимиятләрнең һәм мәхкәмә органнарының карарларына сез ничек йогынты ясый аласыз? Резолюцияләр сорап, хатлар языпмы?—дип, аптырашка төшүләре аңлашылып җитми. Ул гына да түгел, андый каләмдәшләребезнең үзләренең төп коралы булган Галиҗәнап Сүзнең кодрәтенә ышанып җитмәүләре гаҗәпләндерә.

Ә шул ук вакытта язучыларны бүген дә бөтен дөнья буйлап кичәгедән бер дә ким төрмәләргә тыгып куймыйлар. Шушы мәсьәлә буенча беренче көндә үк төрле

илләрдәге хәл-әхвәлләрне яктыртып, зур экранда "таш капчыкка" ябып куелган әдипләрнең портрет-сурәтләрен күрсәтә-күрсәтә "җинаять" эшләре белән таныштырып берничә докладчы чыгыш ясады. Әйе, язучы әйткән сүз шулай бәһаләнә—аның өчен Нобель премиясе дә бирергә мөмкиннәр һәм "тимер рәшәткәгә" дә эләгүең ихтимал!..

"Язучылар төрмәдә" дигән темада катнашучыларның тулы булмаган исемлеге түбәндәгедән гыйбарәт иде: Ананта Тоер (Индонезия), Разак Махмун, Ассәдулла Валведжи (барысы да Әфганстаннан)...

Тоткынлыкта газап чигүче язучылардан тыш, бер төркем әдипләр мөһаҗирлектә көн күрергә мәҗбүрләр. Мәгълүм ки, соңгы елларда чит җирләрдә—Германиядә яшәргә мәҗбүр булган күренекле беларусь язучысы Василь Быков якты дөньядан китеп барды. Хәтерлим әле, 1998 елда Финляндиядә без аның белән ничек дустанә аралашып алган идек! Ә бу конгресс көннәрендә икенче бер беларусь әдибе, ягъни Владимир Некляев, безнең төркемдә сыену тапты. Лукашенконың сәяси системасы аңа туган илендә яшәргә һәм иҗат итәргә мөмкинлек бирми икән. Аны Финляндия үз "кочагына" алган. Гомумән, Скандинавия илләре, шул исәптән Норвегия дә, дөньяга карашлары үзгә булу сәбәпле, мөһаҗирлектә гомер итәргә мәхкүм ителгән язучыларга аеруча кунакчыл. Халыкара ПЕН-клуб нәкъ менә шундый әдипләргә яшәү өчен мөмкинлекләр табарга ярдәм итә; ни дисәң дә, алар бит иректә илдә булса да чит мохитта гомер кичерәләр.

Ярар, күңелсез хәлләр турында җитеп торыр.

Тромсёдагы иң күп санлы делегация, аңлашылса кирәк, Норвегиядән иде. Моңа охшаш конгрессларда гадәттә гел шулай була. Норвегия ПЕН-үзәгенең эшчәнлеге белән кызыксына башлагач, иң беренче чиратта мин менә нәрсәгә игътибар иттем: баксаң, аны Норвегиянең Чит ил эшләре министрлыгы финанслый икән. Һәм моны "сер" итеп сакламыйлар, бу хакта форумның барлык документларында да ачыктан-ачык бәян ителә. Менә бит дөньяның иң алдынгы илләреннән берсендә үзенең ПЕН-үзәгенә нинди сәяси һәм мәдәни статус бирәләр?!

Конгресс барган көннәрдә безнең янга еш кына, кем әйтмешли, казакъ әдәбиятының тере классигы, китаплары дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән, танылган прозаик, Казакъ ПЕН-үзәге президенты Абдиҗамал Нурпеисов килгәләп китте. Базык гәүдәле, өлкән яшьтәге бу әдип һәр сүзен үлчәп сөйләшә, әңгәмә барышында озын-озын тукталыш ясап ала,—кыскасы, һәр хәрәкәтеннән, һәр кыланмышыннан вә кыяфәтеннән синең алда могтәбәр зат басып торганлыгы шәйләнә. Без, әлбәттә, аның белән тугандаш әдәбиятлар алдында торган бурычлар, илдә һәм дөньяда барган сәяси хәл-әхвәлләр хакында моназара кылып утырдык. Абдиҗамал ага конгресска дөньякүләм террорчылык мәсьәләләренә кагылышлы, аның мөселманлык белән бернинди дә уртаклыгы булмавын искәртүче махсус хәзерләп алып килгән Белдерүен игълан итте. Конгрессның соңгы эш көнендә аксакал әдип казакъ халкының чиксез фаҗигасенә әверелгән Арал диңгезенең юкка чыгуы турында бәян итүче "Соңгы әҗәт" дигән роман-дилогиясен миңа бүләк итте. Моны ул жанр ягыннан туганлык билгесеннән чыгып эшләгәндер дип беләм; чөнки Гәрәй Рәхим белән Газинур Морат—шагыйрьләр, ә Борис Пантелеев юрист иң. Китапның форзацына: "Бу китап—минем вакыт белән алыш-бирешемне үтәү нәтиҗәсе. Мин тулысы белән анда" дигән истәлек язуы язылган иде.

Конгресска без дә буш кул белән килмәдек. Болар—инглиз телендә басылып чыккан Габдулла Тукайның "Шүрәле" һәм Равил Фәхретдиновның "Татарлар тарихы" дигән китаплар иде. Без аны төрлечә ысуллар белән тараттык: форумда катнашучы илләр китаплары белән бергә күргәзмәгә дә куйдык; лингвистика комитетында катнашучыларга да тәкъдим иттек; шәхси кешеләргә дә бүләк итеп бирдек. Безнең китапларның эчтәлеге, гомумән татар халкының тарихы, республиканың бүгенге хәле турында Тадеуш Шабровский (Польша), Сибила ханым Петлевски (Хорватия; ул безнең латин графикасына күчү проектын комитет утырышларында ялкынланып һәм кире каккысыз дәлилләр китереп яклап чыкты), Эдвард Ковач белән кылган моназаралар аеруча истәлекле булды. Эдвард әфәндене исә, татар халык музыкасының борынгылыгына һәм үзенчәлегенә кагылышлы

фикерләре бик тә кызыклы һәм гыйбрәтле иде. Ул бездән китапларны кабул итеп алганда, "спасибо" сүзе татарча ничек була дип сорады да, белеп алгач, чын күңелдән "Рәхмәт!" яудырырга кереште.

Халыкара ПЕН-клуб президенты Иржи Груша бездә аеруча җылы тәэсир калдырды. Нәзәкатьле, яшь Наполеон Бонопартны хәтерләтүче чибәр, матур йөз кыяфәтле бу кеше үзенең асылы белән әлеге тарихи шәхескә бөтенләй охшамаган иде. Аңа, әйтерсең лә, абруйлы иҗтимагый оешма кәнәфиендә утыру да билгеле бер кыенлык тудыра иде кебек. Президент еш кына конгрессның президиумын ташлап чыгып китеп, "гади" делегатлар белән аралашып йөрде. Ул безне латин графикасына күчү мәсьәләсендә чын күңеленнән яклап чыгарга алынды, хәтта делегатлар Ассамблеясында тикшерелгәнчегә кадәр, Россия Федерациясенең Конституция судына лингвистика комитеты хәзерләгән хатка кул куярга ризалыгын да белдерде. Үзенең фикерләвендә һәм эш-гамәлләрендә хөрлеккә омтылучы, үз вакытында фикердәше Вацлав Гавел белән төрмәдә дә утырып чыккан бу милләтпәрвәргәме соң, теләсә нинди чагылышта булсын, һәртөрле чикләүләрнең нәрсә икәнен белмәскә! Кызганыч, аның белән шәхсән күрешеп сөйләшкәндә һәр халыкның туган телендәге бәйсезлеккә хокукы барлыгы турындагы алдан махсус хәзерләнгән нотыгымны мин аңа үзем теләгәнчә бәян итәргә өлгермәдем. Ул безнең белән саф рус телендә сөйләште һәм, хөрмәт-аңлашу билгесе итеп, дусларча кочаклап алды. Саубуллашу мәҗлесе барган вакытта ул без утырган өстәл янына килде дә, татарларның кәефе белән кызыксынды һәм эчкерсез вә дустанә елмаеп, безнең лингвинистика өлкәсендәге хафаларыбыз хакында болай диде: "Шунысы ачык, оппонентларыбызның акылга килүенә ышанып хәрәкәтсез ятарга ярамый. Ләкин шунысы бик тә мөһим: бу хәрәкәт туктаусыз алып барылырга тиеш. Кем әйтмешли, аккан су ташны тишәр". Әңгәмә соңында без бергәләп фотога да төштек.

Безнең өчен конгресс менә шундый пентатоника аһәңе белән ягъни үзенә күрә һәрбер зур эш-гамәлне төгәлләп куйгандагы һәм рәсми протоколда каралмаганча күтәренке рух белән төгәлләнде. Бу минутларда безнең күңелләр чынлап та "җырлап" тора иде.

...Инде килеп, "без дә без" димен, шулай булгач үзебезнең команда турында да берничә сүз әйтеп китим булмаса. Гәрәй Рәхим белән Газинур Морат турында әйтеп тә торасы юк, татар җәмәгатьчелеге өчен алар билгеле һәм танылган шагыйрьләр; Борис Пантелеев исә, күбрәк хокук саклаучылар даирәсенә таныш. Ул Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган, Казан шәһәренең Мәскәү районында халык судьясы булып эшләгән, республика прокурорынын—мәрхүм С. Нәфиевнең ярдәмчесе булып торган. Хәзер Б. Пантелеев Мәскәүдә яши, әле күптән түгел генә дәүләти һәм иҗтимагый оешмаларның үзара бәйләнешенә багышланган кандидатлык диссертациясе яклады. Борис керәшен татары Николай дәдәй гаиләсендә, Азнакай районының Әгерже авылында туып үсә. Әйтергә кирәк, аның язучыларга бөтенләй хас булмаган гамәли фикерләү рәвеше һәм француз телен яхшы белүе конгресс вакытындагы безнең эшчәнлеккә бик тә уңай йогынты ясады.

Безнең делегацияне мин "команда" дип юкка гына атамадым. Кеше буларак, сүз дә юк, без төрлебез төрле холыклылар, ләкин Норвегиядә без бер-беребезне тулыландырып, бер йодрык булып эш йөрттек, дип әйтә алам. Шулай булмыйни, безнең бит уй-максатлар уртак, идеаллар югары иде ләбаса!..

## Норвегия кронасының тишегеннән караганда

Хәзер Норвегия Корольлегенең үзе хакында сөйләп узыйк.

Иң элек шунысын искәртеп узу зарур: Халыкара язучылар форумының соңгы ун елда үткәрелгәннәреннән монысы оештырылуы ягыннан, мөгаен, иң яхшысы булгандыр. Норвегия биредә дә үзенең дөньяда иң тәртипле илләрнең берсе икәнлеген раслады. Юбилей Конгрессын тантаналы рәвештә Король Галиҗәнапләре крон-принц Хаакон ачып җибәрде.

Бу көнне, ягъни 7 сентябрьдә, Заполярьеда урнашкан төньяк Норвегиянең фьордлары, диңгез култыклары белән телгәләнеп беткән ярлары кар белән капланды.

Конгрессны үзенә кабул иткән Тромсё шәһәре бер утраучыкка урнашкан һәм бу "Төньяк Париж"ны материктагы Норвегия белән күп чакрымнарга сузылган өч күпер тоташтыра; ә Төньяк Париж дип аны туристлар кунакханәләр, рестораннар, һәртөрле барлар күп булганга атаганнар—баксаң, 60 меңлек шәһәр бәрьюлы 25 мен кешене кабул итә ала икән. Аннары бу чагыштыруның асылында шәһәрнең гүзәллеге дә ята булса кирәк. Әмма бу үзенчә, төньякча гүзәллек! Төрле төстәге уенчык сыман җыйнак йортларны, яр буена ялга туктаган океан лайнерларын, яхталарны, эреле-ваклы балыкчы көймәләрен күз алдына китерсәгез—бу порт шәһәре Тромсё булыр... Ә тирә-юньдә—"ак башлы" тау тезмәләре; тигез-тын вә чиксезлеккә барып тоташкан су өсте; давыл хәбәрчеләренең ачынулы тавышлары гына шушы әкияти күренешне сискәндереп җибәргәндәй була.

Безнең бирегә килеп житүебез ел фасылының гадәти агышлы вакытына—көнне төн алыштырып килгән мәлгә туры килде. Югыйсә, җәйләрен бу көннәрдә кояш төнлә белән дә офык артына төшеп югалмый (йә, әйтеп карагыз, төнге кояшны кайда очратырга мөмкин!). Аның каруы, кышын дөм-караңгы поляр төннәр башлана. Бәлки шунадыр да Норвегия рәссамнарының картиналарында төньяк балкышының күптән-күп кабатланмас бизәкләре чагылыш табадыр, ә кыссалларда, иртәнге аш вакытында да, шәм яна.

Норвегиядә тагын—эчәр су культы хөкем сөрә. Ул өстәлгә боз кисәкчекләре белән бирелә. Хәтта кунакханәләрнең һәр катына да сезгә боз белән сыйларга әзер торучы автоматлар куелган. Ул гына да түгел, Норвегия "боз" дигән товарны экспортка да чыгара икән. Экспортның төп өлешен исә, нефть, нефть продуктлары, табигый газ, тимер рудасы, титан, диңгез кораблары, балык, кәгазь һәм агач тәшкил итә.

Узган гасырның 60 елларында Төньяк океанда нефть ятмалары табыла һәм Норвегия тиз арада нефть державаларының берсенә әверелә. Нефть һәм нефть продуктлары бүгенге көндә илнең иң зур табигый байлыгы булып исәпләнә. Бу нәүбәттән, Норвегиянең диңгез бораулау установкаларын төзү буенча специальләшүен һәм электроэнергияне эшләп чыгарудагы үзенчәлекләргә дә тукталып үтми булмастыр. Электр энергиясенең чыганагы булып биредә түбәләре кар белән капланган таулар итәгенә бәргәләнә-сугыла агып төшүче шаулы елгалар хезмәт итә. Карап торсаң, хәйран калырлык матурлыкка ия бу күренешләр! Ә без аларны балыкчылар поселогына автобуста экскурсиягә барганда да, диңгезгә кыска вакытлы сәяхәткә чыкканда да, һәм, әлбәттә, борынгы вакытлар кебек утыз гына кеше сыешлы житез көймәләрдә балыкка "йөргәндә" дә күзләребезне ала алмыйча күзәттек, бер-беребез белән алган тәэссоратларыбызны уртаклаштык.

Сәяхәт барышында кеше дигәнең ирексездән "яңа илен" үз ватаны белән чагыштырып йөрүчән була... Нишлисең, "ирексездән" без дә күзәтеп йөрдек. Дөрес, китлар, семга балыклары, диңгезләр, таулар, боланнар һәм ак аюлар Татарстаныбызда юк-югын, бу нәүбәттән тәжрибә туплыйсы түгел. Аның каруы, башка өлкәләрдә гыйбрәт алырлык нәрсәләр житәрлек иде биредә.

Норвегия озак вакытлар Дания һәм Швеция кул астында була. Һәм бәйсез дәүләт булып тулы булмаган йөз ел яшәү дә верендә Норвегиялеләр тормыш дәрәҗәсе буенча дөньяда беренче урынга чыктылар. Бу—бәхәссез һәм кире каккысыз факт!

Сүз дә юк, идеологик яктан да һәм, вакыт күрсәткәнчә, яшәүнең гамәли асылын раслау буенча да Норвегия тарихында әдәби тел өчен көрәш әһәмиятле урын алып тора. Дания кул астында чагында Норвегия әдәбияты даниялеләр теленнән файдаланырга мәҗбүр була; Норвегия теле исә, сөйләшү һәм аралашу теле буларак кына файдаланыла. Мондый күренеш, аңлашыла ки, норвегиялеләрнең сәламәт рухлы милли хисләрен рәнжетеп килде һәм Норвегиянең алдынгы карашлы язучылары үзләренең әдәби телен булдыру өчен өзлексез көрәш алып бардылар. Бу юнәлештә Генрик Ибсен аеруча күп эш эшләде.

Шул рәвешле, XIX гасырның икенче яртысына Норвегия һәм Дания телләре үрнәкләрен берләштергән **риксмол** дип аталган әдәби тел барлыкка килә. Икенче бер төркем язучылар һәм лингвистлар саф Норвегия теленә нигезләнгән **лансмол** өчен көрәш алып баралар. Нәтиҗәдә, бәйсез Норвегиянең рәсми теле булып лансмол

таныла. Шул ук вакытта риксмол да бүгенге көнгә хәтле әдәби әһәмиятен югалтмаган.

Сөйләп тә торасы юк, үз вакытында бездә социалистик һәм коммунистик җәмгыять төзү турында күп фәлсәфә саттылар. Ләкин без аны үзебезнең илдә түгел, нәкъ менә Норвегия Корольлеге мисалында күрдек һәм гамәлдә ышандык, гәрчә ул идарә итү формасы ягыннан конституцион монархия булып исәпләнсә дә.

Норвегиядә Лондонның "Челси" клубын сатып ала алырлык мультимиллионерлар юк-югын, ләкин шул ук вакытта анда бомжларны гына түгел, фәкыйрьлекнең "теге ягына" чыккан кешеләрне дә күрә алмассың. Биредә бөтен кешеләр дә бер чамадарак байлыкта гомер кичерәләр: норвегиялеләрнең һәрберсе диярлек ике автомашина куярлык гаражы булган, күрер күзгә үк матур-назикъ коттеджларда яши; йорт алдында—пөхтә итеп кыркылган ямь-яшел аланчыклар; кечкенә фонтанчыклар, клумба-түтәлләр һәм зур булмаган сын-статуялар. Авыл җирендә шәхси биләмәләр шактый зур мәйданны били, алар күп очракта көтүлек җире буларак та файдаланыла. Без бу илдә "күп этажлы" Россиягә хас булганча, байлыгы белән күзгә бәрелеп торган көяз "хансарайлары" күрмәдек. Биредә фатирда түгел, йортта яшиләр. Норвегия архитектурасын мин, барлык чиркәүләре, университетлары, вокзаллары, рәсем галереялары белән бергә, функциональ-аскетик өслүбтәге архитектура дип атар идем. Йорт-биналарда бернинди дә артык бизәкләр, колонналар, әвәләп эшләнгән сурәтләр, алтын-мазар белән йөгертелгән түбә-кыеклар бөтенләй юк диярлек. Металл, бетоннан корылганмы ул яки агачтан эшләнгән—аэропорт, собор, ресторан залларының һәртөрле төзелеш конструкцияләре эчкә яшерелмәгән; Норвегия барларының һәм пабларының түшәмнәре, стеналары буйлап сузылган өрлек-балкалар, борыслар—болар инде үзенә күрә бер культ-йолага әверелгәннәр. Кыскасы, норвегиялеләрнең тормышындагы һәрбер төзелеш бинасы һәм көнкүреш кирәк-ярагы функциональ мәгънәгә ия.

Норвегиялеләр сәяхәт итәргә яраталар, үзләренең шәхси катерларында һәм яхталарында гына да түгел. Моңа гына аларның акчасы җитәрлек. Ләкин, турысын әйтергә кирәк, бу илдә яшәү кыйммәткә төшә. Әйтик, безнең акча белән исәпләсәң, бер шешә аракы 1200 сум чамасы, сыра—450 сум тора. Әйе, Норвегия кыйммәтчелек иле. Безнең күзлектән караганда, әлбәттә. Норвегиялеләр өчен исә, бу гадәти күренеш. Һәркемнең дәүләти-газ һәм нефтендә үз өлеше бар. Менә шулай, җәмәгать! Аннары хезмәт күрсәткән өчен Норвегиядә чәйлек бирү гадәте юк; тәкъдим итә калсаң, хезмәт күрсәтүченне нык кына рәнҗетеп куюың да бар. Һәм, киресенчә, кибеттән берәр әйбер сатып алсаң да, сине шоколад белән сыйлыйлар.

Норвегиялеләр рус кызларына, күп очракта Мурманск һәм Петербург бичәләренә өйләнергә тырышалар. Мәсәлән, кунакханә ресторанында безнең өстәлгә Санкт-Петербургтан килгән Наташа исемле кыз-ханым хезмәт күрсәтте. Ул акцент белән сөйләшә иде, чөнки норвегияле егеткә кияүгә чыкканына да җиде ел вакыт узган икән. Конгресска хезмәт күрсәтүчеләр арасында Тромсё шәһәренә Россиядән вузара алмашу тармагы буенча килгән волонтерлар шактый күп иде.

Норвегия—глобализмга каршы уңышлы көрәш алып баручы алдынгы илләрнең берсе. Анда бөтен дөньяга таралган "Макдональдс"ларны, "Рамстор"ларны, "Икеа"ларны һәм "Метро"ларны күрә алмассың... Корольлек Евросоюзга да кермәгән, гәрчә "вето" хокукы тавышка ия булса да. Викингларның оныклары, "евро" акчасы әйләнештә йөрсә дә, Норвегия кронасыннан да баш тартырга җыенмыйлар. Крона дигәннән, мин уртасы тишек булган башка ил акчасын хәтерләмим. Хәер, моны борынгы монголлар уйлап чыгарган дигән риваятьләр дә йөри. Ә норвегиялеләрнең ышануынча, акчадагы шушы тишектән кояшка карасаң, бәхетле буласың, имеш.

Ни хәл итәсең, Тромсёда Конгресс эшләгән җиде көн дәвамында кояш бөтенләй күренмәде, янгыр койды да койды.

Норвегиядә төп дин булып лютераннар христианлыгы хисаплана. Шәһәрнең лютеран соборларында түләүле зур музыкаль концертлар уздыру күптән гадәткә кергән. Без дә ике соборда—агачтан эшләнгән борынгысында һәм, кем әйтмешли, пыяла белән тимер-бетоннан торгызылган яңасында булдык. Беренчесендә классик, инструменталь-хор музыкасы башкарылды; икенчесендә исә, халык уен кораллары

һәм колак тондыргыч электрогитарада фольклор әсәрләре яңгырады.

Норвегиядә мин нәрсәне күрмәдем дә, ниләрне ишетмәдем—хәзер сүз шул хакында булыр. Мин "оригиналда" үзем яраткан "А-ха" рок-группасын тыңлау бәхетенә ирешә алмадым—гап-гади генә итеп әйткәндә, алар чит илдә чыгыш ясый иде; һәм Эдвард Мунканың күптән кызыксындырып килгән "Кычкыру" исемле картинасын күрә алмадым—чөнки без Ослога килеп төшәргә берничә генә көн кала аны... урлаганнар иде.

Норвегиядә без шулай ук бер генә полисменны да очрата алмадык. Махсус карангалап йөрдек—ләкин алар юк иде. Һич югы аларның нindирәк формада киенгәннәрен булса да күрәсе килгән иде... Кунакханәләрдә швейцарларның, рестораннарда "вышибалаларның" заты да күренми. Шулай бер вакыт миңа кунакханәдәге номерымның ишек төбендә ачкычсыз басып торырга туры килде. Ә мин иптәшләрем Гәрәй Рәхим һәм Газинур Морат белән бергә идем. Турысын әйтим, дуслар ич—үпкәләмәсләр, аларның чырайлары бер дә шагыйрьләрнекенә охшамаган бит, ягъни алар назикъ йөз кыяфәтенә ия түгелләр. Һәм менә без, өчәүләшеп, бүлмәнең ишеген ачып бирүләрен үтенәбез. Ә кунакханә хадиме җавабында бер елмаеп алды да бернинди документ, бернинди кунакханә визиткасын сорап тормастан (жетон дигәнең анда бөтенләй дә юк икән), безнең белән өченче катка күтәрелде дә, ишекне ачып, безне эчкә уздырып җибәргәч, берни булмагандай китеп тә барды. Бездә булсамы?!.

Күз күреме җирдә бер генә автомобиль күренмәсә дә, әйтик, төнге сәгать өч булса да норвегиялеләр светофорның яшел уты янганын көтеп торалар. Шулай ук автомобильчеләр дә, син урамны тиешсез урыннан чыгып барасың икән, туктап торалар. Ләкин бу җәяүле инде, күренеп тора, мөгаен, норвегияле түгелдер.

Туктаусыз яңгырлар яуды дигәннән... Норвегиянең диңгез буе чиге Скандинавия ярымутравының төньяк-көнбатыш яры буйлап шактый озынга сузылган. Шунадырмы, Заполярьедагы Тромсё шәһәрендә яңгырлар койганда, көньяктагы Осло шәһәрендә һавалар җылы һәм аяз торды. Аэропортта мин Норвегия кронасын кулыма алдым да, аның уртадагы тишегеннән озак кына күктәге кояшка карап тордым һәм Мәскәүгә очып төшкәнчегә кадәр күкрәгем бәхет белән тулык булды.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклаган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

*Татарстан язучыларының XV корылтаен каршылап*

**Фоат Галимуллин**

# ИЛҺАМЛЫ ХЕЗМӘТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Без Татарстан Язучылар берлеге тормышындагы бик тә әһәмиятле тагын бер этапка килеп җиттек. Яңадан чираттагы корылтаебызга җыелабыз. Инде унбишенче тапкыр. Иҗади берлекнең җитмеш бер ел яшәүе дәверендә каләмдәшләр дистә ярым тапкыр бергә җыелып, үткәндәгеләргә йомгак ясап, якындагы һәм ераграк киләчәктәге офыкларны билгеләделәр. Һәр корылтай үз чорына караган иң мөһим мәсьәләләрне уртага салып сөйләшкән, әйтергә кирәк, һәрвакыт хәл-әхвәлгә муафыйк карарлар кабул иткән. Бу юлы да каләмдәшләребез шундый ук зирәклек күрсәтерләр, акыллы нәтиҗәләргә килерләр.

Беренче карашка, корылтайда үз эшчәнлекләре өчен берлек рәисе һәм идарә хисап бирә кебек. Монда дөреслек тә бар. Чөнки нәкъ менә алар бөтен әдәби хәрәкәтнең башында торалар, тегe яки бу мәсьәләләр хакында карарлар кабул итәләр, аларны үтәүне оештыралар. Шуңа күрә төп хисапны да алар тотарга тиеш. Әмма, мәсьәләгә тирәнрәк караганда, корылтай—һәр язучының берлек алдында җавап тоту урыны да ул. Мин әдәбиятны үстерү өчен нәрсә эшләдем һәм ниләрне эшләп бетерә алмадым? Мондый сорау берлекнең һәр әгъзасы алдында торырга тиеш. Ник дигәндә, тулаем иҗат оешмабызның тиешле югарылыкта булуы һәр каләм әһеленең күңелен ниләр борчуы, аны халык күңеленә үтеп керерлек әсәрләр ярдәмендә әйтеп бирә белүе белән билгеләнә.

Без бүген сүз алып бара торган 2002—2005 еллар гадәти генә вакыт аралыгы булмады. Ил, халык тормышындагы катлаулылыгы ягыннан аларны узган гасырның дөньяны селкеткән, илебез халкын зур сынаулар алдына куйган вакыйгалары белән тиңләргә мөмкин. Чөнки, телисеңме-теләмисеңме, икърар итәргә кирәк, нәкъ менә шушы соңгы өч ел эчендә бер системаны инкарь итеп, икенчесен барлыкка китерү юлында бихисап газаплар кичердек, бу юлда бик күп демократик казанышларыбызны югалттык. Ахыр чиктә болар һәммәсе күпчелек халыкның матди хәлен кыенлаштырды, бу исә аларның яшәү рәвешенә тискәре йогынты ясады. Монысы инде язучылар өчен иң мөһиме булган күңел дөньясының, уйлау һәм хис итү рәвешенең үзгәрүенә сәбәп булды, әйтергә кирәк, әлеге борылыш күпчелек очракта теләмәгән якка булды. Шул ук вакытта язучы өчен иң кадерле иҗат ирегe саклану бу елларның мөһим казанышы булып тора. Моны безнең һәрбер каләмдәшебез яхшы тоя, иҗатының нинди дә булса кысалар белән чикләнмәве, каләменең иркен хәрәкәт итүе ана канәгатьлек бирә. Без моның мисалларын күпләп китерә алыр идек. Иҗаттагы уңышларыбыз һәм җитешсезлекләребез хакында корылтайда махсус докладлар булачак, алардан һәр каләм иясе үз язганнарына карата бәя алачак һәм фикер табачак. Алар белән танышкач, һәр кешедә безнең бүгенге тулаем әдәбиятыбыз һәм аның аерым фидакарь иҗат лидерлары хакында тулы мәгълүмат булачак.

Язучылар берлегенең төп вазифаларыннан берсе—барлык каләм тибрәтүчеләр өчен оешмада иҗади мохит тудыру. Идарә һәм аның рәисе моны үз эшчәнлекләренең үзәге буларак карадылар, һәр утырышта, идарәнең киңәйтелгән утырышларында бу өлкәгә караган актуаль мәсьәләләр үзәккә куела торды. Берлекнең структурасы менә шушы төп бурычны тормышка ашыруга мөмкинлек тудырырлык итеп оештырылган. Биредә шушы эш белән җитәкчелек итүгә зур мөмкинлекләр булдырылган һәм әхлакый-этик яктан шуңа тулы хокуклары булган шәхесләр тупланган. Берлек рәисенең әдәбият фәне буенча фән докторы дәрәҗәсендәге белгеч булуы мәсьәләләрне белеп һәм компетентлы итеп тотып алу, кую һәм хәл итү мөмкинлеген бирә. Рәис

урынбасарлары Г. Гыйльманов һәм Ш. Мостафин шулай ук киң карашлы, күпкырлы иҗади шәхесләр. Алар бу елларда берлеккә житәкчелек итү буенча зур мәктәп үттеләр, кешеләр белән эшләүнең гаять четерекле якларын үзләштерделәр, үзләре дә иҗатчы булараk нык үстеләр, укучылар арасында киң танылдылар.

Иҗат остаханәләренең эшенә даими игътибар—берлектәге төп иҗади "гамьнең" нәкъ менә шуларда тупланулы белән аңлатыла. Аларның кимендә айга бер мәртәбә уздырылучы утырышларында идарә җитәкчеләренең катнашып килүе әлеге мөһимлекне аңлаудан килеп чыга. Шигърият, проза, рус телле язучылар, балалар әдәбияты, әдәби тәнкыйть, тәржемә остаханәләренә З. Мансуров, М. Маликова, Л. Газизова, Ж. Дәрзаман, Р. Корбан, М. Вәлиев, К. Миннебаев кебек үз өлкәләрендә чын мәгънәсендә иҗади абруйлы, эшлекле, оста оештыручы шәхесләр уңышлы җитәкчелек иттеләр. Әлеге остаханәләрнең утырышларында тормыш алга китереп куйган актуаль мәсьәләләрне уртага салып тикшерү эзлекле рәвештә алып барылды. Шул ук вакытта аерым каләмдәшләребезнең иҗатларын үзәккә алып бәяләүгә багышланган утырышларның әһәмиятен тагын бер тапкыр ассызыклыйсы килә. Теге яки бу әдәби бүләкләргә кандидатураларның нәкъ менә шушы остаханәләрдә каралуы һәм тәкъдим ителүе берлек эшендә чын мәгънәсендәге демократизмның ныклап урнашуына китерде. Дөрес, кайбер очракларда, сирәк кенә булса да, бу мәсьәләдә сәламәт булмаган нигездә оешып алган кайбер төркемнәрнең дә уңышка ирешүләренә күз йомарга ярамый. Алар аз булды, ләкин әдәби мохиткә сизелерлек зыян ясады. Киләчәктә мондый көчләргә мөнәсәбәттә бик сизгер эш итү зарурлыгы кала бирә.

Драматургия буенча остаханә турында аерым әйтергә кирәк. Соңгы елларда иҗатның бу тармагына булган ихтыяҗ үскәннән-үсә бара. Традицион рәвештә эшләп килүче күренекле театрларыбызга өстәмә булып Казан дәүләт татар яшьләр театры, Чаллы дәүләт татар театры, Түбән Кама татар театры барлыкка килде һәм уңышлы эшләп киләләр. Аларга актуаль һәм сәнгатьчә камил әсәрләр кирәк. Бу исә драматургия үсешен таләп итә. Әмма бу өлкәдә проблемалар да җитәрлек. Менә шуңа күрә идарә үзенең бер киңәйтелгән утырышын бүгенге драматургия мәсьәләләренә багышлады. Нәтиҗәдә барлык драматургларыбыз, театрларыбызның баш режиссерлары, директорлары, театр белгечләре һәм тәнкыйтьчеләре катнашында эшлекле сөйләшү булды. Әлеге утырыш җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте, вакытлы матбугат та аңа битараф калмады. Драматурглар активы белән хөкүмәттә дә фикер алышу уздырылды. Идарә драматургия буенча махсус остаханә оештырырга дигән карар кабул итте. Аның җитәкчесе итеп бу өлкәдә шактый нәтиҗәле эшләүче М. Гыйләҗев билгеләнде. Шунысы куанычлы, бу остаханә үзенең беренче адымнарын уңышлы башлап җибәрде, аның эшендә алга таба да инициативалылык, нәтиҗәлелек булыр дип өмет итәбез.

Болары инде язучы булулары рәсми төстә расланган, талантлары шиксез танылган шәхесләр белән эшләү структуралары булды. Шулар өстенә яшь талантларны барлау, үстерү юнәлешендәге эшчәнлеккә ике корылтай арасында зур әһәмият бирелде. Татарстанның югары уку йортлары, район газеталары редакцияләре каршында эшләүче иҗат берләшмәләренә, әдәби түгәрәкләргә җитәкчеләр итеп күп кенә танылган каләм осталарыбыз билгеләнде. Аларның күпчелеге эшне әйбәт алып бара. Казан университеты каршында "Әллүки" иҗат берләшмәсенең Г. Гыйльманов җитәкчелегендә яңадан терпәкләнеп китүе аеруча зур казаныш булды. Әдәби консультантлар В. Корчагин һәм Ф. Әһлиуллиналар бу эшләрне оештыруга байтак көч салдылар. Н. Ахунова җитәкчелегендәге "Белая ворона" яшьләр иҗат берләшмәсенең эше Татарстан белән генә чикләнеп калмады, алар Россия Федерациясе күләмендәге бик җаваплы иҗади конкурсларда катнашалар һәм иң югары урыннарны яулыйлар. Мәсәлән, мәртәбәле "Триумф" бүләгенә лаек булучылар арасында берничә татарстанлы булуы канәгатьлек хисе тудыра.

Ел саен яз көне яшь язучылар семинарын уздыру матур традициягә әверелде. Л. Шәехов, Р. Исхаков, Л. Гыйбадуллина, Л. Мөстәкыймова, Р. Әгъләметдинов һәм башка өметле каләмнәр нәкъ менә шушы семинарлардан үсеп чыктылар. Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының "Идел" яшьләр үзәге белән берлектә "Иделем акчарлагы" конкурсы уздырылып килү, аның йомгаклау турында уздырылган иҗади

семинарлар шулай ук яшь талантлар белән эшләүнең бик мөһим формасы буларак ныгып урнашты. Алга таба да бу яхшы традицияләргә зыян китерелмәскә тиеш.

Язучылар берлеге каршындагы кабул итү Коллегиясе эше нигездә әйбәт кенә барды. Язучылар сафын сыйфатлы тулыландыру шушы коллегиягә бәйле (рәисе—Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин; коллегия әгъзалары—Ә. Баян, М. Хәбибуллин, Г. Зәйнашева, В. Корчагин, М. Галиев, Н. Хисамов, Г. Морат, Ж. Дәрзаман, Р. Зәйдулла, Р. Ш. Мостафин). Өч ел эчендә 34 кеше берлеккә әгъза итеп кабул ителде, алар барысы да әдәбиятта танылган шәхесләр.

Бу елларда Язучылар берлегенең пропаганда бүлеге дә (житәкчесе Р. Сәгъди) районнар, уку йортлары белән элемтәне шактый жанландырды, әдәбияттагы казанышларыбызны укучыларга житкерүдә эшне төрләндерүгә иреште.

Тулаем республикабызда иҗади мохит тудыруда Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт һәм Чаллы бүлекләре эшчәнлеге бәя биреп бетергесез әһәмиятле. Хисап чорында ике бүлек тә нигездә әйбәт эшләде. Үз регионнарында әдәби үзәк буларак, алар һәр районга, әдәби берләшмәгә, уку йортларына барып житәргә омтылдылар. Иҗади конкурслар, әдәби бәйрәмнәр, юбилейлар уздыру, яшь язучылар белән эшләү кебек тармакларда Татарстан Язучылар берлегенең чын мәгънәсендәге урыннардагы таянычлары булдылар.

Әлмәт бүлеге оештырылуга 40, Чаллы бүлегенә 25 ел тулу уңаеннан уздырылган тантаналар да бу төбәкләрдәге әдәби хәрәкәтне жанландыруга китерде. Хисап чорында әлеге бүлекләрдә оештыру жыелышлары да булды. Чаллы язучылар бүлегендә, бераз соңга калып булса да, бу жыелыш оешкан рәвештә, житди әзерлек белән үтте. Анда бүлекнең жаваплы секретаре итеп өченче срокка яңадан прозаик В. Имамов сайланды. Әлмәт бүлегендә исә мондый жыелышны чираттан тыш жыярга туры килде. Чөнки биредә Татарстан Язучылар берлегенең бөтенлегенә зыян китерә торган хәл туды. Әлмәт Язучылар бүлегенең күпчелек әгъзалары мондый омтылышларга принципиаль бәя бирде һәм житәкчелекне алыштырырга дигән карар кабул итте. Бюроның яңа составы, бүлекнең вакытлыча жаваплы секретаре итеп прозаик һәм шагыйрь Н. Әхмәдиев сайланды. Ул кыска вакытта оешманы матди һәм оештыру ягыннан шактый ныгытуга иреште. Өч айдан соң Әлмәт язучыларының гомуми жыелышы, Н. Әхмәдиев тәкъдиме белән, даими жаваплы секретаре итеп прозаик Зөфәр Дәүләтовны сайлады. Әлмәт язучылары һәм ул төбәктәге жәмәгатьчелек бу карарларны дөрес һәм вакытлы дип тапты. Әмма читтәге кайбер көчләр, аңа тискәре мөнәсәбәт күрсәтеп, жәмәгатьчелек фикерен тудырырга тырыштылар. Шул рәвешле, бу берлектәге бердәмлекне таркатырга теләүчеләрнең кемнәр булуы да ачыкланды. Хәзер, бу киеренке хәлгә ике ел вакыт узгач, без нәтижә ясый алабыз: Әлмәт бүлегендә без уздырган кискен оештыру чаралары бик вакытлы һәм кирәкле булган. Язучылар берлеге идарәсе мондый хәлгә читтән күзәтүче булып торган очракта, бу бик күңелсез нәтижәләргә китергән булыр иде. Без бердәмлегебезне саклап калдык, Татарстан Язучылар берлеге оешуга 70 ел тулуны нык оешкан хәлдә каршы алдык.

Барыбызга да мәгълүм, бу бәйрәм 2004 елның 26 октябрендә "Пирамида" мәдәни күңел ачу үзәгендә уздырылды. Анда Россия Федерациясе Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре Г. В. Иванов, "Наш современник" журналының баш редакторы, күренекле шагыйрь С. Ю. Куняев, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Р. Т. Бикбаев, Түбән Новгород өлкә язучылар бүлеге житәкчесе В. А. Шамшурин, Чуваш Республикасы профессиональ язучылар идарәсе рәисе В. В. Тургай, Марий Эль Язучылар союзы рәисе В, В. Крылов һәм башка кунаклар катнашты. Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев бәйрәм белән котлап чыгыш ясады. Ул болай диде: "Бу, чыннан да, иҗади зыялылар өчен генә түгел, Татарстанның күп милләтле халкы өчен дә бик мөһим вакыйга. Хәтта Советлар Союзы таркалганда да сезнең берлегегез—Язучылар берлеге сакланып калды. Бу иҗат хезмәткәрләренең туплану көче турында сөйли, һәм мондый берлекнең кадерен белергә кирәк. Сез беркайчан да өстән кушып иҗат итә алмадыгыз. Язучылар берлеге—ирекле шәхесләр берлеге ул. Бер генә әһәмиятле вакыйга да язучыдан читтә кала алмый. Бөтен гомерегез буе кешене рухи яктан баету өстендә эшләвегез өчен рәхмәт сезгә".

Юбилей тантаналары Татарстан Язучылар берлегенең тагын да ныгуына, туплануына китерде. Юбилейга багышлап чыгарылган күкрәк тамгасын күпчелек язучыларыбыз бүген дә горурлык хисләре белән тагып йөриләр.

Без соңгы елларда Татарстан Язучылар берлегенең чит илләр һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләре белән элемтәләрен ныгытуга нык игътибар бирдек. Ф. Галимуллин, М. Хәбибуллин, Х. Әюпов Истанбулда, төрки әдәбиятлар форумында катнашып, бүгенге татар әдәбиятының хәзерге торышы һәм казанышлары белән таныштырдылар. Шундый ук очрашуларда Р. Фәйзуллин, Ф. Латыйфи, М. Закир да катнашты. Халыкара "Ауразия диалогы" журналының редколлегия әгъзалары буларак Ф. Галимуллин һәм Р. Вәлиев Бишкәктә (Кыргызстан) һәм Анталиядә (Төркия) Евразия диалогы платформасы конференцияләрендә катнаштылар. Ф. Галимуллин 2004 елның декабрь аенда Молдова Республикасындагы Гагауз милли территориаль автономиясенең 10 еллыгы уңаеннан оештырылган тантаналарда катнашып, бу илнең язучылары белән дә аралашты.

Шулай ук С. Юлаевның тууына 250 ел тулуга багышланган чараларда Ф. Галимуллин, Р. Миннуллин, Н. Хисамовларның катнашуы, Татарстан Республикасы көнен уздыру тантанасына Уфадан Р. Бикбаевның килүе, Башкортстан Язучылар берлегендә яшьләр иҗатына багышланган чараларда "Әллүки" иҗат берләшмәсе вәкилләре катнашуы, Чаллы бүлегенең 25 еллык тантаналарында А. Юлдашбаев, М. Сәлимовларның кунак булуы соңгы вакытларда Башкортстандагы коллегаларыбыз белән элемтәләрнең елдан-ел яхшыра баруы турында сөйли. М. Кәримнең 85 еллыгы уңае белән Татарстан делегациясенең Уфада уздырылган тантанада катнашуы һәм чыгыш ясавы ике республика матбугатында да киң яңгыраш алды. Чуваш язучылар берлегенең 80 еллыгында Татарстан делегациясе катнашуы, Чувашстанда татар әдәбияты, ә Татарстанда чуваш әдәбияты көннәре уздырылу, 2004 елда ике республика язучыларының "галстукларсыз", ягъни рәсми булмаган шартларда очрашуы бу ике халыкның дуслыгын тагын да ныгытуга кертелгән зур өлеш булды. Кырымда, Марий-Эльдә уздырылган мәдәният көннәрендә безнең язучыларның катнашуы, Мәскәүдә Г. Тукай, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатларына багышланган кичәләр уздырылу, Россия башкаласындагы күргәзмәләр вакытында әдип-шагыйрьләребезнең татар китаплары витринасы янындагы чыгышлары шулай ук Язучылар берлеге башкарган җаваплы эшләр тезмәсен тәшкил итә. Татарстан Язучылар берлеге рәисенең Идел буе федераль округына кергән республикалар һәм өлкәләр язучылар оешмалары җитәкчеләренең киңәшмәсендә катнашуы һәм чыгыш ясавы бу әдәбиятлар белән элемтәләрне җайга салуга ярдәм итте.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллинның һәм Татарстан халык шагыйре Р. Харисның Россия Язучылар союзының XII съездына кунак сыйфатында чакырылулары шулай ук ике корылтай арасындагы әһәмиятле вакыйга булып тора. Хәзерге социаль-сәяси һәм икътисадый шартларда бу ике иҗат оешмаларының хезмәттәшлеген ныгытуга юнәлдерелгән адымнар ясау һәм чараларны тормышка ашыру иң дөрес юл булачак.

Ике корылтай арасында иҗади берлекнең материаль базасын ныгыту, бинаны ремонтлау, язучыларга торак шартларын яхшыртуда ярдәм итү, матди ярдәм күрсәтү буенча да системалы эш алып барылды. Васильевода иҗат йорты ачылу—оешмабыз тарихында беренче тапкыр тормышка ашырылды. Шушы вакыт эчендә анда сиксәннән артык язучы ял итте, сәламәтлеген ныгытты. Безнең каләмдәшләребезгә шушындый яхшы иҗат мөмкинлекләре тудырган өчен республикабыз җитәкчеләренә ихлас рәхмәтебезне җиткерәбез.

Безнең әдәби журналларыбыз: "Казан утлары", "Идел", "Мәйдан", "Салават күпере"—барысы да үз вакытында чыгып киләләр, укучыларга язучыларыбызның әсәрләрен даими җиткереп бару эшен дәвам иттерәләр. Татарстан китап нәшрияты, "Мәгариф" нәшрияты, "Татнефть"нең "Рухият" нәшрияты яңа китапларны вакытында һәм югары сыйфатлы итеп чыгаруда зур тырышлык куеп эшлиләр. Халыкара күргәзмәләрдә дә татар китаплары бары тик яхшы яктан гына бәяләнә. "Идел пресс" нәшриятының китап басу буенча мөмкинлекләре артуын шулай ук зур казаныш дип билгеләп үтәргә кирәк.

Татарстанның халык шагыйрьләренең биш томлыкларын бастырып чыгару эше дәвам иттерелде. Билгеле булганча, бу бик әһәмиятле эш XIII һәм XIV корылтайлар арасында башланган иде. Без ул чагында Ә. Еники, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә. Баянов, Н. Фәттахның бишәр томлыкларын чыгардык. Ә соңгы елларда мондый томлыкларга Ф. Яруллин, Г. Афзал, Х. Камалов ия булды. Хәзер исә М. Мәһдиев, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис әсәрләрен бастыру турында сүз бара.

Нәшриятлар, вакытлы матбугат, радио-телевидение турында сүз алып барабыз икән, аларның күбесенә рәхмәт әйтергә кирәк. Чөнки алар әдәбиятка хәерхаһ булулары белән гомуми мәдәниятебез үсешенә даими рәвештә өлеш кертәләр. Бу очракта "Ватаным Татарстан", "Республика Татарстан", "Мәдәни җомга", "Мәгърифәт", "Шәһри Казан", "Татарстан яшьләре", "Казанские ведомости", "Сабантуй" газеталарын, "Татарстан", "Ялкын", "Сөембикә" журналларын рәхмәт хисләре белән телгә аласы килә. Аларның күпчелеге, кирәкмәгән ыгы-зыгыга бирелмичә, әдәбият үсешенә файда китерерлек материаллар басалар, язучыларыбызның әсәрләрен көне-сәгате белән дигәндәй укучыларга тәкъдим итәләр. Бу эштә күп еллар буена "Татарстан" радиосы һәм телевидениесе зур эш башкарып килде. Ш. Усманов, Г. Кутуйлар нигез салган радиода К. Нәҗми, Г. Бәширов, Г. Гобәй, Х. Туфан, Ш. Мөдәррис, Ә. Маликов, Б. Камалов, Ә. Рәшитов, З. Насыйбуллин һәм башка бик күп язучыларыбыз эшләде. Сәгатьләр буе яңгырап торган радиопостановкаларны тыңлап, миллионнар үзләренә тормыш дәресе, рухи азык алды. Күпме әдәби әсәрләр, шигырь-поэмалар, язучыларның чыгышлары яңгырады. Алга таба ничек булыр? Әле моны беребез дә ачык кына күз алдына китерә алмый. Һәрхәлдә, реформалар вакытында исән калган радио һәм телевидение программалары моннан соң да "Татарстан" радиосы һәм телевидениесе югарылыгында эшләсеннәр иде дигән теләктә калабыз.

Бу еллар ватанпәрвәр шагыйребез М. Җәлилнең 100 еллыгына әзерлек чоры да булды. Әлеге датаны бөтенхалык бәйрәме итеп уздыру хакында Татарстан Президентының махсус фәрманы да кабул ителде. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә яшьләрнең казанышларын бәяләү максатында М. Җәлил исемендәге бүләк яңадан торгызылды. Аңа Ж. Сөләйман җитәкчелегендәге республика яшьләренең "Сәләт" иҗтимагый фонды, Татарстан Республикасының "Мәгариф" Милли китап нәшрияты (директоры М. Вәлиев) талантлы яшь авторларга эзлекле ярдәм күрсәткәне өчен лаек булды. Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген Я. Зәнкиев, М. Хәбибуллин, М. Юныс алдылар. Р. Сибат, А. Хәлим, Р. Юныс, Х. Миңнегулов, Д. Салихов исә—Г. Исхакый исемендәге; Р. Газизов, К. Кәримов, Р. Зәйдулла—хикәя өлкәсендә Ф. Хөсни исемендәге; Р. Хафизова, Г. Гыйльманов, И. Сөнкишева, Р. Корбан, Й. Жамалетдинова—балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен А. Алиш исемендәге; С. Хафизов, Р. Шәрәфиев, Ф. Галимуллин әдәби тәнкыйть өлкәсендәге казанышлары өчен Ж. Вәлиди исемендәге бүләкләргә лаек дип табылдылар.

2005 елда шигърият өлкәсендәге казанышларны билгеләү өчен бөек шагыйребез Һади Такташ исемендәге премия булдырылды. Аңа беренче булып Рәдиф Гаташ лаек дип табылды.

2000 елдан бирле рус телендә иҗат итүчеләрнең казанышларын тәкъдир итү өчен Татарстан Язучылар берлеге һәм Лаеш районы администрациясе Г. Р. Державин исемендәге бүләк булдырганнар иде. Соңгы өч елда Ә. Мушинский, Л. Газизова, Л. Кожевников аның лауреатлары булдылар. Шулай итеп, хәзер безнең иҗади берлегебездә әдәбиятның һәр жанры буенча казанышларыбызны билгели торган премияләр булдырылды. Боларның һәммәсе безнең каләмдәшләребезне иҗатка рухландыруда әһәмиятле этәргеч булып тора.

Без бүген нибары өч еллык эшчәнлек турында сүз алып бардык. Күрәбез, идарәнең бу составы эшлекле, максатчан булып чыкты. Әдәби тормышның бик күп юнәлешләрдәге эшләрен нәтиҗәле оештыра алды. Бу чараларга язучыларның барысын да җәлеп итәргә тырышылды. Димәк, барлык бу куанычларыбыз—уртак хезмәтебез нәтиҗәсе. Яна идарә, аның җитәкчеләре, шушы уңай җирлеккә таянып, күптармаклы эшне тагын да алга алып китәр дигән өметтә калабыз. Шулай булса иде.

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*

**Рафаэль Мостафин**

## ТӨГӘЛ БУЛЫЙК!

—Айдар Хәлимнең мәкаләсен укыдыңмы? Шәп язган бит, әй!

—Укымыйча... Биргән кайберәүләрнең кирәген!

Моның ише сөйләшүләрне соңгы вакытта Матбугат йорты коридорында еш ишетергә була. Сүз Айдар Хәлимнең “Сез беләмсез кая барганны!” исемле мәкаләсе турында бара *(“Казан утлары”, 2005 ел, 1-2 саннар).*

Чыннан да, А. Хәлим үзенең чыгышы белән пыскып кына барган дискуссияне, бер кочак коры утын ташлагандай, гөлт итеп кабындырып җибәрде. Мәкалә кайнар кан белән, чын күңелдән, дулкынланып язылган. Автор үзен оста прозаик, нечкә күңелле шагыйрь, ялкынлы публицист итеп кенә түгел, очлы каләмле тәнкыйтьче итеп тә күрсәтә.

Аның колачы бик киң. Ул бүгенге әдәби агымны да, бөтен әдәбият тарихын да инли, барлык жанрларга да *(проза, шигърият, драматургия, халык авыз иҗаты)* үз карашын белдерә, тормыш проблемалары турында да саллы гына фикерләр әйтеп китә.

Минем күңелгә шунысы аеруча хуш килде: автор әдәбиятка изге нәрсә, җан азыгы бирә торган өлкә дип карый. “Әдәбият кешене илһамландырырга, бер карыш булса да җирдән күтәрергә тиеш”. “Укучыга вакыт үткәреп укырлык әсәрләр күп, тик җан чистартыр дәрәҗәдәге мәхәббәтле әсәрләр генә сирәк”. Мондый фикерләр белән ничек килешмисен?! Бигрәк тә алар конкрет мисаллар, реаль фактлар белән раслангач.

Әмма нигездә файдалы һәм кызыклы бу мәкаләдә шактый буталчык, мин һич тә килешмәгән фикерләр дә күп. Мактау сүзләрен авторга миннән башка да күп ишеттергәннәрдер, шуңа күрә полемика өлешенә күчәм.

Мәкаләнең иң көчле ягы—таләпчәнлек. Беркемнең исеменә-дәрәҗәсенә карамыйча, автор үзенең фикерен ярып сала, шактый усал тәнкыйть фикерләрен әйтергә дә тартынмый. Бәс, болай булгач, без дә Айдар Хәлим мәкаләсенә шундый ук таләпчәнлек белән якын килик.

Иң элек шунысы күзгә ташлана: мәкалә артык озын, журналның ике санына сузылган, журнал мәйданының шактый өлешен биләп тора.

Озын булуы бер хәл, мәкалә композицион яктан да таркау. Төп темадан читләшеп, автор әледән-әле чигенүләр ясый, әдәбият тарихына мөрәҗәгать итә, теге яки бу күренешкә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Мәкаләнең икенче яртысы исә бөтенләй башка темага язылган. Автор монда әдәбият дәреслекләренә һәм хрестоматияләргә күзәтү ясый, беренче сыйныфтан башлап унберенче сыйныфка кадәр булган әдәбият әсбапларын барлап чыга. Сүз дә юк, кирәкле тема, җитлеккән мәсьәлә. Ләкин журнал битләрендә барган дискуссиягә аның турыдан-туры катнашы юк. Дәреслекләр турында аерым бер дискуссия үткәрергә мөмкин булыр иде. Менә

шунда инде А. Хәлим мәкаләсе *(журналның икенче санында басылган өлешен аерым мәкалә дип атарга була)* бик урынлы һәм файдалы булыр иде. Мондый дискуссиягә педагогларны һәм хрестоматияләрне төзүчеләрне үзләрен дә тартырга булыр иде. Бу көенчә автор дискуссияне бөтенләй башка якка алып китә.

## Милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге

"Чорлар чатындагы үзгәрешләр" исемле мәкаләмдә *("Казан утлары", 2004 ел, 5-сан)* мин бүгенге татар әдәбияты буыннар алмашыну кризисы кичерә, дип язган идем. Бу фикер белән нигездә килешеп, А. Хәлим кризисның тамырларын тирәнрәк катламнардан, беренче чиратта, тормышның үзеннән эзли. Чыннан да, буыннар алмашыну—табигый, һәрвакыт үз агымы белән бара торган процесс. Ә менә тормышыбызда без укучылар аудиториясенең көннән-көн тарая баруын күрәбез. Бу исә, үз чиратында, илебездә бара торган ассимиляция, ягъни руслашу процессы белән аңлатыла. Хәер, безнең илдә генә түгел, бөтен дөньяда милли үзенчәлекләр югала бара, вак милләтләрнең телләре бетә, кыскасы, глобальләшү шаукымы көчәя.

Шуна күрә дә А. Хәлим үз мәкаләсен глобализм төшенчәсен ачыклаудан башлый. Аның тамырларын ул бик тирәндә, әле Иван Грозный башлаган сәясәттә үк күрә. Көчләп чукындыру, руслаштыру, чит милләтне һәм физик, һәм рухи яктан юк итү. "Советлар алып килгән глобализм исә, интернационализм күлмәген киеп, тагын да нечкәрде, телне, жанны, катнаш никахлары белән гаиләне басты",—дип яза автор.

"Менә шушындый катлаулы, байтак язмышларны ботарлап ташлаган, хәтта катаклизмнарга кадәр барып җиткән җәмгыятьтә әдәбиятның, анызрак әйткәндә, матур әдәбиятның роле кимеде түгелме?—дигән сорау куя безнең алга журнал. Бик тә вакытлы, бик тә катлаулы, бик тә кыю вә куркынычлы сорау бу". *(Шушы урында автор нокта куйса, бер каршылыгым да булмас иде. Әмма автор дәвам итеп, чамасын онытып җибәрә. Р. М.)* "Татар җәмгыятенең генә түгел, гомумкешелек җәмгыятенең дә әле мона кадәр, бары тик матур әдәбиятка бәйләп, мондый сорау югарылыгына күтәрелгәне юк иде..."

Тукта әле, Айдар дус! Әллә син көндәлек матбугатны бер дә укымыйсыңмы? "Литературная газета", "Новый мир", "Дружба народов", үзебезнең "Мәдәни Җомга", шул ук "Казан утлары" журналы ише басмаларда бу мәсьәлә сан саен диярлек күтәрелә. Чөнки ул өлгергән, күзгә ташланып тора. Хәер, автор үзе дә бу турыда белә. Янәшә битендә генә ул Равил Фәйзуллинның "Казан утлары" журналында басылган "Китап гасыры китәме?" исемле мәкаләсен телгә ала. Димәк, бу мәсьәлә, бик җитди һәм өлгергән булса да, яңа түгел.

Әлбәттә, бу—кечкенә кимчелек, бәйләнеп тормасак да булыр иде. Ләкин авторның төп ысулы шундый. Ул мактаганда да, тәнкыйть иткәндә дә, чамасын онытып җибәреп, йә күккә күтәреп мактый, йә тырнак астыннан кер эзли башлый.

А. Хәлимнең ачынуын аңлыйм, борчылуын уртаклашам. Ләкин кризистан чыгуның юлларын кабул итә алмыйм.

"Рәсми рәвештә биш миллион исәпләнгән, әмма аның урыслашкан, носарилашкан, мәҗүсиләшкән (?) өч миллионын җинел генә (?) коеп калдырып, иманлы, татар телле, саф татар-мөселман саналган ике миллион татарыбыз белән дә дөньяның күркәм милләтләре исәбенә баса алачакбыз".

Боларга өстәп, берничә йөз мең саф татар телле, әмма христианлашкан, саф татар-мөселман булмаган керәшеннәрне дә шулай ук "җинел генә" "коеп калдырырга" кирәктер... Айдар Хәлимнекеләрен белмим, әмма, ни кызганыч, бик күп милләттәшләребезнең балаларын, оныкларын, якын туган-тумачаларын да читкә тибәрергә туры киләчәк. Әмма без аларны, А. Хәлимчә, "коеп калдырсак", алар безгә ничек карар? Аларны чит күргән милләттән ваз кичеп, үз тамырларын бөтенләй онытмаслармы?

Бу фикерен А. Хәлим мәкаләсенең буеннан-буена кабатлап, саннарны гына бераз төрлечәрәк китереп бара: "Без хәтта бер миллион, хәтта биш йөз мең татар белән дә дәүләтебезне аякка бастырачакбыз". Димәк, уннан берсе генә "саф татар" булып санала ала. Калган тугызын читкә тибәреп, көчләп диярлек, башка милләтләргә кушырга кирәк. Дәүләт дигәннән... Бу мәсьәлә бүгенге шартларда көн

тәртибендә тормый, матур, ләкин чынбарлыктан ерак хыял булып кына кала. Моннан ун-унбиш ел элек яулаган суверенитетның "с" хәрефе дә калмагач, нинди дәүләт турында сүз алып барырга мөмкин? Яна шартларда телебезне, динебезне, мәдәниятебезне, милли аңыбызны саклау турында уйларга кирәк. Мондый шартларда русча укыган, русча сөйләшә торган милләттәшләребездән баш тартсак, тагын да тизрәк эреп бетәчәкбез. Бу ахмаклык булыр иде. Минем күзәтүләремчә, хәтта рус телле татарлар да, аеруча читтә яшәүче милләттәшләребез, милли аңнарын югалтып бетермәгәннәр. Алар милли музыкага, театрга, тәрҗемәдә булса да татар әдәбиятына тартылалар. Шуна күрә, аларны "су астыннан өстерәлеп барган ләнгәр" *(тимер якорь)* дип түгел, милләтнең читтәрәк кала килгән резервы дип карарга кирәк.

Яһүдиләрне генә искә төшерик. Ике мең ел буе үз Ватаннарын югалтып, чит-ят җирләргә китеп, башка халыклар арасында сибелеп-чәчелеп яшәү дәверендә алар туган телләрен ике мәртәбә алмаштырдылар. Беренче мәртәбә борынгы иврит *(еврей)* телен онытып, бераз үзгәрәк немец теленә—идишка күчтеләр. Соңыннан, Россия җирләрендә яши башлагач, күбесе моны да ташлап, рус теленә күчте. Ләкин милли аңнарын югалтмадылар, бердәм, үзенчәлекле, сәләтле, бер-беренә искиткеч ярдәмчел милләт булып кала алдылар. Һәм, тиешле шартлар тугач, үз дәүләтләрен янадан аякка бастырдылар.

Әлбәттә, бу һәр милләтнең яшәү көче, рухи ныклыгы белән бәйле. Шундый ныклык бар икән—милләт яши. Булмаса—бетә, башкалар арасында эри.

Ассимиляциянең *(руслашуның)* никадәр көчле һәм котылгысыз агым икәнен автор үзе дә аңлый булса кирәк. Моның тамырларын ул җәдитчелек хәрәкәтендә күрә. Шул унай белән, Гаяз Исхакый, Фатыйх Әмирхан кебек классик язучыларны гаепләп, ул болай ди: "милләтне руслаштыру пропагандасын йөз процент кадими татарның бер ун процентын җәдитчә урыслаштырудан туксан процент татарга бер нинди зыян булмас дип, "уйнап" кына башлаганнар булса, хәзер без туксан тугыз процентка урыслашкан татарны калган бер генә процент "милли татары" белән кушып кире татар ясый алмыйбыз инде.

Игътибар итегез: "Бу юлы инде А. Хәлим татарның 99 проценты урыслашкан, ди. Димәк, ул бер генә процент "саф татар-мөселман" булган милләттәшләренә таяна. Бу бит илле мең тирәсе генә. Ә калганнары белән нишләргә? Себереп ташлап читкә түгәргәме? Әллә яңа шартларны истә тотып, башка юлларны эзләргәме? Мәсәлән, рус телендә пропаганда алып барыргамы? Шәһәр җирендә яшәүче руханиларыбыз моны бездән алдарак аңлап алдылар. Алар хәзер хәтта җомга вәгазьләрен дә күпчелек очракта рус телендә сөйлиләр.

Татар телле әдәбиятның нигезе, чыннан да, көннән-көн тарая бара. Мәсәлән, татар календаре *(ул һәр татар гаиләсендә була торган әйбер)* илле мең тираж белән басылган. Монда да шул ук сан... Башка китаплар исә, ике-өч мең белән басылып та, таралмыйча яталар... Шул исәптән Гаяз Исхакыйның күптомлыклары да...

Милләтнең эри, югала баруының төп сәбәпләренең берсен А. Хәлим катнаш никахларда күрә: "Татар үз карынында йөртеп, тудырып, миллион расходлар тотып, балалар үстерә дә, аларны ят кияүләргә коллыкка сата, инде йөз ел катнаш никахларда башка милләтләрне арттыра",—дип яза автор. Авторның борчылуы аңлашыла. Тик нигә әле татар кызының башка милләт кешесенә кияүгә чыгуы "коллыкка сатылу" булсын? Ул бит аны үз ирегe белән, мәхәббәт нигезендә башкара. Язучыга ошыймы-ошамыймы—бу процесс чыннан да йөз ел буе бара һәм киләчәктә дә барачак. Бу—җәй артыннан кыш килгән сыман котылгысыз. Кыш көне—начар, суык. Әмма кышны күпме генә сүксәң дә, ул барыбер киләчәк. Димәк, башка чарасын күрергә кирәк. Бу очракта исә, туган теленә, мәдәниятенә, тарихына хөрмәт тәрбияләү, милли горурлык тойгысын югалтмау турында сүз алып барырга кирәк.

Шундый сорау да туа: кайсысы мөһимрәк—кеше ирегеме, милләт хокукымы? Минемчә, кеше хокукы өстенрәк. Кеше ирегеn кыса башласак, без үткән чорның коллык заманаларына кайтачакбыз.

Катнаш никахларны каһәрләп язганнан соң, автор мондый "ташлама" ясый: "Котыла алмаган хәлдә, катнаш никахны мөселман кысаларына кертә алсак, без инкыйраздан котылачакбыз. Безгә кияүлеккә килгән Иван иманга килергә тиеш. Безгә киленлеккә килгән Елена да иманга килергә һәм хиҗап ябынырга тиеш".

Татар кызларының күпчелеге дә кимәгән хиҗапны кидерерсең хәзерге

Еленаларга! Иванны да көчләп иманга китерергә кирәкми. Үз динендә калсын. Тик бер-берсенең телен, динен, милләтләрен генә хөрмәт итсеннәр.

"Татарның иң акыллы укыган баласы татарның үзенә түгел, чит Германия, Америка, Израильгә хезмәт итә"...

Беренчедән, бу процесс бездә генә түгел, бөтен дөньяда бара. Русларда ул тагы да кинрәк рәвештә җәелде. Икенчедән, әгәр татар баласы үз илендә үз хезмәтенә тиешле бәя алмый икән, чит илгә барып бәхет һәм лаеклы тормыш шартлары таба икән—нигә моңа борчылырга? Борчылган тәкъдирдә дә, чит илгә китүчеләрне гаепләү турында түгел, үзебездәге тормыш шартларын яхшырту турында уйларга кирәк.

Милли "чисталыкны", милли үзенчәлекләрне яклап, автор әледән-әле интернационализм төшенчәсен тибеп китә, аны мыскыллап, "советларның котырган интернационализмы" дип атый. Әмма уйлап карыйк—интернационализм—башка милләтләрне хөрмәт итү, үзенекен генә түгел, башка милләтләрнең дә казанышларын күрә белү, алар белән тату яшәү дигән сүз. Дөрес, совет чорында интернационализм алгы планга чыгып, милләт мәнфәгатьләре кайчакта күләгәдә кала иде. Әмма икенче чиккә дә ташланырга ярамый, чөнки моның милли чикләнгәнлеккә китерүе ихтимал. А. Хәлим мәкаләсендә исә мондый чикләнгәнлекнең чалымнары әледән-әле чагылып китә.

"Шул ук нефтең синеке, ләкин аны татар түгел, урыс белән ябрәй сата, бәрәңгең, сөтең, итең юридик яктан синеке, әмма фактик яктан синеке түгел, базарда аны әзәри белән ярышып әрмән сата..."

Сезгә ничектер, минем өчен бу юллардан милли чикләнгәнлек исе аңкып торган сыман тоела. Нәрсә, хәзер, нео-фашистик элементларга ияреп, әзәрбайҗан белән әрмәннәрне Россия җиреннән куаргамы? Еврейлар калмады да диярлек—барысы да Израильгә китеп бетте. Ә менә антисемитизм чаткылары әлегәчә кала бирә...

Үз милләтенне күтәрергә телисең икән—күтәр, горурлан. Әмма шул ук вакытта башка милләтләрне кимсетмә. А. Хәлим мәкаләсендә исә мондый моментлар әледән-әле очрап тора.

"Әгәр урыс шигърияте Василий Жуковский 1802 елда инглизчәдән тәрҗемә иткән утыз-кырык юллык "Авыл кәберстаны" элегиясе белән нибары моннан ике йөз ел элек башланган булса, безнең татар шигърияте үлемсез Кол Галинең сигез мең юллык "Йосыф вә Зөләйха"сы белән моннан сигез йөз ел (!!!) элек башланды". Чыннан да татар әдәбияты, аеруча шигърияте, Болгар һәм Алтын Урда чорларыннан ук үсеп, камилләшеп килә. Горурланыр өчен нигез бар. Әмма шул ук вакытта бөек рус әдәбиятын да кимсетергә кирәкми.

Рус әдәбияты белән чак кына таныш булган кеше дә рус әдәбиятының XI—XII гасырларда ук "Слово о законе и благодати", "Повесть временных лет", "Поучение Владимира Мономаха"ише әсәрләр белән башлануын яхшы белә. "Слово о полку Игореве" (1185-87) әсәрен исән чын мәгънәдә поэтик әсәр, ягъни поэма дип атап була. Бүгенге мәгънәдәге шигъриятне алсак та, рус әдәбиятында Симеон Полоцкий, Сильвестр Медведев, Карион Истомин (XVII гасыр), А. Д. Кантемир, В.К. Тредиаковский, М. В. Ломоносов (XVIII гасыр) кебек үз чоры өчен шактый күренекле вә сәләтле шагыйрьләр иҗат иткән. Поэмаларга килсәк исә М.М. Херасковның "Чесменский бой" (1771) һәм "Россиада" (1779) поэмалары һәрберсе берничә мең юлдан тора.

Тагы бер мисал. Алдарак автор татар халкының каһарманнарын санап китә дә *(Колшәриф, Батырша, Сөембикә, Мәрҗани, Солтангалиев, Муса Җәлил һ. б.)*, шундый сорау куя: "Кайсы милләттә бар мондый алыплар?" "Мин моңа болай дип җавап бирер идем: һәр милләтнең үз алыплары, үз батырлары бар. Рус милләтенең Илья Муромецтан башлап маршал Жуковка хәтле каһарманнарын санап китсәң, бик озынга китәр иде. Бер милләт тә башкалардан ким-хур түгел.

Автор бер яктан үз халкы, татар мәдәни уңышлары белән масайса, икенче яктан артык түбәнсенеп тә китә:

"Без вак, без—тузан... Юк, безнең искиткеч талантлы, әмма изелгән, кол, колониаль милләтебез галәми масштабтагы ук Сервантес, Шекспир, Рабле, Бальзак, Ги де Мопассан, Джон Голсуорси, Теодор Драйзерларны тудыра алмады". Күрәсен мондый кимсенү сүзләрне автор, алдарак артык мактап киткәнен аңлап, хакыйкатьне

бераз тигезләр өчен китергәндер. Минемчә, артык масаерга да, кимсенергә дә кирәкми. Безнең үз тарихыбыз, үз телебез, динебез, мәдәниятебез бар. Без беркемнән дә өстен дә, начар да түгел.

А. Хәлим үзен бик хаклы рәвештә "максималист-милләтче" дип атый. Мин исә мондый позицияне кабул итә алмыйм. Тәрәккыят без теләгәнчә генә, югалтусыз бармый. Елдан-ел аның кире яклары күзгә ныграк ташлана. Әмма искегә ябышып, прогрессив юнәлешкә каршы килеп әллә ни майтарып булмый. Тормыш үз агымы белән бара, безгә әйләнеп тә карамый. Элекке кадимчеләр дә берни эшли алмадылар. Хәзергеләре—бигрәк тә... Яна меңьеллыкта ничек яшәргә, милли аңны яна шартларда ничек сакларга, мәдәниятне, әдәбиятны ничек үстерергә—шул турыда күбрәк уйланырга кирәк. Әнә бит Чыңгыз Айтматов рус телендә язса да кыргыз язучысы булып кала белгән.

## Ватан бер генә була

А. Хәлим мәкаләсенең яртысы чамасы М. Вәли-Баржылы белән бәхәскә багышланган. Начармы бу? Димәк, тәнкыйтьче ана бәхәс өчен этәргеч биргән. Әмма мин күпчелек очракта А. Хәлим ягында түгел, тәнкыйтьче ягында.

Мәкаләсенең башлангыч өлешендә *("Казан утлары", 6 сан, 2004 ел)* М. Вәли-Баржылы "герой" төшенчәсен ачыкларга теләп, Ватан сугышы каһарманнары Шакиржан Мөхәммәтҗанов (Александр Матросов), Газинур Гафиятуллиннарның батырлыгын үрнәк итеп китерә. А. Хәлим исә моны "провокация" дип атый. Анынча, амбразурага үз күкрәкләре белән капланган геройлар "өнсез пушка ите булып" "чит империягә" генә хезмәт иткәннәр. Ул аларны һәм башка шуныңише батырлык күрсәткән каһарманнарны "мәгънәсез корбаннар" дип атый. "Үз милләтең алдында каһарманлык кылуның бөтенләй кирәге юкмыни?"—дип тәнкыйтьчегә бәйләнә. Әмма М. Вәли-Баржылы мәсьәләне алай аңламый. Ул үз милләте өчен шәһит киткән каһарманнарны уртак Ватан өчен һәлак булганнарга капма-каршы куймыйча, икесе дә кирәк, ди. Һәм, минемчә, дөрес эшли.

А. Хәлим фикеренчә, "бары тик милли азатлык, милли мөстәкыйльлек, милли консолидация, милли тәрәккыят, милли дәүләтчелек өчен көрәшкән шәхес кенә каһарман булып исәпләнә ала". Әгәр дә хәзер XXI гасыр башы түгел, календарьда 1552 ел булса, мин дә Рус илен икенче ил, "чит ватан" дип атаган булыр идем. Ләкин заманалар үзгәрә, миллионнарча милләттәшләребез Россия буенча сибелеп яшиләр. Аларны хәзер уртак ватаннарыннан пычак белән дә кисеп алып булмый.

Болай фикер йөртсәк, без Муса Җәлилне һәм аның иптәшләрен дә "чит ватанга хезмәт иткәннәр" дип читкә тибәрергә тиеш булабыз. Аларны гына түгел! Менә, әйтик, рейхстаг гөмбәзенә беренче булып җиңү байрагы кадаган Гази Заһитов. Ул да чит илгә хезмәт иткәнме? Әмма автор үзе дә аның батырлыгы белән горурлана. Күкрәкләре белән фашист амбразурасын каплаган татар егетләреннән тыш безнең әле Гитлерның империя канцеляриясенә беренче булып бәреп керүче татар полковнигы Идрис Гомәров бар. Сугыш елларында АКШта совет разведкасы резиденты булып эшләгән татар егете Исхак Әхмәров бар. Ул Япониянең СССРга һөҗүм итү куркынычын икенче якка юнәлтеп, АКШның сугышка керүенә сәбәпчеләрнең берсе һәм иң житдие була. Горурланабызмы без андый батырлар белән? Әлбәттә! Бөек Җиңүнең 60 еллыгы көннәрендә—аеруча. Шуны да онытмыйк: сугыш елларында Советлар Союзы каһарманы исемен татарлардан 161 кеше алган. Халык саны буенча бүлеп исәпләгәндә, татарлар—беренче, руслар өченче урында тора.

Автор бер яктан Ватан сугышында катнашкан каһарманнарыбызны яманлый, алардан баш тарта. Икенче яктан үзе үк уртак Ватанны сакларга кирәк дип әйтә *(Дөрес, шул ук вакытта ул аны "икенче Ватан", "көчләп тагылган Ватан" дип атый.)*: "яшәгән жиреңә, көчләп тагылган Ватаныңа дошман явы килсә, туган жиреңне һәм шушы көчләп тагылган Ватаныңны, кем кулы астында яшәвеңә карамастан, Коръән-Кәрим дә якларга куша". Житмәсә, әле болай дип тә өстәп куя: "Никадәр ихлас һәм изге күрсәтмә". Бу сүзләргә тулысынча кушылып, шуны гына әйтәсем килә: болай булгач, авторның алдарак сөйләгән сүзләре юкка чыга түгелме соң?

Мондый каршылык мәкаләнең буеннан-буена чагыла. Бер урында ул "татар

канлы империя ялчылары Кутузовлар, Аксаковлар, Державиннарны" читкә тибәреп китә. Минемчә, боларның берсенең дә татар халкы каршында гаепләре юк. А. Хәлим сүзен тыңласак, Державинга Казан уртасында куелган һәйкәлне яңадан жимерергә кирәк. Хәер, А. Хәлим фикерләренә колак салучы булмас, дип уйлыйм, чөнки аның хаксыз булуы көн кебек ачык.

"Каһарманнар ни өчен кирәк?"—дигән сорауга А. Хәлим болай дип җавап бирә: "Милләтне *(мин монда халыкны дип әйтер идем. Р.М.)* үлемсез итү өчен кирәк!" "Милләтнең батырлыгы сурәтләнми калгач, ничек итеп рухи батыр милләт тәрбияләргә мөмкин?" Бик дөрес, ике куллап кушылам! Әмма А. Хәлимгә ияреп, булган каһарманнарыбыздан баш тарта башласак, кемнәрнең мисалында халыкны тәрбияләрбез?

Бу бик принципиаль мәсьәлә. Сүз патриотизмны ничек аңлау турында бара. Юк, Ватан бер генә, аны яклау, аны кайгырту, аның өчен хезмәт итү—безнең барыбызның да патриотик бурычы.

## Иң замандаш әсәр белән иң бөек шагыйрь турында

Укучының: "Тукта, тукта!—дип әйтүе ихтимал.—Бу мәсьәләләр барысы да кызыклы, житди, өлгергән. Ләкин аларның "Заман герое" турындагы дискуссиягә ни катнашы бар? Бу сөальне мин А. Хәлимнең үзенә кайтарыр идем. Ул мәкаләнең кереш өлешендә 15-20 бит буе төрле мәсьәләләргә кагылып, һаман да үгезне мөгезеннән тотып ала алмыйча азаплана. Тик шуннан соң гына Мансур Вәли-Барҗылы мәкаләсен исенә төшереп, аның белән бәхәскә кереп китә. Төп гаепләүләрнең берсе—тәнкыйтьче соңгы егерме-утыз елда иҗат ителгән әсәрләргә анализ бирү урынына, бик тирәнгә кереп, моннан 50-60 ел элек язылган әсәрләргә туктала икән.

Бу фикер белән килешергә дә булыр иде, әгәр автор үзе дә нәкъ шул юл белән китмәсә. Мәсәлән, А. Хәлим Муса Акъегетнең моннан йөз егерме ел элек язылган "Хисаметдин менла" исемле беренче татар романын "бүген иң актуаль, иң милли, безгә иң замандаш әсәр" дип атый. Ә романның төп персонажы Хисаметдин менла, анынча, "мәңге сокландыра торган чын "заман герое".

Кайчандыр мин бу әсәрне беренче тапкыр укыганда роман миңа бик йомшак, хәтта примитив булып тоелган иде. А. Хәлим романны күккә күтәреп мактагач, хәтта бүгенге язучыларга үрнәк итеп күрсәткәч, иренмичә әсәрне тагы бер мәртәбә укып чыктым. Элекке фикерем үзгәрмәде. Заманасы өчен әсәр бәлки чыннан да яңа сүз булып кабул ителгәндер. Әмма хәзер аны мисал итеп күрсәтү—120 елга кире кайтырга чакыру дигән сүз. А. Хәлим әсәрнең язылу рәвешен дә мактый: "Сез андагы телне карагыз, телне!" Карыйк соң.

Романның стиле госманлы төрекләрдән яки борынгы төрки телдән алынган авыр, киң массага аңлашылмый торган сүзләр белән чуарланган, сүзлексез аны гомумән укып булмый:" "Кардәшләремез бең төрле дәрдә мөбтала улып, наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуг вә гаддар дошманның әленә төшеп, жа талашдыкы..." "Нурлы вә күк күзләре сәтра сахифәи йөгереп кәчәерләр"...

Соңгы жөмләне автор үрнәк итеп китерә. Ләкин башта аны хәзерге татар теленә тәржемә итә: "Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп үтәрләр". Димәк, мисал китергәндә дә автор фальсификация юлына баса.

Нишләп әле автор шактый искергән, примитив, иске телдә язылган әсәргә ябышып ята? Зәвыгы түбән булгангамы? Юк, күрәсең, эш башкада. Автор, гомумән, искелек, кадимчелек тарафдары. Анынча, "латин әлифбасы өчен генә түгел, гарәп әлифбасы өчен көрәш тагын да мәһабәтрәк вә мәхәббәтлерәк булыр иде"... Тора-бара ул хәтта Фатыйх Әмирхан, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай кебек олы язучыларыбызны жәдитчелеккә чакыруда, ягъни "сәяси сукырлыкта" гаепли. Аның ихтыяры булса, язучы татар жәмәгатьчелеген йөз елга кире кайтарыр иде. Башка төрки халыкларның гарәп әлифбасыннан баш тартып, латинга күчүендә аның эше юк.

Акъегеттән Кандалый ижатына күчеп, автор аны да бүгенге әдипләргә үрнәк итеп күрсәтә. Имештер, ул—"бөтендөнья поэзиясендә дә сирәк очрый торган шагыйрь". "Мин дөнья әдәбиятында Кандалыйдан да бөек мәгъшук-шагыйрьне белмим". Белмисең икән, Айдар-дус, анысы синең проблема. Дөнья әдәбияты исә

мәхәббәт лирикасында Шекспир сонетларын, Лорка, Элюар, Пушкин, Цветаева, Ахматова, Пастернак әсәрләрен белә һәм таный. А. Хәлим хәтта Кандалыйны Пушкиннан да югары куя. Нәрсә дияргә моңа каршы? Дидактик алым белән мавыгучы, үгет-нәсихәт рәвешендә язучы шагыйрьнең моңа карап кына дәрәҗәсе күтәрелмәячәк.

Тагын кемнәрне А. Хәлим "заман герое" дип таный? Гаяз Исхакыйның Сөннәтче картын. "Заман героемы?"—дип сорый автор аның турында. Һәм үзе үк өзеп җавап та бирә—"заман герое!" Әйе, ул чыннан да заман герое. Ләкин үткән заман герое. Ә без исә, автор үзе искәртеп киткәнчә, соңгы 20-30 ел турында сүз алып барабыз.

М. Вәли-Барҗылыны заман герое темасыннан читләшүдә гаепләп, үзе тагын да борынгырак чорларга кереп китә дә, автор үзенчә акланырга маташа: "милли әдәбиятның "заман каһарманы"—без телибезме-теләмибезме—ике меңьеллык тарихыбызның патриотик чагылышларына милли дәүләтчелегебезнең булмышына барып бәйләнә". Әмма М. Вәли-Барҗылы да үзенең үткәнгә чигенүләрен нәкъ шулай ук аклый, ул да сүзен "патриотик чагылышлардан" башлый. Тик "Ватан", "патриотизм" төшенчәләрен башкачарак аңлата.

Тора-бара А. Хәлим бүгенге чор әдәбиятына да килеп житә. Һәм бик җиңел котыла. "Казан утлары"нда соңгы 20-25 ел дәверендә басылган иң күләмле, иң күренекле әсәрләрне санап чыга да (Хәсән Сарьяннан алып Зөлфәт Хәкимгә чаклы барлыгы 53 язучының йөзгә якын әсәре), шундый нәтиҗә ясый: "боларның барысының да роман, повесть, хикәяләре объектив һәм кырыс бәядән читтә калырга тиеш түгелләр иде". Бик дөрес! Ләкин кайда соң ул—объектив һәм кырыс анализ? Фәкил Сафинның "Саташып аткан таң" романыннан тыш, А. Хәлим хәзерге заман авторларының бер әсәренә дә җентекләбрәк тукталмый.

## Тыелган алым

Дискуссия булгач, ул намуслы рәвештә барырга тиеш. Кеше әйтмәгән, аның уенда да булмаган сүзләрне тагып, шуны ялкынланып "фаш итү"—тыелган алым дип атала. Кызганычка каршы, А. Хәлим кайвакытта нәкъ шундый алымнар куллана. Менә, әйтик, М. Вәли-Барҗылы, заман герое турында уйланып, болай дип яза: "Ә бераз гына ераккарак карасак, без Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" повестендагы Бибинурны, Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыяте"ндәге Акъәбине күрәбез. Үзләренең рухи ныклыклары, сафлыклары һәм фидакарьлекләре белән алар безнең хәтердә Габдрахман Әпсәләмов геройларына һәм Нәфисәләргә *(Г. Бәширов)*, Миңлекамалларга *(М. Әмир)* килеп ялганалар".

Минемчә, бик дөрес әйтелгән, бәйләнерлек урын юк. Әмма А. Хәлим бәйләнер өчен җаен таба. Ул М. Вәли-Барҗылыны әле генә искә алган язучылардан "диссидент" ясауда гаепли. Безнең әдәбиятта, Салих Батталдан гайре, диссидент булмады, ди. Моны раслауга мәкаләсенең берничә сәхифәсен багышлый.

Чыннан да, Әмирхан Еники дә, Аяз Гыйләҗев та, хәтта Хәсән Туфан да чын мәгънәдә диссидент булмадылар. Кыйналдылар, тәнкыйть утына эләктеләр, ләкин коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең ачыктан-ачык дошманнары булмадылар. Бу юлларны укыгач, М. Вәли-Барҗылы мәкаләсен тагы бер укып чыктым. Анда "диссидент" сүзе бөтенләй кулланылмый. Хәтта шуңа охшаш фикер дә үткәрелми. Болай булгач, Хәлимебез җил тегермәннәре белән сугыша түгелме?

Минем белән бәхәскә кучеп, А. Хәлим минем Ф. Сафинның "Саташып аткан таң" романына бирелгән бәя белән килешми, минем анализны "коры мактау" дип атый. "Мактау гына түгел, бу әле әдәбиятта "А"сын да, "Б"сын да әйтеп өлгермәгән авторны очындыру дип атала". Ярый, А. Хәлим минем фикерем белән килешмәсен дә, ди. Әмма "Гөлҗиһан", "Соңгы көз" повестьлары, дистәләгән хикәя һәм саллы гына роман авторын ничек инде "А"сын да, "Б"сын да әйтмәгән дип кимсетергә була?

Аңлыйм: язучы да кеше. Аның да теге яки бу әсәргә башкалардан аерылып тора торган үз карашы булуы ихтимал. Әмма әдәби тәнкыйтьтә һәр субъектив караш та житди итеп нигезләнгән, дәлилләнгән булырга тиеш. Ничек дәлилли соң А. Хәлим үз бәяләмәсен?

Иң зур кимчелек итеп ул әсәрдә яңалык юклыгын атый. "Әгәр Фәкил Сафин

романын моннан бер утыз-кырык, хәтта егерме ел элек язган хәлдә дә ул әле чагыштырмача яңа күренгән булыр иде". Минемчә, утыз-кырык та, егерме ел элек тә мондый әсәр языла да, дөнья күрә алмас иде. Сиксәненче еллар уртасында Бөек Октябрь революциясен "саташып аткан тан" дип атарга кемнең башына килер иде? Күмәкләшү хәрәкәтенең никадәр кирәксез корбан китереп, көчләп үткәрелүе турында язарга кем рөхсәт итәр иде? Ниһаять, 1937 ел репрессияләрен болай итеп җентекләп, эчке пружиналарын ачып, гаепләләрне күрсәтеп тасвирларга мөмкин булыр идеме? Юк, әлбәттә.

Кыскасы, А. Хәлимнең дәлилләре ышандырмый. Мин үз фикеремдә калам. Ф. Сафиннын романы тарихыбызны яңача аңлау, заманча фикер йөртә белүе белән, тормышның үзеннән алынган чын заман героен күрсәтә алуы белән башка бик күп әсәрләрдән уңай якка аерылып тора.

Әсәрнең тагын бер җитди кимчелеге, А. Хәлимчә, төп образ итеп большевиклар партиясе әгъзасы Дәүләтъяровны алуда. Аныңча, большевик кеше уңай герой була алмый, чөнки большевизм "татар тарихында Явыз Иваннан кала икенче катастрофа булды". Әйе, булды. Әмма бу әле барлык большевиклар да начар кеше булган дигән сүз түгел. Мондый фикергә дә җәмәгатьчелегебез XX гасыр ахырында гына килде. Гасыр башында һәм гражданнар сугышы елларында татарның бик күп алдынгы вәкилләре, большевикларның милли азатлык лозунгларына алданып, партиягә керделәр, алар белән бер сукмактан атладылар. Хөсәен Ямашевны, Галимҗан Ибраһимовны, Мирсәет Солтангалиевләрне генә искә төшерик. Әлбәттә, алар алдандылар. Ләкин ялгышларын бик соң, кайвакыт төрмә камерасына эләккәч кенә аңладылар. Ф. Сафин шундый алданган кешенең фаҗигасен ача. Аның романында шундый эпизод бар. Кыйналган, җәзаланган Дәүләтъяров төрмә камерасында "ата бульшавик", комиссар, ә хәзер үзе дә тоткын хәлендә булган Шамил Усманов белән очраша. Дәүләтъяров аңардан: "Ни өчен бу газаплар безгә, безнең ни гаебебез бар?"—дип сорый. Күпне аңлап өлгергән Ш. Усманов болай дип җавап бирә:

"Гаепме? Бар анысы. Без революциягә сукырларча ышандык. Без тарихның табигый агышына каршы гамәл кылуда турыдан-туры катнаштык, кан, үле гәүдәләр өстендә яңача тормыш төзергә маташтык. Бу иң зур ахмаклык булган. Мин моны соңрак аңладым, таш капчыкка эләккәч, уйланырга вакыт бар менә..."

Искиткеч кыю фикерләр! Ф. Сафин большевик булган татарларның ачы фаҗигасен ачып бирә, үткән тарихыбыз турында яңача уйланырга мәҗбүр итә.

Ш. Усманов сүзләрен шундый ук ялкынлы революционер М. Солтангалиев тә кабатлый алыр иде. Бер уйласаң, аның гаебе тагы да зуррак. Ул Ленин тәгълиматына ышану гына түгел, хәтта үз милләтенә дә хилафлык кыла, "Болак арты республика"сын таркатуда, татар дәүләтчелеге яралгыларын җимерүдә катнаша. Сүз уңаенда, А. Хәлим аны гаепләми, хәтта татар халкының "титаннары" рәтенә кертә.

Кабатлап әйтәм: А. Хәлим дәлилләре ышандырмый, алардан субъективизм исе аңкып тора.

## Классикларның ни гаебе бар?

А. Хәлим мәкаләсендә күп проблемаларга кагыла, йөзләгән исем атый, бик күп әсәрләргә үзенчә бәя бирә. Күп очракта аның фикерләре оригиналь, кыю, яңача булулары белән күңелне җәлеп итә. Әмма оригиналь булу—бу әле һәрвакыт та дөрес дигән сүз түгел. Уйлап карыйк, кемне мактый да кемне хурлый соң ул?

Менә ул үткән чор әдәбиятына кагылып, Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Гариф Гобәй, Мирсәй Әмир, Гадел Кутуй һ. б. язучыларның әсәрләрен санап чыга да, шундый нәтиҗәгә килә: "Укый торгач, миндә безнең иң яхшы романыбыз Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"е икән дигән фикер дә уянды әле".

К. Нәҗминең әсәренә һич тә тап төшерергә җыенмыйм. Чыннан да, теле матур, вакыйгалары тыгыз, сурәтләү чаралары бай. Үз чоры өчен роман чыннан да җитди ачыш, яңа сүз булып яңгырады. Әмма бүгенге таләпләр югарылыгыннан караганда, әсәрне хәзерге язучыларга үрнәк итеп куеп булмый. Әсәр баштан ахырынача социалистик реализм алымы белән язылган. Автор беренче рус революциясе белән

Бөек Октябрь социалистик революциясе арасында Казан пролетариаты *(гәрчә, чынлыкта татар эшчеләре юк дәрәҗәдә аз булсалар да)* алып барган "революцион көрәш" турында яза. Сыйнфый каршылыкларны күпертеп, буржуазия вәкилләрен фаш итә. Революционерларны исә актан-ак, пакьтан-пакь итеп күрсәтә, күккә күтәреп мактый. Алай гына да түгел, әсәрнең беренче вариантларында "бөек юлбашчы" Сталин образын күрсәтә *(соныннан ул аны тырышып-тырмашып Ленин исеменә үзгәртә)*. Социалистик реализм таләпләренә тулысынча җавап биргән өчен әсәр Сталин премиясе белән дә бүләкләнә.

"Татар әдәбияты тарихы"ның 1989 елда чыккан бишенче томында (340 бит) бу әсәргә шундый бәяләмә бирелә: "...Романның кайбер урыннары, бигрәк тә аны тәмамлау чорында язылган һәм төзәтелгән аерым бүлекләре "ВКП(б) тарихының кыскача курсы" (1938) биргән положениеләргә әдәби иллюстрация тәэсирен калдыра".

Күрәбез ки, А. Хәлим "ВКП(б) тарихына" әдәби иллюстрация кебек яңгыраган әсәрне күккә күтәреп мактый. Ә шул карашларны кире кагып язылган әсәрне яманлый. Хәер, бер Ф. Сафин романыннан гына түгел, башка иң кыю, безнең чорга иң аваздаш әсәрләрдән дә гаеп эзли. Әйтик, ул бер урында "дәүләттән зур бүләкләр алган" "диссидент" Хәсән Туфанны телгә ала. Чыннан да, Туфанның "бүләге" бик зур булды: ун ел төрмә һәм тагы алты ел сөрген. Икенче урында ул шул ук фикерне куәтләп, тагы бер кабатлап китә: "Хәтта Баржылы диссидент ясаган Хәсән ага Туфан белән Әмирхан ага Еники дә *(югарыда әйткәнемчә, М. Вәли мәкаләсендә "диссидент" сүзенең "д" хәрефе дә юк)* үлгәнче "партиягә генә кагылмагыз, хөкүмәткә генә тел тидермәгез" дип яшәделәр һәм партия белән хөкүмәтнең зур бүләкләренә ия булдылар".

Монда автор, минемчә, ике нәрсәне бутый. Тормышта тыйнак, партиягә каршы чәчрәп чыкмый торган затлар булсалар да, бу әдипләр әсәрләрендә шактый кыю, алдынгы фикерләр үткәрделәр, бүгенге үзгәрешләрне халык аңында бик күптәннән әзерләделәр. Бүләк алсалар да, тормышларының соңгы елларында гына, җәмәгатьчелек фикере басымы астында алдылар.

Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Х. Туфан кебек әдипләргә ул мәкаләсенең буеннан-буена, кайта-кайта бәйләнә. Ә менә Афзал Таһиров, Имай Насыйри, Гомәр Толымбайский кебек икенче пландагы язучыларны "титаннар" дип атый. Мондый бәяләмә белән мин саграк кыланырга киңәш итәр идем. Хәтта рус әдәбиятында да титан дип бер Лев Толстойны гына атыйлар.

Нәрсә ошамый соң А. Хәлимгә үткән чорның иң камил, иң кыю фикерле "Әйтелмәгән васыять" әсәрендә? Бу әсәрдән Айдар Хәлим, кат-кат кайтып, кимчелекләр эзли. Эзли торгач, таба тагын: "Безнең Әмирхан Еникиебезнең атаклы "Әйтелмәгән васыять"е татар әдәбияты әсәре түгел икән. "Әбзи"нең "кылганнары дала буйлап йөгерә" йөгерүен, тик аларның кайсы якка йөгерүен "әбзи" үзе генә белә икән. Алар бит һич кенә дә Казан ягына түгел, Уфа ягына йөгерәләр, ләбаса! Ул татар әдибе тарафыннан язылган башкорт әдәбияты әсәре лә!"

Менә сиңа мә—юкәдә икән чикләвек! Без, татар укучылары Ә. Еники әсәрен татар әдәбиятына карый дип төптән ялгышканбыз икән! Алайса, Галимҗан Ибраһимовның атаклы "Казакъ кызы" романы да татар әсәре түгел, казакъ әдәбияты әсәре булып чыга. *(Хәер, автор Г. Ибраһимовка да "чит кешеләрне" тасвирлаган өчен дәгъва белдерә).* Мондый карашлар белән бәхәсләшеп тору да кирәк түгелдер. А. Хәлим фикеренчә, Акъәби милли әдәбиятыбыз каһарманы була алмый. Чынлыкта исә ул күптән инде милли героебыз булып китте, моңача аңа шик белдерүче дә булмады. Бөтен мәсьәлә дә шунда шул. Әйе, ул милләте буенча башкорт. Ләкин без, укучылар, аны үзебезнең милли каһарманыбыз дип кабул итәбез.

Автор фикеренчә, Ә. Еники үзенең әсәрендә халыкның руслашу, милли үзенчәлекләрен югалту сәбәпләрен ача алмаган. Имештер, Ә. Еники үз әсәрендә "большевикларны да, совет системасын да ләм-мим гаепләми". Совет чорында, коммунистик партия идарә иткән елларда чыккан әсәргә мондый таләпләр куюны ахмаклык дими, нәрсә дисең? Ә. Еники болай да бик күп нәрсә әйтә алды—образлар системасы, подтекст аша. Художстволы әсәр белән публицистик мәкалә арасында принципиаль аерма бар ич!

"Әйтелмәгән васыять" әсәренең авторы, имеш, "үз милләтен яшереп, икенче

милләт аша *(ягъни башкорт милләте аша. Р. М.)* үлемсезлеккә дәгъва итә". Һич аңламыйм: ничек инде икенче милләт аша үлемсезлеккә дәгъва итеп була? Автор үзе исән булса, тиешле җавабын бирер иде.

Гаяз Исхакый белән Фатыйх Әмирхан да, А. Хәлим фикеренчә, милләт каршында торган чын куркынычны аңламыйча, ягъни руслар белән дус яшәргә чакырып чынбарлыкны "позитивтан негативка, негативтан позитивка" әйләндергәннәр. Алай гына да түгел, заман сулышын аңламыйча, "сәяси сукырлык" күрсәткәннәр. Авторның дәлилләре нинди соң? Г. Исхакый бер әсәрендә "русча укыту сезгә зарар түгел ул!" дип әйткән икән. Шул сүзләре өчен бүгенге кадимчебез классик язучыны тәнкыйтьли. Әмма Г. Исхакый барлык әсәрләрендә русча укып та, татар булып калырга кирәк дип әйтә ич! Икенче урында рус кызын мактап язган өчен А. Хәлим Г. Исхакыйны мыскыллап "урыс әдәбияты классигы була ала" дип яза. Автор фикеренчә, башка милләт кешеләрен, бигрәк тә, рус милләтен, фәкать яманлап-хурлап кына язарга була. Аның сүзләреннән шундый нәтиҗә килеп чыга.

Фатих Әмирхан иҗатына күчеп, ул аның да әдәбият тарихындагы ролен шик астына ала: "Фатыйх Әмирхан татар чынбарлыгына "коммунистик интернационализм" орлыкларын коммунистларның үзләреннән дә алданрак чәчкәне өчен мактала икән. Минем фикеремчә, татар милли публицистикасында һәм романистикасында Фатыйх Әмирханның роле зурдан түгел". Нәрсәгә таянып ясый соң автор мондый "кыю" нәтиҗәне? "Хәят" романында бер персонаж "дускаем, сөю дигән нәрсә милләт аермаларын белми торган көчле нәрсә икән ул",—дип әйткән өчен. Чыннан да, кадимче күзлегеннән караганда, бик зур, кичерелмәслек гөнаһ. Югыйсә, тормыш көн саен киресен раслый.

Шул ук "Хәят" романының икенче бер җирендә берәүнең йорты "рус урамында" урнашкан дип әйтелә. Бу сүзләрдән җене чыгып, автор классик язучыны фаш итә: "Фатыйх Әмирхан "чукындыру интернационализмының" Ильминскийлар тәкъдим иткән ысулларыннан да нечкәрәк ысуллар тәкъдим итә..." Мондый "яңа карашларда", минемчә, ни тарихи дөреслек, ни чама белү юк.

Авторның кискен тәнкыйтеннән атаклы прозаик Шәриф Камал да читтә калмаган. Аның ни гаебе бар, дип сорасагыз, авторның җавабы әзер: "Шәриф әбзи үзе эчкәнмедер, белмим, әмма капиталистик шартларда балык тота башлаган әдип әсәрен аракы белән дыңгычлапмы-дыңгычлый". Әйтерсең, реалист әдибебез реаль тормышка күз йомып, алдап-бизәп язарга тиеш булган!

Классик мирасны күздән кичереп, А. Хәлим хәтта "Идегәй" эпосыннан да гаеп таба. Имештер, эпосның төп каһарманы Идегәй үз иленә каршы сугышкан, Алтын Урда дәүләтен таркатуга китергән. Тарихта бу чыннан да шулай. Әмма эпосның каһарманы халык күңелендә башка яклары белән истә калган. Идегәй образы безнең каршыда батыр рухлы, илен, милләтен кайгыртучы шәхес, курку белмәс сугышчы булып килеп баса. Реаль шәхес белән эпос каһарманы арасында тигезлек билгесе куеп булмый. Эпосны чын милли әсәребез дип тә автор ялгыша. "Идегәй"—бернично милләтнең уртак хәзинәсе. Татар вариантыннан тыш аның нугай, казакъ, каракалпак вариантлары да бар.

Эпостан соңгы дәвер татар әкиятләренә күчеп, автор аларның ясалма булуын, пародия сыман гына янгыравын күрсәтеп китә. А. Хәлим белән килешергә дә булыр иде. Чыннан да, әкият заманы үтте. Әмма автор андый ясалма әкиятләрне чыгаручыларны гына түгел, язып алучыларны да гаепли: "Аны *(әкиятләрне, Р.М.)* яздыручылары гына түгел, язып алучылары да сыйныфсыз, милләтсез, сукбайларга әверелгәннәр. Алар милли зәвык, милли әдәп дигән нәрсәне онытканнар". Хәзерге әкиятләрнең шундый очсыз булуында авылдан авылга йөреп язып алучы галимнәр гаеплеме?

Юк. А. Хәлим тәнкыйть белән генә чикләнми. Кайбер очракта ул кемнедер мактый да. Ләкин монда да ул, кызып китеп, чамасын онытып җибәрә. Әйтик, "диссидент" Салих Батталга кагылып, ул аны "бөек шагыйрь", "Тукайдан кала беренче бишлеккә керә торган сирәктән-сирәк шагыйрь", хәтта "киләчәк шагыйре" дип атый. С. Батталның кыю фикерле, баш бирмәс шәхес булуын мин дә таныйм. Бу турыда аерым мәкалә дә язып чыккан идем *("Татарстан" журналы, 2004 ел, 12-сан)*. Әмма чын шигърият югарылыгыннан караганда аны, минемчә, һич тә бөек дип атап булмый. Шигъри осталыгы чамалы, метафоралары сай, поэмалары артык озын һәм күбесенчә

коры сөйләмгә корылган. Беренче бишлеккә түгел, егерменче бишлеккә дә керүе шикле.

Ә инде чын мәгънәсендәге бөек әдипләргә кучкәч, автор аларны ничек тә түбәнрәк төшерергә, өсләренә күләгә ташларга тырыша. Әйтик, кырыс реалист, тирән прозаик Аяз Гыйләжев, А. Хәлим фикеренчә, "лагерь синдромыннан котыла алмыйча, озак икеләнү аркасында гел генә... сонга калды". Кемнән сонга калган соң әдип? Чыңгыз Айтматовның "Җәмилә"сеннән икән! "Йөгез, бер дога" әсәрен дә А. Гыйләжев "бер утыз гына ел булса да" алданрак язарга тиеш булган икән.

Әмма әдәбият—ат чабышу мәйданы түгел. Монда кем беренче, кем икенче булып килүе дә иң төп максат була алмый. Әсәр тулы канлы булсын, тормыш, кешелек яшәеше турында яналык алып килсен. Һәр әсәр язучы күнелендә үз вакытында өлгерә. Моннан тыш торгынлык чоры шартларын, цензураның ни дәрәҗәдә таләпчән булуын да истән чыгарырга ярамый. Хәзерге сүз ирeге сонрак килде ич! Шундый ук гаепне автор һич нигезсез Фоат Садриевка да ташлый.

Әгәр кемнедер сөймәсән, кемгәдер үч саклап йөрсән, аның гаебен һәрвакыт табып була. Менә, әйтик, тәнкыйтьче һәм Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин талантлы язучы Рафаэль Сибатның вафатыннан соң ихлас күнеленнән, җылы һәм хисси мәкалә белән чыгыш ясады. А. Хәлим исә тәнкыйтьчегә: "ни өчен Р. Сибатның кимчелекләре күрсәтелмәгән", дип бәйләнә. Некролог рәвешендәге язмада кимчелекләр турында язалармыни?! Бу урынсыз гына түгел, әдәпсезлек дип кабул ителер иде.

Жаен табып, А. Хәлим балалар әдәбиятына, аерым алганда, Ш. Галиев белән Р. Миңнуллин иҗатларына кагылып китә. "Әдәбиятта Чуковскийлардан үрнәк алып Шәүкәт Галиев башлап киткән юнәлеш—баланы ничек кенә булса да, "кытыклап" булса да, көчләп көлдерү шаукымы безнең милли идеологиягә, балалар тәрбиясенә зыян китерде". Балаларның иң яратып укыла торган язучысы аларга зыян гына китерә икән! Бигрәк тә Корней Чуковскийлардан үрнәк алгач! Чуковскийны исә рус җәмгыяте генә түгел, бөтен дөнья таный. Бер А. Хәлим танымаудан әллә ни зарар булмас. Ш. Галиев кенә түгел, "котылгысыз шәүкәтист" Роберт Миңнуллин да "ялгыш юлдан" киткән икән. Ул да балаларга вәгазь укымыйча, уйнап-шаяртып кына тәрбияли ич! Юморны аңламаган кеше белән бәхәсләшәсе дә килми. Балалар исә бу әдипләрнең әсәрләрен яратып, чын күнелдән кабул итәләр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк. Һәркем әдәби әсәр турында үз фикерен әйтергә хаклы. Әмма мондый фикер нигезле булмаса, киң масса укучылар фикеренә таянмаса, аның бәясе—базар көнне бер тиен. Субъектив карашлар яшәргә хаклы, шулай да объектив хакыйкать булуын да онытырга ярамый. Кыскасы, субъективизм сазлыгына батмыйча, бәяләмәләрне дөрес кулланыйк, төгәл булыйк!

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# А

**АҖИЕВ** Анвар Абдулгамид улы (10.3.1914, хәзерге Дагстан Респ-касы, Хасавйорт р-ны Костек а.—1991), Дагстан АССРның халык шагыйре (1969). Комык телендә язган. "Яңару" (1934) җыентыгына тау халыкларының яңа тормышка аяк басулары турында, "Чапкын" (1942), "Кылычлар" (1943) җыентыкларында Дагстан халыкларының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары хакында язган. "Йөрәк януы" (1972), "Тәрәзәләрдәге ут" (1980), "Ташчы һәм шагыйрь" (1983) җыентыкларында тупланган шигырьләрдә лирик геройның рухи дөньясына тирән үтеп керү, чынбарлыкны фәлсәфи күзлектән чыгып аңлауга омтылышы күзәтелә. А. иҗатына Тукай шигърияте зур йогынты ясаган. Ул Тукай шигырьләренә нәзирәләр язган, аларны комык теленә тәрҗемә иткән ("Туган тел", "Казан", "Государственная думага", "Бер татар шагыйренең сүзләре" һ.б.).

Әсәр.: Сайламлы йырлар. Магъачкъала, 1954.

**АИТОВ** Аитзәк (1908, хәзерге Саратов өлкәсе, Дергач р-ны Алтата а.—28.10.1941), шагыйрь. 1928 елдан комсомол эшендә. 1930 нчы елларда А.ның күмәкләшү, комсомоллар тормышы турындагы, патриотизм белән сугарылган шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә басыла. Алар 1961 елда чыккан "Алар сафта" исемле күмәк җыентыкка да кертелә. Смоленск өлкәсе Демидов ш. өчен барган сугышта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**АЙДАР** (Айдаров) Әсгать Харис улы (6.6.1906, Самара губ-сы Иске Сорочино а.-24.1.1959), язучы. Әсәрләре 1928 елдан басыла башлый: "Әсгать Айдар шигырьләре" (1928), "Барабызлар турында" (1929) шигъри җыентыклары, балалар өчен "Ташбай" (1932) повесте, армия хезмәте турындагы "Соңгы сулышта" (1935) хикәясе, геологлар турындагы "Таулар легендасы" (1960, рус теленә тәрҗемә 1964) повесте. 1935–38 елларда нахакка репрессияләнә. Шул сәбәпле 1940 та Казаннан китәргә мәҗбүр була. Бөек Ватан сугышында катнаша. Гомеренең соңгы елларында Үзбәкстанда яши.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**АЙМАНОВ** Якуб (1891, хәзерге Казакъстан Респ-касы Талды-Курган ш.—2.11.1937, шунда ук, Павлодар ш.), шагыйрь. "Галия" мәдрәсәсендә укый. 1920–30 елларда Павлодарда урта мәктәп директоры. Шигырьләре "Кояш" г-тасында һәм "Шура" ж-лында басыла. "Табигать" (1913) исемле шигырьләр җыентыгында Казакъстан һәм Алтай табигатенә мәдхия җырлый. "Саман" поэмасы—төркиләрнең борынгы тарихына багышлана. А.ның романтик характердагы шигъриятендә Тукай иҗатының йогынтысы сизелә. Нахакка репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Табигать. Уфа, 1913; Хөрмәтле шагыйремез Тукаевка // Кояш. 1913. 9 апр.; Саман. Семипулат, 1914; Шигырьләр // Мирас. 1998. № 3.

Әд.: Мусин Г. Яңа юлда // Йолдыз. 1915. 23 окт; 29 окт; Рәмиев З. Алтайлы татар шагыйре. // Казан утлары . 2001. 11 сан.

*З.З.Рәмиев.*

**АЙТМАТОВ** Чыңгыз Төрәкол улы (12.12.1928, хәзерге Кыргызстан Респ-касы, Киров р-ны Шекер кышлагы), язучы, Кыргызстан ССРның халык язучысы (1968), Кыргызстан ССР ФА нең хакыйкый әгъзасы (1974). Кыргыз һәм рус телләрендә яза. Авыл хуҗалыгы ин-тын (1953), М.Горький исем. Әдәбият ин-туты каршындагы Югары әдәбият курсларын (Мәскәү) тәмамлый. 1988–90 елларда "Иностранная литература" ж-лының баш мөхәррире, 1990–94 тә СССР һәм РФнең Люксембургтагы илчесе, 1994 елдан башлап Франция һәм Бенилюкс илләрендә (Бельгия, Нидерланд, Люксембург) Кыргызстан илчесе. Әсәрләре 1952 дән ба-

сылып килә. "Җәмилә" (1958), "Хуш, Гөлсара!" (1966), "Ак пароход" (1970) повестьлары, "Гасырдан да озын көн" (1980), "Ахырзаман" (1987) романнары авторы. Психологик портрет остасы. А. иҗатының төп проблемасы—кеше һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтләре. А.ның әсәрләренең геройлары—үзе яшәгән чорның актив, көчле рухлы замандашлары. "Кызыл яулыклы гүзәлкәем", "Беренче укытучы", "Анам кыры" повестьлары һ.б. татар теленә тәрҗемә ителгән. "Кызыл яулыклы гүзәлкәем" ("Гүзәлем Әсәл", 1966), "Ахырзаман" (1987) әсәрләренә нигезләнеп эшләнгән спектакльләр Татар академия театры сәхнәсендә, "Анам кыры" (1971) Әлмәт татар драма театрында зур уңыш казандылар. 1966—89 да СССРның ЮС депутаты, 1989—92 да СССР халык депутаты. Ленин бүләге (1963), СССР Дәүләт бүләкләре (1968, 1977, 1983) лауреаты.

Әсәр.: Собр. соч.: В 3 т. М., 1982—84; Плаха. Буранный полустанок: Романы. Днепропетровск. 1989.

Әд.: Гачев Г.Д. Чингиз Айтматов (В свете мировой культуры). Фр., 1989; Акматалиев А.Л. Чингиз Айтматов и взаимосвязи литератур. Бишкек, 1991.

**АЙТУГАНОВ** Ләбиб Кәрам улы (21.10.1935, Әгерҗе р-ны Нарат а.—24.3.1964, Казан), шагыйрь, композитор, журналист. 1959 елда Казан педогогия ин-тын тәмамлый. 1957 елдан алып ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында музыкаль тапшырулар редакторы булып эшли. Беренче шигырьләре 1950 елларда "Яшь сталинчы" газетасында басыла башлый. "Төнбоек" (И.Юзеев шигыре), "Юллар" (Ә.Ерикәй шигыре), "Безнең күңелләр" (Р.Гарипов шигыре) кебек халыкчан көйләр, "Һаман истә" (И.Шакиров көе), "Ышанам" (Р.Еникеев һәм Р.Яхин көе), "Сандугач җыр суза" (А.Монасыйпов көе) җыр текстлары авторы. Аның җырлары "Һәрвакыт истә" (1972), "Ышанам" (1995) җыентыкларында тупланган.

Әд.: Исрафилов М. Күңелемдә күпме моң бар //Әгерҗе хәбәрләре. 1995. 17 окт.

**АКБИЕВ** Солтанмурад Хаҗак улы (18.7.1938, Дагстан АССР, Хасавйорт р-ны Боташйорт а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1989), проф. (1990), Дагстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1994). Дагстан ун-тын тәмамлый (1967). 1982 елдан Дагстан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре комыкларның гарәпчә язма әдәбияты тарихына, Россия халыкларының әдәби бәйләнешләренә карый. Кол Гали, К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил иҗаты буенча мәкаләләр авторы.

Хезм.: Дагестано-татарские литературные связи XIX—начала XX веков: Дис. А.-А., 1989.

Әд.: Исламов Ф. Әдәбиятлар дуслыгын яктыртучы хезмәт // Казан утлары. 1988. N 5.

**АКМАЛОВ** Нияз Рәшит улы (14.2.1954, Сарман р-ны Каташ-Каран а.), язучы. 1976 елда Казан ун-тын тәмамлый. "Яшь ленинчы" г-тасы (1979-87), "Казан утлары" ж-лы (1987-91), "Татарстан хәбәрләре" г-тасы (1991-95), 1995 елдан "Мәдәни Җомга" г-тасы редакцияләрендә эшли. Язмалары 1970 еллардан бирле басылып килә. А. шигырьләренә нечкә лиризм, фикер тирәнлеге хас. Аның туган җиргә мәхәббәт хисләре, гражданлык рухы белән сугарылган шигырьләре, балладалары "Учак" (1986), "Килер бер көн" (1988) китапларына тупланган. А. хәзерге заман кешеләренең катлаулы язмышларын бәян иткән, кискен сюжетка корылган детектив характердагы проза әсәрләре дә яза. Аның "Үз урамым" (1991), "Күгәрчен сөте" (1993), "Бохара мачысы" (1999) кебек хикәя һәм повесть җыентыклары шундыйлардан. Публицистика өлкәсенең төрле жанрларында да А. уңышлы иҗат итә. Көндәлек матбугатта аның памфлет һәм фельетоннары, татар мәдәниятының күренекле вәкилләре турында язылган очерклары еш басылып килә.

Әд.: Гыйльман Г. Осталык // Заман сүз сорый. К., 1991.

*Автор: Г.М.Габделхакова*

**АКМУЛЛА** (тәхәллүс; чын исеме Мифтахетдин Камалетдин угылы) (27.12.1831, Туксанбай а., Оренбург губ., Бәләбәй өязе, хәзер Башкортстан Рес-ның Миякә р-ны—8.10.1895, Миасс ш.), татар шагыйремәгърифәтче, чичән. Иҗат мирасы башкорт һәм казакъ әдәбиятларының да уртак хәзинәсе буларак тәкъдир ителә. Авыл имамы гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне Ябалактамак авылында ала, аннан Мәләүзтамак, Әсән, Эстәрлебаш авыллары мәдрәсәләрендә һәм Троицк мәдрәсәсендә укый. Шагыйрь һәм дин галиме Шәмсетдин Зәкинең шәкерте. Троицкида дин гыйлемен Зәйнулла ишан Рәсүлидән өйрәнә. Мәдрәсә елларында җәйләрен казакъ далаларында мөгаллим-

лек итә. Соңга таба Көнбатыш Себер, Казакъстанның төньяк-көнбатыш төбәкләрендә балалар укыта, халык арасында татар мәгърифәтчеләренең фикер-карашларын таратып йөри. Сүздә тугрылыгы һәм гаделлеге өчен Акмулла кушаматы алып, үз заманы өчен кыю фикерләре белән таныла. Гаскәри хезмәттән качып йөри дигән әләк б-н кулган алынып, 1867—71 елларда төрмәдә утыра (сәбәбе Зәйнулла ишан б-н элемтәдә булганы өчен дигән фаразлар да бар). Төрмәдә чагында атаклы "Төрмә шигырьләре"н иҗат итә. 1871 елда А.ярлыкау сорап гариза яза һәм залог кертү шарты б-н иреккә чыгарыла. Әмма шагыйрь, үзен бөтенләй аклауларын теләп, соңгы казакъ ханнары токымыннан булган ген.-полковник Гобәйдулла Букиевка мөрәҗәгать итә, аңа мәдхия багышлап, аның бу эштә ярдәмен сорый. Генерал, шагыйрьнең гозерен тыңлап, патша тәхете тирәсендәге элемтәләре аша эш йөртеп, А.ны ярлыкау турында патша Александр II нең фәрман чыгаруына ирешә. Бер елдан А. Петропавел (Кызылъяр) шәһәрендәге Рәхмәтулла имам мәдрәсәсенә мөгаллим булып урнаша, аннары Күкчәтау шәһәре тирәсендәге авылларда мәгариф эшчәнлеген дәвам иттерә. 1894 елда А. Уфа шәһәрендә Риза Фәхретдин б-н очраша. Мәгърифәтче галим аңа шигырьләрен чыгарышуда ярдәм кулы сузарга вәгъдә итә, әмма шагыйрьнең фаҗигале үлеме бу эшне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми. А. 19 йөз татар поэзиясендә Шәрекъ һәм Көнбатышның фәлсәфи фикер казанышларын бергә кушу, синтезлау җирлегендә шигырьдәге традицион жанрларны халык авыз иҗаты, хикмәтле сүз хасиятләре б-н баетуның гармоник үрнәкләрен биргән шагыйрьләрнең берсе булды. Аның шигъри иҗаты фикер тирәнлеге, эчтәлегенең заманча булуы, телсурәтләү чараларының образлы, афористик, үткен, эмоциональ лирик бизәкләргә бай булуы, фәлсәфи фикернең, публицистик һәм лирик башлангычларның, сатираның шигырь тукымасында гаҗәеп табигый яңгырашта гәүдәләнүе б-н үзенчәлекле. Катлаулы фикерләрне дә А. укучыга тел-стиль чаралары б-н җиңел аңлаешлы итеп җиткерә белә. Иҗатында ул гади кешеләрнең теләк-омтылышларын чагылдырды, аларны белемгә, мәгърифәткә өндәде, кеше шәхесенең рухи хөр булырга тиешлеге идеяләрен раслады. Мәгърифәт, гаделлек өчен көрәшүче шагыйрь образы аның төрмә шигырьләрендә аеруча ачык сизелә: ул тормыштагы золымны, мәрхәмәтсезлек күренешләрен ачы тәнкыйтьли, бер үк вакытта кеше акылының, гаделлекнең җиңеп чыгачагына тирән ышанычын белдерә. А. фикер ияләреннән бигрәк тә Ш.Мәрҗанине үзенә остаз итеп саный, аңа багышлап үзенең мәгълүм мәрсиясен яза, анда Казанны татар мәдәниятенең үзәгенә тиңләп, үзен шул мәдәниятнең бер вәкиле итеп күрә. Әлеге мәрсия—А.ның үзе исән чакта басмада дөнья күргән бердәнбер әсәре. Иҗатында иске карашлы дин әһелләрен кискен тәнкыйтьләп, А. аларга каршы ислам дөньясының үткәндәге бөек галимнәрен, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм замандашларыннан М.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин образларын үрнәк итеп куя. Әсәрләре өчен тема һәм сюжетларны А. реаль тормыштан—19 йөзнең 2 нче яртысындагы чынбарлыктан алган; алар егерменче гасыр башында да бик актуаль яңгырап, укучыларда зур кызыксыну уятканнар. Вафатыннан соң, 1904, 1907 елларда шагыйрьнең тагын ике җыентыгы дөнья күрә. А.ның күпчелек әсәрләре төрки халыклардагы чичәннәр, акыннар иҗаты традициясе калыбында язылганнар, ятлау өчен алар бик җиңелләр. Теле—катнаш казакъ-татар теле, арада башкорт сөйләше элементлары да очрый. Әсәрләреннән кайберләре исә саф иске татар әдәби теле традициясендә язылганнар һәм хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраштырмыйча да укучыга җиңел аңлаешлылар.

*Әсәрләре*: Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе. К., 1892; Акмелла әфәнденең иншад итдеке мәнзуматилә башка бер кач мөншәдатене кәндесенең тәрҗемәи халене мөштәмил мәҗмугадыр. К., 1904; Акменланың Шиһабетдин әл-Мәрҗани мәрсиясе вә башка шигырьләре. К., 1907; Өлеңдер жыйнағы. Алматы, 1935; Шиғырьзар. Өфө, 1981; Шигырьләр. К., 1981; Күндер мен түндер. Өлеңдер, толғаулар, термелер, айтыс. Алматы, 1986; Стихи. Уфа, 1986.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Гайнуллин М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. К., 1968; Госманов М. Мифтахетдин Акмулланың иҗаты һәм мирасы // Акмулла. Шигырьләр. К., 1981; Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла. Тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. К., 1983; Әхмәтев Р. Мифтахетдин Акмулла // Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Миңнегулов Х. "Милләт өчен зарлы" Акмулла

// Дөньяда сүземез бар... К., 1999; Харисов Ә.И. Башкорт халкының әдәби мирасы. Өфө, 1965; Вильданов Ә.Х. Акмулла—яктылык йырсыһы. Өфө, 1981; Калижанов У. Агартушы—демократ акын // Акмола. Күндер мен түндер. Алматы, 1986.

*Р.Ә.Әхмәтев.*

**АКСАКОВ** Сергей Тимофеевич (1.10.1791, Уфа ш.—12.5.1859, Мәскәү), язучы. 1801–05 елларда Казанның беренче ирләр гимназиясендә, 1805–07 дә Казан ун-тында укый. А.ның дөньяга карашлары педагоглар Г.И.Карташевский һәм Н.М.Ибраһимов йогынтысында формалаша. Язучының әдәби, театраль, фәнни карашлары студент елларында ук тәгаенләнә. 1807 дән ул "Рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте" әгъзасы. А.И.Панаев (шагыйрь И.И.Панаевның бертуганы) б-н кулъязма ж-ллар, ш.и. "Журнал наших занятий" ("Безнең көнегүләр журналы", 1806–07) чыгара, анда үзенең беренче шигырьләрен урнаштыра. К.Ф.Фукс йогынтысында күбәләкләр җыю, табигатьне өйрәнү б-н мавыга. Болар барысы да А.ның язучы-реалист булып формалашуына тәэсир итә. Ун-т каршындагы студентлар театрын җитәкли, спектакльләрдә үзе дә катнаша. 1807 дә, укуын тәмамламыйча, А. С.-Петербургка күчә. 1801–15 еллар вакыйгаларын яктырткан "Истәлекләр" ("Воспоминания", 1856) һәм "Күбәләк җыйганда" ("Собирание бабочек", 1859) хикәясендә А. гимназия һәм ун-т тормышын киң яктырта, укытучыларга бай характеристикалар бирә. А.нең әсәрләре Казан ун-ты тарихын, 19 йөз башында Казанның мәдәни тормышын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора. А. үзенең кеше, язучы буларак формалашуын Казан гимназиясендә һәм ун-тында укуы белән бәйләп: "Күңелемдә сакланып калган яхшы сыйфатларыма мин гимназиягә, университетка, укуыма, анда хөкем сөргән якты бер җанлылыкка бурычлымын",—дип яза.

Әсәр.: Собр. соч.: Т.1–4. М., 1955–56.

Әд.: Архангельский А.С. С.Т.Аксаков: Детство и студенчество: 1791–1807 // Русское обозрение. 1895.N 7–9; Машинский И.С. С.Т.Аксаков. Жизнь и творчество. М., 1973; Аристов В.В. Первое литературное общество Поволжья. К., 1992.

*Л.Е.Бушканец.*

**АКСЁНОВ** Василий Павлович (20.8.1932, Казан), язучы. П.В.Аксёнов һәм Е.С.Гинзбургның улы. Ата-анасы кулга алынганнан соң (1937) туганнарында тора. 1950 елда Казан мед. ин-тына укырга керә, 1954 тә Ленинград мед. ин-тына күчә. Укып бетергәннән соң табиб булып эшли. 1960 тан Мәскәүдә яши. 1960 елларда яшьләр прозасында билгеле бер урын алган "Хезмәттәшләр" ("Коллеги", 1960), "Йолдызлы билет" ("Звёздный билет", 1961), "Марокко әфлисуннары" ("Апельсины из Марокко", 1963), "Вакыт җитте, дустым" ("Пора, мой друг, пора", 1965), "Тулган мичкә" ("Затоваренная бочкотара", 1968), повестьлар авторы. "Безнең алтын тимеребез" ("Золотая наша железка", 1975), "Пешкән җәрәхәт" ("Ожёг", 1976), "Кырым утравы" ("Остров Крым", 1977), "Жанрны эзләү" ("Поиски жанра", 1978) романнарында һәм повестьларында зыялыларның "җепшек чоры" (1960 нче еллар) эзләнүләре тасвирлана. "һәр вакыт сатуда" ("Всегда в продаже", 1969), "Дүрт темперамент" ("Четыре темперамента", 1978), "Торна" ("Цапля", 1980) пьесалары авторы. Иҗатының башлангычында ук Көнбатыш әдәбиятына йөз тоткан А.ның беренче повестьларында ук модернизм элементлары күренә башлый. Аны рус модернизмы традицияләрен дәвам итүче дип санарга мөмкин. 1980 нән А. Джорж Мейсон ун-ты (Вашингтон) профессоры. Чит илдә дә, иҗатында башлыча рус темасын яктырта: "Кәгазьле күренеш" ("Бумажный пейзаж", 1982), "Йөзем дип әйт" ("Скажи: изюм", 1985), "Мәскәү кыйссасы" ("Московская сага, 1991), "Желток яйца" ("Йомырка сарысы", 1989), "Яңа татлы стиль" ("Новый сладостный стиль", 1996) романнарын яза. Тормышының Казан дәвере истәлекләре Россиядән киткәнче үзенең биографиясеннән һәм Казандагы туганнары, дуслары тормышыннан чыгып язылган "43 нче елның иртәнге ашлары" ("Завтраки 43-го года", 1962), "Мәйданда һәм елганың ары ягында" ("На площади и за рекой", 1967), "Ишек алдыбызның бакырбашы" ("Рыжий с нашего двора", 1967), шулай ук инде АКШта басылган "Зөя" ("Свияжск", 1981), "Моңсу баланы эзләгәндә" ("В поисках грустного бэби", 1985), "Йомырка сарысы", "Яңа татлы стиль" әсәрләрендә урын алган. 2002 елдан Франциядә (Биарриц ш.) яши.

Әсәр.: Собр. соч. Т.1–5. М., 1995.

Әд.: Глэд Джон. Беседы в изгнании: Русское литературное зарубежье. М., 1991.

*Е.С.Тимофеева.*

**АКЧУРИНА** Мәхбүбҗамал (март 1869, Сарытау губ., Кузнецк өязе Димау а.—1948, Баку ш.), язучы. Сембер сәүдәгәрләре Ак-

чуриннар нәселеннән. 1908 елдан башлап "Шура" һәм "Сөембикә" ж-лларында язы-ша башлый. Игътибарын татар җәмгыя-тенең 20 йөз башындагы иҗтимагый һәм әхлакый проблемаларына—балалар тәрбия-ләүгә, татар хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урынына һ.б. юнәлтә. "Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә" (1914), "Шәфкать-сез ата яки мишәрләр тормышы" (1914) исемле хикәяләре тормыштан алынган ре-аль фактларга нигезләнеп язылган. "Сәйфелмөлек", "Таһир һәм Зөһрә" дастан-нарын өйрәнеп, татар халык иҗаты әсәрләренең балаларны әхлакый һәм эс-тетик яктан тәрбияләүдә әһәмияткә ия бу-луын күрсәтә. 1929 елда А. Бакуга күчә, әдәби эшчәнлектән читләшә.

Әд.: Гайнуллин М. Татар әдипләре. К., 1978; Өмет йолдызлары. К., 1988.

**АКЪЕГЕТЗАДӘ** (Акъегет, Акҗегетев) Муса Мөхәммәдҗан улы (3.12.1864, Пенза губ., Чембар ш.—24.9.1923, Истанбул), язучы, журналист, икътисадчы галим. Бабасы Ал-тынбай Акъегетев 1812 елгы Ватан сугы-шында күрсәткән батырлыгы өчен дворян-лык дәрәҗәсен алган була. Муса әүвәл әти-сенең туган авылы Мочалида (Чембар өязе) татарча укый, аннары Чембарда (хәзерге Белинский ш.) рус мәктәбендә, аннан соң Пен-за шәһәре гимназиясендә белем ала. 1884 елда гимназияне тәмамлагач, туган төбәге авылларында мөгаллимлек итә. 1886 елда Кырымга күчеп, "Тәрҗеман" газетасына эшкә урнаша. 1888 елдан А. Төркиядә. 1888—91 елларда дәүләт оешмалары өчен югары белемле хезмәткәрләр әзерли тор-ган "Мөлкия" мәктәбендә укый. Рус, гарәп, төрек, француз телләрен өйрәнә. Мәктәпне тәмамлагач, Истанбулдагы Югары Хәрби мәктәптә һәм Хәрби академиядә рус теле һәм икътисад фәнен укыта, "Мәтен" ("Асыл нөсхә"), "Өч кардәш" исемле газеталар нәшер итә, Измир һәм Сивас шәһәрләрендә җирле идарә оешмаларында эшли. 1914 елда Истанбулга кире кайтып, гомеренең ахырынача Казаннан сатып алынган Н.Ф.Катанов китапханәсендәге кулъязма һәм китапларны барлау, тәртипкә салу, ка-талогларын төзү эше б-н шөгыльләнә. А. татар әдәбияты тарихында мәгърифәтче-лек реализмы юнәлешендә язылган "Хи-саметдин менла" (1886) беренче роман ав-торы буларак билгеле. Язучы романда үз заманының татар тормышына кагылышлы күп мәсьәләләрне күтәрә, яңалыкка, белемгә омтылучы яшь геройлары аша милләтнең киләчәк язмышы турында кайгыртып яза. Роман укучылар арасында зур уңыш каза-на, әсәр төрек теленә дә тәрҗемә ителә. Г.Ибраһимов А.ны "татар реализм әдәбия-тының атасы" дип бәяләде. А. нигез сал-ган релистик роман традицияләре соңга таба З.Бигиев, Ф.Кәрими, Р.Фәхретдин, Г.Ис-хакый һ.б.лар тарафыннан дәвам иттерел-де. Фәнни-публицистик хезмәтләрендә А. Шәрекъ мәдәниятенең дөнья цивилизаци-ясенә керткән өлеше турында кат-кат искәртә. Аның "Аурупа мәдәниятенең әса-сына бер нәзар" ("Европа мәдәниятенең нигезенә бер караш") исемле хезмәте Төркиядә аерым китап булып чыга,өзекл-әре "Әлгасрелҗәдид" ж-лында басыла (1906). Икътисад фәнен, аның классик вәкилләре Адам Смит, Давид Рикардо һ.б. галимнәрнең хезмәтләрен тирәнтен өйрәнү аңа "Икътисад, яхуд Гыйльме сәрвәт" ("Икътисад, яки баю гыйльме") исемле мо-нографиясендә (1918) кайбер икътисади тәгълиматларга фәнни-тәнкыйди анализ ясарга юл ача. А. нең фикер-карашлары 20 йөзнең беренче яртысында Төркия Рес-публикасы икътисадын яңартуда киң фай-даланыла.

Әсәре: Хисаметдин менла. К., 1886.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Миңнегулов Х. Татар реализм әдәби-ятының атасы // Татарстан. 1996. N 5; Әйди Т. Муса Акъегет Төркиядә // Казан утла-ры. 1996. N 4; Өлкән Х.З. Муса Акъегет / / шунда ук. 172—178 б.; Гайнуллин М.Х. Татар әдипләре. К., 1978; Газизуллин Ф.Г. Социально-экономическая мысль татарс-кого народа как феномен его духовной культуры. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Җиңүнең 60 еллыгына*

# ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ— ФРОНТ СӘХИФӘЛӘРЕ

*"Еллар үтәр, тарихчылар безнең газетабызның саргайган битләрен дулкынланып актарырлар, хәрби язучыларыбызның һәм журналистларыбызның иң кечкенә генә хәбәрләрен укып та:*

*—Нинди изге, нинди бөек эш эшләгәннәр!—дип, аларның исемнәрен бик зур хөрмәт белән телгә алырлар".*

**Афзал Шамов***

Әйе, еллар үтә тора. Һәм еллар үткән саен без халкыбызның Бөек Ватан сугышында—фронтларда күрсәткән батырлыкларының әһәмиятен, кадерен, аның бөеклеген аңлаганнан-аңлыйрак барабыз сыман.

Шәт, шулай икән, бүгенге буын кешеләренең баһадир уллары һәм кызларның фронтта күрсәткән батырлыклары турында тагын да күбрәк белергә теләве бер дә гаҗәп түгел. Бөек Ватан сугышы чорына караган һәр документ, һәр тарихи факт,—зурысы һәм кечесе,—һәркайсысы яшь буынны Ватаныбызның чын гражданины итеп, патриотик рухта тәрбияләү чарасы буларак аеруча кадерле һәм алыштыргысыз хәзинәдер.

Мәгълүм ки, ВКП(б) Үзәк Комитеты 1942 елның 6 февралендә кабул иткән "Матбугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары турында" дигән карарында: "...Кызылармеецларны аларның үз ана телләрендәге газеталар белән тәэмин итү өчен бөтен чаралар күрергә",—дип билгеләнә *(О партийной и советской печати // Сборник документов.—М., 1954.—С. 291).*

Шул бурычны гамәлгә ашыру максатыннан чыгып, фронтларда 1942 елдан милли телләрдә хәрби газеталар чыгарыла башлый.

Татар телендә фронт газеталары 1942 елның июленнән дөнья күрә һәм алар тиз вакыт эчендә сугышчылар арасында зур популярлык казанып өлгерәләр. Татар язучылары, журналистлары сугышчылар белән бер сафта атакага баралар; хәрби операцияләрдә катнашалар; дошман уты астында окоптан-окопка йөреп, фашистларга каршы аяусыз сугышкан батыр солдатлар һәм офицерлар белән турыдан-туры танышып, татар халкының баһадир уллары турында хәбәрләр җыялар. Аларның күпчелек әсәрләре җилле-яңгырлы окопларда, дошман уты астында языла. Бу хәбәрләр, газета аркылы фронтның бөтен почмакларына ирешеп, сугышчыларны тагын да рәхимсезрәк көрәшләргә рухландырып торган.

Фронт газеталары әнә шулай туа, радио дулкыннары аша барлык фронтлардан алынган иң соңгы хәбәрләр, фронтлардагы уңышлар турындагы мәгълүматлар, Верховный Баш Командующий приказлары, төн эчендә кургаш хәрефләргә әйләнеп, басу машинасына керәләр. Иртән кызарып кояш чыкканда, газеталар төрле частьларга тарала башлый.

Бөек Ватан сугышы елларында фронтларда 16 исемдә татар телендә газеталар чыга.




**I. "ВАТАН ӨЧЕН"**—Төньяк-Көнбатыш фронтта 1942 елның 10 июлендә татар телендә чыга башлаган беренче фронт газетасы. Газета

*Алга, дошман өстенә. – 1944. – 5 май. – 4 б.

1944 елның апреленә кадәр дөнья күрә. Газета редакциясе Старая Руссадан Житомирга кадәр зур һәм данлы юл үтә. Редакциянең адресы: башта—557 кыр почтасы, 652 бүлек; аннары—18 715-А кыр почтасы.

Газета атнага ике тапкыр рус, татар, латыш, литва, үзбәк, казакъ телләрендә дүртәр битле булып чыга. Форматы—42х30 см.

Җаваплы редактор булып рус газетасы редакторы санала. Газетаның татар редколлегиясе составында редактор урынбасары булып журналист капитан Гани Гыйльманов, хәрби корреспондентлар булып язучы Хатип Госман, яшь шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, журналист А. Әхмәдиев, Нәфыйк Яһудин (сугыш алдыннан Арча ягында укытучы) эшлиләр. Бу редакциягә Казаннан партиянең Өлкә Комитеты командировкасы белән танылган язучыларыбыз Гомәр Разин (бу Гомәр Бәшировның шул вакыттагы тәхәллүсе) һәм Мирсәй Әмир киләләр, ике айга якын анда хезмәт итәләр.

Хатип Госман һәм Гомәр Разин редакциягә 1942 елның август ахырында килеп эшкә керешәләр *(ТР ның Милли архивы.—7083 фонд, 2 тасв, 32 сак. бер. 8,10 бит).* Х. Госман көрәшкә рухландыргыч шигырьләр, хикәяләр, очерклар яза. Аның 1942 елда "Безнең батырлар", "Сакта", "Корыч ташкыны", "Элемтәче Ильяс", "Синең бурычың", "Фронт кызы" һәм башка шигырьләрен солдатлар яратып укыйлар. Аның окопта язган хикәяләре, очерклары халыклар дуслыгы идеясе белән һәм тирән патриотизм хисе белән сугарылган: "Халкыбызның батыр уллары кебек сугышыгыз" *(1942, 28 июль),* "Кеше ашаучылар" *(1942, 20 ноябрь)* кебек хикәяләре, разведчик Заян Хәкимов турындагы "Сугышта чыныккан йөрәк" *(1942, 8 сентябрь; автордаш Г. Разин),* снайпер Насыйр Юнысовка багышланган, "Һәр тамчы кан өчен" *(1942, 11 сентябрь),* "Өлкән кардәшебез" *(1944, 1 апрель),* "Гарасат уллары" *(1944, 5 апрель)* һ. б. очерклары әнә шундыйлардан. Х. Госман 1943 елда "Ялкынлы йөрәк" исемле повестен төгәлли.

Гомәр Разин исә, редакциянең эшен җайга салуда булыша, совет солдатларының батырлыклары турында очерклар яза, фронт тормышыннан бай материал җыя. Аның газета битләрендә басылган әсәрләре түбәндәгедән гыйбарәт: "Татарстанның бүгенгесе" исемле мәкалә *(1942, 28 август),* "Пулеметчының сугышчан көннәре" *(1942, 4 сентябрь),* "Сугышта чыныккан йөрәк" *(1942, 8 сентябрь; автордаш Х. Госман),* "Гармоньчы егет" *(1942, 6 октябрь),* "Бер көнне шулай.." *(1942, 30 октябрь; снайпер Шәяхмәтов сүзләреннән),* "Сержант Хәйруллин" очерклары һ. б.

Кызыл сугышчы Шәрәф Мөдәррис 1942 елның сентябреннән фронт газетасы редакциясенә штаттан тыш кабул ителә һәм баштарак корректор булып эшли. Аның бу газета битләрендә "Ул үч алыр" *(1942, 2 октябрь),* "Онытылмас хәлләр" *(1942, 17 ноябрь),* "Армия, алга" *(1943, 19 февраль)* "Татарстан чәчәкләре" *(1943, 19 февраль, шинель кигән совет кызлары турында очерк),* "Ватан" *(1944, 25 март),* "Зур һәм данлы юл" *(1944, 1 апрель)* кебек шигырьләре, очерклары, мәкаләләре басыла.

Солдат-шагыйрь сугыш кырларында үзенең ялкынлы әсәрләрен—шигырьләрен, поэмаларын, хикәяләрен иҗат итә, аларда Ватан сугышы героикасын, солдатлар тормышын тирән яктыртуга ирешә. Мәсәлән, "Таныш куак", "Аерылу моңы", "Ярсый йөрәк" *(1942),* "Корыч каска", "Минем моңым", "Севастополь", "Ельня, Ельня!", "Синең сүзең", "Землянкада", "Кинҗәбулат", "Сукыр лампа", "Сапер", "Киткәндә", "Смоленщина", "Гөлбәдәр", "Тантана" *(1943)* әсәрләре әнә шундыйлардан. 1943 елның 7 июлендә Шәрәф Мөдәррис Хәсән Хәйригә фронттан җибәргән хатында болай дип яза: *"Үзебез шулай бер көе эшләп ятабыз. Хатип та зур гына әйберләр эшли. Мин дә карап тормыйм. Менә сиңа истәлек өчен үземнең "Тупчы Ваһап" исемле поэмамны һәм рус телендә басылган әйберләремнең иң соңгысын җибәрәм ("Певец русской славы").*

*Хәзер Ватан турында югары аһәнле, ялкынлы рухлы олы гына бер поэмага йөкле булып йөрим. Һәрхәлдә, мин аны ике айлардан Союзга җибәрү бәхетенә ирешермен, дип уйлыйм".*

1943 елның 11 февралендә Мирсәй Әмир дә бу газета редакциясенә эшкә китә *(Әдәбият баскычлары // Татар совет әдәбияты елъязмасы.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1976 218 б.).* Шушы газета битләрендә ул Совет кешеләренең сугыш кырындагы батырлыкларын, югары рухи-әхлакый сыйфатларын, тормышка, туган җиргә

мәхәббәт хисләрен тасвирлаган очеркларын һәм хикәяләрен бастыра. Мәсәлән, "Гөрли Казан" *(1943, 19 февраль)*, "Үлемгә бирмәс ул" *(1943, 6 март)*, "Дошман көтмәгәнчә" *(1943, 12 март)*, "Агитатор" *(1943, 19 март)*, "Курай" *(1943, 6 апрель)*, "Коттыбай батыр" *(1943, 1 май)*, "Мөстәкыйм карт йокысы", "Сыерчык", "Бабайлар" һ. б.

"Курай" дигән язмасында әдип гади генә деталь аркылы фронтовикларнын бай эчке дөньясын ачуга ирешә. Солдат Йомагужа Маликов, гомерен куркыныч астына куеп, камышлар арасына керә дә аю кураен кисеп ала һәм туган як көйләрен сыздырып җибәрә. Әлбәттә, бу көй командирларны да, сугышчыларны да дулкынландыра, әсәрләндерә. Алар кырыс фронт шартларында да кешедә була торган нечкә хисләрне түкми-чәчми саклаганнар лабаса, яу кырында да алар илебезнен гүзәллеген искә төшерәләр.

"Ватан өчен" газетасы битләрендә М. Әмир "Чаян фронтта" дигән бүлек ачып, фашистларга яшен уты булып өркелеп торган үткен һәм тапкыр сатираны җанландырып җибәрә, моңа ирешү өчен ул күп кенә халыкчан алымнар куллана. "Әйдә, шулай булсын" *(1943, 19 февраль)*, "Тотса Мәскәүләр якан", "Немецча бишек җыры" *(1943, 23 февраль)*, "Фриц-фриц сүзеннән чыкмый", "Кем нәрсә күтәрә", "Урманда" *(1943, 12 март)* кебек әсәрләрдә бу бигрәк тә ачык чагыла.

1942 елның 6 ноябрь санында шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең Советлар Союзы Герое Салават Кәримов турындагы "Баһадир" исемле язмасы басылып чыга. 1943 елның 19 февраль санында Кави Нәҗминең "Очучылар җыры" исемле шигыре дөнья күргән, ә 1943 елның 6 апрелендә Идрис Туктаровның "Ягымлы сүзләр" исемле хикәясе һ. б. урын алган.

Бу газета битләрендә юстиция өлкән лейтенанты Мостафа Ногман, командир-зенитчы Нур Гайсин үзләренең патриотик шигырьләре белән катнашалар, шунда ук Атилла Расихның хикәяләре дә басыла.




**II. "АЛГА, ДОШМАН ӨСТЕНӘ"**— 1942 елның ноябрендә Калинин фронтында татар телендә шушы исемдәге икенче фронт газетасы чыга башлый. 1943 елның 20 октябрендә Калинин фронты үзенең тарихи яшәвен төгәлләгәч, газета исемен үзгәртмичә, Беренче Балтыйк буе фронты карамагына күчерелә. Ул 1945 елның 5 июненә кадәр чыгуын дәвам итә. Татар телендә газетаның 308 саны, а рус телендә 386 саны чыгып кала.

Бу газета Мәскәү яныннан Балтыйк диңгезенә кадәр 1295 километрга сузылган зур, авыр һәм данлы тарихи юл уза. Калинин, Ржев, Духовщина (Смоленск өлкәсе), Невель (Великие Луки өлкәсе), Витебск, Полоцк, Паневежис, Шауляй, Мемель (хәзерге Клайпеда шәһәре), Кенигсберг (хәзерге Калининград), Пиллау (хәзерге Балтийск) шәһәрләре аша үтә.

Редакциянең адресы: 21 475-С кыр почтасы.

Газета дүрт телдә—русча, татарча, үзбәкчә, казакъча басыла. Татар газетасы атнага ике тапкыр дүртәр битле булып чыга. Форматы—35х26 см.

Татар редколлегиясе составында редактор урынбасары журналист Минһаҗ Гыймадиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Абдулла Әхмәт, журналист Котдус Ахмәров, корректор Фазыл Басыйров иптәшләр эшли.

Газета редакциясендә рәссам Байназар Альменов иҗади командировкада булып китә. Татарстан Рәссамнар союзы аны редакциягә ярдәм итү өчен җибәргән. "Ул 1943 ел декабренең соңгы сәгатьләрендә безнең янга килеп керде. Фронт тормышына багышланган нәфис альбом әзерләргә ниятләнә иде ул. Моның өчен аңа фронт, сугышчылар һәм аларның тормышы белән һәрьяктан танышырга кирәк иде... Байназар Витебск шәһәре янында барган каты сугышларда иң зур батырлыклар күрсәткән сугышчыларның портретларын ясады. Бу—гвардия рядовое Мөнир Сәфәрмитов *(1944, 15 февраль)*, санинструктор гвардия старшинасы Владимир Александрович Крет, гвардия рядовое разведчик Фазылҗан Әһмәлетдинов һ. б.

Рәссам окоп тормышының аерым моментларын, сугыш күренешләрен, аның хәрабәләрен ашыгып-ашыгып кәгазьгә төшерде, кайберәвенен эскизларын гына сызгалады.

Б. Альменов газетада ике айдан артыграк эшләде һәм ул ясаган күп кенә рәсемнәр газета битләрендә басылды"—дип яза Афзал Шамов аның турындагы үзенең истәлегендә *(Афзал Шамов. Чын хикәяләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.—397 б.).*



"Алга, дошман өстенә" (Калинин фронты) газетасы редакциясе коллективы. Уңнан сулга: баш редактор урынбасары Минһаҗ Гыйлмадиев, хәрби корреспондентлар капитан Афзал Шамов һәм сержант Абдулла Әхмәт. Смоленск өлкәсе. 1943, 5 май.

Шагыйрь Шәйхи Маннур газетага 1943 елның 23 декабрендә эшкә килә һәм 1943 елның апреленә кадәр хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Газета битләрендә аның репортажлары, хәбәрләре, очерклары, шигырьләре басыла: "Яшь снайперлар" *(1943, 24 февраль)* исемле язмасы, "Кечкенәләр жыры" дигән шигыре *(1943, 31 март)* һ. б.

Язучы Афзал Шамов 1943 елның 9 февралендә үзе теләп фронтка китә һәм 1945 елның 5 июненә кадәр бу газетада хәрби корреспондент булып эшли. Газета битләрендә аның күпсанлы репортажлары, очерклары, мәкаләләре, хикәяләре басыла: "Казаннан сәлам" *(1943, 24 февраль)*, "Бер төнне..." *(1943, 5 март)*, "Кушкаен авылында" *(1943, 17 март)*, "Санитар" *(1943, 31 март)*, "Ике дус" *(1943, 21 апрель)*, "Батыр тупчы" *(1943, 8 май)*, "Нәфрәт көче" *(1943, 22 май)*. Әлеге соңгы очеркында язучы турыдан-туры сугышчыларга мөрәҗәгать итә һәм аларны дошманга каршы аяусыз булырга, аны юк итәргә чакыра. "Безнең күңелләрдә,—дип яза ул,—бер үк вакыт нәфрәт тә, мәхәббәт тә ята. Без, искиткеч көчле сөя белгән кебек, искиткеч явыз һәм өметсез нәфрәтләнә дә беләбез. Сөя белү, ярата белү—сөйгәндә көчле итеп, дәртле итеп сөя белү—ул безнең совет халкының гүзәл бер сыйфаты, аның бөек күңеллелеге һәм чын кешелеклеге. Нәфрәтләнә белү, нәфрәт иткәндә искиткеч явыз, өметсез һәм кансыз нәфрәтләнә алу—ул безнең совет халкының горурлыгы, бөеклеге һәм кешелекнең иң матур бер сыйфаты".

Шул ук газета санында капитан А. Тәүгилденең "Изге үч" исемле очеркы басылып чыга. А. Тәүгилде—язучы Афзал Шамовның 1919 елдан әдәби тәхәллүсе. Бу фронт газетасы битләрендә бик күп публицистик мәкаләләре, документаль очерклары, репортажлары, зарисовкалары, хәбәрләре шул имза белән урын алган: мәсәлән, "Тырышкан табар—ташка кадак кагар" *(1943, 15 май)*, "Партиянең турылыклы улы" *(1943, 27 март)*, "Үз-үзен аямыйча эшләгән өчен" һ. б.

Әлбәттә, язучының сугыш чорындагы газетада чыга торган материаллары болардан тыш башка имзалар белән дә дөнья күргән. Бу хакта А. Шамов: "Фронт газеталарында басылган хәбәрләр, мәкаләләр башка имзалар белән басылган булса да, башыннан алып ахырына чаклы минем кулым белән язылган",—дип искә ала.

Язучының шәхси архивында 14 данә фронт дәфтәрләре саклана, анда ул газетада басылган мәкаләләр, репортажлар һәм хәбәрләр исемлеген теркәп куйган һәм соңрак шундый сүзләр дә язып калдырган: "Бу дәфтәрдәге һәм башка дәфтәрләрдәге чит кеше фамилияләре белән басылган мәкаләләр, хәбәрләр һ.б. барысы да минем тарафтан язылганнар. Алар алдан сөйләшенеп, рөхсәт алып, алар фамилиясе белән генә чыгарылганнар". Әйтергә кирәк, фронт дәфтәрләрендәге 350 материалның барысы да газета битләрендә басылып чыккан булган.

Язучы Абдулла Әхмәт бу редакциядә 1943 елның маеннан 1945 елның 5 июненә кадәр эшли. Ул газета битләрендә совет солдатларының сугышчан батырлыклары турында күп санлы очерклар, хикәяләр бастырып чыгара: мәсәлән, "Композитор-

нын җинү маршлары" *(1943, 12 май; Татарстанның талантлы яшь композиторы Мәсгут Латыйпов турында)*, "Татар егете" *(1943, 22 июнь)*, "Комсомолка Галия" *(1944, 12 декабрь)*, "Гвардия офицеры" *(1944, 26 декабрь)* һ.б.



*"Алга, дошман өстенә" газетасы Смоленск җирләрендә. Сулдан уңга: рәссам Владимир Минаев, хәрби корреспондент Афзал Шамов, баш редактор урынбасары Минһаҗ Гыймадиев, корректор Фазыл Басыйров һәм хәрби коррепондент Абдулла Әхмәт. 1943, 5 май.*

Абдулла Әхмәт газетанын 1944 елның 8 июль санында дөнья күргән "Уйламаганда" исемле мәкаләсендә көрәштәш дусты Афзал Шамов турында кызыклы бер вакыйганы сурәтли. "Хәрби журналист, ул оборона вакытында да, һөҗүм вакытында да алгы кырыйда йөри. Дошман оборонасын беренче булып өзүче, ана беренче ударларны ясаучы батырларны күреп, алар белән сөйләшә һәм әле генә үткән вакыйгалар турында фронт газетасы өчен материал оештыра. Мондый кайнар көннәрдә ул сугышчы да, оештыручы да, кирәк булса, командир да булып китә. Тиз генә каләмен куеп, кулына пистолет яисә автомат ала.

...Капитан Шамов, бер частьта эшен бетереп, ашыгып икенче бер частька китә. Бу көнне 30 километр атлаганга һәм берничә төннәр йокы күрми эшләгәнгә күрә дә язучы яхшы ук арган була. Шуңа күрә ул куе арыш арасына кереп, хәл алырга утыра. Язучы тарихи һөҗүм көннәрендәге тәэсирләр турында һәм үзенең язачак хәбәрләре, хикәяләре турында уйлана. Ләкин кинәт кыштырдау ишетелә. Капитан тиз генә кулына револьверын ала һәм арыш арасыннан көнбатышка таба качып баручы бер төркем фрицларны күреп, башта беркадәр каушап кала. Ләкин шунда ук Афзал Шамов үзендә көч, гайрәт тоя, биек арышка ышыкланып килүче эре гәүдәле фрицларны якын ук җибәрә дә кинәт:

—Стой!—дип кычкыра. Аннары немецчә:

—Hände hoch!—дип, боерык бирә һәм һавага атып җибәрә.

Көтелмәгәндә үзләренең каршысына револьвер төзәп торган совет офицерын күргән фрицлар кулларын күтәрергә мәҗбүр булалар...

Язучы Афзал Шамов 7 немецны тиешле урынына илтеп тапшыра. Револьверын кобурасына салып куя да, яңадан үзенең төп эшенә—хәрби журналистның сугышчан бурычларын үтәүгә керешә. Яңадан кулына каләмен ала...

Шулай итеп, хәрби журналист Афзал Шамов уйламаганда үзе дә кыюлык, батырлык күрсәтә. Совет журналистларына хас булган данлы эш эшли. Фронт газетасының заданиесен үтәү белән бергә, язучы-журналист бер үзе 7 обер-ефрейторны әсирлеккә ала". (Бу мәкалә тулысынча "Кызыл Татарстан" газетасының 1944 елның 21 июль санында басылган.)

А. Шамовның архивында шундый документ саклана: *"Расписка. Дана начальнику конвоя капитану Шамову в том, что от него на имя в/ч N 20 НКВД принято 7 (семь) человек военнопленных.*

*Зам. начальника пункта Строкало*

*30 июня 1944 года".*

А. Шамовның әлеге истәлекләрендәге менә мондый юллар да бүгенге укучы өчен гыйбрәтле булыр дип уйлыйм: "...Ялны белми эшлибез, рәтле төн йокысы күргәнебез юк. Кайчак типографиядә генә черем итеп алабыз. Газетаның бөтен авырлыгы Абдулла Әхмәт белән минем өстә: хәбәрләрне дә, репортажларны да, очеркларны да үзебез язабыз, ана кирәкле материалларны да ут эченнән үзебез алып кайтабыз. Баш командование приказларын, әһәмиятле мәкаләләрне—барысын да үзебез тәрҗемә итәбез. Редакторыбыз бары редактор вазифасын гына үти. Бөтен кара эш безнең кулда. Кыскасы, гармунчы да, җырчы да, биюче дә үзебез.

...Сугышка чаклы мондый газетада егермегә якын кеше эшләгән. Ә без әлегә

дүртәү генә (корректор белән)". *(Шунда ук, 324 б.).*

"Алга, дошман өстенә" газетасы битләрендә үткен телле, юморга бай кечкенә хикәяләр, фельетоннар, кызыклы хәлләр, парчалар, гармун көенә җырлана торган такмаклар, сатирик шигырьләр, Хуҗа Насретдин турындагы тапкыр мәзәкләр күп урын алган.



*"Алга, дошман өстенә" газетасы редакциясе коллективы. Беренче Балтыйк буе фронты. 1944 ел, май.*

Бу материалларны матбугатка А. Шамов, А. Әхмәт һәм Ф. Басыйров әзерлиләр. Мәсәлән, Ф. Басыйровның үткен һәм тапкыр сатира белән язылган "1944 нче елгы фрицлар" зарисовкасында *(1944, 17 ноябрь)*, А. Шамовның "Фриц намусы" исемле кечкенә фельетонында *(1944, 15 декабрь)* дошманнарга карата ачы нәфрәт белдерелә.

Газета битләрендә татар халкының бөек шагыйрьләре Габдулла Тукай һәм Һади Такташ шигырьләре дә дөнья күрә, алар сугышчыларга көч һәм дәрт өсти.

Бу газета битләрендә Фатих Кәримнең "Снайпер фәлсәфәсе" *(1943, 15 июнь)*, "Хәнҗәр" *(1943, 25 июнь)*, Әхмәт Исхакның "Тотса Мәскәүләр якаң!" *(1943, 17 апрель)*, "Дөнья бу!" *(1943, 22 июнь)*, Әхмәт Ерикәйнең "Кышкы кичтә" *(1944, 13 гыйнвар)*, Шәрәф Мөдәрриснең "Татар солдаты" *(1944, 15 февраль)*, Әхмәт Юнысның "Илнең батыр кызы" *(1943 8 март)*, Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә К. Симоновның "Көт син мине" *(1943, 18 июнь)* һ. б. шагыйрьләрнең шигырьләре басыла. Фронт частьларында хезмәт итүче шагыйрьләрдән Мансур Гаязның "Түләтербез!" *(1943, 21 апрель)*, "Ватан" *(1943, 22 июнь)*, Рахман Хөсәеневнең "Җавап" *(1943, 20 июль)*, Исхак Закировның патриотик рухлы шигырьләре дә шушы газета битләрендә урын ала. Искәртеп үтик: аларның өчесе дә дошманга каршы көрәштә батырларча һәлак булалар.




**III. "ВАТАН НАМУСЫ ӨЧЕН"**—бу газетаның беренче саны 1942 елның 19 декабрендә Воронеж фронтында чыга башлый. 1943 елның 20 октябрендә Воронеж фронты үзенең тарихи яшәвен тәгәлләгәч, газета исемен үзгәртмичә Беренче Украина фронты карамагына күчерелә һәм 1946 елның 25 маена кадәр чыгуын дәвам итә. Татар телендә барлыгы 377 саны дөнья күрә.

Газетаның үткән данлы тарихи юлы түбәндәгедән гыйбарәт: Острогожск—Воронеж—Киев—Житомир—Тернополь—Черновцы—Львов—Самбор—Дембица—Берлин (сугыш беткәч Прага—Вена). Редакциянең адресы: башта—1875 кыр почтасы, 12 бүлеге; соңыннан—48828-А кыр почтасы.

Газета рус, украин, татар, казакъ, үзбәк телләрендә атнага ике тапкыр чыга. Татар газетасы башта ике битле, 1944 елның 11 апреленнән дүрт битле булып дөнья күрә. Форматы—42х30 см. Газетаның редактор урынбасары булып шагыйрь, капитан Әхмәт Ерикәй, 1943 елның 1 июленнән драматург, капитан Риза Ишморат эшли. Хәрби корреспондентлар булып шагыйрьләр Гали Хуҗи, Әхмәт Юныс,

Мөхәммәт Садри, язучы Госман Бакиров, журналистлар Әнвәр Ямангулов, Зәйни Шаһиморатов, Габдулла Шәрипов эшлиләр. Язучы Газиз Иделле һәм журналистка Фатыйма Галиева 1944 елның ноябреннән 1945 елның мартына кадәр редакциядә иҗат командировкасында булалар.

Әхмәт Ерикәй бу газета редакциясендә беренче көненнән 1943 елның июненә кадәр хезмәт итә, совет сугышчыларын фашизмга каршы көрәшкә өндәгән шигырьләр, очерклар һәм җырлар яза: мәсәлән, "Татар егетләре" *(1943, 23 февраль)*, "Мин кызганмыйм" *(1943, 8 апрель)*, "Дуслык" *(1943, 11 июль)*, "Калкулык" *(1944, 24 март)*, "Якынлаша" *(1945, 14 апрель)* һ. б.

Риза Ишморат бу газетада 1943 елның 10 июненнән редактор урынбасары хезмәтләрен үтәүче буларак хезмәт итә, шул ук елның 1 июленнән чын мәгънәсендә редактор урынбасары булып эшли. Ул озын һәм авыр сугыш юлы үтә. Острогожск шәһәреннән Берлинга кадәр барып җитә, урам сугышлары барганда яралана. Р. Ишморат татар халкы улларының Беренче Украина фронтында җанын-тәнен аямыйча баһадирларча сугышуы турында очерклар, мәкаләләр яза: мәсәлән, "Майор Бәдретдинов", "Висла буенда", "Зәки Шәймәрданов", "Мирза Билаловның разведкага баруы", "Татарстан улы", "Рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар" *(1944, 11 апрель)*, "Берлинда" *(1945, 6 май)* һ. б.



*Беренче Украина фронтының "Ватан намусы өчен" газетасы редакциясе коллективы. Сулдан уңга: баш редактор урынбасары капитан Риза Ишморат, хәрби корреспондентлар өлкән лейтенан Мөхәммәд Садри, өлкән лейтенант Гали Хуҗи.*

Гали Хуҗи һәм Әхмәт Юныс Казаннан газета редакциясенә 1942 елның 27 ноябрендә чыгып китәләр *(ТРның Милли архивы, 7083 фонд, 2 тасв., сак. 32 бер. 204 б.)*. Ә. Юныс, авыру булу сәбәпле, 1943 елның 24 апрелендә кире Казанга кайта. Газета битләрендә аның "Тик алга безнең адым", "Нәфрәтебез көчле булганга", "Ашыгыгыз, кызыл обозлар", "Кавышыр көн", "Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларына" һ. б. шигырьләре дөнья күрә.

Г. Хуҗи бу редакциядә беренче көннән ахырына кадәр хезмәт итә. Ул газетаның җаваплы секретаре була. "Димәк, газетаның иң күп эше анарда. Эшкә дисәң—атлыгып тора. Приказ бирү дә кирәкми, болай дусларча гына әйтү дә җитә. Күп эшне үзе белеп эшли. Җитез эшли. Төгәл эшли. Газетаның әйтер сүзен, оештыру, өйрәтү көчен белеп эшли. Дошман һөҗүме булып, тиз генә күченергә туры килгәндә дә, әйләнә-тирәдә бомбалар ява башлаганда да куркып, каушап кала торганнардан түгел. Кыю егет",—дип яза аның хакында Р. Ишморат "Гомер сукмаклары" дигән истәлекләр китабында *(Р. Ишморат. Гомер сукмаклары // Истәлекләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.—357 б.)*. Газета битләрендә Г. Хуҗиның "Зоя Космодемьянская" *(1942)*, "Исемсез каһарманнар" *(1943, 23 февраль)*, "Россия" *(1944, 15 һәм 18 декабрь)*, "Яу күрке" *(1945, 13 һәм 17 гыйнвар)* поэмалары, "Йөрәк ялкыны" *(1943, 6 июль)*, "Сентябрь" *(1943, 6 октябрь)*, "Канлы эз" *(1943, 17 октябрь)*, "Шинель" *(1943, 12 декабрь)* "Хатип Хәсәнов, Советлар Союзы Герое" *(1944, 3 аперль)* һ. б. шигырьләре, "Советлар Союзы Герое Фәйзулла Әһлетдинов" *(1944, 18 гыйнвар)*, "Совет солдаты" *(1944, 8 сентябрь; автордашы—М. Садри)*, "Менә безнең якташ" *(1944, 7 октябрь; автордашы—М. Садри)* дигән очерклары һәм күп санлы мәкаләләре басылып чыга.

Мөхәммәд Садри редакциягә "Көнбатыш Украина чикләренә якынлашып килгән чагыбызда ГлавПУРККАдан безнең редакциягә дип җибәрелде. Мөхәммәт килгәч, эшебез һәрьяклап җанланып китте. Садри сугышчан заданиене төгәл һәм вакытында үти торган кыю солдат. Туплар, минометлар шартлап, пулялар сызгырып торган җиргә—алдынгы сызыкта сугышучы солдатлар, командирлар янына барып яңа хәбәрләр алып кайту өчен кыюлык иң кирәкле сыйфат. Бу яктан Мөхәммәт

безнең газета өчен кыйммәтле кеше булып чыкты",—дип искә ала Риза Ишморат үзенең әлеге истәлекләрендә.

Газета битләрендә М. Садринең "Атлы батыр алга ашкына" *(1944, 15 февраль)*, "Без жырлыйбыз" *(1944, 11 апрель)*, "Хафиз батыр" *(1944, 1 ноябрь)*, "Халкыма" *(1944, 20 ноябрь)*, "Хәнжәр" *(1945, 12 февраль)* һ. б. шигырьләре, "Каһарман дус" исемле поэмасы *(Советлар Союзы Герое Александр Матросов турында; 1944, 21 июнь)*, "Ай хикәясе" исемле балладасы *(1944, 1 декабрь)*, "Советлар Союзы Герое—Әнвәр Кәлиев" *(1944, 10 июнь)*, "Арслан баласы" *(1944, 16 июль)*, "Совет солдаты" *(1944, 8 сентябрь; автордашы—Г. Хужи)*, "Менә безнең якташ" *(1944, 7 октябрь)*, "Бу—үч көче" *(1944, 12 октябрь, автордашы—Г. Хужи, А. Иванов)*, "Сапер Хәйрулла Шакиров" *(1945, 7 апрель)*, "Сапер Мәхмүт Газизов" һәм "Разведчик Касыйм Садыйков" *(1945, 27 һәм 30 апрель)* очерклары басыла.

Госман Бакиров редакциядә 1944 елның 21 маеннан эшли башлый. Газета битләрендә Г. Бакировның "Егерме сигез елдан соң" *(1944, апрель)*, "Агитатор үзенең командирына булыша" *(1944, 24 май)*, "Коралың төзек, йөрәгең нык булсын" *(1944, 27 май)*, "Бер оешманың эше" *(1944, 30 июнь)*, "Туганлык һәм дуслык армиясе солдатлары" *(1944, 20 июль)*, "Партия члены" *(1944, 1 ноябрь)*, "Ут" *(1944, 24 ноябрь)*, "Казан егете" *(1945, 9 май)* кебек очерклары һәм мәкаләләре дөнья күрә.

Газиз Иделле газета редакциясенә вакытлыча командировкага килгәч, Беренче Украина фронтында сугышучы татар сугышчылары турында тирән эчтәлекле очерклар яза. Жөмләдән "Совет офицеры" *(1944, 27 ноябрь)*, "Якташыбыз Гәрәевнең батырлыклары" *(1944, 11 декабрь)*, "Минзәлә егете" *(1944, 27 декабрь; 1945, 1 гыйнвар)*, "Немец жирендә" *(1945, 10 март)* исемле очеркларны һәм "Очрашулар" исемле хикәясен *(1944, 20 ноябрь)* санап үтәргә мөмкин.

Бу газета битләрендә Фатих Кәримнең "Һөжүм" *(1943, 12 май)*, "Аерылганда" *(1943, 200 июнь)*, "Сугыш кырында" *(1943, 24 сентябрь)*, "Совет солдаты" *(1943, 26 ноябрь)*, "Немец жирендә" *(1945, 17 март)*, "Безнең урамда" *(1945, 26 май)* исемле шигырьләре һәм "Тимер һәм тимерче" балладасы *(1944, 12 гыйнвар)* басылып чыга.

Биредә шулай ук Мостай Кәримнең "Мин синең ягымлы анаңны күрдем" *(1943, 4 май)*, "Кол кыз жыры" *(1943, 23 сентябрь)*, "Дан ордены" *(1944, 1 гыйнвар)*, "Идел кызы" *(1944, 6 апрель)*, "Сталинчыл гвардия" *(1944, 25 октябрь)* дигән шигырьләре дөнья күрә.

Фронт частьларының берсендә хезмәт иткән яшь шагыйрь Гыйлемдар Рамазанов та газетага актив язышa.

Зәйни Шаһиморатов "Ватан намусы өчен" газетасына 1945 елның август аенда эшкә килә һәм 1946 елның 25 маена кадәр анда хезмәт итә. Газета битләрендә аның "Сталинчыл лачынга", "Яшәсен жиңү" исемле шигырьләре, "Туган илемә" дигән поэмасы һәм "Имән әкияте" дигән балладасы басыла.

1945 елның 9 май көнен капитан Мөхәммәт Садри Берлинда командировкада каршылый. "Нәкъ шул вакыт ап-ак тешләрен ялтыратып, Мөхәммәт килеп керде. Яныбызга килеп басты да миңа карап:

—Иптәш майор, задание үтәлде! Жиңү турында материал житәрлек булды. Ә иң мөһиме—рейхстагка күтәрелеп: "Без жиңүчеләр булып Берлинга килеп життек!"—дип яздым да барыбыз исеменнән кул куйдым!—ди.

—Рәхмәт, иптәш капитан, булдыргансың. Үз исемемнән генә түгел, бөтен халкыбыз исеменнән дә рәхмәт сиңа!—дип, Мөхәммәтнең кулын кыстым" *(Р. Ишморат. Гомер сукмаклары...—391 б.)*.

Менә шулай, татар әдипләренең кул тамгасы рейхстаг диварларына да "сугып" калдырылган булган икән. Халыкның рәхмәте буларак...

**IV. "СТАЛИН БАЙРАГЫ"**—бу газета 1943 елның гыйнварында Көньяк фронтта, данлы Сталинград янында оештырыла һәм март аеннан чыга башлый. 1943 елның 20 октябрендә Көньяк фронт үзенең тарихи яшәвен төгәлләгәч, бу газета да исемен үзгәртмичә, Дүртенче Украина фронты карамагына күчерелә һәм Кырым операциясе тәмам булганчы—1944 елның июненә кадәр чыгып килә.

Редакциянен адресы: 19640-А кыр почтасы.

Газетаның редактор урынбасары булып журналист Гани Клиблеев, хәрби кор-

респондентлар булып язучы Ибраһим Гази, журналист Зәкәрия Әхмәров һәм корректор Кыям Хисмәтуллин эшли. 1943 елның 18 гыйнварында язучы Фатих Хөсни, партиянең Татарстан Өлкә Комитеты карары белән, Көньяк фронтка ике айлык командировкага җибәрелә.

И. Гази үзенең истәлекләрендә Ф. Хөсни белән бәйләнешле бер вакыйга хакында болай дип язып үтә: "Бер көлке хәл искә төште. Әле беренче вакытлар, Ростов-Дон тирәләре. Немец кичен тагын килде... Без шельгә кереп постык. Өстән зенит снарядлары оча. Бомбалар читкә төшә, Фатих, башын тотып:

—Нишлим инде, башымда да юк, ичмасам,—дип зарлана (янәсе, башында булса, снаряд ватыгы төшүдән курыкмас иде). Бүреге редакциядә калган" *(И. Гази. Чикләвекләребез төшле булсын.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.—274 б.).* "Машинадан сикергәндә, үземнән алда күзлегем сикереп төшә. Бу күзлек белән күргән җәфалар инде! Әле җәйли, южный поселогында торган чакта, авыл эчендә төнлә адаштым бит. Карангы—маскировка. Житмәсә, янгыр. Күзлекне салсам да күрмим, кисәм дә күрмим. Адашып әллә нинди чокырларга барып төштем, чәнечкеле тимер чыбык коймаларга килеп эләктем. Фриц килеп, зениткалар кызыл чылбыр тезгәч кенә, көндез күргән зенит тупларының торган урыннарын чамалап, шулай гына барасы җиремә барып житә алдым.

Бер тапкыр, бусы инде Мелитополь тирәсендә, машинадан сикереп төшкән чагымда нәкъ күзлегем өстенә килеп төштем. Пыялалар чәлпәрәмә килде. Кылчык-кылчык булып ватылганнар. Алай да бәхет бар икән әле, кысасыннан коелып төшмәгәннәр. Редакциягә кайтып, ак кәгазь белән түгәрәкләп ябыштырып, уртада кечкенә генә ачык пыяла калдырдым. Бер дә юкта ярый, күреп була. Юкса, бит күзлексез бөтенләй сукыр.

Ватык пыялалар белән шактый вакыт йөрергә туры килде. *(Шунда ук...—269-270 б.).*

И. Гази 1943 елның 4 августында язучы Афзал Шамовка болай дип яза: "...үзем—певец, үзем—жнец, үзем—в дудку игрец. Безнең икенче литературный сотрудник каләме әлифне таяктан гына аера. Бөтен авырлык миндә—терпи минем бөкре. Ә Клиблинең телен беләсең... Аннан ул гаҗәп кызык политика тота: бернәрсә дә эшләми, буквально бернәрсә дә—бер җөмлә әйбер язмый, бер кәлимә тәрҗемә итми. Аның бөтен эше—макет оештыру, ул да чиле-пешле... Мин командировкага киткәч, алар бер газета чыгарганнар. Укып карар өчен җибәрәм. Аяк мәкалә *(баш мәкалә—Ә. Ш.)*—аның тәрҗемәсе... Ләкин аның да бер яхшы ягы бар: ул бер эшкә дә тыгылмый, ягъни мешать итми—шул ягы җөдә (үзбәкләрнең "бик" дигән сүзе) яхшы.

Берничә (!) хикәя яздым. Берничә ай эчендә бит... Материал бар да, тынычлык житеп бетми. Ни әйтсәң дә, сугыш бит инде...

Миңа гел тәрҗемә белән (русчадан татарчага һәм киресенчә) шөгыльләнергә туры килә...

Менә шулай, малай, ят-чит җирләрдә, тәмсез су эчеп, бомбалар астында, кайчан муены сына инде бу Гитлерның дип, өмет белән яшибез".

Инде килеп, И. Газинең А. Шамовка язган тагын бер хатына күз төшерик: "Мин Карпат тирәсендә тау төшә, тау менә бераз йөргәч, пайтәхеткә чакырылып, 1 нче ак русча бәрәнге ашарга озатылдым. Резерв дигән җан биздергеч җирдә бераз кыйналгач, 1 нче ак рустагы тастымалның бер почмагыннан барып тоттым. Тиздән, бәлки, сез безнең тастымалга кул (кул гынамы!) сөртә башларсыз".

**V. "ФРОНТ ПРАВДАСЫ"** 1943 елның гыйнварында Волхов фронтында чыга башлый һәм Волхов фронтында сугыш операцияләре тәмам булганчы—1944 елның февраленә кадәр чыгып килә. Волхов—Кириши—Новгород—газетаның фронт гаскәрләре белән үткән данлы юлы шуннан гыйбарәт.

Редакциянең адресы: 48767-В кыр почтасы.

Редактор урынбасары булып журналист Габделхәй Хәбиб эшли. Хәрби корреспондент булып шагыйрь Әхмәт Фәйзи хезмәт итә. Аның бу газета битләрендә "Тәпәрәш егете" *(1943, 8 июнь; Бөек Ватан сугышы батыры артиллерист Ибраһим Сәгыйдуллин турында),* "Лейтенант Вәли Галимов 131 гитлерчыны дөмектерде" *(1943, 12 июнь),* "Кимпреков алдынгы сугышчы булды" *(1943, 15 июнь),* "131"

*(1943, 26 июль; Бөек Ватан сугышында батырлык күрсәткән лейтенант Вәли Галимов турында)*, "Сүз көче" *(1943, 3 август)* һ. б. очерклары һәм мәкаләләре басыла.

Ә. Фәйзинен күпсанлы шигырьләре дә басыла: мәсәлән, "Ятимнәрнең ачы күз яшьләрен..." *(1943, 16 март)*, "Татар сугышчысы" *(1943, 19 март)*, "Фашист-козгын, чыгып чамадан..." *(1943, 5 апрель)*, "Яз иртәсе" *(1943, 27 май)*, "Фронтка хат" *(1943, 17 июль)*, "Кем бу, нинди адәм карачкысы?" *(1943, 11 август)*, "Йөз егерме туптан уникe залп" *(1943, 7 август)* һ. б. Әхмәт Фәйзи "Фронт правдасы" газетасы өчен карикатура-рәсемнәргә эпиграммалар да яза.

Газетада Мәхмүд Максудиның Һади Такташ истәлегенә "Шагыйрь яши" исемле мәкаләсе дә урын алган *(1943, 29 декабрь)*.

**VI. "ВАТАН ӨЧЕН СУГЫШКА"** газетасы Карелия фронтында 1943 елның гыйнварында чыга башлый. Редакциянең адресы: 68331-Д кыр почтасы. Газета рус, татар, казакъ телләрендә чыга. Ул атнага өч тапкыр дүрт битле булып дөнья күрә. Газетаның редактор урынбасары журналист—Александр Герасимов, хәрби корреспондентлар—журналистлар Бари Корбанов, Минһаж Җамалиев, корректор—Каюм Иманкулов. 1943 елның июненнән редактор урынбасары булып журналист Бари Корбанов, җаваплы секретарь булып язучы Габдрахман Әпсәләмов, хәрби корреспондент булып журналист Мөхәммәтша Сабельев эшли.



*Фронтовик язучылардан бер төркем. Беренче рәттә сулдан уңга: Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Халикъ Садри, Татгосиздатның баш редакторы Хәсән Шабанов; икенче рәттә, сулдан уңга: Әмирхан Еники, Госман Бакиров, Абдулла Әхмәт, Әсгать Айдар, Хатип Госман. Казан. 1947, 23 апрель.*

1944 елның февралендә ике фронт—Карелия һәм Волхов фронтлары идарәләре бергә кушыла, чөнки Волхов фронты үзенең тарихи яшәвен төгәлләгән була. Редакциядә дә үзгәрешләр барлыкка килә. Волхов фронты газетасыннан 1944 елның мартында эшкә килгән майор Габделхәй Хәбиб редактор урынбасары итеп билгеләнә. Өлкән лейтенант, шагыйрь Әхмәт Фәйзи—хәрби корреспондент. Бари Корбанов һәм М. Сабельев резервка китәләр. "Әхмәт Фәйзи күзлек белән дә начар күрә иде. Беренче командировкасында ул бер подразделениедән икенчесенә барышлый, ялгышлык белән, мина кырына килеп кергән. Билгеле инде, аны күреп кешеләрнең котлары очкан—менә-менә шартлавы ихтимал бит. Ләкин, бәхеткә, ул бөтен мина кыры аша узып та (үзе, әлбәттә, моны белмәгән) хәвеф-хәтәргә очрамаган. Шуннан командирлар аны туры редакциягә кайтарып җибәргәннәр...",—дип яза шушы көннәр хакында Г. Әпсәләмов үзенең истәлегендә *(Казан утлары.—1975.—N 5, 125 б.)*. Тиздән Ә. Фәйзи дә резервка китә. Редакциягә хәрби корреспондент булып шагыйрь Гыйззулла Габидуллин килә.

"Ватан өчен сугышка" газетасының соңгы саны 1944 елның 12 ноябрендә дөнья күрә. Газетаның барлыгы 89 саны чыгып кала.

"Редакция поезды Акдингез, Кандалакша, Кола шәһәрләрендә тора, ә газетаның саннары Ладога күленнән алып, бөтен Көньяк һәм Төньяк Карелия буйлап, Заполярье һәм Петсамо өлкәсе буйлап, Норвегиянең Керкинес шәһәренә кадәр таралалар" *(Совет әдәбияты.—1947.—N 5)*.

Габдрахман Әпсәләмовның—газета битләрендә бик күп очерклары басыла: мәсәлән, "Приказ үтәлде", "Үлемнән көчлерәк", "Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов" *(1943, 15 июль)*, "Тәвәккәл таш ярыр" *(1943, 29 октябрь)*, "Сәубан Зарифуллин" *(1944, 30 март)*, "Сержант Ильясов" *(1944, 9 апрель)*, "Казакъ егете" *(1944, 16 апрель)*, "Биеклек" *(1944, 18 июнь)*, "Ярсу күнел" *(1944, 2 июнь)*, "Кыска

дулкында" *(1944, 1 июль)*, "Куолоярви фажигасе" (1944, 12 октябрь), "Совет хәрби пленныйларын юк итү" *(1944, 15 октябрь)*, "Күпер" *(1944, 18 октябрь)*. "Галим Шәкүров" *(1944, 22 октябрь)*, "Яшь офицер" *(1944, 29 октябрь)*, "Хат укыганда" *(1944, 5 ноябрь)*, "Төньяк каһарманнары" *(1944, 12 ноябрь)*.

Бари Корбанов үзенең истәлегендә Г. Әпсәләмов турында болай дип язып үтә: "Бу тырыш каләм остасы, газетабызны номердан номерга яхшырта бару өчен аны күп меңләгән татар сугышчыларын явыз дошманны оста дөмбәсләүгә, тизрәк тармар итүгә туплаучы материал белән баету өчен көчен, вакытын кызганмады" *(Социалистик Татарстан.—1971.—28 декабрь)*.

**VII. "ВАТАННЫ САКЛАУДА"** газетасы Ленинград фронтында 1943 елның башыннан 1946 елның июненә кадәр чыгып килә. Газетаның редактор урынбасары—журналист, капитан Заур Исхаков, хәрби корреспондентлар булып Ирек Аргынбаев, Ильяс Сәйфетдинов, Кадыйр Юлдашев эшли. Бу газетага Ленинград фронты частьларының берсендә хезмәт итүче яшь шагыйрь Мәхмүт Хөсәен актив язышა. Аның патриотик эчтәлекле күп кенә шигырьләре һәм "Мактау һәм дан сиңа, Кизатов! *(1944, 20 декабрь)*, "Мидхәт Салиховка мактау һәм дан!" *(1945, 13 гыйнвар)* исемле очерклары шушы газетада урын ала. Газета битләрендә Гамир Насрыйның "Минометчы Нуретдинов" *(1945, 14 март)* һәм Гадел Кутуйның "Куркусыз разведчик" *(1945, 22 март)* исемле очерклары да дөнья күрә.

**VIII. "КЫЗЫЛ СУГЫШЧЫ"** газетасы Мәскәү хәрби округында 1943 елның гыйнварыннан 1944 елның июненә кадәр чыга. Редакциянең хатлар өчен адресы: Москва, 34 Кропоткин урамы, Всеволожск тыкрыгы, 2 йорт. Аның редактор урынбасары журналист, капитан Ярулла Ярмәкиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар Гариф Галиев һәм Мәхмүд Максуд эшлиләр. Газета эшендә капитан Әхмәт Ерикәй актив катнаша *(1943 елның августыннан декабрьга кадәр)*. Гадел Кутуй һәм Мөхәммәт Садри да биредә шигырьләр, мәкаләләр бастыралар.




**IX. "СОВЕТ СУГЫШЧЫСЫ"** газетасы Өченче Украина фронтында 1943 елның маеннан 1946 елның февраленә кадәр чыга. Бу газета фронт частьлары белән Ворошиловград өлкәсеннән Одесса аша Румыниягә, аннары Болгариягә (София), Югославиягә (Вршац) һәм Австриягә (Вена) кадәр озын юл үтә. Редакциянең адресы: 22107-А кыр почтасы. Газета атнага ике тапкыр, икешәр битле булып чыга. Форматы—42х30 см. Газетаның редактор урынбасары язучы Мәхмүд Максуд, хәрби корреспондентлар булып Мостай Кәрим, Г. Әхмәтшин, А. Әсадуллин һәм В. Вәлиев эшлиләр. Бу газета редакциясенә 1943 елның 10 октябрендә иҗат командировкасына язучы Хәсән Хәйри килә. "Мин сау-сәламәт килеп җитеп, эшкә кереште м... Газета начар түгел. Эше дә шактый. Аз гына срокка килгән кеше, мин дә кайбер эшләрне башкарырмын дип торам",—дип яза Х. Хәйри Хәмит Ярмигә 1943 елның 13 октябрендә. 17 октябрьдә язылган хатында болай дип өсти: "Мин эшләрнең эзенә төшеп киләм. Фронт үзенчәлекләрен аңлый башладым. М. Максуд белән бергәләп кайбер эшләрне оештырып ятабыз".

Х. Хәйринең газета битләрендә "Сугышчан әдәбият" *(1943, 20 октябрь)*, "Халык батырларына дан" *(1943, 29 ноябрь)* исемле мәкаләләре басыла. М. Максудиның "Әхтәмовның җавабы *(1943, 6 октябрь)* исемле очеркы, "Патриот-шагыйрь" *(1943, 3 декабрь; Г. Тукай иҗаты турында)* зур мәкаләсе дөнья күрә.

"Совет сугышчысы" газетасы 1944 елның май аеннан дүрт битле булып чыга.

Фронт частьларының берсендә хезмәт итүче язучы Әсгать Айдар да газетада актив язышა. "Ялгыз курган буенда" *(1943, 27 декабрь)*, "Ут эчендә" *(1944, 1 май)*, "Разведчик язмалары" *(1944, 10, 14, 17 июнь)*, "Һөҗүм юллары буйлап" *(1944, 13 сентябрь)*, "Дунайда җилүле таң" *(1944, 20 сентябрь)*, "Унбиш йолдыз" *(1944, 18 ноябрь)*, "Сугышчан дуслар" *(1944, 25 ноябрь)*, "Фриц Шүрләгәнснның төше" *(1945, 3 гыйнвар)*, "Героиня Рауза" *(1945, 8 март)*, "Сапер Копетдинов" *(1945, 7 апрель)* кебек әсәрләре шушы газета битләрендә дөнья күрә.

**X. "СУВОРОВЧЫ"** газетасы Икенче Балтыйк буе фронтында 1944 елның февраленнән 1945 елның маена кадәр чыга. Аның сугышчан юлы Великие Лукидан Ригага кадәр сузыла. Редактор урынбасары булып журналист Мөхәммәт Шәймәрдәнов, хәрби корреспондентлар булып журналистлар Рим Баһау, Мәжитов, И. Гурьев иптәшләр эшлиләр. Рим Баһау, редакция тарафыннан куелган сугышчан бурычны үтәгән чагында, батырларча һәлак була.

Бу газета битләрендә М. Максудның "Батыр турында жыр" *(1944, 2 май)* исемле очеркы басылган.




**XI. "ФРОНТ ХАКЫЙКАТЕ"** газетасы Икенче Белоруссия фронтында 1944 елның маеннан 1945 елның июненә кадәр чыга. Аның сугыш юлы Смоленск—Белоруссия—Польша—Көнчыгыш Пруссия—Померания аша үтә. Редакциянең адресы: 47763 кыр почтасы. Газета атнага ике тапкыр дүрт битле булып чыга. Форматы—42х30 см.

Газетаның редактор урынбасары журналист Гани Гыйльманов, хәрби корреспондентлар булып А. Әхмәров, шагыйрьләр Шәрәф Мөдәррис һәм Гамир Насрый, А. Салеев эшли. Бу газета битләрендә Х. Госманның "Үлемсез егет" *(1944, 9 декабрь)*, М. Максудның "Шагыйрь яши", Ш. Мөдәрриснең "Әлмәт егете" *(1944, 29 март)*, "Бер төнне" *(1944, 13 май)*, "Партизан" *(1944, 19 июль)*, "Шамил" *(1944, 21 июль)*, "Солдат-художник" *(1944, 28 октябрь)*, "Габдулла" *(1944, 13 декабрь)*, "Алтын йолдыз" *(1944, 23 декабрь)*, "Проня—Нарев" *(1944, 2 декабрь)*, "Коммунист" *(1945, 28 март)*, "Дингез ярында" *(1945, 4 апрель)*, "Танкчы Рөстәм" *(1945, 7 апрель)* кебек әсәрләре дөнья күрә. Шулай ук Гамир Насрыйның "Татар солдаты" *(1944, 20 май)* "Батырлык һәм дан" *(1944, 14, 17 июнь)*, "Атаклы сапер" *(1944, 28 июнь)*, "Сугышчан дуслар" *(1944, 8 июль)*, "Капитан Жиһаншин" *(1944, 29 июль)*, "Алтмыш беренче" *(1944, 20 сентябрь)*, "Мәңгелек дан" *(1944, 27 сентябрь)*, "Икенче очрашу" *(1944, 18 октябрь)*, "Сагыну" *(1944, 8 декабрь)*, "Онытылмас көннәр" *(1945, 1 гыйнвар)*, "Күпне күргән солдат" *(1945, 10 гыйнвар)*, "Арслан йөрәкле кеше" *(1945, 17 февраль)*, "Безнең фронт батырлары" *(1945, 4 март)*, "Курыкканга куш күренә" *(1945, 17 март)*, "Гыймади абзый Берлинда" *(1945, 2 май)* язмалары да биредә басылып чыга.

Фронт частьларының берсендә хезмәт иткән Атилла Расих газетага актив языша. Газета редакциясе икенче Белоруссия фронты сугышчыларыннан татар халкына жавап хаты оештыра. Ул шигъри өслүбтә язылган, аның авторы—шагыйрь Шәрәф Мөдәррис.

Хәрби корреспондент Ш. Мөдәррис Жиңү көнен Берлинда каршылый. Рейхстаг диварына "Татар солдаты, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис" дип култамгасын язып калдыра *(Казан утлары.—2004.—N 11)*.

**XII. "ЖИҢҮ БАЙРАГЫ"**—Германиядә сугыш хәрәкәтләре тәгәлләнгәннән соң, "Фронт хакыйкате" газетасы редакциясе исемен үзгәртеп, 1945 елның июнендә Гаскәрләрнең төньяк группасы карамагына күчә һәм шушы исем астында чыга башлый; чыгуы 1947 елның февраленә кадәр дәвам итә. "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнгән бу газета Польшада һәм Силезиядә басыла.

Газета битләрендә Г. Насрыйның "Бер орденның тарихы" *(1945, 6 ноябрь)*, "Биш басманың берсе турында" *(1945, 28 ноябрь)*, Ш. Мөдәрриснең "Рейхстаг стенасы" *(1945, 12 июль)* очерклары басылып чыга.

**XIII. "КЫЗЫЛ АРМИЯ"** газетасы Беренче Белоруссия фронтында 1944 елның ноябреннән 1946 елның февраленә кадәр чыга. Аның сугышчан юлы: Овруч—Барановичи—Берлин. Редакциянең адресы: 48251-А кыр почтасы. Газетаның редактор урынбасары журналист Ярулла Ярмәкиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар Ибраһим Гази, Гадел Кутуй, Гариф Галиев, журналистлар Зәкәрия Әхмәров, Кыям Хисмәтуллин эшли.

Бу газета битләрендә Гадел Кутуйның "Күпердән берәү" *(1944, 19 ноябрь)*, "Илнең рәхмәте" *(1944, 17 декабрь)*, "Безнең күзләр" *(1944, 28 декабрь)*, "Туган ил" *(1944, 31 декабрь)*, "Ул сугышта үсте" *(1945, 4 гыйнварь)*, "Капитан Рәхмәтуллин" *(1945, 10 гыйнвар)*, "Алар өчәү иде" *(1945, 14 гыйнвар)*, "Тетрә, Берлин!" *(1945, 23 февраль)*, "Оста артиллерист" *(1945, 4 март)*, "Күпер янында" *(1945, 8 март)*, "Берлин юлында очрашу" *(1945, 11 март)*, "Иделдән—Одерга" *(1945, 15 апрель)*, "Офицер Исхаков" *(1945, 22 март)* очерклары, "Без—сталинградчылар" *(1945, 4 февраль)* нәсере һәм "Ханҗәр" *(1945, 1 май)* хикәясе дөнья күрә. Шушы ук чорда әдипнең атаклы "Сагыну" нәсере иҗат ителә.

Гадел Кутуй 1944 елның 28 октябрендә Казанга, хатыны Галимәгә болай дип яза: "Кичә алгы сызыкта булдым. Көндезен танк эчендә, төнен танк төбендә утырдым. Суык, көчле жил һәм ядрә кисәкләре яңгыры, өзлексез ату тавышы, әлбәттә, йокларга бирмәделәр... Сәламәтлегем яхшы... Юл бәласе генә бар. Машина туры килсә, машинага утырасың, туры килмәсә яки туктамаса, җәяү атлыйсың. Гариф Галине һәм бүтән иптәшләрне айга якын күргәнем юк".

Бу газета битләрендә И. Газинең "Тупчы егет" *(1944, 19 ноябрь)*, "Синең хатларың" *(1944, 31 декабрь)*, "Йолдызлы малай" *(1945, 11 гыйнвар)*, Г. Галиевның "Дуслык" (1944, 23 ноябрь), "Сержант Хәмидуллин" *(1944, 26 ноябрь)*, "Танкистлар" *(1945, 21 июнь)*, "Агымсу дулкыннары" *(1945, 23 август)*, Г. Насрыйның "Бер орденның тарихы" *(1945, 23 декабрь)* очерклары басыла. Газетага Шакир Абилов та язышa.

**XIV. "ТРЕВОГА"** газетасы Ерак Көнчыгышта 1944 елның июненнән 1945 елның октябренә кадәр чыга. Ерак Көнчыгышта япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләре башланганчыга кадәр ул Хабаровскида, сугыш хәрәкәтләре башлангач Икенче Ерак Көнчыгыш фронтында басыла. Аның хәрби корреспондентлары Сахалинга, Курил утрауларына, Маньчжуриягә кадәр барып житәләр. Редактор урынбасары булып журналист Бари Корбанов, хәрби корреспондентлар булып башкорт шагыйре Хәниф Кәрим, яшь татар шагыйре Мөнир Мазунов, журналист Мөхәммәтша Сабельев эшлиләр. Бу газета битләрендә Г. Кутуйның "Берлин юлында очрашулар" *(1945, 23 май)*, К. Нәҗминең "Тереклек бирүче көч" *(1945. 12, 24 июль)*, М. Әмирнең "Мактау һәм дан герой анага" *(1944, 1 декабрь)* исемле очерклары басыла. Ерак Көнчыгыш авиациясендә хезмәт иткән шагыйрь Салих Баттал һәм яшь каләм-ияләре—разведчиклар отделениесе командиры Әдип Маликов һәм Хәрби Диңгез Флотында хезмәт итүче Сафа Сабиров иптәшләр бу газетага актив язышалар.

**XV. "СТАЛИН СУГЫШЧЫСЫ"** газетасы Беренче Ерак Көнчыгыш фронтында 1945 елның маеннан 1945 елның ноябренә кадәр чыга. Аның үткән сугышчан юлы: Ворошилов-Уссурийск—Муданьдзян—Харбин. Редактор урынбасары, журналист Габделхәй Хәбиб, хәрби корреспондентлар булып язучы Габдрахман Әпсәләмов, шагыйрь Гыйззулла Габидуллин (Гиз-эл Габид), журналист Каюм Иманкулов эшлиләр.

Бу газета битләрендә Г. Әпсәләмовның "Диңгезче" *(1945, 1 сентябрь)*, "Якташым" *(1945, 8 сентябрь)*, "Шанго!" *(1945, 19 сентябрь)* очерклары һәм "Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре" *(1945, 3 октябрь; Фатих Кәрим турында)* мәкаләсе басылып чыга.




**XVI. "СУВОРОВЧА КЫСЫРЫКЛАУ"** газетасы Байкал арты—Амур хәрби округында 1945 елның 28 июнендә оештырыла. Ул Читада дүрт битле булып чыга. Япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләре башлангач, газета корреспондентлары Читадан Монголия далаларын, соңыннан каты сугышлар белән Зур Хинган тауларын һәм Маньчжурия кырларын үтеп, Маньчжурия башкаласы Чанчуньга кадәр барып житәләр. Газета атнага ике тапкыр дүрт битле булып чыга.

Форматы—40х30 см. Редакциянең адресы: 7432-П кыр почтасы. Газетаның редактор урынбасары булып журналист Минһаж Гыймадиев, хәрби корреспондентлар булып язучылар Афзал Шамов һәм Абдулла Әхмәт, журналистлар Котдус Ахмеров һәм Фазыл Басыйров эшлиләр. Кытай җирләрен япон самурайларыннан азат иткәч, бу газета Чанчуньнан эшелон белән Хайлар, Маньчжурия һәм Каримово шәһәрләре аша Хабаровскига килеп җитә. Анда чыгуын 1947 елның апреленә кадәр дәвам итә. Редакциянең адресы: Карл Маркс урамы, 16 йорт.

Бу газета битләрендә. А. Шамовның "Порт-Артур—рус армиясенең даны" *(1945, 9 октябрь)*, "Без антыбызга турылыклы" *(1945, 4 ноябрь)*, "Күпне күргән сугышчылар җыелышы" *(1945, 22 декабрь)*, "Яңа елны каршы алганда" *(1945, 29 декабрь)*, "Якташлар" *(1946, 2 февраль)* h. б. очерклары һәм "Агач башмаклы кыз" исемле хикәясе *(1945, 31 октябрь, 4 ноябрь)* басылып чыга.

***

Бөек Ватан сугышы чорында татар телендә чыккан фронт газеталарының исемлеге менә шулардан гыйбарәт. Аларның гомуми бурычы—дошманны җиңү эшенә хезмәт итү була. Фронт газеталары сугышчыларга, сержантларга, офицерларга партия сүзен, Верховный Баш Командующий приказларын, документларын, чыгышларын, СССР Верховный Советы Президиумы Указларын, Совет Информбюросының оператив сводкаларын җиткереп торалар; бөтен совет халкының теләген белдереп, сугышчыларны яңадан-яңа батырлыкларга, каһарманлык күрсәтергә, көрәштә кыюлыкка, тапкырлыкка, чыдамлыкка чакыра. Сугышчыларның сәяси һәм рухи аннарын күтәрү белән бергә, фронт газеталары сугышчыларны һәм офицерларны хәрби осталыкка өйрәтү, бигрәк тә Бөек Ватан сугышы тәҗрибәсен туплау, гомумиләштерү һәм өйрәнү буенча чиксез зур эш алып баралар. Кыскасы, фронт газеталары дошманны тар-мар итүдә бик җитди роль уйныйлар. Менә шуңа күрә дә без—бүгенге буын кешеләре һәр елны Җиңү көне җиткән саен, фронтовик әдипләребезнең исемнәрен зур хөрмәт белән искә алабыз, аларның изге, бөек эшләре белән хаклы рәвештә горурланабыз.



*Бөек Ватан сугышында катнашкан бер төркем татар язучылары. Беренче рәттә, сулдан уңга: Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Зәйни Шаһиморатов, Мәхмүт Хөсәен, Шәраф Мөдәррис; Икенче рәттә, сулдан уңга: Халикъ Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакиров; Өченче рәттә, сулдан уңга: Габдрахман Әпсәләмов, Гамир Насрый, Әсгать Айдар, Абдулла Әхмәт, Вадим Земной, Хатип Госман; Дүртенче рәттә, сулдан уңга: Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Татарстан китап нәшриятының баш редактроы Хәсән Шабанов. Казан, Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы. 1947, 23 апрель.*

**Әлфия ШАМОВА**

# ФАБРИКАНТ АКЧУРИННАР ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Атаклы татар сәүдәгәрләре һәм фабрикантлары Акчуриннар нәселе—безнең халкыбыз тарихына Рәсәйнең XIX—XX гасырлардагы иң эре һәм булдыклы эшмәкәрләреннән берсе булып кереп калды. Шул ук вакытта алар киң күңелле һәм риясыз ярдәмчел меценат-иганәчеләр дә иделәр. Һәм әйтергә кирәк, Акчуриннар,—Рәмиевләр, Хөсәеновлар һәм татарның эшлекле даирәсенең башка бик күп танылган вәкилләре кебек ук,—мәгърифәт, әдәбият һәм сәнгатькә һәрвакыт һәерхаклы булдылар. Аларның мал-мөлкәте хисабына китаплар бастырылып чыгарылды, газета-журналлар нәшер ителде, мәдрәсәләр һәм башка төр уку йортлары ачылды һәм "асралып" киленде, Рәсәйнең һәм чит илләрнең югары уку йортларында студентлар укытылды. Татар халкының мондый милләтпәрвәр вәкилләре язучыларга, журналистларга һәм сәнгать әһелләренә һәрдаим матди ярдәм күрсәтеп килделәр. Әйтик, әлеге Сембер сәүдәгәрләре һәм фабрикантлары—Акчуриннар—гомумтөрки "Тәржеман"ны чыгаруга үзләренең керемнәреннән өлеш чыгарып киләләр (мәгълүм булганча, бу басманың мөхәррире Исмәгыйль Гаспралы Акчуриннарның кияве була). Алай гына да түгел, матди ярдәм күрсәтеп кенә калмыйча, Акчуриннар нәселе газетаны чыгарышуда турыдан-туры катнашлык кылалар. Мәсәлән, халык арасында зур абруй казанган бу басманы дөньяга чыгару вакытында Гаспринскийның хатыны Зөһрә ханым һәм Әсфәндияр әфәнде Акчуринның башка балалары да һич карусыз нашерлек итү белән шөгыльләнәләр.

Әйтергә кирәк, Акчуриннардан чыккан вәкилләр арасында иҗатка сәләтле кешеләр дә була. Җөмләдән, XIX гасырның 90 еллары башында Мөхәммәтҗан (Мөхәммәтша) Акчурин Н. В. Гогольнең үлемсез "Өйләнү" ("Женитьба") комедиясен татарчага тәржемә итә (ул, "Тәржеман" газетасының ун еллыгы уңаеннан, И. Гаспралыга үзенә күрә бер бүләк була). Бай тарихлы татар әдәбиятында Мәхбүбҗамал Акчуринаның да (1869—1948) үз урыны бар; Мәхбүбҗамал ханым "Шура" журналында төрледән-төрле хикәяләр бастырып килүче мәгълүм шәхес. Ә аның "Шәфкатьсез ата яки мишәрләр тормышы" дигән озын хикәясе 1914 елда Оренбургта аерым китап буларак та дөнья күрә.



*Хәсән Акчурин*

Мөхәммәтйосыф Мөхәммәтәмин улы Дебердиевнең дә нәсел җебе Акчуриннарга барып тоташа. Ул шагыйрь һәм публицист буларак танылa, аның 1910 елда Казанда нәшер ителгән "Эшче намазы" дигән китабы мәгълүм. Фабрикант һәм меценат Хәсән Акчуринның Мәскәүдәге йортында Гаяз Исхакый еш кына кунакта була. Кайбер публицистика әсәрләрен ул Акчуриннар һәм алар даирәсендәге кешеләр сөйләгәннәргә таянып иҗат итә. Үз вакытында киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булган шагыйрә Хәнифә ханым Гыйсмәтуллина XIX гасыр ахырларында Акчуриннарның Гурьевка авылында урнашкан фабрикаларында эшләүче эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең кыз балаларын укыта. Сүз дә юк, бер үк вакытта ул фабрикантларның кыз балаларына да сабаклар бирә, шул рәвешле "хуҗалар" белән тыгыз элемтәдә тора. Тимербулат Акчуринның Маһруй атлы кызы, мәсәлән, үзенең "кесә" акчасына әлеге авторның "Тәргыйб" *(кызыксындыру—Н. Т.)* дигән шигырьләр җыентыгын дөньяга чыгара.



*Шәмсениса Акчурина*

Акчуриннар арасында чын-чынлап әдәбият белән кызыксынучылар да аз булмый. Бу буын вәкилләренең бик тә бай китапханәләренең китап киштәләрендә татар, рус, һәм шәрекъ дөньясы һәм Көнбатыш Европа авторларының әсәрләрен күрергә була. Ибраһим Курамша улы, Хәсән Тимербулат улы һәм башка Акчуриннар татар әдәбияты үсеше белән һәрдаим кызыксынып, китапханәләре фондын Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый һәм башкаларның әсәрләре белән тулыландырып торалар, күп төрле газета-журналлар алдыралар.

Алай гына да түгел, Акчуриннар Россия кинлекләрендә чәчелеп яшәгән татар халкының әдәбияты һәм сәнгате вәкилләренең иҗатлары вә шәхси эшчәнлекләре белән кызыксынып яшиләр, аларны еш кына үзләренә кунакка чакырып, моназара кылып утыралар. Алар аеруча Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан белән дустанә мөнәсәбәттә гомер кичерәләр.

Әйтик, 1908 елда (кайбер мәгълүматлар буенча 1909 елда) фабрикант һәм татар дөньясының иң югары вә кунакчыл шәхесләреннән берсе булып танылган Хәсән Тимербулат улы Акчурин Г. Тукайны Сембер губернасы Карсун өязе Гурьевка авылына чакыртып ала.

Мондый омтылышның тарихы болайрак: Тукайның шигырьләре вакытлы матбугатта күренә башлау белән фабрикант аларның милли-халыкчанлыгына һәм фәлсәфи тирәнлегенә игътибар итә һәм шушындый кызыксыну нәтиҗәсендә анда шагыйрьнең үзе белән очрашып-күрешү теләге уяна. Ул шагыйрьне үзенә кунакка Казан сәүдәгәре Бәдретдин Апанаев аша чакырта. Бәдретдин әфәнде, шагыйрь даирәсендәге кешеләр ярдәме белән, Тукайдан сәфәргә чыгу өчен ризалык ала. Юл чыгымын ул тулаем үз өстенә ала: Казандагы танышлары һәм шагыйрьнең дуслары, аңа әйтмичә генә, Хәсән әфәнде җибәргән акчага Тукайны баштан-аяк киендерәләр дә юлга озаталар.

Дөрес, Тукайның кем белән берлектә сәфәргә кузгалуы турында безгә мәгълүм түгел, әмма К. Кадыйри истәлекләреннән бу сорауга күпмедер күләмдә җавап табарга мөмкин. Б. Апанаевка шагыйрьне кунакка барырга күндерә алганнан соң, ул Акчуриннарга телеграф аша болай дип хәбәр итә: "Габдулла Тукаев сезгә кунакка барырга ризалык бирде, фәлән числода мин Эрбеткә китәм, Тукайны үзем белән бергә алып барачакмын, чыгудан телеграмм бирермен". Тагын берничә көннән соң Акчуриннар Б. Апанаевтан, бу юлы инде сәфәргә чыгуларын белгерткән, икенче бер телеграмманы алалар. Моңа өстәп шуны гына әйтергә мөмкин: танылган Казан сәүдәгәре Б. Апанаев атаклы Эрбет ярминкәсендә даими катнашып һәм анда уңышлы сәүдә итеп килә.



*Барыш станциясенең хәзерге күренеше.*

...Барыш станциясендә шагыйрьне Акчуриннарның якын даирәсе бик җылы каршы ала; ә җилдән житез җигүле аргамаклар кадерле кунакны Барыштан өч чакрымда гына урнашкан Гурьевкага күз ачып йомганчы китереп җиткерәләр. Акчуриннар Тукайга иң зиннәтле "гүрнәчәдән" урын бирәләр. Татар ашлары белән тамак ялгап алганнан соң, фабрикант аның предприятиеләрендә шагыйрь иҗаты белән таныш күп кенә кешеләр эшләве һәм аларның кайберләренең Тукай әфәнде белән күзгә-күз очрашып сөйләшәселәре килүе хакында хәбәр итә. Һәм Россиядә яшәүче татарлар арасында иң мәртәбәле байларыннан берсе булган Хәсән Тимербулат улы шагыйрьдән аның хөрмәтенә аш мәҗлесе үткәрергә рөхсәт сорый. Тукай риза була. Тукталачак бүлмәсенә озата барышлый, Акчуриннарның балалары мөгаллиме Кыяметдин Ка-

дыйри шагыйрьне бильярд залына алып кереп чыга. Әлеге мөгаллимнең раславына караганда, Тукай бу мавыктыргыч уен белән менә шунда таныша. Истәлекнең авторы сүзләренә караганда, Гурьевкага килеп төшү белән Тукай ана Фатих Әмирханнан бер хат-мәктүп тапшыра, анда: "...Тукайны матур итеп күрсәтү, Тукайга күрергә тиешле булган урыннарны күрсәтү, Тукайны кунакка рәхәтләндереп тотып йөртү, озату эшләре сиңа йөкләнә",—дип әйтелгән була. Күренә ки, мөгаллимебез үзенең Ф. Әмирхан белән якын мөнәсәбәттә булуын ассызыклап күрсәтергә тели; әмма чынлыкта да шулай булганмы, әйтүе кыен.

Кич белән Акчуриннарның бай һәм иркен китапханәсенә чакырылган кунаклар җыела. Тукайның пәйда булуын хуҗалар да, кунаклар да аягүрә басып каршы алалар. Әлеге дә баягы К. Кадыйри билгеләп үткәнчә, хуҗа кеше очрашуны ачып җибәргәндә мондыйрак сүзләр әйтә: "Талантлы яшь шагыйребезнең сәламәтлеге һәм киләчәктә татар халкын тәрбияли вә рәхәтләндерә торган җанлы шигырьләрен тагын да күбрәк язсын өчен Габдулла әфәндегә озын гомер, матур тормыш теләп тост күтәрәбез". Бу кыска гына нотык та, безгә калса, Хәсән Акчуринның газиз халкына, аның әдәбиятына, сөекле шагыйренә булган ихтирамлы мөнәсәбәтен күрсәтә булса кирәк.

Акчуриннар йортында үткәрелгән әлеге кичә озак дәвам итә. Хуҗалардан тыш, анда катнашкан фабрика эшчеләре һәм хезмәткәрләре, Акчуриннар мәктәбе мөгаллимнәре һәм шәкертләре Тукайга сорау арты сорау яудырып кына торалар. Тукай исә, ул сорауларга кыска гына итеп, әмма төпле итеп җавап кайтара.

Шагыйрь фабрикантларда җиде-ун көн чамасы кунак була. Ә мондый очрашулар һәркөнне булып тора. Тукай, әлбәттә, фабрика белән дә танышып йөри.

Күренекле драматург Галиәсгар Камал, Тукай Казанга әйләнеп кайткач, бер әңгәмәсе турында болайрак язып үтә: "Тукайның кайтканын ишеткәч, мин аның янына менәм, ни күзем белән күрим, өстеннән яхшы киемнәрен, ак якаларын салып ыргыткан да эчке күлмәктән генә караватына сузылып яткан.

—Нихәл, бик шәп йөреп кайттыңмы, бик шәп сыйладылармы?—дигән сорауга каршы Тукай:

—Сыйлавын шартлаганчы сыйладылар, шулай да үземнең караватымны сагынып кайттым әле; безгә кул кешеләр түгелләр алар, әллә ничә горничный нянька шикелле ашаталар, нянька шикелле эчертәләр, нянька шикелле йоклаталар, үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк. Сыйлары да гел коньяк та шампанский, безнең шикелле кара корсакка кул нәрсәләрмени алар,—диде, ник барганына үкенгән көнгә төшкәнлеген белдерде".

Күренә ки, Г. Камал раслаганча, шагыйрь Акчуриннарны "безгә кул кешеләр түгелләр алар" дип исәпли. Мондый раслау чынлап та хакыйкатькә туры килә: Тукай һәм фабрикантлар җәмгыятьнең төрле баскычларында торалар лабаса. Ләкин әлеге истәлектә шагыйрьнең икенче төрле җавабы да бар ич: "горничный нянька шикелле ашаталар, нянька шикелле эчертәләр, нянька шикелле йоклаталар, үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк". Аңлашыладыр дип беләм, бу сүзләрдә шәхсән фабрикантларга карата әйтелгән бер генә үпкәләү сүзе дә юк, шагыйрь бары тик Акчуриннарның яшәү рәвеше башкача булуы турында гына сүз алып бара.

Тагын килеп, менә нәрсә хакында әйтәсе килә. Г. Камал Хәсән Акчуринның дөньяга карашы турында сүз алып барганда "укымышлы" сүзен куштырнаклар эченә ала һәм: "Ул фабрикант Хәсән Акчурин, мөселманча зур "укымышлы" кешеләрдән саналып, яңа әдәбиятны да сөючеләрдән булган..." дигән нәтиҗә чыгара. Әлеге меценатның тормышын һәм эшчәнлеген тикшеренүләрдән шул күренә; ул, чынлап та, заманының укымышлы һәм зыялы кешесе була, Г. Камал да, әлбәттә, бу хакта яхшы белгән булгандыр. Ләкин XX гасырның 20-30 елларында буржуазия вәкиленә, бигрәк тә татар баена карата хакыйкый бәһа бирү мөмкин эш булмый.

Г. Камалның һәм К. Кадыйриның әлеге хатирәләреннән "Тукай, Акчуриннар ихатасыннан һәм фабрикасыннан тыш, тагын кайларда истирәхәт кылып йөргән соң дигән сорауга җавап алуы кыен (шагыйрь, читлектәге кебек, дүрт дивар арасында гына бикләнеп ятмагандыр бит!). Билгеле, юк: фабрикантларның якын торыннары безгә Тукайны иң яхшы ял итү урыннары буйлап сәяхәт кылдырып йөрүләре хакында сөйләп калдырганнар иде. Ә, мәгълүм булганча, әлеге татар байлары бөтен Сембер губернасы кинлекләренә чәчелгән бик тә матур ял итү почмакларына хуҗа булалар...

Гурьевкада вакытта Тукай, күрәсең, Акчуриннарның башка туганнарында да кунакта булгандыр. Болай дигәндә, без Зөябаш (Старое Тимошкино) һәм Калны


(Калда) авылларында яшәүче туганнарын күздә тотам. Фабрикантларның биредә дә бик тә хозур ял итү урыннары булуы мәгълүм ич.

Әйтергә кирәк, Тукай белән Гурьевкада булган очрашу Акчуриннарның, аларның якыннарының һәм якташларының күңелендә якты эз калдыра. Әйтик, 1913 елның язында Тукайның вафаты хәбәрен ишеткәч, җирле мәктәпнең мөгаллимнәре һәм шәкертләре шагыйрь мәрәсименә багышланган митинг уткәрәләр, мәктәпләрдәге дәресләрне кичектереп үзенә күрә бер матәм игълан итәләр.

Сүз дә юк, Акчуриннарның Тукайга булган ихтирамлы мөнәсәбәте беркайчан да үзгәрми. Мәгълүм булганча, 1916 елның язында Россиянең төрки-татар дөньясы Г. Тукай вафатының өч еллыгын зур югалту билгесе итеп билгеләп үтә. Акчуриннар да, әлбәттә, бу чаралардан читтә калмыйлар. Һәм кала да алмыйлар. Матәм көннәрендә Акчуриннарның мануфактура фабрикасы каршындагы кызлар мәктәбендә (ул яки Гурьевкада, яки Зөябаш авылында була) Тукай истәлегенә багышланган кичә үткәрелә, кичәдә шагыйрьнең кабере өстенә куелачак таш-һәйкәл өчен 97 сум акча җыела. Ә инде кичә чынлап та Гурьевкада үткәрелгән икән, аны оештыручылар арасында фабрикант Габдулла Тимербулат улының хатыны Гөлсем ханым Камалова да булгандыр, мөгаен. Ни генә булмасын, тарих безгә Гөлсем Акчурина (Камалова) җитәкчелегендәге әлеге мәктәбе укытучы мөгаллимәләрнең һәм укучы кыз балаларның бергәләп төшкән фотосурәтен саклап калган. Рәсем 1916 елда, дөресрәге, 15 июньдә алдырылган. Бездә булган мәгълүматларга караганда, рәсемдәге күп кенә балалар югарыда телгә алынган әлеге кичәдә катнашкан булырга тиешләр. Һәрхәлдә, үз вакытында шул тирәләрдә яшәгән өлкән яшьтәге апа-агайлар Акчуриннарның тора торган йортында, мәктәбендә, клубында һәм китапханәсендә музыкаль-әдәби кичәләр һәм очрашулар уздыру традициясе яшәп килүе хакында сөйләп калдырганнар иде.

Гомумән, ул төбәкләрдә яшәүче татарлар сөекле шагыйрьләренең иҗатын кызыксынып күзәтеп баралар: аның китаплары бик күп гаиләләрнең шәхси китапханәләрендә урын алган. Тукайның 1913 елда Казанда нәшер ителгән "Исемдә калганнар" дигән китабы, мәсәлән, Волковлар гаиләсендә буыннан-буынга тапшырылып киленгән. Соңгы хуҗасы Зөләйха ханым Таирова (кыз фамилиясе—Волкова) үтенече буенча мин ул китапны 1995 елда Казандагы Габдулла Тукай музеена тапшырдым.

Табигый буларак, Акчуриннарның "җанлы" сурәте шагыйрьнең әсәрләрендә дә чагылыш тапмый калмый, әлбәттә. Әйтик, "Шыер" дип аталган бер шигырендә шагыйрь болай ди (ул Фәхрелислам Агиевның бер тезмә әсәренә пародия рәвешендә язылган): "Нишләсен вет, Азраил килсә, бар кеше үләр, Тимай бай булсаң да—азанчы күмәр". Ул—1912 елда иҗат ителә һәм шул ук елда "Ялт-йолт" журналында басылып та чыга. Тукайның 5 томлык "Әсәрләр"ен төзүчеләр *(Казан, 1985—1986)* Тимай бай *(Тимербулат Акчурин—Н. Т.)* образында нигәдер "байлыгы, малга хирыслыгы, саранлыгы һәм каты куллылыгы белән телләргә кергән сәүдәгәр"не күрәләр. Безнеңчә, бу—"теге" еллар шаукымы нәтиҗәсе һәм ул берничек тә хакыйкатькә туры килми. Аннары, без китереп киткән өзектә татарның эре сәүдәгәре һәм унган фабриканты турында бернинди дә тискәре бәяләмәләр юк, шагыйрь бары тик вакытның бик тиз узып китүен, бар кешеләрнең дә вакыты җиткәч үлемгә дучар ителүен искәртергә тели: әйе, үлем каршында байлар да, ярлылар да бертигез. Тукай әйткәнчә, үлем дигәнең Тимербулат кебек шәхесләрне дә аяп тормый шул...



*Гурьевкадагы Акчуриннар йорты (хәзерге Барыш шәһәре).*

...Шулай итеп, бөек татар шагыйре Габдулла Тукай Барыш авылында (элеккечә—Гурьевкада) кунакта булып кайта. Бирелә Тукай һәм Акчуриннарның башка бик күп кунаклары тукталган йорт хәзерге көнгә хәтле сакланып калган. Без, шушы төбәктән чыккан берничә кеше берләшеп, әлеге вакыйганы тарихка теркәп калдырырга тырышып йөреп карадык. 1989 елда, әйтик, Барышның берәр урамына Тукай исеме бирү һәм Тукай тукталган Акчуриннар йортына мемориаль такта кую турындагы тәкъдим белән (хәзер анда район үзәк хастаханәсенең поликлиникасы урнашкан) җирле хакимият җитәкчеләренә һәм депутатлар корпусына мөрәҗәгать иттек. Әлеге тәкъдимнәр "Ленин юлы" дигән район газетасында басылып чыккан мәкаләгә дә нигез булып ятты. Бу фикерне бирелә булып киткән шагыйрьләр Р. Миннуллин, Р. Гаташ һәм журналист Ф. Низамовалар да хуплаган иде. Соңрак, журналистларның үтенече буенча, Г. Камал һәм К. Кадыйриның истәлекләре күчермәсен газета редакциясенә һәм шәһәр советының башкарма комитетына да юлладык. (Бу мәсьәләдә безгә мөхтәрәм әдәбият галимнәре Нил Юзиев, Марсель Әхмәтжанов һәм Зөфәр Рәмиев зур ярдәм күрсәттеләр.) Район газетасы исә, үз чиратында 1990 елның җәендә безнең үзара хат алышуыбыз хакында болай дип язып чыкты: "Татар халык шагыйре Г. Тукайның Гурьевкада булып китүенә бәйләнешле вакыйгалар унаеннан кызыксынган кешеләр белән язышып торуыбызга да бер елдан артык вакыт узып китте. Әле узган елның апрель аенда ук Казанда яшәүче Таировлар, әлеге вакыйганы мәңгеләштерү максатыннан чыгып, шагыйрь тукталган Акчуриннар йортына мемориаль такта кую яки берәр урамны аның исеме белән атау кирәклеге турында тәкъдим белән чыктылар.

Шул вакыттан бирле кәгазьләр шактый язылды. Апрель-июнь айларында гына да безнең тарафтан фактлар документаль төстә исбатланган өч хат алынды. Ә исемне мәңгеләштерү турындагы карарны бары тик хуҗа гына—ягъни шәһәр советы башкарма комитеты кабул итәргә мөмкин, ләкин һич тә редакция түгел. Ләкин, шулай да, КПССның шәһәр комитеты каршындагы эшче группаның чираттагы утырышында бу мәсьәлә буенча шәһәр советына бернинди дә тәкъдим кермәве ачыкланды, хәер, асылда моңа карата каршы фикерләр дә юк".

Ниһаять, 1991 елда әлеге газетада, русчага тәрҗемә ителеп, Г. Камал белән К. Кадыйриның истәлекләре бастырылды. Әлеге мәсьәлә 1995 елда Ульяновск өлкәсендә чыга торган татарча "Өмет" газетасы битләрендә дә күтәрелде. Кызганыч ки, кем әйтмешли, боз әле һаман да кузгалмады: шагыйрьнең исеме дә ташка уелмады, Акчуриннарның яхшы атлы абруе да тарих пәрдәсе артында кала килә. Болары, әлбәттә, сүз унаенда әйтелде.

...Акчуриннарга кунакка бер Тукай гына килми, билгеле. Фабрикантлар 1913 елның көзендә олуг татар язучысы Фатих Әмирханны кунакка алдыралар. Бәхеткә күрә дип әйтик, Тукайдан аермалы буларак, Фатих Әмирхан "Кояш" газетасында басылган "Милли көтепханә һәм музәханә" дигән мәкаләсендә хуҗалар турында кыскача мәгълүматлар бирә: бирелә әдип Хәсән Акчурин шәхесенә карата бик җылы сүзләр әйтә, аның югары гыйлемле булуын билгеләп үтә. Ф. Әмирхан фикеренчә, ул гарәп теле һәм Ислам тарихы буенча тирән белемле татар муллаларыннан бер дә калышмый.

Ф. Әмирхан үзенең әлеге мәкаләсендә Хәсән байның китапханәгә һәм мөселман дәүләтләрендә басылган борынгы акчалар коллекциясенә ия булуын да билгеләп үтүне кирәк таба. Ул болай дип яза: "Күптән түгелге бер сәфәремдә мин мәшһүр татар фабриканты Хәсән әфәнде Акчуринда кунакта булдым. Хәсән әфәнденең күп китаплы әгъла көтепханәсе һәм үз иҗтиһады вә мәгърифәте белән җыелган, иске мөселман мәмләкәтләрендә сугылган тарихи тәнкәләр коллекциясе бар икән.

Яхшы бер татар мулласы кадәрголүме гарәбия вә голүме исламиядән хәбәрдар, ислам тарихы белән күп шөгыльләнгән бу татар фабрикантының кирәк көтеханәсе вә кирәк тәнкәләр коллекциясе, яхшы тәфтиш вә голүм белән җыелганга күрә, кыйммәтле нәрсәләрдер. Бөтен ислам хәлифәләре заманында сугылган тәнкәләрне хави (эченә алган) бу тарихи тәнкәләр коллекциясен Хәсән әфәнде күп иҗтиһад, мәгърифәт вә акча сарыф итеп җыйган булганлыктан, теләсә нинди музә өчен әһәмиятле булырлыктыр".

Мәгълүм ки, Хәсән Тимербулат улы 1914 елда гына да 6 мең мөселман акчаларын сатып ала, шул рәвешле аның болай да бай коллекциясе 15 мең данәгә җитә. Шунысын да искәртергә кирәк, фабрикантның уникаль коллекциясендә хәтта Россиянең күренекле дәүләт музейларында булмаган сирәк акчалар да саклана. Җөмләдән, габбасилар һәм өммиядләр хәлифәләре вакытында сугылган акчалар коллекциясенең зур байлыгы булып саналырга хаклылар. Шушы ук елда нумизмат Аксак Тимернең берничә акчасын да сатып ала.

Ф. Әмирханның шушы язмасында без бик тә әһәмиятле бер сорауга җавап алабыз кебек: фабрикант Хәсән Акчурин кульязмалар, китаплар, вакытлы матбугат һәм музей экспонатларының уникаль коллекциясен кем өчен һәм нәрсә өчен җыйган соң? Ф. Әмирхан моны болай аңлата: "Милли көтепханә вә музәханә ачылса, көтепханә һәм тәнкәләр коллекциясеннән әһәмиятле бер кыйсемен шул мөәссәсәләргә (оешма, учреждениегә) хәдия итәргә Хәсән әфәнде хәзер тора вә вәгъдә итә".

Хәсән әфәнденең шундый да абруйлы зат тарафыннан китерелгән әлеге фикерләреннән чыгып, без коллекцияләр, кульязмалар һәм китапларны ул үз мәнфәгатьләреннән битәр, татар халкының киләчәк буын вәкилләре өчен җыйган дип әйтә алабыз. Әлбәттә бит тә кызганыч, Хәсән Тимербулат углы исән вакытта татар халкына ни милли музей, ни милли китапханә ачарга мөмкинлек булмый.

Фатих Әмирханның сәяхәтенә кагылышлы тагын бер вакыйганы искәртеп китәргә кирәк. Әдип Гурьевкада вакытта Акчуриннарның берсенең, Рөстәм Исмәгыйль улының хатыны Шәмсениса белән очрашкан булырга тиеш. Ул, үз чиратында, Чистай ишаны, җирле мәдрәсәнең имам-хатыйбы Мөхәммәтзакир Камаловның кызы була, яшьлегендә әдип аңа гыйшык тотып йөри. (Бу мәдрәсәдә күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый, язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими, шагыйрь Зыя Ярмәки һ. б. белем ала.)

Очрашу ихтималын без нәрсәдән чыгып гоманлый алабыз соң? Хикмәт шунда ки, Камаловлар һәм Акчуриннарның киләчәк буын вәкилләре архивында 1913 елның 4 ноябрендә Оренбург губернасының Троицк каласыннан Гурьевкага Габдулла Акчурин исеменә җибәрелгән почта карточкасы саклана. Әлеге юлламаның авторы Камаловлар—Әмирхановларның туганы Шакир Мәүледов була һәм ул Бибифатыйма Садыйк кызы Камаловага атап сугыла. Димәк, ишан Мөхәммәдзакир Камаловның хатыны шушы көннәрдә Акчуриннарга кунак булып төшкән дип әйтә алабыз. Тагын бер кызыклы нәрсәгә игътибар итик: корреспонденция—мәктүптә Зәйтүнә Мәүледова исеме дә телгә алына. Белгәнебезчә, Тукай нәкъ менә аңа гыйшык тотып йөри ләбаса. Баксаң, Тукай, Акчуриннар, Камаловларның язмыш җебе бер кавым менә шулай үзара чорналып алган булган икән...

Акчуриннар токымының килен-киленчәкләре дә әдәби иҗатка мөнәсәбәтле булалар. Шуларның берсе—югарыда телгә алынган Рөстәм Исмәгыйль улы Акчуринның хатыны Шәмсениса ханым.

Шәмсениса ханым, ишанның башка кызлары кебек үк, үз заманының укымышлы хатын-кызларыннан санала. Ул татар һәм рус әдәби телен яхшы белә, иҗат эшенә сәләтле булуы да иртә сиземләнә. Шәмсениса ханым И. Н. Потапенконың "Букет" дигән бер пәрдәлек пьесасын татарчага тәрҗемә итә һәм ул 1910 елда Казанда "Букет" ("Чәчәк") исеме белән Бөрадарән Кәримовлар типографиясендә аерым китап булып басылып та чыга. Бик мөмкин, әлеге китап Акчуриннар акчасына дөнья күргәндер, чөнки Шәмсениса 1909 елдан фабрикантларның гаилә әгъзасы булып китә ич (аннары, безнең кулдагы мәгълүматларга караганда, Акчуриннар нашерлек эше белән дә шөгыльләнгәннәр икән). Без фәкыйрегезгә әлеге китапчыкның Сембер губернасы Сенгилей, Карсун һәм башка өязләрендә яшәүче татарлар арасында шактый киң таралуын ачыклау мөмкин булды. Аерым алганда, ул Ульяновск өлкәсе Барыш районы Калда (Калны) авылында гомер кичергән әнием Зөләйха Габдрәшит кызы Таированың шәхси китаплары арасында да бар иде. Сүз дә юк, әлеге китапчык Акчуриннарның китапханә шүрлекләрендә дә урын алгандыр.

Бер унайдан тагын бер мәсьәләне ачыклап китү зарур дип исәплим: Биби Шәмсениса туташ Фатих Әмирхан белән кайчан һәм нинди шартларда очрашырга мөмкин соң? Әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин үзенең "Яңа-Татар бистәсе Прометее" дигән китабында 1908 елның ахырларында Шәмсениса Казанда булып китә дип раслый. Кызык, ә ул кемнәрдә тукталды икән? Күп кенә эзләнүләр нәтиҗәсендә Камаловлар гаиләсе белән бәйләнешле почта карточкаларының эзенә төшәргә мөмкин булды. Бу "ачык хатлар" Казанга "Ф. С. Камаловага", ягъни Мөхәммәдзакир ишанның хатыны Бибифатыймага (Фатимага) һәм "Камаловага" (бәлки аңа ук, яки кызларынадыр) адресланган. Сарапулдан һәм Чиләбедән алынган хат-мәктүпләрдә Камаловларның адресы түбәндәгечә күрсәтелгән: "г. Казань, Попер. Казанская ул., дом Баланченко (или Баланчикова)" һәм аларга "1911 елның марты" дип мөһер сугылган. Күрәсең, Камаловлар гаиләсе шушы адрес белән аерым йорт яки бүлмә алып торганнардыр. 1908 елның ахырларында, Фатих Әмирхан белән очрашкан көннәрендә, бәлки Шәмсениса Камалова да биредә гомер кичергәндер? Бәлки, бәлки...

Шәмсениса, мәгълүм булганча, гомерлек юлдашы итеп Рөстәм Исмәгыйль улы

Акчуринны сайлап ала. Әйтергә кирәк, Исмәгыйль әфәнде, Курамша, Сөләйман, Тимербулат һәм башка Акчуриннар кебек "череп беткән" бай булмый.

Рөстәм Исмәгыйль улы үзенен бай туганнарынын фабрикаларында хезмәт итә. Рөстәм белән Шәмсениса никахлашканнан сон Акчуриннарнын фабрикалары урнашкан Сембер губернасына керүче торак пунктларында һәм Ульяновскинын үзендә гомер кичерәләр.

Әдәби эшчәнлек юнәлешендә Акчуриннарнын икенче бер киленнәре—Өммегөлсем (Гөлсем) Камалова да маһирлык күрсәтә. Ул Мөхәммәдзакир ишан һәм Бибифатыйма Камаловаларнын кече кызлары була. Гөлсем башта Чистай мәдрәсәсендә белем ала, аннары Санкт-Петербургнын атаклы Бестужев курсларында тәрбияләнә. Балкан сугышы башлангач, дуслары-фикердәшләре Мәрьям Поташева, Оркыя Юнысова һәм Мәрьям Якупова белән берлектә ерак Төркиягә юл ала. Татар кызлары биредә 1912 елнын көзеннән алып 1913 елнын көзенә кадәр хәрби лазаретларда төрек сугышчыларын дәвалыйлар. Шәфкать туташларына карата гади халык вәкилләре генә түгел, хәтта илнен житәкче әһелләре дә кызыксыну күрсәтәләр. Гөлсем һәм анын дус кызлары белән танылган сәясәт эшлеклесе, Сембер губернасы Зөя башы сукно-постау мануфактурасына нигез салучы Сөләйман Габдулла улы Акчуриннын оныгы Йосыф Акчура да очрашып сөйләшә. Төркиядә булып кайту Гөлсемне һәм анын юлдашларын Россия империясенен бөтен мөселман дөньясына таныта: алар хакында жәмгыятьнен төрле катламнарында мактау сүзләре сөйлиләр, газеталарда мәкаләләр урнаштыралар. Бер газета болай дип язып чыга: "Моннан бер ай элек, бернинди галижәнапләргә ишарәсез һәм белдерүсез, дүрт мөселман хатын-кыз жәмәгате-мөгаллимә, курсистка һәм ике табибә Петербургта вагоннарга утырдылар да Константинопольгә юл алдылар. Менә бер ай инде алар, ару-талуны белмичә, жәрәхәтләнгән кул-аякларны һәм тишкәләнгән баш сөякләрен юалар һәм бәйлиләр". Фидакарь йөрәкле кызларнын фотосурәтләре ул елларнын күп кенә басмаларында басылып та чыга.

Бөтен татар мохитын тетрәткән Тукайнын үлеме турында кайгылы хәбәр аларга 1913 елнын язында ерактагы бер илдә вакытта килеп ирешә. Шәфкать туташлары үзләрен озатып йөрүче танылган журналист һәм театр тәнкыйтьчесе Кәбир Бәкер белән берлектә "Ан" журналына тәгъзия—кайгы уртаклашу телеграммасы сугалар. Анда болай диелә: "Вакытсыз вафаты хәбәре безне сон дәрәжәдә мәэъюс итте..." Истанбулдан сугылган тәгъзиягә Гөлсем, Оркыя, Мәрьям һәм Кәбир кул куя.

Бу урында шунысын искәртеп китү дә урынлы булыр: Гөлсем туташ Тукайны 1912 елнын апрелендә, Петербургка ясаган сонгы сәфәре вакытында күреп кала. Очрашу Г Тукай тукталган күренекле дин белгече, башкала мәчетенен имам-хатыйбы Муса Бигиев йортында була. Үзенен мәгълүм истәлегендә Кәбир Бәкер Муса әфәнденен хатыны ягыннан туган тиешле бер курсистка турында да искә алып үтә. Билгеле булганча, Муса Бигиев Гөлсемнен бертуган апасы Әсма Камаловага өйләнгән була.

Шушы ук 1913 елда Гөлсем Камалованын икенче бер абруйлы журналда да бербер артлы мәкаләләре дөнья күрә; болар "Төрекләр яшәячәктер" *("Шура", 1913, N 6, 175-176 бб.)*, "Тәгаләи нисван" жәмгыятендә" *("Шура", 1913, N 7, 203-204 бб.)*, "Төрек хатыннары" *("Шура", 1913, N 8, 232-233 бб.)* кебек язмалар.

Туган ватанына әйләнеп кайтуга диярлек үк Гөлсем Камалова әлеге нәселнен ин күркенле вәкилләреннән берсе булган Тимербулат әфәнденен улы Габдулла Акчуринга кияүгә чыга. Шул рәвешле ул Акчуриннарнын Гурьевкалагы йортында хужабикә булып китә. Гөлсем ханым Акчуриннар химаясендәге мәктәпкә житәкчелек итә—атаклы Бестужев хатын-кыз курсларында алган ан-белемнен менә кайда кирәге чыга. Фабрика эшчеләре һәм хезмәткәрләренен кызлары истәлекләренә караганда, Гөлсем ханым математикадан бик гыйлемле була, башка фәннәрдән дә төпле вә тәрбияви әһәмияткә ия дәресләр бирә. Шикләнми әйтергә мөмкин, укучыларына ул Габдулла Тукайнын тормышы һәм ижаты турында да сөйләми калмагандыр.

Кыскасы, Сембер сәүдәгәрләре һәм фабрикантлары Акчуриннарнын татар әдәбиятынын күренекле вәкилләре белән үзара мөгаләмәсенә бәйләнешле кайбер истәлекләр менә шуннан гыйбарәт. Димәк, югарыда сөйләгәннәрдән чыгып, Акчуриннар милли мәдәният һәм әдәбият язмышы белән даими рәвештә кызыксынып торганнар, билгеле бер күләмдә мәгариф һәм наширлек өлкәсендә дә ижтиһад иткәннәр, дип әйтә алабыз.

**Наил ТАИРОВ,**

*тарих фәннәре кандидаты.*

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КИРИЛЛИЦА***—Беренче славаян алфавиты, грек алфавитына нигезләнгән. Изге Кирилл һәм Мефодийларның шәкерте Кирилл Болгарский тарафыннан төзелгән. Бу алфавитта барлыгы 36 хәреф булып, күп кенә хәрефләр, грек әлифбасындагы кебек үк, цифрларны да белдергәннәр. Кириллица белән язылган беренче русча Инҗил 1097 елга нисбәт ителә. 1707 елда Петр патша кириллицага нигезле-нигезсез үзгәрешләр кертә, аңардан соң аерым үзгәрешләр, мәсәлән, язучы Карамзин тарафыннан кертелгән. Октябрь инкыйлабыннан соң кириллица беркадәр гадиләштерелде. 1863 елдан алып керәшеннәр дә берничә хәреф өстәлгән кириллицадан файдалана башлаганнар. Аларга бу алфавитны русификатор Ильминский әзерләп биргән. Узган гасырның 30 нчы еллары ахырыннан СССРда яшәүче төркиләр дә, әле күптән түгел генә үзләштергән латиницаларын ташлап, кириллицага көчеп беттеләр һәм күбесе хәзергә кадәр шушы ят һәм уңайсыз алфавиттан файдалана. Татарларның яңартылган латиницага кайту буенча тырышлыклары әлегә нәтиҗә бирмәде. Әзәрбайҗаннар латиницага кайттылар, монголлар да рус алфавитыннан баш тартырга җыеналар.

***КИРПЕЧ***—Төрки сүз, термин буларак рус теленә дә үтеп кергән. Бу исә төзелештә кирпеч куллануның башта төрки халыкларда булганлыгы турында сөйли. Мәхмүд Кашгарый сүзлегенә караганда, ул заманнарда (XI гасырда) ук инде төркиләр яндырылган кирпеч кулланганнар ("бешег кирпеч"), кирпечне калыплар белән сукканнар.

Терминның мәгънәсенә килгәндә, Морад Аджи: "Дөресрәге "кир-печ"—"печтән *(мичтән-А.Т.)* чыккан балчык",—дип аңлату яклы. Чыннан да төркиләр килеп чыкканчы Европа кирпеч дигән нәрсәне белмәгән һәм кантарташтан яки плинфадан төзү белән канәгатьләнгән. Русларның да борынгы корылмалары бүрәнәдән яки акташтан булган.

Кирпечнең киңлеге ике карыш чамасы (27-28 см), калынлыгы 3 иллегә кадәр (5-6 см) булган. Болгар чоры кирпечләре еш кына квадрат формасына якын итеп сугылганнар һәм яндырылганнар. Биләр шәһәрлегендәге XI гасырга караган корылмаларда чи кирпеч тә кулланылган.

Казандагы Сөембикә манарасын төзегәндә 30x15x8 см лы эре бөртекле кызыл кирпеч кулланылган.

Иске чыганакларда *(мәс., "Шура" журналында)* фарсыдан алынган *хишт* (кирпеч) сүзе дә очрый.

***КИРТӘ СИКЕРҮ***— Баштагы мәгънәсе "күчмә киез өйнең курасыннан чыгу, ягъни ил даирәсеннән чыгу" булган. Болгар илендә Ислам рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң, аерым төркемнәрнең яңадан мәҗүсилеккә кайтуларын да "киртә сикерү" дип атаганнар. Татарларны руслаштыру сәясәте алып барылган чорларда бу тәгъбир телдә яңадан активлашкан *(Н.Исәнбәт буенча)*.

***КИСТӘН***—"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә: "Кыска таякның бер очына чылбыр яки каеш ярдәмендә тимер шар, гер һ.б.ш. авыр әйбер беркетелгән, ә икенче башында кулга кию өчен элмәге булган борынгы сугыш коралы". Е.Н.Шипованың "Словарь тюркизмов в русском языке" сүзлегендә "кистән"нең татар һәм башкорт

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

телләрендә "кечкенә сөңге" ("дротик") мәгънәсенә дә ия булуы теркәлгән. Яшьләр урамга кистәнне җиң эченә яшереп тә чыккалаганнар. "Кистән" сүзе рус теленә дә кергән, ягъни аның русча "кисть" ("кул чугы") сүзенә катнашы юк.

***КОЗГЫН***— Төрки бабаларыбыз тарафыннан изгеләштерелгән кош. Козгынның үз-үзен тотышына карап яхшыга яки яманга юрау системасы булган. Төркиләрдә *карга, торна, ләкләк, шонкар* кебек кошлар да изге саналган. Бу факт "Дәфтәри Чыңгызнамә"дә дә телгә алына. Кайбер риваятьләргә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәрне әнисе Әминә сахрада таба, баланың кендеген өзү өчен Аллаһы кендек әбисе итеп бер козгын җибәрә.

***КОЙАР*** *тар.* — Төрки һәм Хәзәр каһанлыкларында, Алтын Урдада сугыш атлары өчен саклагыч кием. Башлыктан, күкрәкчәдән һәм ике яктагы ябынчалардан торган. Алтын Урдада күннән, күп катлы итеп киездән эшләнгән һәм тимер тәңкәләр белән капланган койарлар кулланылышта булган.

***КОМГАН***—Таһарәт алу комганы безнең көнкүрешкә Исламга кадәр үк үтеп кергән дип уйлыйлар. Үзбәкләрдә, мәсәлән, комган юк. Алар, йомышларын үтәгәч, балчык белән сөрткәннәр. Борынгы римлыларда исә моның өчен гаиләдә һәркемнең үз ташы булган. Комган сүзе ("кумган") Мәхмүд Кашгарыйның (XI гасыр) "Диване лөгатет-төрк" сүзлегенә дә кергән ("су салу өчен савыт"), ләкин аның гигиенага кагылышлы мәгънәсе теркәлмәгән. "Древнетюркский словарь"да исә су һәм башка сыеклыклар салу һәм юыну өчен кулланылган кувшин-*бурнак* теркәлгән. Исеменә караганда, аның борыны да булган дип уйларга кирәк. Шулай булгач, төркиләрдә беренче комганнар чыннан да Исламга кадәр дә булган дип әйтә алабыз.

Минзәлә сөйләшендә *чәй комганы* — чәйнек. Фатих Кәримидә чуеннан ясалган комган-*кәтмәр* сүзе очрый. Ул: "Моның илә һәм чәй эчәрләр һәм дә әбдәст (таһарәт) алырлар," — дип яза.

Электә телдә гарәптән кергән *ибрикъ* сүзе дә йөргән (комган, чәйнек, борынлы савыт).

Комганның безгә кайсы яклардан килүен түбәндәге табышмаклар ачык күрсәтә: "Бохара песие бит юа", "Бохарадан килгән елтыр, койрык очы чоптыр", "Бохарадан килгән торна башын сузып су эчә."

"Комган" сүзен В.Даль дә сүзлегенә терки һәм аңа "металлдан эшләнгән азиат кул юынгычы, борынлы, тоткалы һәм капкачлы кувшин" дигән аңлатма бирә. Электә көмеш комганнар да булган, гомумән, комганның күркәмлегенә һәм чисталыгына игътибар иткәннәр.

Казан ханы Мөхәммәд Әминнең бакырчы остасы Насыйр җиз комганга нииндидер шигъри әсәрдән бер өзек чокып язган.

Комган борыны башындагы бөҗра "комганның мулласы" дип атала һәм кайбер төбәкләрдә мулласыз комган белән мәет юу дөрес булмый дип тә санаганнар. Имансызлык хакимлек иткән елларда "комган" сүзе үзе үк артталык, искелек билгесе булып карала башлаган иде. Телдә, мәсәлән, гарәп хоруфатын "комган хәрефләре" дип атау, комганның үзен "комган шәрифләре" дип мыскыллау еш очрый иде. Әйтик, Фатих Әмирхан "комган ияләре" мәгънәсендә "сахибелкомганнар" дигән төртмә сүз кулланган.

Халыкка иман кайта башлагач, сәнагәчеләр матур-матур комганнар җитештереп сатуга чыгардылар.

***КОНДЫЗ ШИФАЛЫГЫ*** *тар.* — Ата кондызның мускус бизеннән алынган сары-коңгырт төстәге сыек майсыман матдә, исле сыекча (русча: *бобровая струя*). Электә кыйммәтле дару булып исәпләнгән. Кипкәч, бармак арасында уалучан коңгырт массадан гыйбарәт. Элек аны төнәтмә рәвешендә кулланганнар. Урта гасырларда Болгар йортыннан чит илләргә чыгарылган товарларның берсе. Вогуллар (мансилар) кондыз шифалыгы белән нәпакь (мәс., хатын-кыз кагылган) нәрсәләрне төтәсләп "пакьләндергәннәр".

Габделвахид мөфти ибне Сөләйманның 1816 ел, 2 февральгә караган кульязмасында "җәндбад" дигән үсемлек даруы турында сүз бара. Аны төрки телдә "углан ашы" дип атыйлар икән, ә рус телендәге исеме — "бобровая струя" (кульязмада: *"бобровый*

*острога"*). Габделвәхид ибне Сөләйман аны "кондыз кайрысы" дип тә атый. Телдә *кондыз уылдыгы (йомыркасы)* дигән сүз дә йөргән. Чыннан да "Древнетюркский словарь"да *"кондыз кайри"* дигән терминга тап булабыз, аннары төркидә *кондыз уылдыгы (йомыркасы)* дигән сүз дә булган. // *Кундуз кайры сувта кинләп туртсун*-кондыз кайрысын суда эретеп (?) сөртсен [битенә]. Борынгы төркичәдән.

Кондыз шифалыгыннан башка, *кабарга шифалыгы* дигән төшенчә дә бар.

***КОРАҖАН*** *бор.* —Аракы, дүрт тапкыр куылган исерткеч эчемлек. Өч тапкыр куылганын *аражан* дип атаганнар. // *Коражан пешеру ("Козы Көрпеч"тән.).*

***КОРГАНЧЫК*** *тар.* — Күчерелмәле агач бура. Шәһәрләрне камап торганда кулланылган. Һади Атласи: "Рузнамәләрнең "тарасы" дип атадыклары нәрсәне без корганчык дип йөртәбез", — дип аңлата. Елъязмаларда Казанда һәм Русьта тараса/ тарасы дигән сугыш җайланмасы булуы телгә алына. *Тәраз, тәразу* — фарсы телендә *үлчәү, бизмән.* Чыннан да бу җайланма зур көянтәле үлчәүгә яки хәзерге сиртмәле төзелеш кранына охшаган булып, шәһәрләрне камап торучыларга ныгытма диварлары аша сугышчыларны шәһәр эченә төшерү өчен хезмәт иткән. Корганчык, әлбәттә, шәһәр эчендәгеләргә камап торучылар ягына (аларның артына) төшәргә дә мөмкинлек биргән.

***КОРЫЧ***—Тимернең карбон (углерод) һәм кайбер башка элементлар катнашкан эретмәсе, булат (пулад). Борынгы төрки телдә *курч тәмур* — үткен тимер, корыч. Кырым татарлары телендә "корыч"-*челик,* төрекчәдә дә шулай. Идел-Чулман төбәге халыклары (чуаш, мари, удмурт) телендә "корыч"ка охшаш яңгырашлы сүзләрнең булуы монда корыч коюның күптән билгеле булуы турында сөйли (Болгар Йорты Европада беренчеләрдән булып тимер эретеп ясарга өйрәнгән). Рус телендәге *сталь* (корыч) сүзе немец теленнән кергән, XVIII гасыр башыннан ук билгеле, ләкин яхшы корычны руслар да Шәрыктан кергән *булат* сүзе белән атаганнар. // *Корычагач*-дардар агачы (бу очракта атама халык этимологиясе нигезендә генә килеп чыккан, Р.Әхмәтьянов фикеренчә, дөресе — *көреч агачы* булырга тиеш). *Дәмәшкъ корычы. Корыч каләм* (каурый һәм җиз каләмнәргә алмашка Европадан килгән).

***КӨН, КӨНӘШ*** *бор.төр.* — Кояш. Борынгы чыганакларда: *кун.* "Көн" сүзенең бу мәгънәсе Себер татарлары телендә актив: *көн куну* — кояш баю, *көн чыгу*-кояш чыгу, *көнкуныш* — көнбатыш. // *Көнәш нур вә эсселекне чыбарланмыш кырларда чәчмеш иде.* М.Акъегет. *Кумуш кунгә урса, алтун адакун келир* — "Бирәү кояшка көмеш куйса, алтын булып кайтыр" мәгънәсендә. Бу мәкаль "Диване лөгатет-төрк"тә очрый. Борынгы төрки телдәге "куйаш" сүзе исә "эсселек", "кояш кыздырган җир" мәгънәсендә йөргән. *"Ай астыннан кайткан, Алтын курай тарткан, Көн астыннан кайткан, Көмеш курай тарткан"* дигән ярымтабышмак мәкальдә сүз төнне көнгә аударып, тырышып басуда эшләгән кешенең ахырда хезмәтенчә рәхәтен дә күрәчәге турында бара дип уйларга кирәк. Дөрес, башкорт галимнәре арасында бу мәкальне (яки табышмакны, җомакны) аучылыкка бәйләп аңлату да күзәтелә, чөнки ярымкүчмә тормыш белән яшәгән башкортлар аның асыл мәгънәсен бөтенләй аңламаганнар.

Фарсы телендәге *хоршид* сүзе дә "кояш" һәм "көн" мәгънәләренә ия. Электә күк җисеме ("планета") буларак, Кояшка *алтын* туры килә дип санаганнар.

Тагын кара: ***КҮН.***

***КӨНЬЯ*** *г.* — Кемгә дә булса угылының исеме буенча бирелгән хөрмәтле кушамат, патронимик исем (*әбу* һәм *өм* кебек сүзләрне кушып ясалган ялгызлык исеме кушаматлары; ата кешенең өлкән улының исеме буенча аталышы — мәсәлән: *Әбу Мөхәммәд* — Мөхәммәднең атасы). Аналар исеме алдына "өмми" сүзе кушылган. Мәсәлән: *Өмми Хөсәен.* Мөхәммәд Пәйгамбәрнең көньясы *Әбү-л-Касыйм* булган, ләкин хәдисләрдән Пәйгамбәрнең үзен көньясы белән атамаска, исеме белән дәшергә кушканлыгы билгеле. // *Көньяланмыш* — кушамат бирелмеш.

Тагын кара: ***ГАРӘПЧӘ ТУЛЫ ИСЕМ.***

***КӨҢКОЛ*** *тар.* — Кәнизәк (*көңкол* сүзе Нәкый Исәнбәттә очрый). Ләкин "Древнетюркский словарь" *күң кол* язылышын бирә һәм аны "кол хатыннар һәм кол ирләр" дип аңлата.

***КӨЧҮРМӘ ОЙУН*** *бор.төр.* — Мәхмүд Кашгарыйның "Диване лөгатет-төрк" сүзлегенә теркәлгән термин — *кучермә уен.* Бу уенда җиргә кальгага охшатып дүртпочмак сызганнар, шунда ун ишек ясалган. Шуларга йомры таш яки чикләвек ташлап уйнаганнар. *Үндүрт* дип тә аталган.

***КУЙАК*** *тар.* — Калын материя яки күн киемне эре тимер пластинкалар белән тышлап эшләнгән сугыш күлмәге. Монгол явыннан соң Европада киң таралган. XIV—XVI гасырларда татар ханлыкларында аксөяк җайдакларның сугыш киеме.

***КУЛ*** *тар.* —**1**.Кул. Иске әдәбиятта кул (әгъза) мәгънәсендә *ал/ил* сүзе еш очрый. Фарси *дәст* сүзе дә кулланылган (*дәстемал/тастымал* сүзендә хәзер дә сакланган). Шулай ук кул чугы, бил бармак мәгънәсендә фарси *пәнҗә* сүзе дә йөргән. **2**.Гаскәрнең бер як канаты, флангысы ("уң һәм сул куллар"), кайбер чыганакларда — гомумән, тезелгән гаскәрдә эре берәмлек. Рус телендә дә "полк левой руки" кебек гыйбарәләр бар. Ихтимал, татар теле йогынтысы белән барлыкка килгәндер (*атаман, ертоул, есаул, хоругвь, түфәк* һ.б. хәрби терминнар турыдан-туры татарлардан алынган, ягъни бүгенге русофил терминологлар ничек кенә карышмасыннар, русча хәрби терминнар системасына һәм сугыш осталыгына татар йогынтысы шөбһәсез). "Монгол империясе оешкан чорда һәм аннан соң да көньякны "алгы як", төньякны "арткы як", көнбатышны "уң як", көнчыгышны "сул як" дип атау гадәте киң таралган була (соңгы дәвер төрки халыкларында киез өйнең ишеген — "алгы ягын" көньякка карату да моңа бер дәлил)." // *Кул башлау*-флангтан сугышка керү. **3**.Татар сөйләшләрендә "кул" сүзенең *төр, төркем* мәгънәсе дә бар. Мәс., *бай кул*-баераклар, баерак катлам, хәлле кешеләр; *ярлы кул*-ярлыраклар, ярлы катлам.

***КУРАЙ*** — Татар-башкорт тынлы музыка коралы. 600-700 мм озынлык — тагы зонтиклы үсемлек сабагыннан (курадан) ясалган флейтадан гыйбарәт. Аның ян-якларында 4+1 тишек була, курайчы шул тишекләргә баскалап, 2-2,5 октава диапазонында моңлы авазлар чыгара, еш кына бу авазларга үз тавышын да куша. Курайның төрләре: агач курай, җиз курай, Казан курае, камыш курай (нәй), көпшә курай. Кыллы курай төшенчәсе дә билгеле.

Хәзерге вакытта Татарстанда курайчылар калмады диярлек, ләкин энтузиастлары юк түгел. Башкорт ягында курайчылар күбрәк.

***КУРГАН*** — Бу сүзне Ш.Мәрҗани кальга мәгънәсендә куллана. // *"Болгар патшасы Мокътәдир Билләһ хәлифәдән дошман патшаларының һөҗүмнәреннән саклану өчен үзенең шәһәренә кальга, ягъни курган салып бирүен сорады."* Ибне Фазлан *(Ш.Мәрҗани буенча).* Рус теленә дә кергән сүз (кечерәк тау, калкулык, өем, кабер мәгънәсендә).

***КУРЕН*** *тар.* — Урлар (казыган чокырлар) белән әйләндереп алынган гаскәр станы. Монгол сүзе булырга тиеш. Рус *(казаклар)* теленә дә кергән.

***КҮК КАПУСЫ (КАБАГЫ) АЧЫЛУ*** — Хәзерге астрономиядә Җир шары үзенең орбитасында хәрәкәт иткәндә метеоритлар агышына эләгү нәтиҗәсендә күпләп йолдызлар атылу күренеше ("йолдыз яңгыры"). Мондый вакыйга елъязмаларга да теркәлгән. Мәс., Каюм Насыйри кәгазьләре арасыннан табылган бер кулъязмада "1866 елда күктән йолдыз яуды" диелгән. Күк капусы рамазан аеның 27 нче кичәсендә ачыла, ләкин аны саф күңелле ләр генә күрә, шул чакта ул ни теләсә, шул була дип ышаналар. Шулай да котып балкышы (яки төньяк балкышы) дигән күренешнең формасы ягыннан күк капусы ачылу дип аталырга "хокукы" күбрәк шикелле. Ихтимал, бу очракта татарча атама мәгънә үзгәреше кичергәндер.

Тагын кара: ***ШИҺАБ.***

***КҮТӘРМӘ** тар.* – Шәрәфетдин Гали Йезди сүзләренә караганда, Урта Азия төркиләрендә сүтелмәгән килеш арбага куела торган чатыр, тирмә. Күченеп йөргәндә аны күтәреп җиргә төшергәннәр. Дәшти-Кыпчакта да шундый ук күтәрмәләр булган дип уйлыйлар. Монголлардагы сүтелми торган һәм махсус платформага куеп күчереп йөртелмәле тирмәләрне Плано Карпини "Монгаллар тарихы"нда һәм Гильом де Рубрук "Көнчыгыш илләренә сәяхәт" китабында тасвир итә. Мондый тирмәнең примитив сурәтләре Лена елгасы буенда А.П.Окладников тарафыннан табылган һәм тасвир ителгән.

Гильом де Рубрук язуынча, күтәрмәле тирмә чыбыктан үреп ясалган, аның чыбыклары өстә урта бер җирдә тәгәрмәч сыман нәрсә хасил иткәннәр (Рубрук аны мич морҗасы белән чагыштыра, татарча чыганакларда – *чаңырак*). Мондый тирмәләрнең киңлеге кайчагында утызар футка җиткән. Аны 22 үгез җигелгән арбада күчереп йөрткәннәр, арба тәгәрмәчләренән калган эзләр арасы 20 фут, ә күчәрләрнең юанлыгы кораб мачтасы кадәр булган. Тирмәне каплаган киез гадәттә ак төстә булган, ачык күренеп торсын өчен аны акшарлаганнар.

Тора-бара җиңел сүтелмәле һәм җыелмалы тирмә уйлап чыгарганнар.

Татар теленең диалектларында күтәрмә-өйалды болдыры яки шуның бер басмасы. Электә озын-көзен чабата табанына беркетелә торган шакмакларны да *күтәр(т)мә* дип атаганнар.

***КҮШ, КҮШЕН** тар.* – Борынгылыкта төрки-татарда хәрби берләшмә-полк. "Рус-украин телендәге *кош* "полк" һәм *кошевой атаман* "полк командиры" – шул төрки сүз нигезендә ясалган". *(Р.Әхмәтьянов.)*

***КҮШЕК** бор.* – Михраб, альков.

***КЫЗ-КЫМЫЗ*** – Казан арты керәшеннәре сөйләшендә: кыз-кыркын. */ / Кызым җук, кымызым җук дидем дә бирдем киленгә* (хәситәне).

Тел белгече Риза ага Газизов шаян сүзне дә чит итми торган иде. Узган гасырның 60-елларында, татар алфавитына яңадан "къ", "гъ" авазларын *(хәрефләрен)* кайтару мәсьәләсе кузгалып алгач, һәммәсе "къ" авазларыннан гына башланган сүзләр "ярдәмендә" язылган яхшук җор мәзәгендәге "кыз-кымыз" сүзен Риза ага хатыныннан ишеткән булыр *(хатыны керәшен кызы иде).*

***КЫЗЫЛ ТЕЛ*** – "Кызыл авыз" гыйбарәсеннән аермалы буларак, "кызыл тел" сүзе уңай мәгънәгә ия, ягъни ул "большевистик" дигән мәгънәдән ерак. */ / Һөнәр башы кызыл тел. (Мәкаль).*

***КЫЙБЛА ЮЛЫ*** – Киекказ Юлы, Торна Юлы, Гуг Юлы. Фарсыдан кергән *Кәһкәшан* сүзе дә кулланылган (русча *Млечный путь*).

***КЫЙБЛАНАМӘ** гф.* – Компас, *бәйт әл-ибрә.* Фарсы теленнән кергән *намә* яки *нөма* сүзе аерым гына да компас мәгънәсендә йөргән. Шиһабетдин Мәрҗани хаҗ сәяхәте вакытында Измир мәчетләренең юнәлешен "тартмалы энә" белән тикшерүләрен телгә ала. Аңардан хәтта бер иранлы килеп кыйбланы сорый һәм ул күрсәткән тарафка карап намаз укый *(Ризаэддин Фәхреддин буенча).*

Электә дөньяның якларын билгеләү өчен уникe еллык хайван циклындагы хайван исемнәре дә кулланылган. Компас әйләнәсе 30 ар градуслы 12 секторга бүленгән булган, анда төньяк (төп) юнәлеш тычканга, көньяк – елкыга, көнчыгыш – куянга, ә көнбатыш тавыкка туры килгән. Сәяхәтчеләр дә урындагы ориентирларны шушы компастагы юнәләшкә карап исемләгәннәр *(барс калкулыгы, маймыл тавы һ.б.).*

Тагын кара: ***ЧАК, СӘГАТЬ.***

*Дәвамы киләсе саннарда*

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ГАЛИҖӘНАП ШИГЫРЬ— ХӘЗРӘТИ ШАГЫЙРЬ...

Минем укымыйча калырга ярамый торган шагыйрьләрем бар. Эзләп табып укый торган, тапмыйча тынычланмый торган шагыйрьләрем алар. Нияз Акмал—шуларның берсе.

Менә күпме вакыт инде мин аның янарак кына дөнья күргән “Күзләремнең төсе үзгәрмәде” дигән шигырьләр җыентыгы[1] тәэсирендә йөрим. Бу китапны мин күптәннән көтә идем инде. Озак кына күренмәгәч авторга ризасызлык та белдерә башлаган идем. Ниһаять! “Сабыр канатлары” сынар дәрәҗәгә җиткәндә килде дә керде ул китап кулыма.




Китап аерым бүлекчәләрдән гыйбарәт. “Төне буе йокламаган чаклар!..” исемле беренче бүлемтә вакыт төшенчәсенең үзенчәлекле образсурәте белән ачылып китә. Бу җәһәттән шагыйрь таң тасвирына иркен мөрәҗәгать итә:

*Таң—яңару,*
*Таңда—яңа дәвам,*
*Таңда—җанның кабат балкышы.*
*Шуңадыр ла, бәлки,*
*бу таңнарга*
*Гел таң калып карыйдыр кеше...*

Таң, әлбәттә, яңа өметләр, яңа хыяллар белән кешене алгы гомер юлына әйди торган якты көч. Әмма бит төннең дә үз матурлыгы бар. Жанга, тәнгә җылы өрүче учакның гүзәллеге төн карангылыгында тагын да серлерәк күренә бит. Уртак учакның! “Күмер түгел, гомер яна, бәгырь, гомер яна бүген учакта!” Уртак учакны сүндерми саклый алу “бер саума гомергә” килгән бәхет түгелмени?

*Без калдырсак,*
*соңгы уты сүнәр,*
*Яңгыр юар көлен,*
*җил алыр.*
*Үзең яккан булгач,*
*учакны да*
*Ташлап китү, бәгырь, бик авыр...*

Күләм, сан ягыннан зур булмаса да, Н. Акмалның милли рух, халыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, татар авылы язмышы белән баглы шигъри иҗаты хәзерге татар поэзиясендә үзенчәлекле бер күренеш булып тора. Шагыйрь катлы-катлы тасвирлар белән мавыкмый гына поэтик фикерне калку итеп бирә ала, традицион язма әдәбиятына нигезләнгән образлылык аша заман фәлсәфәсен бәйге мәйданына чыгара:

*Мең кат югалткан өметләр*
*Һаман да җанда әле.*
*Югалтасы, табасылар—*
*Алда да алда әле.*

Н. Акмалның якты сагыш белән иҗат ителгән образларыннан берсе—ул ана сурәте. Табигый ки, каләм тибрәтүче һәркем өчен бу изге тема һәм ул ана мөрәҗәгать итми калмый: яратып, әрнеп, сагышланып, сагынып, горурланып һәм, әлбәттә инде, хәтер янартып. Әмма Нияз кебек бәгырьне актарып ташлаучылар сирәк. Аның “Кар ява бөтерелеп” дигән шигыренә кабат-кабат кайта-кайта еллар артында калган изге сурәтләрне янартам. Йә, Хода! Минем хәтеремдә әниемнең инде төс-кыяфәте

[1] Акмал Нияз. Күзләремнең төсе үзгәрмәде: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 207 б.

дә тоныклана төшкән иде бит... Иң әүвәл мин анын тавышын онытканидем... Шигырь минем хәтеремдәге сүнгән шәмнәрнең барысын да берьюлы кабызды да куйды! Әсәрдә ипи пешерүче ана хакында сүз бара. Әйе-әйе, без бала чакта авыл мичендә ипи салулар бар иде бит. Без—кыска ыштанлы малайлар—шунда уралабыз. Камыр йолкып алып кечкенә калай капкачта "ипи" пешерәбез. Мин хәтта анын искиткеч тәмен дә искә төшердем бугай...

*Мин сәндерәдә утырам,*
*Мин—малай гына әле.*
*Әнкәйнең йөзе ул чакта*
*Тулган ай гына әле...*
*Җырлый-җырлый камыр изә,*
*Дәрли-дәрли яна мич.*
*Мин, үрелеп,*
*Токмач урлыйм—*
*Әнкәй изгән камыр булса,*
*Чи камыр да тәмле ич!*

Сон, без бит инде бу! Дөресрәге, чабуыбызга ябышкан бала чагыбыз. Янарган хәтернең ургылган сәхифәләреннән бер мизгелгә исәнгерәп калам. Саташкан кеше сыман бүлмәм буйлап йөренергә керешәм. Җаннын әллә кайсы борылышларыннан инде бөтенләй кайтмастай булып җуелган истәлекләр калка. Көзгә каршына килеп басам да сәерсенеп үз сурәтемә карап торам. Инде бу дөньядан киткән туганнарымнын, дусларымнын, фанилыктан бакыйлыкка ашыгып күчкән классташларымнын тавышларын ишеткәндәй булам:

*Кемнәр алда дисәм—аз күренә,*
*Кемнәр кылда дисәм—күп күренә.*
*Өелешеп кереп киттек менә*
*Кылдан нечкә сират күперенә!*

Шулай, шагыйрьләр күп. Тик вакыт иләгән узучы чыннары сирәк. Күнелне кузгата алганнары. Олыгая барган саен алар сирәкләнә. Мин дә студент елларындагы кебек һәрбер шигырь китабына капланып төшмим. Талымлый башладым димме... Әмма бер генә шигыре белән булса да йөрәкне ешрак тибәргә мәҗбүр итә икән—мин ул шагыйрь иҗатын күздән югалтмыйм инде. Аннан сон мин шигъриятне шагыйрь шәхесе белән тәнгәл куюны да өнәп бетермим. Депутат бул син, лауреат, югары дәрәҗәгә ireш, затлы кәнәфи биләп,—әмма, әгәр дә иҗатын кәпшәк, фикерен арзанлы, фәлсәфән вак икән, минә синен затлы киемнән, кәттә галстуктан булуын ни пычагыма?! Талант бит ул кул кисәрлек итеп үткенләнгән чалбардан чыгып билгеләнми. Нияз Акмал да бу җәһәттән "фортовой" әфәнделәргә караганда сукбай булып халкы өчен сәяхәткә чыккан дәрвишләргә өстенлек бирә:

*Тотабыз да тотынабыз кайчак,*
*Алдыбызда ята дәү эшләр.*
*Эшләр бик күп, асыл ирләр шактый,*
*Тик... дәрвишләр җитми,*
*Дәрвишләр...*

Анлаган кешегә уйланырлык нәрсәләр бар монда. Анламаганга инде шагыйрьнен менә бу юллары да анлашылмаячак: "Тавыш килә, кайтавазлар килә Әллә кайдан шунда—үр яктан. Мине дуслар эзләп йөри сыман Мин булмаган яктан, еракtан".

Еш ишетергә туры килә: "Йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә". Ләкин бит ул галиҗәнап Сүзне йөртер өчен әрнүле, кешелек уй-хисен тоярдай, заман афәтләренә каршы торырдай олы йөрәк тә кирәк! Төн каранлылыгын ярып кардәшләренә юл күрсәткән Данко йөрәге кебек.

*Һаваларда йолдыз атылып алыр,*
*Кем күрмичә калыр,*
*кем күрер.*
*Ул кемнеңдер, бәлки,*
*йөрәгеннән*
*Атылып чыккан әйтер сүзедер.*

Китапнын икенче бүлекчәсе "Күкрәгемә тама күз яшем" дип аталган. Исеменнән үк күренгәнчә биредә дә яралы тарих, фаҗигале язмышлар, үлеп, сүнеп баручы татар авылы—димәк ки татар бишегенен киләчәге хакында авыр уйланулар урын алган. Шагыйрьнен каләме нык, тоемы мөкәммәл, әрнүләре нигезле, ышанычы яралы. "Ялгышларнын, югалтуларнын тәгәл хакын инде беләбез..." "Тереклеккә тере су кайда?—дип сорый ул "Тукай" шигырендә. Бүгенгенен икейөзле оятсыз сәясәтчеләреннән,

власть ияләреннән гарык булган халык үзенең тугры Тукаена кат-кат мөрәҗәгать итәчәгенә ышана ул: "Мең яшәгән карт-ка килгән кебек киләчәкләр әле Тукай-га". Әйе, тарихның таралган тармакларын-да адашкан милләт асылына кайту өчен хакыйкый шигъри Сүзне кыйбла итеп алачак. "Пәйгамбәр дә түгел, бары—ша-гыйрь!"—ди ул бераз үкенгән сыманрак. Биредә бәхәсләшергә дә буладыр: ша-гыйрьләргә әүлиялек тә хас бит. Милли мәнфәгатьләрне кыйбла итеп, яшәү мәгънәсе дип билгеләгәннәргә, әлбәттә. Шагыйрьнең йөрәге яралы, җаны тынгы-сыз икән, ул хәтта тынлыкны да тыңлый ала. Дәһшәтле тынлык кайвакытта давыл котырынуыннан шомлырак та була. Тын-лык авазы аша әлегә үзендә гомер сөрергә рөхсәт иткән планетабызның ыңгырашу-ын да тоярга мөмкин: "Шатлыгын да күтәрә Җир, күтәрә афәтен дә. Дөнья ту-лып шайтан йөри кеше кыяфәтендә". Озаккамы?" Шатланыйк без бүген шушы җирдә кеше барга, бәгырь, кояш барга" Ә иртәгә? Без бит бер генә яшибез. "Бу дөньяга яшәр өчен килгән, китәр өчен килгән инде без..." Ярый, без анысын да таныйбыз. Ә әлегә тумаган, дөньяга ки-лергә өлгермәгән буыннар алдында ни дип җавап бирербез? Халык үзе кайгысын да, шатлыгын да җырга салган, ә без мәрсия, бәет языйкмы? Н. Акмал ул шомнарны читкә куарга тырыша: "Синең хакта ләкин, туган халкым, язылмаса иде бәетләр..." Шагыйрь борчыла, шагыйрь күңеле тынгысыз:

*Гөл калырмы, көл калырмы, Җирдә?*
*Кайсы төскә күмелер бу тараф?*
*Яман күңел—мең мәртәбә ямьсез,*
*Ямьсездән ямьсез—битараф.*

Шагыйрь суккан чаң гамьле күңелләргә барып җитеп, гамьсез җан-нарны сискәндерсен иде... Ашыгырга иде, соңламаска иде. Без һәр елны яз урап кайта дип сөенәбез. Яз белән дөнья яшәрә дип куанабыз. Н. Акмал монда да тынычланмый: "Юк, кайтмый ул! Шаулап килгән язлар үткәннәрдән бары кайтаваз".

Ә "Йөз яктысы" дигән бүлек гомум-кешелек, гомумяшәеш мәсьәләләрен күтәрә: мәңгелек һәм фанилык, чиксез-лек һәм чикләнгәнлек, кавышу һәм аерылышу, мәхәббәт һәм хыянәт, шат-лык һәм үкенеч, куаныч һәм афәт...

Тормыш көрәштән, бәхет-бәхетсез-лекнең тартышыннан гыйбарәт. Кешегә насыйп булган гомер юлының ике чиге ул. Безнең яшәү дигән чыгымчы аты-быз әле бер чиккә, әле икенчесенә таш-лана. Бер елганың ике яры... Бер үк күлдә, ике көймәдә калган язмышлар...

*Дулкын безне һаман читкә кага*
*Без нишләрбез, белмим, нишләрбез?*
*Җилкән ауган, ишкәк төпкә киткән,*
*Куллар белән генә ишәбез.*

Бу бүлекчәдә "Кый-гак-к!" дигән озын гына бер шигырь бар. Җанны ай-кый-чайкый торган әсәр ул. Игътибар иткәнегез бармы, без киек казлар төрке-ме баш очыбыздан узганда әллә ничек кенә сагаеп калабыз. Ә бит башка күчмә кошлар—тургаймы, сыерчыкмы, санду-гачмы—сайраганда хушланабыз гына, кинәнәбез генә. Монда исә җанны шөбһә кысып ала. Өлкәннәр борчылып дога пышылдап күккә багалар. Йорт каз-лары тынычсызланып йөгерә, очкан сымак итә башлыйлар. Ул киек казлар тавышында булганмы, булачакмы бер фаҗига бар сымак. Нәрсәдәндер кисәтәләр шикелле алар. Илләр, кыйт-галар өстеннән очканда бәлки алар су-гыш дәһшәтен, кан, үлем афәтен күреп йөрәк өзгеч аваз белән хәбәр җибәрәләр-дер? Әллә кеше, шәхес фаҗигасен җан-нары аша уздырып ыңгырашалармы? Туфанда да бит бу күренеш сискәнүле халәттә тасвирлана:

*Киек казлар кыйгылдаша:*
*—Сау бул, якташ!—диләрдер,—*
*Әллә кайтыр, әллә кайтмас*
*Безнең башлар,—диләрдер.*

М. Әгъләмовның "Тагын бер кош" шигырендә дә ул табигать казының фа-җигале язмышы турында сөйләнелә:

*...Болай гына, кызык өченгә*
*Җибәрелгән ядрә килеп кергән*
*Очып барган төркем эченә.*
*Иң яшенә, көчлесенә тигән*
*Әле күпме очачагына!*
*Тагын бер кош ауды, яшь фидаи,*
*Тагын бер кош синең яныңа.*

Сугыш уты әнә шулай яшәргә, сөенергә, сөелергә тиешле җаннарны кыра. Ирексездән Рәсүл Гамзатовның "Торналар" җыры да хәтергә килә. Н. Акмалда да бу образ сискәнүле, әрнүле төсмерләр тулы символга әверелә:

*...Көнчыгыш та, көнбатыш та*
*Бездән шактый ерак.*
*Бик якында яңгырады:*
*—Ливан!.. Иран!.. Гыйрак!..*
*—Кый-га-к!..*
*..............................*
*Җылы якка очмый ул каз—*
*Оча дөнья буйлап.*
*Безнең якның "SOS" авазы*
*Күчә дөнья буйлап!*

Һаваларны кыеп алган бу аваз—кисәтү, әрнү, борчылу, хәвефләнү... Бу—бүгенге көннәрнең шомлы кайтавазы. Дәһшәтләрнең алда булу мөмкинлеген искәрткән җан кычкыруы. Хәерлегә булсын, хәерлегә... Юраган юш килмәсен дип бер Ходайдан сорарга гына кала инде.

Китап ахырында урын алган "Тау башыннан яулык болгадың" бүлеге шигырьләрендә дә Нияз Акмал заман укучысын яралы җаннарны таныргa, шәхси проблемаларны дөнья биеклегеннән торып бәяләргә чакыра, тулы бер буынның тормышка мөнәсәбәтен, рухы һәм әхлакый эзләнүләрен янача, заманча чагылдырырга омтыла. Тирән, саллы уй, фәлсәфи олы, куе фикер, гражданлык пафосы—шагыйрь лирикасының төп асылын шулар билгели. Бу җәһәттән Н. Акмалның игътибарын фаҗигале язмышлар ныграк тарта. Безнең арабызда яшәгән, артык күзгә бәрелеп тормый торган, ләкин гомере буе рәнҗү тулы йөрәк белән тормыш дулкыннарында чайкалган кешеләр...

Менә әнисенең яшьлек хатасы нәтиҗәсендә дөньяга килгән кыз бала ("Җилдән туган кыз"). Үзләре дә җинаятьчел власть тарафыннан изелгән, яньчелгән авыл кешеләре өерелеп шушы чарасыз, үзен-үзе якларга сәләтсез балага ябырыла: "Җилдән туган"—шушы яман сүзне Ишетте ул яше-картыннан". Гаделсез җәмгыятьнең явызланган бәндәләре шуннан тәм таба. Ә аның ни гаебе бар? Гариза язып килмәгән бит ул бу вәхши дөньяга: "Җилдән туган—мәхәббәттән туган, Гаеп синдәмени, и бала!..". Нәтиҗәдә—кимсенүле язмыш, китек күңел, ачы киләчәк... Гаепсездән гаепле булып яшәү аны ахыр чиктә гаиләбәхетеннән, сөю-сөелүдән, бала иркәләүдән мәхрүм итә һәм гомер соңында картлар йорты бусагасына китереп ташлый... Гап-гади язмыш та кебек, әмма монда роман язарлык эчтәлек бар бит! Яки менә халкына атудан баш тартып үз-үзенә кул салган һәм өстенә никадәр гөнаһ алып мордар киткән офицер образы—"Намуслы офицер турында баллада". Бу бит бөтен бер ил, тулы бер заман трагедиясе! Яисә шәһәр сәүдәгәрләре кулында уенчыкка әйләнгән гөнаһсыз авыл кызы турындагы бәян—"Базар хатыны". Монысы да милләт фаҗигасе түгелмени?! Караңгы авылда туып бик яшьли (әле кызлар кулы да тотып карамаган!) сугышка алынган, гомере хисабына дивизионны һәлакәттән коткарып калган элемтәче егет язмышы да ("Элемтәче турында баллада") кемне генә битараф калдырыр?! Дәһшәтле сугышның билгесез батырлары, исемсез геройлары... "Сугышны генераллар башлый, солдатлар төгәлли",—дигән бер акыллысы. Илгә җиңүне әнә шушы, Ватан өчен соң тамчы канына кадәр антына тугры солдатлар алып килделәр. Каберләре дә билгесез, исемнәре дә вакыт агышында җуелган ил уллары... Нияз Акмалның әлеге моңлы шигъри юллары Сезнең рухыгызга дога булып барып ирешсен.

Күп булмаса да, Нияз Акмал иҗатында күләмле әсәрләр дә урын тапкан. Китаптагы "Сарман" җыры" поэмасы, "Чык ярга!" дип исемләнгән "шигъри кыйсса" шуның мисалы. Биредә авторның иҗади кыйбласы тагын да үзенчәлекле ачылып китә. Әйтер сүзе яхшы ювилер тарафыннан эшкәртелгән асыл таштай янадан-яңа яклары белән балкый башлый. Төп мәгънә метафораларга, символларга урала-урала әсәр ахырында бөтенләй башка, үзгә яссылыкка килеп чыга. "Чык ярга"! әсәрендә шагыйрь бала чагындагы бер драматик хәлне—язгы суга бату вакыйгасын—бәян кыла. Инде беттем, югалдым дигәндә авылдашларының тавышы ана котылып калырга ярдәм итә: "Чык ярга!" Гомер

үтә, тормыш елгасы лирик геройны үзенә суырып ала, заман дулкыннары кага, упкын үзенә тарта һәм шул вакытта өмет булып якты нида янгырый: "Чык ярга!" Бүген исә милләтебез саташкан чорның болганчык дәрьясында чәбәләнә. Кыйбла яктагы ярны куе томан сарган, пычрак сәясәт өметләрне кыеп упкынга өстери һәм шул вакыт күктән илаһиятле авыз инә: "Чык ярга!"

Һәм, ниһаять, "Сарман" жыры" поэмасы... Бу—Нияз Акмал иҗатында гына түгел, бөтен татар әдәбиятының йөзек кашы булып саналырга хаклы! Бу—туган якның гимны, татар теленең бар байлыгын үзенә туплаган бер тажы! Биредә татар халкының фажигале тарихы, милләтемнең өмете, сагышы, жан авазы, күнел жылысы, кыйбласы, фани дөньяларга күчкәннәрнең әманәте... Бу әсәрне укыганда еракларлан килгән авазларны ишеткәндәй булам: "Кичерегез...", "Чигенмәгез...", "Онытмагыз..." Соңгы 30-40 ел эчендә районнарга багышланган жырлар күп язылды. Хәзер инде Татарстанда жыры булмаган берәр район калдымы икән? Арада уңышлылары да аз түгел. Әмма болар—авторлы жырлар. Халык жырлары исә—тарихы күптән онытылып, бик еракларлан, данлы-шанлы-канлы үткәннәрдән килеп, киләчәккә узып баручы бәгырь жимешләре. Кайгысын да жырга салган татар, шатлыгын да! Аның бер канаты ат булса, икенчесе—жыр. Шуңа да "Арча", "Сарман"—алар халыкның мәңгелек юлдашы. Тукайдан мәгълүм юллар искә төшә: "Мәгмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр... Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күнелендә... калдылар, алар сәламәт әле, алар янгырый әле". Татар егетләрен бәхет эзләп чит-ят жирләргә, ил азатлыгы өчен сугыш яланнарына озаткан моңнар алар. Ә күпмесенең соңгы сәламе, бәхилләшү авазы булып кайтавазлары гына урап кайта алды.

*Халык һәм жыр...*
*Жирдә бер үк гомер,*
*Аерылмас тән һәм жан кебек.*
*Жыры барда—халык мәңгелек тә,*
*Халкы барда—"Сарман" мәңгелек!*

"Сарман" жыры"ннан ятланган өзекләрне сәхнәләрдә, аудиторияләрдә, очрашуларда, кичәләрдә ничә тапкырлар сөйләдем икән инде мин?! Ә ничә мәртәбә бу әсәр мине шәһәр тынчуыннан суырып алып, кичектергесез башкарырга тиешле кырык эшне кырык якка чәчеп, туган авылга кайтып китәргә мәжбүр итте! Ничек аңлатырга бу халәтне, бу моң чакыруын? Биредә якташ остазым, халкымның бөек улы Мөхәммәт Мәһдиев ярдәмгә килә: "Исәнме, туган ягым! Исән-сау тордыңмы? Мин бит әллә ниткән күтәренке-романтик хыяллар, куәтле жырлар патшалыгыннан кайтып киләм. Синдә яшәп, синдә үләргә, шушы жирдә күмелергә дип кайтып киләм. Тормышның авыр минутларында юатырга онытма мине. Син бит жырларга бик бай. Бик моңлы, бик хәсрәтле алар. Шулай да, миңа авыр булганда мине юатырга онытма..."

...Нияз Акмал шигърияте̇ндә мин мәңгелек чакыру авазын тоям. Шушы мәңгелек эчендә шагыйрьнең үзенең туган жире, туган туфрагы, туган халкы бар. Алар хакында тәэсирле һәм тирән мәгънәле сүз әйтә алу сәләте сирәк талантларга гына бирелә.

**Фәрит БӘШИР**

⁂

*Вакыйф Нуруллинга 70 яшь*

# КЕШЕ ҮЗЕ ҖАВАП БИРӘ...

Гомерләр уза тора. Заманында әдәбиятыбызның иң алдагы сызыгына чыгып, кызыклы әсәрләре, күңелдән җуелмас геройлары, тормышчан әдәби сурәтләре, күпләрне борчыган сорау-проблемалар күтәрүе белән танылган әдибебез Вакыйф Нуруллинның да "Җитмеш яшь" дип йөртелгән вакыт чигенә ирешеп, башкалар һәм үзе алдында сабыр гына уйлана-уйлана исәп-хисап тоту мизгелләре килеп җиткән икән...



Сабырлык дигәннән, бу сыйфатны өләшкәндә Ходай үзе Вакыйф дусны буш итмәгән төсле тоела миңа. Аның бөтен кыяфәте, килеш-килбәте, үз-үзен тоту рәвеше: "ашыкмагыз, кумагыз бу фани дөнья артыннан, өлгерерсез барысына да, әгәр дә язган булса" дип әйтә төсле. Ә үзенең кабаланмаса-кызуланмаса да, эшлисе эшләрен башкарып, әйтәсе сүзләрен тиешенчә үткәзеп әйтеп, барысына да өлгереп, җитешеп йөргән көне.

Иң әһәмиятлесе: Вакыйф Нуруллин—татар әдәбиятының үсеш юлында байтак игелекле эшләр башкарган шәхес. Ничә еллар дәвамында ул Татарстан китап нәшриятында хезмәт итте, бик күп авторларга киңәшләрен, хәер-фатихасын биреп, китапларын якты дөньяга чыгарырга булышты.

Ә миңа Вакыйфның үз китаплары, үз язганнары бик якын һәм таныш—алар нигездә проза китаплары. Һәм бу мәкаләмдә мин әдипнең проза өлкәсендәге эшчәнлеге турында сүз йөртергә уйлыйм. "Шинельсез солдатлар", "Төкле аягың белән", "Күпер чыкканда", "Әгәр син булмасаң", "Яшьнәп үткән яшьлек", "Аккан су юлын табар", "Һәлакәт", "Җавап бир, кеше!", "Сагынырсыз әле сез дә бер" ("Хыянәтчеләр")—шушы әсәрләргә карап, әдипнең тоткан юлын-мәсләген дә, кайсы әдәби юнәлешләрне-алымнарны үз иткәнлеген дә бик ачык белеп була.

Мәгълүм ки, татар халкы элек-электән күпсүзлелекне, гади генә нәрсәләрне катлауландырып, кабартып, төчеләндереп сөйләүне өнәмәгән, якын итмәгән. Чөнки үзенең тарихында мәгънәсе бигүк анлашылмаса да, матур, шома яңгырый торган сүзләр шаукымына яисә сихеренә уралып ул төп башына да байтак утыргалаган. Андый сүзне гадәттә эз буташтыручылар, ялганчы сәясәтчеләр, булмаганны бар, барны юк итеп күрсәтүчеләр, бушбугазлар сөйләвен хәзер ул яхшы белә.

Бүгенге әдәбият куначасыннан сайраучыларыбызның да тавышлары төрлечә. Нindiләрен үз итә икән соң бүгенге укучыларыбыз? Әлбәттә, үзләре анлардайларын: үз кешеләрен, әдәбият-сәнгатьтәге үз улларын, үз вәкилләрен. Чын бөеклек, чыннан да, гадилектә. Акны ак дип, караны кара дип әйтә белүдә.

Вакыйф Нуруллин—әнә шундый, крестьяннарча гадилек тарафдары. Әсәрләрендә катнашучылар да гадиләр, гадәтиләр. Бу хәл, бу күренеш аның беренче әсәрләреннән үк, мәсәлән, "Шинельсез солдатлар" повестеннан ук (1996) күзәтелеп килә. Ул вакытта әле һаман да рәсмилектән, булганыннан олырак булып күренергә теләүчиреннән аерылып җитә алмаган татар әдәбиятына сугыш заманындагы тормышның

үз балалары, үз кешеләре килеп керде. Сугыш зәхмәтләрен авылда кичергән меңләгән яшүсмерләр "шинельсез солдат" Равил сурәтендә үзләрен танышылар, ул күргәннәр истәлек рәвешендә һәркемгә үзенчә янадан әйләнеп кайткандай булды. Повестьның күпшылык, ясалмалылык, кыланчык романтиканы санламавы яисә өнәмәве авыл хәлләрен белеп, татып үскәннәр күнеленә аеруча якын итте. Әмма әдип Вакыйф Нуруллин әдәбиятта чын романтиканы танымый дигән ялгыш нәтиҗә чыгарырга ашыкмыйк. Автор бу әсәрендә бер, әмма матур романтик адым ясый—ул да булса, повестьнең исеме—искиткеч дөрес һәм тапкыр куелган: "Шинельсез солдатлар" (!). Шушы метафора яктылыгында әсәрнең кырыс сюжетка нигезләнгән мәгънәсе алга таба бермә-бер көчәеп китә. Шулай да укучының зирәклегенә ышанып ук җитмичәме, әллә яшьлек тәҗрибәсезлегеннәнме—автор бер хата да ычкындыра—текстта персонажларның берсеннән: "сез болай ил өчен тырышып эшләп йөргәч, шинельсез солдатлар буласыз инде" дип әйттереп, сюжетның болай да тәмле боткасына артык бер кашык май салып җибәрә. Әмма моның белән кәеф бозылмый, алга таба әсәр барышында исемнең пафосына яңа пар да өстәлми. Чөнки зәвыклы автор чама хисен тоя.

Шушы урында рус әдәбиятчылары бик яратып кабатлый торган гыйбарә искә төште: "Әдәбиятчы, язучы буларак, без барыбыз да Гогольнең "Шинеленнән" чыккан кешеләр". Бу зур төшенчәнең мәгънәсен үзебезгә яраштырып, кечерәйтебрәк әйтсәк, сугыш чоры балаларының, газаплы чорга яшьлекләре туры килгәннәрнең фаҗигале драматик темасы чыннан да Вакыйф Нуруллин һәм Мөхәммәт Мәһдиевтән башланып китте дияр идек. Сүз "Шинельсез солдатлар" (1966) һәм "Без—кырык беренче ел балалары" (1968) әсәрләре турында—татар яшүсмерләр әдәбиятының кабатланмас ике җәүһәре турында бара.

Кабатланмас җәүһәрләр... Әмма кабатларга маташучылар да аз булмады. Болардан соң сугыш елларында чиләнеп, газапланып үскән һәм каләм кыштырдата белгәннәр үз тәрҗемәи хәлләрен укучыларга тәкъдим итеп карадылар. Әдәбиятта шулай да булгалап тора: берәүләр юл яра, алар артыннан башкаларның беренче ачышларыннан файдаланып, шуны кабатлаучылар ташкыны ыргыла... һәм теге алдан баручыларыбызның чын яңалыклары шул масса астында күмелеп тә калгалый. Әмма бу очракта җәүһәрләр җәүһәр хәлендә укучының күңел түренә урнашып калдылар. Чөнки Вакыйф Нуруллин әсәрдәге Равил образы аша яңа сүзне, олы сүзне үтә дә бер ихласлылык белән, фәкать үзе аңлаганча, әмма бик күпләрнең йөрәк кылларын тибрәтерлек итеп әйтергә өлгергән иде. Тагын бер нәрсә безне гаҗәпләндерә: әгәр шундый ук казанышка әдипнең каләмдәше Мөхәммәт Мәһдиев "Без—кырык беренче ел балалары"нда сюжет-композиция алымнарының моңарчы күрелмәгән иң яңа, хәтта шаккатыргыч алымнарыннан файдаланып ирешкән булса, Вакыйф Нуруллин ачышны бер карашка отышсыз булып тоелган элеккеге классик язу җирлегендә ясый.

Бу әдип бервакытта да форма яңалыклары, "стиль модерны" кебек нәрсәләр белән мавыкмады. Һәрвакыт тормышның кешеләр арасында урнашкан яшәү рәвешен үз табигыйлегеннән мәхрүм итмичә, аны күркәм гадилегендә әдәби әсәрләренә дә күчерде. Әлеге табигыйлек шул кадәр ышандыра ки, гүя әсәрләрендә ул Әдәбият дигән шартлы галәмнең махсус кануннары, тәртибе, үзенчәлекләренә ярашу, буйсыну кирәклеге турында уйлап та тормый, баш та ватмый—тормыш вакыйгаларын үз агымында ничек бар, шулай тезә дә тезә генә... Шуңа күрә, Вакыйф Нуруллин әсәрләрендә сурәтләнгән күренешләр иллюзияле әдәби образлар булып түгел, ә тормышның нәкъ үзе булып кабул ителәләр.

Тормыш һәм Әдәбият чагыштырмасына мондый мөнәсәбәт кайбер кыенлыклар, проблемалар да китереп чыгара. Гел тормыш эзеннән генә бару, бар булганны түкми-чәчми тезү кайбер әсәрләрдәге сюжет җебенең чамасыз озынлыгына китерергә дә мөмкин. Безнең карашыбызча, "Әгәр син булмасаң" повестендагы кабатланып-кабатланып тезелгән вакыйгаларны "барысын да язам" дип түгел, ә әдәбият-сәнгать кануннарының җиз иләге аша үткәреп сайлаганда бу әсәр сюжет җыйнаклыгы ягыннан да ота төшәр иде.

Заманында Вакыйф Нуруллин мактау сүзләрен күп ишетте. Объектив тәнкыйть бу иҗатны озак вакытлар күз уңыннан төшермәде. Фәрваз Миннуллин, Рафаэль Мостафин, Флүн Мусин, Фоат Галимуллин, Ринат Мөхәммәдиев кебек әдәбият белгечләре аның чыккан һәр әсәренә хәерле юл теләп, әдипкә иҗади дәрт өстәп тордылар. Мондый игътибар әлбәттә нәтиҗәсез калмады. Җитмешенче-сиксәненче елларда әдипнең иҗат табасыннан бер-бер артлы яңа әсәрләр төшә торды ("Аккан су юлын табар", "Ике урам арасы", "Һәлакәт" һ. б.) Аларның кайберләре хәтта милләт чикләрен үтеп, украин телләрендә дә дөнья күрделәр. Ә инде "Яшьнәп үткән яшьлек" исемле героик повесть режиссер Идмас Үтәганов һәм сценарий язучы Азат Вергазов булышлыгы белән телевизор экраннарында күңелләрне кузгатырлык, ашкындырырлык әйбәт сериал рәвешендә балкып алды.

Менә җәмгыятьтә, ил өстендә күчеш-үзгәреш давыллары купты. Күп нәрсәләргә яңа күзлек киеп карый башладылар. Элеккеге үлчәм-нормалар, алымнар ярамый башлады. Бүгенге юбилярыбызның да иҗат активлыгы ул вакытта сүрелеп, сүлпәнләнеп киткәндәй булды. Әмма әдипкә "иҗат кризисы" дип йөртелүче куркыныч янаганда хөрмәтле белгеч-тәнкыйтьчеләребез ярдәм кулы суза алмадылар. Хәер язучы үзе дә яхшы ниятле чын тәнкыйтьнең гел мактау, хуплаудан гына гыйбарәт булмавын яхшы аңлый башлаган иде инде. Чөнки арттырып мактаудан иҗат офыклары тараерга да, һәм, киресенчә, объектив дөрес тәнкыйтьтән әдипләр үзләре күреп ук җиткермәгән кимчелекләрдән арынырга да мөмкин. Шәхсән үзем, тәнкыйтьче үзенең игътибарын, хәтта елдан-ел күбәя барган юбилей мәкаләләрендә дә игътибар үзәгендә әдипләрнең әлегә ачылып ук бетмәгән иҗат мөмкинлекләрен, иҗат перспективаларын тотарга тиештер дип саныйм. Чөнки һәр юбилярның да әле үткән юлы гына түгел, үтәселәре дә, күренеп торган яңа офыклары да бар.

Ә менә сиксәненче-туксанынчы еллар чигендә Вакыйф Нуруллин әдәби тәнкыйть игътибарыннан мәхрүм калды, аңа үз проблемалары, үз кыенлыклары белән күзгә-күз очрашып, өр-яңа нәтиҗәләр ясарга туры килде. Гасабилы иҗат кыенлыкларын ничек кичергәнен автор үзе генә белә торгандыр—анысы безгә сер булып калсын...

Ләкин шушы шартларда, замана прозасының тематик җирлегендә Вакыйф Нуруллин зур иҗат ачышы ясый алды. Бу ачыш заман тибы җирлегендә, аерым алганда, герой психологиясе, ягъни аның эчке дөньясы җирлегендә эшләнде. Гомумән, тип ясау—бу әдип иҗатының иң көчле ягы икән. Безне элек-электән Вакыйф Нуруллинның типлар иҗат итү сәләте, шул типларның эчке дөньяларына үтеп кереп, аларның үзе булып яшәү сәләте сокландырып килде. Югарыдарак телгә алынган Равил дә әсәрдән әсәргә күчеп йөреп, совет чоры яшьләренең күпчелек сыйфатларын  үзенә туплаган тип-образ иде.

Аннан соң, төп кыйбласыннан бераз тайпылыбрак булса да, автор тарихи-революцион каһарманнар образына мөрәҗәгать итеп карады. "Яшьнәп үткән яшьлек"тәге Миңнулла һәм аның көрәштәшләре шундыйлардан иде. Әмма Миңнулладай каһарманнарның кырыс батырлыкларын күкләргә чөеп мактаган заманнар үтеп, яңа буыннарга андыйларның җете кызыллыклары инде уңып, актуальлекләре җуела төшкән чак иде. Монысын да аңлаган әдип яңадан бер тапкыр үз иҗатының иң көчле ягын, төгәлрәк әйткәндә үзе белгән, үзе күргән авыл-район тормышы кешеләрен, шуларны типларга әвереллдерү сәләтен искә төшерде. Алар арасында гаять тә колоритлылары, гаҗәеп ярашучан, тормыш агышы рәвешенә тиз көйләнеп, үз мәнфәгате дигәндә йөзен кырыкка алмаштырып, җилнең кай тарафтан исүенә аеруча сизгерләре әдипнең игътибарын җәлеп итте. Бу чиркангыч типлар теләсә кайсы заманга ярашырга сәләтле. Күп вакытта андыйларны режим үзе үрчетә, андыйлардан файдаланып, тегеләрне массалар иисә кечкенәрәк төркемнәр белән җитәкчелек итәрлек постларга, урыннарга да куя. Әлбәттә, "номенклатура кешеләре" дип аталган катламнар гел начарлардан гына да тормый. Авторның дикъкате бигрәк тә бер катламга—чын йөзен яшереп югары урынга оялаган җүнсез затларга юнәлтелә.

Мәгълүм ки, тискәре типларны сатира утында көйдереп, капма-каршы идеалларны раслау дөнья әдәбиятында бик күптәннән килә. Мольер, Гоголь, Зощенко әсәрләрен генә искә төшерик. Татар әдәбиятында бу алым байтак вакытлар

онытылып торган иде. Менә соңгы вакытта ике язучыбыз шуңа әйләнеп кайтты. Мин бу урында Тәлгат Галиуллин трилогиясен ("Элмәк", "Тәүбә", "Төнге юллар") һәм Вакыйф Нуруллинның "Җавап бир, кеше!" һәм "Сагынырсыз әле сез дә бер" ("Хыянәтчеләр") әсәрләрен күздә тотам. Соңгы икесенә күз салып үтик.

"Җавап бир, кеше!" повестенең төп герое Ханәфи беренче тапкыр күренгәндә Әмирхан Еникинең "Тауларга карап" хикәясендәге Локман картны хәтерләткәндәй була. Икесендә дә кеше гомеренең көзенә карап хәйран калгандай, тукталып карап тору бар. Күңел халәтләре дә көзге көн төсле. Тик охшашлык беренче күренештә генә икән. Ә аерма тау кадәрле. Картларның икесенең дә гомер очы инде күренеп тора. Үткән-кичергәннәрне барлап чыгып, тормыш белән саубуллашу, бәхилләшү чаклары житеп килә. Әмма әйләнеп карардай юллар төрлечә, хәтта бөтенләй капма-каршы икән дисәң дә ярый. Әгәр дә Әмирхан Еникинең Локман карты, язмыш давыллары тукмаса-кыйнаса да чын кеше булып калган, ил-көн каршында абруен җуймаган ил агасы булса, Вакыйф Нуруллинның Ханәфие исә—гел үз җаен кайгыртып, кайсын алдап, кайсын рәнҗетеп, йөзен яшереп һәм үзгәрткәләп, мәкерфорсатлы ниятләрен тормышка ашырып көн үткәргән бәндә. Тик аның да бүген хисап, җавап тотар көне килеп җиткән икән.

"Ярый әле алтмыш яшькә җиткәннәрдән: "Җавап бир, кеше. Шушы яшеңә җитеп, халкыңа, илеңә, гаиләңә нинди яхшылыклар эшләдең? Үзеңнән соңгы буыннарга сине сагынып искә алырлык нинди мирас калдырып китәсең?"—дип сорау алу юк. Ә ул сорауларга җавап бирүне гамәлгә кертү һәм җавапны алтмыштагылардан түгел, бәлки адәм баласы илле яшькә җиткәч бирдертүне мәҗбүри итеп кую начар булмас иде. Илле яшьтә инде кемнең нәрсәгә сәләтле икәнлеге ачыкланган: адәм баласы кулыннан килердәй эшләрнең күбесен эшләгән була. Шул ук вакытта яшьлектә җибәргән хаталарын төзәтергә һәм, гомумән, киләчәктә акыллырак эш итәргә кимендә тагын ун ел вакыты кала аның. Ун ел вакыт—үзе бер гомер ул". *(Нуруллин Вакыйф. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Том 2. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1991 ел, 403-404 битләр).*

Әнә шулай акыллы, төпле фикер йөртә безнең героебыз. Мөгаен бу сүзләр белән һәркем килешә торгандыр. Ә моны яхшылык битлеген киеп кенә йөрүче тискәре персонаж исеменнән сөйләтүне ничек аңлатырга? Эш менә нәрсәдә. Бу акыллы, мәгънәле сүзләр Ханәфи уйлары рәвешендә бирелсәләр дә, аны тискәренең фикерләве яисә карашларыннан да бигрәк, авторның сюжет кору юнәлешендәге зирәк ачышы дип бәяләргә кирәк. Нәкъ шушы урында гына әдип үзе дә Ханәфинең фикерләре белән килешә сыман. Чөнки бер генә мәлгә тискәре тип чыннан да объектив халәткә керә. Бу эпизодтагы сораулар дөньяда гомер иткән һәр адәм алдына котылгысыз килеп басачак икәнлеге аңлашыла. Әйе, мондый сорауны куйган чакта Ханәфи дә башкалардан аерылмый. Тик соравыннан бигрәк, җавабы әһәмиятлерәк. Җавап бирә аламы соң Ханәфи? Юк—"җавап бир, Кеше!" дигән олы сорауга ул рәтле җавап бирә алмаячак. Башкаларны алдаштырып, үз-үзенне генә кайгыртып, җүнсезлектә үткән гомерне гомер дип атап буламы икән? Һәм Ханәфи үзе дә Кеше дигән исемгә лаеклымы? Бүген ул үзенең кылган гамәлләрен ничек кенә акларга тырышып, гаепне гел башкаларга ягып утырса да, Ханәфи бер нәрсәгә төшенә: аның алдында үткән гомернең ярык тагарагы гына һәм "нишләп мине авылдашларым, элеккеге якыннарым, хәтта балаларым да кайгыртмый?" дип уфтанырга гына калган. Кеше гомеренең гыйбрәтле һәм коточкыч фаҗигале финалы бу! Әмма ул бу һәлакәтне үзенә үзе әзерләгән һәм ул бүген башкалар өчен тозаккое казып, шунда үзе егылып төшүче хәлендә.

Әдипнең гыйбрәт бирерлек, кинаяле һәм үткен каләме андыйларны кызганмый, аларның тайгак юллар сайлап, әшәкелеккә батып, йөзләрен югалтуларын, ямьсезләнүләрен күрсәтеп кенә калмый, ә түбәнгә тәгәрәүнең сәбәпләрен, гомумән, һәлакәткә китерүче шушы хәрәкәтнең көчләрен, механизмын аңларга, аңлатырга, анализларга тырыша.

"Сагынырсыз әле сез дә бер" ("Хыянәтчеләр") исемле повестенда да Вакыйф Нуруллин югарыда аталган ысул белән эш итә—бу юлы ул номенклатура дөньясының

гади халык белмәгән ямьсез, кыңгыр һәм сәер якларын ачып сала. Әсәрнең үзәгенә куелган карьерачы бюрократ Шәриф Шәкурович бик ачык максатлар белән яши: үзе өчен уңайлы, жайлы, тыныч тирәлек, шартлар әзерли һәм башкаларны этеп-төртеп, булдыра алганда, тегеләрнең башларына баса-баса югарыдагы житәкчелек кәнәфиләренә менеп утырырга омтыла. Тик моны "шәп кеше" битлеген кимичә эшләп булмый: халыкны яратучы, аның турында аталарча кайгыртучы булып кыланырга кирәк—югыйсә юлыңны тиз бикләрләр, яңа кәнәфиеңнән ничек очып төшкәнеңне сизми дә калырсың!

Образны һәрьяклап һәм тулы ачар өчен авторның үзенә шушы хамелеонның чиркангыч роленә керергә, аның түмгәгенә басып фикер йөртергә дә туры килә. Һәм, әлбәттә, мондый очракларда уртак сөйләм алымы бик киң кулланыла. Нәтижәдә, түбән зәвыклы, примитив, әмма үзенә дигәндә, шактый ук елгыр һәм житез бер адәм актыгының житәкчелеккә бару юлындагы уңышлары-жиңелүләре, ниһаять, һәлакәте үтемле, аңлаешлы, нәкъ шушы типка туры килә торган әдәби алымнар, чаралар ярдәмендә күрсәтелә. Вакыйф Нуруллинның бу әсәре соңгы елларда инде онытыла башлаган "сатирик проза" дип аталган тармакның яшәргә хокукы зур икәнлеген раслады.

В. Нуруллин иҗатының бер кызыклы үзенчәлеге бар: мин бу язучының китапларына вакыт тар булганда, вак-төякләр белән мәшгуль минутларда, көндәлек ыгы-зыгы арасында кагылырга киңәш итмәс идем. Ул үзе дә иркенләп, ашыкмыйча, бирелеп язарга ярата һәм мәсьәләнең төбенә, нигезенә тәмам төшеп житмичә, аны һәрьяклап тикшереп, тәмам ачып, аңлатып бетермичә, соңгы ноктаны куярга теләми.

Күрәсең, мондый алым укучының да шундыйрагын, характерының крестьяннарча сабыррак булуын сорый торгандыр. Аның каравы, чыннан да түземле һәм кызыксынучан булса, укучы бу иҗаттан бик күп нәрсә ала ала: мәсәлән, үз яшәешенең ни дәрәҗәдә камил һәм дөрес икәнен яисә, киресенчә, нинди ялгыш эзләргә төшеп китүен аңлый ала.

Әдип тормыш елгасының хәрәкәтен, аның нинди тарафларга, кайсы үзәннәргә төшеп агуын игътибар белән күзәтә, аның хәтәр борылышларына, чоңгылларына эләгеп бөтерелүчеләрнең дә хәлләренә керергә тырыша. Алар белән бергә язучы сорауларга җаваплар да эзли, әмма бердәнбер дөрес җавапны Кеше җәнапләре исеменә лаек булган һәркем үзенчә, тик үзе генә таба ала шул!

Вакыйф Нуруллин Кеше дигән олы исемне йөртүчеләргә гомере буена хезмәт итеп килде. Бу игелекле юлда аны яңа ачышлар көтә!

**Рифат СВЕРИГИН**

# КҮПКЫРЛЫ ИҖАТ ИЯСЕ

Мансур Әхмәт улы Шиһапов алтмышынчы еллар башында җәмәгатьчелеккә зур киләчәге өмет ителгән сәләтле артист буларак күренеп алды. Иҗатташы Р. Батулла бер мәкаләсендә аның шул дәвердәге эшчәнлеген болай бәян итә: "Качалов исемендәге театр каршында оешкан театр мәктәбен тәмамлап, байтак вакыт Күчмә театрда, аннан соң филармониядә артист булып эшләде. Сәхнәдә ул иҗат иткән образлар байтак булды. Әйтик, Н. Хикмәтнең "Сәер кеше"сендә Ф. Кастро, Г. Мдиванининың "Терезаның туган көне"ндә—Антонио, Ә. Мирзаһитовның "Әниемнең чал чәчләре"ндә—стиляга Гошка, Г. Минскийның "Тапшырылмаган хатлар"ында—Искәндәр, Хәй Вахитның "Беренче мәхәббәт"ендә—Госман Әкбәревич рольләре аның актерлык унышы санала".



Әйе, Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Мансур Казанга килә. 1957—1961 елларда В. И. Качалов исемендәге Зур театр каршында оешкан театр студиясендә белем ала. Курс житәкчеләре Празат Исәнбәт була. Театр дөньясында зур абруйга ирешкән Наилә Гәрәева, Ирек Баһманов, Вадим Кешнер—аның партадашлары.

Шушы уңайдан байтак татар яшьләренә олы иҗат юлын сайларга юнәлеш биргән, шул рухта тәрбияләгән Олы Солтан мәктәбен һәм аның укытучыларын да олылап искә алып китәсе килә. Анда Татарстанның халык артистлары Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәлалев, күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин Мансур Шиһапов белән бер үк елларда укыйлар. Аларга хәтле һәм алардан соңгы елларда шул мәктәптә белем алучы танылган иҗат әһелләре исемлегендә язучылардан Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Мидхәт Миншин, Әхәт Сафиуллин, Госман Гомәрев һәм өч бертуган Гаффаровлар бар. Татарстанда шушындый ук уңышка ирешкән тагын бер авыл мәктәбен мин белмим. Гомумән дә Балык Бистәсе районы халык күңеленең йөзек кашы булырдай шәхесләр тәрбияләүдә үрнәк бер төбәктер, минемчә. Халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык артисткасы Рауза Хәйретдинова, күренекле драматург Сәет Шәкүров, шагыйрь Әхмәт Гаделләр дә бит шул тарихи, болгар бабаларыбыз яшәгән дәвердә үк оешкан Чаллы ханлыгы җирлегеннән.

Мансур Шиһапов шушы районның Яншык авылында 1940 елның 1 маенда туа. Район күләмендә кечерәк бер вазифа үтәгән, авылдашлары арасында абруй казанган Әхмәт Шиһаповның инде дүрт улы була. Бишенчегә Мансур туа. Әхмәт абый дүрт ел сугышта йөреп, 1 нче группа инвалид булып кайтканда инде ул әнисенең төп йомышчысына әверелә. Сугыштан соң туган сеңлесе белән энесенең беренче тәрбиячесе дә ул була. Әхмәт белән Нәфисә Шиһаповлар гаиләсенең булсынга дип тырышып яшәүләренең тагын бер мисалы—җиде балаларының да югары белемле булуы. Әхмәт Шиһапов сугыш яраларыннан тернәкләнеп китә алмыйча, илленче еллар башында вафат булгач, кече энe-сеңелләрне аякка бастырышуда агалары булышлык итә. Үз авылларында утыз еллап укыткан һәм мәктәп директоры булган Хуҗиәхмәт агасы Мансурга да студиядә алган белем белән генә чикләнмәскә киңәш итә. Мансур, эш арасында укып, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый.

Аңа чаклы ук инде Мансурның тагын бер сәләте—оештыручы, әйдәп баручы сәләте ачылган була. Атасы Әхмәткә, абыйларына хас бер сәләт. Житмешенче еллар башында ул Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау өлкәсендә танылып ала. 1974—1976 елларда Г. Камал исемендәге театрның баш администраторы, аннары Курчак театры һәм Күчмә театрның директоры булып эшли. Күчмә театрның статус-дәрәҗәсен күтәрүгә, аны Дәүләт драма һәм комедия театры дип үзгәртүгә ирешә. Туксанынчы еллар башыннан ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары булып эшләде. Хәзерге көндә—1996 елдан башлап Республиканың Дәүләт Зур концерт залы директоры. 1980 елдан Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1996 дан

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Татарстан Республикасының Мактау грамотасы иясе *(2000)*.

Мансур Олы Солтан мәктәбендә укыган елларында шигырь яза башлый. Дусты Кадыйр белән күрше авыл мәктәбенә барганда-кайтканда алар ярышып шигырь әйтешәләр. Мансурның берме-икеме шигыре район газетасында басылып та чыга. Мәктәптә ул драма түгәрәге "артисты" булудан тыш, татар шагыйрьләренең шигырьләрен оста сөйләүче буларак та таныла. Казанда, театр студиясендә укып йөргәндә, берме-икеме шигыре көйгә дә салына—ләкин әле ул җырчы шагыйрь буларак соңрак танылачак. Беренче шигырь китабы "Әйләнеп кайтыгыз" бик соңлап, 1991 елда гына дөнья күрә. Аңа сүз башын—"Шомыртлар ак шәлен ябынса"ны Мөхәммәд Мәһдиев түбәндәге юллар белән тәмамлый: "Кулъязманы укып чыккач, уйга калдым: тәрәзәдән яз исе бәреп кергән сыман булды, туган авылымның җәйрәп яткан иген басуларын күргән кебек, туган нигеземдәге бакча башында ак шәлен ябынган шомыртны күргән кебек булдым". Соңрак шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин "Исәннәр әйләнеп кайталар" мәкаләсендә *(1993)* Мансур шигырьләренә төпле анализ ясап, аларга бик уңай бәһа бирә. Ул китапның мөхәррире буларак, бу бәяләр мине дә сөендерде, әлбәттә.

Шагыйрьнең икенче китабы фәкать җырлардан тора. Аңа авторның иң популяр җырларының берсе булган "Туй күлмәге" исеме бирелгән *(1997)*. Китапка "Әйләнеп кайтыгыз", "Яшьлегем эзләре", "Өлешемә тигән, әй, көмешем", "Кыр казларын бергә каршылыйк" кебек, җыр, сәнгать сөючеләргә таныш, якын булган кырык-илләләп җыр кергән. Язучы Альберт Хәсәнов "Игелекле яуган яңгыр төсле" бәяләмәсендә М. Шиһаповның җыр иҗаты турында болай дип яза: "Танылган җырчыларыбыз Мансурның "Сагыну", "Васыять", "Бүләк ит син", "Унҗиде яшем", "Язгы җыр" h.б. җырларын аеруча яратып башкара, аларны һәрчак концерт программаларына кертәләр. Талантлы шагыйрьнең сүзләренә көйләрне дә бит Сара Садыйкова, Рим Хәсәнов, Рамил Курамшин, Рәис Нәгыймов, Сафьян Ибраһимов кебек танылган, дан алган композиторлар язганнар. Теләмәсәләр, җан тартмаса, шигырьне укып илһамланмаса, син алардан көйләрне өсләренә күсәк белән янап та яздыра алмассың. Өстәп шуны да әйтергә кирәктер, китап рәвешенә кергәнче әле бу җырлар башта җыр сөючеләргә ике дискетага теркәлеп барып ирешәләр. "Яшьлегем эзләре" җыры *(С. Садыйкова көе)* Нәфисә Василова, "Әйләнеп кайтыгыз" *(Р. Хәсәнов көе)* Асаф Вәлиев, "Өлешемә тигән көмешем" *(Азат Хөсәенов көе)* Зәйнәп Фәрхетдинова h. б. бик абруйлы артистларыбыз *(Римма Ибраһимова, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина, Зөфәр Хәйретдинов)* башкаруында бирелә.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу китаплары дөнья күргәнче вакытлы матбугатта Мансур Шиһаповның күпсанлы мәкаләләре һәм курчак театры тарихын чагылдырган, анда эшләүче артистлар, башка иҗат әһелләре белән таныштырган "Казан дәүләт курчак театры" китабы басылып чыккан иде. Драматург буларак та ул көч сынап карый. Гадел Кутуйның "Рөстәм мажаралары" повестена нигезләнеп "Абага чәчәге" инсценировкасын яза. Ул пьеса 1978 елда курчак театрында куела һәм күренекле әдип Нәби Дәүли, аны уңай бәяләп, матбугатта язып чыга. Гариф Ахуновның "Хәзинә" романына нигезләнеп эшләнгән "Кошның да үз оясы бар" инсценировкасы да театр сәхнәсендә уйнала. Драма һәм комедия театрының Ташкенттагы сәфәре вакытында уйналган төп әсәрләрнең берсе буларак шулай ук уңай бәяләнә. Ташкентта яшәүче милләттәш әдибебез, драматург Зиннәт Фәтхуллин аңа багышлап зур мәкалә бастыра.

Бер гаиләдән ике-өч иҗат кешесенең чыгуы бик сирәк күренеш. Бу җәһәттән дә Әхмәт абый белән Нәфисә апа унганнар исәбендә торалар. Урыннары җәннәттә булсын. Мансурдан ике генә яшькә олы абыйсы Рәшит Шиһапов та биш шигырь китабы, берничә танылган җыр сүзләре авторы иде. Педагогия институтын тәмамлаганнан соң байтак еллар Лениногорск шәһәрендә яшәде: балалар укытты, шәһәр Халык театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе булды. Хәзер җәседе туган авылы каберлегендә. Абыйсы вафат булганчы ук язылган, туган төбәгенә, якыннарына багышланган "Ак болытларга карап" мәкаләсендә шагыйрь Мансур Шиһаповның моңдый юллары бар: "Туган авылым Яншыкка кайтсам, беренче чиратта зиратка ашыгам. Анда җиде буын бабамның, кардәшләремнең каберләре... Үзем дә мәңгелеккә шушы зират куенына күчәрмен—каберем шунда булыр. Ташына язарга инде шигырем дә әзер..."

Мансур Шиһаповның үзенчә моңсу шигырьләре, күңелгә "сеңеп" калучан җырлары, яңадан-яңа пьеса һәм инсценировкалары белән әледән-әле танышып яшәргә язсын. Еллар дәвамында тупланган иҗат җимешләрен ешрак укучыга җиткерсен, күен дәфтәрендә генә сакламасын, дигән теләктә калам.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

*Язучылар берлегенең яңа әгъзалары*

## Рәис Гыймадиев



Рәис Мөбәрәкшә улы Гыймадиев 1954 елның 23 апрелендә Чистай районының Каргалы авылында туа. Бирედә урта белем ала. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Чаллы шәһәренә килеп төпләнә. Волгоград дәүләт физкультура институтын һәм Казан дәүләт университетын тәмамлый. Икътисадны тирәнтен үзләштергән тәҗрибәле белгеч бүгенге көндә шәһәрнең "Пассажир автотранспорты предприятиясе" акционерлык җәмгыятен җитәкли.

Әдәбиятка һәм мәдәниятkә яшьтән үк тартыла ул. Шигырьләр яза, шуларның кайберләренә үзе үк көйләр дә иҗат итә. Монысы, мөгаен, аның өздереп баянда һәм тальянда уйнавына бәйледер. Үзе һәм Фирзәр Мортазин, Зифа Нагаева, Илгизәр Мортазин шикелле үзешчән композиторлар җыр язган шигырьләре дистәләр белән исәпләнә. Алар Салават Фәтхетдинов, Венера Ганиева, Рөстәм Закиров, Лилия Муллагалиева, Булат Нигъмәтуллин һ. б. башкаруында еш яңгырый.

Рәис Гыймадиев—күпкырлы сәләт иясе, гаять үзенчәлекле шәхес. Шигырь дә яза, көй дә чыгара, транспорт хуҗалыгы эшен дә оста оештыра. Ул—шәһәрдәге иң абруйлы җитәкчеләрнең берсе санала, узган ел республика күләмендә үткәрелә торган бәйгедә үз тармагында "Ел җитәкчесе" дип танылды. Ул шулай ук Чаллының мактаулы гражданины исеменә дә лаек булды.

Рәис Гыймадиевның шигырьләре көндәлек матбугатта "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан", "Шәһри Чаллы", "Нур", "Якты юл", "Таң йолдызы" газеталарында һәм "Татарстан", "Мәйдан" журналларында еш басыла. Соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында аның "Җырларымны сиңа багышлыйм…" һәм "Яратып яшәгез!" дигән шигырь китаплары дөнья күрде. Туган җир, мәхәббәт, яшьлек, милләт, әхлак темаларын үзенчә ачкан ул шигырьләргә сафлык һәм самимилек хас. Хәзер шагыйрь үзенең өченче китабын басмага әзерләп бетерде.

Татарстан Язучылар берлеге 2005 елның 31 мартында уздырылган утырышында Рәис Гыймадиевны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итте (тәкъдимнамә бирүчеләр: Гәрәй Рәхим, Рабит Батулла, Факил Сафин).

*Хатлардан юллар*

* * *

Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген! "Казан утлары"ның беренче саны килде. Ул минем дүрт ел ярым юксынып, ачынып, сагынып көткән журналым. 2000 елның икенче яртысында юк булган иде ул безнең Беларусь каталогында. Ятьмәгә эләгеп чабаланган балык шикелле тегендә-монда язып, зарланып карадым, тик файдасы булмады. Бер елны каталогта "Вечерняя Казань" гәзите булды, аны яздырып карадым, тик аны уку эчне генә пошырды, татар жаны юк анда. Бермәлне "Татарстан яшьләре" булды, анысы әйбәт иде, әмма аны "Атна" дигәне белән алыштырдылар. Ә ул балалар өчен генә булып чыкты. Менә шулай жәфаландык инде ничә ел. Ниһаять, менә 2005 ел башында "Казан утлары", "Татарстан", "Татар иле"нә язылу мөмкинлеге ачылды.

Ходайның рәхмәте! Журналның башыннан азагына чаклы укып чыктым. Мондый ләззәтне инде байтактан татыганым юк иде. Әмма тиражын карагач шаккаттым: 7025 данә. Бу кимендә 7 миллион татарга. Ә бит 1968 елның 7 саны 62449 данә булып чыккан.

Бу хәл, минемчә, татарның кая барганын исбатлаучы бик аяныч бер дәлил. Бу хәл мине бик рәнжетте, мыскыллады. "Казан утлары" бик тә олкән (яше белән дә, саны белән дә, әдәбилеге, халыкчанлыгы, татарлыгы, шигърияте, фәнни-гыйльми дәрәжәсе белән дә) чын безнең журнал. Мин аны ун яшемнән бирле укып килә идем. Ул чакта латин хәрефләре белән басыла иде. Журнал хәтта сугыш елларында да чыгудан туктамады.

Аңлы татар зыялылары "татар кая бара, бетәрме, калырмы" дип бик житди чаң сугалар. Минемчә, татар бетмәсен, югалмасын өчен балаларны ким дигәндә 4 сыйныфка хәтле тоташтан татарча укытырга кирәк. Аларга татар теле, моңы сенеп калсын. Менә шуның өчен аяусыз көрәшергә кирәктер, дим.

Журнал хезмәткәрләренә, укучыларга сәламәтлек, бар мәшгульлектә уңышлар теләп,

**Санияф ГАРДАНОВ,**
***Беларусь республикасы,***
***Гродно шәһәре.***

* * *

Кадерле редакция!

Минем сезгә журналның сыйфатын яхшырту юнәлешендә бер-ике тәкъдим язасым килә. Ачуланмагыз инде.

Татарны 7 миллион дибез, әмма Татарстаннан тыш, татарлар дөм надан, бернәрсә белән дә кызыксынмыйлар микәнни дигән сорау туа, әллә китап укымыйлар инде. Мине иң шаккаттырганы: нишләп алар арасыннан берәр язучы чыкмый икән, белешергә иде.

Сугыш вакытында әсирлектә булган, Герман жирендә калган һ. б. кешеләр турында бервакыт очрашуда Искәндәр Гыйләжев дигән галим сөйләгән иде, каберләре, зиратлары бар, дип. Шуларның берәрсен тирәнрәк белешеп, язмышлары белән кызыксынып, күләмле әсәр язарга иде. 1945 елда сугыш беткәч татар егетләрен көчләп Магнитогорскига, Чиләбегә һәм башка шәһәрләргә кудылар. Алар хакында да үтә дә гыйбрәтле, кызыклы әдәби әсәр язып булыр иде. Аннан килеп, бәлки, журнал битләрендә Гаяз Исхакый әсәрләрен бастыруны оештырып булыр иде. Минем аларны нишләптер китапханәләрдән таба алганым юк.

Язучыларның балалары ник татарча укымый. Әнә күренекле бер әдипнең кызы русча шигырьләр яза, матур гына яза, дип сөйлиләр. Язучыларның балалары да татарча белмәгәч, аны кем белер соң?

Менә шушы фикерләргә колак салырсыз бәлки. Үзебезнең журналны баерак, эчтәлеклерәк, матуррак итеп күрәсе килә бит.

**Илгизәр НӘҖИПОВ,**
***Татарстан,***
***Кукмара.***

* * *

Без—Уфада яшәүче татарлар, Татарстан вакытлы матбугатына бик мохтажбыз. Үткән гасырда, хәтта Октябрь инкыйлабына кадәр, Уфада һәр почмакта Казан басмалары сатылган. Ә хәзер көндез шәм яндырып эзләсәң дә табарлык түгел. Бәлки, Башкортстанда татар матбугатын сатуны Татарстан республикасы үз өстенә алыр. Шунсыз башка юлы булмас шикелле. Чөнки Башкортстан хакимияте Татарстанны һәм татар халкын күрмәмешкә салыша.

**Рәмил ИСХАКОВ,**
***Уфа.***

* * *

Татар, башкорт гомер буе туган булып яшәде,
Бергә чәчте, бергә урды, бер казаннан ашады.
Көтмәгәндә ил өстенә килеп туды бер каза—
Башкортстан татарларын "чукындыра" Мортаза.

**Ирек МӨХӘММӘТОВ,**
***Уфа.***

* * *

Узган гасырның 80 елларында "Казан утлары" журналын Мәскәүдә тарату өчен шактый көч куелган иде. Әллә инде без бик каты тырышканга, әллә башка сәбәп булдымы, көтмәгәндә генә "Союзпечать"ның махсус карары белән журналга язылуны тыйдылар да куйдылар. Күпме карышып маташсак та, нәтиҗәсе булмады. Мәскәүдә "Казан утлары"на язылу тыелган килеш кала бирде. Шулай итеп, мин аны 15 еллап алдырмый тордым. Менә бу елны янәдән "Казан утлары"на языла алдым һәм моңа бик шатмын. Беренче-икенче саннарда А. Хәлимнең "Сез беләмсез кая барганны?" дигән мәкаләсен йотлыгып укып чыктым. Бигрәк күптән көтелгән, өметләнгән, әдәбиятыбыз өчен өлгереп җиткән проблеманы күтәрә автор. Дөрестән дә, әдәбиятыбызда яшүсмерләрне тәрбияли торган герой-каһарман образы юк бит. Икенчедән, гомумән алганда татар әдәбиятында тәнкыйть юк дисәң дә була. Шуңа күрә бу тәнкыйди әсәр мине бик куандырды.

Әдәбият, әдипләр—халык өчен, алар милләткә хезмәт итә. Чынлап та, әдәбиятыбызда каһарман образлар булмагач, яшьләребезне ничек тәрбиялик соң? Шушы уңайдан искә төшә, балачакта әнием безгә укый торган иде бик мавыктыргыч хикәяләр: Хәзрәти Али ничек кяферләр белән сугыша, бер селтәнүдә мең кяферне кырып сала, монысы дини каһарман, дин юлында көрәшкән. Безнең күзләр елтырый, сөенешәбез, менә ничек безнең Али дошманны кыра дип. Бу бит сугыш еллары, һәр гаиләдән әтиләр, абыйлар сугышта. Тагын бер Сары Салтык турындагы хикәят истә калган. Бик батыр егет, нинди генә батырлыклар кылмый урыслар белән сугышканда, бар дошманнан өстен чыга, барчасын җиңә. Монысы булгандыр Алтын Урда каһарманы, татар кешесе. Соңгысы хакында бүтән укырга туры килмәде. Менә без—бала-чагалар өчен бик кирәкле үрнәк каһарманнар иде алар. Ә инде үсеп җиткәч укыган китапларда без гел җиңелгән, без гел начар итеп сурәтләнәбез. Билгеле, мондый әдәбиятның яшүсмергә йогынтысы начар.

Уйланыр урын шактый икән шул.

**Мөхәммәт МИНАЧЕВ,**
***Мәскәү.***

# *Нур Баянның туувына 100 ел*

Нур Баян *(Нур Галим улы Баянов)* 1905 елның 15 маенда Татарстанның хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Тормыш авыр булу сәбәпле, Нур ел саен каникул вакытында туган авылыннан читтә эшләп йөри. 1921 елгы ачлыкта ул Пермь шәһәренә үк китә, кара эшче булып эшли. 1923 елда белем алу теләге белән Казанга килә, Татар-башкорт хәрби мәктәбенә курсант итеп алына. Шул елларда әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. 1928 елда ул "Кызылармеец" дигән хәрби газета редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. 1929—1930 елларда ул "Колхоз яшьләре" журналының җаваплы сәркәтибе, аннары Чаллы район газетасы редакторы. 1932 елда ул Казанга кайта, Татарстан Язучылар Берлеген оештыру комитетында инструктор, Татарстан дәүләт нәшриятында (Татгосиздат) редактор була. 1934 елда Н. Баян СССР Язучылар Берлеге члены итеп кабул ителә.

1938 елдан Бөек Ватан сугышына кадәр Н. Баян әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Шагыйрь Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, һәрвакыт алгы сызыкта була. Башта полк партия оешмасы секретаре, аннары дивизия газетасы редакторы һәм полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары сыйфатында сугыша, подполковник дәрәҗәсенә күтәрелә. Күрсәткән батырлыклары өчен Беренче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Җиңү көненә нибары унбиш көн калгач, 1945 елның 23 апрелендә, Австрияне азат итү өчен барган соңгы көрәшләрнең берсендә Н. Баян батырларча һәлак була.

**Nur BAYAN**

## Өç bərket

**Өç tuğan bergə utırıp,**
**Bik ozaq kinəştelər,**
**Baraçaq yulların alar**
**Bergələp səyləştelər.**

**Çəy eçtelər şatlanışıp,**
**Ataları yanında,**
**Cir şarının zur kartası**
**Tordı alar aldında.**

**Əytte ata: "Cigebezgə**
**Ayaq bastı yılannar,**
**Turağız ul şaqşılarnı,**
**Sınatmağız, olannar,**

**Alar şuğışqan urında**
**Qorıp qala igennər,**
**Şinə cirdə isle gəllər,**
**Ağulanalar gəllər..."**

**Ataları өç tuğanğa**
**Өç yünəleş kürsətte,**
**Өçese өç yuldan çığıp**
**Kitəçəkləren aytte:**

**"Aldığızda biek tawlar,**
**Qarurmannar bulırlar,**
**Qarşığızda uqmalışıp**
**Şul yılannar torırlar.**
**Məgez,—dide, ütken qılıç,**
**Yılannarnı kisərgə,**
**Məgez sezgə aqbüz atlar,**
**Urmannarnı kiçərgə.**

**Taw-taşlarğa qaramıyça,**
**Ciŋep alğa barırsız,**
**Planetağa, bərketlərem,**
**Kitsen seznеŋ danığız".**

**Өç bertuğan bertawıştan**
**Kütərep qılıçların:**
**—Yest'! — didelər,**
**Ata upte**
**Üzeneŋ laçınnarın.**

**Bu yegetlər kərəşlərdə**
**Sınalğan ullar ide:**
**Kükrəklərе orden belən**
**Alarnıŋ tulğan ide.**

Sawbullaşıp өç bertuğan
Yulğa çığıp kittelər,
Kiŋ urmannar, zur yılğalar,
Teka tawlar uttelar.

Өcese өc cirdə xəzer
Atanın balaları,
Həm turıylar ber-ber artlı
Gitlerçı bandalarnı.

---

## *Әхмәт Исхакның тууына 100 ел*

Әхмәт Исхак *(Әхмәт Габдулла улы Исхаков)* 1905 елның 1 маенда Казан шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Жиде яшендә "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга керә. 1919 елдан укуын Казандагы татар педагогия техникумында дәвам иттерә. 1922 елны аны тәмамлый, комсомолның Татарстан өлкә комитетындагы матбугат бүлегендә экспедитор, аннары экспедиция мөдире булып эшли. Шушы елларда ул, инкыйлаб алып килгән ижтимагый үзгәрешләр белән рухланып, шигырьләр яза башлый. "Кызыл кошлар" исемле беренче шигыре 1923 елда "Кызыл Шәрекъ яшьләре" журналында басыла.

1925 елда Таткино оешмасы аны Мәскәү Дәүләт кино техникумының сценарий бүлегенә укырга жибәрә. Әмма бу бүлек шул елны ук бетерелә һәм шагыйрь Мәскәүдәге "Эшче" исемле татар газетасы редакциясендә эшли башлый, М. Жәлил белән якыннан аралаша, үзенең шигырь китапларын бастырып чыгара.

1928 елда Ә. Исхак Казанга кайта, "Кызыл Татарстан" (хәзерге Ватаным Татарстан") газетасы һәм "Чаян" редакциясендә, 1939—1942 елларда СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле булып эшли, 1939 елда СССР Язучылар Берлегенә әгъза члек итеп алына.

Ә. Исхак 1942—1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, взвод командиры һәм хәрби журналист була. 1963—1967 елларда ул "Чаян" журналының баш мөхәррире булып эшли, пенсиягә чыкканнан соң бөтен эшчәнлеген тулысынча әдәби ижатка багышлый.

Ә. Исхак үз әсәрләрен язу белән берrәттән дөнья поэзиясе классикларын татарчага тәржемә итү өлкәсендә дә күп эш башкарган язучы.

Шагыйрь 1991 елның 24 июнендә Казанда вафат булды.

**Əxmət İSXAQ**

## Xaqiqət təse

Xaqiqət ul
Asılda
Ap-aq bula.
Ana səte təsle
Saf, pak bula.

Xaqiqətnen bula
Qızılı da,
Qanğa mançılğanda
Kərəş qızuında.

Xaqiqətnen oçrıy
Qayçaq sarısı,
Çağılğanda aŋarda
Cineŀü sağışı.

Xaqiqətneŋ bulmıy
Çuarı, alası
Həm şulay uq bulmıy
Qarası.

Xaqiqat ul
Asılda
Ap-aq bula.
Ana səte təsle
Saf, pak bula.

Tik saqlağız anı
Pıçratudan:
Kügərə həm pıçrana ul
Tik yatudan!

*Шакир Мөхәммәдевнең туууына 140 ел*

# "ЗАМАНЫБЫЗ ТӘРӘККЫЯТ ЗАМАНЫДЫР..."

XX йөз башы татар әдәбиятының реализм юнәлешендә үсеп китүенә, сурәтләүнең сатира алымнары, публицистик эчтәлек белән баюына зур өлеш керткән әдипләрнең берсе—Шакир Мөхәммәдев. Ул безнең әдәбиятка беренчеләрдән булып татар сәүдә буржуазиясе вәкилләрен алып керә һәм иҗатында чынбарлыкның мөһим, моңа кадәр сүз сәнгатендә читтәрәк калып килгән мәсьәләләрен күтәрә. Кеше һәм милләт яшәешен, киләчәген мәгърифәт-белем, әдәп-әхлак, шәхес иреге, әйләнә-тирә йогынтысы белән бәйләп караган мәгърифәтчелек реализмын иҗтимагый тормыш, җәмгыятьтәге шартлар, яшәеш кануннары белән баета. Ул әдәбиятка алып килгән яңа төсмерләр, алым-чаралар реализмны төрләндерә, аның яңа сыйфат үзгәрешенә күчүенә җирлек әзерли.


*Шакир Мөхәммәдев*

Әдипнең иҗат мирасын өйрәнү исә соңарып, 1930 нчы еллар азагында гына башлана. Бу өлкәдә аеруча М. Гайнуллинның хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк. XIX йөз башы татар әдәбиятына бәйле хезмәтләрдә М. Гайнуллин, М. Гайнетдинов, Ф. Мусин, Я. Ханбиков, И. Вәли, Ү. Гыймадиев, Р. Әмирханов, Ф. Бәширов һ. б. галим-тәнкыйтьчеләр Ш. Мөхәммәдевнең әдәби иҗатына, журналистлык эшчәнлегенә югары бәя биреп, аның сүз сәнгатен яңа тема-проблемалар, сурәтләү чаралары белән баетудагы һәм татар журналистикасын үстерүдәге ролен билгеләп үттеләр. Шуның белән бергә, әдипнең сайланма әсәрләренең М. Гайнуллин тарафыннан 1958 елда басылуын да әйтергә кирәк. Хәзер инде әлеге җыентыкны табуы да кыенлашты. Дөрес, язучының аерым әсәрләрен "Казан утлары", "Мирас" журналлары укучыларга тәкъдим итте. Әмма танылган язучы һәм журналистның иҗат мирасын бөтен тулылыгында бастырып чыгару киләчәк эше булып кала бирә.

Шакир Мөхәммәтша улы Мөхәммәдев 1865 елның 20 маенда Буа шәһәрендә туа. Берничә ел мәдрәсәдә белем алган 14 яшьлек егетне тормыш эш эзләп читкә чыгып китәргә мәҗбүр итә. 1879 елны Оренбургка килеп, ул самоварчы малай булып эшкә урнаша, аннары сәүдә конторасына күчә. Шул елларда русча укырга-язарга өйрәнә, хисап-икътисад эшен үзләштерә. Бераздан Мәскәүгә күчә һәм рус сәүдәгәренә ялланып эшли башлый, шунда сәүдә-хисап эшләре буенча курсларда укый. 1900-1901 елларда рус сәүдәгәрләренең Харбин (Кытай) шәһәрендәге сәүдә конторасында эшли. 1902 елда туган ягына кайта. Буада бераз яшәгәннән соң, 1903 елда Оренбургка килә һәм шунда яшәп кала. Әдип һәм журналист буларак актив иҗат белән шөгыльләнә. 1923 елның 10 ноябрендә үпкә авыруыннан вафат була.

Ш. Мөхәммәдев башта прозаик һәм шагыйрь буларак танылa. Әдипнең "Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай", "Яфрак асты, яки Мәкәрҗәярминкәсе", "Япон сугышы, яки доброволец Батыргали агай", "Хан кызы" кебек хикәя-повестьлары һәм күпсанлы тезмә әсәрләре үз чорында гына түгел, бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Шуның белән бергә, Ш. Мөхәммәдев журналист буларак та бай публицистик мирас калдыра. Бу язмада без аның иҗат эшчәнлегенең шул ягына киңрәк тукталабыз.

Үзе мөхәррирлек иткән "Карчыга" журналында (Оренбург) һәм "Вакыт" (Оренбург), "Әлгасрел-җәдит" (Уральск), "Шәркый рус" (Тифлис) һ. б. газета-журналларда дөнья күргән күпсанлы язмаларында чорга, заманга, күптөрле иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга бәясен, карашын һәм иҗтимагый, әдәби караш-фикерләре үсеш-үзгәрешен күрәбез. Безнең каршыда ул тынгысыз җанлы,

һәрнәрсәгә үз мөнәсәбәте булган каләм иясе, милләт язмышы өчен борчылып яшәүче талантлы журналист буларак ачыла.

Әдипнең хикәя-повестьларында публицистик яңгыраш көчле, аерым вакыйгаларны сөйләп аңлатуда, нәрсәнедер ачык итеп яклауда, йә тәнкыйть итүдә очерк төсмере дә чагыла. Ш. Мөхәммәдевнең публицистик язмалары жанр ягыннан да гаять төрле. Арада новеллалар һәм фельетоннар, сатирик мәкаләләр һәм пародияләр, памфлетлар һәм көлкеле миниатюралар, очерклар һәм аллегорик хикәяләр бар. Ул һәр жанрда дип әйтерлек бердәй тигез, уңышлы һәм актив эшли. Әдип яшәешнең төрле якларына игътибар итә һәм публицистик язмаларында чорның актуаль мәсьәләләрен кискен рәвештә күтәрә. Аны милләтнең мәдәни, икътисади яктан артта калуы, мәктәп-мәдрәсәләрнең һаман да заман таләпләренә җавап бирмәве, инкыйлаб яулаган уңышларның реакция тарафыннан юкка чыгарылуы, социаль тигезсезлек, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы байларның әхлаксызлыгы, бозыклыгы, Думаның үз максатларына ирешә алмавы, эшче һәм крестьянның авыр тормышта яшәве, дин әһелләренең әдәпсез эш-гамәлләре һ. б. борчый.

Югарыда әйтелгәнчә, Ш. Мөхәммәдевнең беренче хикәяләре үк публицистик пафос белән сугарылган. Язучы үз күңелендәге теләк-фикерләрне укучыларга җиткерү өчен әдәбиятны файдалана. Истәлек-хатларыннан күренгәнчә, ул шәкертләр алдында чыгыш ясаудан да баш тартмаган, ә татар матбугаты барлыкка килгәнче Тифлистә чыга торган “Шәркый рус” газетасының актив хәбәрчеләреннән берсе була.

1902 елны туган ягына кайткач, Ш. Мөхәммәдев Буа мәдрәсәсе шәкертләре белән очраша. Аның чыгышы 1907 елны “Әлгасрел-җәдит” газетасында басылып чыга. Дөнья күреп, тормыш тәҗрибәсе туплаган әдип милләт язмышы өчен тирәнтен борчыла. “Милләтебез ятимдер, башка милләтләргә нисбәтән гыйлем-мәгърифәттә, тәрәккый вә тиҗарәттә без бик артта калганбыз”,—ди ул һәм моның сәбәпләрен искелеккә ябышып ятуда, гамьсезлектә, наданлыкта күрә. Ш. Мөхәммәдев башка милләтләрдән үрнәк алырга, алар тәҗрибәсен өйрәнергә чакыра. Аның идеалы булып, “иҗтиһад сәясендә, гыйлем-мәгърифәт аркасында бөек дәрәҗәләргә ирешеп, исемнәрене тарихта бакый калдырган” Искәндәр һәм Наполеон, Колумб һәм Эдисон, Шекспир һәм Вольтерлар тора. Халыкның, җәмгыятьнең киләчәге “милләт хадиме ... булачак, имам, мөдәррис, таҗир (сәүдәгәр) булачак” яшьләргә бәйле. Инкыйраздан котылу юлы бер генә—“заманыбыз тәрәккый заманыдыр, гасрыбыз гыйлем-мәгърифәт, һөнәр гасрыдыр”. Шуңа күрә мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп кору, дөньяви фәннәр, шул исәптән рус телен дә өйрәнү чор таләбе булып тора. Әдип театр булдыру, ятимханәләр, хастаханәләр ачу, газеталар чыгару, җәмгыяте хәйрияләр оештыруны да тиз арада хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дип саный.

Халык язмышын үз язмышы итеп санаган Ш. Мөхәммәдев аң-белем тарату, тәрәккыяткә чакыру өчен һәртөрле мөмкинлектән файдалана. Аның “Шәркый рус”, “Вакыт” газеталарында басылып чыккан мәкаләләре заманчалыгы, фикер-карашларының ачыклыгы белән әлеге максатка хезмәт итә. Әдип публицистик характердагы “Кырымга сәяхәт”ендә иҗтимагый үзгәрешләрне, кешенең активлыгын, кызыксынучанлыгын яклый. Әлеге мәкалә XIX йөз башында активлашып киткән сәяхәтнамә жанрына да ачыклык кертә, аның үзенә генә хас үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итә. Автор укучысын сәяхәт кылырга, яңа җирләр, халыклар, аларның яшәү рәвеше белән танышырга чакыра, чөнки “сәяхәт кешенең фикерен ача, күңелен нурландыра, белмәгәнен өйрәтә”. Шуның өстенә “сәяхәтчеләр һәрнәрсәне күзләре белән күрәләр, алар турында фикер йөртәләр, уйлыйлар”. Әдип бу эшнең мөһимлеген, кызыклыгын белдереп, сәяхәт кылучыга төп таләбен дә җиткерә: “география, тарих, чит тел һәм башка өлкәләрдән белеме булу да беренче шарт”.

Ш. Мөхәммәдевнең “Кәрван сарай вакыйгасы яхуд ысулы кадимнәр гимнастикасы” исемле фельетоны искелек тарафдарларын фаш итә. Җәмгыятьнең бөтен өлкәләрендә барган көрәш мәктәп-мәдрәсәләрдә аеруча кискен һәм ачык төс ала. Ул бәхәс, сүз көрәштерү белән генә калмыйча, кайвакыт искелек тарафдарларының физик көч куллануына да барып җитә. Әдип реаль тормышта булган шундый бер вакыйганы күрсәтә: “Коры һәм мәгънәсез бәхәсләшүләр белән

башлары каткан, ялкаулыкка чумган (...), мәгънәсез китаплар укытып, бичара, гөнаһсыз балаларның зиһеннәрен агулаган бер төркем надан, намуссыз хәлфәләр (...) гауга чыгарып, бәхетсез укытучы Ш. әфәндене бик каты кыйныйлар һәм, ярымялангач хәлдә, укучы балалары, китаплары белән барысын бергә, мәдрәсәдән кар өстенә чыгарып ташлыйлар". Сәбәбе нидә соң? Әлеге белемле, намуслы, тырыш мөгаллим җәдит ысулы белән укытып, яхшы нәтиҗәләргә ирешкән икән. Аның укучылары белемнәре белән генә түгел, тәрбияле булулары белән дә аерылып торалар. Кадимчеләр исә көнләшеп, ачуларын әнә шундый "гимнастика" белән чыгаралар.

Беренче рус инкыйлабы яулап алган матбугат ирege уңдырышлы туфракка төшә. Татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә диярлек газета-журналлар чыга башлый. Атаклы меценатлар Шакир һәм Закир Рәмиевләр нәшир иткән, мөхәррире Ф. Кәрими булган "Вакыт" газетасы дөнья күрү Оренбургта гына түгел, башка урыннарда да көтеп алынган вакыйгага әйләнә. Шунда басылып чыккан "Аз булса да алга барабыз" мәкаләсендә Ш. Мөхәммәдев вакытлы матбугатның тормыштагы ролен шактый тулы ача. Татар телендәге матбугатның башлангычы итеп ул Бакчасарайда И. Гаспралы чыгарган "Тәрҗеман"ны саный. Нәкъ менә әлеге газета "Россиядә булган халаиклар яхшы ук күзен ачкан, йоклаган фикерләрен уяндырган вә милләт тамырларын кузгаткан иде". Бөтен төрки-татар дөньясына таралган "Тәрҗеман" мәктәп-мәдрәсәләргә җәдит ысулын кертүгә, мөгаллимнәр әзерләүгә, белем-мәгърифәт таратып халыкның күзен ачуга, әдәбиятның үсеш-үзгәрешенә зур йогынты ясый. "Ходайга шөкер,—дип шатлыгы белән уртаклаша әдип,—ул көткән заманыбыз, дүрт күз илә интизар булган вакытыбыз да җитте: "Вакыт" газетасы бүген мәйданга чыкты". Газетаны гамәлгә куючыларны ул ачык фикер белән халыкка юл күрсәтүче булырга, белем-мәгърифәт, әдәп-әхлак таратырга чакыра.

Ш. Мөхәммәдевнең "Вакыт" газетасында басылып чыккан "Зур кешеләребез" һәм "Төрмәләр тулды" язмалары үткен социаль эчтәлекле. Әдип инкыйлаб аша яулап алынган ирек, азатлыкны, демократия күренешләрен шатланып каршы ала. Бу үзгәрешләрне ул "башка кояш чыгу"га тиңли. Аның карашы киң. Автор тар милли кысаларда калмый. "Нинди генә диндә, нинди генә мәзһәбтә, яки кайсы гына милләттә булмасын (...), һәркем бер иркен сулыш алып, гаҗәпсенеп, унга-сулга карый башлады",—дип яза ул. "Зур кешеләребез" сурәтле тел белән язылган очеркны хәтерләтә. Ш. Мөхәммәдев хөрриятқә бәйле рәвештә күңелендә туган шатлык хисләрен табигатьтәге иркенлек, уяну белән, ташкын дәрьясы белән чагыштыра: "Ничә вакытлар җыелып акмый торган суны ерып җибәргәч, теләгәнчә иркенләп һәр якка шаулап аккан кебек, йөз еллардан бирле Россияле халыкларның йөрәкләрендә бикләнеп торган фикер дәрьялары да, ташып, бөтен дөньяга таралды, чәчелде". Әле медальнең икенче ягы да бар икән. Инкыйлаб давылы түрә булып утырган "зур кешеләрнең" чын йөзләрен ача. Моңа кадәр әдәп-әхлак үрнәге булып йөргән бик күп чиновникларның адәм ышанмаслык мордар эшләр белән шөгыльләнүе халыкка билгеле була. Әдип хөкүмәтнең, бюрократик аппаратның нигезләрен тәнкыйтьли.

Ш. Мөхәммәдев инкыйлабны тулысынча яклый, шуңа да аның "Төрмәләр тулды" язмасы "тугрыны сөйләгән, халыкны яклаган, халык өчен, ватан өчен җаннарын фида кылучы яшь адәмнәргә" теләктәшлек, ә реакция тарафдарларына нәфрәт белән сугарылган. Тарихтан китәргә теләмәгән һәртөр искелеккә, артталыкка, торгынлыкка, мәгънәсезлеккә каршы көрәштә үтемле чара итеп язучы сатираны сайлый. Хикәяләрендәге, бигрәк тә "Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" повестендагы сарказм белән көлү күпсанлы китап укучыларда теләктәшлек таба. Шуның өстенә әдип тизлек белән үзгәреп торган вакыйгаларга үз вакытында мөнәсәбәтен белдерү кирәклеген дә яхшы аңлый. Ниһаять, 1906 елның сентябреннән Ш. Мөхәммәдев "Карчыга" исемле сатирик журнал чыгара башлый. Моңа рөхсәт алынуның хөррият аркасында булуын ул яхшы аңлый, шуңа да журналның исеме астына болай дип язылган: "Хөррият илә каимдер безем хәятымыз, истибдат дәвам идәрсә якындыр мәматымыз" ("Азатлык булганда гына тормышыбыз бөтен була, ә реакция көчәюю үлемебезне якынайта"). Журналның төп юнәлешен, мәсләген Ш. Мөхәммәдев "Максат" исемле мәкаләсендә ачык белдерә: "надан, тәкәббер, залим, ач күзле капиталистлар илә сугышмак, кадәр хәл приказчик, конторщик һәм эшче халыкның файдасына каләм йөртмәктер" һәм "ачлыктан аптыраган,

хокуксызлыктан гажиз калган, жирсез-сусыз авыл халкының тормышыннан (...), мәктәп-мәдрәсәләрдән вә гайре нәрсәләрдән бәхәс итеп, тиешсез һәм килешмәгән эшләрне көлке тарихы (юлы) илә язып, рәсемнәре һәм күрсәтеләчәктер".

"Карчыга"ның татар тормышындагы ямьсез якларны тупас итеп тәнкыйтьләве, бик күпләрнең исемнәрен әйтеп көлүе кайбер газета-журналлар белән каршылыкка китерә. Көлкеле журналларны тупаслыкта гаепләгән "Тәрҗеман"га җавабында Ш. Мөхәммәдев исә үз максатыннан чигенмәячәген әйтә: "ишаннарның догасы бәрәкәтендә тирән гафләт (карангылык) йокысында булган татарларны, ыспайлык кылган булып, колак тишегенә бик нечкә бер йон тыгып кыймылдатканда йокыдан уйгатып булырмы? Әлбәттә, булмас. Гафләт йокысыннан уяту өчен, сукканда авыртканы сизелә торган тупасрак корал истигъмал кылмак (кулланмак) файдалырак булса кирәк".



*«Карчыга» журналының титул бите.*

Кызганыч ки, азатлык һәм үсеш-үзгәреш дошманнары күп һәм көчле була әле. Карагруһ көчләр тырышлыгы белән "Карчыга" журналы 1907 елда чыгудан туктый. Барлыгы 9 сан гына чыгып калуга карамастан, ул искелеккә каршы кискен көрәше һәм мәгариф, мәдәният, тәрәккыят юлындагы эшчәнлеге белән татар вакытлы матбугатында мөһим урын алып тора. Ш. Мөхәммәдевнең журналистлык таланты да тулысынча ачыла. Ул мөхәррирлек итеп кенә калмый, ә күпсанлы мәкаләләр авторы да була. Матбугат ирегеннән файдаланып мәйданга чыккан "Карчыга" инкыйлабны эзлекле яклый. Ш. Мөхәммәдев үзе сәяси мәсьәләләрдә социал-демократлар позициясендә тора. 1906 елдан инкыйлабка каршы көчләр баш калкыта. Илдә реакция сөреме таралуын, аның фаҗигале күренешләрен әдип "Хәзерге хәлләр" һәм "Хәсрәтле көннәр" исемле мәкаләләрендә сәяси үткенлек белән ача. Һәртөр погромнарны, вәхшиләрчә үтерелгән гаепсез хатын-кызларны, бала-чагаларны һәм ирек, җир өчен көрәшүчеләрнең Себергә җибәрелүен ул болай бәяли: "йөзләрчә адәмнәрнең асылуы, киселүе күз алдына китерелсә, инсан гакылыннан шашар!" "Хәсрәтле көннәр" язмасында илне кайгы-хәсрәт, күз яше, ачлык-ялангачлык басып алуы турында борчылып яза. Шулай да ул якты көннәр киләсенә ышана: "Әмма бу иске тормышның нигезе хәзер тәмам черегән, бүгенме-иртәгәме егылачак. Хаклык һәрвакыт өстен булачагында һич шөбһә юктыр. Хәзергә кадәр аяк астында изелгән эшче халык илә җирсезлектән аптыраган авыл халкы да, әлбәттә, бер көн моратларына ирешеп, дөнья яктысы күрәчәкләр".

Тормышка үзгәрешләр кертүнең бары тик көрәш аша гына мөмкин булуын Ш. Мөхәммәдев яхшы аңлый. Ә моның өчен "беренче шарт—берләшү" дип мөрәҗәгать итә ул эшче вә крестьяннарга, приказчик вә конторщикларга. Аның әлеге карашлары "Эшче халыкка" мәкаләсендә ачык чагылыш таба: "Әгәр дә без—үзебезнең кул көчебез, үзебезнең маңгай тиребез берлән тамак туйдыручы эшчеләр—үз кирәкләребезне үзебез сорамасак, үзебезнең ачлы-туклы тормышыбызны яхшыртыр өчен үзебез иҗтиһад кылмасак, (...) безнең көнебез дә, тормышыбыз да яхшыланмаячак".

1904-1905 елларда барган һәм Россиянең хурлыклы җиңелүе белән тәмамланган рус-япон сугышына Ш. Мөхәммәдев битараф кала алмый. Мона сугыш вакыйгаларының үзе кайчандыр хезмәт иткән Маньчжуриядә баруы да йогынты ясагандыр, билгеле. Күпсанлы фельетоннарында генералларның булдыксызлыгы

аркасында русларның җиңелүен ул көлеп яза. Әлеге сугышның илдәге тәртипсезлекне, бюрократик системаны, ришвәтчелекне ачуын да күрсәтә. Шулай ук әдипнең сугыш мәсьәләләренә берьяклы гына каравын да күрәбез. Үзенең атаклы "Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" повестенда да, журналдагы язмаларында да ул әлеге канкоешның империалистик характерын, аның рус һәм япон халыкларына гына түгел, кытайлыларга да кан-яшь, кайгы-хәсрәт, ачлык-ялангачлык алып килүен тулысынча ача алмый. Дөрес, монда авторның мөмкинлекләре чикләнгән булуны, һәр язмасының цензура аша үтүен дә онытмаска кирәк.

Беренче рус инкыйлабы басымы астында патша, законнар чыгару органы буларак, Дәүләт Думасы оештырырга мәҗбүр була. Думага сайлаулар вакытында төрле социаль катлаулар мәнфәгатен яклаган партияләр арасында көрәш башлана. Сайлауларның әһәмиятен яхшы аңлаган Ш. Мөхәммәдев укучыларын да гаять игътибарлы булырга, үз кирәк-яракларын гына кайгыртучыларны якламаска өнди. Сәяси хәлне шактый ачык, тулы аңлаган әдип кадетлар, социалистлар, октябристлар һ. б. партияләр юнәлешенә, максатына зур булмаган аңлатмалар бирә. Татар халкы мәнфәгатен яклау максатында оешкан "Мөселман иттифакы" партиясенә ул тәнкыйди карашта тора. "Мәкәрҗә хәбәрләре", "Яңа төш тәгъбире", "Срочный телеграмм" һ. б. фельетоннарында әлеге партияне гади халыкны яклямаучы итеп күрсәтә. Бу уңайдан аның "Карчыга" журналының сигез санында эзлекле чыгып килгән "Митинг" исемле памфлеты кызыклы. Мәсәлгә тартым язмада Россиянең эчке хәленә шактый тулы характеристика бирелә. Мәкалә, аллегорик формада булса да, мөселман съездларында ясалган чыгышлар белән журнал укучыларын таныштыруны максат итеп куя. Бирелә "Мөселман иттифакы" партиясен оештыручыларыннан булган Р. Ибраһимов белән Й. Акчурин, Урта Азиядән килгән Г. Тупчибашевларның фикер-карашлары да урын алган. Белгәнебезчә, "Мөселман иттифакы" партиясе "дин һәм милләт берлеге" дигән принципка нигезләнә. Милли бердәмлек тигезлеккә, азатлыкка, тәрәккыяткә ирешүдә таяныч булып тора. Бүгенге көндә исә бик күпләр үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту, искелекне яклау белән генә мәшгуль: "Мәсләкләре җил кайдан иссә, шул тарафка авышадыр. (...) Россия золымыннан, миссионерларның фетнәсеннән котылу өчен русларның үзләреннән артык рус телен, рус законын укып, заманасына ярашу, дөнья гыйлемен белү кирәк иде. Әмма алар, курчак уены кебек, тырнак кисү, мыек кырку, ысул кадим, ысул җәдит илә гомер заигъ итәләр".

"Митинг" язмасының ахыры юк, шунлыктан Ш. Мөхәммәдевнең соңгы фикере, мөнәсәбәте ачылып бетмәгән. Әмма башка мәкаләләрдән күренгәнчә, "Мөселман иттифакы" партиясенең эш-гамәлләрен әдип тулысынча хупламый, аеруча аларның дин уртаклыгы, милләт бердәмлеге белән мавыгып, эшче һәм крестьян мәнфәгатьләреннән читләшүен кабул итми.

"Карчыга" журналында искелек-артталыктан, кадимчелектән көлеп язылган мәкаләләр даими урын ала. "Оренбург җәмгыяте хәйриясе" фельетонында автор "Бәдавам" китабындагыча яшәргә чакырган кадимче байдан көлә. Аның кебекләр җыелып "әдәбият кичәләре оештырмаска, гәҗит-журналлар белән шөгыльләнмәскә" дип беркетмә төзегәннәр икән. Боларның 1905 елны Оренбургта И. Кудашев-Ашказарский оештырган беренче театр кичәсен таркатучылар төркеменнән икәнен аңлау кыен түгел. "Карт байның хаты", "Юанкорсаковка ачык хат" язмалары да һәртөр карагруһчылардан сарказм белән көлеп язылган.

Үзенең публицистик язмаларында Ш. Мөхәммәдев яшь буынны тәрбияләү, мәгърифәтле итү, хатын-кызларның җәмгыятьтәге урыны, яшәешнең төрле якларына бәйле әдәп-әхлак һ. б. мәсьәләләрне дә читләтеп үтми. Аның һәрбер мәкаләсе кешегә хөрмәт һәм аңа ярдәм итү теләге белән язылган. Әдип язмаларының сәнгатьчә эшләнешенә, ягъни фикер ачыклыгына, укучыга тәэсир көченә, формасына, теленә җитди игътибар бирә. Аның байтак фельетоннары фикер көрәшенә нигезләнгән һәм алар диалог, пародия, ачык хат, телефонда сөйләшү рәвешендә язылган. Ш. Мөхәммәдев рифмалаштырылган прозаны да яратып куллана. Бу алым аңа фикерне мәгънәви тирәнәйтергә, укучыга тәэсир көчен арттырырга мөмкинлек бирә: "мәктәп-мәдрәсәләр ислах кылынып, укулар көйләнсә иде; мәчетләрдә гавам

аңларлык татарча вәгазьләр сөйләнсә иде; приказчикларның хезмәт хакы байлар тарафыннан сполна түләнсә иде..." ("Рамазан хөрмәтенә теләкләр"). Язучы публицистик язмаларында мәкаль-әйтемнәрдән, халыкчан гыйбарәләрдән уңышлы файдалана ("Болганчык суда балык тоту"; "Комда калган балык" һ. б.). Ул юмор һәм сатираның төрле алымнарына мөрәҗәгать итә. Ш. Мөхәммәдев тормыштагы, аерым кешеләр характерындагы кимчелекле яклардан турыдан-туры күләргә ярата, ә аерым очракларда ул күз яше аша көлү булып яңгырый.

Шулай итеп, талантлы әдип һәм журналист Ш. Мөхәммәдев үзенең хикәя-повестьларында, публицистик язмаларында чорның актуаль мәсьәләләрен күтәрә, үткен каләме белән җәмгыятьтәге каршылыкларны ачып сала, һәртөр искелек-артталыкны, ялган-мәкерне фаш итә һәм гади халык мәнфәгатьләрен, азатлык-тигезлекне яклап чыга. Шуңа күрә аның иҗаты бүген дә заманча яңгырый.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

---

# КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ:

"Оренбург вокзалы... Пассажирлар ташкыны буып өлгермәгән борынгы перрон, тимер юлдан ерак түгел парк... Аннан тынлы оркестрның вальс уйнавына хәтле ишетелеп тора. Ташкенттан Мәскәүгә таба үтүче скорый поезд, әр-яңа вагон һәм... аның баскычында Булат. Акрын гына кузгалып тизләгән арттыра баручы поездга ияреп кыз атлый да атлый, аларның куллары бер-берсенә ябышкан диярсең. Менә шул чакта Нораның күзләре әнә шундый моңсу иде. Югыйсә, кайгырырга сәбәп тә юк иде бит. Барысы да сөйләшенгән, аңлашынган. Булат яңа елга кайтачак, кулына диплом алгач, яз көне аны үзе белән алып китәчәк. Барысы да вәгъдә белән беркетелгән иде түгелме соң?" Бу юллар татар укучысы инде яратып өлгергән язучы **Рауль Мирхәйдәров**ның "Җәй челләсе" дигән романыннан алынды. Илленче еллар башында Оренбург шәһәрендә очрашып вәгъдәләр алышкан Булат белән Нурия исемле чибәр кызның — Нораның язмышы алга таба ничек булыр? Соңыннан райком секретаре дәрәҗәсенә күтәрелгән Булат атлы егет мәхәббәтенә тугрылык саклый алырмы? Әллә түрәлек баскычлары буйлап югарырак үрләгән саен кешелек сыйфатлары башкалары белән алышынамы? Журналның алтынчы санында басыла башлаячак романында язучы кешелек дөньясын мәңге борчып килгән катлаулы әхлакый проблемаларны тыгыз сюжет линиясенә корылган мәхәббәт маҗараларына төреп тасвирлый, уйлана, борчыла.

Журналның бу санында шулай ук язучы **Камил Кәримов**ның "Мин әнигә бик кирәк" исемле яңа хикәясе, шагыйрьләр **Лена Шагыйрьҗан, Шәүкәт Гаделша, Бикә Рәхимова** шигырьләре белән танышырга мөмкин булачак.

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге тулы хокуклы вәкиле **Назиф Мириханов** журнал укучыларга "Хезмәт тәме яки шәҗәрә җебенең унсигезенче төене" дип исемләнгән күләмле хезмәтен тәкъдим итә. Ул татар морзалары һәм гомумән халкыбыз тарихы белән кызыксынучыларны яңача фикерләве, фактик материалның байлыгы белән җәлеп итәр.

Журнал битләрендә әдәби тәнкыйть, публицистика, фән һәм сәнгать мәсьәләләренә дә урын муллан бирелә, "Татар энциклопедиясе битләреннән", "Миллият сүзлеге", "Латинча уку күнекмәләре" кебек сәхифәләр дә кызыксынучан һәм тынгысыз укучыга бай мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итәр.

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Муса Җәлилнең туууына 80 ел тулу уңаеннан үткәрелгән тантаналы җыелыштан күренеш. Мәскәү, Колонналы Зал, 1986 ел.*



*Спасс районының Көек авылында Абдулла Алишка куелган һәйкәл-бюст. 2003 ел.*



*Язучы Самат Шакир һәм Брест крепостен саклаучы легендар герой Петр Гаврилов. 60 еллар.*



*Ватан сугышында катнашкан бер төркем язучылар. Егерме биш ел элек алынган фото. Беренче рәттә (сулдан уңга): Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Афзал Шамов, Госман Бакир, Гомәр Бәширов, Гариф Галиев; икенче рәттә—Атилла Расих, Мөхәммәт Садри, Геннадий Паушкин, Сафа Сабиров, Юрий Белостоцкий, Тихон Журавлев, Шәйхи Маннур; өченче рәттә—Мәхмүт Хөсәен, Сәет Шәкуров, Мәгъсум Насыйбуллин, Габдулла Шәрәфи, Нәби Дәүли, Мәҗит Рафиков, Габдулла Шамуков, Кави Латыйп, Әхмәт Исхак. 1980 ел.*



*Үткән гасырның 70-80 елларында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшләгән фронтовик шагыйрь Зәки Нури. 1975 ел.*



*Фронтовик язучы Мәгъсум Насыйбуллинны туган авылында каршылау. 2000 ел.*

## ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2005 елның икенче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, ярты елга язылу бәясе **132 сум**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары

### М.Ш. ШӘЙМИЕВКӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына М.Ш. Шәймиев кандидатурасы турындагы тәкъдимен карап, "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенен закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 5 статьясындагы 3 пунктының "а" пунктчасы һәм 18 статьясы, Татарстан Республикасы Конституциясенен 75 статьясындагы 16[1] пункты, 91[1] статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар бирә:

**Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен бирергә.**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
**Ф. Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2005 елның 25 марты

### ВАЗЫЙФА БАШКАРУ ДӘВАМ ИТӘ

2005 елның 25 мартында Зур концерт залында Президент Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең яңа срокка яңадән үз вазыйфасына керешү тантанасы булды. Ә тантанага кадәр Дәүләт Советы сессиясе утырышында депутатлар аңа күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен тапшырды.

Дәүләт Советы сессиясенең бу истәлекле утырышында РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле С. Кириенко, РФ Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары О. Морозов, Премьер-министр Р. Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Татарстаннан сайланган РФ Дәүләт Думасы депутатлары һәм Федерация Советы әгъзалары, халык депутатларының жирле Советлары һәм жирле үзидарә органнары вәкилләре катнашты.

С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залындагы тантанада М. Шәймиев Татарстан Конституциясе нигезендә татар һәм рус телләрендә ант бирде.

РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле С. Кириенко әлеге тантанадагы чыгышында: "Минтимер Шәрипович Шәймиевнең Президент булып сайлануы Татарстан Республикасы өчен генә түгел, Россия өчен дә бик кирәк. Татарстан икътисади һәм социаль үсеш өлкәсендә дә, инвестицияләрне үзенә жәлеп итү буенча да лидер булып тора. Бу—республикада житәкчелекнең барлык тармакларда да оешкан төстә эшләве нәтижәсе",—диде. Ул Президентка символик бүләк—яшь алмагач үсентесе алып килгән иде. "Алма ашыйсың килсә, алмагач үстер", дигән мәкальне татарча әйтеп, С. Кириенко: "Сезгә бу агачның алмаларын Президент буларак жыярга насыйп итсен. Селекционерлар мина, алмагач тагын дүрт ел вакыт узып бишенчегә киткәч уңыш бирә башлаячак, дип аңлатты",—диде.

Тантанада шулай ук РФ Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары О. Морозов, Түбән Кама "Нефтехим" акционерлар жәмгыяте генераль директоры В. Бусыгин, Бөгелмә шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы Н. Мәһдиев, Казан дәүләт технология университеты аспиранты М. Гәрәева, КамАЗ акционерлар жәмгыяте генераль директоры С. Когогин, Дәүләт Советы депутаты, драматург Т. Миңнуллин Президент М. Шәймиев исеменә котлау сүзләре белән чыкты.

### "МӘХӘББӘТ КҮПЕРЕ" ТОТАШТЫРДЫ

14 март көнне Мәскәүнең "Россия" Дәүләт концерт залында Казанның меңьеллыгына багышланган "Мәхәббәт күпере" дип аталган бәйрәм концерты узды. Анда Татарстан һәм Мәскәүнең танылган сәнгать осталары катнашты. Кунакларны сәламләп, Мәскәү мэрының беренче урынбасары Л. Швецова Казанда август аенда Мәскәү көннәре узачагы турында хәбәр итте.

Казан мэры К. Исхаков Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең мәскәүлеләргә сәламен һәм тирән рәхмәтен җиткергәннән соң, Россиянең икътисадый, фәнни һәм мәдәни үзәге булган Мәскәү һәм Казан шәһәрләрен борынгы университетлары, бай мәдәни тормыш, яңа инновацион программалар туганлаштырып торуын билгеләп үтте. "Бүген "Мәхәббәт күпере" йөрәкләребезне бергә тоташтыра, без Мәскәүдә яшәүче татарларның бай мәдәни тормышта яшәүләрен күреп сөенәбез. Әлеге ике борынгы шәһәр бер-берләреннән күп нәрсәләргә өйрәнә ала. Мәскәү Казаныбызның меңьеллыгын бәйрәм итүгә әзерлек чараларында актив катнашып, борынгы урамнарыбызның берсе—Мәскәү урамын төзекләндерү эшенә кереште",—диде К. Исхаков.

Бәйрәм кичендә сәхнәгә Россия Зур театры оркестры (дирижеры Ф. Мансуров), Россиянең халык артисты С. Шәкуров, Россия һәм Татарстанның халык артисты Р. Ибраһимов, Россиянең атказанган артисты Н. Фәтехова, Татарстан һәм Башкортстанның халык артисты И. Газиев һәм башкалар чыкты. Россия эстрадасының танылган төркемнәре—"Премьер-министр", "На-на" һәм "Дюна" Казанны юбилее белән котладылар.

Кунаклар арасында Татарстан Республикасының РФдәге Вәкаләтле вәкиле Н. Мириханов, Мәскәү шәһәр Думасы рәисе В. Платонов, Мәскәү шәһәре татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Р. Акчурин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров бар иде.

### ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА КҮРГӘЗМӘ

РФ Дәүләт Думасында "Меңьеллык Казан" дигән фотокүргәзмә ачылды. Әлеге чараны оештыручылар—ТР "Татмедиа" агентлыгы һәм "Дәвер портреты" төбәк фестиваль-фотоконкурсын оештыру комитеты.

Күргәзмәне ачу тантанасында Россия парламенты вице-спикеры О. Морозов, "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры М. Моратов, Дәүләт Думасының Мәгълүмат сәясәте комитеты рәисе В. Комиссаров, ТРның РФдәге Вәкаләтле вәкиле урынбасары А. Фәйзуллин, Татарстаннан Россия Дәүләт Думасы депутатлары—Ф. Гайнуллина, А. Хәйруллин, Ә. Мөхәммәтзакиров, И. Гыйльметдинов катнашты.

"Казан—Россиянең барлык шәһәрләре арасында кабатланмас җәүһәр кебек. Бу шәһәр гаять күп мәдәниятләр, башлыча татар һәм рус мәдәниятләренең уртак чагылышын гәүдәләндерә. Ә бу күргәзмә башкалабызның искитмәле гүзәллегенә соклану мөмкинлеген бирә",—диде О. Морозов үзенең чыгышында.

М. Моратов күргәзмә оештыру мөмкинлеге биргән өчен РФ Дәүләт Думасы җитәкчелегенә, шулай ук республикабыз исеменнән эш итүче депутатларга рәхмәт белдерде.

"Меңнәрчә ел дәвамында бер-беребез янәшәсендә яшәү тәҗрибәсе—Россия Федерациясе территориясендә гомер итүче барлык тугандаш халыкларның милли горурлыгы. Башкалабыз юбилее—Бөтенроссия юбилее бит ул",—диде М. Моратов.

### ПИТЕРДА КАЗАН БӘЙРӘМЕ

Санкт-Петербургның Д. Шостакович исемендәге филармониясенең Зур залында Казанның 1000 еллыгына багышланган "Санкт-Петербургның камера оркестрлары" дип аталган IV халыкара фестиваль узды.

Фестивальдә Санкт-Петербург филармониясенең академик симфоник оркестры, Татарстанның танылган музыка коллективлары, башка илләрдән килгән сәнгать осталары катнашты.

Фестиваль адресына Татарстан Президенты М. Шәймиев сәламләү телеграммасы юллады. "Татарстан Республикасы һәм Санкт-Петербург арасында халыкларыбызны рухи баетырга булыша һәм күптәннән дәвам итә торган мәдәни элемтәләр яши. Фестивальдә петербурглыларны һәм Төньяк башкала кунакларын республикабызның бай традицияләре һәм заманча музыкаль-мәдәни казанышлары белән таныштыручы талантлы коллективлары һәм башкаручылары катнашуына чын күңелдән сөенәм", диелә телеграммада.

### КАЗАН ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ—МӘСКӘҮДӘ

Россия башкаласында Казанның меңьеллыгына багышланган бәйрәм чаралары дәвам итә. Шуның чираттагысы: Третьяков галереясе залларында ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее экспонатлары урын алды.

ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева сүзләренә караганда, әлеге күргәзмә ачылу—Россиядә, шулай ук якын һәм чит илләрдә юбилей уңаеннан бара торган чараларның иң күренеклеләреннән берсе.

З. Вәлиева күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең котлау сәламен җиткерде. "Россиянең алтын картасы" кысаларында оештырылган бу вакыйга Татарстанның илебез тарихында, аның мәдәнияте үсешендә кыйммәтле сәнгать җәүһәрләренә сакчыл карауда Татарстанның әһәмиятле ролен ассызыклый. Күргәзмә Россия сәнгать мирасын өйрәнүгә һәм саклауга зур өлеш кертер дип ышанам",—диелгән Президент котлавында.

### КУНАКЛАР ЧАКЫРЫЛА БАШЛАДЫ

Казанның 1000 еллыгына санаулы көннәр калып килә. Бәйрәмгә Татарстан хөкүмәте билгеләгән квота буенча дөньяның төрле кыйтгаларыннан 1000 милләттәшебез киләчәк. Бүгенге көндә аларга чакырулар җибәрелә. БДБ һәм Балтыйк буе илләрендәге татарларга виза һәм юл чыгымнарын федераль үзәк каплаячак.

### МӘГАРИФ МУЗЕЕ

Балык Бистәсе—рухи хәзинәләребезне баетуга шактый зур өлеш керткән язучылар, артистлар, композиторлар, гомумән, сәнгать кешеләре туып-үскән як. Димәк, тәрбия-укыту өлкәсендә тарихи тәҗрибә зур. Шуңа күрә Балык Бистәсе районы үзәгендә Мәгариф музее ачылу табигый хәл. Ул—балалар иҗат үзәге бинасында ачылды. Музейны ачу тантанасында район советы сессиясенә килгән Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады. Тантанада шулай ук Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Балык Бистәсе якташлык җәмгыяте рәисе Илсур Хадиуллин, район администрациясе башлыгы Равил Хәйруллин һәм башкалар бар иде.

### ТЕАТРДА БӘЙРӘМ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында (Халыкара театр көне уңаеннан) "Сәйяр" труппасында хезмәт юлларын башлап җибәргән Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Вәлиулла Мортазин-Иманский, Фәхерниса Сәмитова, Нури Сакаев кебек артистларны искә алу булып узды. Аларның иҗаты белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова таныштырды. Аннан соң драматурглар Туфан Миңнуллин белән Рабит Батулла төзегән "Сәхнә ул—могҗиза" дигән, щепкинчыларга багышланган китап тәкъдир ителде. Артистлар үзләре турындагы әлеге җыентыкны киләчәктә Башкортстанда "Нур" театрында эшләячәк яшьләргә бүләк иттеләр. Әлегә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында белем алучы бу студентлар Н. Исәнбәтнең "Гөлҗамал" спектакленнән бер өзек әзерләгәннәр иде. Бу кичәдә шулай ук "Яңа татар пьесасы" конкурсы җиңүчеләре дә мәгълүм булды. Лауреатлар: Зөһрә Фатыйхова, Раилә Мөхсинова, Дилә Мөхәррәмова, Равил Сабыр, Илгиз Зәйниевкә акчалата бүләкләр тапшырылды. Конкурсның икенче турына үткән катнашучыларга да бүләк белән дипломант исемнәре бирелде. М. Галәүнең "Болганчык еллар. Мөһаҗирләр" әсәре буенча сәхнәләштереп язылганнар арасында иң яхшысы дип артистлар Илтөзәр Мөхәммәтгалиев белән Фәнәвил Галиев инсценировкалары табылды.

### ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

Чаллы дәүләт педагогия институтында "Укыту-тәрбия процессын милли төбәк компонентын исәпкә алып оештыру" дигән региональ фәнни-гамәли конференция булып узды. Татарстан Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы халыкларының телләрен үстерү бүлеге һәм Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы белгечләре белән берлектә оештырылган бу форумда Казан, Чаллы, Алабуга, Түбән Кама вузлары һәм педучилище вәкилләре, мәктәп укытучылары алдында институт ректоры Г.Р. Әгъләмова котлау сүзе белән чыкты. Анда шулай ук Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Хатыйп Миңнегулов, Флүн Мусин, Наил Лаисов, Әнвәр Шәриповлар да катнашты, алар бүгенге шартларда татар телен һәм әдәбиятын укытуның актуаль мәсьәләләре турында докладлар белән чыгыш ясадылар. Ул чыгышларда, аерым алганда, әдәбиятны укыту программалары һәм дәреслекләрендәге унай һәм кимчелекле яклар анализланды, әдәби әсәрләрне бүгенге күзлектән чыгып ничек укытырга кирәклеге турында эшлекле киңәшләр бирелде. Конференция материалларын туплап аерым җыентык нәшер ителде.

### МОРЗАЛАР ҖЫЕНЫ

"Казан" милли мәдәният үзәгендә безнең өчен гадәти булмаганрак бер кичә булды. Бу кичәгә Татарстанның төрле шәһәрләрендә, тирә-як төбәкләрдә яшәүче 70 кеше—бүгенге көн морзалары, ягъни морзалар нәселеннән булган кешеләр чакырылган иде. Аларга нәкъ менә шул хакта—морзалар нәселеннән булуларын тәгаенләгән таныклык та тапшырылды. Россия дәүләт архивлары документларына, борынгы актларга, бояр кенәгәләренә теркәлгән документларга таянып эшләнгән бу таныклыкларны Татар морзалары мәҗлесе исеменнән шушы Мәҗлеснең геральдика комиссиясе әзерләгән. Шунысын да әйтик, таныклык алучылар арасында төрле һөнәр кешеләре—эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре, студентлар һәм укучы яшьләр, сәнгать әһелләре, дәүләт эшлеклеләре бар.

### БҮЛӘКЛӘҮЛӘР

#### Урманче исемендәге

Бакый Урманче музеенда ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан булдырылган Урманче исемендәге премияне тапшыру тантанасы узды.

Быел бу премиягә "Рәсем сәнгате" номинациясендә иң яхшы дип табыл-

ган ТР Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин лаек булды. Жюри "Графика" номинациясендә Анатолий Егоров эшләрен иң яхшысы дип тапты, ә "Декоратив-гамәли сәнгать" номинациясендә Надир Әлмиев һәм Ирина Колмагорцева җиңүчеләр дип аталдылар. Моннан тыш, рәссамнар Ренат Газиев, Земфира Бикташева, сәнгать белгечләре Йолдыз Нигъмәтуллина, Розалина Шаһиева, Рөстәм Шәмсутов, Лилия Саттарова һәм Роза Солтановалар махсус премияләр белән бүләкләнде.

### Һади Атласи исемендәге

Милли мәгърифәтне һәм татар халкының үзаңын үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен танылган шагыйрь, "Мәдәни Җомга" газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров "Мәгърифәтче" исеменә һәм Һади Атласи исемендәге премиягә лаек булды. Әлеге хөрмәтләү чарасын Бөгелмә шәһәрендә эшләп килүче Һ. Атласи хәйрия вакыфы гамәлгә куйган. Шагыйрь үзенә бирелгән бүләк акчасын туган авылы Түбән Ушмыда (Мамадыш районы) тарихи җамигъ мәчетен төзекләндерү фондына тапшырды.

### Илдар Юзеев исемендәге

"Мәйдан. Чаллы" әдәби-нәфис, иҗтимагый журналы Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев исемендәге премия булдырды.

Премия һәр елны журнал битләрендә дөнья күргән профессиональ осталыгы, яңалыгы һәм оригинальлеге белән аерылып торучы, үзенчәлекле автор стиленә ия әсәрләргә бирелә. Лауреатларга акчалата бүләк һәм диплом тапшырыла.

Журналның редакция советы 2004 ел өчен Илдар Юзеев исемендәге премияләрне әдәбият галиме Дания Заһидуллинага һәм язучы Марат Кәримовка бирергә дигән карар чыгарды.

### КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУ

"Казан утлары" журналында галим, төркиләр тарихына багышланган "Полынь половецкого поля", "Тюрки и мир: сокровенная история", "Европа. Тюрки. Великая степь", "Кипчаки" исемле китаплар авторы Мурад Аджи (Морад Искәндәр улы Хажи) белән очрашу булды. Мәшһүр галимнең төркиләрнең дөнья цивилизациясендә тоткан урыны, тарих фәнендәге стереотиплар, үткәндәге бөек шәхесләрнең асыл гамәлләре һәм башкалар турындагы фикерләре тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Язучылар һәм "Ватаным Татарстан", "Татарстан", "Сөембикә" газета-журналлары хезмәткәрләре катнашкан бу очрашуны "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин алып барды.

### УРДА ШАГЫЙРЬЛӘРЕ РУСЧА "СӨЙЛӘШӘ"

Мәскәүнең "Наталис" нәшрияты поэзия сөючеләргә быел зур бүләк ясады. Ул Лондонда яшәп иҗат итүче мәшһүр якташыбыз, шагыйрь, драматург, публицист һәм галим, Татарстанның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Равил Бохараевның яна саллы хезмәтен бастырып чыгарды. "Поэзия Золотой Орды" дигән бу китапта Харәзми, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи кебек мәшһүр Алтын Урда шагыйрьләренең поэмалары, газәлләре, мәдхия вә дастаннары рус теленә тәрҗемә итеп бирелгән.

Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында әлеге китапны тәкъдир итү кичәсе булды. Анда катнашучы язучылар, галимнәр, журналистлар Равил Бохараевның бу хезмәтен югары бәяләделәр, аның борынгы төрки-татар поэзиясе җәүһәрләрен русчага зур осталык белән тәрҗемә итүен билгеләп үттеләр.


2005 елның 17 февралендә күренекле язучы, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре **Шамил Җиһанша** улы **Рәкыйпов** 76 нчы яшендә вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкнын беренче битендә:* Казан. Җиңү паркы. ***Н. Исмәгыйлев** фотосы.*

*Тышлыкнын дүртенче битендә:* драматург **Рәдиф Сәгъди**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Камил Кәримов. **Сакау күке.** Роман һәм повесть.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—304 б. Тиражы—3000 данә.

Язучы Камил Кәримовнең беренче зур әсәре—“Ком сәгате” романы моннан биш ел элек журналыбызда дөнья күргән иде. Монарчы сатирик, юморист, эстрада остасы булып танылган язучыны бу романнан соң әдәбият сөючеләр житди прозаик итеп кабул иттеләр. “Сакау күке”—әлеге беренче романның дәвамы рәвешендә язылган. Әсәрдә артезиан чишмәләр бораулап йөрүче өч егетнең гыйбрәтле язмышы сурәтләнә. К. Кәримов иҗатына хас нечкә юмор, жор тел, образлы фикерләү бу романда да матур чагылыш тапкан. Китапта, шулай ук, авторның элегрәк язган “Ак бүрек” повесте да урын алган.

Мөхәррире—Ф.Хафизов, рәссамы—Г. Хисмәтуллина.




Тәлгат Нәҗмиев. **Тагын... тагын... Саба мәзәкләре.**—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—416 б. Тиражы—5000 данә.

Танылган журналист, язучы Тәлгат Нәҗмиевнең Саба ягы кешеләре тормышында булган уен-көлке хәлләр турында сөйләүче өченче китап бу. Эчтәлек-мәгънәләренә карап, автор мәзәкләрне сигез төркемгә бүлеп биргән (“Көлке түрәләргә дә ярый”, “Өеңдәге—тышыңда”, “Исәнлеккә—саулыкка”, “Мәзәккә—хөрмәт” һ. б.). Китап Туфан Миңнуллинның “Көлке көлә килә” дип исемләнгән кыска гына кереш сүзе белән ачыла. “Тәлгат Нәҗми хикмәтле хәлләрне, кызыклы кешеләрне зәвык белән бәян итә, көлеп-шаярып туган-яшәгән төбәгенең Саба якларының тарихын яза, энциклопедиясен төзи” диелә анда.

Мөхәррире—Р. Корбанов, рәссамы—Р. Абзалов.

Индекс 73210



Рәдиф Сәгъди

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)